ISSN 0206—4189



# Казан утлары

10.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**1987**

## *Бу санда*

Ш. ГАЛИЕВ. **Төрле еллар дәфтәреннән.** *Шигырьләр* . . . . . . 3
З. ЗӘЙНУЛЛИН. **Үрләр аша.** *Повесть* . . . 7
З. МАНСУРОВ. **Балкыш.** *Поэма* . . . . . . 45
Ә. МУШИНСКИЙ. **Ак Бүре.** *Повесть* . . . 52
А. МИФТАХЕТДИНОВ. **Кыз урлаучы.** *Хикәя* . . . . . . 95
Г. САДӘ. **Җиргә якты күбрәк төшсен.** *Шигырьләр* . . . . . . 105

КОЯШ ТИМБИКОВАГА 50 ЯШЬ

Ф. ХУҖИӘХМӘТОВА. **Яшьлек дәвам итә** . . 107
К. ТИМБИКОВА. **Ник сагынам икән?..** . . 108

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Н. МОРОЗОВ. **Тау сыртларын кисеп** . . . . 121

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

М. П. ВИНОГРАДОВ. **Үсеш юлыннан** *(Балык Бистәсе районы)* . . . . . . 128

Д. ГЫЙСМЕТДИНОВ. **Польшага — дуслык күпере** . . . . . . 131
А. ГАФИЯТОВ. **Алисә — дөнья чемпионы** . . 135

ҖАМАЛ ВӘЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Фидакарьләр фидакарьлек көтә** . . . . . . 139
Җ. ВӘЛИДИ. **Яшь йөрәкләр. Шигырьләр тирәсендә. Татар шагыйрьләре** . . . . . . 143

БИБЛИОГРАФИЯ

М. БАКИРОВ. **Заман күзлегеннән карап** . . 153
Г. САБИРҖАНОВ. **Мәдәниятыбыз тарихы сәхифәләре** . . . . . . 156

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

З. МӨХӘММӘТҖАНОВА. **Дәрмәнд йорты** . . . . . . 160
Җ. МИҢНУЛЛИН. **Шигъриятебез шоңкары** . . . . . . 161

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Ж. ВӘҖИЕВА. Остазыбыз иде... . . . . . . 162

ӘДӘБИ МИРАС

Габдрахман Әпсәләмов хатлары . . . . . 164

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Ф. ЯХИН. Кояш чыкты, нур балыкты... . . . 176

СӘНГАТЬ

Г. МӘҖИТОВА. Туплар атса да, музалар тынмады . . . . . . . . . . . . 179

Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . 183
Т. РАМАЗАНОВ. Эшчеме, галимме? . . . . 186
Китаплар дөньясында . . . . . . . . . 187
Культура тормышы көндәлеге . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФӘҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Повесть З. ЗАИНУЛЛИНА «Через кручи», повесть А. МУШИНСКОГО «Белый Волк», рассказ А. МИФТАХЕТДИНОВА «Аттаукай». Поэма З. МАНСУРОВА «Сияние», стихи Ш. ГАЛЕЕВА, Г. САДЕ.
К 50-летию К. ТИМБИКОВОЙ — лирический очерк «Близкое далекое».
В рубрике «Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» статья Н. МОРОЗОВА о наших земляках, участвующих на строительстве Байкало-Амурской магистрали.
«Татарстан — родной мой край» — выступление первого секретаря Рыбно-Слободского райкома КПСС М. П. ВИНОГРАДОВА.
Статья Д. ГИСМЕТДИНОВА «Мост дружбы в Польше».
Очерк А. ГАФИЯТОВА о юной шахматистке, чемпионке мира Алисе Галлямовой.
К 100-летию Дж. Валиди: статья Р. МУХАМАДИЕВА и материалы из творческого наследия.
В номере рецензируются однотомное издание поэта XVIII—XIX веков Г. Утыз-Имяни и монография «Культурная революция в Татарии (1917—1937)». (М. БАКИРОВ; Г. САБИРЗЯНОВ).
«Памятники татарской культуры в Оренбурге»: дом Дэрдменда. Воспоминания ДЖ. ВАЗИЕВОЙ о Г. Нигъмати.
Неопубликованные письма Габдрахмана Абсалямова.
«К истории культуры» — статья о становлении татарской демократической печати в Уральске в 1905—07 гг.
В рубрике «Искусство» статья Г. МАЗИТОВОЙ о культурной жизни в Татарии в годы Великой Отечественной войны.
Письма читателей.
В мире книг.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках — народные ювелирные изделия из серебра и памятник А. М. Горькому в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 28.07.1987 ел. Басарга кул куелды 25.09.1987 ел. ПФ 05355. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 66849. Заказ М-344. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

## Шәүкәт Галиев

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

### Күпкә китсә...

Күпкә китсә, сүзнең кадере калмый,
Күп сүз — юк сүз, бетә бәясе.
Әйткән сүзләр аткан уктай булсын,
Киерелсен мәгънә җәясе.

Инфляция булмас борын, әйдә,
Бу хакта без болай киңәшик:
Сүздән эшкә күчик һәм сүзләргә
Экономия өчен көрәшик!

1969

### Ятим бер сүз йөри...

Чит телләрнең кара урманында
Адашканга түзем, көч телим,
Тавыш бирде бүген бер ятим сүз,
Нәрсә әйтмәк була — Усть Илим?

Бәргәләнә микән: онытылдык,
Мин ялгызым калдым, иш телим!
Аваздашлар инде күптән тынган,
Таныш аһәң көтмә, Усть Илим...

Мин аңларга сине бик тырышам,
Нинди хикмәт, сер син, Усть Илим —
Бар җиһанга сөрән саласыңмы,
Монда диеп, минем үз илем?

Ятим бер сүз йөри сукбай сыман,
Ни аңлатмак була Усть Илим?
Халкымнан син аерылмасаң иде,
Адашмасаң иде, үз телем!

1983

---

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ *(1928) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән күп санлы лирика, сатира-юмор һәм балалар өчен шигырь китаплары авторы. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Ул шулай ук Г.-Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы дипломга лаек булды. Казанда яши.*

*

Берни булмый чуенга ут тигәннән,
Күмер кала андый утта имәннән...
Ә диңгездә ул корычка охшый ди!
Чуен исә израп төшә, йомшый ди.

Шундый бер уй тырнап узды күңелдән:
«Кемнең кайда сынатасын кем белгән...»
Авырлыкны җиңгән кеше кайчакта
Бирешә дә куя тәмам җай чакта...

1963

*

Асфальтны тишкән үсенте
Юлда очрады исә,
Сокланып туктап калабыз:
«Яшәү көче зур бит, ә!»

Гайре табигый бу хәлләр
Булмауга соң ни җитә —
Үсәргә дигән гомерләр
Асфальтлар тишеп үтә...

1974

## Елдам...

Электән үк
Әләкләгән —
Кемнәр генә
Әләкмәгән...

Ни кыланмас
Бала-чага...

Инде — олы,
Әмма — чага!

Елгыр кеше,
Елдам кеше,
Ә бит эше —
Елан эше...

1969

## Календарь бүләк иткәндә

Ил алдында бурычың бер,
Ватан кушкан урының;
Юллары төрле якларда
Татарстан улының.

Төрле кыйтгада төрлечә
Чыга да байый кояш...
Кайсы улың кайсы көндә
Изге сагыну тоймас?

Ностальгия белән авырый
Һәрбер рухы сәламәт...
Ерактагы уларыңа,
Туган җирем, сәлам әйт.

Һай, белмисездер, чит җирдә
Кылдай тартыла хисең...
Татарча календарь сорый
Төрле яктан дус-ишең.

Казан вакытын күрә дә,
Казан кояшын таный —
Баеган сәгатен түгел,
Чыккан сәгатен карый!

...Кайсы елгы календарь һәм
Кемнән килгән булса да,
Язмыш кая ташласа да
Кайтыр көннәрне сана!

1970

## Кәсеп

Халтура
Лаф ора:
— Ант! Урра!
— Ант! Урра!

Чакыра,
Акыра,
Бакыра —
Колакны
Тондыра.
...Ул шулай
Тамагын
Туйдыра!

1969

❀

Уйлап баксаң, кеше тозлы бит ул:
Эшләгәндә чыккан тир тозлы,
Җылаганда тамган яше тозлы,
Ярасыннан аккан кан тозлы...

Кәеф-сафа корып яшәсә гел,
Төчеләнеп читтә торса ул,
Кешелеген саклый алмас иде —
Бозылыр иде тозсыз булса ул!..

1973

## Сабыйга

Ирнеңдәге сөт тамчысы кебек
Пакь әле син, сабый.
Бу йортта иң сафы —
Намуслы,
Тәүфыйклы,
Инсафлы.

Ят әле сиңа
Яклашу,
Белмисең
Яраклашуны.
Азат син
Мәкердән,
Икейөзлелектән,
Мәгънәсез үзсүзлелектән...

Син әле саф, сабый,
Тыныч ят,
Бишегеңне тарсынма.
Берзаманны өйрәтерләр
Тәпи йөрергә,
Сөйләшергә,
Барсына, барсына:

Өйрәтерләр
Ялгыш юлдан йөрергә,
Ялган сөйләргә,
Эчәргә-тартырга,
Үз җаеңны көйләргә...

Өйрәтерләр,
Үзләре кебек итәрләр,
Аннары
Искелек калдыгы дип орышырлар,
Үзләре бозыклар киңәш бирерләр,
Төзәтергә тырышырлар.

Алай да шүрләмә,
Арын биләүләрдән,
Тор син бишектән,
Зур дөньяга чык
Төбенәчә ачып
Тар ишектән!

Син әле саф, сабый,
Әшәкелек күреп дөньяны тарсынма,
Өйрәтә алырсың барсын да —
Сафлыкка,
Намуска,
Хаклыкка —
Яхшылыкларның барсына, барсына!

1966

❁

Юл газаплы булды, читен булды,
Узган авырлыкны киметмик —
Җиңү яулаганнар батырлыгын
Ихтыярсыз шулай кимсетмик...

Дәвам итүчеләр тынычланып,
Күтмәсен гел алда такырны —
Авырлыклар җиңеп бару гына
Көчле иткән һәрчак батырны.

*1962*

❁

Уянып күз салсам, бүлмәм якты —
Кай арада әле таң аткан?
Баксаң, дөньяларны иркенәйтеп
Күткән шатлык булып кар яткан!

Ярый әле алмашынып тора
Декорация — елның фасылы.
Күңелләр бит гел үзгәреш көтә,
Яңарышта тормыш асылы!

*1967*

❁

Юаш идем, кызык өчен
Үртәп елаталар иде;
Кыюсызлык хак сүзне дә
Әйттермичә тыеп килде.

Бүтәннәрне рәнҗеткәнне
Тыныч карап узалмадым —
Хакыйкатьне әрсезләрдән
Яклар өчен усалландым!

1970

## Синхрофазотрон караганда

(ДУБНО ИСТӘЛЕГЕ)

Атом серен ача торган җир бу,
Тантаналы, серле, шомлы да.
Мин сагаеп атлыйм һәр адымны,
Як-ягыма карыйм шым гына.

Ышанычлы микән бу әкәмәт,
Диварлары нык.мы, тазамы —
Дулап-нитеп китә калса әгәр,
Шул могҗиза — атом казаны...

Ничек моны уйлап чыгарганнар,
Кемнәр тота моның тезгенен?
Кеше әнә әллә ниләр корган,
Берни кырмаганбыз без генә...

Бу яшь физик бездән — лириклардан
«Шигырьчеләр» диеп көлмиме?
Сөйләп авызына караткан га
Галимнән мин, ахры, көнлимен...

Без дуслашып киттек соңга таба,
Һәм уртак бер табын ясадык,
Физиклар да, лириклар да бергә
Тату гына кыяр ашадык.

Алар да нәкъ безнең ише икән,
Шаян сүзле икән, җор икән.
Атом казанының уртасында...
Чын күңелдән туган җыр икән!

1960

**Зәки Зәйнуллин**

# ҮРЛӘР АША

ПОВЕСТЬ

## I

Мең тугыз йөз кырык беренче елның август урталары. Көньяк Урал. Бу якларда киртләчләнеп төшкән таулар бетә һәм далалар башлана. Таулар белән далаларны тоташтырып аккан елгалар буенда — татар, башкорт, рус, чуваш, украин, латыш авылларында ирләрне сугышка озату бара. Һәркемнең телендә моңа хәтле ишетелмәгән ят сүз: гомуми мобилизация.

Зиреклебаш авылының кыйбла ягында урнашкан рус һәм татар мәктәпләре арасындагы мәйдан төрле телдә сөйләшүче халык белән тулы. Мәйданның урта бер җирендә чи каеннан әмәллап куелган трибуна кебегрәк нәрсә күренә. Аның янында татар мәктәбе завучы Сәлимгәрәев белән военком Маликов басып тора. Менә алар китәсе халыкны барлый башлыйлар. Исеме аталганнар, кайсысы киндер капчыгын, кайсысы фанер чемоданын күтәреп, сафка тезеләләр. Шау-шу, елау-сыктау басылды, киеренке тынлык урнаша. Тик кайбер хатыннар гына, яулыгы белән авызын каплаган килеш, сулкылдап куя.

Зиреклебаштан бүген сугышка утыз белән утыз биш арасындагы унсигез ир китә. Күбесе гомер буе җир сөреп, иген игеп, мал карап, кара эш белән дөнья көткән халык. Өйдә һәркайсының вактан-вак өч-дүрт баласы, чәчәкле алъяпкыч кигән хатыны кала. Китәсе ирләрнең байтагы сугышка хәтле авылдан чыкмаган, армия хезмәтен үтәмәгән, җирдән аерылмыйча яшәгән халык. Күбесе киң күкрәкле, тыгыз тәнле, көрәктәй зур куллы, тәүлек буе туктамыйча эшли ала торган тазасау кешеләр.

Гарасат башланган көннәрдә: сугыш безгә бер айлык ул, немец пролетарлары безгә каршы сугышмаячак, барысы да әсир төшеп бетәчәк дип, трибуналардан чыгып сөйләүчеләр хәзер бетте. Июнь азакларында чыгып киткәннәрнең хатлары килгәнгә дә байтак вакытлар үтте. Ул хатларда, тиздән кайтырбыз, дигән сүзләр юк иде. Киресенчә, кайта алмасак, бәхил булыгыз, бала-чагаларны исән-сау үстерергә тырышыгыз дип яздылар. Аннан тыш, клуб башына эленгән кара тәлинкәдән хәвефле хәбәрләр ишетелеп кенә тора.

---

ЗӘКИ ЗӘЙНУЛЛИН *(1933) — полковник, техник фәннәр докторы. Рига шәһәрендә яши.*

Үткән герман сугышында өч елдан артык окопта аунаган, күп тапкырлар кул сугышында катнашып, шуларның берсендә немецларның кырлы штыгыннан ике иренен ярдырган Гобәйдулла Пәрәү фронтка китәсе һәр төркем ир-ат белән сөйләшми калмый. Беренчеләрне озаткан көнне үк кичен аның йортына милиция башлыгы килеп керде.

— Син, Гобәйдулла абзый, дошманның кул сугышына шәплеген халыкка гел сөйлисең икән. Мин, как начальник милиция, сиңа андый паникалы сүзләр таратуны заприщать итәм...

Аның сүзе бетүен дә көтмичә, Гобәй Пәрәү болай диде:

— Син, энем, миңа бәйләнмә! Күзең күрәдер, кара минем иреннәрне! Күрдеңме? Немец штыгыннан, кул сугышында алган яра ул минем. Монысы бер. Икенчедән, сугышка кеше бәлки кайтмаска китәдер ул. Барганда ук сабан туена бармаганын белеп барсын. Бу сугыш бер айлык түгел ул, менә хәтерләрсең Гобәй Пәрәү әйткәние диеп. Безнең егетләр ил сакларга, үлем белән алышырга китә. Белеп барсыннар сугышның каты булачагын, анда барып, немецның плин төшкәнен көтеп йөрмәсеннәр, ныклап торып сугышсыннар.

Бүтән вакытта сүзне коры һәм кыска тотарга яратучы милиция башлыгы Гобәйдуллага сүзсез генә кулын бирде дә капкага юнәлде. Шуның белән аерылыштылар. Шул сөйләшүдән соң Гобәй Пәрәү киткән һәрбер авылдашына сугышның каты булачагын тукыды, агач таяк тотып, мылтык уенын күрсәтте. Бераз төшереп алган ирләр аның сөйләгәнен, күрсәткән алымнарын кызык итеп кенә кабул иттеләр. Сугыш афәтләре алардан ерак иде әле.

...Сәгатьтән артык вакыт үтмәде, мәйданга җыелган халыкны барлап, тезеп чыктылар. Китәселәргә мөрәҗәгать итеп берничә кеше чыгып сөйләде. Инде сөйләүчеләр бетте дигәндә, чи каеннан әмәлләп куелган трибунадагы Сәлимгәрәевкә авылның иң шәп балта остасы, илле яшьләр тирәсендәге Басыйр Торна дәште.

— Карале, энем Сәлимгәрәев,— диде ул, кысылып алга үтә-үтә.— Миңа да китәсе егетләргә бер-ике сүз әйтергә ие бит, рөхсәт булса.

— Әйдә, әйдә, Басыйр абзый, рәхим ит! Күтәрел монда,— диде аңа Сәлимгәрәев.

Басыйр Торна өскә күтәрелде, анда басып торганнарның алдына үтте. Колаксыз бүреген салып, аның эчендәге үзбәк түбәтәен башына киде, халыкка карады. Мәйдан да аңа төбәлгән килеш тынып калды.

Матур кеше иде Басыйр Торна. Матур булса да, мәдрәсәдә укыганда Торна исеме алып, шуны гомер буе йөртте. Артыннан үсеп килгән энеләре Җаббар белән Газиз дә Торна булдылар. Басыйр малай чактан ук төрле кош-корт, мал-туар тавышына охшатып кычкырырга бик оста иде. Шулар арасында иң яратканы торна тавышы булып, малай аны аеруча оста итеп башкарды. Тик уку ягына гына әллә ни исе китмәде. Бер кышны, сабагын әзерләп килмәгәне өчен, Фәхри хәлфә аны идәнгә сузып салып суктырды.

— Юньсез нәрсә! Һәфтияк уку сиңа торна булып кычкыру түгел ул! Аңа баш кирәк, баш! Башсыз торна! — дип җикеренде.

Шул көннән Басыйрны малайлар Башсыз Торна дип йөртә башладылар. Әмма тора-бара «башсыз» сүзе онытылды, Торнасы гына калды. Шул көенчә ул үсеп җитте, ир булды, Торна килеш илленең теге ягына чыкты.

Менә шул гомере буе балта белән эш иткән Басыйр Торна Сәлимгәрәевтән сүз сорады. Сөйләгәндә колаксыз бүреген киндер алъяпкычы астына бер тыкты, бер чыгарды. Китәсе кешеләр дә, каласылар да аның сүзен тын да алмыйча тыңладылар.

— Егетләр! — дип эндәште Басыйр авылдашларына.— Сез бүген фронтка чыгып китәсез. Сугышның нәрсә икәнен белми идегез моңарчы. Мин елдан артык германга каршы сугышкан солдатмын. Минем сезгә әйтәсе бер сүзем бар: сез нимеснең Рур дигән өлкәсен тизрәк алырга

тырышыгыз. Шунда инде аның тимер шахталары, чуен коя торган заводлары. Шул Рур өлкәсен алсагыз, Басыйр абзый әйткәнне диярсез, сугыш тизрәк бетәр. Шушы нәрсәне исегездән чыгармагыз, егетләр! Ул халыктан җиңдермәгез! Алар җиңсә, без беттек дигән сүз!..

Көндезге берләр тирәсендә китүчеләр төялгән олаулар кузгалды. Елау-сыктау, кычкыру, хушлашу-саубуллашу авазларына килеп кушылган көпчәк шыгырдаулары күңелләргә шом салды. Арбалар яныннан, артта калмаска тырышып, елап шешенгән хатын-кыз, бала-чага йөгерә. Мөтәч Хәмитенең Бикәсе дә, корама юрганга төрелгән имчәк баласын күкрәгенә кыскан килеш арба янәшәсеннән атлый, иренең чабаталы аякларын кочакламакчы була. Хәмите исә аякларын читкә ала. Бикәгә калырга куша, нәрсәдер кычкыра. Шау-шу аркасында хатыны исә аның сүзләрен ишетми, йөгерүен белә. Менә баланың юрганы чишелеп китә, Бикәнең ботларына уралып, барырга комачаулый. Ә хатын аны күрми, аның күзләре ирендә, абына-сөртенә атлый да атлый.

Менә дилбегә тотып утыручылар атларны ныграк куа башладылар. Ияргән халык кими төште, артта калды. Тик Хәмитнең җиде-сигез яшьлек улы Равил гына һаман йөгерә, калмаска тырыша. Әтисенең нәрсәдер әйтеп кул селтәгәнен дә, әнисенең арттан кычкырганын да ишетми. Янгын каланчасы яныннан сулга борылып, атлар кала юлына чыккач, Хәмит янәшәсендә утырган Папай Гинияте үксеп барган иптәшенең башыннан кепкасын алды да Равилга ыргытты.

— Тот, улым, атаңның кипкесен, төсе итеп киярсең!

Малай йөгергән җиреннән туктала биреп очкан кепканы тотмакчы булды. Тик кепка юл тузанына килеп төште. Ул аны күтәреп алганда арбалар инде, Хаҗи Карга йортын узып, кала юлы белән юырталар иде. Малай китеп барган атлы арбаларга карап бераз басып торды да, юл читендәге канауга тәгәрәп, җан өзгеч тавыш белән еларга тотынды.

## 2

Сәлимгәрәев олауларны авылдан ике чакрымда урнашкан Сыйраклы елгасына чаклы озата барды. Күпер төбенә җиткәч, арбадан төште дә китүчеләр белән саубуллаша башлады. Ирләр дә җавап итеп:

— Хуш, Сәлимгәрәев туган! Күрешмәсәк, бәхил бул! Туры килгәндә безнең семьяларга да күз-колак булгала инде, яме,— дигәнрәк сүзләр әйткәләделәр.

Пар атлар җигелгән үзенең арбаны күпер өстендә басып озатып калды укытучы. Бу минутта аңа авыр иде. Ирләрнең барысы да танышлар, балалары яңа гына мәктәпкә йөри башлаган халык. Укыган кешегә Зиреклебашта гомер-гомергә ихтирам белән карыйлар иде. Ничәмә еллар инде Сәлимгәрәев монда балалар укыта, үзенең сабыр холкы, эшчәнлеге, ярдәмчеллеге белән абруй казанды, халыкның күңелен яулады. Аны барысы да фамилиясе белән атап йөртәләр. Хатынлыкка да ул читтән килгән укытучы украин кызын алды. Сәлимгәрәевнең бу эшенә дә халыкның әллә ни исе китмәде. Укыган кеше бит, үзе беләдер инде диделәр дә бетерделәр. Хатынын да яраттылар. Аның Клавдиясе ире кебек гади иде, чатнатып татарча сөйләшә, мәҗлесләрдә сузып җырланган җырларга кушыла, тыпырдап «Әпипә»гә бии, авыл халкы белән аралаша белә.

Күпер өстендә бер ялгызы басып калды Сәлимгәрәев. Киткән ирләрнең күбесе мәңгелеккә чыгып киттеләр. Ә Сәлимгәрәев үзе кырык дүртенче елны Польшада, дошманның танк атакаларын кире какканда, һәлак булачак. Капитан дәрәҗәсендә. Төз гәүдәле, көләч йөзле, өч орденлы дивизион командирын Висла ярында җирләячәкләр. Ә хәзергә андый уй әле беркемнең дә башына килми...

Дүртенче, бишенче арбаларда барган Калиновка чувашлары бер җырладылар, бер еладылар. Николаевканы үткәч, арбаларга аркылы-торкылы ятып, тынычсыз йокыга чумдылар. Алар артындагы олауда Банковка латышлары килә иде. Болар зур гәүдәле, зур куллы, аз сүзле халык. Латышларның эшчәнлеге бөтен районга билгеле. Иң эре бәрәнге аларда үсә, кара борчак та аларда гына була. Сыерлары да иң күп сөт бирүче коба маллар. Җәй җитте исә, алар төнен су буйларында учак яга, ялкын аша сикереп уйный, Лиго дип аталган яфрак бәйрәме үткәрәләр. Калган арбаларда төрле авыллардан җыелган башкорт, рус, татар бара.

Икенче арбадагы Мөтәч Хәмитен тынычландыра алмый байтак азапландылар. Ул нык өзгәләнде, елады, ахыр чиктә Гыйниятка елышты.

— Эх, белмисез эчнең ничек янганнарын! — диде ул, күкрәгенә күрсәтеп.— Минем хатын балаларга катырак бит ул. Берүзе калды, хәзер нишли ала инде ул. Биш бала бит, биш бала! Әйтергә генә ансат. Бер генә малай бит, калганнары кызлар. Аларны бит үстерәсе бар, кияүгә бирәсе. Зурысына ун тулды, төпчеге ай ярымлык. Нишләр инде Бикәм, нишләпләр бетәр бу балалар белән... Үзем бит мин юньләп йөгерә дә алмыйм, аю табан... Сугышта анда гел йөгерергә ди бит... атакага барганда, пуля тимәсен өчен...

Гыйният Папай аны тынычландырырга тырышты:

— Ярар инде, Хәмит дус, тукта, кайгырма юкка. Бергәрәк эләгергә тырышырбыз. Минем яндарак йөрерсең. Егет чакта мин бөтен Югары очны дер селкетеп тордым. Сугышта да югалып калмабыз дип уйлыйм. Нимес дигәннәре Югары оч егетләреннән дә елгыррак түгелдер, шәт, аңа да көч җитәр. Әмма бик каты булыр дип уйлыйм мин бу сугышны. Бөтен мәмләкәтләрне җиңеп алды бит моңарчы бу Гитлер. Радионы тыңласаң, әллә кайларга килеп җиткән бит алар хәзер...

Арбада тынлык урнашты. Һәркем үз уена батып, үз кайгысында йөзә башлады.

...Икенче көнне ирләр утырып килгән унике пар ат белән арбаны, товар вагоннарына төяп, сугыш барган якларга озаттылар. Ә Зиреклебаштан килгән халыкны каладан туксан чакрымда торган Краевкага озаттылар — монда аларны, хәрби киемнәр киендереп, атарга, граната ыргытырга, кул сугышына өйрәтергә тиешләр иде.

## 3

Колхоз келәтләрендә ашлык тазарткан җиреннән өйләгә балаларын ашатырга кайткан Зөбәйдә янына, хәле-тыны бетеп, Югары оч Мөнәвәрә килеп керде:

— Әй илаһым, ярый әле өйдә икәнсең, ахирәт! Исән-саулар торасыңмы? — дип, изүен чишеп җибәрде ул.— Бүген каладан Галиуллам телефоннан почтага шалтыраткан. Теге Кара Куян Мәрзиясенең кызы Сәрвәргә туры килгән. Без барыбыз да Краевкада ятабыз, хатыннарга барып әйт, безнең янга килсеннәр берүк дигән. Монда җыйналган халыкның исәбе юк, ашау ягы начар дигән. Күп итеп азык алып килергә кушкан. Бүген-иртәгә чыгып китәргә торабыз, әллә әйләнеп кайтабыз, әллә юк, хушлашып калырга ие дигән.— Шушы сүзләрдән соң Мөнәвәрә, бер кулын авызына куеп, яшь тә сыгып алды.— Әй, илаһым кәрим! Бар икән күрәселәребез, ахирәткәем! Берүк барып әйт, килми калмасыннар, дигән. Вәт шул. Әле сиңа килешли Гомәр бабай Зифасына, Рәйханага, Гали Мәфтухасына, Зәйнәпкә, Басыйр абзый хатынына, Асия сеңеленә, Ике су арасы Рәхми хатынына да сугылып чыктым. Кайсы өйдә, кайсы юк, елаш та сыкташ китте бөтен җирдә. Өйдә югының эшләгән җиренә бала-чагасы чыгып йөгерде. Рәйхана инде мичендә дә ягып җибәрде. Миңлебаемны бер күреп, туйганчы ашатыр өчен җир

читенә хәтле дә барам ди. Һәркемнең үз мәхәббәте үзендәдер инде. Өр-яңа чабатага төп салам дип калды.

— Син сөйләгәндә мин шуны уйлап алдым әле: әйдә, персидәтел Кави абзыйга барыйк та ат сорыйк. Бирсә, шуны җигеп китәрбез...

— Бирмәсә?

— Кит, нишләп бирмәсен ди инде, бар да бит колхозның җимертеп эшләүче ирләре иде. Шулар алып бара иде бит инде колхозны!

— Анысы шулай, ахирәт! Зифа әйткәние аны, туры Зөбәйдә апага барырга кирәк, бүтәннәргә аннан соң да әйтергә була дип. Тыңлый белмәдем шул сүзен. Әйдә киттек алайса Кавига.

Идарәгә барганда да һаман үзенекен сөйләде Мөнәвәрә:

— Әй бу Галиулланы! Утка да сала инде бу мине, суга да. Үткән җәйне ирең теге Әтер авылы Кызбану белән йөри дип килеп әйттеләр бит, эткәем! Шуны ишеткән кичтә күзен-башын вич тырнап бетердем Галиулланың. Юк ди бит, әй, күзгә карап алдый бу. Шуфир булгач, атна буе шул тырналган җирләрен солидолга майлап йөрде бит, мескенкәем. Үземә дә әләкте инде әләгүен. Андый чакта аны карап торасыңмыни инде. Өстенә очып кунып торам, ул да алып очырып тора. Ул алып очырганчы мин тырнап өлгерә торам. Икебезгә дә әләкте инде, әй! Ирләрнекен белеп бетереп буламыни, ант итеп туктады инде, шул. Бернәрсә юк, син нәрсә ди. Барыйк, ахирәт, барыйк яннарына, ат булмаса да барыйк. Ичмасам, бер тамакларын туйдырып, аз булса да үзебез дә иркәләнеп кайтырбыз.

— И-и, синең шул булыр инде.

— Ник, баргач-баргач инде шул тиклем җиргә, ансыз кайтырга. Янымда чакта да ирдән туйган көн юк иде әле.

— Ярар, әйдә Кави абзыйга кереп чыгыйк та, аннан соң мин Ясаклы урамына, эниләргә менәрмен, пешерешергә чакырырга.

Идарәдә председатель Кави сүзне кыска тотты:

— Нинди Краевка ди, нинди бару ди ул тагын! Мондый уттай эш вакытында дисталәгән хатын-кыз авылдан чыгып китсен, имеш. Намус дигән нәрсәгез кайда сезнең, ә? Икмәк кирәк дәүләткә, икмәк, чибәркәйләр!

— Эшләгәндә шәпләр ие, китеп баргач кирәкләре беттемени? — дип ачу белән тотынды Мөнәвәрә.— Кара син аны ничек сөйләшмәкче була! Син миңа, Кави абзый, күзеңне акайтып карама, курыкмыйм, беләсең килсә! Нигә, аларны әллә кайтмаслар дип уйлыйсыңмы? Кайтырлар, алла кушса! Шунда исеңә төшермәсәкме, күзләренә ничек карарсың икән шунда! Чибәркәйләр, имеш, әйтерием инде...— Председательнең ат бирмәслеген аңлап, Зөбәйдә ахирәтенең җиңеннән тотты. Тегенең, кызып китеп, артыгын әйтеп ташлый торган гадәте бар иде.— Әйдә, Зөбәйдә ахирәт, киттек, бер җаен табарбыз әле. Җәяүләп булса да теркелдәрбез. Әйтерсең, без кунакка барырга сорыйбыз ул атны. Ирләребез, бәлки, мәңге кайтмаска китеп баралардыр, ил сакларга, сине сакларга китеп баралардыр. Ә син атыңны жәллисең.

— Соң, жәлләмим мин, Мөнәвәрә, жәлләмим. Иген ташыйлар бит алар, аңла шуны.

— Башыңа капла атыңны алай булгач. Әйдә, Зөбәйдә, киттек.

Мөнәвәрә әле урамга чыккач та байтак тынычлана алмый барды. Һаман председатель Кавины сүкте. Бераз басыла төшкәч, Зөбәйдә аңа әйтте:

— Әй усал да инде син, Мөнәвәрә! Ул да бит урындагы кеше, бигрәк каты бәреләсең, күңеле калыр дип тә уйламыйсың, ичмасам.

— Калмагае тагын, сугышка бармый әле, түзәр! Хәзер без аның төп көче. Миндә аның кайгысы түгел хәзер, ирем кайгысы. Өч-дүрт көннән харап булмас, кайткач артыгы белән кайтарырбыз, бездән калмас.

Калган юлны тын гына бардылар. Һәркайсы үзенекен уйлады. Зөбәйдә үскән йортка килеп житәрәк кенә Мөнәвәрә телгә килде:

— Әйдә, этиең белән сөйләшеп карыйк әле. Гобәйдулла абзый ул, сиңа үги булса да, әйбәт кеше. Дөньяның әчесен-төчесен күп күргән, берәр киңәш бирмәсме.

Гобәйдулла абзый хатыннарның сүзен, ясаган камытын читкә куеп, каратут төшкән яңагын сул кулы белән сыпыргалап, игътибар белән тыңлады. Аннан соң гына салмак итеп сөйләп китте:

— Я, еламагыз, балалар! Хәзер ул нужа белән михнәткә чыдагыз гына инде. Бу сугыш дигәне елда гына бетмәскә охшый. Гитлерны бит аны башта туктатырга кирәк, туктаткач кире борырга, кире боргач та озак куарга туры килер әле. Аннан соң гына сасы өнендә тончыктырырга кирәк. Ай-һай, балалар, алда зур эшләр, күп каннар, бетмәстөкәнмәс нужалар бар әле. Герман сугышының башыннан ахырынача сугыштым, беләм мин ул каһәрнең нәрсә икәнен. Хөкүмәт башында утырганнарга да, мылтык тотып атакага йөргәннәргә дә ходай сабырлык вә куәт бирсен.— Гобәйдула абзый, урыныннан торып, алъяпкычын ук салып куйды.— Халык Краевкага ат белән йөрүдән соңгы алты-җиде ел эчендә генә туктады, калага тимер юл килгәч. Элек аның бездән йөри торган туры юлы да бар ие. Бездән чуваш Калиновкасы аша Курмайга чыгасың, аннан соң Янгырчыга барып җитәр-җитмәс, Чуваш Үрен менгәч, уңга борыласың. Ике чакрым ара үткәч, латышларның Баковкасы, аннары юл Карамалыга китә. Шунда инде юлның яртысын үттем дисәң дә була. Карамалыдан соң Софиновка, аннан Чебенлегә. Вак-төяк авылларны санамаганда, Чебенледән соң Краевка. Барысы алтмыш ике чакрым андагы юл арасы.

— Юлы ничек соң, әйбәтме? — дип сорады Мөнәвәрә.

— Әйбәтме диеп, безнең якның юлларын беләсез инде, тау да таш. Бигрәк тә Карамалы үрләре авыр. Ай-һай, анда өзелгән камыт баулары, тәртә төпләре, атларның бөкрәйгән янбашлары. Аллага гына ышанып үтеп булмый инде ул үрләрне: солы ашаган елгыр маллар кирәк тә, нык тәгәрмәчле арба, дөнья нужасы күргән ир-егетләр кирәк...— Иң кирәгеи сорамый торам бит дигәндәй, карт алга талпынып куйды: — Сез әйтмисез дә, нинди ат җигәргә уйлыйсыз соң, килде-киттене җигә күрмәгез...

Председатель Кавиның ат бирми җибәрүен ишеткәч, Гобәйдулла абзыйның болай да каратут йөзе тагын да караңгыланды.

— И-и, балалар, атсыз эшегез җәяүгә кала бит инде болай булгач. Җәяүлегә янчык та авыр дигәндәй, ике поттан артык күтәрә алмыйсыз инде. Анысы белән дә ул билегез ни күрә дә, ул аркагыз ни күрә. Аякларыгызны әйткән дә юк инде — чыдарсызмы икән?

— Ни булса да барырга кирәк безгә, Гобәйдулла абзый, бүтәнчә ярдәм итә алмасаң, берәр яхшы киңәш бир инде,— дип үтенде Мөнәвәрә.

— Алайса менә ничек итегез: берәр җиңелрәк арба тартырга кирәк булыр сезгә. Әнә безнең Хәмитнең ясап куйган бәләкәй генә фурманы бар, әйдә шуны өстерәгез. Беренчедән — азыкны күбрәк алырсыз, икенчедән — бөтенегезнең йөге бергә булыр.

— Әти, нинди фурман ул? — дип сүз катты Зөбәйдә.— Теге чегән аты җигәм дип ясаган нәрсәме әллә?

— Шул инде, шул. Хыяллана бит инде Хәмит бәләкәй алмачуар бияне шуңа җигәм диеп. Май аенда милиция, тиешле кәгазьләре булмагач, чегәннәрдән алып калган иде бит, хәзерге көнгәчә кая куярга белмиләр атны. Арбага жиксәң — ишәк кебек, атлансалар — аяклары җиргә тия. Безнең колхозга биргәннәр. Бездә дә шушы көнгә кадәр җигүче табылмады. Хәмит кенә җенләнеп йөри. Хәзер Мөхетдин Чәүкә янында тимерчелектә эшләштерә. Шул Чәүкә янында ясаган фурманны. Кулы бик оста имансыз малайның. Әйдәгез, барып карыйк әле, иртән тәгәрмәчләрен салидул белән майлап ята иде.

— Бирсә ярый да бит...

— Шулхәтле эшкә бирмәскә тагын...

Чыннан да Хәмит каршы килеп тормады, тик кире кайтканда ташлап китә күрмәгез дип кенә әйтте дә, арба астына бәләкәй дегет чиләге бәйләп, тимерчелеккә китеп барды. Фурманы бик матур, җыйнак, кузгатырга җиңел итеп ясалган иде. Куллары чыннан да алтын икән бу үсмернең.

Авыр юлга чыгарга тәвәккәлләгән алты хатын, таң беленү белән кузгалырга килешеп, ирләренә азык хәзерләргә кереште. Башкалар бара алмады. Бикәнең бишенче баладан котылганына ай да юк. Ике су арасы Гаязның хатыны калага ашлык ташый — шунда киткән. Басыйр хатыны өч чакрымдагы сыер фермасында маллар карый икән. Зәйнәп авырып ята. Өтек Галинең Мәфтухасы нигә бармаганын әйтеп тә тормады...

Шулай итеп, алты хатын төн буе пешеренеп-төшеренеп юлга әзерләнделәр. Кавидан курку башларыннан чыкмаса да, хәстәренә керешкәч, уйлары каядыр китеп юк булды. Башларын бүтән мәшәкать басып алды. Нәрсә пешерергә, күпме пешерергә, нәрсәгә төрергә, ничек итеп алып китәргә... Шул ук кичне авылның төрле урамында куркынган этәч-тавык кыткылдавы ишетелде, йөзләре мич кызуында алсуланган хатын-кызларның тыз-быз йөгерүләре, җиңел аяклы малайларның йомыш үтәп бер очтан икенче очка чабулары күзгә чалынды.

## 4

Байгара тавы артыннан сызылып таң беленеп килгәндә Кара Гобәй йортыннан тимер тәгәрмәчле фурманга җигелгән алты хатын килеп чыкты. Мөнәвәрә төпкә җигелгән, аның ике ягында Зөбәйдә белән Зифа, яннан Кара Гобәйнең унсигез яшьлек кызы Асия атлый. Артта фурманга ябышкан килеш бәләкәй буйлы Учак Миңҗамалы белән Рәйхана титаклый. Фурман төрле зурлыктагы капчыклар, төенчекләр белән тулган. Аның урта бер җирендә Учак Миңҗамалының унбер айлык улы Мөнир утыртылган. Миңҗамал баланы үзе белән алуын хатыннарга, каенанам авыру, калдырырга кеше юк дип аңлатты. Әмма тегеләр аны-моны әйтмәгәч, тора-бара төп сәбәбен дә ачты:

— Сәләхетдинем бик ярата иде шул бәләкәчне. Бигрәкләр дә күрәсе килгән иде шул баланың йөри башлаганын. Атасы киткәнгә төп-төгәл бер атна дигәндә, китте дә барды бит сабыем. Дөнья хәлен белеп булмый, күреп калсын баланың аяк басып тәпи йөргәнен. Өстәвенә «әттә» дип тә әйтә әле ул минем йөрәккәем. Яле, улым, «әттә» диген әле, сабыем...

Югары очны үткәндә ишегалларыннан сыер сауган тавышлар ишетелә башлады. Хәким Борычлар йортына килеп җитәрәк, тегеләрнең капкасыннан чыгып килүче милиционер Антипов белән председатель Кавины күреп, хатыннарның котлары алынды. Беренче уйлары — «безне ирләребез янына җибәрмәс өчен көтеп торалар» иде. Ни хикмәт: арбалы хатыннарны күреп алгач, Кавиның караңгы йөзе яктырып китте. Кул хәрәкәте белән Антиповны капка төбендә калдырды да, юл уртасында туктап, аның ягына куркышып карап торган хатыннар янына килде.

— Сез, чибәркәйләр, миңа ачу тотмагыз инде,— дип башлады ул сүзен.— Ат бирергә бер дә җае юк бит. Син, Мөнәвәрә, төпкә җигелгәнсең икән, караштырып алып кайт инде барысын да... Бер-берегезне юлда ташлап китә күрмәгез, өч көннән артык йөрмәскә тырышыгыз инде, ямме? Рәйхана күрше, син юкка йөрисең түгелме соң, юл газабы — гүр газабы диләр бит...

— Калмыйм, Миңлебаемны...— дип, Рәйхана елый ук башлады.

— Я, я, берүк елый күрмә инде, барсаң — бар, тик аякларың чыдармы диюем генә,— дип Кави аны тынычландырырга ашыкты.

Форсаттан файдаланып, Мөнәвәрә исә сүзне әлеге сәфәргә борды.

— Ярар инде, Кави абзый, без кузгалыйк булмаса. Кичә минем катырак бәрелгәнгә үпкәли күрмә инде. Ир диеп әйтүе генә җиңел бит, үзең беләсең. Өч көндә әйләнеп кайтырга тырышып карарбыз, әгәр инде тагын берәр көн соңласак, син аны-моны уйлама инде.

— Ярар, алайса, кузгалыгыз, бик зур эшкә тотынгансыз. Юлыгыз уң булсын!

Хатыннар кузгалды. Аларны алда биек таулар, текә үрләр, күп михнәтләр көтә иде.

Бу күренешкә аптырап, аларның Чуваш юлына күтәрелә башлауларын карап торган Антипов Кавидан сорап куйды:

— Кая бара алар?

— Краевкага, сугышка озатыласы ирләре янына...

## 5

Хатын-кызның бер арбага менеп утырса, үргә күтәрелгәндә дә төшми торган алама гадәте бар. Шул сәбәпле юлга чыкканда ир-ат аларны үзе белән алмаска тырыша. Алтысы алты җирдән арбага ябышкан хатыннар үргә менгән саен йөк тарткан атның хәлен ачыграк аңлый башладылар. Арбаны арттан этеп килгән Рәйхана үрнең башына менеп җитеп килгәндә авыр сулап тавыш бирде:

— Нәзер итеп әйтәм, моннан соң гомеремдә дә үргә утырып менмәячәкмен, гел җәяүләп йөрермен.

Аның сүзләренә хатыннар моңсу гына елмаешып, тау башында бераз хәл алырга туктадылар. Яулык астыннан чыккан чәчләрен төзәткәләп, кием-салымнарын рәткә китергәч, фурман тартып, Чуваш юлы белән алга атладылар. Көпчәкләр юл буйлап тәгәри, ә хатыннарның һәркайсы үз уенда, үз кайгысында йөзә. Нәфрәт кузгалган күңелләрендә әле гомердә күрмәгән Краевкада ятучы ирләре яки өйдә калган бала-чагалары күз алларына килеп баса. Шул ук вакытта, туганнан алып, әлегә хәтле бер генә дә нужа күрмәгәннәр икән дигән шомлы уй йөрәкләренә тынгысызлык сала. Күңелләре тула, күзләренә яшь килә, әллә нинди утлар үйның башлый...

Тигез җирне үтеп, Поскын чокырына төшә башлагач, арбаны тыеп барырга туры килде. Чакрымнан артык түбән карап сузылган текә юлдан, тузан туздырып, фурман тәгәри, аны тыеп хатыннар йөгерә. Тик артта торып калган Рәйхана гына гарип уң аягын тизрәк атлатырга тырышып карый. Әмма тумыштан гарип аяк тыңламый. Поскын чокыры төбенә төшеп җиткәч кенә хатыннар Рәйхананың артта калганын күреп алдылар, тиргә батып, арба артында басып торган Миңҗамалга эндәштеләр:

— Рәйхана артта калды диеп ник кычкырмыйсың?

— Күрмәдем.

— Соң күрмәскә янында барган кешене.

— Аны карыйммы, баламнымы? Мөнирем төшеп кала диеп котларым очты. Рәйхана кайгысы түгел әле монда, йөгерә алмагач йөрмәсен кеше әрәтеннән, өендә ятсын...

Мөнәвәрә Миңҗамалны тиз туктатты:

— Син телеңне хәзер үк тый, яме! Тыя алмасаң, азактан үпкәләштән булмасын. Гарип көенчә ирекледән йөримени ул, синең кебек үк, ир диеп җәфа чигәргә кузгалмаганмыни? Әле юньләп торып юлга чыгып җитмиенчә, кем кирәк, кем кирәкми турында сүз озайтмый торыйк, яме? Шул чакта гына сиңа яхшырак булыр, башкаларыбызга да... Бергәләп чыкканбыз икән, шулай барып җитик әле, аннан карарбыз кемнең кем икәнен.

Ахылдап, лап-лып атлап килеп җиткән Рәйхананы азрак хәл алып өлгергән хатыннар, кызгануларын сиздермәскә тырышып, якты йөз белән каршылады.

— Син, ахирәт, алай бик артта калырга тырышма инде, яме. Таудан төшкәндә җәһәт кенә Мөнир янына мен дә утыр. Шулай итмәсәң, артта каласың, сине көтеп вакыт та үтә бирә.

Сүзгә Гомәр бабайның әле яңа гына кияүгә чыккан кызы Зифа да кушылды:

— Бигрәк текә булды юлның бу төшә торган ягы. Безнең әтинең сөйләгәне бар ие бу Поскын чокыры турында. Шушы урында пөз еллар элегрәк кеше үтеп йөрмәслек кара урман булган ди. Юллар-фәләннәр бөтенләй булмаган ди. Шушы чокыр эчендә Пугач дигән казак патша, Ырымбур янында Әби патша гаскәрләреннән җиңелгәч, качып яткан ди. Шуннан соң тирә-яктагы башкортлар бу урынны Боскын диеп, Пугач Поскан Чокыр диеп йөртә башлаганнар. Шул Пугач патша гел ярлы халыкны яклап сугышып йөргән ди. Үләннәр яшәрә башлагач, Әүҗән якларына, туп ясый торган завудлар ягына чыгып киткән ди. Шул вакытларда безнең авылдан да бик күп ярлы-ябага аңа ияреп киткән ди.

Шулай сөйли-тыңлый хатыннар чуваш авылы Калиновкага килеп керделәр. Авыл уртасында туплана башлаган сыер-сарык көтүен ерып алга үтә башладылар. Чиккән чып-чуар киндер күлмәкле чуваш хатыннары моңа хәтле күзгә күренмәгән бу бик тә сәер олауны бик аптырашып каршы алдылар. Алардан берсе түзмәде, сорады:

— Кая китеп парасыс, пелешләр?

— Краевкага, ирләребез янына.

Бу сүзне ишетеп, чуваш хатыннары арбаны сырып алдылар, сорашырга тотындылар:

— Кайчан киткәннәр ие ирләрегес?

— Минем Микалай анда түгелме, пелмисесме?

Чуваш хатыннары берсен-берсе бүлгәләп сорау биргәндә соңрак килгән берсе, башкаларны ерып алга үтте дә, Зөбәйдәгә кулларын сузып, елап ук җибәрде:

— И-и, пелеш, исәнме, исән-саулармы?

Зөбәйдә аның сузылган кулларын кысып җавап бирде:

— Исән, исән, тик мин сине белеп бетермим бит әле?

— Ния пелмәскә, минем Трофимым синең ирең пелән пергә китте пит. Синең аягыңда матур куныч лы итек иде пит. Мин дә парам полай пулгач Краевкага.

Мөнәвәрә белән Зөбәйдә бер-берсенә карашып сүзсез генә аңлаштылар да арбаны кузгата башладылар:

— Син, белеш, безне гаеп итмә инде, үпкәләштән булмасын — без сине көтә алмыйбыз. Алган итләребез бозыла башлар, персидәтел дә вакытны бик кыска бирде...

— Юк, юк! Нишләп мине көтәргә. Хәзер үк Аннага йөгерәм. Икәү парапыс пес аның пелән, икәү... Сес әйдә юлыгызда пулыгыз, аллагыс ярдәм итсен!..

Калиновканы чыгу белән юл текә генә тауга үрмәләде. Тауны да меңделәр кара тиргә баткан хатыннар, түбәнгә дә төштеләр, бер-берсенә сиздермәскә тырышып, мышык-мышык елап та алдылар. Тулы ботларын кыймылдаткалап әнкәсен суырган Мөниргә карап елмайгаладылар да. Нәрсә уйлап, ни генә кичермәсеннәр, тарттылар арбаны хатыннар, эттеләр... Аларның тырышлыгына аптыраган озын юл фурманның дүрт тәгәрмәче астында бер йөгерде, бер туктар-туктамас барды. Юл газабы — гүр газабы диюләр дөрес икән. Егерме белән утыз арасындагы пешкән алма кебек алты матур хатын моның шулай икәнен кырык беренче елның август юлында белделәр. Татар Курмаен үтеп, аның да тавын менделәр, Шангырчы авылын сулда калдырып, үн елга якын ташландык хәлдә яткан, үлән баскан иске юл белән Карамалыга таба борылдылар.

Шушы тирәләрдә Уралның Урта Сырты тәбәнәкләнеп, казах далаларына таба вак-вак таулар, калкулыклар тезмәсе сузылып китә. Әмма алар карап торырга гына бәләкәй, юл йөри башласаң, ай-һай, үзәккә үтәләр бу текә үрләргә үрмәләүче юллар. Хатыннар барган юл шуларның берсе иде инде. Ул аларны, Зиреклебаштан алып чыгып, Олы Себер тимер юлында урнашкан Краевкага китерергә тиеш иде.

Фурман шул тауларга карап келтер-келтер тәгәрәвен белә. Алты хатында алтмыш төрле уй. Аларның очы-кырые юк. Миңжамал белән Рәйханада өчәр бала, Мөнәвәрә белән Зөбәйдәдә дә икешәр бәләкәч. Өстәвенә, Мөнәвәрә кулында ире Галиулланың авыру әнисе, Миңжамалда — каенанасы Гайникәй карчык. Асия белән Зифада гына бала юк. Ирләре сугышка чыгып киткәндә алар икесе дә, төшмәгән килен булып, аталары йортында утырып калдылар.

Зифаның ире Габдрахман Акмалов, читтән килгән егет буларак, аларга йортка кергән иде. Гражданнар сугышы вакытында ятим калып, балалар йортында үскән иде ул. Өйләнешүләренә ай ярым тула дигәндә сугыш кузгалды. Гомәр бабай бик яратты киявен. Кулаксыз бүреген җәен-кышын салмыйча, гомере буе ат күрмичә, үгез җигеп дөнья көтте ул. Өстәвенә, бер җитешсезлеге дә бар — ике аягы да тумыштан эчкә карап торалар иде. Шуңа күрә үз гомерендә аягына чабатадан башканы кия алмады. Балчык идәнле читән өй, бер сыер, ике-өч баш сарык белән кәҗә, авыру карчыгы, бердәнбер кызы — бөтен дәүләте шул иде картның. Балалары туа барды, үлә барды. Хатыны белән икесе кырыкка җиткәндә генә шушы кызлары туды һәм исән калды. Үсеп җиткәнче ник бер авырсын, ник бер елап карасын. Гарип карт белән авыру карчык өчен Зифа дөньядагы бер шатлыкка әверелде. Колхоз чыккач, керергә бик күзе кызып йөрсә дә, кермәде Гомәр бабай. Илгә имгәк булмыйм, кеше хакы ашарга туры килмәгәе дип кермәде карт. Аннан соң инде бабайга кер дип әйтүче дә булмады. Кызлары Зифаның исеме җисеменә туры килде — чыннан да зифа буйлы, таза, чибәр булып үсте. Гомәр карт кызының чапкан покосларына сокланып бетә алмый иде. Кияүдән дә уңган кебек иде бабай, тик менә сугыш афәте чыгып кына харап итте дөньяны. Сугыш башланганга ике ай тулыр-тулмаста, яшь хатынын, гарип бабасын, авыру әбисен калдырып, Габдрахман яуга чыгып китте. Хәзер бабайның коръәне эчендә яңа йортлык бүрәнәгә кияве яздырып алган кәгазь белән Зифаның колхозга керү гаризасы гына калды. Йорт салырга дигән бүрәнәләр һаман да Мирдер урманында шаулап үсеп утыра...

Зифа шомырт тәртә башын тарта, кызларныкыдай зифа гәүдәсенә ачуы килеп бара. Буйга узса, ичмасам, бер күңел юанычы калыр иде, дип уйлый ул. Тора-бара уйлары бутала, әйтерсең лә, туктаусыз тәгәрәгән арба күчәренә урала башлыйлар. Ирен соңгы тапкыр күрәчәге Зифаның әле башына да килми, ул Краевкага ашыга, ярын сагынудан күңелләре тула, бүтәннәргә сиздермәскә тырышып, яшь хатын тозлы яшен йота...

Шомырт тәртә башының икенче очын тотып, яшь килен Асия атлый. Аның хәле дә Зифаныкы сыман. Март аенда кыз ягында туй үткәрделәр, шуннан соң ире Мәҗит сугыш башланганчы кияүләп йөрде. Күзләр җитеп, маллар суйгач, килен кияү йортына төшәргә тиеш иде. Көмеш кыңгыраулы атларга утырып йөрисе урында, хәзер менә Асия үзе җигелеп Краевкага таба юырта. Ике тәртә арасына, төпкә җигелгән Зөбәйдә — апасы. Аларның ана бер, ата башка. Асия Кара Гобәйдән туган кыз. Авылда аннан башка да Гобәйләр җитәрлек: Көрпә Гобәй, Пәрәү Гобәй, Шалпык Гобәй...

Атасы гомере буе көршесе Миңлебай карт белән авыл халкына мич чыгарды. Зур гәүдәле, киң күкрәкле, көрәктәй зур куллы Гобәй янында Миңлебай карт яшүсмер малай кебек кенә күренә. Шулай да

Гобәй, Миңлебайны зурлап, ихтирам итеп, аңа берсүзсез буйсынып яшәде. Ник дисәң, Миңлебай сирәк очрый торган миччеләрнең берсе иде. Эш башлагач, аларның һәркайсы үзенчә тырышты: Миңлебай карт кирпеч салды, ә Гобәй бу вакытта балчык изде, ком ташыды, кирпеч ватыкларын, җыелган чүп-чарны чыгарып түкте. Ай-һай, оста да мичче иде соң Миңлебай карт! Кемнең йорты нинди җирдә утыра, җил кайсы яктан күбрәк исә, түбә кыегы текәме, морҗа чыккан турыда зур агачлар бармы — бөтенесен исәпкә ала иде ул. Өч мәхәлләле авылның барлык өйләрендә дә диярлек ул чыгарган мичләр яна, хуҗаларына җылы бирә. Эш хакын да кешесенә карап сорыйлар иде. Ятим, күп балалы хатыннардан хакны алган булып кына кыландылар. Миңлебай карт һәрчак киң күңелле, кешегә игелекле, ярдәмчел булды. Шулай да картның ачу чыккан чакларын да хәтерли Гобәй.

Бер елны авылның Түбән очында утырган яңа баеп килүче бер адәмне кызык итте ул. Дүрт көн буе ике якка ике зур мич чыгардылар Гобәй белән. Анысы ярар, тик авыр эшкә ашы да рәтле кирәк бит. Хуҗа начар ашатты миччеләрне. Бәлки шулай тавыш-тынсыз узып та киткән булыр иде, тик эш башланганның икенче көнендә осталар иртән капкадан килеп кергәндә өй эчендә хуҗаның хатынына кычкырганын ишеттеләр:

— ...нишләп аларга тавык ашатыйм ди мин. Бик юмартланып китмә, әнә аларга сызыклы умач житеп ашкан...

— Оят бит кешегә шул хәтле эштән соң умач ашатуы...

— Ояттан күлмәк текмиләр, үтәр әле. Әллә син аларда акча юк дисеңме, синең белән миннән бай әле алар...

Миңлебай карт аны-моны дәшмәде. Аңа карап Гобәй дә сүз кузгатмады. Өч көннән соң эшне бетереп, хакны алдан сөйләшкәнчә алып, миччеләр кайтып киттеләр. Ләкин шул елны хуҗалар кыш буена интектеләр зур яктагы мич белән. Атна буена әйбәт кенә яна да, көннәрдән бер көнне әйтерсең лә эчендәге пәриләр төтен юлынябып куя. Мич пырых-пырых итеп өй эченә төтен бөрки башлый, морҗа тартмый, гөрләп янып яткан утын агачлары пыскып ята. Шулай берничә көн холыксызланып алганнан соң мич тагын җайга салына, өйне май кебек итеп җылыта. Күпмедер көн үткәч, элекке хәл тагын кабатлана, тагын мичнең җене кузгала. Мичнең янасын-янмасын белми азапланган хуҗалар зур якка бөтенләй чыкмас ук булдылар. Кыш буе яңа салынган йортның рәхәтен-ямен күрә алмадылар.

Карлар китеп, урамнар яшәрә башлаган чакны хуҗа хатыны Миңлебай карт янына килде:

— Инде, Миңлебай бабай, зинһар өчен, бала-чага хакы өчен генә булса да, барып кара инде безнең мичне. Әллә нәрсә эшли бит, илаһым, тәмам үзәккә үтте. Үзе җылы була, күмәчне дә әйбәт пешерә, тик бер киреләнсә, өйдән чык та кач инде...

— Ярар, килен, ярар,— диде Миңлебай карт.— Иртәгә иртән барып чыгармын үзегезгә. Егермеләп кирпеч хәзерләп куегыз, балчык, ком. Комы, матри, тау башы комы булсын...

Мич хуҗасы борылып китәргә торганда, күзләрен салынып торган кашлары астына яшереп сорады карт:

— Зур ягыгызның миче төтенлидер бит?

— Зур якныкы, зур. Шул көн күрсәтми...

Икенче көнне Миңлебай карт, такта түбә өстендәге морҗаны озынайтып, аңа төпсез чиләк ныгытып төште. Хуҗа хатынның биргән акчасын да алмады:

— Мичеңнең игелеген күр, килен, акчаны ireңә кире бир, хакын үткән ел алдык бит инде без,— дип өенә кайтып китте.

Капканы чыккач, Гобәйнең аптырашлы карашын күреп, җавап бирде:

— Кыйбла җиле, Гобәйдулла энем, кыйбла җиле. Өй артындагы тирәкләрнең кәүсәсе юан, ботаклары куе бит, әй-йе... кһем...

Асиянең әнкәсе Садрикамал — Кара Гобәйнең икенче хатыны. Беренчесе егерме беренче елгы ачлыкта үлеп китте. Хатыны үлгәнгә ай тулыртулмаста Гобәйдулла Садрикамалның ишеген шакыды. Кергәч сәке йөзлегенә утырып дога кылды да, битен яулык чите белән каплап, мичкә сөялеп торган хатынга сүз катты:

— Мин менә нигә килдем әле, Садрикамал. Әйдә без кушылыйк, бергә тора башлыйк. Я синең өйдә, я минекендә. Ике йортның берсен сатыйк. Хәзер мал кайгысы түгел, җанны саклап алып калырга кирәк. Мин Зөбәйдәңә эти булырмын, син минекенә әни бул. Ходай рәхмәтеннән ташламаса, шулай исән калырбыз.

Шул кичне Гобәйдулла, Садрикамалның тугыз яшьлек кызы Зөбәйдәне ике тәгәрмәчле кул арбасына утыртып, хатынның үзен тәртәгә тотындырып, өенә алып кайтты. Садрикамал йорт-җирен алабута катыш өч пот арыш бәрабәренә бакчасы терәлеп торган Мөслим байга саттылар. Егерме ел бергә тору дәверендә Гобәйдулла хатынына бер генә авыр сүз дә әйтмәде. Табыннарда, мәҗлесләрдә, Садрикамал кулына тальян гармун алып уйный башласа, дөньясын онытты. Ачы балны азрак төшереп алган чагы булса, гел хатыны янына елышырга гадәтләнде. Еллар үтеп, картая барган саен, карчыгын ныграк яратты Гобәй. Чит якларга чыгып йөрмәскә, нужа куган юлларыннан да тизрәк әйләнеп кайтырга тырышты. Атлары житез, арбалары җиңел, дирбияләре гел каештан гына булды.


Асия этисе Гобәйдуллага охшаган. Азрак каралыбрак торган алсу йөз, шомырт кара күзләр, энҗе кебек тезелешкән ап-ак тешләр. Алар кызга үзенә бер сөйкемлелек, ягымлылык биреп тора.

Унсигез яше яңа тулып үткән бу яшь хатын ирнең нәрсә икәнен юньләп аңламыйча торып калды. Кияү куенына кергәнче ул егетләр белән йөрү-үбешүләрнең нәрсә икәнен белмәде. Базар артындагы кичке җыр-бию уеннарыннан да анасы үзе барып алып кайта иде аны. Таралыр вакытлар якынлаша башласа, читән тыкрыктан кызыл француз яулык бәйләгән Садрикамал түти килеп чыга. Ул күренү белән эш бетә, әнкәсенә ияргән каз бәбкәсе кебек, кыз өенә кайтып китә.

Кияүгә чыккач та Мәҗитнең үбү-кочуларына өйрәнеп китүе кыен булды Асияга. Бәхеткә, ире бәйләнчек адәм түгел иде, җайлап кына, сабырлык белән генә иялəштерде үзенә. Аннары матур итеп кияүләп йөргән җиреннән сугышка чыгып китте Мәҗит. Асия исә төшмәгән килен рәвешендә атасы өендә торып калды. Менә хәзер башында һаман бер тынгысыз уй: буйга узды микән ул? Ире киткәнгә бүген әле унсигезенче генә көн, тик аларның һәркайсы Асия өчен елдан да артык булды. Сагына ул Мәҗитен. Үз хәле турында апасы Зөбәйдәдән сорар иде — оят, ә башка сер уртаклашыр кешесе юк. Докторга барырга да тартына: ничек итеп анда аяк атлап керәсең дә, ничек итеп шундый эш турында чит кешегә сүз катасың? Өстәвенә, шифаханә ишегалды тулы сугышка каралырга килгән ир-ат. Эштән кайтышлый шул тирәдән үтә башласаң да, дәшеп, арттан көлешеп, теңкәгә тиеп бетәләр. Каты итеп җавап бирер идең, бәлки, кем белә, кире кайтмаска китүләредер... Мәҗит алай-болай әйләнеп кайтмаса, нишләр ул ялгызы бала белән? Шул ук вакытта табасы да килә Асияның баланы. Ире сугыштан җиңеп кайтуга каршысына бала күтәреп чыгу үзе ни тора бит ул...

Асия арбада төче күмәч кимереп утырган өч-дүрт тешле Мөниргә карый да, күңеленнән дулкын үткәнен сизә: табасы иде, табасы иде баланы... Мөнир үзе нәрсәдер лыгырдый, үзе кимерүен белә. Арыгач, ыштансыз артын август кояшында ялтыратып, йоклап та ала. Бераздан тагын, юл сикәлтәсендә уяныл китеп, ипи кисәген эзләп табып кулына ала да йоклап китә.

Баласының һәр хәрәкәтен күзәтеп барган Минҗамал я арба кырыеннан, я арттан атлый. Бәләкәй гәүдәле булса да, житез хатын ул.



*— Ни булса да барырга кирәк безгә. Гобәйдулла абзый, бүтәнчә ярдәм итә алмасаң, берәр яхшы киңәш бир инде,— дип үтенде Мөнәвәрә.*

А. Тимергалина рәсеме.

Өйдә аның тагын ике баласы, каенанасы бар. Йортлары авылның кырыенда, Тал Борыны дип йөртелгән сазлыклы җирдә урнашкан. Бакчалары арты белән Төрек Күленә килеп тоташа. Гомер буе базларын су басып интектерде, көзен-язын урамнарына ат керә алмады. Йорт тирәсен, малтуарны, бала-чаганы Миңҗамал үзе карады. Бәхетенә туры килгән ире Сәләхетдин бәләкәйдән ат җене кагылган кеше иде. Малай чактан ук көтүгә куна баруны урамнарында Сәләхетдин оештырды, гел алдан йөрде, бакча басу, абзарлардан тавык күкәйләре чәлүләр дә аның катнашыннан башка эшләнми иде. Күрше-күлән Сәләхнең бу эшләренә бармак аша гына карады, чөнки малайларын Сәләх җыйнап алып китсә, атлары тук кайтты. Яхшы үләнлек табып, атларны тышаулап шунда кушмыйча торып, берәүне дә учак янына якын җибәрми иде малай. Сәләхнең иң яраткан учак булды. Киндер капчык эченә төреп салган бәләкәй балтасы күз ачып йомганчы утын агачларын турап ташлый. Сәләхнең бер шырпы сызуы белән ут та гөрләп янып китә. Кызу көлгә күмелгән бәрәңгеләр, тавык күкәйләре — барысы да әллә кайларда калды. Малай чак рәхәтеннән Сәләх өчен ике генә нәрсә — малайлар биргән Учак кушаматы белән атларга булган мәхәббәте генә сакланып калды.

Авылның яше-карты аны Учак Сәләх дип йөртте. Йомышка кергән бала-чага да Учак Сәләх абзый дип дәште. Нәниләрне бик ярата, бервакытта да каты бәрелми, гел аларның йомышын йомышлый иде ул. Буаз биясен, авырлы хатынын ияртеп, Учак Сәләх беренчеләрдән колхозга керде. Башкалар кебек чыгымлап йөрмәде, кергән көненнән алып сугыш чыкканчыга хәтле күмәк хуҗалыкта атлар карады. Эшләгәнен алды, артыгын кумады. Сәләх караган атлар һәрвакыт ашатылган, эчертелгән булдылар. Шушы яше җиткәнче юк-бар малай-шалай белән ат көтеп йөрде. Бергә тора башлаган елларны Миңҗамалы, ризасызлык белдереп, мыжып караган иде дә, җиңә алмады. Ире китте, ә Миңҗамал менә өч бала, авыру каенана белән торып калды. Олы улы Зәйнетдин менә быел өченчегә күчте. Хәзер инде йортта ир-ат затыннан шул хуҗа. Быел менә түбәнең саламын алыштырасы бар, читән тузган, кышка утын кирәк, бала-чаганың өс-башы тузып килә, тагын әллә нәрсәләр...

Миңҗамал уйларының очына чыга алмый, башы аңгы-миңге килә, тез буыннары йомшара... Шуңа күрә ул тәртә арасына кермәскә тырыша.

## 7

Чатан булса да, Рәйхана да арбаны тырышып этте. Ә юл түбән авышса, арба артына утырып төште. Кояш күк гөмбәзенә торган саен биеккәрәк үрмәләде. Вакыт үткән саен Рәйхананың аягы ныграк арый һәм авырта башлады. Юлга чыкканнан бирле хатыннар калдырып китмәсәләр ярар иде дигән уй аны куркытып килде. Тумыштан гарип булганга, балачактан бирле кимсенеп үсте Рәйхана. Өч малайдан соң туган гарип кызларын әтисе белән әнисе дә бик кызганалар, яраталар иде. Йөгереп уйнарга ярамаганлыктан Рәйхана бәләкәйдән үк өй тирәсендә чуалды: шәл бәйләде, чабата үрде, юкәдән баулар иште. Үсә төшкәч, бу яктан хәтта абыйларыннан да уздырып җибәрде. Егет-җиләннән тартынып, уеннарга чыкмады кызый, кичке утырмаларда да гел почмак якта гына утырды, бүтән кызлар кебек идән такталарын сыгылдырырлык итеп бию бәхетләре тимәде аңар.

Миңлебайга кияүгә чыгуы да кызык кына булды аның. Яңа еллар үткәч, әтиләре Аллагуат авылындагы туганнарына атналык атлы кунак булып чыгып киткәннәр иде. Рәйханага иптәшкә күршеләрендәге Сөяксез Гайшә һәр кичне куна керде. Ул көнне өйләдән үк җил кузгалды, караңгы төшә башлау белән тышта гарасат тагын да көчәйде, тоташ

бер үкергә әверелде. Буран бөтен көченә йортның кыйбла як стенасына килеп бәрелә, өйне дер селкетә иде. Гайшә карчык зур симез гәүдәсен кая куярга белмәде: кече улы Мөсәлим, ат җигеп, иртә таңнан Шарлык ягына чыгып киткән иде.

— И-и ходаем, мәрхәмәтләреңнән ташлый күрмә инде без бәндәләреңне! Юлда йөргәннәргә рәхим-шәфкатеңне кызганма, балачагаларны ятим калдыра күрмә,— дип юанлыгы аркасында Сөяксез Гайшә кушаматы алган карчык бертуктаусыз укынуын белде, алладан ярдәм сорады, нәзерләр әйтте, ятимнәргә, гарип-горабага хәер-сәдакалар өләшергә сүзләр бирде. Тик Мөсәлиме генә Шарлыкка барып җиткән булсын, юлын гына адашмасын, явыз бәндәләр генә очрамасын...

Әбинең тавышын тыңлап, Рәйхана ярты төнгә кадәр йокыга китә алмый ятты. Намазлык өстендә чайкалган карчыкка карап, аның да күңеле кузгалды. Төн буенча өйдә ут сүнмәде. Шул ут Миңлебайны үлемнән коткарып калды...

Ярты төн үтеп барганда тәрәзә кактылар. Намазлык өстендә утырган карчык сискәнеп китте:

— Ләхәүлә вәлә куәтә, юньле бәндәләр генә булсын инде, таңрем...

Карчык агарынып урын өстендә утырган Рәйханага эндәште:

— Бу вакытта кем йөрер икән, кызым, бар, сорале!

— Кирәкми, Гайшәттәй, куркам мин.

— Ай, куркам дип инде, тотып ашамаслар, үз өебездә бит әле, бар...

— Юк, куркам мин, чыкмыйм.

— Әйдә алайса, икәү чыгыйк.

Карчык аһ-уһ килеп сәкедән төште, мич янындагы табагачны алды да өялдына атлады:

— Кем бар анда бу вакытта?

— Зинһар өчен кертә күрегез, адашкан юлчы мин.

— Кем соң син, мөселман бәндәсеме?

— Мөселман, мөселман! Зирекле авылыннан мин, Миңлебай дигән егет булам.

— Атаң кем?

— Ходай хакы өчен кертегез инде, аяк-кулларымны өшеттем шикелле. Үлемнән башка чарам калмады...

Рәйхана белән карчык бер-берсенә карашып нәрсә эшләргә белми торганда, ишек артыннан тагын ялвару тавышы ишетелде:

— Үзегезнең бер дә адашканыгыз юкмыни, зинһар миһербанлык итегез инде...

Шунда карчыкның исенә юлдагы улы төште, ахрысы, авыз эченнән нәрсәдер укый-укый, аркылы салынган агачны алып ташлады. Ишек шунда ук ачылып китте дә, карчык аяк астына бер гәүдә ауды. Икәүләшеп көч-хәл белән юлчыны өйгә өстерәп алып керделәр. Аны чишендереп, байтак вакыт кул-аягын, битләрен ышкып, һушына китерделәр. Аяк-кулы өшемәсә дә, егет бик нык туңган иде. Гайшә карчык аның күшеккән тәнен кар белән бик каты итеп угач, кызарып кан йөгерә башлаганчы коры киндер чүпрәк белән ышкыды, авызына Рәйхана җылытып китергән кайнар шулпаны салды, аннан соң тагын тәннәрен ныклап ышкыды.

Егет киң күкрәкле, баганадай юан беләкле бик таза адәм иде. Тире астындагы юан аркан кебек мускуллары, түгәрәк таза кулбашлары, киң җилкәсе — бик сирәк кешеләрдә генә була торганнардан иде. Көчле, куәтле икәне бөтен килеш-килбәтеннән үк күренеп тора. Гайшә карчык эшен туктатмый гына әйтеп куйды:

— Сөбханалла-машалла, ай-һай, гайрәтледер бу җегет, бигрәк таза күренә.

Бер чүмеч җылы шулпа эчкәч, егет тирән йокыга китте.

Иртән ул уянганда, буран басылып бетмәсә дә, инде йомшарган иде. Сөяксез Гайшә, юан гәүдәсен авыр кыймылдатып, намаз укый, ә Рәйхана учак тирәсендә нәрсәдер пешеренә иде. Миңлебай уянган жиреннән кузгалмый гына Рәйханага дәште:

— Сеңелем, кайсы авыл бу?

— Әмир авылы, абый.

Миңлебай дәшмичә тагын азрак ятты. Ул Чигодай дигән рус авылыннан өйлә үткәч кенә жәяүләп Зиреклебашка кайтырга чыккан иде. Капылт кузгалган буранда адашып, чокыр-чакырлы яланда бик озак юл таба алмыйча интекте. Аның күп тапкырлар: каты буран вакытларында карга күмелеп ятарга кирәк дип ишеткәне бар иде. Тик алай эшләргә Миңлебайның өс-башы начар, киеме жылы тотарлык түгел иде. Шуңа күрә ул ары барды, бире килде, жилнең кай яктан искәнен чамалап, юл табарга тырышты. Караңгы төшкәч, кайсы якның кайда икәнен аңламаслык хәлгә килде. Күңелен курку баса башлады, юл табуга өмете торган саен сүнә барып, нәрсә булса да барыбер инде дигән уй башыннан китмәде. Шундый вакытта дәүәтисе Йосыфның сүзләре исенә төште. Имеш, адашкан кешене шайтан үзенә сиздерми генә житәкләп гел бер тирәдә әйләндереп йөртә икән. Кеше шуны үзе сизми ди. Шул исенә төшкәч, Миңлебай жилгә арты белән борылды да, барыбер берәр авыл, я утар очрар әле дип, барды да барды. Күпме барганын, нинди жирләрдә йөргәнен ул инде хәзер исенә дә төшерә алмый. Хәле бетеп, берничә тапкыр утырып ял итәсе килде, тик ул утырмады. Утырса тора алмаячагын белә иде ул. Бәхетенә, Сөяксез Гайшә төн йокламыйча, юлга чыгып киткән кече улын, догалар укып, юл бәлаләреннән коткарырга ниятләп утыра иде. Төнге буран эчендә жемелдәгән кечкенә ут яктысын күргәч, Миңлебай үзенең котылганын аңлады.

Иртәнге табынга алар өчәү утырдылар. Зур табага өеп китергән кабартмаларны Миңлебай «ә» дигәнче юк итте. Шуның өстенә ит турап пешергән ярты табак токмачлы ашны да ашап бетерде. Рәйхана егетнең туймаганын сизде, ахры, чоланнан бер зур гына түгәрәк казылык алып керде. Миңлебай тартынып тормады, Гайшә карчыкның сокланып, аптырап карап торуына елмайгалап, ипи белән ул казылыкны да бөкләп куйды.

Бит сыпырып дога кылгач, кетмәгәндә килеп чыккан кунак малтуарны, йорт тирәләрен карап, андагы эшләрне бетереп керде. Рәйхана өйлә ашын әзерләде. Кызның очына-очына, бер кереп, бер чыгып йөргәнен Гайшә әби уйчанланган күзләре белән дәшми-тынмый гына күзәтеп утырды да, Рәйханага бер киңәш биреп куйды:

— Бу бәндә, балам, өйләнмәгән егеткә охшаган, тик үзе бик ярлы кеше баласыдыр. Киткән вакытында син аңа, юл уңае булса, кергәләп йөре, диген.

Өйләдән соң Миңлебай юлга чыкты. Рәйхана аңа өр-яңа жылы чолгаулар белән яңа үреп бетергән матур чабаталар бирде, капка төбенә кадәр озата чыкты. Озата чыкты да капканы япкан чакта, ояла-ояла, тотлыга-тотлыга, Гайшә әби өйрәткән сүзләрне әйтте.

Миңлебай китте. Рәйхана исә егет ераклашкан саен әле туып та өлгермәгән өметенең себергән буран астында күмелә баруын сизенеп басып калды.

Ай ярым вакыт үтүгә Миңлебай, Рәйханаләр өенә килеп, авылның иң комсыз кешесенә ялчылыкка керде. Кара яздан, ак карлар төшкәнче, Әмир мишәрләренә аптырап сөйләргә жим булды: Ярулла бай ялчысы ифрат күп ашый һәм аңардан да күбрәк эшли икән! Халыкның иң аптыраганы — гомер буе комсызлыгы белән авылда дан тоткан Яруллаunion ялчысыннан зарланмавы иде. Алай-болай Миңлебайның күп ашавы турында сүз чыкса, Ярулла сүзне кыска тотты:

— Ашасын!

Көз житеп, кар төшәр вакытта Зиреклебашның түбән очы атна буена шаулап алды. Матур гына кола бия җигеп, арбасына аяклары бәйләнгән ике сарык салып, артка бер тана бәйләп, чибәр яшь бичәсен утыртып, авылга Миңлебай кайтып төште. Аларны каршы алырга чыккан Вәликәй карт белән карчыгы каушауларыннан капка ача алмый азапландылар. Миңлебай капканы этисенә үзе ачты. Шуны ачканда атасының колагына нәрсәдер пышылдап та өлгерде. Миңлебай хатынлыкка чатан мишәр кызы алып кайткан икән дигән хәбәрдән авыл бер гөрләп алды да тынды. Рәйхана каенана белән каенатасына да, күршеләргә дә ярады. Уңган булып чыкты Миңлебайның чатан хатыны. Шул уңганлыгы, түгәрәк тәне һәм бигрәк тә аш-суга оста булуы белән ошады Рәйхана Миңлебайга. Үзе холыкка җиңел, кызу канлы иде Вәликәй Капар малае Миңлебай. Атасыннан килгән Капар кушаматын үсә-үсә аклады ул. Шул Капар кушаматы белән Миңлебай малай чагын үткәрде, егет булды, шул Капар исемен күтәреп ир уртасына житте. Хәзер инде Капар Миңлебае Краевкада штык сугышына өйрәнә, фашист шәүләсе төшкән мәрәгә ата, граната ыргыта, окоп казый — фашистлар белән сугышырга әзерләнә иде.

Миңлебай бала чактан ук күп ашый иде. Ике-өч яшендә ук Вәликәй абзый аны печән чапканда булсын, иген иккәндә булсын, арбаның ике тәртә арасына кертеп утырта да ашатырга тотына. Миңлебай күп итеп катыклы умач, боламык ашый — нәрсә бирсәләр дә, күпме бирсәләр дә кире какмый. Ә атасы Вәликәйгә бу кызык тоела. Ашап бетергәч, Миңлебай, камыт аякларын күтәреп җирдә яткан тәртәне генә атлап чыга алмый. Тулган корсак авыр, аяклар тыңламый. Миңлебай ике тәртә өстенә аркылы яткан этисен урап чыкмакчы була. Вәликәй үзе кет-кет көлә, үзе улын тәртә аша атлатырга тырыша, шуңардан ләззәт таба. Малайда да атасы каны. Озак аптырап тормый, кулына бирәр нәрсә эләктереп, яисә йодрыкларын йомарлап, атасына һөҗүм итә. Китә сугыш, китә көрәш. Шулай үсте Миңлебай. Күп ашаса да, малай-шалай аңардан көлә алмады. Көлә башласалар, Миңлебай күп сөйләп тормады: үзеннән ике-өч яшькә зур малайларны да бер сугуда тәгәрәтә торган булды. Бәләкәйдән күп ашап, күп эшләп, күп көрәшеп, күп сугышып үсте ул. Миңлебай үсә торды, үзенә ияреп ике даны да үсте: Миңлебай Капар күп ашый диделәр, өстәп, ашавыннан да күп эшли диделәр. Дөньялары фәкыйрь булганлыктан, колхозлар чыкканчы гел ялчылыкта йөрде ул. Атасы гомерен авылдан сигез чакрымдагы Урыс Карамалысының Юдашкин дигән кулагында ялчылыкта үткәрде. Тамагы ипигә, өсте киемгә туймады. Миңлебай да атасы кебек, ялчылык юлы белән китте. Егерме сигезенче елның март азакларында аңа унтугыз тулып үткән иде. Хажи Карга Миңлебайның күп ашаганын да, нык итеп эшләгәнен дә белә. Аңа Миңлебайның шәп эшләве, тик азрак ашавы кирәк. Шул теләгеннән Миңлебайга болай итебрәк аңлатып карый:

— Син, Миңлебай, энем, эшкә бик тә уңгансың инде, әй-йе. Бер чүмәләне бер генә кадап очырасың инде. Анысы дөрес. Тик миңә теге, ни бит әле... үзең беләсең бит инде, әй-йе... теге ашау ягыңны әйтәм. Еллар бик авыр килергә охшаган. Калиновка чувашлары да шулай диеп әйтәләр ди. Үзең беләсең, алар сихер-күрәзә ягына, ай-һай, осталар бит инде. Җәй корырак килсә, син азрак ашарга тырыш инде, энем, яме, алуын мин алам. Син гаеп итмә инде, дөнья эше бит, үзең беләсең...

Миңлебай моңа бик аптырап тормый, җавабы әзер:

— Ярар, Хажиәхмәт абзый! Килештек алай булгач. Минем бәхет бар ул — бу ел әйбәт киләчәк, күр дә тор. Алла кушып шулай булса, син минем ашаганга бик карап тормассың инде, ярармы?

Килешәләр болар. Ел чыннан да бик әйбәт килеп, үскән игеннең игечиге булмый. Миңлебай теләгәнчә ашап, житмәсә, сорап алып, җәй буе Хажи Карганың саран күңелен имгәтеп бетерә яза. Икенче ел язын тагын ялланырга килә бу Хажи Каргага. Әмма бай Миңлебайны алмый:

— Юк инде, энем, үткән елда да, бер утыруда бер бөтен икмәкне ашап бетерүләренне күреп, эчләремнең ничек өзелгәнен үзем генә беләм. Шуңа карап вакытыннан элек якты дөньядан китәр хәлем юк. Эшеңә сүзем юк, тик бу ел алмыйм, энем, бүтән җиргә яллан.

Әмирдән унган хатын алып кайткач, Миңлебай ялчылыкны ташлады. Аты да, сыеры да булгач, йортларына ямь керде. Атасы белән атна-ун көн эчендә читән абзар үреп алдылар, үзләре сыладылар. Колхозлар төзелә башлагач, Вәликәй абзый озак уйланып тормады. Бер кичне куйган әче балына Гобәй Бамбырны чакырды да, аның белән кич буе бал эчә-эчә сөйләште. Өйләнгән булса да, эчүдә олылардан тартынган Миңлебай аларны тавыш-тынсыз гына тыңлап утырды. Өч көн үтүгә, кола бияне җитәкләп, аталы-уллы колхозга керделәр. Монда, Юдашкин хуторында, беренче көннәреннән үк Миңлебай хатыны белән эре мөгезле мал карады. Дүрт елдан артык кайтмыйча эшләделәр. Миңлебай маллар ашатты, тирес түкте, Рәйхана сыерлар сауды. Беренче малайларына Миңгали, икенчесенә Габдерәшит исеме куштылар. Утыз алтынчы елны колхоз идарәсе Миңлебай белән Рәйханага, яхшы эшләгәннәре өчен, кулаклардан калган бер йортны арзан гына хакка сатып бирде. Бер ай эчендә дус-иш, күрше-күлән ярдәме белән шул йортны Миңлебай атасының бакчасы артына күчереп утыртты. Утыз җиденче елны аларның тагын бер уллары туды. Унган хатын ул таба дигәннәре дөрес булды, ахрысы. Рәйхана малайлар тапкан саен Миңлебайның базары күтәрелә барды. Хатыны өченчегә малай — Габдерәхимне тапкач, Миңлебай, шатлыгын эченә сыйдыра алмыйча, күршесе Хәмиткә:

— Ну, күрше! Мин хатынны малайлар табарга көйләп куйдым бит әй! Шушы табуы белән тапса, бер ун елдан урамыбызга тик үзем теләгән кешеләрне генә кертә башлыйм инде. Күңелгә ошамаганнарын кире борам да җибәрәм,— дигән.

Тагын ике ел үтүгә Рәйхана үзенә охшаган кыз бала тапты.

Шәп яши башладылар Миңлебайлар сугыш алдыннан. Атасы Вәликәй абзый, күзен ачып, гомердә чабата белән ыштырдан башканы күрмәгән аякларына кышын пима, язын-көзен итек кия башлады. Тик күпме генә киеп караса да, читеккә өйрәнә алмады Вәликәй карт. Читек киде исә, үзен урамда эшсез йөргән кеше сыман сизә иде ул. Кырыгынчы елның көзендә хезмәт көненә алган игеннең иге-чиге булмады. Ике гаилә өчен уртак булган келәт кебек нәрсәнең буралары шыгырдап торган бодай, тары, солы, арыш белән тулды. Халыкка иген таратып йөргән Шәрифә Тимеркәе, соңгы ике йөк алтын кебек бодайны салырга урыннары табылмагач, Миңлебайларның ишегалды уртасына аударып китте. Аударуын аударды, тик Миңлебайның холкын яхшы белгәнгә, алар капкасы каршыннан ике-өч көн атын гел юыртып кына үтеп йөрде. Кем белә ул Капарлар уенда нәрсә барын: ник бодайны ишегалдына түгеп киттең диеп, казык күтәреп куа чыкса да, берни эшли алмыйсың. Игенне күп алган кайбер кешеләр, салырга урын булмагач, йөк белән килгән Тимеркәйне, житте, урын юк диеп, кире борып та җибәргәләделәр.

Кич белән атына утырып эштән кайткан Миңлебай, капкасын ачып, ишегалдына килеп кергәч, көлеп җибәрде. Үзе кебек җитез улы Габдерәшит бодай өеме яныннан таяк белән кош-корт куа, ә өч яшьлек Габдерәхиме, бодай өеменең өстенә менеп утырган да, зәңгәре чыкканчы кырылган такыр башына учлап-учлап бодай сибә. Гәрәбә кебек бөртекләр катыкка буялган күкрәгенә, корсагына сикереп төшә, аннан бодай өеменә килеп кушыла иде. Габдерәхимгә кызык та, рәхәт тә, ахрысы, чөнки ул шырык-шырык бертуктаусыз көлә. Ә абзар ягыннан, йөзенә чыккан елмаюын тыя алмыйча, кулына сөт тулы чиләген күтәргән хатыны килә...

Мәскәү янындагы Гороховка авылында барган кул сугышында немец автоматыннан чыккан биш пулядан һәлак булды Миңлебай. Мус-

кулллардан гына торган көчле гәүдәсе дөнья белән саубуллаша алмыйча озак тартышты. Сул кулының тырнакларын каера-каера, бозланып каткан, тапталган карны тырнап җан бирде ул. Кул сугышы бетеп. Гороховка азат ителгәннән соң, Миңлебайны авылдашлары Басыйр белән Ике Су Арасы Гаяз эзләп тапты. Алар килеп җиткәндә Миңлебайның битенә төшкән кар бөртекләре эреми иде инде.



8

Алты хатын азык-төлек төягән арбаны үлән үскән ташландык юлдан Краевкага таба өстери. Алар өчен хәзер кояш эссесе дә, арый башлаган аяклар да, күперсез елга, чокыр-чакырлар да, туза башлаган чабаталар да юк. Алда — моңарчы күрмәгән Краевка да, таза гәүдәле, киң күкрәкле ирләре генә бар. Ә тагын да әллә кайларда, кояш баеган якларда, танкка атланып, бала-чагаларны, карт-корыларны таптатып, илне басып килгән фашистлар бар. Шул фашистларны туктатырга, аларга каршы сугышка китәргә әзерләнеп Краевкада яткан ирләре бар.

Юлга чыкканнан бирле төпкә җигелеп тарткан көч тә, хатыннарның төп терәге дә — Мөнәвәрә белән Зөбәйдә булды. Киленнәр яшь, Миңҗамал буйга бәләкәй, көчсез, Рәйхана гарип, шуңа күрә йөкне әлеге ике хатын тартты. Менә Курмайны үтеп, үрне менделәр, Карамалыга дип уңга борылдылар. Бу урында юл бер-берсенә охшаган өч сукмакка әверелде. Уртадагысында ат тоягы эзе, ике кырыйдагыларында — арба тәгәрмәчләренеке. Заманында олы саналган юл Карамалы аша Краевкага, аннан соң Агыйдел якларына сузыла. Элек бу тарафның кара туфрагында үскән алтын бөртекләре кебек игенне, сарык йонын, төрле хайван тиреләрен, түшкә-түшкә итләрне һәм бәйләм-бәйләм чабаталарны зур баржаларга төяп озатканнар. Агыйделдән Камага чыгып, аннан мәшһүр Идел буенча китә торган булганнар ул баржалар. Аннан арысын бу якта яшәгән халык бик белеп тә бетерми. Тик зимагур булып яки кызыл мал белән йөргән, елан аягын кискән бәндәләр генә ул баржаларның, данлы Казанны үткәч, я Мәскәүгә инде алар, яисә Мәкәрҗәнең үзенә үк, диеп җибәрәләр. Ә хәзер борынгы юл ташландык хәлдә — һәрбер чокыры, һәрбер үре хатыннар өчен авырайганнан-авырая бара. Тау үрен менгән саен туктап ял итәсе, кызышып тирләгән эссе тәнне җилгә ачып суытасы килә, утырып, я ятып, арыган аякларга аз гына булса да ял бирәсе килә. Тик хатыннар туктамый. Аларны сугышка китәргә әзерләнеп яткан ирләре көтә, кире авылга әйләнеп кайтуга, колхоз яланнарында коела башлаган бодай кырлары көтә...

Уналты яшеннән кияүгә чыгып, биш бала табып, шуларның тере калган икесен үстереп килгән Зөбәйдә, ике тәртә арасына җигелеп, тау түбән юырта. Аның үз этисе Җамалетдин Зөбәйдәгә биш яшьләр чамасы булганда, ни сәбәп беләндер, кинәт үлеп китте. Ул үлгәч, күрше-тирә карчыклары, Җамалетдин сугыштан йөрәк тамырларын өздереп кайткан икән, шуңа үлгән икән, диделәр. Нәрсә икәнен белә алмадылар. Җамали урман кискән җирдән, ах-ух килеп кайтты да иртән тора алмады. Әнкәсе Садрикамал алып килгән Гыйззениса әби бик озак догалар укыды, өшкеренде-төкеренде, су жылытып Җамалиның күкрәгенә май эрекмәннәре дә ябып карады. Ахырда, урман зәхмәте тигән моңа, кызым, урман зәхмәте диде. Шулай итеп, аның әфсен-төфсене файда бирмәде. Шуннан соң алар әнисе белән икәү генә торып калдылар. Әнисенә ул чакта егерме дүрт яшь тулып кына килә иде әле. Ире үлгәч, Садрикамал аягын ат итте, кулын камчы итте, иллә дөньяны күтәрергә тырышты. Кешегә ялланып йон эрләде, көнлеккә йөрде, палас сукты.

Зөбәйдә кияүгә иртә чыкты. Ире Сәйфулланың үги әнисе каты күңелле хатын иде. Тик, тормыш үги итсә дә, Сәйфулла шат күңелле, җырга-биюгә ихлас булып үскән иде. Җырламаган җыры, белмәгән биюе юк иде. Чуваш авылына барса, аларның үгез куыгыннан ясаган сыбызгыларына тыпырдады, урыс авылына барып эләккән чагында шат күңелле марҗа кызлары белән «Барыня»ны, Золотоножка авылына барып чыккан чакларында тулы түшле украин чибәрләре белән үзе дә белмәгән әллә нинди биюләр биеде. Матур да иде Сәйфулла, елгыр да иде. Шуңа күрә Зөбәйдәгә килеп юлыгуы булды, ике яшь күңел, бер-берсен тапканга шатланышып, кушылдылар да куйдылар. Тик өйләнешеп бергә тора башлагач кына дөньяның әчесен-төчесен татырга туры килде.

Кара Гобәй, үги булса да, яхшы ата була алды Зөбәйдәгә. Сугуның, әрләүнең нәрсә икәнен белмәде, үз гомерендә сүгенмәде, авызына аракы капмады, эче балны да бик сирәк кенә авызына алды. Андый чагында ул бала-чагага күренмәскә тырышты. Үги аналы Сәйфуллаларга килен булып төшкәч, аларның икесенә дә авыр булды. Сәйфулланың атасы да кырыс холыклы иде. Шуның өстенә яшь хатынның арттан әйткәнен бик тә тыңлаучан иде. Сәйфулла белән Зөбәйдәнең беренче кызлары туып, өч айлык булгач, куып җибәргән кебек итеп башка чыгардылар...

Бу мең тугыз йөз егерме тугызынчы елның арыш урагына төшкән чак иде. Арышны Локман Атрубы дигән җирдә дүртәүләп урдылар. Аталары Зәйнулла, Сәйфулла белән Зөбәйдә һәм Сәйфулланың буйга җитеп килгән сеңелесе Маһинур. Зөбәйдә үзе белән өч айлык имчәк баласын да ала иде. Атна-ун көн тирәсе бер кайтып, бер куныл эшләгәннән соң, җомгага каршы бераз иртәрәк кайтып, мунча керделәр, өс-башны алыштырдылар. Аталары Зәйнулла кичтән үк Сәйфуллага:

— Иртәгә иртүк төшеп тугайда көлтә бавына күрән урыгыз, ике көнгә җитәрлек булсын. Бик озак маташмагыз, ишетсен колагың, тизрәк кыймылдагыз,— дип әйтеп куйган иде.

Иртән барысын да үзе уятты, йорт тирәсен ыгы-зыгы китереп, таң беленеп килгән вакытта чыгып китте. Калган халык та, тиз генә эшләрен бетереп, ат җигеп тугайга юнәлде. Аларны озата чыккан үги аналары, капканы япкач, авызын каплап бер иснәнде дә кереп йокларга ятты.

Тугайга төшеп өчәүләшеп күп итеп күрән урдылар. Зөбәйдә әле елаган баланы имезде, әле күрән урды, урылганын арбага төяде. Күрәнне кирәк кадәр урып төягәнче байтак вакыт үтте, кояш төшкелеккә күтәрелеп килгәндә генә алар кайтырга чыктылар. Сөзәк кенә күтәрелгән юл белән ярты чакрым тирәсе китәргә өлгермәделәр, Маһинур:

— Абый, карале, әнә теге каршы килгән кешенең атлаулары безнең әтинекенә охшаган, әллә чыннан да шул инде,— диде.

Барысы да борчылып алга төбәлделәр. Дөрестән дә, юлны тотырып каршыларына килгән кеше аталары Зәйнулла иде. Кызу-кызу атлап якынлашты да атын йөгәненнән тартып туктатты. Сәйфулла сикереп арбадан төште.

— Нәрсә эшләп йөрдең бу вакытка хәтле? Кояш кая менеп җитте бит, ә? — дип җикеренде карт улына.

— Үзең кушканча күрән урдык бит, күрмисеңмени?..

— Нинди уру ди ул тагын көне буе, эт ялкавы нәрсә...

Зәйнулла кулындагы каеш чыбыркы, еландай уралып, Сәйфулланың күлмәкчән генә аркасын яндырды. Арбадагылар чырылдап җибәрделәр, ә Сәйфулла, тәненә ут тигәндәй, үрсәләнде.

— Чырылдамагыз, марҗалар, мин сезгә дә өлеш чыгарырмын.— Аннан килененә җикеренде: — Төш арбадан, нәрсә утырасың җәелеп...

Зөбәйдәне йөк өстеннән куып төшерде дә арбадагы бала бишеген, таганны, әллә нинди төеннәрне юл читенә алып очырды. Шул уңайдан бәләкәй казан, җиз комган да җиргә очты. Аннан каенатасы сикереп арбага

менеп утырды да чыбыркысы белән атка сыдырды. Юл читендә аркасы әрнегәнгә чыдый алмыйча басып торган Сәйфулла, кызчыгын кысып кочаклаган, куркудан агарынган Зөбәйдә, мышык-мышык елаган Мәһинур, төрлесе төрле җирдә аунап яткан әйберләр калды.

Кояш өйләне узганда, бала, бишек, таган, казан-комганнар күтәргән Сәйфулла белән Зөбәйдә, кеше күзенә күренмәскә тырышып, читән буйларыннан, ташландык тыкрыклардан йорт эчендә торган кечкенә генә җәйге өйгә кайтып керделәр. Бер-берсенә карарга уңайсызланып, байтак вакыт сүзсез генә сәкедә утырдылар. Сәйфуллага атасының Зөбәйдә алдында тартынмый-нитми каеш чыбыркы белән сыдырганы өчен уңайсыз иде. Өйләнешкәннән бирле, үзенең егет чагы үтеп, хәзер инде мин дә бала атасы дип горурланып йөри иде Сәйфулла. Ә атасы аны бакчага төшеп суган урлап йөргән малай-шалай хәтле дә күрми икән. Зөбәйдәнең дә йөрәге яна. Мондыйны күреп үсмәгән иде бит ул. Сөеп, яратып килгән, туктаусыз эшләп йөргән Сәйфулланы кулмәге, тәне ярылганчы каеш чыбыркы белән кыйнасыннар инде. Ярасына берәр нәрсә сөртер иде — бөтен булган нәрсә олы өйдә. Күршеләргә керер иде — сиздерәсе килми...

Утыра торгач, Сәйфулласы ниндидер бер уйга килде.

— Ярар, мин әнигә кереп чыгыйм әле, ул нәрсә әйтер икән.

Сәйфулланың үз энисе үлгәнгә ун елдан артык инде. Немец пленыннан кайткач, Зәйнулла ике тапкыр хатын алып караган иде, уңа алмады. Беренчесе көн-төн йоклауны, күршән-иннекне яратты. Анысын куып җибәрде. Икенчене алган иде, анысы тәмле тамак булып чыкты. Зәйнулланың җыенып эшкә чыгып китүе булды, әллә нәрсәләр пешерде, чаж да чож китерде, кыздырды, эче бал куйды, кесәсеннән конфетын өзмәде. Анысын да куды Зәйнулла. Шуннан соң күрше карчыгы Зәйнулланы урамнарда озак чәйнәде, белмим инде, моңа ярарлык хатын бар микән тирә-яктагы авылларда диде. Агыйделнең аръягыннан, бу якны белмәгән кешеләр арасыннан гына тапса табар диде. Хәзерге көндә торган хатыны Хәнифә начар булмады Зәйнулла өчен. Ике бала өстенә килгәч, ел ярым үтүгә, бер малай тапты, ә үткән ел кызы булды. Хәмидулласы да, Кәшифәсе дә таза, матур булып үсеп киләләр иде. Тик менә үги улы Сәйфулла унсигезе тулыр-тулмаста көтмәгән җирдән өйләнеп ташлады. Күтәрелеп, баеп килгән дөньяда хәзерге көндә ике гаилә. Хәнифә, башка чыгарырга кирәк шуларны дип, көн тукыды Зәйнуллага, төн тукыды. Тукулары бушка китмәгән, күрәсең, морадына ирешеп килә хәзер. Инеш буендагы сукмактан күтәренеп кайтып килгән Сәйфулла белән Зөбәйдәне күргәч, Хәнифәнең эченә шомлылык белән бер төрле куану хисе килеп керде. Шулай да куануын сиздермәде, Сәйфулла зур йортка килеп кергәч, аңа кушылып ах та ух килде, кайгырды, аның ярылган аркасын карап кызганды. Шулай эшләсә дә, сүз азагын үзенә кирәкчә бетерде:

— Атаңнан узып бернәрсә дә эшли алмыйм инде, балам. Аның кызу канлы икәнен миннән яхшырак беләсең, котик инде кайтканын.

Утыр да димәде, чәй куям, эчәргә кирәгез дә димәде, шул юк-бар сүзләр белән озатты Сәйфулланы.

Зөбәйдә әниләренә барып кергәндә, Садрикамал алты яшьлек кызы Асияга ботка ашатып утыра иде.

— Әйдүк, әйдүк, киңү! Мактап кына йөрисез икән, әйдә, түрдән үтегез, утырыгыз табын янына.

Кызыл юрганга төрелгән баланы чиша-чиша, Садрикамал аның белән сөйләшергә тотынды:

— Үти-ти-ти-ти, минем үсә башлаган кызым, бигрәк чибәр икән дә бигрәк акыллы икән. Әйдәле, кызым, менә шушында ятып тор, әниең чәй эчеп алсын. Менә-ә шу-у-лаай!

Чәй янында нәрсәдер сизенгән күзләре белән киявенә дә, кызына да караштыргалап утырды да җайлап кына сораша башлады:

— Арыш урагына төшкән идегез, әллә кода бүген бармаска булдымы?

Сәйфулла дәшмәде. Зөбәйдәнең елый башлаганын күргәч, тынычсызланып өстәп куйды:

— Капкадан кереп килгән чагыгызда ук күңелемә әллә нинди шом төшкән иде аны: мондый уттай эш вакытында нигә болар, бала күтәреп, урам буйлап йөри икән, дип уйлаган ием. Я, күзеңне бетереп елап утырма монда, мин сине алай җебек булырга өйрәтеп үстермәдем. Олы кешенең холкы шулайрак инде аның. Коданың әзрәк кызулыгы бар инде, нишләтәсең. Ир кешедә була инде ул алай гына. Чәй эчеп бетергәч, кайтыгыз үзегезгә. Бүген кич үкенер алар, менә әйткән не әни диярсез. Иртән торыгыз да, бернәрсә дә булмагандай, арбасына чыгыгыз да утырыгыз. Уттай эш вакытында урырга дастуен, эшкә атлыгып торган әзмәвердәй ике кешене алып бармый калмаслар. Син дә, кияү, холкыңны тый инде берүк, сыртың белән тора күрмә, ата бит ул. Ә син, кызым Зөбәйдә, минем элек-электән үк әйткәнемне исеңдә тот: чәчең белән җир себер миңа дисәң, тик каенанаң белән каенатаңа яра, хезмәт күрсәт. Барыгыз, бар, эшегезне күрсәтегез иң әүвәл, аннан күз күрер нәрсә эшләргә икәнен, иншалла.

Бераздан тавыш-тынсыз гына үзләренә кайтып керделәр. Туганнан бирле эшләп үскән кешегә иң авыр хәл — эшсез тик утыру. Зөбәйдә баласы белән мәшгуль, ә Сәйфулла кая керергә, нәрсә эшләргә белмичә җәфаланды. Караңгы төшеп, ут алгач кына яланнан аталары белән Маһинур кайтып төште. Тик такта өйгә керүче дә, чыгучы да булмады. Ясаклыдан ашап кайткан белән йокларга яттылар. Ниятләре — иртән, чакырмасалар да, арбага чыгарга да утырырга, ялангa эшкә — арыш урырга китәргә иде.

Ананың тынычсызлыгы сөт белән балага да бирелә бит. Бәби кичтән үк көйсезләнде, нәрсәгәдер үрсәләнде, шыңшыды, йокламады. Бала өчен тынычсызланып, яшь ана белән ата да юньләп йоклый алмадылар. Тик төн таңга авышкан чакта гына өчесе дә изрәп йокыга талдылар.

Байгара таулары артыннан шәфәкъ аллана башлаганда, беренче булып Зөбәйдә уянды:

— Тор әле, Сәйфулла дим, тор! Әткәйләр китә башлар, йоклап кала күрмик.

Сәйфулла тиз генә торып, ишек төбендәге комганны әләктерде дә юынырга чыгып китте. Чыкты да шунда ук кире борылып керде:

— Киткәннәр бит...

— Ничек киткәннәр?

— Ничек, ничек? Капка тишеп, ничек булсын.

Кичке өметләре тагын киселде. Зөбәйдә бала имезгәндә, Сәйфулла бер керде, бер чыкты — үзенә урын таба алмады. Баласын имезеп, биләп йокларга яткыргач, Зөбәйдә сыер саварга исәпләп чыгып китте. Чыкты да, аз гына вакыт үтүгә, кире борылып керде:

— Әнкәй сыерны саварга рөхсәт итми, «үзем савам, үзем куам», ди.

— Кумагае, чәнчелсен лә! Чукынсын сыеры белән! Әйдә, беткән дөнья беткән, ятыйк та йоклыйк.

— Кит, юньсез, төн үтеп беткән, нинди йокы кирәк инде сиңа тагын.

— Әй, төкер лә дөньясына. Бер юне чыгар әле. Мин кичә үк бер уй уйлый башлаган идем, шуның очына чыкмасаммы бүген...

Кайвакыт кичтән уйлап, иртәгә эшләрмен дип әзерләп куйган уйлар, яңа көн туып, кояш чыкмас борын ук бөтән төрлегә әйләнеп киткәли. Бүген дә шулай булды. Сәйфулла сүзен бетерә алмады, такта өйнең ишеге ачылып, аннан киндер капчык тоткан Хәнифә килеп керде. Ярты-лаш та тулы булмаган капчыкны сәкегә китереп утыртты да Сәйфуллага дәште:

— Менә атагыз сезгә кертеп бирергә кушты. Бездән сезгә тиешле нәрсә шушы. Бүгеннән башлап үз көннәрен үзләре күрсен, бездән фатиха диде.

Шул сүзләрне, кабалана-кабалана, бер-берсенә тәсбих тешләре кебек тезде дә, берәр нәрсә сорамасалар ярар иде дигән кебек, артыннан ишегеп дә япмыйча, шундук чыгып та китте. Сәйфулла, аптыравын яшерә алмыйча, капчыкны бәйләгән сүс бауны чишеп карады.

— Арыш оны бу. Пот ярым чамасы бардыр. Әллә әремле инде, кабып карале?

— Кит, кирәге юк. Кире кертеп бир оннарын. Әй, ходаем, тагын нәрсәләр күрәселәребез бардыр инде...— дип, Зөбәйдә еларга керешгте.

— Күрде ди, күрми ни! Патша заманыдыр бу сиңа! Этлеккә киткәч, мин дә эт!

Сәйфулла чөйдән салам эшләпәсен алып киде дә, чыгып китәргә дип, ишеккә табан борылды.

— Карале, мин берүзем нишлим монда? Кая китәсең мине ташлап дәшми-тынмый...

— Ташламыйм, ташламыйм, курыкма. Көрпә бабакайга барам әле. Ул бит безнең иң зурыбыз. Син өйдә генә утыр, чыгып йөрмә, хәзергә әниләреңә дә барма. Мин аңа батрак урынына ничәмә-ничә еллар эшләгәннән соң, буш кул белән башка чыгармакчы. Ничек җинел генә котылмакчы була. Иске заман түгел хәзер.

Ашамый-эчми чыгып киткән ирен кызганып, ялгызы утырды такта өй эчендә Зөбәйдә. Азаккы сынык арыш ипиен суга манып кына ашаган булса да, үзен аңарга караганда тук хис итте. Бер утырды, бер торды, үзенә урын, җанына тынычлык таба алмады.

Сәйфулла барып кергәндә, Гобәйдулла бабакае арба тирәсендә яланга китәргә әзерләнеп йөри иде. Иртәнге кунак сүзен арба янынннан китмичә генә тыңлый башлаган иде, мәсьәләнең асылына төшә башлагач, өй эченә чакырды:

— Әйдәле, улым, өйгә керик әле!

Сәйфулланың сүзе беткәч, бабай, атаң әле кайда дип сорады да озак кына дәшми утырды.

— Кая, Өммеһани, сыйлале безне улым белән,— диде ахырда Гобәй хатынына.

Ашап-эчеп, дога кылгач, Гобәй Көрпә Сәйфулланы капка төбенә кадәр озата чыкты. Табыннан торып кузгала башлау белән, Өммеһани Сәйфулланың кулына бер төенчек азык белән бер чүлмәк катык тоттырды:

— Монысын, Сәйфулла улым, киленгә бирерсең. Кайгырма, улым, Гобәйдулла бабакаеңның исәнлеген теләп дә ходай тәгаләдән ярдәм сора. Бабакаең тотынгач, җиренә җиткерә ул эшне, менә күрерсең.

Капка төбенә чыккач, бер мизгелгә тукталдылар.

— Бар кайт, улым, өйдә генә утыр, әллә кая китә күрмә. Әнкәң кая бардың дип сораса, әйтмә кайда йөргәнеңне. Влач үзебезнеке. Хәзер аны акылга утыртса, Бамбыр гына утырта инде, башка кеше булдыра алмас. Ул юньсезне юньгә кертеп булмас инде, вакыты үткән аның комсызланып. Тик сине рәнҗетергә ирек куймабыз.

Көтү кайтыр алдыннан Зәйнулланың ишегалдына авыл советы председателе Бамбыр Гобәй, аның секретаре Габдулла Төрек һәм Гобәй Көрпә килеп керделәр.

— Исәнлек-иминлекме, Зәйнулла, мал-туарлар, бала-чагалар исәннәрме, дөньялар барамы? — диделәр сагаеп калган өй хуҗасына.

— Аллага шөкер, исәннәрбез хәзергә,— дип, Зәйнулла тегеләр белән коры кына исәнләште.

Бамбырны күргәч үк аңлады Зәйнулла боларның нинди эш белән йөргәннәрен. Җирән сакал-мыеклы Бамбырны, аның янында кыҗрап торган абзасын күргәч, Зәйнулланың эченә суык йөгерде. «Юньлегә йөрми инде болар төнгә каршы, теге чучканың эше инде бу. Җыен йолкыш, аналарын сатыйм»,— дип, авыз эченнән генә мыгырданды ул.

— Я, Зәйнулла, игеннәр ничек бу ел, уңдымы?

— Уңдымы дип, эшләсәң уңа инде. Киләткә керткәннән соң билгеле була инде уңганы-уңмаганы.

— Эшләргә синдә кул көче җитәрлек инде. Улың, киленең, кызың, хатының белән үзең. Хатының өйдә пешеренеп, бала-чага карап торса да, зур ярдәм...

Бамбыр Гобәйдулла эшкә, үз дәрәҗәсен белеп, кабаланмыйча тотынды. Мең тугыз йөз тугызынчы елны, кар төшәр алдыннан патша хезмәтеннән кайткач, дус-ишләре, туган-тумачаларына анда күргәннәрен сөйләгәндә:

— Мин солдатта бомбардир булган кеше,— дип кенә җибәрергә ярата иде ул. Берничә җирдә шул сүзләрне кабатлавы булды, авыл халкы, иртәгәгә калдырмыйча, аңа Бамбыр Гобәйдулла дигән кушаматны тагып та куйды. Ишеткән чакларында да ул аңа ачуланмый, чөнки тумыштан бирелгән табигый акылы белән бүтәннәр аңламаганны аңлый: авыл халкы теләнә кушамат булып кергәнне алла үзе дә бетерә алмый. Авылда халык аны ярата, үз итә. Бамбырга киңәш сорап барсаң, ул акыллы, төпле киңәш бирә, ярдәм сорап барсаң, үзеннән соңгысын өзеп булса да, ярдәм итә. Шуңа күрә авылның өлкәне Гобәй Көрпә аңарга авыл Советы председателе итеп кенә түгел, акыллы, төпле булганга да ярдәм сорап барды.

Зәйнулла белән сүзне Бамбыр башлады, ә Гобәй Көрпә ник бер сүз әйтсен. Аңлый ул: хәзер Зәйнулла, эчтән кыза барып, килүчеләргә бәйләнергә юл эзләячәк. Ә Бамбыр белән эш башкача булачак, Зәйнуллага кызып китәргә җай калмаячак. Бамбыр — урындагы кеше, Дюльдин отрядында партизан булып, акларга каршы сугышкан, үнсигезенче елның язында Зәйнуллага байларның җирен бүлеп биргән кеше. Гобәй Көрпә белә: Бамбыр сүзне төпле итеп сөйли...

— ...ярый, ярый, арышны яртылаш ургансыз икән, әйбәт булган. Я, килен ничек соң, килен өлгерәме? Әнкәсенә охшаса, уңган булыр ул. Тик имчәк баласы булгач, авырракка киләдер инде. Нәселе бик уңганнардан инде киленеңнең, игелеген күрергә язсын...

Зәйнулланың түземе бетте:

— Сез нәрсә мине бала-чага кебек кыйландырасыз. Нәрсә дип килдегез монда йортыма, ә? Минем сезнең белән тел чарлап торырга вакытым юк, каян килгәнсез, әйдә шунда...

— Чү-чү, Зәйнулла, кызмый тор әле син алай сәбәпсез! Без монда уйнарга диеп килмәдек. Нindirәк итеп сөйләшмәкче буласың син безнең белән, ә? Элекке заман булган булса, бу сүзләрең өчен староста Җәләли сиңа әллә кайчан ике күз араңа берне таягы белән тондырыр иде инде. Алай сүз бүлеп сөйләшергә гайрәтең житкәч, әйдә, рәхим ит, күчик төп эшкә. Менә сиңа сорау алайса: улың Сәйфулланы хатыны һәм имчәк баласы белән башка чыгарасыңмыни?

— Кешедән сорап тормадым, чыгардым!

— Ярар алайса, анысын әйбәт иткәнсең. Шуннан нәрсәләр бирдең инде аларны башка чыгарганда?

— ...

— Я, нигә дәшмисең? — дип кабат сорады Бамбыр.

— Сезнең ни эшегез бар анда?

— Безнең бөтен нәрсәдә дә эшебез бар, чөнки без совет влачы. Имчәк баласын күтәреп, хатынын җитәкләп, ул авыл буйлап хәер сорарга чыгып китәргә тиешмени, ә?

— Эшләсен, туйдырыр тамагын. Эшләмәгән ашамый дисез бит. Эшләсә...

— Тукта, мине тыңла. Нигә, ул синдә унтугыз яшькә җиткәнче түшәмгә төкереп эшләмичә тик яттымыни? Бар әле, адаш абзый, авырсынмасаң, алып чык әле ул егетне монда. Мин үзем сорашыйм әле аңардан. Син, Габдулла энем, мин сораганны, әтисе-улы сөйләгәнне яза бар. Ни өчен дисәң, эш монда зурга китәргә охшаган. Кирәк вакытта

шул язулардан гына карап искә төшерә торган нәрсәләр булуы мөмкин. Монысы ярар,— дип, Бамбыр сүзнең бер өлеше беткәнне белдерде.— Азрак кирегә чигенеп әйтим әле: син бит өеңә дә чакыра белмисең. Безнең татарда юк эшне эшлисең, Зәйнулла, ай-һай, ялгышасың. Хәзер картая торган чакларыбыз җитте, ә яшьләр көч ала, алдагы тормыш аларныкы булачак бит, азрак уйлый белергә кирәк.

Ул арада Гобәй Көрпә Сәйфулланы алып чыкты.

— Исәннәрмесез, абзыйлар?

— Әйбәт кенә әле, улым, үзең исән-саумы?

Бамбыр Сәйфуллага кул биреп исәнләште дә, бер якка ишарәләп, болай диде:

— Аяк өстендә сөйләшә торган сүз түгел бу, хуҗа чакырмаса да, әйдәгез, әнә анда, келәт алдына барып утырып сөйләшик. Безнең дә аяклар кәҗүнни түгел бит.

Келәт янында яткан бүрәнәләргә тезелешеп утырдылар. Алларында көрәктәй зур кулларын кая куярга белмичә бер Сәйфулла басып калды.

— Я, улым, сөйлә инде безгә, язгы чәчү вакытында атаңа иген чәчештеңме?

— Чәчештем.

— Ничек итеп?

— Куна ятып чәчтем. Башта җир сөрдем, кул белән чәчтем, анннары тырмаладым.

— Тубал белән йөри беләсеңмени?

— Белмичә, нәрсәсе бар аның? Ундүрт яшьтән бирле йөрим мин тубал белән.

— Тырмага кайчаннан бирле йөрисең?

— Үземне үзем белгәннән бирле.

— Печәнне күп әзерләдегезме?

— Йортка унсигез фурман китердек, яланда тагын өч кибәнебез бар.

— Печән әзерләгәндә кеше ялладыгызмы?

— Юк, ялламадык, үзебез эшләдек бар эшне дә. Әти кибән башында торды, мин ыргыттым, Зөбәйдә белән сеңелем чүмәлә тарттылар.

— Ә әниегез?

— Безнең әни ялан эшләрен яратмый ул, аннан балалары да бар бит.

— Ярар, аңлашылды монысы. Әтиең башка чыгара икән сезне.

— Иртән әни шулай диде шул.

— Нәрсә белән чыгардылар соң?

— Пот ярым тирәсе булыр, арыш оны бирделәр...

Ишегалдында утырганнарның берсе дә дәшмәде.

— Ничек яшәргә уйлыйсың инде хәзер?

— Белмим...

Келәт алдында авыр тынлык урнашты.

Бамбыр, урыннан торып, Сәйфулланың иңенә сул кулын салып, уңы белән такта өйгә күрсәтте, әкрен генә әйтте:

— Бар, улым, кереп тор, без, зурлар, сөйләшик әле монда азрак...— Аннан соң кире килеп урынына утырды, кесәсеннән янчыгын чыгарды: — Син, адаш абзый, миңа рөхсәт ит инде, бу нәрсәне азрак төтәтеп җибәрим, югыйсә, баш әңке-меңке килә сыман.

— Тарт, энем, тарт,— диде Гобәй Көрпә.

Бик ныклап бер-бер артлы ике тапкыр суыргач, Бамбыр Зәйнуллага дәште:

— Я, Зәйнулла, син нәрсә әйтәсең инде безгә?

— Бернәрсә дә әйтмим, чыгарган, эше беткән...

Гобәй Көрпә чыдамады, утырган җиреннән сикереп торды:

— Җирбит, мин сине...

— Утыр, адаш абзый, утыр! Иң әүвәл совет влачы исеменнән мин сөйләшим әле. Габдулла, син туктама, энем, яза бар,— дип, Бамбыр секретарьга да дәшеп алды. Аннары кабат Зәйнуллага борылып:

— Бу малай синең баланмы? — дип сорады. Сорау мыскыллау кебек килеп чыкты.

— Нигә, минеке булмыйча, кемнеке булсын, минеке...

— Шулаймы? — дип гаҗәпләнгән булды Бамбыр.— Кылануыңа карағанда, мин аны әллә җилдән туганмы, яисә читтән килдеме икән әллә, дип уйлаган идем. Алай булгач, син аны нигә бернәрсәсез урамга куасың?

— Нишләп урамга булсын ди, әнә бит өе бар.

— Ә-ә-ә, шулаймыни? Габдулла, яз, энем, болай диеп. Зәйнулла фәләнев диген, олы улы Сәйфулла фәләневкә, хатыны һәм имчәк баласы белән башка чыгарганда түбәндә күрсәтелгән әйберләрне бирде диген: пот ярым арыш оны, ике тәрәзәле, салам түбәле җәйге өй, икенче яше белән барган тана бозау...

— Нинди тана ди ул тагын!..

— Шаулама, Зәйнулла, шаулама, кешегә түгел бит, үз балаңа... Син, Габдулла, яз, энем, туктама!

— Язам, абзый!

— Яз! Өй салырга кырык баш бүрәнә диген...

— Көпә-көндез талыйлар бит, я алла, нәрсә карап торасың, син...— дип, Зәйнулла абзасы Гобәй Көрпәгә карады.

— Ә-ә-ә, шулаймы? Аллаһы тәгаләне исеңә төшердеңме, җирбит. Эти мәрхүмнең бөтен җыйганы сиңа калды өелеп. Без, бер тиенсез чыгып китеп, кайсыбыз кая таралып беттек. Хәзер хатын сүзе белән йөрисең син, бүрексез нәрсә. Хатыннар туймый ул. Әнкәсе исән булса, бу бала шушылай эт типкесендә йөрер идемени, ә?

— Үз малаеңны бел, миңа кысылма,— дип, Зәйнулла күзләрен ялтыратты.

— Мин сиңа эти урынына калганмын хәзер. Минем улым, бер йортта торса да, аерым өйдә тора. Бүген башка чыгам дисә — ярты дөньям аныкы...

Бамбыр да сүзгә кушылды:

— Ярар, Гобәйдулла абзый, тынычлан. Без бу эшне кызу чагында бетерик инде, төн кыска, ял кирәк барыбызга да. Сүзне менә болай алып китик.— Ул кабат йорт хуҗасына борылды.— Зәйнулла, менә болай: үзең, хатының, өч балаң. Улыңның: үзе, хатыны, кызы. Сез бишәү, алар өчәү. Ата кеше булуыңны исәпкә алып, сиңа дөньяның ике өлеше, малаеңа бер өлеше. Бөтен нәрсәне өчкә бүләбез дә, шунын бер өлеше улыңа тияр. Шуңа күрә аңа тананны, бәрәннәре белән ике сарыгыңны бирәсең. Сарыкның берсен үзең бир, икенчесен ул сайлап алсын. Урмаган игенне сажинлап бүлегез, урганын көлтәләп. Һәркайсыгыз үзенә тигәнне үзе җыйнап алсын. Бәрәңгене буразналап бүлегез. Оят эш бу, беләм, тик башка чара юк, ничарага бичара булып беттегез инде. Бернәрсә дә эшләп булмый, Зәйнулла, үзең сәбәп иттең. Син, Габдулла, энем, яз барысын да шушыларның. Әгәр дә инде, Зәйнулла, безнең шушы әйткәннәргә риза булмасаң, иртәгә үк кәмиссия төзеп, бөтен нәрсәңне исәпкә ала башлыйбыз. Кәмиссиягә күрше-тирәдән дә ике-өч кеше кертербез. Сине дә, малаеңны да белгәнрәкләрен. Менә шул сиңа, әйтәсе сүзеңне әйт тә, без китик.

Зәйнулла байтак вакыт дәшмичә утырды, аннан соң гына теләр-теләмәс сүзләрен чыгарды:

— Влач булгач, нишләтергә кирәген беләсездер инде. Әйдә, сезнеңчә булсын...

Моңа каршы Бамбыр әйтте:

— Беләбез! Чөнки без, унсигезенче елны партизан булып, мылтык тотып, ул влачны көрәшеп алдык, кан түктек аның өчен. Совет влачы

бар вакытта синең кебекләргә авызлыкны да тиз табачакбыз. Син бит ир уртасын куган кеше, ике тапкыр солдат хезмәтен үтеп, сугыш, плин күргән кеше. Үз баланнан үзең кызганасың, ярамый алай. Байлар җирен бүлгәндә, совет влачыннан файдаланып, иң алдан син йөрден. Сикермә, Зәйнулла, ил каршында яхшы түгел...

— Сездә дә үсәләр малайлар, күрербез әле...

— Үсеннәр, амин! Тик үзем исән булсам, улым, синеке кебек, күзләрен мөлдерәтеп, кеше күзенә карап ярдәм эзләмәячәк. Бетте шуның белән. Габдулла, чакыр егетне!..

Секретарь егет такта өйдән Сәйфулланы чакырып чыгарды. Теге картлар каршына килеп басты.

— Менә, улым, атаң белән сөйләшкәннән соң, аның ризалыгы белән чыгарган карарыбыз,— дип, Бамбыр Сәйфуллага сөйләшүнең нәтиҗәсен аңлатырга керешә...— Калган нәрсәләрне бүлешергә бабакаең ярдәм итәр.

— Ярар, энем, ярар, шулай итәрмен,— дип канәгать рәвештә баш какты Гобәй карт.

Аннары ул әле һаман тез өстендәге кәгазьләргә иелеп утырган секретарьга эндәште:

— Кая, Габдулла энем, язган киягазеңне бир әле монда, алай-болай ялгыш теркәп куймадыңмы икән.

Алып азрак караштырды да Габдуллага кире бирде.

— Я, Зәйнулла, шушының белән сүзне кире кайтмаслык итеп бетереп куйыйк инде без, син нәрсә әйтерсең...

— Җитәр...— Йөзенә тимгелләр бәреп чыккан йорт хуҗасы читкә карап утыруын белде.

— Син, Гобәйдулла абзый, ике-өч көн эчендә эшне бетереп куй. Шимбә көнне кичләтеп сугылып китәрмен өйгә кайтканда. Бүгенге эшнең азагын шунда сөйләшербез.

— Соң үзем керермен, энем, кәнсәләреңә...

— Юк, юк, йөрмә. Олы башыңны кече итеп әле дә күп йөредең. Я, ярар, Зәйнулла, исән бул, гаепләп калма, ил эше бит. Минем синең белән бүлешә торган малым юк. Бу бит киләчәк буыннарың өчен кирәк.

Капканы чыгып, зур урамга борылгач, Бамбыр секретарь егет Габдуллага шелтәле тавыш белән эндәште:

— Ничә тапкырлар әйткәнем бар сиңа, энем: шул язган киягазеңнең өске өлешенә яңьле сәнәк төшереп куй, диеп. Югыйсә, кай ягы өс, кай ягы ас икәнен белеп булмый бит. Ярый әле Зәйнулла да укый белми...

Бамбыр Гобәйдулла яңа әлифне танымый иде әле...

Шулай итеп Сәйфулла белән Зөбәйдә көтмәгәндә башка чыктылар. Гобәй Көрпә мал бүлешкәндә, тезгенне нык тотты. Ялан игенен дә бүлеп бирде, бәрәңгене дә, келәт игенен дә, малларны да. Яландагы өч кибәннең иң зурысын бирдерде. Энесе Зәйнулла абзасына каршы килә алмады. Басылды. Ике көн үтүгә бүлешеп беттеләр. Шул тирәдә гаугалы йортка юкны бар итеп йомышка кергән күрше карчыгы: Хәнифәнең уң күз төбе кара янып чыккан, Зәйнулла биргәләгән ахрысы дип сөйләнеп йөрде.

Башка чыкканнан соң яшьләр ашау-эчүгә Кара Гобәйләргә күчтеләр. Ул турыда бабасы үзе сүз кузгатты:

— Синең, кияү, авыр чагың. Әйдә бездә рызыкланып йөрегез хәзергә. Тора-бара күз күрер. Көзләр үтеп, игеннәр җыйналып беткәч, карарсыз аннан соң үзегез.

Нечкә итеп кырылган мыегы астыннан сизелер-сизелмәс кенә елмайган карт, казан тирәсендә уралган карчыгына:

— Син ничек, Садрикамал, каршы түгелсеңдер бит, нигәдер тавышың ишетелми монда?— дип эндәште.

— Әй, шушының теле...

— Ә, ярар алайса.

Атнадан артык бил турайтмыйча арыш урдылар. Бүленгән кырның бер очында — Зәйнулла белән Маһинур, икенче очында — Сәйфулла белән Зөбәйдә. Бер-берсенә дошман түгелләр түгелен, тик ял итәргә туктаган җирләре аерым. Атлары булмагач, Сәйфуллалар куна яталар, ә тегеләр кичен авылга кайтып китәләр. Араларында иң авыры Зөбәйдәгә. Ярый әле баласы елак түгел, тик суыра инде, нык суыра. Шул атнаүн көн эчендә хатын сулыгып, ябыгып китте. Алсу йөзенә азрак сары йөгерде, күзләрендә ниндидер капыл килеп чыга торган сискәнү барлыкка килде. Арыш урагын кыса биреп, бодай өлгерде. Ташырга аты булмагач, урган арышына карап, нәрсә эшләргә белмичә башы катып йөргән чакта, Сәйфуллага Кара Гобәй ярдәмгә килде. Шимбә көн кич чәй эчеп бетергәч, уйланып утырган Сәйфуллага:

— Син, кияү, вакыт табып тиз генә Төхфәт баҗаңа барып кил әле. Кара айгырын сатарга ниятләп тора бит әле ул. Иллә дә шәп хайван инде,— диде.

— Ә, шулаймы? Киттем мин,— дип капыл кузгалды Сәйфулла.

Тик бабасы аны җиңеннән тотты:

— Тукта! Менә сиңа унбиш тәңкә акча. Кем әйтмешли, маяга.

Сәйфулла, Төхфәтләргә барып кереп исәнлек-саулык сорашкач, шундук төп сүзгә күчте:

— Синдә, баҗа, сатлык ат бар, ди бабай. Әйдә карыйк әле.

— Ай, каравын карарбыз да бит, тик синең сәмән ягың ничегрәк соң?

— Әйдәле, әйдә, күрсәт, аннан соң сөйләшербез калганын,— дип ашыктырды Сәйфулла.

— Алай бик күрәсең килә икән, әйдә, күрсәткәнгә акча сорамам.

Абзар капкасын ачып, ярым караңгыга килеп керделәр. Бәйдәге өч-дүрт яшьләр чамасындагы кара айгырның күзеннән ут чаткылары, танау тишекләреннән ялкыннар бөркелеп тора. Төхфәтнең гомере буе итек-читек тегеп, күн белән булышкан куллары ялына тию белән, айгыр тынды. Тик дугаланып килгән муеныннан арт сыртына табан бер-бер артлы ике дулкын йөгереп үтте. Кара айгыр көр дә, елгыр да, матур да иде. Малны күргәч, Сәйфулла телсез калды. Ул аны бүтән вакытларда да күргәне бар иде. Тик ул чакларда айгыр Төхфәтнеке иде бит. Ә хәзер эш бүтәнчәрәк тора. Бер алдына чыкты ул айгырның, бер артына. Куллары калтыранды, тирләде, тамагы кипте.

— Әйдә, алып чык әле, баҗа, ишегалдына бу хайванны. Яктырак җирдә карыйк әле үзен, аннан тоякларын да...

— Һә, күрсәтер ул сиңа тоякларын. Аның һәр тоягы саен бер баш кирәк. Әйдә, башың дүртәү булса...

Төхфәт үзе сөйләнде, үзе, айгырны бертуктаусыз сөя-сөя, ишегалдына алып чакты. Куе озын яллы, озын койрыклы, елкылдап торган кара күзле, кечкенә башлы иде айгыр. Ишегалдын бер итеп, кая басарга белмичә ыргылып-ыргылып сикергән бу изге җанга карап, сүз дәшә алмый озак басып торды Сәйфулла. Төхфәтнең куллары сикерергә ирек бирми башлагач, айгыр аягы белән җир тырнады, башын каера биреп, ирек эзләп карады. Ә Төхфәт һаман елмайды:

— Ошыймы?

— Һы... Күпме сорыйсың?

— Сиксән тәңкә!

Айгырга гашыйк булган Сәйфулла кесәсеннән Кара Гобәй биргән акчаны чыгарды:

— Менә сиңа, баҗа, унбиш тәңкәсе, калганын яңа елга түләп бетерәм, сат миңа бу хайванны.

— Әзрәк сатулаш инде ичмасам, хәлеңә кереп, берәр ун тәңкәсен төшерермен, мужыт.

— Юк, кирәкми, төшермә! Моның хәтле асыл затка акча җәлләп торырга мине әллә карун дип беләсеңме?

— Һәрхәлдә акыллы диеп әйтеп булмый инде сине, чамалы күренәсең ул яктан. Ярар, тот әйдә тезгенен, бергә яшисе көннәребез күп бит әле алдагы киләчәк гомерләрдә. Җитмешне түләрсең инде, шуның белән вәссәлам.

— Юк, сиксән дигәч, сиксән инде. Китер тезгенен, шуңа риза булсаң.

— Ярар алайса, килештек, бир кулыңны.

Кулга-кул сугышкач, Сәйфулла тезгенгә үрелде.

— Тукта, бажай.— диде Төхфәт.— Казаки чабуың белән тот. Игелеген шунда күрерсең, аллаһы боерса. Атландырып өйрәнмәгән, камыт кимәгән, холкы усал түгел, бик тә бала-чаганы яратучан хайван үзе. Тик астын тазартканда сәнәк, көрәк белән сукканны яратмый. Абзар капкасын ачып кергәндә, хайванкай диеп иркәләп кер, яме.

— Ярар, ярар, бажа, шулай итәрмен. Бик әйбәт булды бит әле бу эш.

— Ярар, алып кит инде булмаса. Мәгәрич кирәкми, аның урынына, җигеп өйрәткәч, бахбайны Шарлыкка кунакка барып кайтырга бирәр биреп торырсың инде.

Сәйфулла айгырны туры Кара Гобәйләргә алып кайтты.

— Ай-һай, кияү! Ирләргә генә хас зур тәвәккәллек күрсәткәнсең син. Игелеген күрергә насыйп булсын, бик тә асыл мал, берүк бәла-казалардан, яман күзләрдән саклый күр инде...— дип хуплап каршы алды аны бабасы.

Карлар ява башлаганда, тырышып эшләгәннәрнең игеннәре ындыр табагына ташылып, кибәннәргә кереп беткән иде инде. Кешенеке арасында, бик зурлардан булмаса да, Сәйфуллаларның да кибәннәре утыра. Тик сатып алган атның хакын түли-түли, Сәйфулла йөгенә башлады. Игеннәр нык уңганга, базарда аның хакы түбән, ә башка сатар нәрсә юк. Сарыклар да, үсеп җиткән бәрәннәр белән бергә иткә әйләнеп, базар аша үтеп, юк булдылар. Соңгы унике тәңкә бурычын Сәйфулла бабасы Кара Гобәйдән алып түләде. Кызык та, уңайсыз да хәлгә калды ул шушы унике тәңкә акча белән. Кичке ашны үткәргәч, кияве белән кызын озатырга чыккан Садрикамал капканы япканда, Сәйфулланың кулына өч тәңкә акча төртте:

— Мә, кияү, бу акчаны, тегенең янчыгыннан үзе күрмәгәндә генә чәлдергән идем. Изге эшкә алынгач, гөнаһысы бик зур булмас әле, алла боерса. Ал, ал, мендтерәк. Яши биргәч, барыбер сездән кире әйләнеп кайта торган акча ул. Без картаябыз, сез көч аласыз. Аның янчыгында тагын бар әле. Мич чыгарганга Пачарлардан да тиясе әле, пима да төпли башлады — кулы һөнәр белә, аллага шөкер. Я, исән-сау кайтып җитегез. Баланың бите ачыла күрмәсен, карап бар кайтканда.

Икенче көнне, бабасының йөзенә карамаска тырышып, Сәйфулла аңа өч тәңкә акчаны бирде:

— Тагын тугызы кала инде, анысына янә берәр төрле җаен чыгарырбыз әле.

— Әй-йе, кияү, шулай инде, җан биргәнгә җүн бирә ди ходай тәгалә. Чыгар, чыгар җае.— Гобәйдулла карт иреннәрен кыса төшеп, самавыр артында чәй ясап утырган хатыны Садрикамал белән Сәйфуллага карап елмайды:— Әмма, кияү, ул бурычны өч тәңкәләп түләп этләнмә инде, яме. Барыбер минем янчыктан. Сездерми генә аласыз да бурыч түлисез. Без ул бурычны вәссәлам итеп, бит сыпырыйк та куйыйк инде. Югыйсә, Садрикамалның да гөнаһлары күбәеп китәр дип куркам.

Шушы сүзләрне ишеткәч, әчтән чәе ялгыш тын юлына китеп, иң әүвәл Зөбәйдә кылкынды. Яулык очы белән авызын томалады да, сәкедән төшеп, почмакка кереп китте. Сәйфулла да кызарып, тирләп чыккан йөзен кая яшерергә белмичә, акчалы кулын сузган көйгә аптырауга калып утыра бирде. Тик Садрикамал гына үзен-үзе югалтмыйча, әллә ни исе китмичә, чәй ясавын дәвам итте:

— И-и-и, кара мунча ташы! Мин аны алсам да белеп алдым. Санаусыз акчасы булмас, нәрсә эшләр икән, белер микән, белмәс микән, диеп сынавым гына иде сине, кара чуен...

Хәтердә калган ул авыр да, күңелле дә көннәрне уйлап, Зөбәйдә арба тарта, үзе елмая. Кара Гобәйнең күп ярдәме тиде аларга. Шуңа күрә аны үги дип уйламыйлар да, барысы да өзелеп яраталар, хөрмәт итәләр, зурлыйлар. Кара Гобәй һаман да шулай күп эшли, җайлап кына сөйли, кешегә ярдәмчел булып яши бирә. Картаеп барган Садрикамалын үзенчә ярата һәм аңа авыр көннәр күрсәтмәскә тырыша.

Арба тартып баручы Зөбәйдә, сагышлы елмаеп, истәлекләр дөньясында йөзә. Авылда әнкәләрендә калган сигез яшьлек кызы Сәвия, яшь тә өч айлык улы Мансур өчен ул көенми. Чөнки анда тынгы белмәс, шат күңелле әнкәсе Садрикамал бар, уйчан йөзле, аз сүзле, зур куллы, киң күңелле атасы Гобәйдулла бар. Бу гарасат заманда зур ышаныч, зур терәк алар Зөбәйдә өчен.

## 9

Эсседән әлсерәгән, арба тартып арыган алты хатын Карамалы авылына килеп кергәндә, өйлә җитеп килә иде инде. Авылдашлары Сорур апаның Карамалыга килен булып төшкәненә ун елдан артык. Сорурның әтисе белән Мөнәвәрәнең каенатасы бертуганнар. Татар туган эзли дигәндәй, юлаучы алты хатын Сорурларның капкасы төбенә килеп туктадылар. Утынлыкта агач кисеп маташкан ун яшьләр чамасындагы малай, балтасын тоткан көйгә, дәшми-тынмый, боларга карап тора башлады. Мөнәвәрә туза башлаган читәннән үрелеп аңа дәште:

— Әниләрең өйдәме, акыллым?

— Яланда эштә.

— Син Иншар буласыңдыр әле?

— Әй-йе.

— И-и-и, илаһым! Бигрәк үскәнсең икән. Өегездә кеше бармы соң?

— Дәүәни өйдә, керегез, апалар!

Башка хатыннар да телгә килде:

— Кереп тормыйк, Мөнәвәрә, вакыт юк бит. Юлчының юлда булуы хәерле.

Мөнәвәрә якын да килмәде:

— Китегез, кит, нишләп кермәскә ди. Бер ярты сәгать булса да тын алыйк ичмасам, бит-кулны юыйк.

Хатыннар икеләнеп торган арада Сорурның каенанасы, кабалана-кабалана, өй болдырыннан төште:

— И-и-и, алланың рәхмәте төшкерләре, Мөнәвәрә кодача, син түгелме соң? Карагыз әле нинди бәхет иңгән безгә бүген. Әйдүк, әйдүк, керегез. Бүген иртән үк баш өянәгем кузгалып китте дә, шул басылмасмы икән дип, азрак ятып торган идем. Бу баланың утын чапканына түзеп ятып булмый: балта тутәсе белән лепкәгә сугалармыни. Әйдәгез, әйдә, керегез. Хәзер самаварымны куям, әзрәк хәл җыегыз. Әй ходаl Тагын дөнья нужасы баса башлады инде халыкны. Нәрсә эшләп йөрисез фурманнар өстерәп? Кая китеп барасыз?

— Ирләребез янына,— диде Мөнәвәрә.

— Кайда алар?

— Краевкада.

— Әй аллакаем! Ат та үзем, бот та үзем дигәндәй, җәяүләп китеп барасыз түгелме соң? Байтак ара бит әле анда хәтле, ул табаннарыгыз ниләр күрә инде анда барып җиткәнче?!

Карчык үзе сөйләнгән арада самавырын кагып су салды, ут кабызып күмер өстәде. Хатын-кызлар арбаны йортка кертмичә генә салкын кое суы белән юынып алдылар да яшел чирәмгә чыгарып җәелгән зур

киезгә тәгәрәштеләр. Исәпләре тиз кузгалырга булса да, барып чыкмады — сәгатьтән артык вакыт үтеп китте. Кайнар чәйдән соң аларга бераз хәл керде. Алдагы барасы юлның озынлыгын тоеп, тагын юлга чыктылар.

Карамалы урләре йончытты яшь хатыннарны. Карамалы урләре... Юлны күп йөргән, яхшы атлы, яхшы дирбияле житез ирләрнең йөрәге дә сыкрап куя шул сүзләрне ишеткәндә. Күпме көчләр түгелә, күпме тирләр ага, күпме камыт баулары, тәртә төпләре, тәжеләр өзелә. Күпме ат сыртлары бөкрәя шушы урләрне менгәндә...

Ат көче белән түгел, алты хатын көче белән үрмәләде фурман Карамалы урләренә. Маңгайдан аккан тир күзләрне әчеттерә, юешләнгән күлмәкләр тәнгә ябыша, тын кысыла, аяк-кулның хәле бетә, тамаклар кибә. Иелгән башны күтәреп, алга карарга йөрәк житми — юлның очы тау уренең әллә кайсы төшләренә китеп югала. Күпме тартсан да, күпме өстерәсәң дә, тауга үрмәләгән юлның очы-кырые булмас, әллә кайдагы Краевкага һич тә барып житмәс кебек тоела. Өч урне менгәнче өч кенә тапкыр туктап ял итте хатыннар. Ешрак туктарлар иде, Зөбәйдә белән Мөнәвәрә ирек бирми. Туктыйк дип тә әйтмәделәр, барыйк та димәделәр, зур тырышлык белән фурманны өстерәделәр дә өстерәделәр. Ял итәргә туктау белән, кайсы кай якка юл кырыена тәгәриләр. Теләкләре бер генә: шул Зөбәйдә белән Мөнәвәрә озаграк утырсыннар иде дә арыган аякларга тагын аз гына ял бирсеннәр иде. Кызышкан тәнне искән жилгә куеп, аз гына булса да суытырга иде дә, күзләрне йомып, бала чактагы кебек уйсыз-ваемсыз ятарга иде. Юк, ул ике хатыннан мәрхәмәт көтәрлек түгел. Яңа гына туктаганнар иде, шул арада менә күлмәк-яулыкларын караштырып, чабаталарын каккалап, үләннән яңа олтырак салып, әпәзер булып торып та басканнар.

— Ягез, я! Нәрсә утырмага килгән яшь кызлар кебек жәелешеп утырдыгыз. Баргач утырырсыз да, ятарсыз да, торыгыз, тор!

Мөнәвәрә барысын да кузгата, юлга өнди башлады. Аның тавышы чыгу белән, Зөбәйдә дә арбаның тәртәләренә тотына, аңа ияреп, Рәйхана кузгала, аннан калганнары. Тагын тарталар арбаны, тагын этәләр. Карамалы урләрен үткәннән соң, юл бөтенләй авырайды. Моңа хәтле таудан түбән яхшы ат булып кыйланып чапкан Мөнәвәрә дә басынкыланды.

Бер текә үрне менеп житкәннән соң юл читенә тәгәрәгән Миңжамалның күкрәгеннән чыккан жан өзгеч сүзләр хатыннар күңеленә шом салды:

— Я ходай! Әгәр булсаң, мәрхәмәтеңнән ташлама. Шушы хәтле жәфалар күрсәтсәң күрсәт, тик без барып житкәнче ирләребез генә китеп өлгермәсен. Этисез калган сабыйлар хакына, карт-корылар хакына ялварам сиңа...

Арба тартып ярсыган йөрәкләрен баса алмыйча утырган хатыннар Миңжамалга ябырылдылар:

— Авызыңнан жил алсын, юньсез, тәүбә диген! Бигрәк кирәкмәгән нәрсә уйлыйсың...

— Бу хәтле жәфаланып та, күрешә алмасак, нинди алла ди ул тагын?!

— Гомер буе шулай тозсыз сүз сөйләде инде шушы Миңжамал...

Фурманның арткы тәгәрмәче янына чүгәләп утырган Миңжамал лышык-лышык елый иде. Хатыннар борынын тарткалап, яулык очы белән күзләрен сөрткәләп, бәләкәй генә булып бөрешеп утырган Миңжамал янына жыелдылар. Байтак дәшми торгач, Мөнәвәрә телгә килде:

— Син, Миңжамал, без эчтән генә уйлап килгәнне тышка чыгарып, күңелләргә шом салдың. Дәшмәсәк тә, барыбызда да андый уй бар инде. Бер ярты сәгать тирәсе генә тын алабыз да китәбез. Үлмәбез әле, калган юлны барып житкәнче куабыз. Үргә каршы ашыкмыйк, ә түбәнгә таба күпме тизрәк йөгерә алабыз, шул хәтле чабарбыз. Син, Рәйхана ахи-

рәт, тау түбәне булса, утыра алмыйча торып кала күрмә — кетеп торырга вакытыбыз юк...

— Ярар, ахирәт...— дип күзләрен сөртте Рәйхана.

— Аннан соң инде болай итәбез,— Мөнәвәрә сүзен дәвам итте.— Тау түбәненә Рәйхана кебек итеп тагын икәвебез утырып төшсен. Аз булса да аякларыбыз ял итәр ичмасам. Арбаны тыеп булышмыйк, тотынып йөгерик тә йөгерик. Тик карап йөгерик, арбабыз юлдан чыгып китмәсен.

Тагын кузгалдылар. Карамалы авылы да, тау артында калып, күренмәс булды. Хатыннар шул кузгалудан башка ял итәргә туктамадылар. Тик Софиновкага житәргә берничә чакрым калгач кына, Бурлар Талы дип йөртелгән жирдәге инеш буенда баш-күзләрен сөрткәләделәр. Мөнәвәрә берсенә дә су эчәргә рөхсәт итмәде.

— Тешләрне чатнатырлык суык, эчә күрмәгез. Без хәзер чабып килгән атлар кебек кызыштык. Эчсәк, хәзер аяксыз калабыз, бара алмыйбыз. Авызларыгызны чайкагыз да тизрәк китәбез,— дип кисәтте.

— Минем Сәйфулламны шушыннан биш-алты чакрым жир үткәнче ике юлбасар куган. Арттан дүрт тапкыр аттылар диеп сөйли иде. Әй асыл да иде соң аты! Ике рәт кенә сыдырдым дип сөйли иде. Борын-борыннан ук, шушы таллыктан чыгып, юлбасарлар кеше талый торган булганнар. Егерме тугызынчы елның дикәбер башлары иде шикелле. Ут алынгач кайтып кердә, бураннар туздырышмый ишегалдында. Ул аты кызган, ул үзе — икәүләшеп кая басарга белмиләр менә...

Чыннан да куе таллык белән капланган Бурлар Талы шомлы урын иде. Яшь киленнәр Зөбәйдәнең сөйләгәнен тыңлап бара-бара шүрли калдылар:

— Хәзер шул юлбасарлар килеп чыкса, нәрсә эшлибез инде, әйдәгез тизрәк атлыйк,— диештеләр.

— Миңа чатан диеп тимиләр инде. Минжамалның баласы бар. Зөбәйдә белән Мөнәвәрәгә дә, болары төпкә җигелеп килеп йончыганнар, диеп, кагылмаслар. Алай-болай килеп чыксалар, ике яшь киленне бирик тә китик,— диде Рәйхана.

Мөнәвәрә, елмаюын тыя төшеп, Рәйханага бармак белән янады.

— Я, телеңә салынма, түгәрәк жирләреңнең барысы да киленнәрнекеннән ким түгел, сине дә читкә куеп тормаслар.— Аннан кырысланды.— Ягез, кузгалыйк! Нинди бурлар, юлбасарлар булсын ди монда. Ил өстенә килгән әнә илбасарлар, бөтен халык илне саклап алып калыр өчен туплана.

Бер генә урамлы рус авылы Софиновкага килеп кергәч, хатын-кыз шомлана төште. Бәләкәйдән ук татар авылында үсеп, ипи белән туздан башка рус сүзе белмичә, Зиреклебаштан беркая да чыкмыйча яшәгән хатыннар бу авылны тизрәк үтеп китәргә ашыкты. Бәхетсезгә жил каршы дигәндәй, авыл уртасына житәрәк, арбаның ике тәртәсенә аркылы кадаклангаи шомырт агачы суырылып чыкты. Нәрсә эшләргә белмичә, бераз аптырап тордылар да, юлда яткан ташны алып, таякны кире кадакларга керештеләр. Бу эшкә бүтәннәргә караганда Рәйхана остарак булып чыкты. Тик таяк элекке кебек нык беркелеп бетмәде. Шулай ни эшләргә белмичә аптырап торганда, арба тирәсенә сары чәчле, зәңгәр күзле, төрле яшьтәге рус балалары жыйналып өлгерде. Арбаның бер артына, бер алдына чыктылар, нәрсәдер сөйләнделәр. Кайберләре кызыксынып арба янына ук килделәр. Мөнире өчен курыккан Минжамал аларны куа башлады. Бала-чага, көлешеп, төрлесе төрле якка чәчелә дә тагын арбаны уратып ала. Шул вакыт болар янына кулына өч япьле агач сәнәк тоткан, авызына кәкре трубкасын капкан олы яшьләрдәге бер рус агае килеп туктады:

— Здоровы, молодки?— дип исәнләште жирән агай.

Хатыннар башта шым булдылар, аннан соң гына берсе телгә килде:

— Әй ходаем, нәрсә ди?

— Исәнләшә бит.

— Что случилось?— дип кызыксынды агай һәм арба янына якынрак килде.

Зифа араларында русчага остарак иде, ул җавап бирде:

— Вәт, дәдә, тәртә паламался бит, ни знай инде...

Карт тәртә башын күтәреп карады да янында уралган зәңгәр күлмәкле малайга нәрсәдер боерды. Карт сүзен әйтеп бетерүгә, ике малай каядыр торып йөгерделәр. Аз гына вакыт үтүгә, малайлар чүкеч, кадаклар алып килделәр. Эшкә керешкәнче, карт икенче малай кулыннан тоткалы зур чүлмәкне алды да Зифага сузды:

— Пейте квас.

Мөнирен күтәреп, фурман артында басып торган Миңҗамал шундук телгә килде:

— Кит, урыс кулыннан ала күрмәгез! Гөнаһысы зур була ди аның шәригать буенча.

Зифа, берни булмагандай, чүлмәкне карт кулыннан алды да куас эчәргә тотынды. Эчте дә Мөнәвәрәгә бирде. Мөнәвәрә исә кулыннан ычкындырмыйча гына Мөниргә эчерергә тотынды:

— Үзең эчмәсәң, балаң эчсен, юньсез нәрсә. Кеше аңа изгелек эшләп тора, ул — үзенә күрә түгел — урыс дигән була.

Бала чыннан да нык сусаган иде. Йотлыга-йотлыга, ике кулы белән тоткалы чүлмәккә ябышып эчте дә эчте. Ул эчкән саен, чуар чәчәкле күлмәге астыннан корсагы түгәрәкләнгәннән-түгәрәкләнә барды. Болар эчкән арада карт, трубкасын төтәтә биреп, арба тирәли әйләнеп чыкты. Буш чүлмәкне кулына алгач, арбага карап телен шартлатты, соклануын яшерә алмады.

Хатыннар кузгала башладылар. Салкын куас эчкәч, аларга хәл кереп китте. Софиновкадан соң Нарыс Тау, Чебенле, Тебет һәм исемнәре истә калмаган тагын берничә эреле-ваклы татар-башкорт авыллары үттеләр. Краевкага якынлашкан саен, авыл аралары кыскарды. Олы Себер тимер юлына якынлашу сизелә иде. Краевкага килеп җитәр алдыннан Зим елгасының теге ягында башкорт авылы Чурай күренеп үтте, аннан соң хатыннар, арба өстерәп, Кармыш авылына килеп керделәр. Авыл уртасында арба артыннан килгән Рәйхана егылды: гарип аягы чыдамады.

— Әй, ахирәткәйләрем! Күбесенә түзгәч, әзенә генә түзегез инде, берүк ташлап китә күрмәгез мине, балаларым хакына, Миңлебаем хакына, бергә үткән юлыбыз хакына...

Миңҗамал Зөбәйдә белән Мөнәвәрәгә эндәште:

— Инде ни күрсәк тә күрербез, калдырмыйк Рәйхананы. Барсын утырып.

Кармышны чыгып, күпмедер араны үткәч, Краевка элеваторының башы күренде. Бу вакытта кояш офыкка якынлашып, көтү кайтыр чак җитеп килә иде инде. Хатыннарның өс-баш тузанланган, аякларындагы чабаталар тузып, мыек чыгарып бетергәннәр иде. Мөнәвәрә туктарга кушты. Аның әмере кыска булды: бу хәлдә Краевкага кереп, ирләр күзенә күренмәскә!

— Кем килгән — Зиреклебаш хатыннары килгән дисеннәр. Өстегезне кагыгыз, селкегез, юыныгыз — әнә сезгә Кармыш инеше. Аяк-кулларыгызны юыгыз, баш-күзләрегезне карагыз, чәчләрегезне кеше рәтенә китерегез.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, үзе капчыгын чиште дә баш яулыгына төреп салган бала итәкле, эре чәчәкле бик матур күлмәген алып киде. Аякларына балтырының уртасына җитеп торган, ак шнурлы, биек үкчәле, ялтыравык кара ботинкалар киде. Башына исә, артка тартып, зур роза чәчәкләр төшкән кара яулык бәйләде.

— Кит, Мөнәвәрә! Биек үкчәле ул нәрсәң белән матур күлмәкләр киеп, үзебез фурман тартып, кеше көлдермик инде...

— Башында акылы бары көлмәс. Ә көлгәне көләр аларның авызын томалап булмый. Әллә күрәм тагын, әллә юк Галиулламны, тузанлы күлмәкләр киеп, арып-талган көйгә күңелендә каласым килми. Алар өчен безнең бүгенге килүебез бәйрәм булырга тиеш. Зур бәйрәм! Ишетсен колагыгыз! Күзегезне чылатып, аларның җанын ашамагыз. Нәрсә теләсәләр, шуны кыйлансыннар, ирек куегыз! Әйбәт итеп үткәрегез бергә булган минутларны. Бөтен нәрсәне дә әйбәт диегез, бала-чагалар, эти-әниләр исәннәр диегез, игеннәрне җыйныйбыз диегез. Менә шул сезгә, исегездә тотыгыз.

Хатыннар тиз арада кагынып-юынып, өс-башларын төзәткәләп алдылар. Миңҗамалдан башкаларының аякларында кайсысының чүәк, кайсысының резин галуш иде. Рәйхана, гарип аягына тирән эчле галуш кия-кия, зарланып куйды:

— Кешеләр кебек бәхетем булып, шул ялтыравык урыс ботинкаларын киеп булмады инде, гомер үтеп бара заяга...

Хатыннар Краевкага килеп җиткәндә, кояш баерга күп калмаган иде инде.

## 10

Алты хатын сәфәрнең максаты булган Краевкага килеп керде. Авыл якынлашкач, Рәйхана түзмәде, арбадан төште.

— Кыен булса булыр, төшим әле,— диде ул.— Болай кукыраеп йөк өстендә бару кешедән оят.

Авылга кергәч тә уң якта тимер коймалы зур мәктәп бинасы күренде. Коймага эчке яктан сырышкан ирләрнең исәбе-хисабы юк иде.

— Кайсы авыллар сез?— дип сорады аларның берсе.

— Зиреклебашлар.

Бу хәбәр ирләр арасында дулкын булып үтте, көлгән, шаярган тавышлар да ишетелми. Фурман өстерәгән хатыннар, туктап тормыйча, мәктәп капкасына таба атладылар. Аларны күргән ирләрнең күзләреннән яшьләр чыкты. Бу хатыннар әллә кайларда торып калган тук һәм тыныч тормышның кадерле бер кисәге иде. Бергә-бергә җир сөреп, печән җыеп, ашлык сугып, бала үстереп яшәгән бәгырьләре бит. Ни булды бу дөньяга? Ниткән сугыш булды соң әле бу? Кемгә кирәк соң әле ул? Кая аларның җигеп чапкан елгыр атлары, бала-чага тулы өйләре, гәпләшеп утыра торган кичке капка төпләре? Болар берсе дә юк. Алар урынына алда дәһшәтле, фаҗигале сугыш. Ут эченә керәсе бар. Фашистны куып җибәрәсе...

Шулвакыт кемнеңдер:

— Мөнәвәрә-ә-ә...— дип кычкырганы ишетелде.

— Әй, ахирәт, синең Галиуллаң тавышы түгелме соң, карале.

Рәшәткәнең эчке ягындагы кешеләр арасында Галиулланың башы яртылаш күренеп алды да тагын юк булды. Баш өстенә күтәрелгән ике кулы, очарга талпынган кош канатлары кебек селкенә, юлда туктап калган хатыннарга ниндидер серле ишарәләр ясый сыман иде. Сырып алган халыкны ерып, Галиулла рәшәткә янына үтте:

— Шушы урам буйлап барыгыз да, беренче тыкрыктан сулга борылып, икенче урамга чыгыгыз,— дип кычкырды ул. Әнә-ә-ә, күренеп тора моннан да, биек тупыллы йорт. Мин хуҗа белән сөйләшеп куйдым, шунда туктагыз. Хуҗа бабай Шәрифҗан исемле, хатыны Зөләйха түти. Мин хәзер, рөхсәт сорап, ирләрегезне җыйнап, алып барырмын.

Галиулла әйткән йорт ишегалдында аларны башына кара түбәтәй кигән илле биш-алтмыш тирәләрендәге бер бабай каршы алды:

— Бик хуш киләсез, чибәркәйләр! Әйдүк, әйдүк! Хәзер мунчага ут төртеп җибәрәм, килүегезгә Галиулла мунча ягарга кушкан иде. Үтегез, өс-башларыгызны караштырыгыз. Йөгегез өчен кайгырмагыз, үзем карармын. Бар нәрсәгез үз урынында булыр.

Хатыннар ишегалдындагы кое улагында шешенгән аякларын юарга тотындылар. Салкын кое суы белән тулы улакка ялангач аякларын тыгып байтак утырдылар. Тик табаннары кабарган аяклар, җилсенгән баш-күзләр, салынып төшкән куллар тиз генә хәл ала алмады. Бик зур авырлык белән кузгалып, хатыннар капчыкларын бабайның келәте янына ташыдылар. Хуҗа карчык күршеләрдән алып чыккан ике чиләк сыешлы самавырны куеп, сәкегә табын әзерли башлады. Килгәннәренә сәгатьтән артык вакыт үтеп, караңгы төшкәндә, урам капкасы ачылды — ирләр күренде. Әзмәвердәй сигез ир килеп кергәч, өй эче кысрыкланып та, күңелләнеп тә китте. Миңлебай үзенең күршесе Хәмитне, ә Сәйфулла Гыйниятне алып килгән иде. Зireклебашның башка егетләре, Галиулланың әйтүенә караганда, бүтән взводта икән дә, аларның командиры, сезнең хатыннарыгыз юк анда дип җибәрмәгән икән. Тик Сәләх белән Мәҗитне, хатыннары килгән булгач, бүтән взводта булсалар да, җибәргәннәр. Сигез ирнең бишесе сәкегә менеп утырып, өчесе идәнгә урнашып, табын ачтылар. Ашъяулык ит-май, пешкән күкәй, вак бәлеш, төче күмәч, бавырсак, казылык, төрле зурлыктагы пәрәмәчләр, тагын әллә нинди ниг ъмәтләр белән тулы иде. Яулык очлары белән күзләрен сөртә-сөртә, хатын-кызларның кайсысы табынга утырды, кайсысы, аяк өсте торган килеш, ирләрен сыйлады. Алар барысы да гомер буе күп һәм авыр эштә эшләп, таза ашап өйрәнгән, икмәк үстереп, мал карап көн күргән ир-егетләр иде. Соңгы көннәрдә ризык туйганчы эләкмәгән, ахрысы, нык итеп тавыш-тынсыз гына ашадылар. Ике чиләкле самавырны эчеп бетергәч, табын янынннан аерылып чыгып, ирле-хатынлы мунча керә башладылар. Бер пары чыгуга — икенчесе, анысы чыгуга — өченчесе. Аннары тагын барысы да табын янына җыйналдылар. Аннан кузгалганда, барысының да кыяфәтләре тук, хәрәкәтләре салмак иде. Ярты сәгать үтәр-үтмәс, кем кайда урын табып, хатыннары белән парлашып, йортның төрле почмакларында — печәнлектә, келәт эчләрендә тирән йокыга талдылар.

Өй эчендә хуҗалар белән Гыйният кенә утырып калды. Зөләйха җиңги, күз яшьләрен сөртә-сөртә, табында калган азык-төлекне, савыт-сабаны җыйный иде. Шәрифҗан абзый, дәшми-тынмый гына, тәмәке көйрәткән кунагына герман сугышында күргәннәрен сөйли башлады:

— Анда кергәндә, энем, аллага тапшырып керәсең инде. Чөнки әллә кире чыгасың, әллә юк. Якты дөньядан берәүнең дә туйганы юк бит, яшисе килә. Хәзерге сугышта ничектер, анысын әйтә алмыйм, тик әүвәлгесендә рукапашныйга өч солдатның бер булып кергәне кулай иде.

— Ничек инде ул өчеңнән бер булып?

— Берең уртада, икең ике як кырда. Уртада барганы иң елгыр булырга тиеш. Ул кәнечкәндә дә тирә-яктагының барысын да күрергә, барысын да чамаларга тиеш. Алай-болай берең егылса, туктап, нәрсә булды икән диеп, иелеп тормагыз. Бетсә, беткән инде ул, әгәр яраланган икән, азактан эзләрсез. Ялан, ачык җирдә мылтыкны ташлама инде син. Безнең мылтык аларныкыннан шәп иде. Суга төшсә дә, ком тулса да, чыдый, алып азрак селкисең дә тотынасың атарга. Тик акуп эчендә озынлая да куя инде — анда уңайсыз. Акуп эчендә сугышканда, иң уңае теге бәләкәй көрәк инде. Бер кырын әзрәк игәүләп алсаң, балта кебек җиппәрә инде чапканда...

Тып-тын йөргән карчыгы Шәрифҗан картны орышырга кереште:

— Кит инде, әй! Төнгә каршы әллә нәрсәләр исеңә төшерәсең. Ят, улым, бар, абзаң ул, тыңлаучы булгач, төне буе сөйләргә риза.

— Һе-е, әйтер идем инде, кеше бар,— диде моңа каршы карт.— Мин бит ана, баргач, аптырап тормаска өйрәтәм. Безнең камандир рут яңа килгән салдатларны рукапашныйны белгән салдатларга беркетеп куйдырта иде. Шуннан әллә күпме вакытлар тегеләрне атарга да, кадарга да өйрәтә торган идек. Сугыш бит ул, келтә ташу түгел.

— Нимесләр көчкә ничекләр, алдырып буламы аларны! — дип кызыксынды Гыйният.

— Төрлесе бар инде, тик безнең халык ныграк — пахутка да, суыкка да. Нигә икәнен белә алмадым, иллә аларны бет тиз баса инде. Безнең кебек, кайда туры килде шунда юына белмиләр алар, җылы су кирәк аларга. Шуңа диеп уйлыйм мин. Фрунтта ни хәтле булдыра аласың, шул хәтле тәнне чиста тотарга кирәк. Аннары юк-бар малга кызыкмагыз, улым. Андый җирдә, сугыш булгач, алтыны да очрый аның, бүтәне дә. Шуңа кызыккан салдат — салдат түгел инде. Күрәсең, сугышка кергәндә дә шул алтынын уйлап керәдер ул. Иң кирәге — бер сынык икмәк, феләгеңдә әзрәк аракы яки су, капчыгыңда зур гына таза чүпрәк. Тик ефәк булмасын инде, канны туктатмый ул. Аракы дигәннән, кыш көне фелә гедәге су туңа, шуңа күрә аракы я спирт җайлырак.

Озак утырдылар Шәрифҗан абзый белән Гыйниятулла сугыш турында сөйләшеп. Өч елын окопта үткәргән Шәриф солдат күп нәрсәләр сөйләде.

Алар аерылышканда, Зим артыннан таң беленеп килә иде.

Икенче көнне иртән мылтык уенына чыгып йөгерешкән ирләрен озак көтте хатыннар. Көне буе көттеләр, ирләр күренмәде. Башка ирләр кайтты, ә алар юк. Кич булды, караңгы төште, итле ашлары дүрт чиләкле зур казанда әллә кайчан пешеп, әллә кайчан суынып, куерып, бәрәкәте китеп бетте. Алар аны тагын җылыттылар, аш тагын суынды, ә ирләре юк та юк...

Алты хатын ул кичне капка төбен саклап үткәрде. Караңгы төшеп, әллә ни кадәр вакыт үткәч кенә, элеватор ягыннан ирләрнең сафларда җырлап килүләре ишетелде:

> Армия-а-а әзе-ер бул,
> Буржуйлар суза-алар кул...

Бер сәгатьтән ирләре җыйналып килеп тә җиттеләр. Тик Гыйният белән Хәмит кенә юк иде. Арыган булсалар да, ирләр шат күңелле иде, чөнки бу юлы аларны иртәгә көндезгә икегә кадәр җибәргәннәр...

Таң атып килгән чакта урам яктан тәрәзә кактылар:

— Тревога, тиз булыгыз, торыгыз җәтрәк!

Бу Гыйният иде. Барысы да сикерешеп тордылар. Әпен-төпен киенә башладылар. Келәттән чыккан Галиулла аптыраулы тавыш белән сорады:

— Нәрсә булды, Гыйният, әллә озаталармы?

— Командир: «Тагын бер сәгатьтән төяләбез», — диде. Әйдәгез!

Елаган хатыннардан арына-арына, ирләр мәктәп ягына йөгерештеләр. Барлык дөньяларын онытып, хатыннар да шул якка китте. Алар барып җиткәндә, ирләрен исемлек белән барлыйлар иде. Ярты сәгать вакыт үтмәгәндер, ирләрне, сафтан чыгармыйча, элеватор ягындагы тимер юлда торган кызыл вагоннарга таба алып киттеләр. Шуны күргән хатыннар барысы да Шәрифҗан абзыйның өе ягына йөгерделәр. Калган азыктөлекне, ничек туры килде шулай капчыкларга тутырып, элеватор ягына ашыктылар. Иң арттан иңенә ике зур капчык аскан, кулларына ике төенчек тоткан Рәйхана титаклый иде. Тыңламаган чатан аягына чыккан ачуын ике күзеннән атылып чыккан күз яшьләре белән юарга тырышып атлый иде ул...

Ирләр китәргә ярты сәгать кала һәр вагон эченә бәйләме чишелмәгән шинельләр ыргыттылар, икешәр әрҗә консерва куйдылар, унар кирпеч икмәк бирделәр.

Үзәк өзгеч тавыш белән паровоз сызгыртты, вагоннар тартылып куйды. Кузгалган вагоннарга ияреп, хатыннар йөгерештe, вагон эченнән ирләре кул болгадылар. Чыккан төтен, пар эчендә күмелгән хатыннар поездга ияреп алмыйча, артта кала башладылар. Вагон ишегенә бер

кулы белән тотынып, бөтен гәүдәсе белән тышка асылынган Мәҗит нәрергә тырышып йөгергән хатыны Асияга ачыргаланып кычкырды:

— Кал инде, Асиякәем, йөгермә инде, кал инде, йөрәккәем...

Ирләр китте. Вагоннарга төялеп хатыннарның тормыш терәкләре, балаларының аталары, өйдәге картларның уллары китте. Торып калган хатыннарны нужалы еллар, ялгызлык, туктаусыз ашарга сорап елый торган балалар, ирләре бүтән аяк басмаячак юллар көтә иде.

Мең тугыз йөз кырык беренең август аенда Зиреклебаштан чыгып киткән унсигез игенчедән, сугыш беткәндә, бары тик өчесе генә әйләнеп кайтачак иде.

## II

Хатыннар сәке тирәсенә утырышып, чәй эчә-эчә, киңәш итәргә тотындылар. Йончыган аяклар бер генә көн булса да ял сорый, ә йөрәкләр сүлпән тибә иде. Кайтасы юл хәзер танышлыгы, озынлыгы белән хатыннар өчен әллә ничә тапкыр авыррак күренә.

Шәрифҗан абзый хатыннарның кайгырышып сөйләшкәнен тавышсыз гына тыңлап утырды да сүзгә кушылды:

— Сез, булмаса, болай итеп карагыз. Илибатыр янында ат белән иген китерүчеләр күп була. Мөгаен, Зиреклебаш ягына кайтучылар да очрар диеп уйлыйм. Карамалылар, Чебенлеләр, Каенүзәкләр, аннан Сафиныфка урыслары. Өрмәк немецләре...

— Кит, Шәрифҗан абзый, ниткән немец ул тагын?— дип сорады Зөбәйдә.

— Нигә, үзебезнең немецләр. Немецнең бары да фашист булмый бит инде, алар арасында да әйбәт халык бар.

— Каян бу якларга килеп чыккан алар?

— Әби патша вакытында ук күчеп килгәннәр бу якларга. Бик бай аларның калхузы, үзләре бик тә эшчән инде. Алай-болай туры килсәләр, куркый, утырмый кала күрмәгез тагын. Барыгыз, бар, белешегез!

— Кит инде, илаһым, таныш-белеш булмаган чит ирләргә утырып юлга чыгуы да инде...

— И-и-и, сеңелкәйләр! Сез андагы ирләрне барып карагыз, аннан сөйләрсез. Аларның күбесе малай-шалай да карт-коры бабайлар бит.

Зөбәйдә, шәлен ябына-ябына, ишеккә юнәлде:

— Ягез, күп сөйләнеп вакыт үткәрмәгез! Мөнәвәрә, кузгат барысын да, юлга әзерләнә торыгыз, мин барыйм әле, чыннан да, бала-чага бәхетенә берәрсе очрамасмы икән? Өйгә кайтырга кирәк тизрәк, бала-чага янына.

Ул элеватор янында җыйналган йөкләр тирәсендә байтак йөргәч, морадына иреште. Билен биштән буган, ак сакаллы, зур куллы, көләч йөзле бер бабай үзе эндәште:

— Кызым, берәрсен эзлисеңме әллә?

— Мин, бабай, Зиреклебаш ягына баручы буш олаучы булмасмы икән дип йөри идем. Болай төбәп эзләгән кешем юк үзе.

— Ай-һай, кызым, таба алырсыңмы икән. Ул як хәзер тискәре сана-ла бит. Үзең син Зиреклебашныкымыни?

— Әйе, бабай, Зиреклебашныкы. Син үзең кайсы авылныкы, бабай?

— Мин, кызым, Каенүзәктән. Ишеткәнең бардыр бит?

— Бә-ә-әй, нишләп булмасын, бар ишеткәнем. Каенүзәк бездән утыз чакрымнар чамасы гына бит ул. Әй, бабай, син безне апкайт инде үзегезнең авылга хәтле генә булса да. Ирләребез янына килгән идек. Барыбыз да Зиреклебаштан. Инде атларга һич хәлебез калмады. Өстәвенә, беребез чатан да җитмәсә.

— Атыгызга ул-бу булдымы әллә?

— Атыбыз юк шул.

Бабай, ышаныргамы-ышанмаскамы, дигәндәй, беравык Зөбәйдәгә карап торды.

— Бабай, ходай хакы өчен, ал инде син безне, калдырма,— дип ялварды Зөбәйдә.— Хакын да түләр иек. Тик, бабай, фурманны гына так, үзебез арба артыннан җәяү дә атлар иек...

— Әйдә, кызым, без болай итик, булмаса. Сез җыйналып килегез тиз генә, мин монда өйлә авышуга игенне бушатырмын диеп уйлыйм, иншалла. Атларым таза, бричкам майланган. Юнен күрербез әле бергә-бергә, барыгыз да килегез!

Хатын-кыз тиз җыйналды. Зөбәйдә кайтып кергәч, барысының да күңеле кузгалды. Әле күрмәгән, белмәгән әллә нинди бабайга рәхмәтләр укый-укый, әйберләрен арбага тутырдылар, шулар арасына Мөнирне дә чыгарып утырттылар. Бик күп рәхмәтләр укый-укый, йорт хуҗалары белән хушлаштылар. Озата чыккан Шәрифҗан абзый белән Зөләйха җиңги хатыннар биргән акчаны алмады:

— Кирәкми, кирәкми, безнең халыкта булмаганны кыланмагыз. Мондый афәт заманда ни бит белән алырга кирәк, ди. Хуш иттек, юлыгыз җиңел булсын да, иптәшкә ходайның изге бәндәләре очрасын...

Өйлә авыша башлаганда, Краевкадан пар ат җиккән, артына бәләкәй фурман таккан арба чыкты. Андагы салам, буш капчыклар өстенә елаудан күзләре шешенә төшкән алты хатын утырган иде. Күп тә үтми, ирләре китеп барган тарафтан авылга похоронкалар килә башлаячагын да, бу сугышның, үтә дә рәхимсез булып, дүрт елга сузылачагын, үзләреннән бик күп көч, түземлек, батырлык таләп итәчәген дә алар әле белми иде...

Зиннур Мансуров

# БАЛКЫШ
## яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар

ПОЭМА-РУЛАДА

### Автордан

Рулада... Җырның бик тиз башкарыла торган өлеше музыкантлар телендә шулай атала. Көй агышының тизләнүе күбесенчә азактарак була. Гомер җырының руладасы кешедә кайчан башлана? Язмыш юллары ахырына табамы? Шулайдыр... Төпкә кадәр янган шәм дә якты балкыш ясап сүнә. Вакыт тарафыннан билгеләнгән соңгы гомер чиге ягасында, имеш, һәркем хыялый тизлектә балачак сукмакларыннан йөгереп кайтыр... Сугыш фаҗигасе күпләрнең гомер агышын тизләтте һәм яшен яшәмәгән яшьләрнең дә чәчен агартты. Кырык чиген узып киткәч, гадәттә, еллар болай да ашыга башлый. Ниндидер катализатор вакыт агышын тизләтә шикелле. «Минем җилкәдәге кырык яшь...» Данлыклы полк командиры полковник Мөҗәһит Хәйретдиновка да гомеренең соңгы өч елында аеруча тыгызга килгәндер. Соңгы чиккәчә кысылган шушы вакыт аралыгында ул үзе бер гомергә торырлык еллар кичкән. Бөтен гомер буена янучы йөрәге Дахау мичендә дөрләгән халдә кергән!.. Гомер җыры руладасы. Яшьнәп үткән еллар. Рәхимсез сынау вакыты. Цейтнот эзәрлекләве. Йөрәкнең бөтен барлыгына янып балкуы!.. Кыскасы, әлеге әсәр Ватан солдаты, шагыйрь, коммунист Хәйретдин Мөҗәй турында.
һәм башкалар хакында да.

*1. «Монда нәкъ безнең Ык елгасы буендагы кебек, кара бөрлегән үскән. Бүген көн буе куаклар арасында бөрлегән ашап йөрдек. Бармакларым да, иреннәрем дә бөрлегән төсле күм-күк булды».*

«Сугыш язмалары». 27.8.41.

Әгәр төштә ашап йөрсәм
бөрлегәннең карасын,
әнкәй мәрхүм сыгар иде
күзендәге бар яшен...

«И ходаем! Хәтәр-хәвеф
килмәгәе илләргә...»
Кулларымның каралуын
юрар әллә ниләргә!..

---

*ЗИННУР МАНСУРОВ (1949) — шагыйрь, «Күл бизәм», «Йөз суы» исемле татарча һәм русча («Тысячелистник») китаплар авторы. Әдәби тәнкыйть-эссеистика өлкәсендә дә эшли. Казанда яши.*

«Нишләтмәкче кара язмыш
кара җиләк йоттырып?
Юкка гына алар шулай
уңмаганнар котырып...»

Үзе булса, «Кагылма!» дип,
сугар иде кулыма...
...Төштә түгел, өндә ашыйм —
аермасы шул мөнә.

Нигә юрап торуларың,
килгән инде киләсе...

Ачыттыра кара җиләк —
тамган мәллә ил яше?!

Соңгылары күңелемә
ятышмады бигрәк тә.
Шундый тойгы: җиләк каптым
үзем яткан зиратта (?!).

Әллә сугыш сыйламакчы
мине шундый сый белән?!

...Куакларга җиләк түгел,
кара күмер сибелгән...

Мондый хәлне ни дип юрыйм —
бәлки, йөрәк сизәдер?!
Җиргә кара җиләк булып
кайтырга да без әзер...

Куйчы әле — ватандарның
буламыни үз гаме;
бөрлегәнгә кунган бары
олы юлның тузаны.

Безне күмер хәлендә дә
танучылар табылыр.

Бөек Җиңү табынында...
кара җиләк тә булыр.

...Соңгылары күңелемә
ятышмады бигрәк тә.
Шундый тойгы: җиләк каптым
үзем яткан зиратта...

*2. «Минем блиндаж янында бертуктаусыз снарядлар ярыла. Башны күтәреп-күтәреп карыйм. Менә окопта аягы өзелгән ак әтәч тыпырчына...»*

19.9.41

...Әллә ниләр хәтерләтеп,
әйләнде дә тулганды.

Бакчасарай тарихында
шундый бер хәл булган ди...

Дошман явы якынлашкан
шушы гүзәл мәркәзгә.
Килеп җиткәч, кем әйтмешли,
«очраган ди бер тазга»...

Сукранганнар: «Женле урын!
Әйләндереп йөретте...
Килгәчтен дә табып булмый,
әллә үзен җир йотты?!»

Хан сарае табылмаган,
кайнап ташкан яу үче.
Һәм шулвакыт ишетелгән
«сатлык» әтәч тавышы...

Манаралы түбәләрен
бакчаларга күмгән дә,
утыра ди Бакчасарай,
оеп тирән үзәндә...

Туган йортны искәрмәстән
була икән сатып та.
...Яраланган әтәчебез
тыпырчына окопта.

Ярый әле баш өстендә
канат җилпеп очынмый;
дошман күзе ак әләмгә
охшатмасын өченме?!

Җәрәхәтле гаярь кошкай
кызганыч та, кызык та,
гыйбрәтле дә: әтәчләнеп
булмый алгы сызыкта!

Бөркетләрем!
Әтәчлектән —
куркаклыкка бер адым...

...Сугыш коштан корбан чалды —
исәнлеккә юрадым.

*3. «...Басудагы эскертләргә ут төртеп, төтен каплавы астында Журовкага кадәр китәргә булдык».*

19.9.41

Ничек инде ышанмыйсың
сезләрдә дә җан барга.

Рәнҗемәгез, эскертләрем, —
кемдер тиеш янарга!

Тәрәккыят паровозы
алга бармый һич кенә,
Лазо төсле фидакярләр
ташланмаса мичкенә.

«...Атсаң, яндырсаң да...»

Немчурага җавабымны
шулай әйттем шигырьдә.
Вөҗдан кушып яздырганда
алдаламыйм мин бер дә.

Кирәк икән, утка каршы
кабынырмын ут булып.
Төтен очар, көлем калыр
Җир шарына йотылып.

Эскертләрем, менә шулай
утырыгыз җай янып.
(Илеңдәге төтенгә дә
була икән таянып!)

...Төрекмәнем. Урта басу.
Шулкадәрле үз инде...

Авылыма чигендереп,
каралтсагыз йөземне?!

Кара мунча төтененә
качырмагыз сез мине!

Мәсләгемнән тайпылмыйча,
кичтем күпме төн-көнне.
Исерталмас теге яктан
кергән ладан төтене!

Гүрдән атам-анам каргар:
«Ватанга да син үксез!»
Адашмаска! Туган йортка
кайта алмыйм җиңүсез.

...Тотынырга сыңар салам
калдырмыйча үзенә,
төтенеңнең очкынлысын
җибәр фашист күзенә!

Мәңгелеккә томалансын —
уртак максат шушы ла.
Сезнең төтен Жанна д'Арк
һәм дә... Болгар тәрәккые
төтененә кушыла...

Әнкәй яккан коймак миче
төтенен дә табарсыз.
Ә хәзергә озатыгыз
Журовкага кадәр сез.

*4. «Таң ата. Аз гына ятып аласы килә. Ятам, ләкин күзләр йомылмый, баш һаман уйлавын дәвам итә. Кайчагында бөтен гәүдә кисәк-кисәк сикереп куйган төсле була».*

20.9.41

Тәүлек буе башым уйда —
татым беткән йокларга.
Вакыт әрәм — черем итү
кебек җыен юк-барга.

Инде менә ничә атна
итекләрне салган юк.
Сәгатемдә минут угы
гына йөри әйләнеп.

Салмак аккан вакыт хәзер
шарлавыктай ишелә!
Сәер халәт: уяу килеш
әллә нинди төш килә...

Күкрәгемдә йөрәк типми,
ә сәгатьле шартлаткыч!..
Мандолинам кыска көйләр
генә уйный — шаккаткыч...

Янар көчкә ашыктыра —
башка вакыт үлчәве.
Арттан дулап килгән чалгы
кыеп ала үкчәне.

Вакыт белән санлашмаган
чак та булды югыйсә.
Ә сәгатең шартлаткычта
гомереңә чик куйса?!

Үкенечле салмаклыкта
башкарылган көй башы.

Көндәлеккә әллә нокта,
әллә өтер куясы?!

Мәрьямемә «Исән!» сүзен
язарга дип мең кыздым.
Хатың килсә — нуры төсле
инде сүнгән йолдызның?!

Булсын шундый тизлегендә
гомер атлы көй-агыш!
Исә дә ул үзебезнең
тегермәнгә коя ич.

Җилкәдәге кырык яшем
җитәр әле, хуш, әйдә,
ахыр чиктә газиз халкым
гомеренә кушарга.

*5. «...Күзәтү урыны өчен җил тегермәненең эчен һәм эшләнүен карадым. Мин ул тегермәннәрне бик күп очраткан булсам да, эченә кереп караганым юк иде әле. Онга буялып чыктым».*

6.10.41

Яшәү утын көчәйтергә
ташы күпме ут биргән.
Нигезенә көнләп-еллап
он тузаны утырган...

Онта белән ныгытылган —
кальгәләргә торырлык!
...Ничек күзләү торбасына
керә алган бер орлык?!

Карап туймыйм — шуннан гына
тора, имеш, бар эшем.
Олуг икмәк күзе аша
күзлим сугыш барышын.

Ачлык явы тылдан бәрсә?! —
җиңү авыр монысын...

Тегермәндә дары исе
баса төште он исен.

Миндәй авыл баласына
иң авыры шул хәзер.
Безнең өчен сугыш исе,
бәлки, шундый буладыр.

Бутамаска иде бергә
дары белән он исен!
Тегермәннең канатына
Дон-Кихотның сөңгесен
кадап, җиргә егылудан
файда килә кем өчен?

Икмәк атлы хакыйкатькә
кадый, җыеп бар көчен...
..Дурбин[1] дагы бөртек аша
күзлим һөҗүм барышын.

Бәлки алар сугыш ачкан
синең өчен җир даулап?! —
Авыр сорау төсле орлык
тора мием бораулап.

...Туган йортта мине көткән
икмәк хәзер таш инде...
Ризык — булыр, әгәр сугыш
ашамаса башымны.

Ятып калсам, шытып чыгар
кесәмдәге арышым.

...Яуга икмәк аша карыйм —
шуннан тора бар эшем...

*6. «Эчтем, бераз үзем дә кыздым...»*

24.11.41

Йоттым шул: тахилгә генә
эчкән ди бит тавык та.
Яшәү өчен күтәрдем мин
утырсам да табутта[2].

Юк, әҗәлгә каршы дару
салып эчмим касәмә...
Сугышта син көн дә үләр
куркак булсаң — яшәмә!

Халыкларның канын эчеп,
исергәндә паразит,
көн дә үлем исереклеге
белән йөрү — хәрәм бит!

Эчми исерек булырлар ди
мәхшәр-үлем күзендә.
Ә мин аеклыктан гаҗиз,—
нигә? Белмим үзем дә.

Шәраб сорап тилмерттеме
җанымдагы хәйямлык?!

Бераз кыздым, әмма җебеп —
мәлҗерәргә чамам юк!

Юк, кыюлык өчен түгел,—
кыз катына ашкынмыйм;
шулай ук җан сызлавын да
хәмер белән басмыйм мин.

Тиредән үк чыга-чыга,
бер сөйләшер өчен дә
эчмәдем мин. Болай да сүз
тоткын түгел эчемдә.

Шундый афәт вакытында
түгел күңел ачуым.
Бу башыма йөз ләззәттән
өстен бер уй баш бүген.

Риза: янып үләргә дә,
булсын хәерхаһ кына.
Эчтем гомер шәрабымны
Ватанымның
исәнлеге хакына!

[1] Күзәтү торбасы.

[2] Җор күңелле сугышчылар землянканы шулай атаганнар.

Юындырды каен кызы! —
әйләндем күк сабыйга.
Карт тәнемә төште бугай
себеркенең сабы да.

Без бит сөттә коенмаган,—
ник яшерим мин аны?!
Юк, үзең дә керләнмичә
пакьләп булмый дөньяны.

Ләйсән, үзе пычранмыйча,
җирне ничек агартсын?!
Дөлдел түгел,— тапсыз тотып
булмый мирнең ак атын.

Кызу сугыш үзе үк, дим,
кара мунча түгелме?

7. *«Бүген мунча кердем...»*

28.11.41

Йокса йоксын тәнгә корым —
каралтмасын күңелне!

...Ә мин, бәлки, үз мәетен
үзе юган үлемдар?!

Җирне мунча кертешергә
әле гомер түлем бар!

Пычрануга түзалырмын
ант пакьлеге хакына.
Тик төшмәсен ил алдында
йөзгә нахак тап кына.

Җанга — мунча?! Сафлануның
бардыр башка юлы да.
Халкың өчен фида булсаң,
барысы да юыла.

8. *«Ат бер юрта, бер атлый.*

*Кучер 39 яшендәге бер кызылармеец, аның үзе дә, тавышы да акрын, бер дә минем гадәткә дә, минем әтәйнең гадәтенә дә охшамый. Акрын хәрәкәтенә эч кенә поша...»*

7.12.41

Атның салмак атлавыннан
җаным өшеп, кан катты.
Бәгыремнән өстерәлә
салпы чана канаты.

Әгәр өйсәм алашага
иңемдәге бар йөкне!..

— Дошман угы каршысына
коштай очып барыйкмы?!

Эчпошыргыч үшән кучер
әнә шулай ду килә.
Ә мин ярсыйм: «Соңгарырга
ярамый,— дип,— дуэльгә!»

— Бүлдерергә теләмисең
йоклап барган ат төшен...
— Ашыктырмыйк, Хәйретдиныч,
алгыр вакыт агышын.

Әллә сәгать туктап калган —
салып карыйм учка да.
Кыймылдамый утырамдыр
сыман кара мушкада...

Әллә инде, тирбәткәләп,
саташтырды ат мине?!
Шушы мыштыр кучеремдә
күрәм Сапый абзыйны.

Ябык чана зинданында
Апуш бара Җаекка!
Үрсәләнә янәшәдән
йөгерерлек җай юкка...

Шулай урап чыгуымы
тәкъдирендә язганны?
Әллә ясый маневрлар
алыр өчен Казанны?

Атышырга ашыгамы
Кара елга катына?
Шул ук канлы чана бугай,
башка, ахры, ат кына...

Кемгә икән, кемгә икән
артка таккан чанасы?!

Бөтен илгә яный бүген
бароннарның яңасы.

Буран булып сукты оран:
«Патроннарны не жалеть!..»

Юк, җәяүле йокы, җитте —
бишегеңдә син ял ит!

Яный барлык шагыйрьләргә
бәрелешнең яңасы.
Ватан исән калсын өчен
кемнәргәдер — атыласы,
кемнәргәдер — асыласы,
кемнәргәдер — янасы...

...Әкренлектән йөрәк сызлый,
кучеремнең — янбашы...
Төштәй кыска гомеренә
гасырларны сыйдыралган
Тукайҗанның чанасы
алсачы!..

*9. «Бүген бер фотокорреспондент мине, ак халат киертеп, фотога төшерде».*

15.2.42

Гасырлардан: «Төш, төш! — диеп,
киңәш бирә Кол Гали.—
Сүздән сурәт ясаучылар
сурәтсез дә калгалый...»

Канкай углы Бәхтиярдан
ишетмәдем хаклау ник?
«Дастан булып калучыга
сурәт нигә, полковник!..»

Мәгълүм инглиз китапчысы
сорап язгач фотосын,
Шиһабетдин Мәрҗанидән
галим ник бер хат алсын...

Мондый ядкарь таратуны,
бәлки, чүпкә саныйдыр:
«Хәтердәге сурәтеңнән
гайреләре фанидыр!..»

Сукыр Каюм: «Минем кебек
сурәт-сынсыз калма, дим!..
Һич югында охранкадан
төшерттерә алмадым...»

Шаярткандай итте шулай
«академик» Насыйри.
Фанатиклар кычкырышты:
«Сурәт — харам — җан сорый!»

...Фото-маһир Ксенофонтов
биләп алды бар гамем.
Бреслауда төшермәкче
булган фашист мәргәнен...

«Истәлеккә» калдырырга
ниятләгән ул аны.
Һәм төшергән... йөрәгенә
очып килгән пуляны...

Сурәтчене аткан фашист,
аткан, димәк, үзен дә.

Кара шәүләң катып калса
үлмәс халык күзендә?!

Аермачык күзаллана
Кол Галидәй зур затлар.
«Мәңгелекнең суларында
агып китте сурәтләр,
агып китте сурәтләр...»

...Ә фотокорр ашыктыра,
алдырмыйча сулыш та:
«Моңланмагыз — Сезне ташка
басыйк әле шук төстә...»

Юк, рәсемгә уйсыз гына
төшеп булмый сугышта.

*10. «Сугыш башланганчы хатын-кызга минем караш бик ялгыш булган. Мин хатыннарны сугышта паника күтәрергә генә ярый торган кешеләр дип саный идем».*

9.11.

*«Бүген Настя белән (без торган квартирада торучы 21 яшьлек кыз, кара чәчле, мөлаем йөзле, аның белән ни сөйләшсәң дә хәтере калмый) «Мин бу Скородноеда үлсәм, минем исемгә бер колхоз төзергә» сүз бирештек».*

21.11.41

«...Әтәч менгән читәнгә,
«Кик-ри-күк!» итәргә.
Әтәчкә дә хәбәр килгән
Армиягә китәргә».

Көйли-көйли киткән идем
шушы никрут җыруын.
Итегемне әле һаман
сала алмый йөрүем.

Җиңеп кайткач басмачыны —
әллә ничә бәк явын,
мине күпме үгетләде
Хаҗуафа апаем...

«Кал», дип, кызлар кочагына
кертмәк булды җим белән.

Имеш, гыйшык гашрәтендә
сәргаскәрләр җиңелгән!..

Йотылырсың — әгәр язса
юха кыздай зәһәр яр.
«Китәм,— дидем,— өйдә ятып,
алып булмас шәһәрләр...»

Ымсындыргыч «Калчы!..» сүзе —
агып тора баллары...
Сугышта да очраштырды
арзан ишек баулары.

Гыйбрәтләрнең төрлеләрен
күрдем сугыш юлында:
Мәхәббәттән нәфрәткәчә
төшкән гаурәт колын да,

«Илем, анам, ярым!» диеп,
янган йөрәк көлен дә...

«Зәгыйфь затлар» аркасында
чыккан кайчак сугыш та...
Юк, юк, мондый нәтиҗәгә
килмәм соңгы сулышта.

...Бүген Настя әйтеп куйды
үзәгемне өзәр сүз...
Ярый, кызлар, исемемне
кушып колхоз төзерсез.

Ташбилгем дә калмас, бәлки,
ядка алып еларга.
Яратудан янды, диеп,
я-ра-ту-дан ян-ды, диеп,
аңлатырсыз елларга.

*11. «...Минем үлемем — минем Ватаным, минем сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без: «Безгә үлем юк!» — дибез».*

«Сугыш язмалары», 6.1.42

Үзен-үзе утка бирер
әкияти феникс —
янә көлдән яралучы
мәңге үлмәс фани кош...

Шушы җанкай әллә ничек
төшкә кереп йөдәтә.
Нигә язмыш катгый сүзен
читләп-читләп йөз әйтә?!

Юраунамә, чегән төсле,
матур алдап көл миннән.
Без... яңадан яралганнар
мәгъмүр Болгар көленнән!

*...Шәһре Болгар каласында*
*Көлбикәнең*
*коесы тирән, суы юк.*
*Шәһре Болгар каласының*
*исеме калган, үзе юк.*

Хәтта нәсел агачының
көле күккә очса да,
халык рухы, фениксгай,
яңарырга көч таба!

Кат-кат янган Идел-йортын
яңабаштан гөл итә.
Хәрабәдән Мәрьям ана
булып калка Көлбикә...

Утка каршы фидаича
януыңны ил көтә!

Синнән тимер бөти[1] генә
торып калса көллектә?!

Мәңгелекнең балдакланган
кошы булу язганмы?
Башка үйлар эзәрлекли
әле бүген абзаңны.

Фашизмның каракошы
янар — тынмас җан һаман.
Әллә ничә башлы булып
терелмәсме яңадан?

Тагын гайрәт иңдерсәләр,
авызына салып кан?!

...Җирдә күпме мәдәният,
янып, кабат калыккан.

Җирең янса, Кояш улы
янган төсле яшендә,—
көлгә җан-рух өрер өчен
ярдәм итмәс әфсен дә...

Миләремне изә вакыт —
тыгызланган бигрәк тә.
Тамырларым, бикфорд кебек,
янып килә йөрәккә!

Утка каршы фидаича
януыңны ил көтә.
Йөрәккәйне күңел кошы
«Үлем юк!» дип җилкетә,
«Үлем юк!» дип җилкетә!..

...............

[1] Харбиләрнең кемлеген ачыклаучы ямьый торган тимер билге күзда тотыла.— Автор.

## Әхәт Мушинский

# АК БҮРЕ

ПОВЕСТЬ

1



Кичен син безгә килеп чык әле,— диде Аня, язу машинкасына чиста кәгазь бите кыстыра-кыстыра,— бүген безгә Тау Капланы кунакка килергә тиеш.

— Чынлапмы? — дип колагын торгызды Сергей.

— Әйе, ала каплан. Әнә, теге минем туным кебек,— дип, Аня ишек катындагы элгечкә ым какты,— койрыгы да бар.

— Я, я, үпкәли дә башлады инде. Юньләбрәк аңлатып бир әле.

— Әй, журналист исемен күтәреп йөргән буласың шунда. Спорт бүлегенә алып бара бит әле җитмәсә...

— Аһ, шайтан, шулай бит әле! — Сергей маңгаена сугып куйды: Аняларда бер төркем альпинистлар җыелырга тиеш иде ләбаса. Шунда илдәге иң зур пикларның дүртесен яулаган әлеге «Тау Капланы» да килергә тиеш иде.— Зырянов килгән, димәк?

— Кичә иртән самолет белән килеп төште. Тукталуын бездә туктады.

— Шәп булган бу,— дип Сергей кулларын уып алды,— күптән койрыгыннан тотарга йөри идем мин аның.

— Киләсеңме соң?

— Әлбәттә! Тик менә...

— Нәрсә?

— Дуремарыңны беләсең ич инде. Тагын шикләнеп карый башлар...

— Исемен бозмасаң ярамыймы? Теләсә кемнән көләргә генә торасың, бер дә бизәми бу сине, Сережа. Ә Нуриманның сиңа ни начарлыгы тигәне бар? Авыз ачып бер сүз әйткәне юк, ә син менә...

— Миңа ни булган? Соң, ул үзе, авызына су капкандай, бер сүз әйтми, күзенең агы белән тик карап утыра.

— Дәшмәү — дошманлык билгесе түгел ич әле. Ул болай да күп сөйләшә торган кеше түгел.

— Көнләшә бугай ул бездән, Аня.

— Куйсана, булмаганны.

— Куйдым, куйдым, бетте. Күптән шул Зырянов турында язарга кулым кычытып йөри иде. Эш беткәч уйнарга ярый ди: мин сезгә

---

ӘХӘТ МУШИНСКИЙ *(1951) — прозаик. Рус телендә Татарстан китап нәшриятында чыккан «Треугольники» дигән китап авторы. Казанда яши.*

кунак рәвешендә түгел, ә «коеп куйган» корреспондент буларак кына барырмын. Каплан белән очрашу өчен. Кемнең ничек каравында минем ни эшем бар?

— Акыллы кешедән акыллы сүз чыга. Карале, хоккеецны кайчан кертәсең? Сәгать биштә мин таям, машинкада үзең басарсың, безгә кунаклар килә.

— Чаптым! Сәгатеңә карап куй, ун минуттан текстны колагыңа тукый башлыйм.

Сергей шкафтан язу кәгазьләре алып, Аняга күз кысты да үзләренә чыгып йөгерде.

Яшьләр газетасының спорт бүлеге мөдире Сергей Матушкиннан кала, бер йөз унберенче бүлмәдә тагын культура бүлеге мөдире Бельский, авыл буенча хәбәрче, әле университет бетереп кенә килгән Красноперов һәм кырык биш яшьләрендәге, һәрчак көләч, түгәрәк йөзле Гөлсинә Шакирова да утыра иде.

Матушкин йөгереп килеп тә керде, утырып, автокаләмен кәгазь буйлап сәяхәткә дә җибәрде. Алканы кем, ничек, нәрсә белән каккага керткәнен уйлап торасы юк, мең тапкыр язылган инде: репортаж очерк түгел — ун минут, күп дигәндә унбиш минуттан эш беткән булырга тиеш. Кеше сөйләшкәне аңа комачауламый, ул хәтта үзе дә сүз кыстыргалап ала иде, яисә ул аны бөтенләй ишетми, беркемне дә күрми дә,— материал гына кызык булсын. Бүген исә ул яза да ала, сораганга җавап бирергә дә әзер, үзе дә сораштыра ала.

— Сережа, хоккейчылар заводка акча алырга гына киләләр икән, әйеме?

Моныcы Гөлсинә инде, башка берәү дә алай димәс.

— Беркатлы кеше дә инде син, валлаһи. Уйлап кара: аларның кыш буе уеннан, күченеп йөрүдән башлары чыкмый, ә җәен — тренировка, җыелулар, ял... Я, кайчан станок артына бассын ди алар?

— Нинди билет ди тагын, мин сиңа кассир түгел ич,— дип телефон трубкасына Бельский кычкыра.

— Әй, Бельский, карале, син миңа премьерага ике билет табам диган идең.

— Соң, ходаем, Сережа, бар да ал, билетлар иркен бит.

— Билетлары иркен булгач, нинди премьера инде ул?

Матушкинга иң якын утырганы Дима Красноперов иде. Ул, җилкәсе белән трубканы яңагына кысып, беренче биткә турыдан-туры хәбәр алырга тырыша, вакыт-вакыт:

— Күпме, күпме? — дип гаҗәпләнеп сорый.— Китегезче, андый ук савым булыр микәнни! Туктагыз, бер генә минут. Сережа, ничек синеңчә?..

— Дима бәгърем, эре мөгезлеләрдән башка теләсә нәрсә хакында сора — әйтәм дә бирәм. Ә аларны белмим.

— Ашаганда беләсеңдер бит?

— Ашаганда беләм. Аеруча сарык итеннән кәбаб яратам мин.

Матушкин сөйләшә торды, яза торды. Аның йөгерек алтын каләмен редакциянең иң каныгучан кешесе — җаваплы секретарь, күзлекле Хафизов кына туктатса туктата алыр иде. Бүлмәгә ул көтмәгәндә мыштым гына килеп керә, син җибәргән хата өчен ояла-ояла гына, болай язарга ярамаганлыгын аңлата башлый. Әгәр аның белән мәгънәсез бәхәскә керсәләр, ул кычкырынып, үзенең тоткан урыны белән масаймас, «сызып ташлыйм, бетте-китте» димәс, ә бәлки эчтән генә дулар, эчтән генә тантана итәр. Тыштан исә бу халәт күзлек тәртәсен ешрак төзәткәли башлавында һәм юл санын үлчи торган линейка белән янбашына шапылдатырга тотынуында күренә иде.

— Сережа, мин материалга мондый исемнәр куймаска үтенгән идем бит... Менә тагын...

Алтын каләм сөрлеккәндәй булды. Матушкин урындык артына сөялеп торайды. Хафизов тыныч кына дәвам итте:

— Үткән атнада син язманны «Кунакта югалткан алка» дип исемләгән идең. Астарлы шинель турында язганыңны гаепләп тормадым. Син солдат боткасы ашаган кеше түгел, шинельнең бернинди астарлыгы булмаганын белмисең. Головар, очколар турында сүз барганда, бөтенләй башка эш — стилистика!

Бу — перчаткага шап итеп сугып тавыш чыгару гына түгел, ә касыкка кундырып, астыртын нокаутка җибәрү! Монда ык-мык итеп тора алмыйсың инде.

Матушкинның аклануы бик сыек килеп чыкты. Соңыннан дикъкатен туплый алмый озак азапланды, яза башлагач та каләме җөмлә саен төртелде. Вакыт соң иде инде — материалын да үзенә түкелдәтергә туры килде.

Аняларга ул сәгать җиденчедә генә китеп барды. Күңелендә упкәчел бер хис тә бар иде: репортажын күтәреп машбюрога килеп кермәгәч, ни булды икән дип, китәр алдыннан Аня кызыксынып керергә тиеш иде кебек тоелды. Лифтта төшеп килгәндә: «Бармыйм!» — дип тә уйлаган иде, урамга чыккач, салкынча саф һавада бу фикердән җилләр очты. Аняларга ун минутлык кына ара иде һәм ул, каршы бәргән җилгә йөзен куеп, аларга таба йөгерде. Аня чакырды ич аны, һәм ул килеп сарырга түгел, ә эш белән бара аларга. Нуриман белеп торсын моны!

## 2

Аня Сабировага Матушкин ярты ел элек гашыйк булган иде. Аның чираттагы ялга китеп барышы, ә яңа машинистка Аняның ул көнне редакциядә беренче эш көне иде. Аня редакторның бер үк вакытта машбюро хезмәтен дә үтәгән кабул итү бүлмәсендә нидер басып утыра. Алар озак кына бер-берсенә кызыксынып карап тордылар, хәзер инде юньләп искә дә төшереп булмый торган, танышканда әйтелә торган бер-ике юк-бар сүз алмаштылар һәм аерылыштылар, дөресрәге, ул чыгып китте, ә Аня эшләп калды.

Көннәрнең берендә ул житди генә сәбәп табып, машбюрога керде, һәм тагын Аня аны сөенеп каршылады, алар озак кына сөйләшеп утырдылар. Дүртенче көнне — ул җомга көн иде — Аня:

— Нәрсә соң әле, Сергей, без һаман эш арасында гына сөйләшәбез? Әйдәгез, бүген безгә барабыз? Нуриман да синең белән танышуына шат булыр,— дип әйтеп куйды.

— Ә кем ул Нуриман?

— Ирем.

Үзенең чирек гасырлык гомерендә спорт журналисты Сергей Матушкин үз капкасына гарьләнерлек шайбаларны шактый керттерде керттерүен, әмма бу кадәресе булганы юк иде шикелле әле. Аны, әзерлек группасына яңа килгән бер малайны шаярткандай, кәкре каенга терәткәннәр булып чыга түгелме соң бу?

— Ирең бармыни синең, Аня? — «Ир» дигәне аның башына сыймый иде.

Аня елмаеп:

— Белмәгән булып кыланмасана! — диде.

Мондый ихтималны Матушкинның уйлап та караганы юк иде.

— Юкка гына Сабирова түгел икәнсең шул.

— Кияүгә чыкканчы Стрельникова идем мин. Син чынлап та минем кияүдә икәнемне белми идең мәллә?

Сергей башын чайкады: каян белсен ди? Һәм аны дачага чакырырга ниятләгәнен, әнисенең дә бу хакта белеп калганын әйтте, ә ул,

менә сиңа мә, ир хатыны икән ләбаса! Аня көлде генә: дачага Нуриманны да чакырса, бу эш барып чыкмаслык түгел, янәсе...

— Яхшы, икегезне дә чакырам,— диде Матушкин.

Шул көнне ул Аняның ире белән танышты.

Озын буйлы, җилпучтай җилкәләре өстенә шакмак башы менеп кунаклаган Нуриман арык спорт бүлеге мөдиренең күңеленә бер дә хуш килмәде. Буйлары болай бер чама да чамасын, арыклык, каһәр, аны Нуриман янында бер малай-шалай итә дә калдыра шул. Ишек катында алар кул биреп күрештеләр. Матушкин үзен иркен тотарга тырышкан булды, кем белән генә танышырга туры килмәде аңа — космонавтлар белән дә, чемпионнар белән дә... Аның һөнәре — танышу. Ул хәтта Сабировның җилкәсеннән дә кагып куйган булды. Нуриман исә хатыны сүзенә караганда аның яңа дусты булган әвәләнеп җитмәгән газетчыны күреп, артык соклану галәмәте чыгармады, бары теләр-теләмәс кенә: «Бик әйбәт»,— дигән булды.

Сабировлар бер бүлмәле фатирда тора иде. Бүлмәсе зур. Аны китап киштәсе икегә бүлгән: түр ягында киң тахта, бирге якта язу өстәле куелган. Шулай итеп, монда йокы бүлмәсе дә, кабинет та, кунак бүлмәсе дә бар дияргә була. Стеналарның бер генә буш урынын калдырмыйча карлы тау түбәләрен сурәтләгән эреле-ваклы фоторәсемнәр ябыштырылган. Почмактагы телевизор астында боз чаба торган балта никеле ялтырый.

Матушкин кызыксынып китеп: «Син альпинист мәллә, Нуриман?» — диде. Нуриман бер сүз дә әйтмәде, ул язу өстәлендәге кәгазьләрен, китапларын рәтләштерә, әйбәт кенә эшләп утырган лыгырдык бер журналист дачасына килеп сарырга чык та кит, имеш,— аның бөтен кыяфәте шуны әйтеп тора иде.

Аня:

— Әйе шул, ул мастерлыкка кандидат, ә минем беренче разряд,— дип мактанып алды.— Нәрсәсенә шаккаттың аның?

Матушкинның кыяфәте чынлап та сәеррәк булгандыр ахры, чөнки Нуриман да йомшап:

— Ыы, тощно,— дип куйды. Ул татар акценты белән «ц»ны «с» дип, «ч»ны «щ» дип әйтә иде.

Аня:

— Ул безнең физика-математика фәннәре кандидаты да әле,— дип өстәп куйды.

Ләкин Матушкин үзен кулга алып өлгергән иде инде һәм бу белдерүне гамьсез генә кабул итте. Нуриман, монысы нигә кирәк инде тагын дигәндәй, хатынына үпкә белән озак кына карап торды.

— Тынычлан, Нурым, кызма, күз нурым! — Аня аны иркәләп шулай «Нурым» дип йөртә иде.

Матушкинның йөрәгеп көнчелек хисе телеп узды, ул киштәдән ниндидер бер китап алды, укыштырган булды. «Ике тапкыр кандидат бит әле җитмәсә,— дип ачу белән уйлады ул,— өстәвенә Нуриман да түгел, Нурым. Инглиз Хиллари[1] диярсең, шайтан алгыры!»

Икенче көнне Нуриман, эшләр бар дип, Аняны дачада калдырып, шәһәргә китеп барды.

Шулай итеп, якшәмбе көнгә алар дачада, әнисен санамаганда икәүдән-икәү генә калдылар. Төштән соң, туйганчы кояшта кызынып, сулар коенгач, Матушкин Аняны гөмбә җыярга дип алып китте. Алар урманга байтак эчкәре кергәннәр иде ахры, егет шөбһәләнә калды: кая карама урман да урман, бер ачыклык күренми. Ә бит кич якынлашып килә, аяклар да авырайды, өйгә, шәһәргә кайту ягын да карыйсы бар. Аня, аның вәсвәсәсен күреп, бер кычкырып көлде дә озакламый

---

[1] Эдмунд Хиллари — Яңа Зеландия альпинисты, Эверестка беренчеләрдән булып менгән кеше (Автор искәрмәсе).

яр буена алып та чыкты. Алар талчыгып җылы комга утырдылар, кояшның елга аръягына төшеп баруын күзәттеләр. Су өсте киңлеге ялкау гына дулкынлана, каршыдагы шул киңлектә тынычлык тантана итә иде. Аня:

— Дөньяда шушы Иделдән дә матуррак җир бармы икән? — дип әйтеп куйды.

— Ә таулар соң? — диде Матушкин. Ул һаман да Аня белән альпинизмны янәшә куеп карый алмый иде. Ничек инде шундый зифа, нәфис Аня кыя-ташлардан үрмәләп йөрсен ди!

— Таулармы? — дип кабатлап сорады Аня.— Таулар ул башка...— Аның тавышы уйчанланды, ә карашы кояш баеп бара торган алсу-зәңгәр офыкка төбәлгән иде. Матушкин әле елга аръягына, әле кояш баешына, әле Аняның йөзенә, кояш баешы чагылган күзләренә карады, һәм аның шушы янындагы матурлыкка кушылып китәсе килде. Һәм ул яңагын Аняның чигәсенә тидерде...

Аня читкә тайпылды:

— Бусы нигә инде? Шунсыз гына булмыймыни?

Матушкин ни дип әйтергә дә белмәде. Гөнаһсыз бер хәрәкәтне нишләп әле теләсә ничек аңларга мөмкин икән бу дөньяда? Аның бит Аняга фәкать орынып кына карыйсы килгән иде. Ә нәрсә килеп чыкты: ул, имеш, ир хатынын юлдан яздырырга тели икән ләбаса. Оялудан Матушкин баеп бара торган кояштай кызарып чыкты.

Аня, чебеннән фил ясарга тырышуын аңлаптырмы, гаепле сыман:

— Үпкәләмә,— диде һәм кулын аның ут янган битенә куеп торды.

Якшәмбе сәяхәтеннән соң алар арасында ирләр белән хатын-кыз арасында сирәк очрый торган дуслык мөнәсәбәте урнашты. Андый дуслык ике якның берсе аз гына йомшаклык күрсәттеме, хәзер уалырга тора. Егет үз хисләренә хуҗа була белмәсә, яки хатын-кыз заты тойгылары тулып ашкан бер мәлдә үтенечле карашка таба беренче адымын атласа, бу дуслыкның эзе дә калмый.

Аняның ире аз сүзле, һәрчак үз эше белән мәшгуль, күңелсез бер адәм булып тоелды Матушкинга. Ул язу өстәленә тәртип белән салынган кәгазьләреннән башка хатынын да, аның дустын да күрми иде кебек. Һәм Матушкин, Аня ничек үзенә урын таба икән, ничек тора ала икән ул бу утын агачы белән дип гаҗәпкә кала иде. Хәлбуки, Нуриман вакыт-вакыт аларга авыр караш ташлап ала, һәм Матушкин ул караштан: «Аня, нәрсә таптың син шушы кәгазь бите буяучыдан?», яки: «Әйдә, әйдә, вакыты килеп җиткәнче гөрләшегез әле...» — дигәнрәк мәгънәне укый иде. Ә кайвакыт бу караштан: «Житте сиңа, туганкай, канны кыздырма»,— дигәнне дә аңларга була. Шуларны тойган минутларында Матушкин үзен үзе иң соңгы сүзләр белән битәрли, «Вәссәлам, монда минем соңгы тапкыр аяк басуым»,— дип антлар эчә. Аз гына күрми торса, тагын Аняның нурлы да, йомшак та, чакырулы да күзләрен сагына һәм аяклары үзеннән-үзе Сабировлар ягына тарта башлый торган булды.

Һәм менә тагын ул җилкенә-җилкенә аларга чаба. Аңа Зырянов белән көрәшеп, үзебезнең моңарчы караңгыдарак кала килгән альпинистларыбызны «яктыртырга» кирәк. Аннары, дөресен генә әйткәндә, альпинизм турында аның юньләп язганы юк. Әнә, газета укучылар бер мәкаләдән соң хәтта «Идел буенда нинди альпинизм булырга мөмкин?!» — дип хат җибәргәннәр.

Шуларны уйлый-уйлый, Матушкин, декабрь карын шыгырдатып, Анялар фатирына ашыга. «Кызык,— дип уйлады ул,—ниндирәк кеше икән бу Тау Капланы? Аның белән әйбәт кенә интервью эшләргә кирәк. Юк, очерк язу хәерлерәк булыр. Җентекләп сорашырга һәм шундый итеп язарга кирәк ки! Хафизовның күзлеге маңгаена менеп утырырлык булсын! Афәрин, Матушкин, менә сиңа җилкендергеч яңа бер эш күренеп тора...»

## 3

Тау Капланы тәбәнәгрәк буйлы бер адәм булып чыкты. Ул өстәл түрендә башкаларны тыңлап утыра иде. Чалара башлаган чәчләре кашына кадәр төшеп тора, ә каш астында бик эчкәртен кереп урнашкан үткен күзләре я әңгәмәдәшенә төбәлә, я уйчанланып кала. Табын янындагы һәр сүз аның монда икәнлеген истә тотып, кычкырып, махсус аның өчен, мондагы иң хөрмәтле кунак өчен әйтелә иде.

Тау Капланы — Зырянов Юрий Степановичка сүз бирделәр. Ул болай диде:

— Ак ашъяулык бөркәлгән табын янында без елга бер тапкыр, ике сезон арасында гына җыелабыз. Касәләрне дә менә шушылай итеп, елга бер генә күтәрәбез бугай. Галстук таккан килеш сезнең барыгызны бергә шулай ук елга бер генә тапкыр күрәм. Аны таккач, сез үзегезгә түгел, әллә кемгә охшап каласыз кебек, хәерле булсын... Быелгы тау менүләрне йомгаклап, алдагыларын билгеләгәндә, әйдәгез, бүген безнең арада булмаган кадерле дустыбызны искә алыйк.

Матушкин әкрен генә итеп, Анядан:

— Ә кем арада юк? — дип сорады.

— Зәйтүнә Даутова.

— Ә кайда соң ул хәзер?

— Кавказда һәлак булды.

— Ничек?

— Соңыннан аңлатырмын,— диде Аня,— тыңла.

Зырянов сөйли иде. Аның тавышы карлыкканрак, тәмәке тарткан-нандыр дип уйларга мөмкин иде. Әмма ул тәмәке тартмый, димәк, сәяхәтләр вакытында тавышына салкын тидергән. Матушкин Капланны күзәтә һәм уеннан аның сурәтен ясарга эпитетлар эзли, ул тауга менгәндә җил-давылларның көчсез булып калуын күз алдына китерергә тырыша иде.

— Я, егетләр, Коммунизм пигын уздык,— диде Зырянов.— Безне хәзер Тянь-Шань һәм тагын өр-яңа ике биеклек көтә.

— Тагын Терскей-Алатаумы? — дип сорады Матушкин каршында утырган җирән сакаллы иптәш.

— Юк, аны без инде аркылыга-буйга йөреп чыктык.— Зыряновның тоныннан, тирәдәгеләрнең аны игътибар белән тыңлавыннан Матушкин республика җыелма командасы члennарының чираттагы экспедициясе житди булачагын аңлап алды.

— Күкҗалга менәбезме?

— Күкҗал — гүзәл тау, тик ул бераз көтсен әле. Шулай бит, Нуриман?

— Әйе,— дип җөпләде Нуриман.— Безне Иркен Кылыч күбрәк кызыксындыра.

— Шулай,— диде Зырянов,— Иркен Кылыч — житди сырт.

— Кайсы сыртка караганда житдирәк...— дип, җирән сакал фәлсәфәгә бирелмәкче иде, аны Зырянов бүлдерде:

— Җитди булмаган тау булмый ул, Шура. Минем моны сиңа йөз тапкыр әйткәнем бар. Иркен Кылыч тапталмаган, шунысы әйбәт тә. Бөтенесе дә Җиңү пигына карый, Хан-Тәңрегә ашкына яки Терскей-Алатауны сөрә. Бу нәкъ менә шуларның уртасында — вертолеттан карап узу рәхәт, ә тәпи-тәпи барырга ераграк.

Зырянов ашыкмыйча гына өстәл янындагыларны карашы белән сөзеп чыкты. Нуриманнан башка берәүнең дә ул тирәдә булганы юк, шуңа күрә берәү дә сүз әйтә алмый тора иде. Беравыктан Зырянов дәвам итте:

— Хозурның хозуры ике пик! Һәркайсы алты мең тирәсе. Берсе — Ак Бүре, бик яман нәрсә. Дүрт ел чамасы элек шунда ике грузин альпинисты һәлак булды. Ә икенчесе, анысының исеме юк, төп сыртта — Күкҗал белән Ак Бүре арасында, тегеләрнең икесе белән дә басма

кебегрәк кичү белән тоташкан. Үзенә күрә өчпочмак кебегрәк.— Зырянов кулы белән ясап күрсәткәндәй итте. Бөтенесе дә аңладылар, бер Матушкин гына аңламады. Аңа күңелсез иде. Ул монда шаккаткыч вакыйгалар ишетермен дип килгән иде, хәзергә бар булганы — исемнәр дә атамалар гына. Һәм бу озакка киткән сүзләр, табыннан бигрәк, производство киңәшмәсенә охшап калган кебек иде.

— Ә ул исемсез түбәгә менеп тору кирәкме икән соң? — дип сорап куйды Җирән (аның Шура Шитов дип кул бирүе Матушкинның исенә төште).— Тасвирламасын язасы-нитәсе була... Вакыт әрәм итеп!

Зырянов аны ишетмәде дә диярсең:

— Шәп таулар. Икесе дә. Аеруча исемсезе. Чибәр дә чибәр, ул да чибәр! Яшь чак булса, анда сезне үзем алып менгән булыр идем. Билләһи, искитәрлек түбә ул. Күкҗалдан тәбәнәгрәк, ә Ак Бүредән биегрәк. Урталарында зифа манара күк утыра. Зәйтүнәбез ачуланмаса, без аңа аның исемен кушар идек. Зәйтүнә Даутова пигы, ә? Аның исемендәге урам бар, ә нигә тау да булмаска тиеш әле!

Табын дәррәү шаулый башлады. Фикер һәркемгә ошады. Матушкин да исенә килде. «Кызык бу информация»,— дип уйлап алды ул һәм янында утырган озын буйлы, бөркет кыяфәтле егеттән (исемен бу кадәр кеше арасында исендә калдыра алмаган иде):

— Карале, кая соң ул Даутова урамы? — дип сорады.

— Олы Утарда,— диде тегесе борылып та тормастан. Аның үз уйлары уй иде.

— Ак Бүредә, Юрий Степанович, берәрсе язу язып тур калдырмагандыр дисезме: «Монда без фәлән-фәләннәр булдык, термостан чәй эчеп утырдык»,— дип?

— Юк. Тауның исеме булса да, аның түбәсендә берәүнең дә булганы юк әле. Бүре дип аңа әллә кайчан, альпинизм барлыкка килгәнче күп элек исем кушканнар.

— Ә грузиннар?

— Алар, үткелне кичеп, түбә төбеннән кире борылганнар. Нык әзерләнеп, тылны да ныгытып куйганнар югыйсә. Мәгарә казып, бензинын, ризыгын, аяк киемнәрен калдырганнар. Тик өлкәне үпкә белән авырып киткән дә ике көннән вафат булган. Иптәше дустының гәүдәсен бивакка алып кайтырга тырышса да, хәленнән килмәгән. Аларны Ак Бүре белән исемсез түбә арасындагы әлеге үткелдән тапканнар.

— Мин аларның берсен беләм,— диде Нуриман,— Михаил Чаурия, шәп альпинист иде.

— Туктагыз әле, ник соң алай? Нәрсә хакына? — дип уянып киткәндәй булды Матушкин.— Даутова да... Ни өчен?..

— Алар үлемгә дип түгел, тау менәргә дип чыкканнар лабаса,— диде Док, тәлинкәсенә винегрет өсти-өсти. (Команданың докторы Ринат Вәлиев кул биргәндә үзен шулай дип таныштырган иде).

— Бу теманы туктатыйк әле,— диде Аня.— Сережа, син үзең дә нигә икәнен яхшы беләсең бит.

— Акылым белән аңлыйм да бит, ә менә күңел... Гомерләре үзелер булгач, нигә шулай ашкынырга?

— Романтика,— дип куйды Док.

— Шулай,— дип килеште Матушкин,— кеше үзе романтика инде ул. Җан иярләреннән бары кеше генә үз тормышын үзе катлауландырырга сәләтле.

— Бу таш безнең бакчага инде,— дип көлеп куйды Шитов.

— Кыек атып туры тигезде, дип өстәде кемдер.

— Без кешедәге мөмкинлекләрне сынаучылар,— дип икърарлады өченче берәү.

— Куйчы әле! — дип кул селтәде аңа каршы Шитов.

Ниндидер бер көч Матушкинның теленнән тарта иде. Нинди көч икәнлеге мәгълүм инде — журналистлык шаукымы. Хәзер ул үз эшенә керешкән, егетләрне кыздырырга тотынган иде.

— Принципта ул альпинистларның ни файдасы бар соң? Футболистлар бер хәл инде — алар кассаны баеталар, ә сез соң? Гомерегезне жилдә җилфердәтеп, шуның белән горурланасызмы? Гомумән, альпинизм миңа шикле һәм нормаль булмаган нәрсәдер кебек тоела. Рух көчегезне сынап карыйсыгыз киләме? Моны шәһәрдә дә эшләргә мөмкин. Әнә күпме икейөзлелек, эшкуарлык, башбаштаклык, хулиганлык... Мәйдан җитәрлек, җиңеңне сызган да сынал гына! Ул-бу була калса, инде монда сине бау да, хәтта капрон аркан да коткарып кала алмаячак. Егылсаң — беттең дигән сүз. Менә шул. Ә сез әллә кая Каф таулары артына, Тянь-Шань биекләгенә сикерәсез.

— Үзеңнең тауларда булганың бармы соң? — дип сорады Шитов.

Матушкин тыныч кына:

— Юк,— диде.

— Бер дәме? — дип кабатлап сорады Шитов.

— Бер дә, ә нәрсә?

— Шул. Шундый журналистлар күбәйде хәзер.

— Ничек инде «шундый»?

— Күрмичә белә, белмичә хөкем чыгара торган.

«Нигә җирән кешеләр мыскыллаучан булалар икән?» — дип уйлап куйды Матушкин. Ә Шитов, күзләрен хәйләкәр кысып, дәвам итүендә булды:

— Бер бәләкәй генә тауга, беренче категория кыенлыктагысына менеп карасагыз иде. Бүрек чаклысына күтәрелгәнегез булса, башкачарак сөйләшер идек тә бит... Ә болай...— дип кулларын җәеп җибәрде ул,— бер-беребезне аңламыйбыз шул.

— Менә алмас дип уйлыйсызмы?

— Ә нәрсә монда сүз куертып торырга, ди? Тянь-Шаньнан булса да бер әйләнеп кайтыгыз. Бер уңайдан җанашыгызга эдельвейслар да җыеп кайтырсыз.— Шитов шулай диде дә Аняга карап алды. Матушкин аның ниятен аңламады аңлавын, әмма Нуриманның башы аска иелгәнне күрде. Бу вакытта Шитовның профессиональ журналист белән чәнчешүен бөтен табын тынлый иде инде. Аларны Зырянов та күзәтә иде.

— Форсаты килеп чыкса, ник әле барып карамаска икән? — диде Матушкин.

— Әлбәттә, әлбәттә,— дип кыланды Шитов,— ник барып карамаска ди? Тянь-Шань таулары безнең культура һәм ял паркындагылардан бер дә ким түгел. Әйдәгез, безнең белән бергәләп сәйран кылырбыз. Ничек, Юрий Степанович? Үзебез белән алабызмы егетне? — Шитов күңелле генә итеп Зыряновка карап алды. Тегесе сүз катмады.— Берике тауга алып менәрбез, җөйләре сүтелмәсә, әлбәттә.

— Сүтелмәс,— диде Матушкин катгый гына.— Тик, кызганычка каршы, мин сезнең белән бара алмам: контроль пункты җибәрмәс.

— Куркасыңмы? — дип йомгаклап куйды Шитов.

— Һич юк, әйтәм бит...

— Ну, монысы чүп кенә аның, Юрий Степановичтан сорасаң, берниндн кыртә-фәлән булмаячак.— Шитов Матушкинга сынаулы карашын текәде.— Теләгең булганда...

— Бик рәхәтләнеп барыр идем дә бит, миңа газетчы буларак та кызык әле ул. Аннары, минем күптән инде альпинизмның мәгънәсен аңлыйсым килеп йөри. Ә кабинетта утырып кына аңа төшенеп булмый бит.

— Ә ул мәгънә кемгә кирәк соң? — дип, җилкәләрен җыерып куйды Док.— Мәгънә, имеш... Ә штанга күтәрүдә ни мәгънә, мәсәлән?

Докның соравын Матушкин җавапсыз калдырды, чөнки аның иң төп сорауга җавап бирәсе бар: күзен дә алмыйча җирән Шитов аңардан сүз көтә. Аня да көтә. Зыряновның дәшми утыруын аңлап булмый, ләкин бер нәрсә ачык — монда күзгә төтен җибәреп кенә котылырлык түгел, үзенең куркакмы-түгелме икәнен турыдан-туры әйтергә кирәк иде.

— Юрий Степанович, сез, зинһар, бәхәстә артык кызучан дип уйламагыз инде. Бик күптәннән альпинистлар белән тауларга китәсе килеп йөри иде. Сәяхәт тәмен үз җилкәмдә татыйсым килә. Китаплар күп укыдым, фильмнар карадым һәм һәрвакыт үз-үземә: «Миннән булыр иде микән?..» — дип сорау куя идем. Аннары сез сөйләгәннәрдән чыгып кына түгел, кем әйтмешли, натурадан язасым килә. Юрий Степанович, үзегездән калдырмасагыз, мин шундый материал умырып ташлар идем!

— Эш материалда түгел! — дип җавап кайтарды Зырянов.

— Нәрсәдә соң?

— Нәкъ әнә теге «мәгънә» дигәнегездә: сезгә кирәкме икән соң ул?

— Дөресен генә әйткәндә, мин монда шуның өчен дип килдем дә. Сүздә генә башкачарак килеп чыкты.— Матушкин Шитовка карап алды.— Бер яктан караганда, яхшыгадыр да әле бу: мин нәрсәдән башларга икәнен белмичә аптырап йөри идем. Эш шунда ки, альпинизм турында очерклар циклы язып, спортның бу төрен һәр яктан капшап карамакчы идем. Үзегез дә килешәсездер: журналистлар сездән шактый ерак тора. Тау түбәсенә менү турында радиодан да, телевидениене әйткән дә юк инде, турыдан-туры репортажлар тапшырмыйлар әлегә.

— Анысы шулай,— диде Док.

— Менә сез зур нәрсәгә оеткы салгансыз,— дип дәвам итте Матушкин,— беренчеләрдән булып тау түбәсен алу. Ә моны кемнәр беләчәк соң? Кайткач язылган бер-ике мәкалә кисәге эшләнгән эшнең йөздән берен дә күрсәтә алмаячак. Экспедициянең тәрбияви әһәмияте хакында әйтеп тә тормыйм инде. Анысы — ачык нәрсә. Ләкин сезнең йомыкый компаниягезне, бигрәк тә аның хезмәтен, романтикасын күпчелеккә аңлатасы иде. Шулай булгач, йөз мең тиражлы безнең газета трибунасын санга сукмау гөнаһ булыр иде. Юрий Степанович, команда һәм газета дигән сүзләр — сүз генә түгел, безнең уртак эшебез дә бит әле. Мин бер нәрсәдән генә куркам: ризалык бирсәгез, мин сезгә җәфа гына булмам микән?

Матушкинның сүзе бетте. Табын да сүзсез калган иде. Зыряновка ни булса да киңәш итү, аннан үтенү, аны ышандырырга тырышуның кирәге юк иде ахрысы. Зырянов ашъяулыкны сыпыргалады, ипи валчыкларын чүпләгәндәй итте.

— Юк, җәфа булмассың,— диде ул, ниһаять, башын күтәреп тормыйча гына.

— Димәк, сез мине дә алачаксыз?

Зырянов башын күтәрде:

— Уртак эш хакына, Сергей.

— Ничек була соң әле бу? — дип гаҗәпләнде Матушкин.— Медосмотр үтмичә, капыл гына? Гади бер алла бәндәсе сезнең белән тау менәрме?

Җавап булмады. Аня, аны кочаклап, битеннән үпте, бөркет борын касыгына нык кына төртеп алды да, табын дәррәү гөрли башлады. Матушкин үзен герой итеп сизде. Хәтта Шитов та үзгәрде:

— Курыкма, егет,— диде ул.— Тауларда калага караганда да хәвефсезрәк.

Бер ун минутлап Матушкин игътибар үзәгендә йөзде дә, аннары сүз әүвәлге эзенә төште. Өстәл уртасындагы коньяк муенын сузып утыра бирде, ә компания аны бөтенләй күрмәгәндәй, тырнаклар[1], ка-

---

[1] Тырнак — тау бозлыгында альпинистлар ботинкасына кидерелә торган очлы тешле металл җайланма.

рабиннар, ыргаклар конструкциясе, курткалар һәм йокы капчыкларын ничек тегү, корыч һәм титан, тавык һәм гага мамыгы сыйфаты турында фикер алыша иде. Чиратлашып, кычкырмыйча гына вәкарь белән сөйләделәр. Матушкин, күпме тырышмасын, кызыксынып тыңлый алмады, аңа күңелсез булып калды, гүя ул инженер һәм фән кандидатлары, разряд ияләре һәм спорт мастерлары — кызыклы, көчле, күпне күргән кешеләр белән түгел, ә берни аңлап булмый торган бер баптистлар янында утыра диярсең.

— Үткән елгы тырнаклар юньле булып чыкмады,— дип сөйли иде Шитов.— Уйлап, баш ватып карагач, Док белән без алгы тешләрнең почмагын киметергә булдык.— Ул кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь тартып чыгарды (сызымдыр, күрәсең). Барысы да аның иҗат җимешен карарга сузылды. Матушкин да тыгылмакчы булып караган иде, бер дә кызыгын тапмыйча, Аня янына кухняга чыкты.

— Я, Аня, мине Тянь-Шаньга аласыңмы?

— Алам.

Матушкин аның җилкәсен кагып алды. Аня бәрәңгесе чыжлый башлаган табага иелде:

— Сережа, бар егетләр янына чык.

Матушкин китте.

Ул арада тегеләр томат соуслы килька хакында, аның ерак сәфәрдә бүтән һәртөрле консервага караганда әйбәтрәк «үтүе» турында гәпләшә иде инде.

— Майлы консерва, бәлки, бөтенләй алмаскадыр? — диде Док.

— Юк,— дип җавап кайтарды Нуриман,— ассортиментны чикләмик.

Сөйләгән арада Нуриман әле генә кухня ягыннан килеп чыккан Матушкинның күзләре белән килька урынына ашый иде. Үз сугындагы килька урынына. Дөресрәге, кипкән килька урынына. «Карап карарбыз,— дип уйлап куйды Матушкин,— чебешләрне тау башына менгәч санарлар».

## 4

Икенче көнне йөз үнөченче бүлмәдә Матушкинның тауларга китүен тикшерүдән дә зуррак эш булмады.

— Киселерсең, картлач,— дип сагайтты Бельский.— Синдәйләр кулыннан килә торган эшме соң, кара инде үзеңә — эчеңдә җаның гына калган бит. Анннары анда, биектә, эчтә яткан бөтен чирең өскә калкып чыгачак бит. Менә, әйтик, син монда чакта язвалың барлыгын белми йөрисең ди, ә тауларда бит — килде-чыкты булыр һәм вәссәлам. Кайдандыр укыган идем әле, анда гади генә ангина кешене сындыра да кабергә дә кертә икән. Ангина түгел, гади генә томау да хәтта! — дип Бельский елмайгандай итте.

— Ой, ой, алай димә, юрама,— диде куркып куйган Гөлсинә.— Сережа, ә редактор нәрсә ди?

— Ә редактор, Гөлсинә ханым, ял бирә, аңа тагын ун көн командировка өсти — бар, Сергей Матушкин, тауларыңа, җый эдельвейсларыңны ди.

— Алай,— дип кабатлады сокланган Красноперов.— Алай, Сережа!

Бельский кызыксынып:

— Ә әҗерен ничек кайтарырсың? — диде.

— Очерклар белән. Хәзер үк башымда фикерләр кайнап тора. Кайбер бүлмә ияләренә күрмәгәннәрен күрсәтәм әле.— Матушкин имән бармагы белән җавaплы секретарь утырган якка төртеп алды.— Ничек эшләргә кирәген күрсәтәм әле бер.

Матушкин мөрәҗәгатен ишеткәндәй, ишектән Хафизов килеп керде.

— Сережа, син Тянь-Шаньга җыенасың икән,— дип, ул күзлек дугасын рәтли башлады.

— Шулай шул. Эдельвейска барам.

— Шәп нәрсә. Кайчанрак соң?
— Дүртенче июльдә Пржевальскига очам.
— Әзерләнә башларга кирәк.
— Иртәгәдән күнегүләрне башлыйм.
— Юк, мин ул хакта түгел. Шәп кенә сораулар белән берәр анкета әзерлисеңме шунда. Альпинистларның кызыклы җавап кайтарырлык итеп.
— Әйтик, тау менгәнче төшүеңне уйла дигән әйтем дөрескә туры киләме? — дип теш шомартты Бельский.
— Нигә, андый сорау да булырга мөмкин. Шәп сорау,— диде Хафизов.— Альпинистлар җавабын табар. Тагын нинди сораулар куярга мөмкин икән, уйлашыйк?
— Җәмәгать, баш ватмагыз,— дип сүзне бүлдерде Матушкин,— үзем уйлармын.— Шулай диде дә, үзләреннән чыгып, күршедәге хатлар бүлегенә керде, аннары Аня бүлмәсенә таба атлады.
Аня машинкада Красноперовның «боламыгын» басып утыра иде. Бераз тын утырганнан соң Матушкин: «Кичәгедән соң кәефләр ничегрәк соң?»— дип сорады.
— Әйбәт,— диде Аня,— син киткәч, без әле Памир слайдларын карап утырдык. Бераз арытты инде, өчләр тирәсендә генә яттык.
— Күзәтүемчә, сезнең компания аз эчә, күп ашый икән, аеруча Док.
— Анысы бар инде. Ул үзендә «ашказаны чокыры» дигән авыру бар дип әйтә.
Матушкин көлемсерәде, аннары бераз уйланып торгач, беләгеннән тотып:
— Нуриманга минем сезнең белән бару ошамый бугай? — диде.
— Әйе,— диде Аня, эшеннән туктап,— ул Зыряновның синең хактагы фикерен иртәрәк дип уйлый. Бернинди күнегүләрсез... Уен эш түгел бит.
— Ә нигә ул аны әйтмәгән соң?
— Чөнки Зырянов белән бәхәстән файда юк. Барыбер ул хәл иткәнчә булачак. Өчебез генә калгач, Нуриман шиген әйтте аңа. Тик... ни файда.
— Зырянов — егет кеше, ә синең карткаең көнләшүеннән тиресенә сыя алмый.
Аня җавап бирмәде. Ул тагын машинкасын шыкылдата башлады.

## 5

Матушкинны Нуриман бер күрүдә сөймәде. Ниндидер эленкесалынкы, таркау, әйтерсең, модалы кием астында ниндидер бик кирәкле гайкасы ычкынган; үз бәясен үзе белә торган, чибәр генә йөзле, солитер кебек юка һәм аксыл Матушкин аның саруын кайната иде. Акыллы һәм зирәк, фальшьны бик тиз тотып ала торган Аня Матушкинда боларны сизми, күрәсең. Матушкинның көзге алдында чуалуыннан, шкаф ялтыравыгыннан да үз кыяфәтен эзләвеннән үк аның Нарцисс икәнлеге күренеп тора бит. Һәм ул икенче бер кеше хакына үзен корбан итәргә дә сәләтле кеше түгел. Андый кеше белән тауларга юл тотарга ярыймы соң? Кәкре каенга шәп терәтте ул үзләрен: альпинизмны спорттан алып ташлый торган софизмнардан башлады да, аңа булган кайнар мәхәббәте белән тәмам итте. Хәтта экспедициягә чыгарга рөхсәт тә алды. Башта бит юкса Шитов аңардан куркаклыгын таныта язган иде инде. Коры чыкты судан — профессионал шул, ни әйтсәң дә журналист. Юк, Матушкин, анысы, ир кеше түгел дә түгел инде. «Ә, бәлки,— дип уйлады Нуриман.— Бу аңа гына шулай тоела торгандыр. Башкалар өчен ул егеттер. Аня өчен дә, бәлки. Бәлки, иң әлек аның өчендер дә әле».
Юк, ул Аняны аңлый алмый. Эштә үз бүлегендәге кырык сигез хезмәткәрне аңлый ала, ә менә өйдә үз хатынын аңлар әмәле юк.

Нуриманның Аня белән танышуы ел ярым элек Памирдагы «Варзоб» лагеренда башланган иде. Әллә ние булмаган бер тау түбәсеннән төшеп килешли, бивакка кайтып життеләр дигәндә генә, инде бауларны иңнән салып, чорнап куйгач, аягы таеп, Аня ком-таш өсләтеп тәгәрәп китте. Аста — трамплин кебек текә кыялар түбәсе. Нуриман аның артыннан сикерде. Алар трамплинга икесе берьюлы диярлек килеп чыктылар һәм Аня, Нуриман аны билбавыннан эләктереп алганда, һавада иде инде. Үзе кәрнизгә ничек кирәк алай ябышкан килеш, бер-ике секунд ул аны шулай тотып торды да әкренләп өскә таба өстери башлады. Аняның умрау сөяге сынган, каты бәрелүдән ул шактый курыккан иде.

Шушы вакыйгадан соң Аня гел Нуриманга ияреп йөри башлады. Нуриман башта мондый көтелмәгән игътибардан кыенсынып йөргән иде, иптәшләре ачыктан-ачык көлә башлагач, аның белән, гомумән, очрашмаска тырышты. Әмма һичнәрсәдән бәйсез нормаль ир кеше, акыллы һәм чибәр кыз аны мәхәббәте белән бәхетле итәргә торганда, нишли алсын ди. Яман авызлар, үзен коткарып калган өчен Аня Нуриманны шуның белән ризалаткан икән дип лыгырдадылар. Яшьләр үзләре исә, Варзоб вакыйгасын искә бик төшермичә, тату гына яшәүләрендә булдылар, һәм Нуриман, сабыр табигатьле кеше буларак, хатынын көннән-көн ныграк ярата барды.

Һәм менә Аня янында көннәрнең берендә Матушкин пайда булды.

Теге кичәнең икенче көнендә Аня:

— Ник син аны шулкадәр сөймисең? — дип сорады.

Нуриман никадәр генә сабыр булмасын, үзсүзле һәм башбирмәс көнчелеген никадәр генә эчкә яшерергә тырышмасын, бу юлы ул хис аның күз карашында гына түгел, ә уйлаганын ачыктан-ачык әйтеп салуда да чагылды:

— Аны син яраткан да бик житкән!

— Яче, зинһар. Ул миңа иптәш кенә. Эшем буенча. Бары шул.

— Артыграк түгелме?

— Түгел.

— Ярый,— диде тынычланган йомшак тавышы белән Нуриман,— ярый. Тик берәр нәрсә сизсәм... Әгәр белсәм, мин аны...

— Нәрсә? Нишләтмәкче син аны?

— Бернишләтмим,— диде Нуриман салкын гына.

Ул башка бер сүз дә әйтмәде. Язу өсталенә җәеп салган сызымы өстендә карандашын йөртте, һәм аның бу бертөрле хәрәкәтләрендә нин-дидер хәвеф һәм мәжбүрият бар кебек тоела. Аняның ирен беренче тапкыр шундый кыяфәттә күрүе иде.

## 6

Киләсе көннән Матушкин, Хафизовка вәгъдә биргәненчә, ныклап әзерләнергә тотынды. Болытлар өстендәге Тянь-Шань түбәләренә экспедициягә чыгу ул, чыннан да, «Динамо» стадионындагы футбол матчына бару гына түгел. Бельский хаклы: күнегүләрсез анда бик тиз сыгылып төшәрсең. Матушкин, үзенең мөмкинлеген истә тотып, физик күнегүләр планын җентекләде, альпинизм буенча әдәбият исемлеге, туклану һәм, гомумән, яшәү режимы төзеде. Ул лифтта йөрми башлады: сигезенче этажда (эш бүлмәсенә) һәм уникенчегә (өйгә) ракета кебек кабынып килеп керә, бик житдиләнеп пульсын тотып карый һәм һәртөрле сөйләшүне тау араларында кислород житенкерәмәү темасына күчерә торган булып китте. Февраль буранындамы, апрель пычрагы янсә июнь челләсендәме — аның Казанка суы дамбасыннан юырткaнын, иртәнге якта пляж турникларында тартылганын һәм алдагы экспедициягә кагылышлы бөтен мәсьәләләр тикшерелә торган альпинист «чәршәмбеләре»ндә утыруын күрә иделәр. Апрель ахырында киләчәкнең тау менәре балконда Шитов биргән йокы капчыгында берничә төн үткәрде. Капчыкта алай салкын

түгел, әмма бик җайсыз иде. Алда вакыт күп әле дип, Матушкин кабат бүлмәгә кереп, җылы урынында йоклый башлады.

Һәм менә дүртенче июль — юлга чыгу көне дә килеп җитте.

Иртәнге сәгать тугызда әнисе Евдокия Ефимовна рюкзакны тутыра башлады.

Саубуллашу ашына Красноперов белән Гөлсинә килеп җитте. Бер ун минуттан Хафизов та килеп керде. Матушкин рас уйлаган булып чыкты: әшем кешесе Бельский иптәшен озатырга вакыт таба алмады. Башка чакырылган кеше юк иде. Матушкинның исәп-хисапсыз дуслары аның маҗаралары хакында газетадан укып белсеннәр әйдә.

Спорт киемнәре кигән Матушкинны иптәшләре һәм әнисе озата чыктылар. Рюкзакны Красноперов күтәргән. Ул үзе мышный, үзе троллейбуска чыкканда адым саен:

— Сережабыз шушы кадәр йөкне тауга күтәреп менәчәкме инде?! — дип туктаусыз гаҗәпләнә иде.

Троллейбус озак килми торды. Яңгыр сибәли башлады. Евдокия Ефимовна хафаланып зонтигын ачып җибәрде.

— Менә күрдеңме инде, зонтсыз нишләмәкче буласың анда? — дип аны улына сузды.— Бер дә артык булмас ул анда.

Сережаның ачуы чыкты:

— Я инде, әни!

Озак көткән троллейбус, өсләренә пычрак сибеп, туктамыйча да узып китте. Такси тотарга туры килде.

Аэропорт. Экзотик альпинистлар төркеме гомум игътибар үзәгендә иде. Аларның төрле төстәге киемнәре дә, ялык-йолык килеп торган боз кәйләләре дә, ат сыртына гына салырдай авыр йөкләре дә вокзал халкын кызыксындыра иде. Матушкин килеп исәнләште дә танырлыклары калмаган иптәшләрен карый башлады. Беренче итеп, ул, әлбәттә, Аняны күрде. Спорт киеме — чалбар, майка аның сыгылмалы, альпинистларча көчле буеның зифалыгын яшерми генә түгел, киресенчә, көчәйтебрәк күрсәтә һәм бу хәлдән Матушкинның пульсы бермә-бер ешаеп китте. Ул экспедициянең бүтән катнашучыларын да күздән кичерә иде. Әнә Шитов — су үткәрми торган чалбар кигән, француз боз кәйләсен кочаклап Док утыра. Ә Матушкинның үе Аняны ташлап китә алмый, һаман шул тирәдә бөтерелә. Әйе, ул аны сөя! Сөя һәм шуңа күрә генә дөньяның аръягына юлга чыкты да. Аняга якын булган бу компаниядән, аның барлык дусларыннан ким булмавын ул, ниһаять, исбат итәргә тиеш. Ул аңа үзенең ялтыравык буш курчак түгеллеген раслап күрсәтер. Менә бер ел инде Аня аны үрти дә, газаплый да, ә үзе кул белән орынырга да рөхсәт итми. Иренә тугрылык саклыймы? Аның кияүдә, ә Сережаның егет башы белән аңа гашыйк булуына кем гаепле соң? Шул Нуриманнан — нафталин исе килеп торган аяклы сандыктан нәрсә тапкан Аня? Бер генә дә үз фикере юк бит аның ичмасам. Үзе фәннәр кандидаты булып йөргән була бит әле тагы, лаборатория мөдире, имеш!

Нуриман турында уйлаганда, Матушкин аның рейс расписаниеләрен карап торганын күрде. Әгәр кичә аңа Сабировның сәфәр киемендәге якынча кыяфәтен сурәтләп бирергә кушсалар, Матушкинның бу эше барып чыкмаган булыр иде. Бу очракта хыял байлыгы да, альпинистик әдәбияттан алган тирән гыйлем дә ярдәм итмәс иде, мөгаен.

Спорт мастерлыгына кандидат Нуриман Сабиров «кырык ямаулы» шакмаклы фланель күлмәк, чалбар диярлеге калмаган трикотаж спорт чалбары кигән иде. Бу нык уңган, тезләре чыккан чалбарны озын ыштан дисәң, дөресрәк булыр иде. Нуриман сул кулын су үткәрми торган зәңгәр материалдан тегеп куелган артќы кесәсенә тыккан, ә уң янбашында сүтеп алынган кесә урыны уңарга өлгермәгән, ул кара тап сыман чекерәеп тора. Шушы Нуриман өендә язу өстәле янында галстук киеп утыра диген! Әллә юри шулай киенгән микән?

Матушкин үзенең зәңгәрле-кызыллы-аклы кроссовкасына карап алды: юк, ул Нуриман кебек карачкы хәлендә түгел.

Рюкзакларын, тартмаларын, капчыкларын күтәреп, ишеккә таба юнәлделәр. Аларга озатучылар иярде.

— Сереженька, берүк сак була күр!

— Газета йөзенә тап төшермә, Сергей!

— Эйдельвейс алып кайтырга онытма!

— Сау бул, әни, хушыгыз, егетләр!

## 7

Пржевальск кечкенәрәк кенә, тузанлы, бер этажлы шәһәр икән. Алма-Ата аэровокзалында куныш, Пржевальскига килеп төшкәннең икенче көнендә команда көн буе такта басмалар буйлап бер азык кибетеннән икенчесенә йөгерүдә булды. Азык-төлек башлыгы итеп Нуриман билгеләнгән иде. Ул, блокнот-ручкасын кулына тоткан килеш, кемгә нәрсә алырга, нәрсәне кая куярга, кемгә нәрсәне карарга кирәклегенә боерыклар бирә. Алынган әйберләр күплегенә сатучылар бер дә шаккатмый: бу шәһәрдә альпинистлар шаукымына күнеккәннәр инде.

Кибет ыгы-зыгысы Матушкинны кыбырсыта башлады. Пржевальскиның үзеннән торып тауларны бөтенләй диярлек күреп тә булмый. Беренче тапкыр ул аларны Алма-Атадан очканда самолет иллюминаторыннан күргән иде. Уенчык кебек кенә булып шәйләнсәләр дә, алар өстендә кар ята, болытларны тишеп чыккан тауларның очы-кырые юктыр сыман. Җиргә килеп төшкәч, эсселек, кибетләр, кырмыска кебек чабулар башланды. Төш вакытына Матушкинның тәне дә, жаны да тәмам арыган иде.

Озакламый Кыргызстанга поезд белән баручы төркем килеп житте. Алар арасында башкомандующий Зырянов та бар иде. Ул: «По коням!» — дип кычкыруга, команда брезент япмалы ике грузовикка менеп төялде дә тауларга карап юлга чыкты.

Машиналар көчәнеп, үкерә-үкерә бормалы-сырмалы тау юлыннан һаман үргә менәләр. Машина менә-менә упкынга очар кебек тоелган текә борылышларда, кайнап-шаулап аккан тау елгаларын кичкәндә Матушкинның җаны табан астына төшеп киткәндәй була, тәннәре чымырдап китә. Ул бердәге шоферларның тәжрибәле халык икәнлекләрен белә һәм бу бормалы юлларда аларның үзләрен кала урамындагыдан иркенрәк сизгәннәрен дә аңлый, тик уй дигәнне нишләтәсең аны. Руль тотмаса яки шофер берәр борылышта авызын ачып калса, нәрсә буласын Матушкин бик ачык күз алдына китерә иде.

Ниһаять, бәрелә-сугыла өч сәгатьләп баргач, туктадылар. Матушкин оеган аягында көчкә басып тора иде. Әйберләрне бушату бер сәгать чамасы вакытны алды. Машиналар җинел сулап куйгандай фырылдап китеп баргач кына, ул тирә-ягына каранып алды.

Тау түбәләренә кояш соңгы нурларын сибә иде. Ә монда — үткел төбендә, кар суларыннан котырган елга янында, Тянь-Шаньның шәмсыман чыршылары астында салкынча иде инде. Егетләр, мамык куртка киеп, палатка куя, ризыкларны тәртипкә сала башладылар. Зырянов ноль-ноль сәгатьтә генә ятарга команда бирде, ләкин барыбер күп нәрсәгә куллары җитми калды.

Төн. Ай йөзә. Йодрык кадәрле йолдызлар. Һәр тарафта кара тау диварлары төсмерләнә. Тынлык. Елга гына, ай нурында елтырап, палаткалар яныннан үкереп ага.

Матушкин, йокы капчыгын каптырып, күзен йомды. Ләкин мондый коточкыч үкерү астында йоклап була димени? «Урынын да таптылар соң! Елгадан ике адым читтә, төнлә бөтенебезне юып алып китмәсә ярый», — дип уйлады ул. Күзгә йокы керми — юкка гына, «йокы капчыгы» дип атаганнар моны. Рәхәтләнеп өйдә, йомшак мендәрдә ятасың килмәгәч, газап чик әйдә!

...Ул үз тавышыннан үзе куркып уянып китте. Күршеләре Шитов белән Док мышнап йоклыйлар. «Төшен дә әйтер идем инде!» — дип көрсенде Матушкин. Имеш, редакциягә Матушкин тәнкыйтьләп язган пилмәнханә мөдирәсе килеп кергән дә озын кухня пычагы белән аның бармакларын турамакчы икән. Янәсе, кәгазьне дә пычратмасын, кешеләргә дә кара якмасын...

Матушкин палаткадан чыкты. Лагерь томан эчендә. Кухняда кызлар табак-савыт шалтырата. Матушкин чүгеп тезләрен язып алды, бармакларын селкеткәләде. Бу аның тау арасында каршылаган беренче иртәсе иде. Нинди сынаулар әзерләп куйдың икән син, килер көн?

## 8

Кояш нурлары турырак төшә башлагач, томан, сөт кебек куерып, чык булып үлән арасына иңде. Ә сәгать тугызларда, Ыссык-Күл ягындагы таулар артыннан кара болытлар чыгып, үткелне бик тиз каплап та алдылар. Үлән арасында авыр тамчылар шыбырдашты, палаткаларга шак-шок бәреп, томалап ява да башлады. Егетләр, һәркайсы үз «өенә» кереп, зифа чыршыларга ышкылып яуган яңгыр җепләренә моңсу гына карап утырырга мәҗбүр булдылар.

Нәкъ сәгать унда, расписание таләп иткәнчә, Зыряновның фәрманы яңгырады һәм команда палаткалардан чыкты да тау сукмагы буйлап сәфәргә кузгалды.

Астан караганда яшел массив арасыннан калкып торган кыялар Матушкинга чүмәлә кебек кенә тоелган иде дә, чынлыкта исә алар яулыйсы түбә кул җитмәс ныгытмага тиң иде. Егетләр, тыл ягыннан чыгып, аны тиз «иярләделәр», саклык бауларын беркеттеләр һәм менә беренчеләр текә таш стена буйлап өскә үрмәли дә башладылар.

— Әй-ей-ей! — Аязып өлгергән күктән Аняның ачык тавышы яңгырады. Ул кыя очына ук басып кулын болгый иде.

— Сиңа бу,— дип Шитов Матушкинның касыгына төртеп алды.— Төшүенә эдельвейслар җыеп куй, бирерсең.

— Каян чыгып әйтәсең аны?

— Бездә алай бакырмыйлар. Ул син булган хөрмәткә кычкыра. Карале, нинди эдельвейс!

— Шушы мени инде ул эдельвейс?

— Сорап торасың тагы! — Шитов йолдызга охшаган зәңгәр гөлчәчәк өзеп алды.— Аның мондый эреләре фәкать Тянь-Шаньда гына үсә. Ә, беләсеңме, кыргызларда кияү егете эдельвейслар бүләк иткән кәләш кенә бәхетле була дигән йола бар икән.

— Мин кияү кеше түгел ләбаса.

— Барыбер инде.

Матушкин, тыңлап тормадылармы икән дип, як-ягына каранып алды. Ул эрерәк таҗлы биш эдельвейс өзеп алды да Аня төшеп җиткәнне көтә башлады. Чәчәкләр әллә соргылт, әллә яшькелт иде, ә бәлки зәңгәр булгандыр, һәрхәлдә, үлән арасында алар кычкырып, күзгә кереп тормыйлар иде.

Тагын бер маршрут буйлап, ябышыр урынын озаклап капшыйкапшый, Нуриман шуыша иде.

— Кыя минү өчен авыррак санлы күренә, ә шулай да әйбәт үрмәли,— дип әйтеп куйды Матушкин.

— Әйе шул,— дип килеште Шитов һәм бераздан өстәде: — Берничә ел элегрәк шушындый ук күнегүләр вакытында ул, ычкынып китеп, кыя итәгенә кадәр очып төшкән иде. Бер-ике ташка бәрелгән, җиргә килеп сыланыр алдыннан гына бау тотып калган. Андый хәлдән соң тауларга бөтенләй дә кул селтиләр.

Нуриман озын тау ярыгыннан, кәрниз янлатып, аннары тагын ярык буйлап, кыяга сеңәрдәй булып, әкрен-әкрен өскә үрмәли иде. Бер

мизгелгә катып кала да тагын кузгала. Менә ул тау башында! Матушкин артында кемдер җиңел сулап куйды. Бу Аня иде. Матушкин аның төшеп, үз янына килеп басканын сизми дә калган иде.

— Сиңа,— дип, Матушкин аңа чәчәк бәйләме сузды.— Хәлбуки, миңа да үземне сынап карарга вакыттыр. Шулай бит, Юрий Степанович?

Зырянов, күзен кыса төшеп, баш какты:

— Әйдә, тәвәккәлләп кара.

Матушкин кыюланып китте. Аның кай җире Нуриманнан ким? Бер дә ким түгел. Ул юкарак, җиңелрәк, елгыррак та әле. Матушкин чүкте, торды, тирән итеп сулыш алды. Аның бәйләрен чорнадылар, карабинга[1] бауны чартлатып керттеләр дә: «Әйдә!»— диделәр.

Һәм ул кузгалып китте. Әлбәттә, сантиметрларны сәгать теле тизлегендә үтүне бару дип әйтсәң генә бару иде бу. Ярап торыр иде дә әле, тик бераздан Матушкин бөтенләй туктап калды. Менә аңа аркылы төшкән нәрсә — яңгыр һәм җил шомартып ялтыраткан таш киртә. Матушкин, шома ташны кулы белән капшап, калтырана-калтырана, нинди дә булса берәр ярык, тотыныр урын эзли. Аста аның өчен борчылалар. «Сулгарак, сулгарак ал!»— дип кычкыралар. Сулда да шоп-шома таш. Бармак очлары белән генә бер чыгынтыга ябышкан уң кулы да оеп бара. Ләкин ул үз күзе белән күреп торды бит: аңа кадәр моннан үттеләр ләбаса, үттеләр! Берни тоймаслык булып каткан кулы ычкынды да Матушкин стенадан аерылып, чалканып китте һәм, сак бавында асылынып калды. Аны җайлап кына җиргә төшерделәр.

Күңелдә — үкенү, ачу. Яңадан һөҗүмгә ташланасы килү теләге. Ләкин чират бүтәннеке инде. Маршрутка команда повары Илдус Исмагыйлев чыккан иде. Ул темпны әйбәт алды һәм Матушкин тукталып калган урынны җәфаланмыйча гына узып китте.

Матушкин хәл алды, Шитовның маршрутны ничек узуын карап торды. Әллә ние юк, үтәрлек икән үзе. Ул җилкенеп тагын менеп китте. Һәм тагын аны аска тартып төшерделәр. Шул кадәр шаһитлар алдында, Аня карап торганда, Матушкинның мондый җиңелү ачысын татыганы, бу кадәр хурлыкка калганы юк иде әле.

Лагерьга борылып кайтканда ул иң артта сөйрәлә иде. Янында гына Аня бара. Ул, аны юатырга теләп: «Кайбер тау түбәләренә альпинистлар кыялардан шуышып тормыйча гына menәләр»,— дигән була. Матушкин гарьлегеннән нишләргә белми, кая керер тишек тапмый.

Юлда аларны Нуриман куып җитте. Ул Матушкинның кайту белән кухнядагыларга булышырга тиешлеген әйтте. Начпрод буларак әйтте:

— Калган кешеләр исә алдагы көн өчен кирәк-яраклар әзерләп куярлар.

«Дөрес,— дип уйлады Матушкин,— минем урын — кухняда, мин кыяменәр түгел, ә йомышчы малай».

Яшь бәрәңге вак иде. Матушкин үзе бәрәңге әрчи, үзе «тырнак»ларны үткерләп, бауларны рәтләп маташучы егетләргә карый. Егетләр Аю-Тер үткеленә күчеп, анда булачак беренче тау менү күнегүләре үткәрергә әзерләнәләр. Бер Нуриман гына юк, ул елга буенда таш актара иде.

— Нишли ул анда? — дип сорады Матушкин кизүдәше Шитовтан.

Тегесе, суган турый-турый, күз яшьләрен сөртеп:

— Мунча ташы салырга җыена,— диде.— Син бәрәңгене алай каезлама, яшь бәрәңге бит, кабыгын кыр гына.

Моның бер азагы булырмы икән, юкмы! Бөтенесе сине өйрәтә дә өйрәтә.

Кичен ашап, савыт-сабаларны юганнан соң, Шитов гитара уйнап утырыйк дисә дә, Матушкин барак-палаткада калмады, туп-туры үзләренә кайтып, капчыгына кереп ятты. Аңа ямансу иде.

---

[1] Карабин — саклык бавы белән эшләгәндә ялгау өчен кулланыла торган металл буын.

Чыңлап торган кояшлы иртә. Тугыз сәгатьлек каты йокыдан соң Матушкин палаткасыннан бик дәртләнеп килеп чыкты. Кырынып, елгада бозлы су белән юынгач, битләре рәхәтләнеп китте. Аннары ул фотоаппаратын корырга дип кереп китте.

— Хәерле иртә, Сережа! — Палаткадан Аняның тузган башы күренеп тора иде.— Нигә качтың кичә?

— Йокы килде.

— Беләм. Мин сезгә сугылган идем дә, син йоклаган идең инде.

— Әйе шул, кичә бик арыткан иде.

— Мин кәефең кырылган ахры дигән идем. Алай кирәкми, күрче нинди матур иртә!

— Искитмәле!

— Әйдә гөмбәгә барабыз. Аю-Тер бераз сабыр итәр — кирәк-яраклар әзер түгел. Зырянычның бик ачуы чыккан.

— Ә ярыймы соң?

— Ә без шыпан-шыпан гына. Иртәнге аштан соң ук.

— Әйдә,— дип сөенеп куйды Матушкин.

— Сергей! — дип дәштеләр шулчак.

Нуриман иде бу. Ул азык-төлек короте өчен куелган чатырдан кычкыра иде. Аның янында Зырянов та бар иде. Тау Капланы, мичкә өстенә менеп утырган килеш, Матушкин кергәнне дә күрмичә сөйләнеп утыра иде:

— Егетләргә Аю-Тер алдыннан яңа суйган сарык ите пешереп ашатырга кирәк. Егерме биш метр җитәме аңа? Артыгын бирә алмыйм. Бу бауны ничек тапканны үзең дә беләсең.

— Мәмәтбәк кырыкны сорый,— диде Нуриман.

— Ярый, хәерле булсын. Тик син тәкәне үзең сайлап ал. Үзең белән кемне аласың?

— Әнә, Сергейны.

— Дөрес.— Зырянов Матушкинга карап куйды.— Барып кил, Сережа, сарык итенең кайда үскәнен дә карарсың шунда. Юкса, син шәһәр кешесе бит...

Шундый матур башланган иртәдә — менә сиңа мә!

Көтүче Мәмәтбәк Әбдекадыйров тирмәсе лагерьдан ике сәгать ярым чамасы бара торган күрше үткелдә корылган иде. Сөйләшми генә бардылар.

Түгәрәк йөзле, таза кыргыз Мәмәтбәк кунакларны тирмәсе төбендә каршылады. Сәлам бирештеләр. Мәмәтбәк башта вәкарь белән Матушкинга ике кулын сузды, аннары Нуриманны дусларча кочагына алды:

— Сәлам, Нуриман!

— Саумы, Мәмәтбәк!

Һәркайсы үз телендә сөйләшә башладылар. Матушкин Мәмәтбәкнең кыргызча, Нуриманның татарча сөйләшкәнен төшенеп алды. Алар берберсен дусларча әйбәт аңлап гәпләшәләр иде. Көтүче авызын ерып, камчысы белән итек балтырына суккалап ала, Нуриман, гадәтенчә, башының арт чүмечен сыйпаштыра. Алар тирәсендә бала-чага кайнаша.

— Сезнекеләрме? — дип сорады Матушкин.

— Минекеләр,— диде Мәмәтбәк, ап-ак тешләрен күрсәтеп. Бу елмаюдан аның кояш ашаган йөзе яктырып киткәндәй булды.— Тугызау,— дип бармакларын тырпайтып күрсәтте,— сигез җегет белән бер кыз бала. Кызны күргәнең юк әле, Нуриман. Кыш көне туды.— Көтүче камчысын итегенә шартлатып сугып куйды.— Нәрсә басып торабыз әле, әйдәгез, тирмәгә керик, кымыз эчик. Байсылу, кунакларны каршы ал!

Тирмә ишегендә чәчен шома итеп тараган, кыска гына буйлы бер хатын күренде. Ул тирмәнең киез чаршавын ачып:

— Керегез, кунаклар, керегез,— диде.

Тирмәдә ышык, җылы һәм рәхәт иде. Идәндә дә, сәкедә дә, бишектә дә — бөтен җирдә бала-чага кайнаша.

Кергән шәйгә, ишек катында аяк чалып, киезгә утырдылар. Матушкинның аркасын артта чыжлап янган тимер мич кыздыра. Бичә касәләргә кымыз сала. Беренче булып авыз иткән Нуриман, баш селкеп, телен шартлатып:

— Яхшы,— диде.

Матушкин бер тәмен дә тапмады. Атаклы кымыз аңа бик әче әйрән кебек тоелды.

— Ничегрәк? — дип сорады Мәмәтбәк.

— Тешләрне камаштыра,— диде Матушкин.

Мәмәтбәк көлеп җибәрде:

— Башта гел шулай була ул. Күнеккәч тәмен белә башлыйсың аның.

— Әйдәгез, бөтен гаиләгезне рәсемгә төшерик әле,— дип тәкъдим кертте Матушкин.

Әбдекадыйров озак кыстатмады. Тик җыену сузыла төште — Байсылу киемен алыштырды, бишекне тышка алып чыктылар, тезелделәр. Нуриман төшмәскә булды.

— Гаилә булгач, гаилә кешеләре генә төшсен,— дип, ул бер читкәрәк барып басты.

Рәсемгә төшү бер тантанага әйләнде һәм ул Әбдекадыйровның күңеленә хуш килде. Балалар фотограф абыйларын чорнап алдылар, ә Мәмәтбәк телен шартлатып куйды һәм хатынына комузын алып чыгарга кушты. Ләкин бер малае, әнисеннән алданрак өлгереп мандолинага охшаган уен коралын күз ачып йомганчы алып чыгып та бирде. Мәмәтбәк комузны нечкә генә муеныннан эләктереп алды һәм бөтенесе берьюлы аның тирәсенә җыелып утырдылар. Байсылу: «Нәрсә җырлыйбыз?» — диде.

— Бекбекейне,— диде Мәмәтбәк. Ул да хатыны янына аягын чалып утырды. Башын иде дә, кылларга чиертеп алды, аннан бөтен бармаклары белән берьюлы комузга китереп сукты да аның кулы өч кылдан гаҗәеп моңлы озын көйне суза-суза тибрәнә, бии башлады. Менә ул, гүя чабып барган, ярсыган аргамакны туктатып, кемнедер үзе белән алып китәргә теләгәндәй, түбәнрәк авазларга күчте, хатынына карады һәм тегесе җырлап җибәрде. Байсылуның тавышы моңлы һәм җиңел чыга иде. Әйтерсең, ул үзе җырламый да, авызын гына ачкалый, ә җыр үзеннән-үзе ирек хозурына түгелә иде.

Матушкин җырны кырын ятып тыңлады. Җыр аңа ошавын ошый, әмма ул аны ничек кенә тырышмасын, тотып ала алмый, сүзләрен дә аңламый иде, бары көйнең моңлы икәнен генә тоя иде. Ул үткел төбендә шаулап аккан елгага, елга буеннан тирмәгә кадәр бөтен тау итәгенә сибелгән көтүгә карый һәм үзен җырны ишетеп тә аны һич аңларлыгы булмаган көтү сарыгы белән тиңләп елмаеп куя. Комуз соңгы аһларын әйтеп бетергәч, Матушкин:

— Нинди җыр булды бу? — дип сорады.

— «Бекбекей» бу,— дип җавап бирде Мәмәтбәк.— төнлә көтү көтә торган хатын турындагы җыр.

— Матур җыр,— диде Матушкин һәм Казан урыслары әйткәнчә итеп:— Бик якши,— дип өстәде.

Тагын бер җыр җырлагач, Мәмәтбәк сарыкларын күрсәтәсе итте.

— Тянь-Шаньның ите дә, йоны да шушында инде,— дип сөйләнде Мәмәтбәк, чемченеп йөрүче мүкләк хайваннарның куе йоннарын сыпыргалап. Ул бу нәселнең әйбәтлеге, көтүдәге барлык сарыкның һәм андагы шәхси куйларның саны турында аңлатып алды. Малларны капшыйкапшый хуҗаларча каравыннан барлык бу көтүнең дә, тирмәнең дә, көтү тирәсендә чабучы этләрнең дә, бу яшел үткел һәм шуның уртасыннан

ага торган елганың да аның өчен дөньяда бернигә алыштырмас газиз тормыш икәнлеге сизелеп тора иде.

— Юк, өйдә генә утыра алмыйм мин,— диде ул.— Үткән ел ялымда Фрунзегә олы малайларга барган идем дә — кая ул бер айга түгел, бер атнасына да түзеп тора алмадым. Сыпырттым шушы дүрт аяклы малларым янына.— Мәмәтбәк, юри усалланган булып, аяк астында чуалган сарыкның янбашына тибеп алды.— Ә мин китеп торган арада кайсылары суык тидереп тә өлгергән шуларның!

Башкалардан берние белән дә аерылып тормаган бөкре танаулы, гәүдәле генә сарык янында көтүче туктап калды:

— Менә, Нуриман, сиңа вәгъдә иткәнем шушы инде. Чатанлый башлады, каһәр. Ә казанга салгач, егетләр аның аксаклыгына карап тормаслар, гуй.

Мәмәтбәк сарыкны, арт аягыннан эләктереп, өстерәп алып китте. Теге бичарасы карышып та маташмады, авызында калган үләнне күшәп бетерүендә булды. Мәмәтбәк тыны кысылып туктады:

— Байсылу, табак алып чык әле.

Ул бил каешына таккан кыныдан хәтәр кәкрәеп торган очлы башлы пычагын тартып чыгарды да Нуриманга сузды.

— Мә, тот.

— Үзең генә башкарасыңмы әллә? — дип, начпрод баш тартып карады.

— Я, я! Егет бул әле. Бабайлар кушканча, кыйблага каратып куй да аллага тапшыр.

Мәмәтбәк пычакны бирде дә, тазны сарык муены янынарак тартып, дәү куллары белән хайванның дүрт аягын чытырдатып тотты.

— Әйдә, Нуриман, тунавын үзем тунармын.

Сарык уйламый да тыныч кына ята иде. Начпрод муенына сызып җибәргәч тә кымшанмады диярлек. Табак бик тиз кан белән тулды. Карaборынлы бер малай аны күтәреп бәйдәге овчарка алдына илтеп куйды. Пары чыгып торган куе кызыл сыекчаны эт комсызланып эчәргә тотынды.

Икенче табак тулып җиткәндә тәкә, ниһаять, тартышып куйды.

— Җаны чыкты,— диде Нуриман һәм пычакны Мәмәтбәккә кайтарды. Начпродның кулы канга баткан, йөзе тыныч иде: күрәсең, малны беренче тапкыр гына суюы түгел аның.

Ул арада Мәмәтбәк, сарыкны тунап, эчен-бавырын алгач, түшкәне турап, итен чиста табакка өя башлады. Байсылу килеп аннан берничә кисәген алып китте. Беравыктан ул табынга пешкән ит алып килде.

Мәмәтбәк, кулын сөртеп, кайнар ит кисәген авызын яндыра-яндыра тамагына озаткач: «Тәмле булган!» — диде.

Нуриман да сыйдан авыз итте. Байсылу кулындагы тәлинкәсен Матушкинга сузды. Ул, олы бер кисәкне алып, әле кайчан гына үлән чемченеп йөргән хайванның тиресенә, табактагы кызгылт итләренә, эчәкбавырына карый-карый чәйни башлады. Кайдандыр эч тирәнлегеннән бугазына дулкын кебек бер нәрсә килеп менде, ул сикереп торып читкәрәк китте дә укшый башлады.

Байсылу су алып чыгарга дип йөгерде, ә Мәмәтбәк көлеп җибәрде:

— Өеңдә ничек ашыйсың соң син итне! — диде.

Нуриман бер сүз дә әйтмәде. Читкә барып яткан Матушкинга балалар шаккатып карап торалар иде. Аның хәле мөшкел иде — тәнендә җеп өзәрлек тә хәле калмаган. Исенә редакциядә Красноперов белән сүз көрәштергәне килеп төште: «Ашаганда яратасың бит?!» «Ашаганда яратам. Аеруча шашлык яратам мин, сарык итеннән...»

Лагерьга кайткач, Матушкин палаткага кереп яткан иде дә, Аня кире чакырып чыгарды аны:

— Әйбәт ит алып кайткансыз, Сережа. Кичке аш бер дигән булачак. Ә хәзер әйдә гөмбәгә барабыз.

Алар ике бүрәнәдән салынган басманы чыгып, Зырянов бер кочак яңгыр гөмбәсе төяп кайткан тау итәгеннән өскә менә башладылар. Тик аларның юлы уңмады, сулгарак каерган булып чыктылар һәм чәнечкеле арча куаклары арасында тукталып калдылар. Тау битенә үрмәләп үсә торган карсак арча киемнәрне тарткалый да йолыккалый торгач, Матушкин белән Аня кире борылырга уйладылар. Алар, елга буена төшеп, яр буйлатып киттеләр.

— Нәрсә булды сиңа бүген? — дип сорады Аня.

— Гөмбә юк бит,— дигән булды Матушкин.

Матушкин бүгенге «канлы» сәяхәт хакында, командада үзенә-үзе урын таба алмавы, беркемгә кирәк түгеллеге турында сөйләмәкче иде дә кире уйлады. Бу үзенең көчсезлегенә тану булыр иде. Ул, башын югары чөеп:

— Мин көне-төне бер генә сорауга җавап эзлим,— диде.— Синең бәгыреңне ничек, ни рәвешле йомшартып булыр икән дим. Аннары син кияүгә чыкмаган булсаң да, йөрәгең миңа карата шулай салкын калыр идеме икән дим. Әйтик, мин Нуриманнан алданрак очраган булсам?..

— Тиле,— диде Аня.— Кара, кояш ничек булып баййй.

— Нәкъ кояш баеган кебек инде. Сүзне читкә борма әле син.

— Юк, алай түгел. Монда кояш баерга өлгермичә бата. Ә кояшның чын-чынлап баеганын күрәсең килсә, тау башына — бик биеккә менеп карарга кирәк.

«Аня, мин сине яратам, ләкин мин биеккә-биеккә менә алмамдыр инде»,— димәкче булган иде Матушкин, дәшми калды. Ул уйлаган уйларының тамчысын да әйтмәде. Кояш тау артына тәгәри иде...

## 10

Утыз көн узды да китте. Утыз тапкыр каршылады Матушкин иртәнге, алсу битле Тянь-Шань кояшын. Ерактагы Җиңү пигы артыннан балкып чыккан күк чырагын ул утыз тапкыр инде еш кына я болытлар артында, я томан эчендә булганы хәлдә мәгърипкә озатып калды. Бу вакыт нәрсә бирде соң аңарга? Барыннан да элек, ул ике блокнот язып тутырды. Гаҗәеп ямьле ландшафт уртасыннан күп чакрымнар үтте, тик әллә ни хозурлык кичермәде. Җиде-сигез сәгать буе миеңне кайнатып чыгарырдай эсседә дә, чиләкләп яңгыр койганда да, борының тезеңә тигәнче бөгелеп, иләмсез рюкзакны өстерәгәндә як-якка бик каранып барасы килми икән ул. Шунда аңа, альпинистларны тауга әйдәүче көчләрнең берсе — табигать матурлыгы дисәләр, ул: «Шаярма, агайне, альпинист үз алдыннан баручының башмагыннан бүтән бер нәрсә дә күрми»,— дияр иде.

Ә менә уникенче көнне күнегү тәртибендә «ГТО» пигына менеп, аста — әле генә өсләренә яңгыр булып яуган болытларны, тирә-якта йөзләрчә тау түбәләрен, иксез-чиксез зәңгәр күк гөмбәзен һәм искиткеч якында балкыган кояшны күргәч, беренче тапкыр ул үз алдына: «Шушыны күрү хакына булса да, килергә ярый монда!» — дип уйлап куйды.

«ГТО» пигы карап торышка дөя өркәче кадәр генә, әлбәттә. Ләкин бу чираттагы җиңүләрнең берсе иде. Хәзер инде Матушкин башлары күкләргә тигән Тянь-Шань гөмбәзләренең җилләр җилфердәткән карлы әләмнәренә күзләрен кыса төшеп, озаклап карап тора.

— Бабалар авазы бу,— дип көлде бервакыт Шитов.

— Шулай шул, гаҗәп нәрсә бу таулар,— дип, Матушкин фотоаппаратын чертләтеп ала һәм соклану сүзләре белән тула баручы өченче блокнотына сузыла. Хәлбуки, сөйләгәнебезнең төп вакыйгалары алдарак әле — Матушкин үзенең блокнотына бернәрсә дә диярлек яза алмаган җирләрдә.

Шулай итеп, климатка яраклашуга бирелгән утыз көн күнегүләр белән үтеп китте. Терскей-Алатау сыртын ашып, өч зур күчеш ясаганнан соң, команда Ак Бүре белән Исемсез түбә итәгендәге бозлыкта чатырларын корды. Палаткалар куелган, тау-таш ишелгән урын шушы ике тауны тоташтырган «басма»ның нәкъ урта бер җирендә иде. Бер як читтә Күкҗал кәпрәеп утыра.

Зырянов команданы икегә бүлде: берсе — Исемсез түбәгә, икенчесе Ак Бүрегә менәргә тиеш иде. Матушкин иң көчле икенче төркемгә эләкте. Аңа Шитов, Док, Аня Сабирова һәм тагын берничә кеше керде. Аларга «бүречеләр» дип исем куштылар.

Җитәкчеләре Нуриман иде.

Иртән иртүк бүречеләр, көньяк-көнбатыш ягыннан менәргә дип, Ак Бүре итәгеннән аның теге ягына юл тоттылар. Ә «басма» аркылы Исемсез түбәгә менәргә тиешле Зырянов җитәкчелегендәге төркем китте.

Төш вакытына бүречеләр тиешле урынга килеп җиткәннәр иде инде. Алар тиз генә бивак корып, Ак Бүрене күзәттеләр, картага менү юлын төшерделәр, тауның түбәсе күренеп торырга тиешле ниндидер бер чыгынты хакында бәхәсләштеләр. Матушкин гына катнаша алмады, аның вакыты юк иде — Нуриман аны кизү итеп куйды да менә хәзер ул, су буена төшеп, табак-савытларны ком белән ышкып юа-юа: «Ярый-ярый, иртәгә мин барыбер тау башына менеп караячакмын, Зырянов шулай диде бит, Нуриманның аны тыңламаска хакы юк»,— дип юата иде.

Экспедиция башланганнан бирле начпрод артык сүз сөйләшмичә генә, я кизү итеп билгеләп, я кирәкмәгән йомыш кушып, я юкка бәйләнеп, Матушкинның теңкәсенә тиде. Нуриман мәсьәләсендә ул ялгышмый иде. Аня белән гөмбәдән кайткандагы карашлары гына да ни тора иде бит аның! Котың очарлык... Аулак урын булсамы, теге сарыкны суйган кебек, керфеген дә селкетми тотар да ботарлар иде.

— Сергей!

Бу ул иде. Хәзер менә тагын нинди дә булса берәр юк эш табар — Аю-Тердә дә әнә буш банкаларны таптап, җиргә күмеп куярга кушкан иде.

— Сергей, иртәрәк ят бүген. Иртәгә Шитов белән өчәүләп разведкага барабыз. Тору — сәгать дүрттә.

Матушкин, җелеккә үтәрдәй салкын суда соңгы мискәсен чайкап, өстәл итеп җайланган гранит плитә өстенә ыргытты да йокларга кереп китте. «Менә шулай, Нуриман туганкай, боерык боерык әле ул, иртәгә минем урынга башка берәр кеше дежур торып торыр». Матушкин палаткага керде, анда Шитов рәхәтләнеп йоклап ята иде инде. «Ничек итеп кеше шулай күзен йоммас борын йоклап китә ала икән? Исең китәр». Матушкин фотоаппаратын, запас кассеталарын карап куйды һәм, караңгы төшкәнче дип, блокнотына соңгы өч көн вакыйгаларын төшерергә ашыкты:

Палаткага Аня килеп керде:

— Иртәгә йокыдан мин уятачакмын. Иркәләнеп яту булмасын! — диде.

— Минем дежурлык сиңа эләктемени?

— Әйе. Иртәгә кухнядагы бөтен авырлык миңа төшәчәк.

Аня аның баш астын рәтләгәндәй итте. Матушкин, блокнотын куеп, капчыгында җайлабрак ятты, күзен йомды. Түзә торган түгел иде!

— Шитов, хырлама әле.

— Көнләшәсеңмени?

— Әйе, көнләшәм.— Монда, тауларга килгәч, Матушкин үзенең йокысызлыктан иза чиккәнлеген белде. Яңа биеклеккә күтәрелгән саен бу чир тагын да көчәя, тамырлана бара шикелле.

«Бер фил дә бер фил — ике фил, бер фил дә ике фил — өч фил»,— Матушкин, үзенең йокы догасын күпме генә дәвам итсә дә, йоклап китә алмады.

## 11

Аня тагын пәйда булганда караңгы иде инде. Дөрес, ул үзе күренмәде, ә тавышы гына яңгырады:

— Егетләр! Шура, Сережа, торыгыз!

Караңгыда кармалана-кармалана Матушкин капчыгыннан чыкты. Шитов фонарь кабызды. Мышный-мышный, иренеп кенә киенделәр.

— Бигрәк озак юанасыз! Аш суына.— Моны тагын Аня кычкыра иде.

Тышта салкын җил исә иде. Матушкин калтыранып куйды. Ул йөгергәндәй итте, кулларын селеккәләде дә, өстәл янына килеп, чыжлап торган примуслар янәшәсендәге начпрод янына килеп утырды, гаҗәеп бер аппетит белән «геркулес» дигән солы боткасын сыпырта башлады.

— Шура, палатканы алырга онытма,— диде Нуриман яннарына килеп утырган Шитовка.

— Нигә ул?! Без нәрсә, кунмыйбыздыр бит?

— Зырянов аңлатып әйтте түгелме: палаткасыз аяк та атламаска диде. Ишетмәденме әллә?!

— Курыкканга куш,— дип мыгырданды Шитов. Сузыла төшеп ипи, кашык алды.— Ул күтәрәсе түгел шул аны. Ашарга да ул кушканча алыргамы?

— Нәкъ шулай: өч көнлек итеп. Примус белән йокы капчыкларын да онытмаска.

Иптәшләрен юлга озатырга дип, Док чыкты. Ул Матушкинга юл капчыгын бәйләргә, төймәләрен каптырырга булышты. Аның өс-башын энәсеннән җебенә кадәр Нуриман үзе карап чыкты. Беравык уйлап торгач, рюкзагын бушатып яңадан тутырырга кушты.

— Шулай,— дип килеште Шитов та,— янчыгыңны тыгызлыйсы бар. Серега, юкса бик тиз камыт сугар. Әйдә, булышам.

— Тизрәк, тизрәк булыгыз,— дип ашыктырды Нуриман,— хәзер кар эри башлый, яктырып та килә инде.

Сәгать алтынчы киткәч, разведчиклар юлга чыктылар.

— Я, бүречеләр,— дип, һәркайсының рюкзакларына шап-шоп сугып чыкты Док,— кыздыра башлаганчы, кузгалыгыз. Ак Бүре сезне көтеп тора.

— У-у-у,— дип, Шитов бүредәй улап куйды. Аннан калганнары барысы да кычкырып көлделәр.

— Саграк булыгыз,— диде ул. Матушкин аның борчулы кыяфәтенә гаҗәпләнде, әнисенең аэропортта озатып калуы нигәдер исенә төште, һәм ул, саубуллашканда һәр хатын-кыз шундый була торгандыр ахры, дип уйлап куйды.

Юлга болай чыктылар: алдан Нуриман, арттан Шитов бара, уртада — Матушкин. Караңгыда бер-берсен тоныкк адымнардан һәм боз чүкечләренең,ташларга бәрелеп, чыңлап китүләреннән генә беләләр иде. Шитов җиңелчә генә сүгенгәләп ала. Никтер ул башкаларга караганда ешрак абына иде.

Төн тизлек белән эреп тарала барды. Бер заман разведчиклар каршында, караңгылык эченнән сөзелеп, пәһлевандай олы сынлы Ак Бүре калыкты. Аның чал түбәсенә иртәнге кояш нурлары төшкән дә, асылташлы таҗ кигәндәй, ул аллы-гөлле булып балкый иде.

— Юк, бу аның түбәсе түгел әле,— дип аңлатты Матушкинга Шитов,— ә көнбатыш сырты гына. Түбәне шул каплап тора. Әнә теге чыгынтыга менгәч,— дип Шитов кулын сузып күрсәтте,— ул ап-ачык күренәчәк. Сурәтен алдан да, уңнан-сулдан да ясап чын бүречеләр авызына ыргытырбыз. Умырсыннар үзен.

— Тауны саулык өчен буйсындыралар шул,— дип төрттереп кенә аны куәтләгән булды Матушкин.

— Юк, Серега, тауларны буйсындырып булмый. Үгез мөгезенә кунган чебеннең «тауны иярләдем бит» дигән көненә калмыйк. Бүген

син аның түбәсенә менәсең, ә иртәгә юк... Исән-сау кире кайталсаң, рәхмәт диярсең. Миңа калса, тау ул — хатын-кыз кебек, ерактан карaганда гүзәл, каршына килсәң, ул сиңа төшеңдә дә күрмәгән холык-галәмәтләрен күрсәтеп куя.

— Киттек, ашыга төшик,— диде тау түбәсенә сокланып онытыла язган Нуриман.— Кояш күтәрелгәнче, тәкә маңгайларына менеп житәргә кирәк.

Тәкә маңгайлары — шомарып беткән кыя чыгынтылары. Алар тауташ кисәкләрен кар яткан урыннан аерып торалар. Аларга менгәч, Нуриман белән Шитов бер-берсен саклык бавы белән тоташтырдылар. Аны бушата-жибәрә, Нуриман алдан китте. Шитов Матушкинны туктатып торды һәм, Нуриман бер унбиш метрлап киткәч, газетчы егетнең карабинын үзе белән әйдәп баручы арасына каптырды.

— Хәзер атла инде.

— Сезнең уртада миңа, ике багана арасындагы чыбыкка бәйләнгән эт кебек, әрле-бирле йөрисе генә кала.

— Сәяхәтче бака кебек диген,— дип, Шитов кыбырсып билен уып алды.

— Тагын кузгалды мәллә?

— Авырта, хәшәрәт,— Шитов кара күзлеген киде.— Син дә ки, кояш чыкканны көтмә.

— Житешермен әле. Ямьле дә соң, әй!

Кардан бара башладылар. Аның кетердәп каткан өслеге батмый иде. Асфальттан баргандай атладылар. Ак Бүре сыртының уң ягыннан кояш килеп чыкты. Аның туры төшкән нурларыннан күзләр чагылды, кар өсте кызыллы-яшелле, зәңгәрле-сарылы гөлләр кебек балкыды. Матушкин кабыргалары шытырдаганчы киерелеп сулыш алды, күзлеген киде. Аңа карап манзара бозылмады — кар һаман балкуында булды, тау түбәсе ялык-йолык килде, аста бивак чатырлары сары тап булып җемелдәде.

— Рәхәт тә соң! — дип, Матушкин үз халәтенә үз бәя бирде.— Шура, ә мин сезнең белән Коммунизм пигына менә алган булыр идем микән? — Рухланган минутларында Матушкинның теленә салына торган гадәте көчәеп китә.— Шура, нәрсә шаулый анда?

— Тау ярыгы. Аның төбендә су шаулый.

— Тирән микән соң?

— Ярыклармы? Төрлесе була.

Шулай да?

— Дистә метрлар.

— Кызык. Ә кайда соң ул ярык? Шавы бар, үзе юк.

— Син шуның өстендә, бөкедә басып торасың инде. Караңгырак полоса күрәсеңме?

— Китче?! — Матушкин курыкмаса да, бормаланып киткән күрәнсу полосадан читкә тайпылды.— Шунда мин мәтәлгән булсам, нишләр идем?

— Нишләр идең... Аягыңны чылатыр идең,— дип елмайды Шитов.— Куркырлык түгел. Әле сөйләгәннәр иде: бер-ике ел элек берәү егерме метрлап очкан да, ярты гәүдәсе боз арасына кереп кысылган. Ярыклар төпкә таба тарая бара бит. Күпме тырышсалар да, бөтен килеш тартып чыгара алмаганнар.

Кар кыры акрынлап тау битенә әверелде. Аяк тая башлады.

— Тырнакларны киябезме әллә? — дип кычкырды Шитов.

— Бераз сабыр итик,— дип җавап кайтарды Нуриман,— хәзер баскычлар ясыйм.— Ул боз чүкече белән селтәнә башлады. Матушкинның өстенә боз пыяласы сибелде. Бер ярчык битен сызып китте. Матушкин башын июгә, каскасына зуррак кисәк килеп төште.

Шитов Матушкинның аптыравын сизенде.

— Ашыкма син, бераз арткарак кал.

Матушкин аны тыңлады. Нуриман бераздан уңгарак кыйгачлады. Боз кыйпылчыклары хәзер зыңгылдап яннан очып китә башладылар.

Менү юлы һаман саен текәләнә барды. Ләкин Нуриман чукып ясаган басмалардан бару җиңелрәк иде. Аннары боз да жепшеп көпшәкләнә төште, таймый башлады. Кояш күтәрелеп кыздырырга да тотынды. Каска астыннан тир саркый, йөрәк ешрак тибә, авызлар кибеп, тын җитми башлады. Ләкин Матушкин хәзер ару турында уйларга ярамавын, ә барырга да барырга гына кирәклеген, кеше көченең чиксез икәнлеген белә иде. Моны ул үз җилкәсендә татыды.

Бер-бер артлы разведчиклар сөзәгрәк мәйданчыкка күтәрелделәр. Соңгы кеше булып Шитов менде. Сулавы нормаль гына булса да, кыяфәте миләш капкан шикеллерәк иде.

— Ни булды сиңа, Шитов?— дип борчылып сорады Нуриман.— Тагын билме?

— Шул, каһәр. Чыдар хәл юк,— дип сыкранды Шитов. Ул рюкзагын салды, утырды. Нуриман текәлеп аңа карады.

— Бара алырсыңмы?

— Барам,— диде Шитов. Ләкин торып язылa башлагач, ул ике кулы белән билен уа-уа көчкә тураеп баса алды.

— Шура, бар син кире төш,— диде Нуриман.— Ярты сәгатьтән кайтып җитәрсең. Докның кулы шифалы аның.

Сакалын умырып алырга теләгәндәй ачуланып, Шитов:

— Ярты сәгатькә алданракмы, бер сәгатькә соңракмы,— ни аермасы бар инде аның,— диде.

— Эш анда түгел. Төшкәндә авыртмый ул, ә менү дигәндә син хәзер артыгын менә алмыйсың. Төшкәндә билгә җиңелрәк бит ул. Бир монда палатканы. Сүз озайтмый гына. Үргә барысы сәгать ярымлык ара калды, без түбәне тиздән күрә алачакбыз. Ә син әкрен генә аска төшә тор.

— Бәлки, мин Шураны озатып килермен?! — диде Матушкин.

— Ташла әле,— дип кырт кисте Шитов.— Үзем дә төшеп җитәрмен.

— Җитәрсеңме? — дип кабатлап сорады Нуриман.

— Әлбәттә, үз эшегезне карагыз.

— Безгә әнә теге үркәчкә менеп җитәргә кирәк,— Нуриман Матушкинга карап куйды.

— Сүз дә юк,— дип кыю җавап бирде Матушкин.— Мин Зырянов белән шул урынга кадәр барырга дип сөйләштем дә. Минем материал язасым бар лабаса, ә тау түбәсен үз күзем белән дә күрми торып, ничек язасың аны?

Әмма аның Нуриман белән икәүдән-икәү генә каласы да килми иде. Юк, куркудан түгел, болай, дөресрәге — сөйләшер сүзләре булмаудан. Исендә әле: акклиматизация вакытында бер күченгәндә ул, теле кычытып, Нуриман белән сөйләшергә тырышып караган иде. Тегесе шунда:

— Беләсеңме, тауга мин ни өчен йөрим?— дип сорады. Зирәк бер сүз ишетергә әзерләнгәндәй, Матушкин кызыксынып:

— Юк,— диде.

— Азрак сөйләшү өчен.

Менә шул инде ул гади генә итеп әйтсәк — бер-береңә яраша алмау!

Ике ир кешенең яраша алмавы. Һәм, әлбәттә, «гади генә» яраша алмау түгел инде бу. Матушкин монысын шәп аңлый иде.

Шитов, борылып та карамыйча, түбән төшеп китте. Нуриман белән Матушкин, Ак Бүре түбәсен күрүне өмет итеп, әлеге үркәчкә таба кузгалып киттеләр. Юл тагын да кыенлаша төште: беренчедән: Шитов китү сәбәпле, рюкзаклар тагын да авырайды, икенчедән, кар тәмам җебеп, хәзер аяк балтырларына тикле бата-бата атлый башладылар, аннары инде хәлләре дә элеккечә түгел. Аяк, бил, иңбашлары, муеннар сулкылдап сызлый иде.

Текә генә бер күтәрелеш алдыннан Нуриман ял игълан итте — радиоэлемтә вакыты җиткән иде. Матушкин гыжлый-гыжлый рюкзагына терәлеп утырды, ә Нуриман рацияне көйли башлады.

— База, база,— дип һаман бер тонда тәкърарлады ул,— мин разведка, тыңлыйм...

Ниһаять, рациядән Док тавышы ишетелде.

Ул Шитовның бивакка якынлашып килүен, аларның исә әйбәт күренгәнлеген хәбәр итте. Киләсе радиоэлемтә вакытын нәкъ бер сәгатьтән дип килештеләр,— ул чакта разведчиклар, үр өстендә утырып, Ак Бүре түбәсенә карап хозурлана-хозурлана чәй эчәргә тиешләр иде, янәсе. Шулай булып чыкты да. Бер сәгатьтән Нуриман белән Матушкин тиешле урында иделәр инде. Ләкин чәй эчеп торырга гына туры килмәде...

## 12

Барып життек кенә дигәндә, күрше таудан, коточкыч тавышлар чыгарып, берьюлы диярлек ике ташкын ишелеп китте. Төтенсу-ак болыт өермәсе куптарып, күтәргесез таш кантарларын чәя-чәя, ватып-жимереп, тузанга чыгарып, кар силе аска шуышты. Коточарлык гүзәл күренеш иде бу. Бозның ярылып кубып киткән урыны күзне камаштырырлык зәңгәрлек белән кояшта ялтырап калды. Ә ташкын аста, тау итәгендә, тәхетеннән сөрелгән тиран кебек, әле һаман да сукрана-сүгенә иде.

Бөтен кассетасын «черт»ләтеп бетергәч, Матушкин күрше тауның зәңгәрсу жәрәхәтен төшерергә дип төсле яңа тасма куярга уйлаган иде дә, Нуриман вакыт юклыгын, элемтәгә кергәнче, үргә менеп житәргә кирәклеген әйтеп, тагын кузгалдылар.

Ике ыргак кагып, күләгәле яктан текә боз кыясын «тырнак»лар ярдәмендә үттеләр. Шәрә кыяга караганда бозлыкта Матушкинга рәхәтрәк иде — кыялы жирдә аннан башта ук рәт чыкмады. Бозда бөтенләй башка эш. Боз чүкечеңнең борынын кадап, «тырнак»ларыңны батыр да шәрә стенада үрмәкүч кебек туйганчы эленеп тор кирәксә. Тыгыз кар исә тагын да шәбрәк. Бу яктан Матушкинның юлы уңды: Ак Бүредә шәрә кыялар бөтенләй юк диярлек, бу баштанаяк кардан гына торадыр сыман иде.

Кояшлы якка килеп чыктылар. Тагын жепшек кар ярып бара башладылар. Металл тырнаклар аякны туңдыра. Нуриман туктады.

— Бергшрунд,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә, ләкин аңлаплык итеп.

— Нәрсә?

— Әнә күрәсеңме, нинди ярык анда.

Матушкин үзләреннән ике-өч адымдагы киң генә кара-кучкыл тасманы шәйләп алды.

— Менә монда, шуның кырыена утыр,— диде, рюкзагын сала-сала Нуриман,— сакта торырсың.— Ул боз чүкеченә бау бәйләп аны Матушкин артында тирән итеп карга батырды. Аннары шул бау белән юлдашының биленнән чорнап алды.

— Ничек сакта торасын беләсеңме?

— Беләм, күнегүләрдә өйрәткәннәр иде.— Матушкин бауны кулына тотты. Нуриман аның хәрәкәтләрен сынап күзәтеп торды.

— Дөрес тотасың,— диде Нуриман һәм чүкече белән кар күперенең ныклыгын чамалый-чамалый алга китте. Ярыкның теге ягына житкәч, бауга бәйләп рюкзакларны тартып алды, аннары инде үзе, Матушкин кебек жайлы гына утырып, сакта торырга әзерләнде.

— Йөр,— диде ул, жайлабрак урнашкач.

«Шахмат уйныймыни — «йөр», имеш, актан кара шакмакка»,— дип уйлап алды Матушкин. Һәм төбендә жәһәннәм жәйрәп яткан каракучкыл кар өстенә атлады.

Ярты араны да үтмәс борын, кайдадыр өстә рәттән генә, сул колдарак колак тондыргыч шытырдау яңгырады. Матушкин башын күтәреп карады. Анда, өч йөзләп метр арырак, текә стена кебек торган таудан

хоккей мәйданчыгы зурлыгындагы боз кантары аска шуышып төшеп бара иде. Бар тирә-як тетри, ташкын ягыннан кар күпере ярыкка убылып килә иде. Таң калган Матушкин бергшрундның ачылып килгән авызына тагын бер мизгел карап торды, ә икенче мәлдә аның аяк астындагы җир әллә кая китеп, ул үзе җәһәннәмгә очты... Мәтәлчек атты, башы белән ташка бәрелде, аннан җилкәсе белән... Якты дөнья белән бәхилләшергә дә өлгермәде, бау тартылып, аның эчен китереп кысты, сул боты бик нык авыртып китте — бау аны кысып алган иде. Маятник кебек стенага килеп бәрелгәч, Матушкин тезе иягенә тиеп торган хәлдә бераз янтаебрак, кыя каршында чайкалып калды.

Ярык кин, бик кин иде. Аның шоп-шома яшькелт стеналарыннан челтерәп эрегән кар суы ага. Аска, як-ягы кайдадыр бергә килеп кушыла торган, карарга да котың очарлык төпкелгә ага. Шитов әнә шундый ярык турында сөйләгән дә иде инде. Тик моннан Матушкинның гәүдәсен тартып алу турында уйлыйсы да юк, чөнки дә күрмәячәкләр аның. Төбенә үк төшеп китсә әле... Ләкин иң мөһиме — бау аны тотып тора! Матушкин башын күтәреп өскә карады. Анда шундый зәңгәр иркен күк йөзе... һәм Нуриманның чырае киткән йөзе.

— Исәнме син?

— Исән кебек.— Матушкинның батыраеп, бәйсезрәк итеп әйтәсе килгән иде дә, ләкин мескенрәк аваз килеп чыкты бугай.

— Курыкма, Сережа, бау ычкына торган түгел.

«Курыкма, имеш! Бу җәһәннәмгә, бу бүре өненә син үзең килеп эләксәң, карар идек!..— Матушкин саклык белән аягын бушатты.— Күңелем сизгән иде, шушы такыр баш иблис белән бергә дөмегермен дигән идем аны!» Тыштан исә ул:

— Нуриман, чыгып булырлыкмы моннан, ә?— дип кычкырды.

Тик аның сүзләрен әле тынып та җитмәгән ташкын шавы күмеп китте. Аның кайтавазы, ярыктан үтеп, кар күперенең соңгы калдыкларын да аска койды. Бәйдән ычкынган боз һәм кар өеменең гөрелтесе тынгач, Нуриман тавышы ишетелде:

— Сережа, чайкалмас өчен стенага ябыш, тырнакларың, чүкечең белән. Мин икенче бауны ыргытам...

Ул әлеге бау белән, бозкиткеч, тырнаклар, кул-аяклар белән нишләргә кирәген аңлатты.

— Сережа, мин тарта башлыйм.

— Әйдә.

Матушкин өскә күтәрелә башлады. Әкрен-әкрен, сантиметрлап кына. Өскәрәк, өскәрәк. Ике якның берсе команда бирсә, туктап ял иттеләр. Ниһаять, Матушкин ярга якынайды, өскә менде, терсәгенә, кулына таянды. Нуриман аны, якасыннан эләктереп алып читкә өстерәде, һәм алар ярыктан ерак китеп кар өстенә аудылар.

— Баш бетүе шушы икән дигән идем инде,— диде Матушкин бераз тын алгач. Аның бөтен тәне калтырый, ул үзенең исән калганына ышанмыйчарак тора иде әле.

Нуриман ике кулын ике тез арасына салындырып, каскасыз, башлыксыз килеш авыр сулап утыра. Тәртеп чыга башлаган чәч төпләрендә тир бөрчекләре ялтырый. Суга төшкән тавык кебек чыланган, калтырап торучы Матушкинга карап, ул беренче тапкыр елмайды:

— Бик җиңел түгел икәнсең бит син, әй,— диде. Бераз тын торгач:— Ә болай егет икәнсең үзең, булыштың. Берүзем генә сине тартып чыгара алмаган булыр идем.— Ул рюкзактан термос алып, капкачына чәй салды да Матушкинга бирде:— Эчеңә җылы керсен, эчеп җибәр.

Матушкин чәйне алып, тешләрен шакылдата-шакылдата эчә башлады. Ә Нуриман ярык буйлап китте. Кире килеп, икенче буйны карады, тагын борылып килде. Матушкин, чәен эчеп бетергәч:

— Ә ничек кайтабыз?— дип сорады.

Нуриман җавап бирмәде.

— Әйләнеп чыгабызмы?

Нуриман дәшми иде.

— Ник дәшмисең син?

Бауны чорный-чорный, Нуриман ярыктан читкәрәк китте. Матушкин ярыкка таба елышты. Нуриман аны кырыс кына үзенә таба тартты:

— Кит аннан, тагын ычкынып китүең бар.

— Син шуны әйт миңа: бу упкын аркылы теге якка ничек чыгарбыз без?

— Берничек тә. Җыен әйдә, кузгалырга вакыт.

— Кая тагын? Ә ничек кире кайтабыз? Әйләнепме?

— Юк,— Нуриман башын селекте,— аны әйләнеп чыгарга көчебез җитмәячәк.

— Күреп торам шул.

— Шулай булгач...

— Нәрсә шулай булгач? Шундый тыныч сөйләшәсең син, әйтерсең, безнең алда сукыр тычкан казыган бер тыкрык диярсең.

— Әйдә, үргә меник, аннары күз күрер.

Башка тәкъдим итәр сүзе булмагач, Матушкинга баш иясе генә калды.

## 13

Разведчиклар үргә егерме минутка соңарып менеп җиттеләр. Шулай да радиоэлемтәгә тиз керә алдылар. Күрәсең, Док рацияне бәла вакытында ташлап китмәгән, егерме минут буе өзлексез эфирга чыгып торган.

— Я, ничек, Ак Бүренең маңгае күренәме?— дип сорады ул беренче эш итеп.

— Бар, күренә,— дип җавап кайтарды Нуриман.— Түбәсе әйбәт күренә. Тик эш шунда... Кыскасы, безнең кайтыр юл киселде.— Ул ике-өч сүз белән булган хәлне сөйләп бирде.— Минем фикерем мондый һәм бердәнбер чара кебек: Сережа белән безгә траверслап түбә аша кичәргә кала. Анда, карап торышка, үрмәлисе җир юк кебек, төшүен теге якка, Зыряновлар янына төшәчәкбез. Әйе, басмага. Ә сез хәзер үк шунда китегез һәм аннан безне алмага коткаручылар җибәрегез.

Док бәхәсләшә китте:

— Ул ярыкны ыклап карарга, исәпләргә кирәк, без хәзер Зиннәтуллин һәм Исмәгыйль белән сезнең эздән китәбез.

Зыряновтан кала, Нуриман командада беренче аксакал, ниһаять, төркемнең командиры, шуңа күрә соңгы сүз аныкы иде. Ул:

— Кадерле Док, җаным, мине тыңла,— диде.— Бергшрундка сезнең белән безнең генә көч җитәрлек түгел. Сезнең монда килеп җитеп бу сүзләрнең дөреслегенә ышанганны көтеп торырга вакыт юк. Безгә ашыгырга кирәк. Зырянов инструкциясенә рәхмәт, тик барыбер безнең ашау күпмелек икәнен үзең беләсең. Көн әйбәт торса, җитәргә тиеш. Бүген түбәне үтәрбез дип уйлыйм, иртәгә иртән басмага таба юл тотачакбыз.

Нуриман элемтә тәмам икәнне әйткәч, Матушкин:

— Иртәгә беренче лагерьда булабыз алайса...— диде. Аннары ул биноклен алып алга карады, куен дәфтәренә нәрсәдер төшерде.

— Сережа, бүген без тауга менеп җитәргә тиеш.

— Аңлыйм,— дип җавап бирде Матушкин,— тик моны башта миңа әйтсәң дә була иде, Докка әйткәнче. Миңа... Ни дисәң дә бергә-бергә атлыйсы бит.

— Кәефең бик шәптән түгел иде бит һәм син...— Нуриман сүз уртасында туктап, бер үк бауга бәйләнгән юлдашына карап торды-торды да бөтенләй башка эздән алдырып әйтте:

— Әйдә болай килешик: без монда бульварда йөрмибез. Этикет, үпкә, горурлык дигәннәрне читкә куеп торыйк. Мин кушкан һәр нәрсәне син бәхәссез һәм җиренә житкереп үтәргә тиешсең. Минем һәр карарым, һәр боерыгым, күпме генә абсурд булып күренмәсен, ул — закон, аңлашыламы? Ә хәзер рюкзагыңны монда бир.

Матушкин дәшми генә рюкзагын өстерәп китерде. Нуриман, аның авызын чишеп, Шитов калдырган әйберләрне үзенекенә тутыра башлады.

— Нуриман, кемгә саныйсың син мине?— диде түземен җуеп Матушкин.— Синдә болай да палатка, боларын да үзеңә төямәкче...

— Әле генә әйттем бит... Карышмаска дип әйттем. Һәм борыныңа кәгазь кисәге ябыштыр, тиресен салдырасың килмәсә.

Матушкин тешен кысып булса да түзде, әрнеп торган борынын тотып карады, сүзсез генә Нуриманга рюкзагын кияргә булышты, үзенең дә җиңеләеп калган капчыгын җилкәсенә салды һәм разведчиклар тагын кузгалып киттеләр. Хәер, алар хәзер разведчик кына түгел, ә бәлки ихтыярсыз рәвештә беренче тауменәрләргә әверелделәр.

Очы-кырые күренмәгән карлы тау битеннән алар тыныч кына йокымсырап яткан иләмсез зур тау түбәсенә үрмәләделәр. Матушкин нурда коенган Ак Бүре башына карап соклана, халыкның зирәклегеннән гаҗәпләнгәннән-гаҗәпләнә бара иде. Тау түбәсе яннан караганда чыннан да бүре башына, ә түбәсе сөзәк маңгайга охшабрак тора. Хәтта колаклары да бар кебек — ниндидер сәер кар өентеләре аңа сагаеп калган кыяфәт өстиләр сыман.

Ак Бүре йокламый иде. Ул корбанын көтеп ята. Ә бу ике бәндә, бер бауга бәйләнгән ике мескен, кояшлы көнгә куана-куана, аңа якынайган булалар, аның авызына кермәкчеләр. Табигать хакимнәре дип масайган ике тузан бөртеге...

Грузиннар калдырган төенчекне Нуриман таба алмады. Тау тишегенең кайда булырга тиешлеген ул якынча чамалый чамалавын, бер-ике сәгать юанса, тапкан да булыр иде, мөгаен, ләкин икенең берсен сайларга кирәк: төенчекне табып, шушында коткаручыларны тик көтеп утырырга (ә төенчекне тапмавың да бар бит әле), яки көн әйбәт торганда Ак Бүрене кичәргә дә аннары, бер төнне артыграк кунсаң да, аның теге сөзәк ягыннан ничек тә булса басмага кадәр тәпиләргә.

Эзләнүне туктатып, аннан-моннан гына тамак ялгадылар да Ак Бүренең көньяк-көнбатыш кабыргасыннан кисәк өскә күтәрелә башладылар. Шулай да Нуриманның исәпләве бик үк дөрес булып чыкмады — кайбер урыннардан үрмәләп шуышырга туры килде. Дөрес, алай ук кыен эш түгел иде бу. Аннары Нуриман шундый ярыклар, шундый киштәләр таба торды ки, алардан Одессадагы Потемкин баскычыннан баргандагы кебек атлап була иде. Ә менә биеклек дигәне... Анысы үзен сиздерә башлады. Сулыш кыенайды, рюкзак, адым саен бер таш өсти барган кебек, авырайганнан-авырая барды. Һәм аннары иң гаҗәбе — үтереп ашыйсы килә! Ә Нуриман, механизмын борып куйган уенчык машина сыман, һаман өскә менүен белде. Матушкин ачу белән бер төкергән иде, сулышы капты. Төкерү дә кыенлашты.

Ниһаять, Ак Бүре сыртына килеп житкәч, Нуриман уңгарак борылды. Текә кабыргадан диагональ буйлап, сөзәк тау кикригенә таба юл алдылар. Матушкин бу маневр турында күптән уйлап килә иде. Ләкин Нуриман тау кабыргасына менүнең катлаулы булуына да карамастан, юлны кыскарту өчен, бар мөмкинлекне ахырынача файдаланды.

Тау кикригенә дә аяк бастылар. Радиоэлемтә өчен махсус туктап алдылар. Ләкин рация тауменәрләрне күзәтчеләр белән тоташтырудан баш тартты. Әллә ватылган, әллә батарейкалары утырган, ә бәлки, тауменәрләр радиоэлемтә зонасыннан чыкканнардыр...

Тамак ялгадылар. Тәннәренә көч керә башлады. Кәеф тә күтәрелеп китәргә тиеш иде: матур булып кояш баеп бара, шагыйрәнә манзара

үзе, ләкин Матушкин ял итеп хәл алгач, моңарчы җиңелчә генә сагаетып килгән нәрсәнең чын-чынлап өркетә башлаганын тойды. Әйе, ул йокы капчыгы алмаган иде. Шитовны тыңлаган булды: «Нигә, имеш, миңа капчык? Юлга ярты көнгә чыгабыз, ә бер атналык йөк алабыз. Үз күләгәңнән үзең курку бу, мин алмыйм», янәсе. Ә төнлә нишләрсең? Хәзер үк суыта башлады.

Матушкин Нуриман артыннан сөйрәлә, колак ишетмәгән сүзләр белән үз-үзен тирги иде. Нәрсә дип әйтер ул аңа? Зырянов инструкциясен мин белмим, юлга чыгар алдыннан әйткәннәрне ишетмәдем, дипме? «Диванадыр син, Сергей түгелсеңдер. Дивана Матушкин. Менә ул үзе, рәхим итеп карагыз, сәйранга чыккан!»

Саклык бавының тартылып-тартылып куюына буйсынып, моңсу уйга баткан Матушкин Мәмәтбәк пычагыдай үткен тау кикригенә аяк басты. Монда җил хакимлек итә иде. Җил тамакка, үпкәгә килеп тыгылды. Матушкин авызын ачып, тураеп басты да шашкан кебек күзләрен бер ачып, бер йомып тора башлады. Ә җил штормовка астыннан шуып керде, тирләп аркага ябышкан футболка салкыны арканы чымырдатты.

— Нәрсә, тынны капладымы әллә? — дип кычкырды Нуриман. Тавышы көрәйгән иде. Күрәсең, борыны монда чакырып китергән романтика җилен сизгәндер. Ул сырт өстеннән ышыграк җиргә төшеп, Матушкинны да дәшеп китерде.

Бераз ял итеп, кием алыштырып алдылар. Нуриман Матушкинга аркасы лычма су булган футболканың артын алга әйләндереп кияргә кушты.

— Тизрәк кибәр. Штормовкаңны да сал, дымланган. Свитер һәм мамык курткаңны ки, биш минуттан салкын төшәчәк.

Матушкин рюкзагына тотынды. Сүзсез генә киенде. Башында бер генә уй иде: йокы капчыгы турында ничек сүз башларга? Соңгарак калдырып торасы итте. Буласы булган инде. Хәзер аның менә тагын үтереп ашыйсы килә башлады, иң мөһиме шул иде.

— Әллә бирәнем кузгалды инде, коточкыч! Нуриман, әллә капкалап алабызмы?

— Әле генә ашадык бит әле,— дип гаҗәпләнде начпрод, ләкин каршы төшмәде:— Әйдә, алайса,— диде. Ул килька банкасы алды, ипи белән берәр алма тартып чыгарды.— Кайнар ашны тегендә ашарбыз инде,— дип, тау түбәсе ягына ым какты.

## 14

Тау түбәсенә ым кагу бер хәл дә, аңа тәпиләп менүе бөтенләй башка нәрсә шул.

«Тәпиләп» дип яратып Зырянов әйтә. Менә шулай Матушкин Нуриман артыннан тәпиләде.

Ә җил көчәя бара. Ул, бер дә өмет калдырмыйча, сызгырып ук исә башлады. Һәм менә астан, дошман өередәй булып, ертык-ертык яман болытлар очып чыкты. Алар бик тиз кояшны да, тау түбәсен дә капладылар, тирә-юньне караңгылык чорнап алды. Яңгыр ява башлады. Ә тетенсыман сәләмә болытлар упкын төбеннән бер-бер артлы чыга гына тордылар. Аларны өстә җил тулгандыра-тулгандыра да су тузаны һәм өстәмә караңгылык итеп җиргә бөрки. Матушкин үзенең әйдәүчесен күрми башлады. Бер-ике метр арада шәйләргә мөмкин әле, аннары ул көлсыман пар эчендә эреп юкка чыга. Куркыта. Җил вакыт-вакыт шундый итеп китереп бәрә, тау битеннән себереп алып, җәһәннәмгә олактырыр кебек тоела иде. Атлаган саен Матушкин бозкиткечнең сабын карга ныграк батыра барды. Ул Нуриманның аяк эзенә басып барырга тырыша. Күзлекне су элпәсе каплап, юньләп күреп тә булмаганлыктан, болай хәрәкәт итү бер дә ансат түгел иде. Ә әйдәүче әледән-

але бауны тарткалый. Матушкин үзенчә генә атламакчы булып караган иде, ләкин бик тиз тыны кысылып, артка кала башлады һәм бау тагын тартылып-тартылып куйды. Ниһаять, Матушкин атламас булды, күзлеген салды һәм бау тартылганга илтифат итмәде. Нуриман килеп житте.

— Хәзер үк ки күзлегеңне!— диде ул.

Матушкин, ярдагы балыктай авызын ачып сулый-сулый, дымланган күзлеген күрсәтте:

Нуриман:

— Хәзер үк ки, сукыраясың!— дип кабатлады.

— Болыт та, кояш та юк лабаса...

Нишләсен, Матушкин күзлеген киеп куйды. Хәзер аның пыяласына ак көрпә килеп сугыла. Ешрак туктый башладылар. Сүз катасы булса, Матушкин Нуриманга кычкырмый, ә бауны гына кага.

Бер туктальштан соң Нуриман тагын:

— Бүген түбәне узарга кирәк,— диде.

— Ә кайда соң ул?— дип гасабиланып сорады Матушкин.— Мени хәзер мин синең тавышыңны гына ишетәм, ә үзеңне күрмим.

Нуриман җәптәшенең хәл җыйганын түземлек белән көтеп торды һәм тагын алга атлады.

Көч беткәннән-бетә бара, ә тау сыртының очы-кырые юктыр кебек. Матушкин бер тапкыр сөртенеп егылды, тик бау тартылмады, Нуриман сизми дә калды. Матушкин тизрәк торырга тырышты, ике тапкыр кандидат Сабиров каршында сер бирәсе килми иде аның. Дистанцияне урнаштырды, ләкин тыны бетте. Хафизов карап торса иде хәзер, Бельский, редактор!..

Тиздән бу соңгы уйлар да әллә кая китте, башта соң дәрәҗәдә аңгыралык билгесе — томан гына утырып калды.

Өскәрәк менгән саен, һава җитми. Ул хәзер суынып, өтеп ала торганга әйләнде, әле күптән түгел генә шыбыр тиргә батып барганнардыр дип башыңа да китермәссең. Кул-аяклар күшегеп катты. Ә жил тагын да котыра төште, бүредәй уларга, киектәй ырылдарга тотынды. Кайдадыр гөрселдәп кар ишелде. Тагын бер адым, тагын, я тагын... Кулындагы чүкече кар астындагы бозга бәрелеп чыңлады, таеп китте, Матушкин, чайкалып китеп, борыны белән карга төртелде. Җайлы төште. Аска тәгәрәмәде тәгәрәвен, әмма торып баса да алмый иде.

— Нишлибез?— диде ул янына килеп житкән Нуриманга.

— Хәл алыйк,— диде Нуриман.

Ун минуттан тагын алга таба кузгалдылар. Түбә итәгенә текә күтәрелеш башланды. Нуриман басмалар чокырга, ыргаклар кагарга, култыксалар тарттырырга тотынды. Хәзер инде ташбака адымы белән туп-туры диярлек күккә менә башладылар. Матушкинның өстенә боз пыяласы коела, каскасында барабан кага. Матушкин чокылган басмада башын иеп басып тора, юлдашының боерыгын гына ишетә иде.

Матушкин, бауга махсус кыстыргыч белән ябышып, өскәре менә башлый — бау өчен ул бары бер йөк кенә иде, һәм бау өзелми — ыргактан ычкынмый, чыдый, күтәрә иде.

Нуриман өчен дә ул шулай ук бер йөк кенә булгандыр инде.

Матушкин баш түбәсе белән Нуриманга килеп төртелгәнче үрмәли дә туктап яңа команда көтә, һаваны йотлыгып сулый-сулый тагын кузгала. Инде бу юлы Нуриман янына менеп житә алмам дигәндә генә стена да бетте.

— Шәп балкон бу,— яңа үр алдыннан бу мәйданчыкка аяк баскан да Матушкин шулай дип әйтә алды.

— Балкон түгел бу, түбә итәге,— диде Нуриман.

Озак кына ял иттеләр. Җил тынмады, һава температурасы төшкәннән-төшә барды, чыланган киемнәр катыланды, төн якынлашты.

— Балкем, шушында гына туктарбыз?— дип тәкъдим кертте Матушкин.

— Юк,— диде Нуриман,— моннан безне җил «эһ» дигәнче себереп төшерәчәк. Җил бу якта уйный.

— Ә теге якта юкмы?

— Анда ышыграк.

— Каян беләсең аны?

— Кабыргада чакта флагтан[1] чамаладым.

— Минем аяклар катты.

— Тырнакларыңны салып тор. Бераз җылынып китәрсең.

Нуриман, бияләен салып, туңган бармаклары белән чияләнгән төенне чишәргә тотынды. Төенне чүкеч борыны белән казый-казый сөйләнде үзе:

— Илле метрдан да артык калмады, гел җитмеш булсын, ди.

Метрлар, километрлар... Тауларда болар үлчәү берәмлеге түгел. Матушкин, бу юлның чиге булмаячагына әзерләнеп, бер сүзсез тагын алга сөйрәлеп китте.

## 15

Бүренең маңгае чынлап та сөзәк иде — басма чокыйсы да, култыкса тартасы да булмады. Суыкта шытырдап ката башлаган кар өсләтеп тәпилисе булды. Кул егылганда гына кирәк иде.

Алда Нуриман, аның артыннан сузаеп Матушкин атлый. Күпме барганны, күпме ял иткәнне исәпләргә баш җитми иде.

Төн килде. Ләкин, соры болытлар эчендә болай да караңгы булганлыктан, бу хәл әллә ни зур үзгәреш кертмәде.

Көтмәгәндә җил бар тарафтан бөтерелә башлады. Матушкин мүкәләп алга үрмәләде, ә үр кебек нәрсә юк иде, сөзәге дә, текәсе дә — бернинди үр юк.

Аякларын аерып атлый-атлый Нуриман килде.

— Түбә бу!

— Берни күрмим.— Матушкин торып басты.

Алар, бөтен инструкцияләрне бозып, кулга-кул тотыныштылар да як-якка карый-карый атлап киттеләр. Алардан өстә җир юк — яңгыр белән бушлык кына иде.

— Тизрәк моннан төшәргә кирәк,—дип кычкырды Нуриман,—тизрәк.

— Фоторәсемгә дә төшеп булмый бит. Кем ышансын инде миңа!

— Тизрәк!

Нуриман Матушкинны өстерәп алып китте. Ак Бүренең колаклары булып күренгән ике боз пирамидасын узып киттеләр һәм саклыкның бөтен кагыйдәләренә туры китереп, егерме метрлап түбәнгә — ышыграк урынга төштеләр.

Матушкин килеп утырды, ә Нуриман куну урыны эзләп китте. Кар ява башлады. Җил аны биткә дә китереп сылый, муенга да тутыра. Матушкин, күзен йомып, рюкзагы өстендә утыра һәм берни дә уйламый иде.

— Сережа, Сережа! Ник җавап бирмисең? Киттек.— Нуриман иптәшен күтәреп торгызды да, тагын сигез метрлап аска төшкәч, кеченәрәк кенә тигез бер урынга туктадылар. Нуриман палатка кора башлады.

— Булыш әле.

Матушкин Нуриман күрсәткән нинди дер бер бауны тотып торды, аннары икенчесен: аның башы әйләнә, тәне калтырый — хәле мөшкел иде.

Ниһаять, торак әзер булды. Бу — махсус тау палаткасы иде. Ул ике ишек-җиңсәле. Нуриман — аның берсеннән, Матушкин икенчесеннән керергә булдылар. Керешли Матушкин палатканы тарттырган бауга

[1] Флаг — тау түбәсеннән җил себергән кар. Ул, чыннан да, җилфердәп торган әләмгә охшый.

аягы эләгеп егылып китте. Ташка уралган бау ычкынып китеп, чатыр кыегаеп калды. Җинсәдән башын тыккан Нуриман, иптәшен янында күргәч, иркенәеп сулыш алды да тагын тышка чыкты.

— Бәхетең бар икән әле,— диде ул, бауны яңадан тарттыра-тарттыра,— басмага кадәр тәгәрәп төшүең бар иде.— Ул элмәкне ташка элэктерде. Матушкин сүз катмады, рюкзагын палаткага тыгып, үзе дә кереп китте. Палаткада җәннәт кебек иде — кар да яумый, җил дә юк, тын һәм тыныч; бураны да, ташкыны да тышта, еракта калды. Алардан хәзер курыккан юк. Йокларга, тизрәк йокларга!

Ыргакларын зыңгылдатып, Нуриман килеп керде. Ул караңгыда мышный-мышный кыштырдады, аннары фонарь кабызды.

— Ә син нишләп утырасың? — дип гаҗәпсенде ул.— Әйдә, капчыгыңны ал да — ятабыз.

— Капчык юк минем,— диде Матушкин.

— Аңламыйм.

— Мин аны алмаган идем.

Нуриман Матушкинга күзләрен киң ачып карады.

— Мин кисәтеп әйттем бит... Син инструкция белән таныш ич...

— Мондый хәлдә калачакны кем белгән! — Матушкин моны ачу-дан буылып акырып салды ки, әйтерсең, бергшрундны кичкәндә кар күперенең ишелеп төшүенә дә, көн бозылганга да, Шитов киңәшенә дә Нуриман гына гаепле иде.— Синең белән юл уңмаячагын күңелем сизгән иде аны. Әле моның,— Матушкин бармагын өскә төртеп куйды,— башы гына икәнен белми дип уйлыйсыңмы әллә син мине?

Нуриман Матушкинга аптырап карап торды да, башын иеп, рюк-загын бушата башлады.

— Нәрсә телеңне йоттың мәллә? — дип гасабиланды Матушкин.

— Ярый, Сережа, тынычлан. Минем капчык зур — күңелең киң булса, икебез дә сыярбыз,— диде Нуриман һәм капчыгын җәеп җибәрде.— Кереп ят. Аягыңа минем тире катаны ки, тиз җылынырсың, ә мин примус кабыза торам.

Матушкин күзен йомды. Ә Нуриман ягымлы тавыш белән:

— Хәзер аш куям. Көн буе ашамый йөр дә, билгеле инде... Чәй дә куябыз. Ашау җитәрлек. Ашагач, тиз җылынасың ул.

Матушкин башын селкеп куйды: «Бу ни булды соң әле миңа?» Ул күзен ачты, әкрен генә ботинкасын салды...

— Ятканда оекбашыңны футболка астына күкрәгеңә куеп ят,— дип киңәш бирде Нуриман примус белән кайнашкан арада,— иртән-гә кипкән булыр.

Беравыктан Матушкин аңга килә башлады, аягына мең инә чән-чегәндәй булды, куллары янды, ашыйсы килә башлады.

— Исе дә исе! Син, Нуриман, бер дигән аш-су остасы икәнсең.

— Тот мискәңне.

Матушкин ике мискә аш шупырды, бер банка соуслы кильканы үзе генә сосып бетерде диярлек.

— Ә син ник алай? Аппетит юкмы әллә? — дип ашый-ашый Нури-маннан сораган булды.

— Минем чәй эчәсе килә әле,— дип тыныч кына җавап бирде начпрод,— чәй яратам мин.

Ашагач, йокы капчыгына ябырылдылар. Әлбәттә, ул ике кешегә исәпләнмәгән иде. Шулай да ничек кирәк алай сыйдылар — Нуриман-ның капчыгы киңрәк иде. Матушкин бик юан булмагангамы, хәтта «Молния»не дә каптыра алдылар. Дөрес, ятканда икең дә бер генә якка карап, кулларны җыеп ятарга туры килде. Нуриман шундук йоклап китеп, аның кайнар тыны Матушкинның муен арты тирәсенә бәрә баш-лады. Ул гарасат уртасындагы палатканың отыры ныграк дерелдәвен дә, очып китәрдәй булып, канат кагынгандай шапылдый башлавын да ишетми иде. «Ярабби,— дип уйлады Матушкин,— ярабби, бетәр микән

бу, юкмы?» Ул йоклап китә алмый иде. Тормышның кыл өстендә булып, кыймылдый алмыйча да ятканда, ни җаның белән йоклап китмәк кирәк?!

Сулыш алуы кыенайды. Бәлки, шулай тоела гына торгандыр. Юк, пульс ешайган, чигәдә еш-еш һәм каты итеп кан тибә.

— Нуриман, нәрсә соң бу?

— Көрт күмеп киткәндер безне.— Нуриман да йокламый, уянган иде инде, ул замокны ычкындырып, капчыктан чыкты, арырак кыштырдый башлады.— Әйе шул, безне кар күмеп киткән. Казып чыкмыйча булмас.

## 16

Таңгача кар казыдылар. Иртән торакларының мәгарәгә әйләнеп калганлыгын күрделәр. Нуриман разведкага дип чыкты да, биш минуттан кире әйләнеп кереп, юлны дәвам итеп булмаячагын әйтте.

Матушкин моны разведкасыз да — туктаусыз җил ыжгыруыннан да чамалый иде.

— Һаман бер җырны җырлый...— диде ул, тышка колак сала-сала.— Нуриман, беләсеңме, хәзер без кемгә охшаган? — Һәм, җавабын көтмичә үк дәвам итте:— Сарыкларга. Ике ахмак сарыкка. Һәм Ак Бүре безне хәзер кабып йотарга тиеш. Теге көнне без тәкәне ялмаган кебек, кимерә-кимерә ашарга тиеш ул безне.

Сакал төкләрен ышкып, Нуриман көлемсерәп куйды:

— Хәтереӊ шәп икән синең. Тик син ул чакта итне ашамадың лабаса. Гөнаһтан куркасың юк.

— Барыбер ашаячак. Акмы, сорымы, бүре бүре инде ул... Аерма юк.

— Әйтмәгәнең булсын, Сережа. Ак бүре бөтенләй башка ул. Ак бүре кыерсытырга тиеш түгел.

— Карарбыз, карарбыз,— дип Матушкин кар баскан чатыр түбәсенә ишарәләп, ым кагып алды.

Нуриман, кирегә сукалауны сабыр гына тыңлып торды да, башлаган сүзен дәвам иттерде:

— Менә син тыңлап кара әле алай булгач. Тик мин чәй кайнатканчы капчыкка кереп ятып тор... Безнең татарда һәм, гомумән, төрки халыкларның күпчелегендә, бүре изге зат булып, безнең бабаларыбыздан исәпләнә. Ә без — татарларда, гомумән, ул — халыкны коткаручы. Бу турыда әкиятләр дә күп. Балачактан ук онытылып укый идем шуларны. Зоопаркка баргач та ак бүрене таптырып аптыратып бетерә идем. Ә ак бүре юк. Сорылары, каралары, хәтта ниндидер кызыллары да бар, агы гына юк. Әти: «Ул безнең бабабыз бит, ул борын-борын заманда гына яшәгән булган»,— дип көлә торган иде. Мин үземнекен тукыйм: «Син бит аны тылсымлы бүре дигән идең, ә тылсымы булгач, үләргә тиеш түгел ул».

Нуриман, кайнап чыккан суга бер чеметем чәй салып, хуш ис иснәгәндәй «әх!» дип куйды.

— Хәзер була чәй. Әйе, ак бүре турында әтидән дә кызыграк итеп сөйләүче юк иде. Китапта бик гади ул, ә әти озын итеп, тәфсилләп сөйли иде, һәм һәрвакыт төрлечә сөйли торган иде... Борын-борын заманда безнең бабаларыбыз урман-таулар гизеп яшиләр икән. Һәм аларның ханы — хәзергечә Ак Кояш булыр иде — Ак Көнекәй дигән бер батыр була. Бервакыт дошманнары, кысрыклап, боларны карурманга куып кертәннәр. Беркая барыр юл юк икән: алда башы күк белән тоташкан тау, артта — дошман явы, имеш. Шунда Ак Көнекәй кояшка карап дога кылган: «Әй, кояш-кояшкаем, үз исемеңне йөртүче бу баланы һәм аның ыругысын ач үлемнән коткарып калчы, шушы тауны кичәргә ярдәмеңне бир. Ак Көнекәйне дошманга бирелү хурлыгыннан йолып калчы»,— дип ялварган. Кояш, әлбәттә, ялварган тавышны ишеткән

һәм нәкъ көн уртасында уктай төз нурын егетнең аяк астына текәгән. Нур шунда ук Ак Бүрегә әверелгән дә егеткә: «Атлан минем сыртыма,— дигән,— мин сине хәзер тауның теге ягына күчереп куям, безнең арттан нәсел-ыруың да шунда күчкән булыр»,— дигән. Ак Көнекәй Бүрегә менеп атланып, аның ак ялына ябышкан һәм шул җанвар, батыр белән аның бөтен ыруын тауга менгезеп, теге якка алып төшереп куйган ди.

— Полный траверс икән,— дип йомгаклады Матушкин. «Басмага» ук килеп төшкәннәр, дисеңме?

— Мин алай димәдем бит.

— Барыбер, шәп уйлап чыгардың. Тик, кызганычка каршы, мин татар түгел, һәм ак бүре мине коткарып маташмаячак.

— Ярый, аның белән синең өчен мин сөйләшермен.— Нуриман ике кулын авызына куеп кычкырырга тотынды: — Ак Бүре-е-е, Ак Бүре-е-е, ишетәсеңме мине? Сергей Матушкин, татар булмаса да, шәп малай...

Икәүләп көлеп җибәрделәр.

— Кәмит инде,— дип куйды яшь аралаш Матушкин.

— Яле, мин аңа әкият сөйләдем, ә ул «кәмит» ди. Әйдә, чәй эчәбез.

Чәен өрә-өрә Матушкин:

— Нуриман, әйт әле, ник син бу кадәр сәләмә кием белән йөрисең — ямау өстендә ямау? Яңаны алырга хәлең бардыр инде. Шулай йөрергә оялмыйсыңмы? Ни дисәң дә, син Зыряновның уң кулы бит, мастерлыкка кандидат, сиңа тигезләнәләр.

— Чапаев үзенең Петькасын тәрбияләгән кебек тәрбиялисең әле син мине.

— Шулай да булсын ди.

Начпрод авызын яндыра-яндыра чәй уртлагандай итте. Дәшми торды.

— Бу минем киемем, Сережа... Ничегрәк итеп аңлатырга икән сиңа? Шушы кием белән моннан биш ел элек без Зырянов белән шушындый ук бер көнне Күкҗалда исән калган идек. Ә бер җәйне, кыядан ычкынып китеп, егерме метрлап очып төшсәм дә, исән калдым. Аннан... шушы киемнән Аня белән таныштык... Варзобта... Әйе. Чыгарып ташлавы кызганыч. Ямыйм да киям шунда.

— Ырымга ышанасың икән син, Нуриман — Ак Бүре, ямаулар...

— Моннан котылсак, алыштырам. Валлаһи, алыштырам!

Ашап алгач, чыгар тишекне киңәйтергә тотындылар. Көрәксез эшләве кыен иде — җайлырак булганда, чүкеч белән кар шакмаклары кисеп түбәнгә ыргыттылар, яки кул белән казыдылар. Аз гына хәрәкәттән дә тын кысылып, хәл бетә иде. Ә буранның туктарга исәбендә дә юк. Җил котырып улый, аяктан егардай булып китереп бәрә. Тирә-якта — кар да кар... Болар күпме генә тырышмасыннар, кар астыннан палатканы чамалап булырдай түгел иде инде...

## 17

Нуриман боерыгы белән Док килешмәгән иде. Өлкән урынына калган булганлыктан, ул бергшрундка менәргә әзерләнергә кушты. Аня каршы төште:

— Нуриман төп бивакка күченергә кушты, димәк, ул ярык янында безнең эш беткән. Тизрәк Зырянов лагерена чыгып, Ак Бүрегә шуннан менә башлау ягын карарга кирәк.

Шитов та Аня яклы иде. Ныклы бер фикергә килә алмыйча бәхәсләшә торгач, болай хәл ителде: Шитов белән Аня төп бивакка китәләр, Зыряновка хәлне аңлаталар, ә Док, Исмәгыйлев һәм Зиннәтуллин бергшрундка менәләр.

Басма янындагы бивакка Шитов белән Аня радиоэлемтәгә ярты сәгать кала килеп җиттеләр. Ягъни, барысы да уйлаганча килеп чыкканда,

Зырянов белән Нуриман һәркайсы үз лагереннан торып алдан килеш кәнчә бер-берсе белән рация аша сөйләшә башларга тиешләр иде.
Зырянов башта Шитовны, ә аннан соң Аняны тыңлады, кашлары җыерыла барды. Ул аларның хәрәкәтләренә бәя биреп тормады:
— Көн бозыла,— диде. Һәм тагы: — Көн бозыла, егетләр,— дип өстәде.
Иртән, Нуриман төркеме юлга чыгып киткәч, ул монда планны үзгәртмәкче — Исемсез түбәне разведка ясап тормыйча гына алырга уйлаган иде. Аның нәрсәсен тикшереп торасың инде, әнә, ул болай да уч төбендә кебек ич.
Иртәнге сәгать сигездә штурм төркеме хәзергә әле картада гына күрсәтелгән маршрутка чыгып киткән. Аня белән Шитов килеп җиткәндә, егетләр Исемсез түбәдән әйләнеп кайтмаганнар иде әле.
Үзенең кызыл палаткасы янында командор Зырянов Аняга бүген Нуриманнарны алмага чыгып булмаячагын аңлатты.
— Әнә, ничек котыра бит! — Зырянов күзләрен күккә текәде. Күк йөзе төтенсыман соры пәрдә белән капланган, яңгыр коя, көчле җил өермәләп-өермәләп бөтерелә иде.
— Кайталар,— дип, Шитовның кычкырганы ишетелде. Ул дулап торган караңгылык эченнән килеп чыккан дүрт кешене беренче булып күреп алган иде. Бивактагылар, бөтенесе дә бер сафка тезелеп, җиңүчеләрне тәбрикләргә әзерләнделәр.
— Зәйтүнә Даутова пигы алынды! Чал тауларны җиңүчеләргә ура!
Башкалар белән бергә Аня да җиңүчеләрне котлады. Командада бердәнбер хатын-кыз буларак, ул аларны традицион кайнар компот белән сыйлады. Тик аның күңеле Ак Бүредә, аның түбәсе белән әлеге ярык арасындагы кар баскан биеклектә иде — ул Нуриман белән Сережа турында уйлый. Монда, тауларда, бер-береңне аз гына яратып бетермәүнең дә тау менгәндә фаҗигагә әйләнүе мөмкин икәнлеген Аня белә иде. Ә бит алар бер-берсен «яратып бетерми» генә түгел... Зыряновка Сережа экспедициягә барырга теләк белдергән кичтә Нуриман әйткән коточкыч сүзләр исенә килеп төште. Ник кенә җибәрде икән ул аларны кичә? Ник йөрәк сизенүенә колак салмады? Хәзер менә көннең бозылып китүе тагын. Әнә, кар ничек бөтерелә-бөтерелә ишелеп ява, берни күрерлек түгел. Аня, күзләрен Ак Бүре ягына теләп, үзен шул сораулар белән җәфалый, аның башында да хәзер кар яугандагы кебек үк, ап-ак буталыш иде...
...Юк. Юк, Нуриман андый кеше түгел... Аның чебенгә дә чирткәне юк. Әшәкелек эшли ала торган кеше түгел ул. Үзе үлсә дә, кешене коткарырга тырышачак. Сережа турында да: «Әзерләнмәгән кешене алырга ярамый, алай тиеш түгел, казалы булуың бар»,— дип кисәтте генә бит ул. Көнли, нибары шул, дип уйлаган иде Аня... Чынлап та, яратамы әллә ул Сережаны? Нечкә күңелле, илһамына чумган, канатланып йөрүче Сережа Нуриманга капма-каршы һәм Аня күңелендә вәсвәсә булсын өчен генә яратылган кебек иде. Аның сабыйныкы кебек рыясыз җаны беркемгә дә яхшыдан башканы тели торган түгел. Аняның аңа котылгысыз тетрәүләр һәм үкенечләр җиле тидерәсе килми иде, киресенчә, алардан саклыйсы килә. Чынында моны, Сережаның җаны турында гына түгел, ә тәне турында да кайгыртып, Нуриман эшләргә тырышкан булып чыга. Көчле җил Аняның йөзенә китереп бәрде, башыннан капюшонны суырып төшерде, тынына капланды. Җил аны Памирга, «Варзоб» лагерена алып киткәндәй, кыя террасасына алып менеп, упкынга бөтереп ыргыткандай тоелды...
Юк, Матушкинның пәйда булуы белән Аня мәхәббәтенә хыянәт итмәде. Ул әүвәлгечә Нуриманына тугры иде. Әмма шулай булу да ихтимал: йөрәгендә берьюлы ике кеше йөрергә мөмкин икән.

Тауменәрләр ышыкта компот эчкәннән соң Зырянов, барысын да чатырына җыеп, хәлне аңлатып бирде. Иптәшләрне тыңлагач, үзенең карарын игълан итте:

— Бүген Исемсез түбәгә менгән дүрт кешелек төркем иртәгә иртән алты сәгатьтә бәләдә калганнарны алмага чыга...

## 18

Көн тагын да бозылып киткәнлектән, коткару отряды икенче көнне юлга чыга алмады. Гарәсат басыла төшкәч, бары тик бишенче иртәдә генә кузгалып китә алды ул. Алар хәзер алтау иде инде — хәле бераз җиңеләйгән Шитов белән Аня да кушылды. Шушы биш көн, биш төн эчендә Аня үзен кая куярга белми йөрде. Ул хәзер Нуриман белән Матушкин арасы турында да, аларга карата үз тойгы-хисләре турында да уйламый, ул аларны зарыгып көтә генә иде. Икесен дә.

Ә Док үз кешеләре белән бергшрунд янында бивак корган иде. Егетләр теге көнне бергшрундны карап-тикшереп чыкканда, һава тәмам бозылган иде инде. Бишенче көнне, ялтырап чыккан кояш нурларында ярыкны кичү мөмкин түгеллегенә тәгаен ышангач, алар төп лагерьга юнәлделәр.

Бишенче көнгә Ак Бүре башында да кар ямый башлады. Нуриман белән Матушкин ояларыннан тышка чыктылар. Күкҗал артыннан кояш күтәрелеп килә, җил әле үрсәләнсә дә, күк йөзе аязып, чистарып калган иде. Нуриман тирә-юньгә күз салгач:

— Җыенырга вакыт,— диде.

Суыкта каткан әйберләрен ничек кирәк алай рюкзакларына тутыргач, алар палатканы казый башладылар. Матушкинның күз аллары караңгылана, әледән-әле ул егылып китә иде. Менә ничәнче тәүлек, көнен-төнен белми, ул кулы белән кар көри...

Палатка́ны бөкләп җыярлык түгел иде. Чыланып каткан брезент бөгелгән җиреннән сынарга гына тора. Ләкин Нуриман бирешергә уйламады. Мышный-мышный ул ничек тә булса аңа булышырга маташкан иптәшенә күз төшереп ала. Тегесе һаман башы белән карга барып төртелә. Калайланган күзләреннән аның көч-хәл белән генә аңын югалтмый торганлыгы күренә иде.

Кояш Күкҗалдан тәмам күтәрелгәч кенә, алар Исемсез түбә янынпан Ак Бүрегә таба киттеләр. Көчкә-көчкә бөкләнгән палатканы рюкзагы өстенә куеп, Нуриман бик җайсыз күтәренгән иде. Палатканы җил өстери, һәм Нуриман, җилкәнле көймәдәй, бер яктан икенче якка авыша, ыңгыраша, шыгырдый иде. Өстәвенә әле яңа яуган калын карга бата-бата эз салып барырга да кирәк. Ул кар сарган төкләренә пошкыра-пошкыра, туктала-туктала алга бара, башын күтәреп күккә, офыкка карый, бүре кебек һаваны исни. Ул көннән курка: әгәр тагын да бозылып китсә,— ә монда Тянь-Шаньда бу бик мөмкин хәл,— алар бу тозактан котыла алмаячаклар. Нуриман бер генә тапкыр утырып ашарлык ризыклары, һәм дүрт кенә шырпылары калганлыгын, бензиннары тамчысына чаклы бетеп, шуңа күрә примусны атып ыргытканын да белә: белгәнгә күрә сүзне икенчегә борырга тырыша иде. Ак Бүредә үткәргән тәүлекләрдә Нуриманның, ризыкны бик сак тотарга кирәк, дип тукуы сүздә генә булмыйча, чынында авызына юньләп тәгам ризык капмаганлыгын, шуның белән азык-төлекле вакытны икеләтә сузганын да Матушкин белми иде. Нуриман аппетит юк, болай да май күп җыелды дигән булды, алдады-юлдады, һәм күпмедер ышандыра белде.

«Паркинсон, Паркинсон... Нәрсә соң мин һаман аның белән саташам әле? — Нуриман кар яра, боз чүкеченә бөтен гәүдәсе белән салынып, авыраеп хәл ала, һәм көчкә-көчкә генә башын эшләтә.— Паркинсон... Ә, әйе, Паркинсон законы бит әле: әгәр дә бәла киләсе икән — ул килмичә

калмый, шулай бугай». Ул Матушкинга, тирә-юньгә карап ала, тагын кузгала.

Һәм менә — бәла дигәне күренде: астан, басма ягыннан, кара-кучкыл болытлар агылып менә башлады. Нуриман саклык бавын кыскартырга дип туктады. «Бәлкем, болай гына үтеп китәрләр? Кысыр болытлардыр, бәлки?» Өстерәлеп Матушкин килеп җитте һәм җил улавына аның саташулы сүзләре дә килеп кушылды:

— Мин сине яратам, Аня. Күптән әйтергә йөрдем, йөрәгем генә җитмәде. Сүз кирәкмәгәнен үзең дә беләсең инде. Бу газап күпмегә барыр? Нуриманмы? Нуриман нәрсә? Әйтик аңа да...

Нуриман юлдашының саташулы-йокылы күзләренә карады, чуалган чормавык бауларын төзәткәләде һәм, бил тиңентен кар ярып, түбәнгә төшүен дәвам итте. Ашыгырга кирәк иде. Биеклекне бик тиз киметкәндә генә авыруны һушына китерергә мөмкин. Кар ишә башлап, күзне генә томаламасын иде. Матушкин, нәрсә сөйләгәнен үзе белмичә, берничә адым арттарак бара. Нуриманга өзек-өзек сүзләр ишетелеп куя:

— Синең өчен мин... Аня... Китә бирсен, мин үзем әйтәм аңа... Әгәр дә... Булсын, мин яратам икән... Монда да бит синең өчен... Ә, күпме алар! Бөтенесе дә ак... Бүреләр... М-мә!..

Бау каты итеп тартылды. Үзен һәм сөрлеккән иптәшен тау яңагыннан шудырмый калу өчен, чүкечен карга батырып, аның өстенә ятарга әзер булса да, Нуриман аягүрә калды. Юк, Матушкин сөрлекмәгән, абынмаган һәм аны җил дә бәреп екмаган иде: ул ниндидер күзгә күренмәс бер дошманның бугазына ябышкан да, имеш, аның белән кар өстендә әүмәкләшә иде. Нуриман, рюкзагын салмыйча гына, карда аунаган Матушкин янына килде, аны аягына бастырып, каты гына җилтерәтте.

— Сергей, аңыңа кил, Сергей!

Алар тагын әкрен генә киттеләр. Нуриман мыгырданып баручы иптәшен я култыклап ала, я тагын сукмак ярырга тотына, һәм андый чакларда Матушкин аннан бераз арттарак калып өстерәлә, я дүрт аякта мүкәйләп шуыша башлый иде.

Кояш тагын бар дөньяны баскан кара-кучкыл болытлар артында калды. Ләкин әле кар төшми һәм, чигенү юлына билгеләр куеп, алга барырга мөмкин иде. Алар өч-дүрт метр саен тын алырга туктый башладылар. Ә бер егерме метрлап алда җиңелчә тау ташкыны гөрселдәп ишелеп төшкәч, Нуриман хәзер шул хәвефле җирдә басып тормаулары өчен сөенеп, үзләрен тоткарлаган кар көртләренә эчтән рәхмәт тә укып куйды.

Кар ява башлаячагын Нуриман алтынчымы, унынчымыдыр — үзе генә белгән бер тойгысы ярдәмендә сизенде. Бермәлгә җил тынган арада болытлар куерып киттеләр, тирә-якны караңгылык сарды, һәм ишелеп кар ява башлады. Әмма алар вакыт ягыннан откан иде, азмы-күпме алар түбәнрәк төшә алдылар. Һәм бу Матушкинга да әйбәт тәэсир итте. Ул һушына килде. Моны Нуриман Матушкинның бик озак мәгънәсез сөйләнүләреннән соң, кыска гына итеп: «Мин аякны өшеттем, ахры»,— дигән сүзләреннән аңлап алды.

Беренче кар бөртекләре артыннан ук күтәрелгән көчле өермә астында палатка кора башладылар. Бу катлаулы эш булып чыкты — палатка боз булып каткан иде һәм Нуриманга өтеп ала торган ачы җилдә бияләйләрен салып, ялан кул эшләргә туры килде. Моның нәрсә икәнен ул белә иде, әмма бүтәнчә чара күренми...

Нуриман кулын өшетте. Примус та булмаган салкын, караңгы палаткада тунны кайтару мөмкин түгел иде. Куллары, көрәнсу тап төшеп агарып каткан, ә бармак очлары каралып та чыккан иде. Матушкин, аларга тире ката кидереп, бәйләп куйды, лагерьга барып җиткәнче аларга кагылмаска булдылар. Каты гына итеп бау белән тукмагач, Матушкинның аягы бик сызлап җылына башлады, ул үрсәләнеп улады-улады да, капчыкта Нуриманны кочаклап яткач, тынычланып йокыга китте.

## 19

Кичкә кадәр йоклаганнар икән. Һаман җил улый, тик бу юлы палатканы көрт басып китмәгән иде. Ике шырпысы сүнеп, өченчесеннән Матушкин шәм кабыза алды. Нуриман үзенең начпрод капчыгыннан соңгы ике кисәк сохарины, бер карамель конфетын һәм бодай боткасы брикетын алырга кушты.

— Менә бар булганы шул,— диде Нуриман, Матушкинның сулган йөзенә карап. Ул йөз хәзер тагын да очлаеп калган, аксыл шома түгел, ә каралып тигәнәксыман төкләр белән капланган, яңакларыннан тире элпәләре кубып, асылынып тора, бөтен битендә, иреннәрендә, буеннан-буена тиресе яргаланган борыны өстендә кан бөртекләре укмашып-укмашып каткан. Күзләре генә нурлы һәм тере иде. Юк, Матушкин, әлбәттә, үзенең шашуын оныткан, саташып сөйләшүләрен дә, бүреләр беләнме — ни беләндер әүмәкләшүләрен хәтерләми. Хәтерләми дә, хәтта белми дә.— Сережа, синең нык ашыйсың киләме?

— Әйе, Нуриман, бик нык. Көндез үлеп йокы килде, аяк өсте йокладым шикелле, ә хәзер менә ашыйсы килә.

— Алайса мискәгә кар тутырып ал. Саграк бул, кулыңа ки... Менә шулай. Кар алдыңмы? Хәзер шуны ялкын өстендә тот.

— Ботка пешерәбезме?

— Нәкъ өстенә бастың. Савытыңны өстәрәк тот, юкса, утның файдасы булмый.

Матушкин кулы белән мискәне тотып, буш кулына брикет алды.

— Ничек пешерергә,— дип брикет кәгазен укый башлады,— изәргә, су салырга, әйбәтләп болгатырга, кайнатып чыгарырга һәм егерме биш минут буе пешерергә. Моңа ничә шәм кирәк булып чыга соң әле?

— Тот, тот,— диде Нуриман.

— Саклау срогы ун ай,— дип соңгы язуны укыды да Матушкин мискә эченә бакты. Кар бик тиз эри башлаган иде.

— Менә булды да.

— Ярты пачкасын су белән аша, Сережа, калганын кире тыгып куй.

— Ә син?

— Ашыйсы килми, бераз су гына эчәрмен.

Матушкин сулы мискәне Нуриманга сузган иде дә, аннары исенә килеп, аны үз кулыннан эчерде.

— Капкалап алыр идең.

— Чын, ашыйсы килми.

Матушкин, брикетны ачып, аны бер почмагыннан комсызланып кимерә башлады.

— Суга манып ал,— дип киңәш итте Нуриман,— әйбәтрәк барыр.— Ул төрүле кулларын берсе өстенә берсен куеп, чайкалыбрак утыра иде.

Утны сүндереп, Матушкин ашауны караңгыда түгәрәкләгәч, йокларга яттылар. Шәмне саклау кирәк иде әле.

## 20

Иртән тау төшүне дәвам иттеләр. Кар да яумый, җил дә туктаган иде. Күпкәме икән? Күкҗал белән Исемсез түбәгә сырышкан болытлар тын калганнар.

Җыенуын озак җыендылар. Сүзне начар өйрәнгән актерлар янындагы суфлер кебек, Нуриманга авызын ябып торырга да вакыт булмады. Ул бичара кулларын күкрәгенә кушырып, нәрсә эшлисен әйтеп кенә торды. Матушкин баш күтәрми аларны үти барды. Соңгы шырпыны кабызып, су җылытты, соңгы сохари кисәген, калган ботка катысын чыгарды. Бу юлы Нуриман ярты сохари ашады.

Тамак ялгап алгач, Матушкин әйберләрен җыештырды, палатканы җыярга тотынды. Аның баулары, җөйләре, элмәкләре кулны тыңламыйлар, Матушкин аларга абына, чуала, ачуы чыга. Нуриман аны тынычландыра, өйрәтәсен сабыр гына өйрәтә. Матушкин тагын эшкә тотына.

Алар тигез җирдән, карлы киң платодан — Ак Бүре аркасыннан баралар. Текә җир алдарак иде әле. Аның рельефын, текәлеген Нуриман бик аз чамалый һәм бу аны борчый, хәтта куркыта да. Ул үзенең хәлсез куллары хакында уйламас та иде, ә кәттәрәк берәр стенага юлыга калсаң, ничек итеп төшмәк кирәк? Анда Матушкинга киңәш биреп, әйтеп торулар белән эш майтарып булмаячак, бу инде сиңа палатка җыеп тору гына түгел. Ул, һава бозылып, кайдадыр, басмада ук тертелеп туктап калган коткару отряды хакында да уйламаска тырышты.

Хәле бик авырайса да, Нуриман кар кабыгын бозваткычтай сыта-сыта тирән эз салып баруында булды. Аның сыртында палатка күпереп тора да, сәлперәеп калган рюкзак селкенеп бара,— ул килбәтсез кулларын билендәге бауга аскан.

Төш турысына үз вакытын онытмый гына җил күтәрелде, болытлар бәйләреннән ычкынып Ак Бүрегә ябырылдылар, кар китереп иштеләр. Нуриман белән Матушкин ярты сәгатьләп кар таптап, палатка куяр урын әзерләделәр. Менә бит нинди кыен хәл: әйтеп тормасаң, Матушкин палатка терәвен дә озынайта белми, ә Нуриман Матушкиннан башка кечкенә хаҗәтен дә үти алмый иде.

Соңгы сохари белән конфетны ашадылар. Ботинкаларын салмыйча гына капчыкка кереп яттылар.

— Нишләп ак бүрең киреләнә соң әле синең? — дип сорады Матушкин, экияткә чынлап торып ышангандай.

— Курыкма,— диде Нуриман.

— Минем курыкканым да юк, миңа барыбер.

Кичкә кадәр сөйләшмәделәр. Сөйләшер сүз юк иде. Аннары... сөйләшергә хәлләре дә беткән иде. Ярым төш-ярым өн халәтенә чумдылар. Нуриман артына чумган Матушкинның сулышы туктагандай була. Нуриманга шом төшә. Ул арада Матушкин тагын тын ала. Шулай озак кына яттылар. Бөтенләй караңгы төшкәч кенә Матушкин кымшанып куйды:

— Куллар ничек, нык авыртамы?

— Түзәрлек,— дип җавап бирде Нуриман.— Минем «молния»не ычкындыр әле.

— Мунча ташы кебек булгансың син! Каян болай бу? — дип гаҗәпкә калды Матушкин.— Мин катып үләм, ә син...— Матушкин, куркып, ярты сүздә туктап калды. Шушындый салкында, әчендә бер тамчы ягулык булмый торып, температура болай күтәрелү нормаль хәлмени?!

— Йокла,— диде Нуриман,— мин һәрвакыт шундый, кайнар инде.

Авызларын йомдылар. Иртәнгә чаклы сөйләшмәделәр дә, кыймылдамадылар да. Тышта буран дулады, калын пыяланы шакыгандай палатка яңакларына килеп бәрелде. Ерактан ишетелгәндәй тоелганга күрә, бу авазлар күңелне әллә ни борчымады.

## 21

Беренче булып Нуриман хәрәкәткә килде.

— Яктырган инде, Сережа, тыныч торганда кузгалыйк.

— Кирәкме икән? — Матушкин аңлашылыр-аңлашылмас кына җавап кайтарды.

— Монысы ни сүз тагын! — дип ачуланды Нуриман.— Ач капчыкны.

— Барыбер басмага төшеп җитә алмыйбыз, ә төш вакытында тагын буран башланачак...

— Кайдадыр шушы тирәдә грузиннар калдырган төенчек булырга тиеш — бензин да, продуктлар да...

— Менгәндәге кебекме?

— Анда рәтләп эзләмәдек тә бит без.

— Хәзер,— диде Матушкин,— бер генә минут көт инде.

— Бер минут та көтү юк.

— Миннән булмый бит. Хәл юк. Мин шыкраеп катканмын.

— Сережа, җаным, әйдә, җыен. Безне көтәләр...— Нуриман, кыегайган палатка тәрәвенә карап, артында яткан Матушкинга әкрен, утыргач тавыш белән, гомерендә беркемгә, беркайчан сөйләмәгән сүзләрне сөйли: — Безне тере килеш көтәләр. Без бит синең белән җиңүчеләр, Сережа! Бу хакта синнән бүтән кем язсын?!

Матушкин борынын тарта-тарта «молния»не ычкындырды һәм тышка чыкты. Нуриман да кузгалмакчы иткән иде, ләкин кинәт, кымшана да алмаганын сизеп, куркына калды. Аның бөтен тәне калтырый, шәрә электр чыбыгы тоткандай беләкләре тартыша, чигәләрендә кан тибә, шуның басымы чорнаулы кулларында сулкылдап яңгырый.

— Сережа, булыш әле, бөтен тәнне нидер куыра.

— Әйтәм бит, синдә җар, авырыйсың, ә үзең «ярый, ярый»... дисең,— дип үртәшә-үртәшә Матушкин иптәшенә булышты.— Я, ничек, кузгалмак кирәк? Ятарга иде көчне әрәм итмичә. Ничек тә безне тапмый калмаслар иде әле.— Ул капчыктан арынып чыккан командирының өстен рәтләштерде.— Тагын ыштаның ертылган. Кайткач, ямауның чибәррәген сал, ялтырап торырлыгын.

— Ярый, Сережа, аңа синең исемеңне дә чигеп куярмын.

Матушкин юлдашының свитерын бриджи эченә тыкты, каешын кысып тартты һәм кигергән курткасын кулыннан ычкындырмастан:

— Тышка чыгасың килмиме? — дип сорады.

— Рәхмәт, чыгар нәрсәм калмаган.

— Алайса киттек.— Матушкин аның курткасын ныклап каптырды, башлыгын рәтләп кигерде. Палатка капкачын чишеп, мүкәләп карлы тышка чыкты. Аның артыннан Нуриманның башы күренде. Палатка җиңсәсеннән ул көчкә-көчкә үтте. Матушкин күпме генә булышмасын, сызлаган кулы нәрсәгәдер эләгеп, авыртудан аңын җуя язды.

Нуриман, гыйбадәт кылгандагыдай кулларын кушырып, карга тезләнгән, күзләре киң булып ачылган. Күзләрне чагылдырган ап-ак карны да, зәп-зәңгәр күк йөзен дә, болытлардан котылган кояшны да, Ак Бүрене дә, Күкҗалны да, хәзер инде мәрхүмә дуслары Зәйтүнә Даутова исемен йөртә торган атсыз түбәне дә күрми иде Нуриман. Ул хәзер бөтенесен ишетеп, аңлап торса да, коточкыч авыртудан аңы томаланып, сүз катар, хәрәкәт итәр хәлдә түгел иде.

— Нуриман, Нуриман,— дип җилкәсеннән тотып җилтерәтте аны Матушкин.— Бас әле аягыңа. Ни булды сиңа? Торып бас. Мин сине күтәрә алмыйм бит. Ничек алып кайтыйм мин сине моннан, Нуриман? — Матушкин аның яргаланган кытыршы битен сыйпап елап җибәрде.

— Булышчы, Сережа.

— Менә шулай,— дип сөенде Матушкин,— миңа таян.

Нуриман тезләнеп тураеп басты. Тыны беткән Матушкин чүгәләп утырды.

Битләре сыдырылып канаган Нуриман, күкрәген киереп, тирә-юньгә бакты. Ул бу яман өчпочмактан — Күкҗалдан да, Исемсез түбәдән дә, Ак Бүредән дә өстәрәк һәм биектәрәк иде, ул кулын Күкҗалга таба сузды. Күкҗалны кулына кигән тире ката каплады. Иләмсез тау шул тире катадан кайтышрак иде. Нәрсә соң ул тау дигәнең! Кулы белән Нуриман кояшны да каплый ала. Ул кулын күзенә якын китермәкче булган иде дә, кинәт сулкылдап авырту аны яңадан сабый бала кебек итеп күкрәккә кысарга мәҗбүр итте. Якты нурлардан күзе чагыла, ул еракка — плато бетә торган якка карый, аннан, мөгаен, Зырянов бивагын күреп була торгандыр.

— Нәрсә күрдең анда? — дип сорады Матушкин. Ул чүгәләп утырган, сулыш алган саен аскы тешләре ялтырый. Каралган битендә алар бигрәк тә агарып күренәләр.— Грузин күчтәнәче мәллә?

— Юк,— дип җавап бирде Нуриман,— мин котылганыбызны күрдем! Матушкин командирга текәлде: алай-болай ычкынмады микән бу, янәсе, бигрәк тантаналы итеп әйтте бит.

— Әллә берәр яңа әкият уйлап чыгардыңмы?

— Юк, әкият түгел.

— Нәрсә соң?

— Бинокльне ал әле. Безне алмага киләләр.

— Кайда-а? — Матушкин торып басты.

— Кара,— Нуриман алга таба ымлады. Ул ялтырап яткан ап-ак платоның теге кырыенда бер-бер артлы пунктир булып тезелгән алты кара тапны аермачык күрә. Алар башта дүртәү иде, аннары тагын икәү пәйда булды,— бер бәй, димәк! Кемнәр булыр бу?

— Кайда? — Матушкин бинокль окулярын көйли иде.— Ә-ә! Күрдем! Алтысын да. Алда Шитов. Аня да шунда! Мә, кара! — Матушкин бинокльне иптәшенең күзенә якын китерде. Ләкин Нуриман берни дә күрә алмады, чөнки, Матушкин кулында калтырап, бинокль я өскә менә, я аска төшә, я борынына килеп бәрелә иде.

— Рәхмәт,— дип башын читкәрәк алды Нуриман,— бераздан болай да танырбыз. Әйдә, әнә теге кантарлар янынарак, кар өстенә чыгып басыйк, алар да безне күрсеннәр.

Матушкин белән Нуриман, бер-берсенә сыенып, соры кыядан читкәрәк киттеләр. Тыннары кысылды, кантарлар янына барып җитә алмадылар.

— Әйдә, шушында гына утырыйк, ник кирәк ул кантарлар безгә? — дип тәкъдим кертте Матушкин.— Кар өстеннән без әйбәтрәк күренәчәкбез.

Нуриман килеште. Матушкин палатканы кар өстенә алып бәрде, иптәшенә килеп утырырга булышты.

— Эсселәтә башлады, куртканы салыйм әле мин,— диде ул.

— Көн әйбәт булачак,— диде Нуриман.

Кантарлар белән кыялар сафы уртасында, иңне иңгә куеп, алар күзләрен авырттыра-авырттыра әкренләп үсә, зурая баручы кара тапларга карап утыра бирделәр.

## 22

Грузиннар төенчеген табар өчен Нуриман белән Матушкинга нибары унбиш адым атлыйсы калган булган икән. Төенчек кантарлар янындагы тау тишегендә иде. Коткаручылар, боларны шунда алып килеп, беренче ярдәмне шунда күрсәттеләр.

Беренче ярдәм күрсәтә башлау бик гади булып чыкмады — күз яшьләре, куанып көлүләр, кочаклашулар, тегесен-монысын сорашулар китте...

— Без дә тораташ кебек яттык,— диде Шитов,— борынны чыгарырга да ирек бирмәде буран, палаткаларны сөйрәде. Безнең һич югы ашарга бар иде, ә сез соң ничек?.. Капчыгың да юк...

— Ә без менә болай,— дип кешнәде Матушкин,— менә болай.

Ул, бер кулы белән Шитовны, икенчесе белән Нуриманны кочаклап, елаган Аняга карап тешен ыржайта. Аняның елаганын аның беренче тапкыр күрүе иде. Ул Аняга карый, аларның күзләре очраша һәм үз кыяфәтенең иләмсезлеге Матушкинның башына да кереп чыкмый иде. Борыны яргаланып, бөтен бите җәрәхәттән генә торуы өстенә, ул әле шешенеп тә чыккан иде.— Менә шулай, Шура, без монда курортта яткан кебек яттык.

— Күренеп тора. Симереп беткәнсез, аеруча син, Сережа. Көзге бир әле үзенә, Аня, карап баксын...

— Кирәкми,— ди Аня, күзләрен сөртә-сөртә,— аска төшкәч, аның эзе дә калмый. Борыны төзәлер, битләре, куллары да.— Аның күзе Нуриман кулындагы тире катага төште. Китәр алдыннан гына базарда сатып алганда, бу кырык өченче размерлы аяк киемен ул һич кенә дә ире кулына кигерергә алам дип уена китермәгән иде.— Бөтенесе төзәлер, бөтенесе дә әйбәт булыр.— Ул үзенең Нуры белән Сережасына термостан салып кайнар чәй эчерә, бите буйлап исә күз яшьләре ага, ул аларны сөртә-сөртә сөйләнә:— Барысы да әйбәт булыр, барысы да...

Кантарлар тирәсен егетләр кардан арындырдылар һәм грузиннар калдырган ике юл капчыгын казып чыгардылар. Аның берсендә — бензин, примус, шырпылар, икенчесендә азык-төлек иде. Бернигә ел кар суыткычта яткан котлетларны җылытып ашадылар. Матушкин белән Нуриманга бирми тордылар. Аларны башта чәй белән сыйлап, бераз ботка ашаттылар. Аня аларның җәрәхәтле йөзләрен мумие белән майлады һәм Ак Бүрене җиңүчеләр чүл гарәбләренә охшап калдылар. Нуриманның кулын кузгатмадылар, тире катада килеш калдырдылар — рациядән хәлне белешкәч, Док шулай кушкан иде.

Авыруларны бивакка алып төшү биш сәгатькә сузылды. Шитов җилкәсенә таянган Нуриман, җае чыккан саен, колакларын торгызып кояшта мәгърур балкыган Ак Бүре башына күз ташлый иде. Бу биеклек яуланган дип кем уйлар?

— Аерыласы килмиме? — дип сорады Шитов.

Нуриман дәшми генә уйчанланып башын селкеде.

Бер егерме метрдан соң плато вертикаль шәрә стена булып аска уба иде. Нуриман белән Матушкин, икесе генә булса, моннан төшә алачак түгелләр икән. Башта җиңелрәк тә, кулы да эшләп торган Матушкинны төшерергә булдылар. Аны, элмәк таганга утыртып, упкын янына китерделәр.

— Сабыр итегез,— дип үтенде шулчак Матушкин. Ул, борылып, әле генә әҗәлем шушында икән дип уйлаган тау түбәсенә карады, аннары күкрәген тутырып сулыш алды да тамагы ертылганчы бар көченә сузып кычкырды:

— Ак Бүре, хуш, җаным!

— Хуш, җаным...— дип аның сүзләрен кабатлады тау.

Сәгать җиденче киткәндә Ак Бүре батырларын төп лагерьда каршы алдылар.

Зур таш өстәл янында мәҗлес башланды. Зырянов уймак тикле чәркәсен алтын тамыр салган эчемлек белән тутырды. Шитовның җирән сакалына учак төтене урала кебек. Док, гадәтенчә, нидер кушш. Ярты сәгать элек ул Нуриманның өшегән бармакларын дарулап бәйләде һәм тегесе хәзер Аня кулыннан ашап утыра. Нуриманның температурасы югары иде әле, ләкин инъекцияләрдән соң ул төшә башлады. Матушкинның башы да бәйле иде. Борыны, битләре, колаклары, ияге чорнаулы Матушкин, ипи кабып, шулпа эчеп җибәрергә авызын көчкә-көчкә генә ача. Чәйнәлеп бетмәгән ризыкны каз кебек муенын суза-суза йотып, ул кояшның Ак Бүре артына кызарып кереп баруын күзәтә. Мену нәтиҗәләрен карап чыккач, Зырянов Ак Бүренең көтмәгәндә Күкҗал белән Даутова түбәсеннән биегрәк булып чыкканлыгын әйтте. Бу турыда ул чакта әле исеме булмаган тау түбәсенә менеп җитмәс борын ук штурм группасы хәбәр иткән иде. Бу, күрәсең, Матушкин бергшрундта чәй калганда булгандыр. Нуриман белән Матушкин исә күз ачкысыз буранда бернәрсә дә күрә алмаганнар иде. Хәер, тау ун метрга биегрәкме, табәнәгрәкме — ни аерма? Исемсез тауны, мәсәлән, Матушкин гомерендә дә кичә алмаган булыр иде. Өч түбәнең иң катлаулысы — шул. Күптән түгел генә исемсез булган, ә хәзер Зәйтүнә Даутова исеме кушылган түбәгә дә күз салды. Аның зифа очы кояш баешында алсу-кызыл төскә кергән — рәсемгә төшереп алып күрсәтсәң, кеше ышанмаслык дәрәҗәдә гүзәл иде.

— Чибәр! — дип буйсынмас авызын кыймылдатты Матушкин. Тик аның сүзен аңламадылар. Матушкин туңып китте. Һавада бозлыкның көндезге парлары йөзеп, ярыкларда сулар чылтыраса да, килер төн үзен сиздерә башлаган иде инде. Аның күрше тау башларыннан аккан салкын дулкыннары көннең соңгы җылыларын юып алып, лагерьны өшеткеч дым белән каплый башлаган иде. Егетләр торып җилкәләренә мамык курткаларын салдылар, сүзләр сөйләнеп беткән булса да, таралышырга уйламадылар. Матушкин да торып курткасын алып чыкмакчы булды.

— Син кая? — дип сорады Нуриман.

— Куртка алырга.

— Утыр, утыр,— диде Аня.— Хәзер алып киләм.

— Мин үзем,— Матушкин, авыру иптәшенә һәм аның хатынына мөмкин кадәр ягымлырак елмаерга тырышып, палаткасына таба китте.

Палаткага кергәч, аның күзенә кемдер калдырып чыккан ап-ак кәгазь битләре чалынды. Алар кызыл-зәңгәр белән каймаланган авиаконвертлар янәшәсендә ята иде. Матушкин, бармакларын язып, авторучка эзли башлады. Анысы да шунда ук — палатка кесәсеннән тырпаеп чыгып тора иде. Ничек итеп аны кулына алмыйча кәгазь битеннән сулдан уңга таба рәхәтләндереп йөздереп җибәрмичә түзмәк кирәк! Ә кемгә язасың? Нәрсә турында? «Әлбәттә, бөтенесе турында да,— дип уйлады ул,— бөтенесенә дә. Әнәсеннән җебенә чаклы. Болытлардан да өскәрәк менүе, үзенең хәзер бөтенләй башка кешегә әйләнүе хакында язарга кирәк».

«Кадерле әнием! — дип язылды кәгазьгә беренче сүзләр.— Менә шул. Без кайтырга чыгабыз. Юкка гына борчылгансың. Экспедиция уңышлы үтте, мин тау чаклы материал җыйдым...»

«Красноперов, сәлам! — дип башлады ул икенче хатын.— Миннән башка нишләп ятасыз анда, җен балалары? Газетаның карарлыгын да калдырмагансыздыр инде. Кайткач күрсәтәм әле мин сезгә — егылып китә күрмәгез! Шунысын гына әйтәм, шәп йөрелде. Табигать монда безнең культура һәм ял паркындагыдан ким түгел. Таулар да бар. Бульварлар гына бик төзек түгел һәм асылма юллар гына юк. Аның урынына эдельвейслар — дөнья! Гүзәллекләренә исең китәр... Алып кайткач, күрерсең». Матушкин редакторга, Хафизовка, Бельскийга хәлләренең «О, кей!» икәнлеген һәм «дәвамы бар» дигән очерклары өчен урын әзерләп торуны әйтеп, берничә сүз сызгалады.

Аня килеп керде:

— Хат язасыңмы?

— Яздым инде.

— Ә без сине югалттык. Тот.— Аня аңа кабыктан яңа чыккан тавык чебие кебек йомшак, ачык эдельвейс букетын сузды.

— Каян алдың моны? — дип гаҗәпләнде Матушкин.

— Аста чакта ук җыйган идем. Эшкәртеп тә алдым[1]. Соңгы көнгә ышанып торып булмый. Ал, ал, ансыз ничек кайтасың ди син?

— Җыярмын әле.

— Өлгермисең, Сережа, иртәгә иртән вертолет килә һәм Нуриман белән сез китәсез. Кая, истәлеккә бер үбим әле үзеңне.— Ул аның кытыршы иренен үбеп алды.

— Нуриман янына киттем.

— Бар,— диде Матушкин,— аңа син кирәклерәк.

Аня китте.

Матушкин палатка капкачын күтәреп куеп, капчыкка керде, бәйләнгән башын тышка, саф һавага чыгарып ятты. Салкынча һава башны әйләндереп исертә, оета иде. Күзен йомуга йоклап та китте. Тирмәдән башларын ялтыратып бер-бер артлы далага сибелгән Мәмәтбәк оланнарыдай, аяз күктә һаман калкып торган йолдызлар, бик тә кызыксынып, аның йөзенә баккан иделәр.

[1] Эдельвейсны кайнар комда киптерәләр, аннары ул үз төсен югалтмыйча озак саклана.

## Альберт Мифтахетдинов

# КЫЗ УРЛАУЧЫ

хикәя



Аттаукай кызлар кебек оялчан. Аның белән мәхәббәт, гаилә, балалар, я булмаса тундра, поселок хатын-кызлары турында сүз башладыңмы — кызара да чыга. Җигеп йөри торган этләре, берәр ауга чыгуы яки узган ел авырып ятуы — аягын тайдыруы хакында сөйләргә тотына. Яратмый ул хатын-кыз хакында сүз куертуны, үзеннән көләләрдер, мыскыл итәләрдер кебек тоела башлый аңа.

Утыз биш яшь инде Аттаукайга, әмма һаман буйдак. Чукотлар моны юньлегә санамый. Тундрада: «Хатынсыз ир-ат — кызганыч кеше», дигән әйтем дә бар.

Әйбәт каюр ул Аттаукай. Этләре дә менә дигән. Бармаган җире юк — тундрадагы бригадаларда да була, болан асраучылар янында да, яр буе авылларында — диңгез җәнлекләре аулаучылар янында да. Димәк, хатын табу аңа кыен эш булмаска тиеш иде кебек, әмма...

Бу очракка тундрада бөтенләй башка әйтем дә бар: «Хатын кыз — сукыр чебен».

— Кирәкләре бар иде,— дип кул гына селти Аттаукай.— Тел бистәләре! Берсенә дә ышанырга ярамый! Хатын-кыз булган җирдә бер генә көн дә яши алмыйм мин.

— Сынап караганың булдымы соң?

— Булды.

— Син гел япа-ялгыз,— дип дәвам иттерә кунакка килгән атасы Эттувгы.— Күп йөрисең, өйгә сирәк кайтасың. Андый тормышка нинди хатын риза булыр икән?

Авыр сулап куя Аттаукай, тик никахка фамилиясе аяк чалуын атасына белгертми. «Аттау» — чукотча «хуш» дигән мәгънәне бирә, ә «кай» кушымчасы иркәләү, кечерәйтүне аңлата. Димәк, бу фамилияне «хушкай», «әлегәкәй», «саубулкай» дип тәрҗемә итеп була. Әгәр фамилияң шундый мәзәк икән, кайсы хатын-кыз сәерсенеп карамасын инде сиңа?

Биш ел элек өйләнгән иде ул. Эвенк кызына. Язылыштылар, тик кәләше Аттаукай фамилиясен алырга теләмәде. «Без, эвенк хатын-кызлары, фамилия алмаштырмыйбыз,— диде.— Маржалар алсын әнә, аларга килешә, ә минем үз фамилиям дә бик әйбәт».

---

АЛЬБЕРТ МИФТАХЕТДИНОВ *(1937) — прозаик. Магадан өлкәсе комсомол премиясе лауреаты, СССР ФА География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, рус телендә басылган берничә китап авторы. Әсәрләре СССР һәм чит ил халыклары теленә дә тәрҗемә ителгән. Магаданда яши.*

Аттаукай моны яратмау билгесе, начар фал рәвешендә кабул итте. Шулай булды да. Бервакыт тундрадан йөреп кайтса, өендә кем дә юк: чәй кайнатып каршылаучы да, «Юлларың уңдымы, эшләрең пештеме?» — дип сорашучы да.

Хатынының китүен, хәтта озакка китүен сизенде ул. Кая китүен әйтеп язу калдырмасына гына кәефе кырылды. Көтә башлады. Әмма тундрадан әйләнеп кайткан саен аны салкын өе генә көтеп торды. Хатыны бер ел кайтмый икән, димәк, бу инде шаярту-мазар гына түгел. Чынлап ташлаган икән инде, аның кая китүе кемгә хаҗәт? Шунлыктан ул аны көтми башлады. Ирләр эше түгел бу. Тормышының ямьсез көннәрен онытып, яңа дәверен башларга кирәк, ә аны үткән исәлеккә нигезләү ярамас — төзелеш материалы ул түгел. Тундрада: «Су сибеп учак тергезелми»,— диләр ләбаса.

Әйтем һәм мәкальләрне Аттаукай гадәттә булып узган хәлләрне аклау һәм үз-үзен тынычландыру кирәк чакта исенә төшерә. Болай җиңелрәк булып китә: тундрада юкка әйтмәсләр!

Карт Эттувгы дәшми, Аттаукайның каршы төшүен көтә. Бәлкем шул чак якын киләчәктә оныкларны көтәргәме, юкмы икәнлеген аңлап алыр? Әмма Аттаукай да дәшми, үз эченә бикләнгән. Бу тема аның күңеленә ятмый, туйдырып бетерде инде, менә шул.

Сөйләшми генә чәй эчеп, тәмәке тарткач, Эттувгы юлга җыена башлады һәм өйләдән соң китеп барды. Төнгә чаклы кайтып җитәчәк.

Аттаукай килеп кергәндә колхоз председателе кабинетында ят кеше юк иде, хуҗа тәрәзә янына барып баскан да кем беләндер телефоннан сөйләшә. Аттаукайны күргәч, кер дигәнне аңлатып, кул изәде. Аттаукай кереп утырды да хуҗаның бушаганын көтә башлады.

— Уф! — диде, ниһаять, ачулы председатель.— Район үзәгенә барасың киләме?

— Килә...— Аттаукайның йөзе ачылып китте.

— Менә сиңа язу, складтан запас мех киемнәр ал. Поселокта ронога кереп, бер укытучыны утыртып алып кайт. Безгә яңа укытучы җибәргәннәр.

Аттаукай дәшмәде.

— Я, ярый, сәфәрең ике көнлек, ял ит шунда. Үзең беләсең, анда — кафедыр, ресторандыр... Тик дусларча үтенәм, артыгын кылана күрмә. Ишеттеңме, телефоннан ни дигәннәрен? Кляүл кичә анда туган көнен үткәргән, ә бүген милициядә утыра. Менә сиңа соңгы хәбәр.

Аттаукай башын селкеде, борчылма, янәсе, аңлыйм, бала-чага түгел.

— Ярый, алайса, бир кулыңны, хәерле юл!

Район үзәгенә барырга ярата ул. Кино, кибетләр, ресторанда музыка, төрле колхоздан килгән дуслар. Кунакханәдә дә әйбәт — мөлаем йөзле түти, чәй, чиста урын-җир. Тундрада боларны күрә алмыйсың бит.

Тиз җыенды ул, таң атканын көтеп тормады. Язгы төн салкын, кар өсте каты, йолдызлар иңгә кунгандай — йодрык кадәрлеләр. Ашыкмыйча гына өйләгә барып җитү өчен нәкъ юлга чыгар вакыт. Ә инде аз гына читкәрәк борылсаң, Кымынә әбигә дә кереп чыгарга була. Алар инде язгы яраңгаларын корганнардыр, бригадалары боланнар бозаулату өчен көтүлек сайлаганнардыр. Аттаукайның Кымынә әбисен күптәннән күргәне юк, яңалыклар җыелгандыр. Иртәнге ашка аларга барып җитеп була. Ә бүләккә ул бер нерпа алып барыр. Мөгаен, болан асраучыларның күптәннән нерпа ите ашаганнары юктыр, сагынганнардыр. Кызганыч, әлбәттә, морж ите юк.

— Кая ашыгасың болай? Артыңнан куалармы әллә? — дип кычкырды аңа председатель үз өе баскычыннан.— Иртән китәр идең әле.

— Кирәк!

Председатель, телефоннан Кляүл турында сөйләшкәнен исенә төшереп:

— Аңлашыла...— дип башын чайкады.— Тик кара аны!

Аттаукай көлеп җибәрде.
— Аттау!
— Этләр алга ыргылды, тыеп кына өлгер үзләрен.

Төнге салкын тынлыкта сопкадагы бәс кунган ярангалар очлы башлы кар өемнәрен хәтерләтә. Тирә-якта җан әсәре юк. Учаклардан күтәрелгән талгын нәзек төтеннәр генә хатын-кызларның инде йокыдан торуын, чәй әзерләвен белгертә. Әнә теге кырый ярангада Аттаукайга туган тиешле Кымынә, тынгысыз, мыгырдык, әмма олы җанлы Кымынә әбисе яши.
Ул аны шатланып каршы ала, мәш килә — озак көттергән кадерле кунак бит.
Көтүчеләр чәй эчә, Аттаукай яңа хәбәрләрен сиптерә. Кляул, председатель турында да, яңа укытучы хакында да сөйли. Кайтканда укытучыны күрсәтергә вәгъдә бирә.
Төнлек зур итеп ачылган, кояш нурлары хәтта яранга уртасындагы учакка ук җитә. Яранга эчендә кояш күп, каршыда — кояш стена, нурлар мул, аларны кул белән тотып алып булыр төсле.
— Яз,— дип елмая Аттаукай һәм тагын бер кружка чәй ясый. Чи нерпа итен барысы да яратып ашады. Карчык болан ите пешергән арада ирләр чәйгә ябырылды.
— Син бөтенләй үзгәрмәгәнсең, элеккеге кебек ук житез,— дип шаярта Аттаукай һәм Кымынәне, биленнән түбәнрәк кагылып, сөеп куя.
— Сез язын барыгыз да тинтәк, көзге боланнар кебек!
Көтүчеләр көлә.
— Аның каравы, син яшь чагыңда язмы, көзме икәнен карап тормагансыңдыр! — дип үрти аны Аттаукай.
Әбисе елмая:
— Яшь кан салкында да кайный ул! — ди һәм чытлыкланыбрак иңнәрен сикертә.
Көтүчеләр тагын көлешә. «Әйбәт әйтем,— дип уйлый Аттаукай.— истә калдырырга кирәк. Әмма үз канының салкында «кайныймы» икәнен белмәгәч, яшь микән ул, картмы? Тикшерергә иде дә, тик ничек?» Бу уйларыннан ул ояла һәм кызара.
Бу уйларыннан кәефе китә, бөтен кыяфәте ниндидер тонык төскә маныла, боегып кала. Күңелендә — көзге яңгырлы тундрадагы кебек батбаклык. Тизрәк ялгызы каласы, моннан китәсе килә. Ашыгып кына тагын бер кружка чәй эчеп, этләрен әзерли. Кымынә әбисе аңа төргәк суза. Анда прәрәм — болан сөяге мае белән вак кына итеп туралган ит, бик тәмле ашамлык.
— Ал! — дип ягымлы карый ул Аттаукайга.— Юлда ризык авыр булмый.
Аттаукай рәхмәт әйтә, төенчекне рюкзагына сала, елмая. Этләр дәррәү кузгала, Аттаукай нартага ава, борылып, әбисенә кул изи, нидер кычкыра. Әбисе Аттаукайның ни дип кычкырганын ишетми. Хәер, озакламый тагын кунакка киләсе булгач, ишетмәсә дә ярый.

Шимбә белән якшәмбене ул поселокта ял итеп үткәрде, ә дүшәмбе көн иртүк ронода иде инде.
— Без сезне көттек,— диде мөдир.— Юлга чыгуыгызны җомгада ук шалтыратканнар иде инде. Я, ничек, барысы да тәртипме?
— Тәртип булмыйча! Укытучы кайда соң?
— Кунакханәдә... Мех киемнәрегез әйбәтме?
— Өр-яңа... складтан гына. Тулы комплект.
— Анысы яхшы. Кунакханәгә барыгыз да, укытучы кызны киенderegez.
— Ничек укытучы кыз? Аны хатын-кыз дип әйтмәгәннәр иде бит,— дип гаҗәпләнде Аттаукай.
— Ә сезгә барыбер түгелмени?

«Барыбер түгел шул...» — дип уйлый Аттаукай.

Ир кеше белән кайтырбыз, тормыш турында гәпләшербез, киңәшләшербез, укытучы кеше барысын да белә, дип уйлаган иде ич ул. Ә монда, менә сиңа мә — хатын-кыз! Ни сөйләшмәк кирәк аның белән? Михнәт чигәселәре бар икән әле юлда!

Теләмичә генә кунакханәгә китте.

Төньяк кешесенең күзе үткен, шунлыктан, ул ят укытучыны тиз таныды. Әмма шулай да үзен сынап карарга булды, дежурныйдан:

— Кем «Төньяк балкышына» барырга җыена? — дип сорады.

— Виолетта Сергеевна, сезгә!

Ялгышмаган икән, янына калын свитер, тар балаклы чалбар кигән, бармак араларына сигарет кыстырган, кыска чәчле, тулы йөзле бер чибәркәй килеп басты. Укытучы кызның җитди үк булмаган тышкы кыяфәтенә күз салгач, Аттаукай авыр сулап куйды. «Егермедән аз гына артыграктыр!»

— Мине алырга килдегезме? «Төньяк балкышы»ннанмы? Анда мине көтәләрме? Этләргә утырып кайтачакбызмы? Ай, нинди романтика! Беркайчан да этләргә утырып йөргәнем юк ич әле минем! Әнием белсә икән! Исемегез ничек соң? — дип тәтелдәде ул.

— Аттаукай...

— Шулай гынамы? Исемегезме ул, фамилиягезме?

— Исеме дә, фамилиясе дә шул,— дип сүзгә кушылды дежур хатын. Чукча белән эскимосларның исемнәре генә бар, шул — фамилия дә. Шулай булган. Элек ничек кушсалар — шулай сакланган. Хәзер инде исемнәр дә, отчестволар да булдырылды.

Дежур хатынның кәефе әйбәт, җитмәсә үзен бу яктан бик тә белдекле итеп күрсәтәсе килә иде.

— Ай нинди кызык! Чыннан да, нигә кирәге бар ул исем-отчествоның? Мине Виолетта Сергеевна дип йөртәләр, һм... ягъни Виолетта, Виола, димәк. «Виола» дип кенә дәшегез миңа, ярыймы, Аттаукай?

— Ярар.

— Менә яхшы. Ә кайчан китәбез? Бүген үкме? Ә этләрегез кайда? Карарга ярыймы?

— Иртәгә иртән...— Аттаукай аның тәтелдәвеннән туйган иде инде.— Иртәгә карарсыз... Шушында көтегез.

Пассажир ошамый икән, иң элек каюрның кәефе кырыла.

— Сау бул,— диде Аттаукай.

— Сау булыгыз! Мин көтәм! Минсез китә күрмәгез!

«Кая китим инде?» — дип күңелсезләнеп уйлады Аттаукай.

Юлда ул аны кайгыртты, тауга менгән чакта үзе нартадан төште, ә аңа утырырга кушты. Виолеттага мех киемнәр зур, уңайсыз иде. Берничә адым атлауга ук арый. Моны Аттаукай күреп торды, шунлыктан, тау менгәндә этләргә ярдәм итте.

Каюр юлдашының туктаусыз такылдавыннан курыккан иде. Башта шулай булды да. Аннары аны тирә-юньдәге күренешләр хозурлыгы җәлеп итте. Тын гына яткан ак сопкаларга, гаҗәеп матур булып җемелдәгән карга (поселоктагыча түгел инде) исе китеп, сүзсез генә карап, нарта табаннары шыгырдавын тыңлап һәм этләрне күзәтеп бара башлады. Күңелен көтелмәгән бәхет чолгап алгандай булды. «Я, хода, нинди матурлык! — дип пышылдады ул.— Нинди гүзәллек!»

Кымынә әбигә иртән үк килеп җиттеләр. Көтүчеләр юк иде — дежурлыкка киткәннәр. Көтү ике төркемгә — буазларга һәм кысырларга аерылган, тиздән боланнарның бозаулау вакыты җитә, шунлыктан кешеләр көне-төне дежур тора.

Кымынә кунакның күңелен күрергә тырышты. Ул Виолеттаның болан тиресеннән тегелгән йомшак торбаларын салдырды, икенчеләрен бирде, тузмадылармы икән дип тикшерде. Кунакны җылырак урынга —

чаршау артына кертте. Кем белә, бәлки учак янында читенсенәдер, ә чаршау артында чишенергә, мех киемнәрне салырга да була.

Чи нерпа итен ул Аттаукайга гына бирде, чөнки андыйны русларның барысы да ашамаганын белә. Ә кунак өчен учакта болан ите пешә. Ит пешкән арада чәй эчәргә була. Кымынә яңа чынаяклар ала, әйбәтләп юа. Аннары зәңгәр каеннар, зәңгәр өйләр, зәңгәр бизәкләр төшерелгән тәлинкәләр чыгарыла..

Ипи юк, әмма май, коры печенье, шикәр бар. Аттаукай әбисен ипи белән сыйлый. Ул аңа берничә бөтен ипи алып кайтты, көтүчеләрне сөендерәсе килде. Чөнки тундрада кышын ипи пешереп яталмыйсың. Әби капчыктан бер ипи ала, аның яртысын кисеп, кунакка суза. Ипи яңа, туңган, әмма май һәм кайнар чәй белән бик тәмле. Виолеттаның мондыйны ашап караганы юк иде әле!

Җылыда Виолетта изрәп китә, салкында берничә сәгать булу үзен сиздерә — бите яна. Ул рәхәт арыганлык тоя.

Кунаклар тукланугa карамастан, әби чаршау артына яңадан чәйнек кертә, үзе дә утыра — хәзер инде бергәләп сыйланырга да була. Чәй беркайчан да эчне тишми — ашар алдыннан да, ашагач та. Тундрада чәйсез яшәп булмый, чәйсез әңгәмә дә башлап булмый.

Виолетта дәшми, әмма Аттаукай белән Кымынә әбигә рәхмәте карашыннан ук күренеп тора. Әби белән каюрга барыбер нинди дә булса бер яхшылык эшлим дип уйлый ул, тик әлегә ни эшләячәген генә белми.

Талгын гына аккан әңгәмә вакытында әби Виолеттага егерме ике яшь тулуын, аның Анадырьдан килүен белә. Педучилищедан соң шунда яшәгән. «Төньяк балкышы»ндагы укытучы каникулдан соң кинәт китеп баргач, шунда баруын үтенгәннәр, һәм ул риза булган. Анадырьда яшәсә дә, тундрага бер генә тапкыр да күз салмаган, практиканы да шәһәрдә узган. Төньякта аңа ошый. Ә Мәскәүдә булмаган. Әгәр материкка китсә, һичсүзсез — Ленинградка гына җыеныр иде. Дөрес, анда да аяк басканы юк. Әмма апасы, Ленинградта Мәскәүгә караганда яхшырак, ди. Ә аның апасы барысын да белә, яшьлегендә ул бөтен җирдә булган, хәзер Себердә яши. Юк, юк, гаилә турында уйларга иртә әле, дөнья күрәсе бар. Дус кызлары барысы да кияүгә чыгып бетте, ә ул көтәчәк, өлгерер әле, кая ашыгырга?

«Һм...— дип уйлый Аттаукай,— сораучы булмаган сине, шуңа шыттырып утырасың да. Егерме ике? Күптән вакыт инде бала табарга... Малай... малай да, кыз да булса, тагын да әйбәт, ул чакта күңелсез булмаячак...»

— Тундрада егетләр бөтенесе диярлек буйдак,— ди әби.— Кызлар артык иркә үсә, тундрага барырга, көтүчегә чыгарга теләмиләр...

— Кулларыннан эш килми,— дип мыгырдый Аттаукай.— Ничек барсыннар алар тундрага? Укыган булалар да берәр кәнсәгә кереп оялыйлар. Нәрсәгә генә өйрәтәләрдер аларны? Торбас тегә белмиләр, тире иләү, ашарга пешерүне инде әйткән дә юк. Тундрада кемгә хаҗәт алар?

Әби елмая, ә тегесенең теле тагын да ачыла.

— Андыйларга гомеремдә дә өйләнмәс идем мин. Чынлап!

— Сиңа әйбәт хатын кирәк,— ди әби,— тундрадан эзлә син.

— Тундрада юк шул инде.

— Ә яр буенда... күрше эскимосларда? Эскимос кызлары чибәр.

— Эскимослар артык мода куа...

— Хатын-кызларның барысы да мода ярата,— дип көлә Виолетта.

— Шулай шул! Сезгә киенергә-ясанырга гына булсын... их! — Аттаукай кулын селти һәм үзенә яңадан чәй ясый.

— Сөйләнмә, ичмасам,— ди Кымынә.— Эчәсе килмәгән кешегә янындагы чишмә дә ерак...

Әбисенең һөҗүмен кире кагар өчен Аттаукай Виолеттага:

— Бездә шундый әйтем бар,— дип аңлата.

— Әгәр кәләшне урласагыз? Ай, нинди романтика! Грузиядә әнә кызларны урлыйлар,— дип сөйли Виолетта.
Аттаукай гаҗәпләнә:
— Ничек урлыйлар?
— Урлыйлар инде... Авылга атта чабып киләләр дә хатын-кызны юрганга төреп сыпырталар!
Аттаукай аңламыйча җилкәләрен җыера. Чукчалар гомер буе беркайчан берни урламый, сорамыйча берни алмый. Ә монда кеше урла, имеш! Юк, аңламый моны Аттаукай.
— Кайда соң ул Грузия? — дип сорый ул.
— Кавказда. Шундый тау бар. Тауларда яши алар, республика ул,— дип аңлата Виолетта.
— Ә-ә, беләм...
Үз гомерендә грузинны ул беренче тапкыр «Казбек» папиросы кабында күргән иде. Берәү тау итәгендә атта чаба. Ат — шул ук болан инде ул, тик мөгезе юк та гәүдәгә зуррак. Аттаукай яхшы хәтерли ул күренешне. Тау хатын-кызларын шулай кимсетүләре өчен ачуы килә аның.
— Юк ла,— дип тынычландыра аны Виолетта.— Элек кенә чынлап урлаганнар, ә хәзер ризалык белән генә. Йоласы шундый. Урлаганга риза булып торалар.
«Риза булгач, ник урларга?» — дип аптырый Аттаукай, тик кычкырып сорамый. Ул житез бер грузинның алар торагына килеп керүен һәм Кымынә әбине урлап китүен күз алдына китерә. Әкәмәт тә булыр иде соң! Әбисе «кияү» йортында шундый гауга куптарыр, бөтен грузин күз ачып йомганчы эзен суытыр иде! Барлык явызларны суеп, атып бетерер, матур зәңгәр рәсемле булуларына карамастан, барлык савыт-сабаларны кырып атыр иде!
— Ә савыт-саба металлдан анда, көмештән — дип сөйли Виолетта, аның уйларын сизенгәндәй.
Аттаукай күңелсезләнеп кала:
«Алайса, металл савыт-сабаны кыра алмый икән».
— Ә син үзеңне урлауларын теләр идеңме? — дип сорый ул әбисеннән.
— Грузины яшьме соң?
Виолетта көлә.
Аттаукай гаҗәпләнеп башын селки. «Ай, әбекәй, кунак алдында оялыр идең, ичмасам! Юк инде, ике хатын-кыз очраштымы, юньле нәрсә көтмә син алардан!»
Ул кружкасын әйләндереп куя да әйтә:
— Этләрне карап керим әле...
Якты апрель кояшы кар өстен нурга күмгән. Каюр белән аның юлдашы кара күзлекләрен киделәр. Эссе. Тынлык. Алда барысы да яхшы булыр кебек тоела. Кәеф төшәр, я һава үзгәрер, яисә этләр бәлагә тарыр дип уйга да китерәсе килми.
Аттаукай шулай да ашыкты. Нindидер бер тойгы аңа кояш баеганчы һәм тыныч вакытта үткелне узарга куша иде. Күрәсең, ерактагы болытлар шик салгандыр күңеленә.
Үткелгә җиткәч, этләр карга ятты. Аттаукай ашыкмыйча гына портсигарын алып папирос кабызды. Виолетта, нартадан төшеп, аякларын язарга булды. Кояш нурын сибә, әмма ул башка, салкын иде инде.
— Кара әле,— дип күрсәтте түбәнгә таба Аттаукай. Канатларын киң җәеп, күктә бер урында козгын тора иде. Ә ике сопка арасында буран уйный, җирдән кар себерә, болыт күләгәләре арасындагы кар кояшта ялтырап күренә. Козгын аска, җиргә карый, ул буран өстендә, аңа төшәр урын юк. «Без килгән якка — төньякка китәр»,— дип уйлады Аттаукай.
Виолеттаның бу күренешне беренче тапкыр күрүе, һәм аңа тыныч урыннан буран өерен, кояш нурларына манчылган буран өерен күзәтү сәер иде.

— Безгә шунда барырга кирәкме? — дип сорады ул.

Аттаукай башын селкеде.

Көньяктан болытлар агыла, ә җил инде, дөрес, әлегә карсыз гына, үткелгә килеп җитте.

— Монда да буран кузгалачакмы? — дип сорады Виолетта.

Аттаукай башын селкеде. Сөйләшәсе килми иде аның. Ә нәрсә турында сөйләшәсең инде. Аска төшәргә кирәк, әлбаттә, анда җилдән сопкалар бераз саклар. Ә биредә, үткелдә, үзләренә дә, этләргә дә начар булачак.

— Озак кайтасымы әле безгә? — дип сорады Виолетта.

— Әһе...

Ул папиросын ташлады.

— Ныграк тотын, аска кызу төшәчәкбез.

Ул этләрне кузгатты. Алар тордылар, өсләрендәге карны селкеп төшерделәр, кузгалдылар. Нарта таеп китте һәм, этләрне узып, аска шуды. Аттаукай аны таягы белән тыйды. Бөтенесе бергә кар бураны эченә кереп чумдылар, кояш шундук каядыр югалды.

Йөзләрен җилдән борып, этләр нартаны көч-хәл белән тарта. Монда, аралыкта, кар шактый калын иде. Аттаукай әледән-әле нартадан төшеп янәшә атлый, иелеп куллары белән карны әрчи, сопка түбәләрен күрергә тырышып, як-ягына карана. Алар шулай авырлык белән генә бер сәгать чамасы бардылар. Үткел беткәч тигезлеккә чыгарга тиешләр. Менә кайда адашуың да ихтимал. Шуңа күрә анда житкәнче тукталыш ясарга кирәк. Ышыкланыр урын табып, көтәргә кирәк.

Юлдашы чыраен сытып дәшми генә утыра. Гәүдәсен кар сарган, йөзен колакчын бүрегенә яшергән, төренгән. Бернәрсәгә карыйсы килми, аңа шулай яхшы.

Этләр еш кына үзләреннән-үзләре туктый, Аттаукайга аларны куаларга туры килә. Ул аңлый: аларның да барасы килми, аларның да көтәселәре килә.

Алда текә тауның таш кабыргасы шәйләнде. Аттаукай бу урынны таныды — моннан тигезлеккә чаклы бер километр.

Җил көчәйде. Аның инде хәзер берниндн юнәлеше юк кебек, төрле яктан, хәтта өстән һәм астан да исә. Әмма салкын түгел, җепшек апрель бураны җылы була.

«Кызык, буранда козгын кая китә икән? — дип уйлады Аттаукай.— Көртлекләр, ябалаклар карга чума — анысын ул белә. Җәнлекләр дә көрткә кереп поса. Ә менә зур кара кошның карга чумуын ул күз алдына китерә алмый. Килешми бу аңа. Мөгаен, ул буран булмаган якка очып китеп өлгерәдер. Аның урынында булсам, мин район үзәгенә очар идем,— дип уйлады Аттаукай һәм елмаеп куйды.— Нартаны борып, кире шунда китсәң иде ул... Тик өлгереп булмый... кызганыч».

Этләр, туктап, күзләрен каюрга төбәделәр. Тегесе дәшмәде. Этләр ятты.

— Шушында көтеп торабыз,— диде ул Виолеттага.

Кыз, күзләреннән шарфын төшереп, Аттаукайга төбәлде.

— Нигә көтәргә? Барырга кирәк!

— Кая? Әнә бит, күрәсеңме?

Виолетта кар пәрдәсе аша карарга тырышты, тик хәтта иң якындагы этне дә күрә алмады. Борчыла башлады.

— Нишлибез инде хәзер, Аттаукай, нишлибез?

— Берни эшләмибез, көтәбез...

— Нәрсә көтәбез, нәрсә көтәбез, Аттаукай?

«Дәшмәсәң иде, ичмасам!» — дип уйлады каюр.

— Юлны югалттыкмы әллә? Югалттыкмы?

— Этләр югалтты ул, мин түгел. Мин аны күрмим генә,— диде Аттаукай, авыр сулап. Сөйләшәсе килми иде аның.

— Нишлибез соң инде, ә? Ә?

Тегесе дәшмәде.

— Кич җитте бит, кич җитте!

«Кич җитсә дә, барыбер», Аның сүзләрен ишетмәс өчен, Аттаукай торып этләре янына китте. Алар бөгәрләнеп яткан, үзләрен кар каплаган. Аттаукай каешларны тарткач, этләре торды, карларын селкеп төшерделәр. Ул алдагы маэмайның берсен муенчагыннан тотты да үзе артыннан тартты, барлык этләрне нарта янәшәсенә борып куйды. Этләр белән нарта бергә сынык ярымтүгәрәккә охшап калды.

— Тор! — дип кузгатты ул Виолеттаны.— Бераз йөренергә, сикергәләргә кирәк. Аякларың өшемиме?

Виолетта нартадан иренеп кенә төште. Аттаукай нартаны яны белән күтәреп куйды. Астагы карны көрәде, укытучы утырып кайткан болан тиресен җәйде. Бәләкәй генә ышыкланыр урын әзер. Җилдә торган ише түгел инде.

— Утыр! — дип кычкырды ул.— Юкса күмеп китәр! Менә шулай... Әйбәтме? Бөтенләй җылы, өрми дә, әйеме?

Укытучы шыңшымасын өчен ул үзенең тавышына кыюлык өстәргә тырышты.

— Йокларга да була хәтта! — дип кычкырды ул буран аша.

Җил тынмады, төн якынлашты.

Барлык бу хәлләр Аттаукайны бик тә борчуга салды. Бураннан башка беркем дә — каюр да, этләр дә гаепле булмаса да, Виолетта ачулана һәм үпкәлидер төсле тоелды аңа. Тик тундрада буранга үпкәләмиләр, чөнки кар, кояш, суык, буран — котылгысыз нәрсәләр. Буранга үпкәләргә берәүнең дә башына килми.

«Кызык, Грузиядә буран була микән?» — дип уйлады Аттаукай һәм әбисен исенә төшерде. Мөгаен, хәзер чаршау артында утырадыр, анда җылыдыр, көтүчеләр белән чәй эчәдер, Аттаукай турында сөйлидер. Аһ, бу карчыклар!

— Әй, тор әле! Сикергәлә бераз,— дип төрткәли ул Виолеттаны.

— Юк-юк, кирәкми...— ди кыз калтыранган тавыш белән.

Каюр аңлый: елый ул.

— Елау ... әйбәт түгел...— дип кычкыра аның колагына ук. Башкача юата белми шул.

— А-а-ай... куркыныч миңа, Аттаукай... Без туңып үләчәкбез, а-а-а... Әйдә, китик, Аттаукай матурым, әйдә, кузгалыйк. Кайткач, мин синеке булырмын, Аттаукай... хатының кебек булырмын...

«Какомей! — дип коты очып уйлады Аттаукай.— Ни сөйли ул?»

Рус хатын-кызларының чукот кешесенә кияүгә чыгуы авылда булган хәл түгел. Күрше авылда булды, аларда — юк. Чөнки авылга бер генә рус хатын-кызының да аяк басканы юк, бөтенесе ирләре белән килә. Шакkатырлар иде дә соң Аттаукай марҗа алып кайтса! Председательнең күзе маңгаена менәр иде! Менә егет икәнсең, Аттаукай, менә булдыргансың, диярләр иде.

Әмма аның уйларын Виолеттаның елавы, сулкылдавы бүлдерә. Ул, җилдән борылган да, йөзен каядыр аның муенына яшереп, колагына тукый:

— Аттаукай, кадерлем... коткар мине... коткар. Хатының булырмын, әйдә китик, тырыш инде, юкса, туңып үләбез бит без монда!

— Әйе, әйе, китәбез! — дип юата ул аны.— Аз гына тынычлансын да, бер генә йолдыз булса да күренсен инде... Аннары кузгалабыз. Бүген кайтып җитәбез, борчылма... Уф!

Беркайчан да болай күп сөйләгәне юк иде, Аттаукайның хәтта тыны кысылды.

Буран сызгыруы астында ул көтмәгәндә башына төшкән хәлләр турында уйланды. Рус булса да, дип фикер йөртте ул, бераздан күнегер

але, укытучы лабаса, анлы кеше булырга тиеш. Әтисе хуп күрмәс бу эшен, анысы көн кебек ачык. Әнисе дә өнәмәс, үзен дә, кулыңнан эш килми, дип хатынын да битәрләр. Артык яшь, шунысы начар. Әмма анысы үтәр, кунегер. Бала табарга кирәк аңа, шул чак барысы да рәтләнер, дип хәл итте Аттаукай.

Төн урталары узгач, кар бураны арасыннан йолдызлар күренә, сопкаларның кара шәүләләре шәйләнә башлады. Кузгалырга була, дип уйлады Аттаукай. Этләрне торгызды...

Элеккечә үк әле нык саберә иде. Этләр иртән Аттаукай өенә кайтып житте. Виолетта чәй эчеп тормады: жылыда изрәп, көн буе йоклады.

Кич кенә председатель килде. Өчәүләп чәй эчтеләр. Председатель мондагы тормышны мактады, яшь белгечне тынычландырды. Виолетта юлда ничек кайтулары, нинди куркыныч булуы турында сөйләде, каюрны мактады. Ә каюр дәшми генә елмаеп утырды һәм, бу кыз вәгъдәсе турында әйтсен иде инде, председатель безне котлар иде, дип уйлады. Әмма тегесе ул хакта дәшмәде, әйтерсең лә, буран вакытында бер сүз, бернинди вәгъдә бирмәгән. Борчуга салды бу Аттаукайны.

— Бүлмә зур, хәзергә шушында куныгыз,— диде председатель саубуллашканда.— Ә иртән кызлар килеп жыештырыр.

— Кирәкми, мин үзем,— диде Виолетта.

Аттаукай аңа хатыныннан калган чиста жәймә-мендәрләр бирде, ә үзе идәндә тиреләр өстенә урнашты. Әмма Виолетта чишенми генә ятты. Аттаукай моны яхшылыкка юрамады.

Юлдагы сүзләрне исенә төшереп тормады ул. Чөнки Аттаукай әйткән бер генә сүзен дә онытмый икән, ни өчен ул онытырга тиеш? Монда, бу якларда, бер нәрсәне дә кеше исенә төшермиләр...

Авыр көрсенде Аттаукай, чәй ясап эчте, тәмәке тартты.

Төн буе боргаланып ятты ул, бик тынгысыз йоклады. Өендә күптәннән инде хатын-кыз кунганы юк иде, ничектер үзенә урын таба алмады.

Иртән Виолетта юк иде. Кухняга күз салды — чемоданыннан да жилләр искән.

«Бөтен хатын-кыз бер чыбыктан сөрелгән,— дип уйлады ул,— берсенә дә ышанырга ярамый».

Председательгә наряд алырга китте.

— Кер, Аттаукай, кер! Ничек уйлыйсың, соңгы буран микән инде бу, ә?

— Һе-е... бәлкем, соңгысыдыр...

— Мин соңгысыдыр дип уйлыйм. Май житә бит инде... Булса, бер-ике май бураны булыр да, бетте — яз, әйеме?

— Әйе.

— Тик син жәйне иртәрәк тә күрә аласың. Чәчәкләр, жиләк-жимеш, тансык азык-төлек...

— Ничек? — дип аптырады каюр.

— Яхшы эшләгәнең өчен, сиңа материкка путевка бирергә булдык. Анда хәзер жәй инде. Теләгән жиреңә бар...

— Путевка кая?

— Үзең сайла, берсе — Ялтага, икенчесе — Карпатка... Теләгең бармы? — дип сорады председатель.

«Йөрәк — теләкләр оясы» дигән мәкальне исенә төшерде Аттаукай, лакин дәшмәде.

— Я?

Аттаукай башын селкеде:

— Язын ау әйбәт. Ауга барырга кирәк...

Ул тавыш-тынсыз гына чыгып китте, ә председатель, авыр сулап, яңадан кәгазьләренә иелде. Тик бераздан Аттаукай яңадан кабинетка әйләнеп керде.

— Кире уйладыңмы? — дип сорады председатель.

— Грузиягә путевка бармы?

— Грузиягә? Кавказгамы?

— Әйе.

— Кавказ нигә сиңа, Аттаукай?

Тегесе дәшмәде, бер урында таптанып торды. Күңеле белән ул анда, тауларда, җитез ат өстендә иде инде. Менә ул грузин авылына килеп керә, иң чибәр кызлар аның каршысына йөгереп килә. Аттаукай аларның берсен эләктереп ала да, тирегә сак кына төреп, аты өстенә сала. Бераз уйлап торгач, тагын берсен эләктерә, төрә һәм җайлап кына авылдашы янына яткыра. Монысы Кляүлгә. Унбиш көннән тундрадан кайткач, аңа да хатын кирәк булачак бит. Дустың турында беркайчан да онытырга ярамый.

Бу уйларыннан аны председательнең арыган тавышы уятты:

— Районга шалтыратырмын..., белешермен... Кара син аны, Кавказ кирәк, диген, әйтерсең лә, монда таулар юк! Әнә күпме алар, теләгәнеңә мен!

Аттаукай елмаеп чыгып китте. Әлбәттә, дип уйлады ул, әгәр председатель путевка таба алса, бер ау сезонын корбан итәргә туры килер. Нишләмәк кирәк, җитдирәк эшләр бар шул!

Русчадан **Миргалим ХАРИСОВ** тәрҗемәсе.

# Госман Садә

## Җиргә якты күбрәк төшсен

Җәйгор канат җәйгән җәйнең иртәсендә,
Кояш җиле белән кояш җилкәнендә
Җирдәшләрем сәфәр чыга ерак юлга,
Йолдызларга оча алар — җиде елга...

Оча алар — Җирнең җиде кыю улы,
Алда көтә серле Киек Казлар Юлы.
Киек Казлар — йодызларның тупланышы...
О, галәмнең ачылачак мең ачышы!..

Әйләнәдер ул йолдызлар тирәсендә,
Шундый якты янганының эргәсендә
Җәйгор нуры канат җәйгән көмеш нокта —
Җиргә охшаш, Җиргә кардәш бер планета.

Туфрагында бездәгедәй гөл үсәдер.
Җылы яңгыр вәгъдә итеп җил исәдер,
Нәкъ бездәге кебек икмәк игәләрдер,
Мәхәббәтне зурлап, хөрмәт итәләрдер...

Яшел җәйнең шундый җылы иртәсендә,
Кояш җиле белән кояш җилкәнендә
Җирдәшләрем җиде елга сәфәр чыга:
«Хәерле юл сезгә — космик юлчыларга!»

...Ача галәм тәрәзәсен җиде егет
Бар тарафка тагын да киң, иркен итеп:
Җиребезгә якты күбрәк төшсен өчен,
Гөлләр генә җирдә күкрәп үссен өчен!

## Дуска хат

Анонимка — заман чире,
Сүзнең чүбе, чүбеге,—
Колорадо коңгызыдай
Котырынып үрчеде.

...Хакыйкатьне күзгә карап,
Туры әйтер урында,
Югарыга хат юллаган
Берәү синең турында.

Имештер дә, бүре кебек,
Нәфсең синең котырган.
Күкрәгеңдә йөрәк түгел,
Иблис кереп утырган.

Кеше диеп аталырга
Хаклы түгел син хәтта.
Синең хакта ниләр генә
Язылмаган ул хатта.

---

ГОСМАН САДӘ *(1949) — «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Имзасыз хат — имансыз хат,
Һәр җөмләсе агулы.
Мәкерләләр, елан кебек,
Белә бары чагуны.

Чага алар сиздермичә,
Читтән торып, сүз белән.
Гәрчә алар синең алда
Һәрчак якты йөз белән.

Күрешәләр гел елмаеп,
Телләреннән бал тама.
(Бал дигәннән күбәләк тә
Балга чумып алдана).

Ә елмаю пәрдәсенә
Яшерелгән хөсетлек.
Хат язган ул...
Кыйблаң синең
Булган өчен дөреслек.

Тикшерерләр ул хатны да
(Хатлар калмый җавапсыз),
Канат кисәр имансыз хат
(Кошлар очмый канатсыз!)...

Син дә, дустым, очар чакта
Канат кагып, талпынып,
Ул хат калыр күңелеңдә
Җөйсез яра, тап булып.

Күңелеңдә тап калса да,
Юк, намусың тапталмас.
Беләм, гайбәт каршысында
Намуслылар акланмас.

Ашыгырсың, дәшсә берәү:
«Ярдәм кулың суз әле!»
...Мин дә сиңа бер хат яздым.
Гади хат ул... имзалы.

## Ветеран

Бүлдерде дә купшы нотыкчыны,
Киң сәхнәгә атлап чыкты ул.
Әйтеп бирде чынын...
...Һәм йөрәген
Кинәт учы белән тотты ул.

Кемдер берәү залдан пышылдады:
«Карга күзен карга чукымый.
Эндәшмичә калсаң, нәрсә була —
Нигә дөньяң шунда чукынмый?!»

Шул пышылдау сүзе әлмәк сыман
Буып алды аның сулышын...
Күрмәде ул мондый хыянәтне
Мең мәхшәрен күреп сугышның.

«Эндәшмичә калсаң, нәрсә була?!» —
Бу сүз килә кайсы заманнан?
(Күп чакларда, әйе, дәшми калу
Зур егетлек булып саналган.)

Шуңа микән купшы нотыкчылар
Күзгә карап төтен өрәләр...
Кире якны, күпләр күрсәләр дә,
Күрмәү ягын өстен күрәләр.

«Эндәшмичә калсаң, нәрсә була?!» —
Битарафлар тарта җиң очын.
Ышык урын эзләп,
Читкә тартып
Бумакчылар дәвер сулышын...

Юк, эндәшми калу мөмкин түгел!
Көн яктысы безгә борылган.
...Һәм йөрәген тотып, ныклык белән
Дәвам итте сүзен ветеран.

❀

Өрде дә этләр тындылар
Кышның җилле кичендә.
Чың-чың итеп тәрәз чиртте
Юлчы авыл читендә.
Хуҗабикә, каушый-каушый,
Ачты бикле ишекне.
Юлчы ни дип эндәшкәнне
Җилләр генә ишетте:
«Китеп барам мин сугышка,
Чыгар, зинһар, йоклатып?!»
...Юлчы төне узды назда,
Тол хатынны юатып.
Юлчы китте...

Гаип булды...
Дөньяга малай килде.
Кемдер берәү гайбәт итеп:
«Җилдәндер, ай-һай!» — диде...
— Ышанма син ул гайбәткә,
Гайбәт сөйләү — җил эше,—
Дип юатты ана улын,—
Син — сөюем җимеше!
«Җилдән туган» малай үсте,
Гел этисен көтте ул...
Мәхәббәткә һәйкәл салыр
Шагыйрь булып китте ул...

*Кояш Тимбиковага 50 яшь*

# ЯШЬЛЕК ДӘВАМ ИТӘ



*Аңа илле тулуына ышанасы да килми. Хәер... Мин Кояш Тимбикованы беренче тапкыр күргәндә, 1959 нчы ел иде бит инде. Безнең авылга килгән иде ул. Өстендәге ак юбкасы, чем-кара кофтасы шундый килешле. Җилкәсенә озын баулы кечкенә генә сумка аскан, кулында — блокнот. Җиңел гәүдәле, җитез хәрәкәтле бу кыз, авылыбыз почтасындагы апа белән бергәләп, йорт саен диярлек йөреп, фермага барып, мәктәпкә кереп, халык белән бик ягымлы сөйләшеп, хәл-әхвәлләр сорашып, «Азат хатын» журналына язылырга өндәп йөрде. Үзе — Чистай ягыннан, университет тәмамлаган да яңа гына эшли башлаган икән.*

*Шул еллардан безнең авылга «Азат хатын» журналы күпләп килә башлады. Журнал белән бергә күңелләребезгә Кояш апа Тимбикова да үтеп керде. Һәр өйдә аның берсеннән-берсе гыйбрәтлерәк язмаларын, хикәя, повестьларын көтеп алырга өйрәнделәр. Аның әсәрләре дәртле, рухландыргыч, тормышчан булулары белән халыкка якын иде. Әллә нинди кызык язмышлы геройлар эзләп таба да шулар турында яза ул. Укучылар хәтерлиләрдер: бервакыт ул Социалистик Хезмәт Герое тимерче Сәрвәр апа Нәфыйкова турында язган иде. Бераздан ул Кояш Тимбикованың «Синең өчен» повестена төп герой булып керде. КамАЗ, БАМ төзелешләре илне шаулаткан еллар. Яшьләр удар төзелешләргә җыелды, юлсыз тайгаларга, кеше аяк басмаган җирләргә, яшьләр янына Кояш Тимбикова да барып җитте. Яңа, яшь дуслар тапты, алар белән хатлар алышты. КамАЗ төзелешенә ул бигрәк тә еш бара иде. Гүя яңа шәһәр йортларының стеналарын шомартышты, тәрәзә рамнарын агартышты, биек-биек краннарга менде. Нәтиҗәдә уннарча очерклар һәм «Агым уртасында» исемле повесть дөнья күрде. Укучы — әдибәнең бу әсәрен дә яратып кабул итте. Бигрәк тә яшьләр. Чөнки повесть нәкъ менә алар турында иде.*

*Язучы бу якларга баруны әле дә көтеп ала. Хәзер ул Татарстан АЭСын төзүчеләр янына, аларның хәле белән танышырга яки шигъри митинглар үткәрергә ашыга. Урак өсте җитсә, яшь җырчыларны, шагыйрьләрне дә алып, игенчеләр янына китә.*

*Ул гел яшьләр белән. Каләм тибрәтүче егет яки кызда өметле чаткылар күреп алса, ярдәм итәргә, киңәш бирергә тырыша. Сәнгатебездәге күп кенә талант ияләре дә матбугат аша әйтелгән беренче җылы сүзне Кояш Тимбиковадан ишеттеләр. Шуңа да аның тирәсендә яшьләр һәрвакыт күп. Кайгыларын да, шатлыкларын да, яшьтәш итеп күреп тә, олы итеп тә, ышанып уртаклашалар.*

*Күптән түгел укучылар Кояш Тимбикованың «Тын бакчада» дигән яңа повестен укыдылар. Исеме тынлык вәгъдә итсә дә, әсәрнең төп герое Алия инде кызын кияүгә биреп йөрсә дә, бу әсәр дә яшьлек турында, дияр идем мин. Яшь аның Алиясе! Табигатькә, яшәешкә, тормышка гашыйк җан. Янып-ялкынланып: ваемсызларның үзәгенә төшеп, харап булган алма бакчасын тергезеп, аңа җан өреп йөри. Шулай да авторның үзен Алиягә түгел, яшь килен Рушаниягә охшатасы килә. Кояш Тимбикованың әдәбиятта яшь килен чагы: җиңе сызганган, алъяпкычы бәйләгән...*

*Аңа илле тулган, диләр. Узган юлларын, язылган әсәрләрен, халык яратып укый торган китапларын бергә җыеп карасаң, республика журналистларының Х. Ямашев премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган культура работнигы икәнлеген искә алсаң: «Әле илле генәме?» — дияргә дә мөмкин икән шул.*

*Әмма: «Ул да картайган икән инде»,— дисәләр, ышанмагыз. Мондый җаннар алай тиз картаймыйлар.*

**Фәния ХУҖИӘХМӘТОВА.**

# Кояш Тимбикова

# НИК САГЫНАМ ИКӘН?



Һәр елны, туган көнем якынлаша башладымы, җанны сәер сораулар биләп ала. Үзем, заман гадәтенчә, котларга киләчәк кунакларымны каршыларга әзерләнәм: өебезне бизим, әскәтерләрнең ап-агын алам, тастымалларны барлап куям — күңел түрендә сораулар куера. Аларны сизмәмешкә салышып табын тезәм: иң затлы тәлинкәләрне, чынаякларны чыгарам. Әнием өйрәткән әмәл белән пешерелгән, шуңа күрә бары бездә генә авыз итәргә мөмкин булган татлы бәлешне өлешләргә бүләм — фикерем исә бинийая каршылыклы сораулар арасында адашып-адашып йөри. Бәйрәмем истәлеге булсын әле, дип, кич утырып, сәер бер өлге белән күлмәк тә тегеп өлгертәм, әмма юк, бәйләнчек сораулардан котыла алмыйм. Гомер юлым буйлап эчкәрәк кергән саен сораулар катгыйлаша гына бара, төпле җавап таләп итәләр: сагынаммы соң мин балачагымны, яшүсмерлек елларымны сагынаммы? Үткән гомерне сагынмаска мөмкинме? Нәрсәсен сагынасың аның?..

Читтән караганда, бу сорауларның бер катлаулылыгы да юк шикелле. Мәгълүм ки, кешелектә гомер-гомергә балачакны сагынганнар, бу тойгыга багышлап бик күп җырлар чыккан. Берәве:

*...Сикердем — бакча икән,*
*Яшелдин хәтфә икән.*
*Бу гомернең бар рәхәте*
*Сабый балачактаикән, —*

дип сузган.

Икенчесе:

*Әй, яшь чыгым — рәхәт чагым,*
*Әйләнеп кайтчы тагын! —*

дип хыялланган.

Җырларга күчкән изге хисләрне инкяр итү мөмкинме? Анысы шулай, тик җанны сискәндереп куючан сораулар алдында икеләнеп калуымның сәбәпләре дә шактый җитди. Кайчак мин алардан тәмам каушап төшәм дә: «Юк, юк, яшьлегем әйләнеп кайта күрмәсен!» — дип тә ычкындыргалыйм. Җавапларның һич кире кагып булмастаен эзли китсәм, ерагаеп баручы ул дәвернең шомлы манзаралары яңара да котымны ала.

Әнием, больницадан кайтып кергәч, мин төрелгән биләүсәне бишеккә салган да тәгәри-тәгәри еларга тотынган. Сабыр итәргә киңәш бирүче хатыннарга стенадагы шәп-шәрә киштәләрне күрсәтеп ала икән дә тагын елый икән: «Берсе генә дә калмаган бит! Алардан башка мин нинди укытучы инде? Бөтен таянычым шулар иде...»

Хәл белергә кергән кешеләр таралышкач, әти аңлатып биргән. Көзге кара төндә кемдер тәрәзә шакыган:

— Закир абый, өстеңнән шикаять бар: коръән хәрефе белән язылган китаплар саклыйсың икән. Утка як! Иртәгә тентү килә...

Әти белән абый, ипи салганда гына ягыла торган олы мичкә ут үрләтеп, төне буе китап яндырганнар: янган Мәрҗани, янган Дәрдмәнд, янган Фатих Әмирхан, янган Ибраһимов, янган Тинчурин, хәтта Тукай белән Такташ та янган, чөнки барысының да китаплары гарәп хәрефе белән басылган икән.

Төн хәбәрчесенең сүзе исә рас килгән, иртән әтине, чыннан да кулга алганнар: «Китапларыңны кая яшердең?» — дип интектерә башлаганнар.

— И-и, кара инде, яшерү дигән нәрсә башыма да килмәде, ярамагач, ярамыйдыр, дидем,— әти үзенең беркатлылыгына аптырый калган.— Утка

яктым, ышанмасагыз, өй тирәсендәге карны тикшерегез, китапларның көле шуннан ерак төшмәгәндер...

Мин яңа яуган карның каралган көннәрендә туганмын. Сагыныр дәверме? Уртанчы апама ияреп Наратлы Елга авылының «Балалар мәйданы»на йөргәнемне, анда майлы ботка, мәкле күмәч белән сыйлауларын хәтерләмим. Мул уңыштан авыл кешеләренә ашлык өләшүләрен, кайберәүләрнең: «Житте, бүтән кирәкми, зинһар, кире алып китегез!» — дип, колхоз олавын борып җибәргәннәрен дә ишетеп кенә белдем. Өлкәннәрнең бу хакта сөйләгәннәренә, әкият тыңлагандай, гаҗәпләнеп утыра идем. Җайсызрак чакта туганмын диимме соң: мине тапканда әни — кырык, әти илле яшен тутырган. Мин дөньяны таный башлаганда, гаиләбезнең тирәге булырдай бердәнбер абый, унсигезе тулар-тулмас, фронтка киткән. Халык өстендә кара кайгы җилпенә, илдә Бөек Ватан сугышы бара иде.

Ашлыкны инде олаулап түгел, учлап исәплиләр. Берәр әрсез малай, куырып ашарга дип, басудан бер уч бодай уып алса, артыннан атка атланган бригадир килеп җитә дә, тузанлы юл буйлап, тирги-тирги, куып кайта, кесәсен амбарга бушаттыра иде. Уйныйсыңмы, өйдәге вак-төяк эшкә катнашасыңмы, йокларга җыенасыңмы — гел ашыйсы килә. Әниләр, балалардагы сүнмәс бу теләкне тоеп, казан-казан аш пешерәләр. Аңа байлыктагы бөтен тәм-том салына: шакмаклап туралган бер-ике бәрәңге, куш уч оннан әвәләнгән умач, бер кашык туң майда кыздырылган суган. Беренче коштабак күз ачып йомганчы «ялт» итә. Әни тагын өсти. Анысы да бетә. Тагын салалар, тагын, тагын... тамак туймый.

Язын безгә эш арта: әниләр кайткан җиргә бер табак яшь кычыткан яфрагы җыеп куярга тиеш булабыз. Олы кешеләр белде микән — безнең кебек бала-чага авылның бөтен тыкрыкларын, читән төпләрен бүлешеп чыга иде. Кычытканны да теләсә кайдан эзләргә ярамый. Һәркөнне кыркый торгач, күрәсең, анысы да санаулыга әйләнгән. Өзлексез ашыйсы килү үзәккә шул кадәр үткән ки, мин әле дә, сабый чагымны шау чәчәкле болында аллы-гөлле күбәләк куып уйнаучы нәни кыз хәлендә күреп, елмаеп ятасы урында, төшләремдә ипи эзлим. Таба алмагач, котым очып, уянып китәм. Өзелеп сагынасы җирдә, кире кайта күрмәсен дип, пышылдап куйсам, гаҗәпмени?!

Һәр баланың сабырсызланып көтеп ала торган мәктәпкә керү вакыйгасы өебезгә яңа мәшәкать өстәде, минем өс-башны адәм рәтенә китерергә кирәк иде. Төпчек бала өлешенә ни тия дип уйлыйсыз? Әни башта берәр киемен олы апага чамалап, үзгәртеп тегә. Ул киеп арыгач, уртанчы апага яраклаштыралар. Иң азактан — миңа. Шулай да, мин беренче класста укыганда, яз көне әти, укытучыларга бирелә торган карточкага туры китереп, миңа гына сыешлы галошлар алып кайтты. Ул аларның матурлыгы! Ялт-йолт итеп торалар, эчләренә җылы, йомшак, кып-кызыл фланель ябыштырылган, үзләре көмеш кашык кадәре генә — уенчык урынына кадерләп йөртерлек. Ап-ак йон оекбаш белән киеп куйсаң, курчакка әйләнерсең кебек.

Мин аларны, бер генә киеп салдым да, сыйпап-сырпап кулымда гына йөртә башладым. Күзге каршына куеп та карыйм, китаплар өстенә дә менгезеп утыртам, йокларга ятканда да баш очыма алам. Бөтен барлыгым тантана кичерә — бу галошлар минеке, минеке генә, миңа атап алынган! Җаным шулай күкләрдә йөзгән көннәрнең берендә әни сорап куйды:

— Кызым, аларны кайчан кия башларсың инде? Киеп бар мәктәпкә!

«Дерт» итеп киттем. Мәктәптәге малайларның күбесе — чабата, без, кызлар, «шахтер-галош» киеп йөрибез. Андый галошның эче-тышы тонык кына резина. Кайберсе бик каты була, бер-ике көндә шартлап чыга, йомшагы озакка чыдый. Мин дә уртанчы ападан кечерәеп калган «шахтер-галош» сөйрәп йөрим. Ямаулы оекбаш белән кисәң, тап-таман. Инде үземә атап алынган кызыл эчле галошны киеп барсам... Бөтенесенең күзе миндә генә булачак. Дус кызларым, аягыма иелеп, капшап-сыйпап та карарлар. Оялмыйча, ничек басып торырсың?! Иң яхшысы — кимәскә. Әнигә дә:

— Әй лә! — дигән булдым.— Кия башласаң, тузар ул, торсын!

Язгы көннәр тиз үтте. Сукмак төшүгә, без яланаяклап элдертергә тотындык. Җәй узып, көзге яңгырлар коя башлаганда, минем матур галошлар аягыма сыймый иде инде...

Кием-салымга безнең әллә ни ис китми иде лә ул. Бераз алгарак сикереш ясап булса да әйтим: авылда гына түгел, мәшһүр Казан университетының иң зур залында уздырыла торган яңа елны каршылау кичәсендә дә, ападан калган зәңгәр бизәкле штапель күлмәкне киеп, пыр туздырып танцевать итә

идем мин. Кешенең кыйммәте киемендә түгел, калебендә, дигән хакыйкатькә ихластан ышанып үсү бик затлы киенеп йөрүче яшьтәшләр арасында да горурлыкны сындырмый сакларга нык ярдәм итте.

Авыл мәктәбендә исә үзәккә үткәне китап-дәфтәр җитмәү иде. Дәфтәр урынына латин хәрефе белән басылган иске китаплар тотабыз. Язый́м дисәң, карасы бозга әйләнгән. Кара савытын куенга тыгып, кабыргасы беленеп торган арык тәнгә тидереп, өстенә сулыш өреп, эреткәндәй итәбез.

Болары да түзмәслек түгел, һәр иртәдә классташларның әле берсе, әле икенчесе, күз яшенә буылып, башын аска иеп, кара кайгыга батып килә. Сәбәбе бер — фронттан өмет өзгеч хәбәр алганнар. Күршедәге дус кызым Мәйсәрә Мәхмүдованың әтисе Хәйдәр абыйның һәлакәтен ишетү аеруча авыр булды. Әниләре Кәшифә апа түшәккә егылды. Без кергәндә, аның биш баласы да караватк тирәсенә сырышкан, тын да алмый куркышып торалар иде. Кәшифә апа ара-тирә сулкылдап куя, олы улы Җәүдәт абый аңа тартыла да:

— Әни, ярар инде! — ди.— Ярар инде, әни!

Башка сүз юк. Салкын өйнең ватык тәрәзәсендә шомлы җил генә улый.

Әтисез калган балаларга мәктәп ярдәм итәргә тырыша: киез итек, ботинка яки бүрек-фәлән бирәләр. Шулай да кайберәүләр укуын ташлый, әниләренә ярдәмгә алына, колхоз эшенә йөри башларга мәҗбүр була иде.

Мин 1943 елны укырга кергән Иске Роман авыл мәктәбе җидееллык кына иде. Аннары биш чакрымдагы Каргалы урта мәктәбенә йөрдек. Күрше авылда укуның өстәмә мәшәкатьләрен санап кына бетерерлек түгел. Каргалы кызларына караганда, кимендә, ике сәгать алдан торырга кирәк, өйгә дә караңгы төшкәндә генә кайтып егыласың. Буранлы көннәрдә куна калырга фатир да табасы бар. Мәктәпнең иске тулай торагы барыбызны да сыйдыра алмый. Юл йөрү өчен кием-салымның да җайлырагы кирәк. Кирәк, кирәк, кирәк... мөмкинлекләр генә чамалы. Әле бит сугыш беткәнгә дә күпме генә?! Ил җимерекләкләрдән арына.

Кагыйдәләр кырыс. Ул елларда имтиханнар да дүртенче класстан соң ук башлана. Дүртенчедән башлана да — һәр елны. Җиденче класстан соң укуы да түләүле. Рәтең юкмы, әйдә, ни белгәнең җитәр, эшләп аша! Шулай да күпләр, әле урта мәктәпне тәмамламас борын, югары белем турындагы ләззәтле хыялларга бирелә иде. Авыл китапханәсендәге эреле-ваклы бөтен китапларны укып бару хикмәте булгандыр бу. Күп укый иде безнең буын: таң атканда да — кулында китап, ай яктысында да укып ята, сукыр лампа янында да. Китаплар гел алга, матурлыкка, каһарманлыкка дәшәләр. Тик...

Ул чакта вузларга инде тернәкләнеп килүче илнең урта белемле күп яшьләре агыла башлады. Конкурслар коточкыч. Мин барып борын төрткән Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә, мәсәлән, бер урынга җиде кеше иде. Әле шәһәр балаларының, таныш-белешләренә таянып, баш аша үтү осталыгын да чамаласак, без, шәт, көч сынашып тормаган да булыр идек. Юк, без, авылның беркатлы җаннары, бары үзебездәге гыйлемгә һәм имтиханнарның гаделлегенә ышанып, мөгезсез сыерлар кебек, бардык та кердек. Җиде сынау арасында иң куркытканы — русча сочинение. Аның аркасында гына сөрлегеп егылмас өчен кайберәүләребез дистәләгән сочинениены, өтерәнә кадәр, күңелдән ятларга мәҗбүр булды.

Казанда укый башлагач, дөньяның матдилеге тагын кисәтеп куйды: тулай торак юк, стипендия, хәзерге исәп белән, нибары 22 сум. Дүрт-биш ай саен кабатланып торучы имтиханнарның берсендә «өчле» эләктерсәң, аннан да колак кагасың. Шунлыктан без бары бишлегә генә укырга мәҗбүр идек, чөнки гел «биш»кә укучыларга акча күбрәк бирелә. Кыскасы, сабый чактан күрә килгән хикмәтләрнең файдасы тиде, шәһәрдәге киртәләр дә берәм-берәм артта калдылар.

Әмма без дипломлы белгечләр булып өлгергәләгәнче, югары белемлеләр дә шактый күбәйгән, кадерләре китә төшкән иде. Бу хакта миңа олы әдибебез Мирсәй Әмир, матбугаттагы беренче язмаларымны күреп, «Азат хатын» редакциясенә кергәч, ачыктан-ачык әйтте:

— Котлы булсын! — диде.— Бу эшкә алынуыгыз әйбәт, тик хәзер әдәбиятта кызларга түгел, ир-атка да ифрат кыен. Бар иде заманнар, нәшрият кешеләре яңа әсәрне кулдан тартып алалар иде. Китабың килеп чыкканны сизми дә каласың. Каләм тибрәтүче кызларга — урын түрдән иде. Язсын гына! Юк иде алар. Бик азлап, акрынлап килделәр. «Азат хатын» журналына автор таба алмый йөдәгәч, анда җаваплы секретарь булып эшләүче

Такташ кайбер мәкаләләренә, Һәдия Такташева, дип кул куйган. Бар иде сездәйләрнең кадерле чаклары! Хәзер читенрәк булыр...

Дистәләгән еллар ераклыгына төренгән ул дәвернең шушы барлык авырлыклары берьюлы күз алдына килеп баса да: «Нәрсәсен генә сагынып-йм соң?» — дигәнеңне сизми дә каласың.

Шулай да бераү җырлап җибәрсен әле: «...Үтеп бара яшь гомерләр, әйләнеп кайтмас микән?» Яки уйламаганда гына балачак дустың очрасын да:

— Әллә танымыйсың инде? — дип, каршыңа килеп бассын. Азга гына чамалап торуың да оят тоела. Ашыгып:

— Сине дә онытсаң, җир йотар, Фәүзия! — дип, үткәндәгегә кереп китүеңне тоймый да каласың.— Бер телем ипине кыл урталай бүлә идек бит. Мин, сындырып кына бир, дим. Син пычак эзләп азапланасың.

— Сындырганда тигез бүленми ул,— дип, Фәүзия сүзне нәкъ теге еллардагыча дәвам итә...

Инде юлың туган җирләргә барып чыкса, сагынаммы? дип, икеләнеп торуың бөтенләй онытыла. Тамакка елаткыч төер тыгыла, тавыш калтырана башлый. Хәер, нигә болай тәгаенләп маташам? Яшьлек эзләренә кайтып төшкәндә һәркем үзенчә сагышланадыр. Минем дә, сагынаммы-юкмы дип, кирегә тырнап азапланулар, үткәндә кичергәнне адәм баласы чыдамаслык иттереп сурәтләп күрсәтүләр — барысы да сабый чактагы, яшьлегебездәге саф-самими мөнәсәбәтләрне өзгәләнеп сагыну хикмәте ул.

Иң шомлы көннәрдә дә авылдашлар арасында, үз башын хәвеф астына куеп, тәрәзә шакучысы, икенче берәүне һәлакәттән коткаручысы табылган лабаса! Ашарына, киярене такырая барган саен кешеләр бер-берсенә ярдәмчелрәк, шәфкатьлерәк була барган. Алар матди авырлыкларга каршы буыннан-буынга үстерелә килгән рухи байлыкларны калкан итеп күтәргәннәр. Уйлана китсәң, ул елларда көн иткәннәрнең хис-тойгылары сафлыгына, гамәлләренең гаделлегенә хәйран калырлык. Шулары искә төшсә, сагынудан сыгылуыңны көт тә тор!

Бервакыт яшәү өчен иң кирәкле нәрсәләр — тоз, шырпы, сабын, керосин бетте авылларда. Инде берәрсе Чистай ягыннан тоз юнәтеп кайтса, бөтен тирә-күршегә өлеш тия. Каршыбыздагы Гыйльметдин бабай, бер кызы калада яшәгәнгә, тозны ешрак таба иде. Бабай берәр стакан тозны безгә дә керттерә. Әнигә уңайсыз: алырга да, алмаска да белми, кунак ашы кара-каршы, дигәндәй, җавап төсендә бирердәй әйбере юк бит.

— Мә, мич өстеңә куй, эреп китә күрмәсен! — дип, күрше карчыгы кырт кисә.— Ике уйлап торма! Бу дөньяда ялгыз-ялгыз яшәп булмый, берәңнеке — берәңдә...

Шул «берәңнеке-берәңдә» дигән фикер әллә нинди авырлыклардан да йолып калыр кебек тоела иде. Янәсе, кыенлык килгән икән, ул сиңа гына түгел, аны кешеләр бергәләшеп күтәрәләр. Бары да, югы да, кайгысы да, шатлыгы да — уртак.

Шырпы булмау авыл халкын тагын да ныграк туганлаштырды, йорт борынча, чиратлашып, ут саклыйлар иде. Иртән торасың да, яланаякка киез итек кенә элеп, соскыч тотып, күршегә чабасың. «Ни йомыш?» — дип сорап торучы юк, учактан утлы күмер тутыралар.

— Сабыр атла! Бияләең белән каплап бар!

Икенче көнне синең ишекне кагалар, кешеләргә син саклап калган ут кирәк.

Сабынсызлыкка да чара табылды: селте ясыйлар иде. Селтенең утын көленнән кайнатылганы шәп. Тик безнең Иске Роман авылында утын дигәнең теш казырлык кына. Төп ягулык — тирес кирпече. Аны җәйнең иң кызу көннәрендә бала-чага суга. Пычрак эш, көнендә бетүе хәерле дип, без аны тирә-күршеләр белән берләшеп, балалар өмәсендә суга идек. Олы-олы станнарга шыплап тутырылган лычма тиресне ташый-ташый баштанаяк пычранасың. Аруның чиге-чамасы бөтенләй югала. Әмма күршеләрең белән бергә булу, андагы уен-көлке, тиресне үзләндерер өчен таптаганда әйтелә торган шаян такмаклар — кая ул күңелсезләнеп тору! Бии-бии эшлисең!

Тирес утынының җылысыннан да рәхәтрәк җылылык юктыр кебек. Аның белән кыздырылган мичтә «тәгәрәткән» бәрәңге, «тыш бәлеш» шәп пешә. «Тыш бәлеш»не каз өмәләре вакытында салалар. Бәрәңгесен бик вак-лап турап, суганын-борычын кушып, аңа казның эч-башын бутап (казның түшкәсе базарга китә), тирән табага тутыралар да өстенә генә җәймә кап-

лыйлар. Бәлеш тышына җитәрлек он юк. Тирес утыны белән җылытылган мичтә көне буе утыра-утыра тәмам чын бәлеш хәленә килә ул. Ни дисәң дә, шәп иде ул тирес утыны, тик аның көле селте ясарга ярамый. Халык, селте өчен, утын көлен я мәктәп, я колхоз идарәсе мичennән ала. Җыештыручылар чират сыман нәрсә саклый. Берәрсе, әрсезләнеп, ешрак килә башласа, туп-туры әйтәләр:

— Юк, канатым, бүгенге көл — Кәҗә Минһаҗларына тиеш!

Мең дә бер житешмәүчәнлекне җиңәрдәй тапкырлык, шул хәлләрдә дә гаделлеккә хилафлык китермәү сагынып сөйләрлек түгелмени?!

Йорт башына кашыклап бүлгәндәй, аз-азлап кына бирелә торган керосинны мөмкин кадәр озаккарак җиткерү өчен ниләр генә уйлап чыгармады халык?! «Болары чүмечләп чөмерә», дип, затлыдан саналган «егермеле», «утызлы» лампаларны чормага ук менгезеп элделәр. Бераздан «унлы»сы да «ялга» чыкты, «җиделе» лампаның куыгы белән челтәрен салдырып «сукырайттылар», Аннары аны да йорт саен түгел, 5-10 йортка берне генә үрләтеп кич утырулар башлап җибәрделәр. «Унйортлыклар» дип аталган бу «якты» өйләргә хатыннар бала-чагасын да ияртеп керә. Алары дәрес карый, аналар оекбаш бәйли, ямау ямый. Бәйрәм якынлашса, әлеге йортларда, колхоз идарәсе кушуы буенча, сыйлы мәҗлесләр дә үткәргәлиләр иде. Кемнең кайсы йортта бәйрәм итүе алдан билгеләнә:

— Җиденче ноябрьдә, җыелыштан соң, Рәһбәр апаларда утырабыз. Колхоз кеше башына берәр стакан он бирә, калганы — үзебездән...

Безнең ише бала-чаганы аерып чакыру гадәте юк, апаларга ялынып, алар чабуына тагылып бару ягын чамалыйсың. Кем ничек җаен тапкандыр, әмма ләкин мәҗлесле йортта унбиш-егерме җиткән кыз булса, балалар да шуннан ким җыелмый. Аерма шунда гына: апалар — түрдә, без мич артына белән сәндерәне «яулап» алабыз. Безгә бит аның әллә ни кадер-хөрмәте кирәкми, җырлауларын тыңлап, биюләрен, гармунчы абыйның, чибәр кызларга күз кыскалап, аяк тибә-тибә уйнаганын карап торырга булса — җитеп ашкан. Шулай да, мәҗлеснең төп кунаклары табын тирәсенә тезелешкәндә, хуҗа апа безне дә кече як сәкесенә чакыра. Безгә ым кагучы гына кирәк — сәкенең иң арттагы тактасына менеп, кош балалары кебек, кунаклыйбыз.

Ул табыннарда егет-кызларның ни дәрәҗәдә тыйнак, сабыр утыруларын күрсәгез иде! Алар, күңелләре бик кирәксенсә дә, пар-пар булып бүленмиләр, кая ул?! Егетләрне өстәлнең түр ягына чакыралар, кызлар түбән якка тезелә. (Бездә әле хәзер дә, хәтта парлылар мәҗлесендә дә, ир-атлар белән кыз-хатыннар табынның төрле тарафларына утыралар).

Егетләрнең күбесе үз теләгәненең каршына утыра. Утыра да, җан сөйгәненнән күзен ала алмый, гел текәлеп тора. Кызның, бичараның, хәле мөшкел, читлеккә эләккән кош кебек, егет карашының кайнарлыгына түзәр хәле калмыйча, керфекләрен аска ия, йөзе комач, уттай яна. И-и, ул мөнәсәбәтләренең самимилеге! И-и, ул бәхетле бичаралар! Бер-берсенә иң кирәкле сүзләрен дә әйтергә кыймыйча таралышалар иде бит! Кызлары алдан кулъяулык чигеп, перчатка бәйләп тә килгәли. Тик аны ничек тапшырырга?

Менә шул четерекле мәсьәләне хәл кылганда бездәй гөнаһсыз сабыйларның дәрәҗәсе арта инде. Егет яки апа кеше, мич арасына кереп, синнән анымоны сораштыргалый башласа, һич шикләнмә, бу — аның сиңа бик зур йомышы бар дигән сүз: я хат кисәген, я кулъяулык-перчатка кебек бүләкне, берәүгә дә сиздермичә генә, тегенең җан сөйгәненә тапшырырга кирәк. Юк, апалар безне бер дә юкка гына ияртеп йөрмиләр иде, һич юк!

Тик, ни дисәң дә, апаң сине «тулы хокуклы» кунак итеп ияртсен өчен, алдан ук хуҗабикәгә үз өлешеңнең тапшырылуы яхшы. Ул чаклардагы такы-токы «хәзинә»дән кунак табынына тиң булырлык нинди өлеш чыгарырга соң? Шул каһәр суккан сорау ел саен безне тәмам гаҗизләндерә иде. Хәтеремдә: берсендә уртанчы апам миңа кырт кисеп әйтте:

— Салышырга дигән ашамлык табу — синең эш. Тапмасаң, алып бармыйм.

— Ярар, апа, табам! — Миңа «алып бармыйм»нан да куркыныч сүз юк, шуңа күрә алдын-артын уйлап тормадым.— Табам да, Рәһбәр апаларга илтеп тә кайтам, апа, борчылма!

Апам, тонык кына елмайгандай итеп, күз сирпеп кенә алды. Мыскыллы карашы аңлашыла: өйдә коштабакка тутырып кына башка кешегә илтеп бирерлек затлы ашамлык юк. Бар ул әнә бәрәңге, кабак — идән асты тулы. Мәҗлес буласы йортка ит, май, йомырка кебегрәк нәрсәләр кулай. Алары

безнең өйдә — им урынына гына. Безнең эти: «Көн-төн абзарда әвәрә килгән кеше педагог була алмый!» — дип, гомер буе мал-туарны аз асрау ягында иде. Андый йортта нинди ашамлык артсын?!

Төрлесен уйлыйм, баш ватам, тик бу хакта эти-әнигә әйтү юк. Бик яхшы беләм: алар безне мәҗлесләргә йөртү ягында түгел. Әле тагын «ашамлык» кирәген дә сизсәләр, һич икеләнүсез:

— Беркая да бармыйсыз! — диячәкләр.— Башыгыз яшь, йөрисе мәҗлесләрегез — алда!

Шулай итеп, «ашамлык табу» мәсьәләсе каршында мин япа-ялгыз калдым. Башымда гел шул уй бөтерелә: «Нәрсә генә табарга? Ничек кенә мәҗлескә әләгергә?! «Әти-әниләр өйдә юк чакта кеше кулына тоттырырлык, кунак табынына өлеш булып өстәлерлек берәр ашамлык килеп чыкмасмы, дип, өйнең, чоланның астын-өскә китерәм. Ниһаять, таптым! Апа белән киңәшеп алырга да илтеп тапшырырга! Мич арасыннан атылып чыктым да:

— Апа! — дип кычкырып салдым.

— Ни бар? — Апа дәрес әзерләп утырган җиреннән, теләр-теләмәс кенә башын күтәрде.— Борчыма әле, сеңлем!

— Юк, апа, борчымыйм. Әйт кенә: суган — ашамлыкмы?

— Ашамлык, ашамлык.— Ул, әлбәттә, минем бу сорауның ник бирелүен сизмәгәндер.— Бар әле, мәсьәләне чишә алмыйм, кит әле!

— Китәм, апа, китәм.

Мич артына кабаттан кереп киттем дә тукмак башы кадәр суганнар үрелгән метр буйлык теземне кадактан ычкындырдым. Монда андый теземнәр күп, берсенең алынуын әни сизмәячәк. Киез итекне элдем, туганнан туган апа биргән иске, киң бишмәтне кидем. Эчтән муенга суган бәйләмен тактым. Авыр, муенны кисә, тик түзмичә ярамый. Ничек җитте шулай чыгып шылдым. Арт юллар буйлатып Рәһбәр апаларга да барып җиттем. Кирә керешли үк, баһадирларча кычкырып:

— Менә, Рәһбәр апа, бәйрәм табынына — Чәчәк апа белән минем өлеш! — дип, суган теземен бие белән идәнгә сузып салдым.

Бер агарды, бер кызарды Рәһбәр апа. Бәйләмгә күз генә төшереп алды. Сабыр атлап, ишек төбендәге сәке читенә килеп утырды. Актан-карадан сүз әйтмәде. Мин чыгып китү ягына борылдым. «Сау булыгыз!» — дигәндә генә кабат аңа карап алдым: Рәһбәр апа елый иде. Берничә көннән, кызыксынып, мич буендагы суган тезмәләренә күз салган идем, исем китте. Мин бушаткан кадакта суган бәйләме кабаттан эленеп тора. Күрдем дә оныттым, дигәндәй, ул чакта мине анысы бик кызыксындырмаган иде. Хәзер генә баш ватам: кай арада, кем, ничек кире китереп элгән ул бәйләмне?! Бәйрәм мәҗлесендә исә рәхәтләндек без. Җыр, бию, уеннар! Кунаклар ишектән керә-керешли үк уен-көлке башлый. Гармунчының кулы гына талмасын!

Бер мәртәбә җырлап-биеп алгач, табын тезәләр. Октябрь бәйрәмендә сый шактый мулдан була: каз шулпасында белбелдәп кенә күпертеп алынган токмач! Шулпалы бәлеш! Чәй янына — кабак бәлеше! Әле колхоз бал да биргән булса!..

— Әллә чәйне соңгарakka калдырыйкмы? — Табын мул күренсә, арадан берәү шундый тәкъдим кертә.— Уйныйк әле тагын!

Шуны гына көткәндәй гармунчы сыздырып җибәрә. Тотыналар уйнарга: йөзек салыш, күз бәйләш, «станок», әйлән-бәйлән. Кайбер уеннарда «җәза» бирешәләр дә анысы аерым-аерым җырлауга яки биюгә, ягъни ялгыз чыгышларга әйләнеп китә. Таң атканчы шулай.

Мондый мәҗлесләрдән таралышуы да бер тамаша. Кызлар өйне җыештыргалаганчы, егетләр капка төбендә көтеп тора. Гармун һич тукталмый. Колак салсаң, хәйран каласың. Әле аръяктагыларның җырлап таралуы ишетелә, әле түбән очныкылар сыздырып җибәрә. Авыл гөр килә. Кая ул бүгенге дискотека дигән, әллә кайсы чит-ят илләргә ияреп чыгарылган нәмәрсәләренә безнең чын халыкчан мәҗлесләрдәге җыр-биюләр белән тиңләшү! Гармунчыларыбыз, һәрчак диярлек, бүленгән: бездә — Гатин Сәгыйть, Локман абыйларда утыручылар Әпсәли бабайның иң оста улы Шәфикъны чакыралар, Нәҗми абый Садертдинов затлы табыннарга йөри. Укытучылар янында да гел ул була.

Укытучылар әлеге «унъйортлыклардан» үз эшләрендә бик оста файдаландылар, аларны әңгәмә урынына әйләндерделәр. Атнага бер мәртәбә, кич утыручылар янына барып, яңа газеталарны кычкырып укыйлар, хәл-әхвәл сорашалар, кешеләрнең кайгысын-шатлыгын уртаклашалар. Шунда ишетеп белгәннәренә таянып, колхоз идарәсеннән яки мәктәп дирекциясеннән кем-

гэдер ярдэм сорыйлар: берэүнең өен төзэттертэлэр, икенчесенең баласын укырга юллыйлар.

Ул елларда колхозчыларның, завод-фабрика эшчелэренең нинди батырлыклар күрсэтүе турында күп сөйлэнде. Норманы никадэр арттырып үтэгэннэр, күпме отыш ясалган — һэммэсе тиенгэ-тиен саналып, дэлиллэп бирелде. Авыл укытучыларының ул чактагы фидакарьлеген үлчэрдэй берэмлекне кайдан табарга?! Авылның нинди генэ мэшэкатен үз өслэренэ алмадылар алар?! Законда каралган елга ике айлык ялның ике көнен генэ үз хажэтлэренэ файдаландылар микэн? Юктыр, мөгаен. Агитация эшлэрен — әйтсэ дә түгел, шул ук вакытта, чалгы тотып, печэнен чабышу, ат җигеп, ашлык ташу, элеваторга йөрүлэр. Сентябрь җиттеме, дэрестэн соң классын җитэклэп, кырга, башак җыярга, бэрэңгесен алырга, кэбестэсен өзэргэ чыгып китэ. Кар төшкэнче шулай. Болар барысы да — аның төп эшенэ өстэмэлэр генэ бит. Алар бер генэ мизгелгэ дэ иң изге вазифаларын — авыл балаларының, бэхетлэрен сугыш урлаган нэүмиз җаннарның, язмышы алдындагы төп җаваплылыкларын онытмадылар. Хэзер һич икелэнмичэ әйтергэ була: авыл укытучылары бөек бурычларын намус белэн үтэп чыкты, туган ил сугыш китергэн авырлыклардан соң нэкъ менэ алар тэрбиялэгэн көчле рухлы, тугры күңелле, уңган егет-кызларга таянып аякка басты. Шул укытучыларны ничек сагынмыйсың?!

Якшэмбе җиттеме, халык клубка агыла иде. Аны җылытырга утын юк. Барысы да телогрейка кигэн килеш утыра. Зуррак класс укучыларыннан берэү — гармун, аръякныкы сукыр Ибраһим абый скрипка сыздыра. Ул елларда нинди генэ җырлар, уеннар чыкмады?! Берэве Чистайдан ишетеп кайта, икенчесе күрше авылга барган җиреннэн отып ала, кайбер уен-җырлар «Идел аръягыннан» ук килеп ирешэ. Барысы да үзэгеңэ үтэрлек моңлы яки бөтен кайгы-хэсрэтеңне оныттырырлык шаян. Шулай булмаганда, аны кем отып азаплансын да бөтен авылга ишеттерерлек иттереп җырлап йөрсен?! «Көймэ генэ килэ генэ», «Бас эле станокка!», «Идел бит ул», «Рамай», «Хэтерлэ син, иркэм!», «Вэгъдэ»...

Һэвэскэрлэр ел саен район күлэм ярыш — «олимпиада» — уздыралар. Монда соңгы елларда чыккан җырлар гына җитми, борынгыларны да искэ төшерэлэр. Махсус җыр китаплары юк, кем нэрсэне белэ, шуны башкара. Минем энине дэ җырлаталар иде. Ул «Эскадрон», «Ашказар» кебек озын көйлэргэ җырлый. Гармунчысыз гына. Ак кофтасын, кара костюмын киеп, шомырт кара чэчлэрен шомартып тараган килеш, горур кыяфэттэ сэхнэ уртасына чыгып баса да:

*...Җанкай-җанаш китте, ай, сунарга,—*

дип суза,—

*Ашказаркай буена ла чэшкегэ.*
*Чэшкелэргэ китеп вафат булды,*
*Ялгыз башым калды ла яшь көйгэ.*

Сулыш та алмыйча тыңлыйлар. Бераздан, сунарчы юлында түгел, Бөек Ватан сугышында һэлак булган ирлэрнең яшь-яшь көенчэ «ялгыз башы» калган хатыннары «мышык-мышык» елый башлый.

Концертның уртасында «пирамида» дигэн бер чыгыш бар. Анда, хэзергечэ әйтсэк, авылның гимнастлары үз осталыкларын күрсэтэ. Әүвэл иң көчле өч-дүрт малай идэнгэ тезлэнэ. Алар тезенэ кечерэклэр үрмэли. Шулай берничэ катлам өелгэч, иң өскэ кеп-кечкенэ бер генэ «гимнаст»ны күтэрэлэр. Ул — залга кичэнең иң мөһим өндэмэсен «ташларга» тиеш: «Яшэсен Бөек Октябрь социалистик революциясенең 27 еллыгы!» Халык «ду-у» килеп кул чаба.

Кайчагында: «Менэ, менэ, үзе кечкенэ, үзе ябык!» — дип, бу түбэгэ мине дэ менгезэлэр иде. «Шанлы Кызыл Армиягэ — дан!» — дип, бар куэткэ кычкырасың да, кул чаба башлауларына, «дөп» иттереп сикереп төшэсең. Идэн — боз. Син яланаяк. Астагы «гимнастларга» җиңелгэ килсен өчен, синең киемнэрнең дэ иң кирэклесен генэ калдырганнар. Дер-дер калтырата. Шуңа күрэ, аяк идэнгэ тиюгэ, сэхнэ артына йөгерэсең. Анда иске булса да, җылы бишмэт, астына салган булса да, олы киез итек бар, ичмаса.

Укытучылар авыл яшьлэре, укучылар белэн берлектэ «Галиябану», «Ташкыннар», «Мактаулы заман», «Мэрьям», «Изге эманэт», «Гөлзадэ», «Кайту» кебек пьесаларны да сэхнэлэштерэлэр иде. Тукайның «Шүрэле»сен, «Су анасы»н, «Бала белэн күбэлэге»н дэ спектакль итеп куйгалыйлар. Сце-

нарий дигәнен кем язган, костюмеры кем булган да декорациясен кем ясаган? Хәзер мондый чыгышлар әзерләнсә, Казан, Уфа, хәтта Мәскәү капкаларын кагалар. Һәвәскәрләрнең бер кулмәге генә дә йөзләрчә сумга төшә. Безнең авыл спектакльләре исә Иске Роман кешеләренең сандык төбендә сакланган әйберләре белән куела: Гайнижамал әбинең яшел хәтфә камзулы, Биктимер бабайның бәрхет кәләпүше, Галия апаның чигүле калфагы, Гомәр абыйның соры шинеле белән кызыл йолдызлы пилоткасы... Бу кичәләр авылны тагын бер кат туганлаштыра, мәшәкать уртак куанычка әйләнә иде.

Спектакльләрдән соң гомуми уеннар башлана. Гармунчы гына чыдасын да скрипкачы Ибраһим абый гына кайтып китә күрмәсен! Аһ, кайда икән ул скрипка, кайда икән ул гармуннар? Авылга кайтып, бот буе малайларның җилпуч кадәре магнитофон кычкыртып, мактанып йөрүен күргән саен, Әпсәли бабайның кош кадәре генә иске гармуныннан бөтен авылга сирпелгән моң сагындыра. Кулдан килсә, шул ял кичәләренең берсен генә (!) кабат күрер идем. Гәүдәмнең салмакланганлыгыннан тарсынып тормыйча, ерак еллар «пирамидасы» түбәсенә очыплар гына менәр идем дә, быелгы иң зур бәйрәмебезне хуплау йөзеннән, халкыма һәм Октябрьгә булган тирән рәхмәтемне белдереп: «Яшәсен Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгы!» дип, ихлас күңелдән өндәмә ташлар идем. Кешеләрнең биеккә, яктыга омтылуын раслагандай ясала торган шушы «пирамида»лар да сагындырыр дип кем уйлаган?!

Аптыраш: дөньялар тынычланып, тормыш-көнкүреш рәтләнгән саен, җанны рәхәтләндерүчән кадерле нәрсәләребез ераклаша, югала барган икән бит. Каргалы урта мәктәбенең белемле укытучылары — Зөфәр Әхмәдиев, Зәкия Хәмитова, Хатыйп Җәүһәров, Рияз Мәхмүдов «Шүрәле»не сәхнәләштерү белән шөгыльләнмиләр иде инде. Болар җитди рәвештә безне киләчәккә әзерли. Университетта без фән докторларын, фән кандидатларын тыңлый башладык: Латыйф Җәләй, Мансур Габдрахманов, Дмитрий Морозов, Хатыйп Госман, Якуб Агишев, Хәмит Ярми... Шәп укытучыларга туры килдек без. Фәнгә, әдәбиятка тартулары бер хәл, алар үз-үзләрен тотышлары, студентларга кайгыртучан карашлары белән дә күпкә өйрәттеләр.

Бу укытучылар янында нииндидер яманлык кылырга мөмкин дә түгел кебек иде. Шулай да берсендә, инде өлкән курс студентлары булып җитешкәч, группабыздан кайсыдыр кызның туган көн мәҗлесен үткәрергә тәвәккәлләдек. Күбебез моңарчы андый гадәтнең ни икәнен дә белмәгән. Шәһәр шаукымына бирелеп, ясап карамакчы булдык. Үзебез салып кергән тулай торакның әлеге кыз яши торган бүлмәсендә табын әзерләдек. Күп кенә винегрет ясадык, үрдәк ите турап, дөге боткасы пешердек. Чәй янына — маргарин ягылган ипи белән шикәр комы.

Кунакка һәммәбез — группаның егерме егете һәм җиде кызы чакырулы. Мәҗлес башланыр алдыннан гына егетләрнең берсе өч литрлы алюмин чәйнекне сорап алып чыгып китте: имеш егетләр дә табынга күчтәнәч кертмәкче була. Озак үтми, әйләнеп тә кайттылар. Чәйнекне мөлдерәмә тутырып кызыл аракы алганнар. Ул чакта аны иске киоскларда кружкалап саталар. Безнең халык, ул якка күз салырга да куркып, аларны ерактан уратып уза иде. Инде менә үз егетләребез, оялмыйча, шунда барган! Резеда исемле кызыбыз, барыбызның да фикерен белдереп:

— Ә-ә, сез әле шундыйлармыни, егетләр? — дип сүз башлады.— Сез эчкечеләрмени әле?

— Эчкән кеше юк бит әле! — Егетләрнең берсе җаваплылыкны үз өстенә алды.— Ярар, кирәкмәгән сүзне озакка сузмыйк! Утырышыйк!

Дәү чәйнекне өстәл астына шуыттылар. Без винегретны бүлеп чыктык, уртага боткалы кастрүлне китереп утырттык. Бүлмәне үрдәк итенең хуш исе тутырды. Туган көн иясенә теләкләр ява башлады. Барыбыз исеменнән алынган китап — Муса Җәлилнең сайланма шигырьләр җыентыгын тапшырдык. Шул арада егетләрнең берсе чәйнектәге кызыл сыекны безнең чынаякларга коеп та өлгергән. Сүзсез генә һәрберебезнең алдына куеп-куеп чыктылар. Резедабыз тагын безнең фикерне аңлату әмәлен тапты:

— Абау, мәхәббәтсезнең исе, фу! — диде.— Табынның ямен җибәрә күрмәсен! — ул чынаягын читкә этте.

Бу хәрәкәт эчемлекнең ямьшын бөтенләйгә хәл итте. Кызлар аңа ирен дә тидермәделәр, егетләрнең дә, тәвәккәлләп татып карарга кыюлыгы табылмады. Шигырь сөйләүләр, җырлаулар дәвам итте. Ниһаять, чәй эчәр чак җитте.

— Чәйнек, кирәк, егетләр!

Бу сүздән соң табынга ят сый кертергә өтәләнеп йөргән егет үзе үк, чәйнекнең мөлдерәмә кызыл аракысын, туалет бүлмәсендә түгеп, һәйбәтләп, чайкатып, аңа ару су тутырып керде.

Менә шулай. Биш ел бергә укып, без егерме егетебезнең берсен генә дә эчкән хәлдә күрмәдек. Эчмәделәр алар. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: безнең буынның саф күңелле, ап-аек егетләре, соңыннан, сиздертмичә генә канат җәеп җибәргән эчкечелек шаукымына, мәйданга әзерлексез килеп кергән көрәшче кебек, һичнинди күнекмәсез каршы торырга мәҗбүр иде. Бу хәл кайберәүләр язмышына кара күләгә булып капланды. Укытучыларыбыз да ул хакта уйланмаган икән. Аларның кайгыртучанлыгы күбрәк безнең укуга, эшкә бәйле рәвештә гәүдәләнә иде.

Диплом эшемә өстәмәләр эзләп, Габделҗаббар Кандалыйның туган ягына җыенганда, Җәләй ага миңа күз салды да: «Бар, безгә кереп чык,— диде.— Хатын киез итекләр бирер. Ульяновскида кар күп быел, бу ботинкалар белән йөрсәң, аяксыз калырсың»...

«Азат хатын» журналында эшли башлагач, кафедрабыз мөдире Хатыйп ага: «Төшкән урыныңда таш бул! — дип шалтыратты.— Моны яшь киленнәргә әйтәләр. Мин күчермә мәгънәдә кулланам. Яратып, озак итеп эшлә!»

— Бир әле бер хикәяңне! — дип, «Татарстан яшьләре» газетасының баш редакторы язучы Барлас Камалов килеп керде.— Безнең укучылар ничек кабул итәр икән?

Анда чыккан «Имтихан» исемле хикәямне тотып Нәкый ага Исәнбәт килде. Авызы-күзе көлә. Минем әдәбиятта «тәпи басып» китүемә сабый баладай шатланган. Хикәянең өстенә карарлык түгел, карандаш белән әллә нинди тамгалар төшерелгән.

— Телеңдә инверсия күп,— дип аңлатты Нәкый ага.— Безнең телгә ят нәрсә, халык телендә сирәк очрый. Белеп куллан!..

20-25 еллык ераклыкта калган шул кадерле мизгелләрне ничек сагынмыйсың?! Бездәйләрнең беренче китапларын Язучылар союзының проза секциясендә тикшергәндә заманыбызның алтын баганасыдай әдипләре җыела иде: Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Шәйхи Маннур, Гази Кашшаф, Фатих Хөсни, Габдрахман Минский, Абдулла Әхмәт, Гариф Гобәй, Афзал Шамов... Секция эшләренә Барлас Камалов җитәкчелек итә. Ул һәм аның яшьтәшләре, инде шактый тәҗрибәле язучылар булсалар да, өлкәннәр тирәсендә итәк-чабуларын җыеп кына йөриләр. Безгә исә алары да бик дәү күренә, алар да безгә бик игътибарлы, киңәш бирергә, ярдәм итәргә әзерләр.

«Зәңгәр күлмәк» дигән беренче китабым чыккач, язучы Газиз Мөхәммәтшин «Социалистик Татарстан» газетасында зур мәкалә бастырды. Авторның иҗатымны хуплавы, изге теләктә икәнлеге язманың исеменнән үк күренә: «Кояшлар яктырак янсын!»

Берсеннән-берсе кадерлерәк бу остазлар үзләрендәге осталык серләрен, һич кызганусыз, безгә дә иңдерүне төп максатларыннан саныйлар иде кебек. Алар үрнәгендә без дә кечеләрне якларга, аларга шәфкать күрсәтергә омтылдык. Әле авыл кешеләре үк әйтәләр иде: яхшылык эшләве авыр, шуңа ирешергә тырышыгыз! диләр иде. Явызлыкка тәһарәт кирәкми, анысына дөнья үзе мәҗбүр дә итә әле.

Шул ук вакытта гаделлек өчен көрәшергә кирәклекне дә һаман искәртә килделәр. «Азат хатын» журналында эшли башлагач, һөнәрем мөмкинлекләреннән файдаланып, мин дә, шул максатны алга куеп, кыерсытылганнарны якларга тотындым. Беренче язмаларым арасында ук усал фельетоннар, тәнкыйть мәкаләләре дә бар: «Балаларың үзеңә охшамасын!», «Сезме бу, ата белән ана?», «Оятсыз куллар», «Җиде карт», «Шагыйрь белән мулла»...

Көннәрдән бер көнне мине республиканың идеология җитәкчесе үзе (!) чакыртты. Идәненә затлы келәм җәелгән бик җайлы, җылы, якты бүлмәдә дистәләгән урындыклар тезелеп торса да, утырырга тәкъдим ясамыйча, йөзгә бәреп сорау яудырырга тотынды:

— Яшь кенә башың белән шундыен да кара тапларны кайдан табасың син? Миһербансыз балалар, зиначы хатыннар, азгын ирләр... Социалистик җәмгыять мәнфәгатьләренә муафыйкмы болар? — Ул Урта Азия халыклары теленә хас төсмерләр белән сөйли иде.— Кем ул сине университетта шуңа өйрәтте? Ник журнал сәхифәләренә күләгә төшерәсең?..

Егылып китә яздым. Егылмадым, ярамый иде. Мин туган елны әтинең

тәрәзәсен шакучы кеше искә төште. Бу коточкыч фикерләргә каршы тору теләге уянды. Юк, мине укучыларыма каршы куярлык дәлилләре юк иде аның. Мин әле укый башламас борын: «Октябрят булам!» — дип, сугыштагы абыйдан калган кызыл йолдызлы бер значокны сакладым. Укый башлагач, октябряты да, пионеры да, комсомолы да миндәйләрне үз сафына алды, үзе тәрбияләде. Җырларыбыз шаһит! Тәнәфес вакытларында иске мәктәпнең караңгы коридорын яңгыратып:

*Без туганбыз октябрьдә, без — Октябрь баласы.*
*Октябрьдә туганнарның Ленин була бабасы! —*

дип җырлый идек. Һәм мин «Октябрь баласы» булудан, Ленин бабайны иң якын бабам итеп санаудан ярты мизгелгә дә тукталмам. Язмаларым турында яман фикер кайдан чыккан? Нишләп мин бердәнбер социалистик Ватанымны тапларга тырышыйм ди әле? Шуңа охшашрак фикерләрне җитәкче затка да аңлатырга теләдем:

— Киресенчә, миң Татарстанны тагын да матуррак итәргә теләп язам. Редакциягә килгән хатларга таянып, укучылар үтенечен искә алып, яман гадәтләрне фаш итмәкче идем...

— Монда бәхәсләшмиләр! — Олуг җитәкченең тавышы галәмәт кырыс иде.— Тыныч кына эшлисең килсә, якты якларны мактап яз, андыйларны таба алмасаң...

Ул тукталыбрак торды. Хәер, мин аңлаган идем инде. «Таба алмасаң, матбугатта эзең булмасын!» — димәкче ул. Әйе, әйе, мин инде сабыйлыктан чыккан, дөньяның гыйбрәтле якларын да күргәләгән инде.

...Бер язда безнең бер баз бәрәңге харап булды. Белсәгез иде: ул елларда язын бәрәңге базын ачкан көнне ничек көтә идек! Ул көнне шалкан кебек шыгырдап торган бәрәңгене казан тутырып пешерәләр. Исәпләп-чамалап тору юк ул көнне. Алдыңа бер чынаяк сөт тә куела. «Шикәр тәмнәре килә!» — ди-ди, мактый-мактый ашыйсың. Олылар да канәгать, айлар буе: «Суык тимәсме, су төшмәсме?» — дип, шикләнеп көтеп алган бәрәңге, ниһаять, табында.

Ул кайгылы язда да без, кечкенәләр, бәрәңге базы ачылу көнен шулай ук көтеп алган идек. Сәкедә авыз суларын чупылдатып утырабыз. Өйгә, зур капчыкны авызыннан тотырып, Энҗе апа кайтып керде. Керде дә, бусагага чүгәләп, үксеп җибәрде. Әни аны ачуланырга тотынды:

— И кызым, тилердеңме әллә, шул тамаша авыр күтәрмәсәң?

— Буш шырпы кабы кебек бит ул. Базның төбенә кадәр төштек, бер таза бәрәңге дә юк. Әллә тычкан, әллә күсе харап иткән...

Өзелдек тә калдык. Көндәлек ашау ягын ничек хәл иткәннәрдер, белмим. Анысы шул гел ашыйсы килеп тору булып хәтергә уелган. Тик бу юлы анысыннан зуррак хәсрәт басты — бакчага ни чәчәргә? Өйдә бер мәл «аһ-ваһ» килеп алдылар да бөтенләй сөйләшмәс булдылар. Чарасызлык дигән нәрсә изсә дә изә икән адәм баласын! Шундый өнсез көннәребезнең берсендә иртән иртүк безгә Садыйк бабай килеп керде. «Камал Садыйгы» дип йөртәләр иде аны. Керде дә:

— Әйдә, Закир кордаш! — диде.— Чыгып ал, кул арбасына салып китердем, орлыкка ярамаслык түгел.Ваклыкка — вак инде, бишташ кебек кенә, терлек-туарга дигән бәрәңге иде. Орлыксыз калгансың дип ишеттем, ничек терлеккә ашатыйм инде? Әйдә!

Әти урыныннан кузгалмый торды. Аннары:

— Ала алмыйм, Садыйк абзый,— диде.— Директор булгач, күп төшерә, дип уйлыйсыңдыр. Айлык хезмәт хакым өч йөз илле сум минем, синең бәрәңгенең поты — алты йөз. Ничек түлим?

— Синнән акча сораган кеше юк бит әле, түләрсең җаең белән.

Котылдык бит баладән! Укытучыларга бирелә торган унбиш сотыйлы бакчаны тутырып утырттык. Тик безне һәлакәттән коткарган Садыйк абзыйга дигән бурычны аның үз кулына тапшыра алмады әти. Бакчага бәйле язгы эшләр тәгәлләнер-тәгәлләнмәс бер арада, район үзәгеннән зур кешеләр килеп, җыен җыеп, уртага Садыйк бабайны бастырып: «Син кулаклыкны яңартмакчы булгансың!» — дип, рисвай итеп, аны авылдан сөрергә ясадылар. Сугыштан яңа гына кайткан сыңар аяклы улы Сәгыйть абый Камалов, куш култык таягында чайкала-чайкала, бабайны бераз озата барды. Халык, куркынып, читтән карап калды. Без, бала-чагалар, аны-моны уйламыйча, олау артыннан чаптык. Күпер төбенә җиткәч, Сәгыйть абый баганага барып

сәялде. Аска иелгән башындагы коңгырт бөдрәләре күзләрен каплады. Шулай да йөзенең җыерылып килүен, җыерчыклары буйлап күз яше саркуын күреп була иде. Сәбәбен генә ачыклавы читен: әллә фронтта өзелгән аягының җәрәхәте сызлый, әллә әтисен югалтуга бәгыре сыкрый? Сызланырлык та, сыкранырлык та булган икән шул. Соңыннан: «Камалов Садыйкның гаебе юк».— дигән кәгазь килсә дә, бабай үзе авылга әйләнеп кайта алмады, ерак якта үлеп калды...

Җитәкчемнең кисәтүеннән соң мин, ихтыярсыздан, шушындый күңелсезлекләрне искә төшереп, бераз онытылып киткәнмен. Кабат тыңлый башлаганымда ул минем өчен «якты темалар» саный иде:

— Беткәнмени хезмәт батырлары? Әзли белергә, күрергә кирәк!

Күрмәгән кая ул! Без балигъ булгалаганчы, тирә-юнебезнең матураюын без дә күрмәгәч, тагын кем күрсен дә кем сөенсен?!

Матди якны әйткән дә юк. Һәр яңа көн муллык өсти сыман. Колхозчыларга да хезмәт хакын акчалата түли башладылар, пенсияләр тәртипкә салынды. Кешеләр берсеннән-берсе уздырырга тырышып мал туплыйлар. Ул гынамы? Мин туган 1937 елны көлләре күккә очкан китаплар: Галимҗан Ибраһимов, Тинчурин, Бурнаш, Бабич әсәрләре күптән безнең китапханәләрне баетты. Хәсән ага Туфан үзе безнең янда йөри, яңа әсәрләр яза иде инде.

Күрмәгән кая ул күркәм яңалыкларны! Татарстан ата-баба белмәгән төзелешләр җәелдереп җибәрде: Зәй ГРЭСе, «Оргсинтез» заводлары тезмәсе, Түбән Кама нефтехимия гиганты, КамАЗ... Аларны коручылар, анңары шунда эшләүчеләр телдән төшерми мактауга лаек. Язый, дигән кешегә «азык» — муеннан. Һәр җирдә җиңүчән адымнар гына эзләү язучыга да рәхәт ул. Хезмәте макталган каһарманнардан рәхмәт ишетәсең: КамАЗ кызлары, БАМ егетләре, Түбән Кама химиклары, авыл уңганнары миңа да мең рәхмәт яудырдылар. Мин булып мин, гомер буе авылда эшләгән гади укытучы баласы, Татарстанның Журналистлары һәм Язучылары союзына алындым. Чит илләргә сәяхәтләр ясадым: Европаның күп илләрендә, Африкада булдым, Мисыр пирамидаларын күрдем.

Бүгенгенең рәхәтен тоймаган кая! Тирес утыны ягып җылынучы безнең Иске Роман авылына газ керде. Аш-су өчен генә түгел, өй җылытырга да өч тиенлек газ ягалар. Элек без ерак чишмәдән көянтәләп ташый торган чәй суы да — өйләрдә, краны мич авызы янында гына. Бор да җаның теләгәнчә агыз! Электр, радио, телевизор, машина-мотоциклны малга да санамыйлар.

Безнең гаиләнең дә эшләре җайга салынды. Абый, берничә тапкыр яраланган булса да, башы сау килеш, Кызыл Йолдыз ордены, әллә ничә медаль тагып, әйләнеп кайтты. Әниебезгә, мәгариф өлкәсендәге тырышлыгы өчен, Ленин ордены бирделәр. Дөрес, хәзер, туксан яшенә якынлашканда, бераз өшәнде, шулай да, төпчегемнең илле яшьлегендә җилпенеп алмый булмас дип, борынгы калфагының сәйләннәрен төзәтеп утыра әле, кулында — чигеш энәсе. Җаны тыныч: дүрт баласы, җиде оныгы югары белемлеләр. Әтиебез генә, мин университетка кергән көннәрдә, дөньядан кичте. Төпчегем урнашсын инде дип көтеп яткан диярсең! Гаилә язмышына төшкән төп авырлыклар аның йөрәге аша үткән, аның җанын суырган, аның гомере бәрабәренә җиңелә килгән, күрәсең. Башкача була да алмый иде, әти бит ул, безнең әти бит ул!

Дөнья шундый: бер сөенечкә — мең көенеч. Дөнья каршылыкларны җиңә-җиңә генә алга бара ала. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә дә, син ихластан иҗат итәсең икән, тормыштагы көрәш килеп керә. Керә дә әсәрнең язмышын почмакка китереп тери. Дөресрәге, тери иде. Әлеге дә баягы, «җәмгыятьне каралап күрсәтмә!» дигән кагыйдәләр әсәрләргә юлны бикли дә куя иде. Минем 1971 елда язылган «Таңкәле тау» повестем, «совет галимнәре арасында конфликт юк», дигән киртәгә дучар булып, 1979 елда гына, анда да нык «кыркылып», дөнья күрде. «Синең өчен» исемле повестемда ятим кызның төрмәгә эләккән әнисе турындагы тулы бер бүлекне тоташы белән сызып ташларга туры килде. Газета-журналларда басылган хикәя, мәкалә, очеркларның кайберләре нинди корбаннар бәрабәренә чыгуын санап бетерү авыр. Миннән күпкә тәҗрибәлерәк, дәү-дәү агайлар да, әсәрнең дөнья күрүе хәерлерәк дип, кулъязмада күтәрелгән җитди мәсьәләләрне шомартып, тәнкыйть тезгенен ычкындырдылар.

Ниһаять, ул хаталануларыбыз фаш булды: без дилбегәне артык дәрәҗәдә бушатып җибәргәнбез икән шул. Бер карасаң, дөньябыз бөтен, бары да бар,

элекке җитешмәүчәнлекләр — гүя төндә күргән төш. Үлчәмнәребез үк башка. «Квартираның дүрт бүлмәлесе генә кирәк!» — дибез. Күпләр бүгенге муллыкның ни бәрабәренә килүен уйлап та бирми. «Беләбез инде! — диләр алар.— Ну, ипигә туймаганнар. Ну, өйләре салкын булган. Ну, чабата кигәннәр. Ну, тол калганнар. Калсалар соң? Инде миңа да интегергә димәгән бит!» Алар горур! Кайберәүләре, бәхаскә керсә, үзгеңә үткәрерлек иттереп әйтә дә сала:

— Мин синең кебек ачлы-туклы яшәп, ятим үсмәдем, беләсеңме? — Икенчесе аны хуплагандай иттерә:

— Минем нәселдә аксөякләр булган. Миндә шулар каны уйный, гади халык кергән ательега кереп күлмәк тектерер хәлем юк...

Бүгенге укучылар балачакта безнең төшләргә кереп йөдәткән ак күмәч белән мәктәп коридорында туплы уйный. Башкага ни сан, борын-борыннан халыкның иң күркәм сыйфатларын саклап яшәгән авыл хатыннары:

— Әй, күчтәнәч дигән булып, конфет ташымагыз! — диләр.— Анысы авыл кибетендә дә буа буарлык. Түгәрәк ипи алып кайтыгыз, арыш ипие, мич төбенә салынганын!

Ни химкәт: авыл кешесе аш-су әзерләргә иренә, өстәлләрендә — кибет ризыгы. Күбесе 50-55 яшьтән пенсиядә бит әле!

Сугыштан соң, тирән бер сулыш алгач, безнең әниләрнең кабаттан сала башлаган ипиен татып карасыннар иде алар! Эшкә киткәнче, караңгылы-яктылый ук өлгертәләр иде аны. Иртәнге чәйгә үк ипи камырыннан пешерелгән кайнар кабартма куела. Аны баздан чыккан сөт белән ашасаң... Аh, юк, мин аның ләззәтен сүз белән генә аңлатып бирә алмыйм! Берәр сәгатьтән өйгә зиһеннәрне чуалтырлык хуш ис тарала. Аннары, көле-күмере ияргәсен өчен, каз канаты белән сыйпый-сыйпый, мичтәге могҗизаны чыгаралар. Аш-су ягының тар сәкесенә тезелгән кояш-кояш ипиләрнең нуры бөтен урамны балкыта иде сыман!..

Болары бүгенге көн өчен бик вак булып калды. Акча, мал, модалы киемнәр, ике бозауга кибәк бүлеп бирә алмаган бәндәләрнең дәрәҗәле урын артыннан кууы китте. Кеше башына басып югары үрмәләү гадәткә әйләнде. Дилбегәнең бушаган ягыннан, без тел-теш тидермәскә, гел матур дип кенә күрергә һәм күрсәтергә мәҗбүр ителгән арада, җәмгыятебезгә чит-ят агымнар үтеп кергән: ялагайлык, күз буяучылык, ришвәтчелек, кода-кодагыйлык, битарафлык... Бер яктан баеганбыз, машиналарның яңадан-яңа маркаларын өйрәнәбез, алганда оттырырга исәп юк. Ул кием-салым, ул өй җиһазлары, ул табыннар муллыгы — күз тия күрмәсен! Табышларыбыз, ирешкәннәребез зур, аh, югалтуларыбыз да булмасачы! Өч тиенлек файда артыннан чапканда кешелектә иң кадерле исәпләнгән күркәм сыйфатларыбыз коелып бетә язган түгелме?

Алтмышынчы еллар башында «Азат хатын» журналы хезмәткәрләре мөхтәрәм язучыларны һәм журналистларны 8 Март мәҗлесенә җыя торган булды. Ел саен. Кичәдә җырлыйбыз, биибез, кызларның үзләре теккән күлмәкләргә, үзләре әзерләгән аш-суларга ярыш оештырабыз. Истәлекле бүләкләр өләшәбез. Монда һичнинди рәсмилек тә юк. Язучылар союзы председателе булган Мирсәй ага Әмир, сүз ала да: «Гыж-гыж курай тартаһың...» — дип, башкортча җырлап җибәрә иде. Фатих Хөсни — күршегә, таба сорарга кереп, шул зур табага утырып, тау шуа-шуа әнисенең йомышын онытып җибәргән малай турындагы моңсу хикәясен сөйли. Сибгат Хәким әнисенә күчтәнәч итеп җибәрер өчен клиндерләр эзләве хакындагы шигырен укый. Хәсән ага Туфан, кызларга карап: «...Кайсыгызның кулы җылы? Бәйлисе бар йөрәкне...» — дип сүз башлый. Шәриф Камал кызы Зәйнәп апа Байгильдиева «Чегән биюе»н башкара. Аннары барыбыз бергә җырлыйбыз.

Егерме еллар буе шулай дәвам итте. Инде күркәм бер гадәтебез артты, дип торганда гына, сүтелде 8 Март бәйрәмендәге якты кичәләр. Беренчел оештыручылар олыгайды, алар урынына килгәннәр майлы бәлешне, коллектив белән уртаклашмыйча, дәү агайлар белән үз өендә генә татый башлады. Кайберәүләр дөньядан ук китте. Яшьләр өлкәннәр белән берләшүне өнәмиләр инде.

Сагынып сөйләргә генә калды. 1978 елның 8 Мартында оештырылган соңгы очрашуларның берсендә Фатих ага Хөсни үтенече белән без «Олы юлның тузаны» җырын сузган идек. Фатих ага үзе дә кушылды. Алай гынамы, дирижер сыман селтәнеп, ул безнең җырлауны бер эзгә салып та торды. Аннары:

— Туктагыз, соңгы строфасы болай аның,— дип, радиода да, сәхнәләрдә дә ишетелмәгән сүзләрне җырлатты:

*...Олы юлдан атлар уза.*
*Безгә кала тузаны.*
*Алда да гомерләр бардыр.*
*Сагындыра узганы.*

Җыр беткәч, озак кына тынып тордык. Фатих аганың, еларга җитешеп, сагышланып калуы барыбызны да тетрәндергән иде...

Инде менә ул кичәләребез тукталганга да ун еллап вакыт узган. Ул чакта әле уен-көлкене хубрак күргән безнең буын да хәзер ешрак сагышлана, үткәннәрнең мәгънәсен тирәннәнрәк эзли.

Башыма сыймый: гомуми мәнфәгатькә күз йомарга, бер-беребезгә битараф булырга кай арада гына ияләнеп үк җиттек соң без? Тирә-юнебезне дошман урап алган, матди яктан өшәнгән елларда да сыгылып төшмәгән саф, нык, куәтле рухыбыз ничек болай такыраеп киткән?..

Бу хакта хәзер зурдан кубып, ил күләмендә сүз алып барабыз. Үзгәреш, кичекмәстән революцион (!) борылыш кирәк, дибез. Бөтенләй үк ялгышканчы, искә төшеп, дөреслеккә борылырга ниятләвебез әйбәт анысы. Чирен яшергән үләр, дигәндәй, инде хәзер дә «җәмгыятебез кара булып тасвирланмасын!» дип, борын төбендәге кырга сыймастай кыланмышларны күрмәмешкә салышып яши бирсәк, тагын да аянычрак булыр иде. Партия яман якларны башлап үзе фаш итте. Халык та бу көрәштәге һәр яңалык турында хәбәрдар булырга тиешлегенә басым ясалды. Әллә мәсьәләнең нәкъ менә шулай, кешелекле төстә алга куелуы нык тәэсир итте инде — күңелдә таштай укмашкан сагыш, еллар буе эчкә йота-йота юшкынга әйләнгән хафалар берьюлы искә төште. Ерак елларда авылдашларның саф, самими мөнәсәбәтләреннән татып-тоеп калган хисләр өр-яңадан сагындыра башлады.

Мин бик тирәннән аңлыйм: адәм баласы ачлы-туклы яшәр өчен тумаган. Юк, мине үткәндәгеләрнең казан-казан умач шулпасы, ямаулы киемнәре, кар базыдай салкын мәктәпләре сагындырмый. Кеше горур, ул бу яманлыкларны бөтенләй татымаска тиеш. Сагындырганы, бөтен вөҗүдемне биләп тартып торганы — халыкның бердәмлеге, адәм баласы чыдамаслык авырлыкларны җиңеп, күңел сафлыгын, әхлакый бөеклеген саклау көче!

Без, үз чиратыбыз җиткәч, ул елларда үзәккә үткән матди кытлыкларга каршы күтәрелдек. Әмма тамак туклыгы, өс бөтенлеге өчен генә яшәүнең мәгънәсе тар. Тук тормышның кешене кеше итеп танытучы күркәм сыйфатларны, буыннан-буынга, мең михнәт аша сакланып килгән рухи байлыкны таптап узарга хакы юк. Электәге күркәм гадәтләребезнең кадерен белеп, рухи хәзинәбезне тагын да тулыландыра барсак, өзлексез камилләштерсәк кенә, еллар узгач, безне дә сагынырлар. Хезмәтебез, омтылышларыбыз яктылыкка, фидакарьлеккә юнәлтелгән. Мин хәтта шаулы бүгенгенең ифрат тиз узуына да пошынам кебек инде. «Ник сагынам икән?» соравы да тикмәгә генә баш калкытмыйдыр, мөгаен. Тик... аңа җавап биреп бетерерлекмени? Бинибая катлаулы икән шул ул. Сорау җанланган саен, күңелдә җавабы да табыла сыман: и-и, нәрсәсен сорыйсың, яшьлекне сагынмыйлармыни инде? Сагындыра. Татлы, ләззәтле бер тойгы белән сагындыра. Капкасының кайдалыгы мәгълүм булса, шул татлы сагышны биргәне өчен генә дә, каршысына барып, бил бөгеп, рәхмәтләр укыр идем лә!..

*1987 ел.*

## Николай Морозов

# ТАУ СЫРТЛАРЫН КИСЕП...

Бу яклар табигате өчен гаҗәеп матур көн иде: явым-төшем юк, җиле дә әллә ни күздән яшь китерерлек үк түгел, тау түбәләрендә кургаш болытлар тын гына йөзә дә йөзә. Аларның агышы ара-тирә тукталып кала да җиргә көлтәсе белән кояш нурлары чәчелә.

Шундый балкышларның берсе вакытында Нургали тау сыртында бинһая биек ике багана күреп калды. Башларында алтынсу таҗлары да бар кебек. Бригада шунда тукталды. Юл түшәү җайланмасының моторы тынды. Бөтенесе сәер баганаларга карап тора башлады.

— Ни бу? Әллә ят планета иясе, безнең эшне хуплап, һәйкәл койганнармы? Анатолий Павлов көлеп җибәрде:

— Әй шәп тә инде минем якташлар! Сэргэ бит бу!

Барысы да комсомол оешмасы җитәкчесе якут егете Анатолийга борылды.

— Нәрсә соң ул — сэргэ?

— Улмы? Ул — кунакларның килүен хуплау билгесе! Без бит тиздән Амур өлкәсеннән Якутия җиренә аяк басабыз. БАМның корыч тасмалары якутларга зур юл ача, беренче поезд бүләк итә. Менә шул шатлыктан якутлар ак багана коеп өлгерткәннәр. Янәсе, рәхим итегез, хөрмәтле кешеләр, атыгызны бәйләр багана әзер: бәйләп куегыз да — өйгә, табын түренә узыгыз!..

Егетләргә рәхәт булып китте. Төньяк халкының бу матур гадәтенә шундый ук күркәм җавап та табарга иде. Тында-Беркакит юнәлешендә сузыла торган әлеге юлның Нургали Ягъфәров җитәкчелегендәге монтерлар бригадасында нинди генә милләт вәкиле юк: рус, украин, литвалы, поляк, немец, якут, еврей, татар...

Бригадир үз кешеләрен яхшы белә. Күзләренең очкынланып кабынуыннан ук аңлап алды: мондый чакта егетләрне әллә нинди фидакарьлеккә дә күндереп була. Тәвәккәлләп:

— Әһә! Сездегезме, егетләр?! — дип сүз башлады.— Бу бит безне ярышка чакыру сыман нәрсә. Алар бер төн эчендә, кеше-фәлән күргәләгәнче, сэргэ утыртып куя алганнар. Ә без икенче таң алдыннан «атларны бәйләп тә куйыйк», ягъни мәсәлән тимер юл рельсын Якутиягә чыгарып өлгертик!..

Бу — моңарчы күренмәгән тизлектә эшләргә чакыру иде. Бер тәүлектә, бик тырышканда да, 2000—2100 метрдан артык юл сузып булганы юк. Монда исә, кимендә, 2500 метр ара бар әле.

Бригаданың арада иң өлкән күренгән, сабыр холыклы кешесе Кәрим Гәрәев Нургалины бераз басылдырырга теләде:

— Тукта, таулар арасында эшләгәч тә, алай күккә үк ашма, җиргә төш әле! — диде.— Син нинди урыннардан узасы барын онытгыңмы әллә? Тигез ара булса бер хәл иде...

Нургали белә: бу төштә рельсларны боргалый-боргалый мең мәшәкатькә батачаклар алар.

— Белмәгән кая?! Беләм. Тәүлеккә 2500 метр рельс салу — гадәти эш түгел, әмма ләкин...— Ул егетләргә берәм-берәм карап чыкты.— Без дә төшеп калганнардан түгел бит! Көч-куәт тә, тәҗрибә дә, осталык та җитәрлек! Ә?!

Бригаданың данлы үткәнен барысы да яхшы хәтерли иде. Әле кайчан гына Тында шәһәренең «Юность» клубында булган җыелышта бригаданы күккә чөеп мактадылар.

Очучы-космонавт В. Лебедев бригадирга «Союз-13» кораблендә Җир тирәли әйләнешләр ясап кайткан вымпелны тапшырды. «Бу төзелеш — һәркем өчен зур сынау,— диде космонавт.— Һәм физик, һәм әхлакый яктан сыный ул кешене. Сез бәхетле, сез мондагы авырлыклардан көчлерәк булып чыктыгыз!

Ул чакта залда утыручылар арасында соңыннан, БАМ сынавына чыдый алмыйча, артка чигенүчеләр дә булды. Бәхеткә каршы, Ягъфәров бригадасында куркаклар күп түгел иде. 25 тән 3-4 әве генә туган якларга кире китеп барды. Гомумән, бу эшкә үз теләге белән алынучылар тырыш һәм түзем булып чыкты. Ул чакта аларга акча өчен килгән дип әйтү дә читен иде, чөнки беренче мәлдә әллә нинди өстенлекләр дә, өстәмә түләүләр дә булмады. Кыенлыклар исә, нинди кирәк шундые котеп алды. Баш тыгарга торагы гына да җитәрлек түгел иде. Тыгыз вагоннарда, тимер мичкә утын ягып, көчкә җан асрадылар. Аның каравы, монда меңнәрчә гитара сатылды. Күз ачкысыз буранарда эшләп, җеп өзәрлек тә хәле калмаган егетләр, шул вагоннарга кайтып, аз гына хәл алалар иде дә тотыналар иде чиртергә — чыдап кына тор! Җире маңгегә туңган бу якларда төшенке күңелле, пешеп җитмәгән адәмнәргә урын юк та кебек.

Дөрес, кайчак «Ура!» кычкыручылар да кыен хәлләрдә калгалады. Җаваплылыкның ни икәнен белмәгән агайларның таләбенә буйсынып, яшьләр: «Кирәк икән — кирәк! Булдырабыз аны!» дип, көн-төн тырышалар иде. Кушылган вакытка өлгертәләр. Тик һичнинди чамага да туры килмәгән тизлектә башкарылган эш, азактан кабат төзәтүләргә килеп тоташа. Салган өйнең стенасы ярыла, рельслардан локомотивлар янтаеп төшә, түшәлгән тротуар убылып, урам уртасында чокыр хасил була. Ул чакта бу хакта ачыктан-ачык сөйләү гадәте генә юк иде.

Ягъфәров бригадасы егетләре туры сүзлеләр, күңелләрендәген ярып салалар:

— Ашыкмыйк, рекорд артыннан куа-куа адәм көлкесенә калуың да бик ихтимал!

— Ашыккан ашка пешкән, диләр бит.

Каршы фикерләрне елмаеп кына тыңлап торды Нургали. Котә белергә дә кирәк. Ниһаять, аның теләгән хуплаучы сүзләргә дә чират җитте. Якут Толя Павлов:

— Их, егетләр! — дип башлады.— Сез минем халыкның бу юлны ничек көтеп торганын белсәгез иде! Әйдәгез, тырышып карыйк, ә!

Менә ичмасам, комсомол җитәкчесе! Кулыннан килсә, Нургали бөтен җитәкчеләргә дә Толядан кеше күңеленә юл яру алымнарын өйрәтер иде. Озын-озак сөйләшеп тә тормадылар. Тагын берничәсе хуплап сөйләгәндәй итте дә:

— Әйдә! — дип, бердәм кузгалдылар.— Безнең куллар ни генә эшләмәгән!

Егерме сәгать буе алга-артка карамый тырыштылар. 2400 метр юл салынган иде инде. Шул җитезлек аркасында бригада «алтын аралык» дип йөртелә торган соңгы 100 метрга рельс салу хокукын яулап алды. Югары дәрәҗәле мондый хокук өчен БАМ төзүчеләр арасында дүрт мең ярым кеше ярышка катнашкан иде. Шуңа күрә егетләрнең ни кадәр рухланганлыгын аңлау кыен түгел. Нургали хәтта, тышта салкын октябрь икәненә дә игътибар итмәстән, күлмәген дә салып ташлады. Иртән эсседән янып уянды, әмма авыру турында уйлап та тормады. Берничә атнадан соң бөтенләй башка сәбәп белән больницага эләккәч кенә, врачлар аның үпкә ялкынсынуын аяк өсте йөреп үткәрүенә «аһ!» иттеләр.

— Үзем дә белмим инде! — дип сөйли ул.— Ничек үткәреп җибәргәнмен? Андый чакта туктап калып булмый, ярамый! Миңа ул көннәрдә гаҗәеп бер очрашу көч бирде.— Нургали Ягъфәров иркенләп сөйли башлады.— Кичен безнең учак янына этләрен иярткән, мылтыгын аскан аучы килеп утырды. Русча авыр гына сөйләшә, үзе бик күп яшь яшәгәнгә охшый.

— Кеш артыннан йөри-йөри ераккарак кереп киткәнмен,— дип, үз хәлен аңлатып бирде ул.— Авылга иртән кайтырмын инде. Сезнең янда гына утырыйм әле!

— Без менә сезне тимер юллы итәчәкбез инде,— диештек.

— Моңа шатланырга да, кайгырырга да белгән юк — сезнең шау-шудан бөтен җәнлекләр качып бетте. Карт-коры да шикләнә.

— Шикләнсәң, төннәр буе йөрергә түгел иде.— Кайсыдыр егетебез әйтә куйды.— Мич башында ята бир!

— Әле син тумаган да чакта, минем ни белән шөгыльләнүемне беләсеңме соң син, энекәш?

— Кешләр аткансың инде, чәшкеләр, тиеннәр!..

— Менә ялгыштың. Мин дә нәкъ синең кебек үк юл салучы идем. Утыз өченче елда Транссибтан төньякка таба рельслар суза башладык...

Бабай түш кесәсеннән фоторәсемнәр чыгарды. Берсендә ул бик яшь. Һич танырлык та түгел. Анысы — утыз өченче елда алдырылган фото. Әгәр яңа фото күрсәтмәсә, аның сүзләренә ышануы да кыен иде. Янасында — бабай... БАМ төзүчеләрнең ин

зур житәкчеләре арасында басып тора. БАМ тирәлегеп үзләштерү мәсьәләләренә багышланган Бөтенсоюз конференциясенә катнашкан икән.

Шуны белгәч, якут бабаебыз белән әңгәмә бөтенләй башка төс алды. Әлеге бабай, Михаил Яковлевич Иванов, гаҗәеп кызыклы язмышка ия. Утыз өченче елны ул, кулына көрәк алып, Большой Невер станциясеннән бүген БАМ үзәге булган Тындага 180 чакрымлы юл сала башлаган. Өч ел эчендә юл әзер була. Тик 1942 елда мондагы рельсларны кире кубарып авыр хәлдәге Идел буена озаталар. 1972 елны юлны яңадан сала башладылар бит инде. Шулай итеп, без Михаил Яковлевичның эшен дәвам итүчеләр булып чыктык.

Хәзер бабай табигатьне саклау буенча зур эшләр майтарып йөри икән. Безнең учак янына килеп чыгуы да һич тә соңарудан түгел, җае барында, безгә мондагы табигатьнең кадере турында сөйләп калырга теләвеннән икән.

Нургали бераз туктап торды.

— Мин иң кирәгенә килеп җитә алмыйм әле,— диде ул аннары.— Карт иртән безгә тагын бер кызык нәрсә ачты.

— Беләсезме, егетләр,— диде.— Минем Мәскәүне күрәсем килә. Кызыл Мәйданга, Ленин мавзолеена барып баш ияр идем. Ашыга төшегез әле! Миндәй картларның озак көтәр чамалары юк.

Аның бу сүзләреннән соң ничек ялкауланып ятмак кирәк?!

* * *

Шулай да Нагорный поселогы янындагы хәлдән соң Ягъфәров больницага кереп ятарга мәҗбүр була. Монысы инде — Якутиягә җиткәннән соң булган хәл. Алар бригадасына 1240 метрлы тауны тишү тапшырыла. Озынлыгы аллә ни булмаса да, эш адым саен катлаулана, әле су ташкыны бәреп чыга, әле балчыгы ишелергә тотына. Бу Становой тау сыртын тишеп узучы Нагорный куышы хакында матбугатта кат-кат язылды. Егетләрнең эшен еш кына «каһарманлык» дип атыйлар иде. Һич тә арттыру булмаган икән.

Ягъфәров бригадасы азакны бер адым араның эшен бетерер алдыннан ифрат дәрәҗәдә текә җиргә килеп чыга. Рельс салынырга тиешле урында берәвесенең бүреге төшеп киткән икән, артыннан куып тота алмаганнар, тәгәрәгән дә тәгәрәгән. Мондый текәлек юл салу кагыйдәләренә һич сыймый. Егетләрнең моңа кадәр андыйны күргәннәре дә юк икән. Мин бу Становой сыртына ике тапкыр машина белән менеп төштем. Яннан Нургалиләр салган тимер юл үтә. Исем китте: ничек тәвәккәлләгәннәр?! Соңыннан миңа бу иңкүлектәге кебек тимер юлның дөньяда башка тиңе юклыгын әйттеләр.

Дөрес, эшкә тотынып алдыннан Ягъфәров бригадасына өстәмә көчләр бирәләр. Техниканың да яңасы килә. Юл салу җайланмасының тормозлары кат-кат тикшерелә, өстәп тепловоз да китерәләр — ышанычлырак булсын өчен. Әмма эшли башлагач, бары да кагыйдәләр кысасына гына һич сыймый. Моның булуы мөмкин дә түгел. Әйтик, әгәр БАМ дагы 4200 күпернең барысы да алдан бирелгән сызымнар нигезендә генә салынса, Якутия чиге әле бүген дә хыял булып калыр иде. «10-Мостострой» тресты управляющие Леонид Блинков, җаваплылыкны үз өстенә алып, сызымнарны читкә куеп тора. Күперләр багана нигезләргә утыртыла — тиз дә, ышанычлы да.

Леонид Соломонович кебек тәвәккәл кешеләр булмаса, БАМ да ерак китә алмас иде. Ә тәвәккәл җаннар күп монда. Бригадир Василий Титомир, мәсәлән, Молдавиядән килүгә, гариза язып кертә: «...һәр айда хезмәт хакының бер процентын Тынычлык фондына тотып калуыгызны үтенәм». Үзе еллык ялында да, диңгез буена бар дип биргән путевкадан баш тарта, торак йортлар салучы егетләргә булыша.

Михаил Пожарицкийның сәерлеге башка төрле. Ул автобазада тик торучы машиналарга игътибар итә. Һәркөнне уннарча машиналар, төзәтүче көтеп, тик тора. Төзәтүче слесарьларның эче пошмый, чөнки хезмәт хакына бәйле нәрсә түгел бу. Машиналар исә күз карасы кебек кадерле «Магирус»лар, ФРГдан һәрберсенә 49 мең алтын түләп кайтартылган. Бер карап үтә бу хәлгә инженер Пожарицкий, ике карый һәм башына фикер килә: ни өчен әле бу слесарьлар окладта утыра? Аларга төзәткән машиналар санынча, ягъни эшләренә карап түләргә иде!

Бу үзгәртүне төрлесе төрлечә кабул итә. Автобаза начальнигының кәефе бөтенләй кырыла.

Яңа ысулны башта бер участокта гына сынап карыйлар. Төзәтүчеләр үзләре дә хәйран кала: яхшы! Машиналар да тик тормый, хезмәт хакы да үсә, чөнки аны юлдагы машиналарга карап, арттырып түлиләр.

Баш инженер Пожарицкийның яңалыкка омтылуы моның белән генә дә чикләнми әле. Шул ук автобазага двигательләрне күтәреп-төшереп йөртү өчен кран

кирәк. Слесарьлар әүвәл автомобильле краннардан файдаланалар. Ул исә цехны агулы газ белән тутыра. Салкын кышкы көннәрдә һичничек җилләтеп тә булмый. Пожарицкий балкага урнаштырылган кран куярга кирәклеген әйтә. Сызымнарын булдыралар да баш технологка, имза салырга җибәрәләр. Теге шүрли:

— Стеналарыгыз чыдамаса?!

— Минем имза ярамыймы? — дип сорый Пожарицкий.

— Ник ярамасын? Сез — баш инженер.

Тәвәккәлли ул. Һәм эш тагын ота.

Нагорныйда Ягъфәровка да шундый бер четерекле мәсьәләне хәл итәргә туры килә. Текә җиргә рельс салу вакыты. Юл салу җайланмасының тормозларына ярдәмгә бирелгән тепловозны, әлегә кирәге чыкмас дип, башка йомыш белән җибәрәләр. Эштә куркынычсызлык өчен җавап бирергә тиешле кеше әллә кая йөри. Ягъфәров егетләренә түшәмгә төкереп ятарга гына кала.

Әмма бригадирның җаны түзми.

— Тормозлар шәпме?

Юл салу җайланмасының машинисты:

— Үземә ышанган кебек ышанам,— дип җавап кайтара.

Эшли башлыйлар. Беренче адымнарда сакланып-сакланып кына маташалар, аннары ышаныч арта бара. Хәтта: «Кара, теге тепловозның кирәге дә юк икән»,— дип уйлап куялар. Ул да түгел, ерактан йомышка киткән тепловозның кайтып килүе күренә, ул эшкә кирәкле материалларга баетачак! Нургали, шатланып, егетләрен күздән кичерә. Һәммәсенең алтынга алыштыргысыз осталар икәнен тоеп канатлана. Шул чак машинистның мотор гөрелтесеннән дә көчлерәк кисәтүе яңгырый:

— Тормозлар тотмы-ы-й!

— Сикер! Сикер! — Нургали үзен-үзе белештермичә кычкырып җибәрә.

Машинист сикерә. Тик егетләрнең аста эшләүчеләре кисәтүне ишетмәгән булуы ихтимал. Юл сузу җайланмасы алар өстенә ыжгырып бара бит!

Нургалинең сөйләп-кисәтеп торыр арасы юк, ул бер егетне сөйрәп ала да эш мәйданыннан читкә ташлый, икенчесен аягы белән тибеп читкә этәрә. Бу күренешләрдән егетләр хәлне аңлап алалар. Берәм-берәм читкә ташланалар. Нургали барысы да төшеп беткәнгә ышангач кына, иң соңыннан үзе сикерә. Бер нәрсәгә дә ышанмыйча, өскә килүче машинадан котылу өчен генә аска ташлана ул.

Аңына килгәч, ул иң беренче:

— Егетләр исәнме? — дип сорый.

— Борчылма! Иң хәтәре сиңа эләккән...

Больницада үткәргән бер ай вакыты тулы гомер кебек тоела аңа. Гаҗәп: трассаның нәрсәсе шул кадәр сагындыра икән? Бер уйласаң, коточкыч авыр бит инде. Көнетөне эш, ял итәргә дә әллә ни уңайлыклары юк, табигате дә ташка үлчим: җәен — черки, кышын җилегеңә төшә торган суыклар. Кул юарга суы да юк, кар белән юыналар. Шул «рәхәт»ләрдән бер-ике көнгә аерылып торсаң, сагындыра башлый.

Нургали башка тормышның ләззәтен аңламый да кебек. Белә ул: шәһәрдәге егетләр бик шәп киенәләр, кичләрен тәмәке көйрәтүче кызлар белән ресторанга да кереп утыралар, аталарының машинасында выжлап кына йөриләр. Менә шушы нәрсәләр һич кенә дә кызыктырмый бит Нургалине! Ул үзе кебек егетләр белән бергәләп салган тимер юлга гашыйк. Күпме кеше рәхәт күрәчәк бит аңардан?! Мондый бәхет — сирәкләр өлеше.

Нургали тимер юл сала башлаганда унҗидедә генә иде әле. Мамадышта унъеллыкны тәмамлагач, иптәш егете белән ветеринария институтына керергә уйлаган иде. Әлеге иптәш дигән кеше, көтмәгәндә, бик начар булып чыкты: ял иткәндә, җәйге учак янында утырганда, утка песи баласын ташлады. Менә сиңа ветеринар! «Ah!» итте Нургали. Институтка керү теләге дә сүнде. Бөтенесенә кул селтәде дә Себергә, юл салырга китеп барды.

158 нче төзү-монтаж поезды начальнигы Геннадий Сороковиковның карашы кырыс иде.

— Иртәрәк түгелме?

— Нишләп иртә булсын!

— Өйрәнчеклеккә генә билгелим, балта остасы булырсың.

«Балта остасы икән, балта остасы инде,— дип тәвәккәлләде Нургали.— Тамак тук булса, әнигә бераз җибәрсәм...»

Беренче тапкыр хезмәт хакы алгач, кибеткә йөгерде. Бөтенесе магнитофон кычкырта, ник Нургали генә калышып торсын әле?! Киштәгә әллә ничә төрлесе тезеп куелган. Егетнең күзләре ут яна. Әле берсен уйнатып карый, әле — икенчесен. Сүзләрен тыңлыйсың киләме, җырлатасыңмы — рәхәтлән! Әнә ничек матур иттереп суза:

«...Әнкәем, алтыным!

Сиңа дип эзләдем дөньяның асылын...»

Нургалинең башына китереп суктыларммыни?! Кибетнең бөтенләй икенче ягына атылды, әнисенә җылы йомшак кофта сатып алды. Әнисенең хаты озак көттермәде: «И улым! — дип язган иде ул.— Әниеңне шатландырган өчен рәхмәт яусын! Ничек болай юмартландың соң әле син? Ашарыңа калдымы соң? Ул кофтаның матурлыклары! Башта киеп чыгарга оялып йөрдем. Аннары кидем, мин әйтәм, кешеләрдән яшерер әйберме, улымның бүләге бит ул! дим. Әй, күрше хатыннарының кызыгуын күрсәң: берсе сулы чиләкләре белән абынып егыла язды. Көлештек...»

Балта остасы һөнәренә өйрәнеп беткән иде инде ул, тик күңеле һаман башка якка тартты. Сороковиков янына керде дә:

— Рельс җыючылар янына җибәрегез! — диде.

— Ярар.— Сороковиковның күңеле әйбәт икән. Сүзсез риза булды.— Тик тагы да онып-кунып йөрергә уйлама. Шул эштә ныгып калырга тырыш.

Яңа урында озак эшләргә туры килмәде, Нургалине армиягә алдылар. Шулай да, гаскәри хезмәттән кайту белән үк, Ягъфәров кабат Сороковиков янына керде.

— Хөрмәтле начальнигым, эшкә тотынырга рөхсәт итегез!

— Хәзер үк рельс җыярга! Әллә кайларда йөрдең син, ә?! — Начальник шаянлыгын онытмаган икән әле. Башта көлдереп алды. Аннары хезмәте турында сораштырырга тотынды.—Ниләр майтардың? Отчет бир башта!

Рельсларны шпалга беркетү — җиңел эш түгел. Бер «рәшәткә» ясаганчы шпалга кувалда белән илле чөй кадакларга кирәк. Өйрәнгәләгәнче беләкләрнең талуына чама юк. Анысы соңыннан үтә. Тик тәүлекләр буе әзер шпалга әзер рельс беркетеп утыру эчне пошыра. Менә шул рельсларны юлга суза барсаң икән ул! Соңыннан: «Бу юлны мин салдым!» — дип искә алуы ни тора?!

Телен әйләндереп яңа эш сорарга кыюлыгы җитмәде Нургалинең. Шактый вакыт рельс җыючылар янында тырышты. Хәтта үзен бригадир иттеләр. Теләген ул, башта рельс җыеп, аннары юл салучылар янына китеп, аларга бригадир булган Витя Лакомовка ачты. Анысы да каршы килде әле:

— Нәрсәсенә кызыгасың безнең эшнең? — диде.— Син анда, сигез сәгатьтән соң, ирекле. Ә юл салучылар гел монда. Җилме, яңгырмы, кармы — гел хәрәкәттә.

— Мин сиңа ышанган идем лә!..

Килештеләр. Шул көннән алып Нургали үзе салган рельсларны чакрымлап исәпләргә тотынды. Талпынган саен — 25 метрлы әзер «рәшәткә» юлга ята. Шул тәртиптә рельслар сала-сала Усть-Илимга җиткәч, бер тиктормаfның коткысына бирелеп, Нургали Свердловскига китте. Янәсе, яшьлек үткәләгәнче зур калага урнашып калырга кирәк! Бардылар. Каласы зур булса да, боларны бик көтеп тормаганнар. Данлы заводларның тулай торагы юк. Хөрти генә бер эшкә урнаштылар. Станоклар да иске, шуларга риза булып эшләп йөрүче кешеләр дә өлкән яшьтәгеләр иде. Хезмәт хакы да пенсия кебек кенә. Эштән соң да әллә нинди күңел ачулар күренми, кызлар да муенга асылынырга тормый. Ир-атлар, эштән чыгалар да, вак төркемнәргә оешып, аракы чөмерәләр.

Нургалине БАМдагы саф күңелле дуслары сагындыра башлады — һич чыдарлык түгел. Билет алды да Тындага китеп барды. 1974 ел иде бу. Эш — муеннан. Киләләр, китәләр, материал ташыйлар. Беренче карашка, ата улны, ана кызны белештерми кебек. Шушындый ыгы-зыгыда Ягъфәров күзгә-күз беренче остазы Геннадий Сороковиков белән очрашты. Бәрелешә яздылар.

— Син нәрсә, күктән төштеңме әллә? Җиңел тормыш эзләп китте, дигәннәр иде.

— Ялгышканмын. Алыгыз яңадан...

Ярты еллап кабат рельслар җыйды әле ул. Аннары гына юл салучылар янына күчерделәр. Шуннан бирле читкә тайпылганы юк. «Бамовский» станциясеннән Беркакитка кадәр ярты мең чакрым чамасы юл сузылды. Тау сыртын кичкәндәге хәлләрдән соң тәндә бер-ике җөй калды. Саксызлыгы өчен шелтә алды, ә батырлыгы өчен — медаль.

Хәзер аның тату гаиләсе бар. Өйләре Тындада. Хатыны Светлана — шәфкать туташы, ике ул үстерәләр.

— Ел саен Татарстанга кайтабыз,— дип сөйли Нургали.— Сабан туйларын күрми калмаска тырышам. Балалар Тындада туып-үсте. Шуңа күрә анысы да күңелгә якын...

Хәзер Тындада алтмыш меңләп кеше яши. Йортлары Мәскәүнең яңа районнарындагы кебек, биекләр, ап-аклар, матурлар. Тындада йорт салу җиңел түгел, ашыксаң, мәңге туң катлам серләре белән санашмасаң, бәлагә очравыңны көт тә тор. Күңелсез хәлләр дә булгалады.

Шәһәрдә торак мәсьәләсе иң авырлардан санала. Социаль-көнкүреш учреждениеләрен салу да акрын бара. Планнар моңарчы юл сузуны ашыктыру хисабына гына

арттырып үтәлә килгән булып чыкты. Меңнәрчә гаиләләр һаман вагоннарда яшәп ятарга мәҗбүр. Мәктәпләр, бакчалар турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Урамнарда әледән-әле очрап торучы: «Бөтен уңайлыклары булган квартирамны илнең теләсә кайсы шәһәрендәге шундый ук квартирага алыштырам»,— дигән белдерүләр бер дә юктан гына килеп чыкмагандыр инде.

Дөрес, соңгы вакытта бу җитешсезлекләр турында ачыктан-ачык сөйлиләр, кичекмәстән төзәтү чараларын билгелиләр. Миңа БАМ тирәлегендә үзләштерүгә багышланган Конференциядә дә булырга туры килде. Монда шаккатырырлык саннар ишеттем. Бу тайга урманнары дәрьясыннан үтә торган меңнәрчә чакрым тимер юлның әлегә әллә ни зур файда китерә алганы юк икән. Азрак күмер, азрак агач ташыйлар. БАМ тирәлеге исә — күз карашы иңләмәслек киңлек, монда космик зурлыклар хакимлек итә, тирәлеге дә миллион ярым квадрат километрлы мәйданны ала.

Шул киңлектә, чын мәгънәсендә, хуҗалык итәргә кирәк — КПССның XXVII съезды алга куйган бурыч бу. Әлеге Конференциядә сүз шул хакта барды. Әле юлның үз эше дә бетмәгән. Сметада каралган чыгымнарның 70 проценты гына тотылган. Әзер тимер юлда хезмәт итәргә тиешле оешмаларга да, торак һәм башка биналарны салучы төзүчеләргә дә эш күп. Төзелеш материаллары әзерләргә алынган предприятиеләр дә көчсез. Тындада һаман йортлар салу комбинаты юк.

Шунысы кызык: эш һәртөрле оешмаларда муеннан дибез, әмма бу якларга ашыгучылар гына юк. Конференциягә 32 министрлык һәм ведомство вәкилләре килде, тик БАМ зонасында эшләүчеләре ун мәртәбә кимрәк. Бу якларда төрле файдалы казылмалар күплеге һәркемгә мәгълүм. Әйтик, кайбер урыннардагы руданың 40 процентлабы тимердән тора. Шуңа да карамастан, металлурглар юк монда. Тимере дә әйбәт, тик ераграк шул диләр.

Кыскасы, БАМ төбәге нефтьчеләрне дә, химикларны да, төзү материаллары белгечләрен дә көтә. Асбест, апатит ятмалары... Шик тә юк, киләчәктә БАМ ягы илнең күп ихтыяҗларын үз җилкәсенә алачак.

Конференциядә ачыкланганча, бу җирнең байлыклары әле төгәл билгеләнеп тә бетмәгән. Һәм хәзерге салмаклык белән кыймылдасак, бары тик 70 елдан (!) соң гына билгеле булачак.

Бу якны эзләштерү-өйрәнүдә бик кирәкле техника мәсьәләсен дә кайгыртасы бар. Аны гел чит илләрдән генә сатып алу — иң отышлы ысул түгел.

Бер җитешсезлек икенчесенә китереп тоташтыра. Эшкәртү комбинатларының төзелмәве, техниканың ярлылыгы чималны әрәм-шәрәм итүгә юл ача. Барысы бергә бу якка ашкынып килгән эш кешесенең күңелен рәнҗетә. Галимнәр исә БАМ төбәгенә, кимендә, тагын миллион эшче көч кирәк дип исәплиләр. Кайда, ничек яшәр ул халык? Тагын Тындадагы кебекме?

Менә бу сорауга җавап эзләгәндә бүгенге көн таләбе, үзгәртеп кору принципларын алга чыгарга тиеш. Инде беренче адымнар бу хакыйкатьне раслый да башлаган. Планнарга караганда, 2000 нче елга, 16,5 миллион квадрат метр торак файдалануга биреләчәк. Бу — һәр кешене 15 квадрат метрлы торак мәйдан белән тәэмин итү дигән сүз.

Иң четерекле мәсьәләләрнең берсе булып БАМ тирәлегендәге табигатьне саклау санала. Академик А. Аганбегян белән сөйләшкәннән соң миңа кайбер сораулар ачыкланды.

— Тирә-юньнең матурлыгын, саулыгын саклап калу өчен без табигать байлыкларыннан комплекслы файдаланырга тиешбез. Кулланыла торган техникабызның һәм технологиябезнең бик камил булуы кирәк. Хәзер без суны әйләнешкә бары тик сафландырып кына кертә торган проектлар расланачак дип өметләнеп торабыз. Ниһаять, күпчелек галимнәр һәм хуҗалык кешеләренең дә акыллылары уртак фикергә килде кебек: табигатьне саклауга тотыла торган чыгымнар, никадәр генә зур күләмдә булса да, үзен аклый ул...

БАМ тирәлеген үзләштерүнең кайсы юнәлештән китәчәге уникенче бишьеллык азагына төгәлрәк күренә башлаячак. Ә аның бөтен хәлен тулысынча күз алдына китерү кыен, чөнки Себер байлыкларын үзләштерү шактый вакытка сузылачак. Монда җир асты казылмалары да, урманы-үсемлекләре дә яңабаштан өйрәнүне сорый.

Шулай да БАМның иң зур байлыгы — кешеләр. Бу якларда йөргән көннәремдә миңа еш кына Роберт Зарипов очрап торды. Үзе — Казаннан. БАМ төзелеше башлануга ук монда килгән. Ул — магистральдәге сәүдә эшләре өчен җаваплы кеше. Беренче көннәрдә аңа хәтта вагонда да урын табылмаган, кабинетында куныптөнеп яшәгән.

— Иртән кешеләр йоклап яткан җиремә килеп кермәсеннәр дип куркынып уяна идем.— Ул читенлекләр турында да шаяртып сөйли белә.— Көнем тимер юл буенда үтә. Бамчыларга вагон-вагон товар юллыйм. Күп алдык әйберләрне. Кирәк бит: бала чүпрәгеннән алып җиңел машиналарга кадәр артыннан йөрергә туры килде.

Планга кертелмәгән. Уйлап та карамаганнар. Кызык фикер йөрткәннәр: янәсе юл салырга егетләр генә җыелыр, аларга гаиләгә кирәкле нәрсәләрнең хаҗәте юк. Чынбарлыкта исә, егетләр юлда ук өйләнешә башладылар. Бары да кирәк булып чыкты.

Роберт, кешеләргә ни кирәген тәгаенләр өчен аркасына биштәр асып, төзүчеләр янына, тайга араларына кереп йөргән...

— Аһ, бөтен хезмәткәрләребез дә шундый булсачы! — дип Зариповны мактап туя алмый КПССның Тында шәһәр комитеты беренче секретаре Юрий Есаулков.— Казанда андыйлар тагын булса, җибәрегез, эш күп монда!

...Кече БАМ рельслары янышнан сузылган шоссе буйлап Алданга барабыз. Тимер юл Алданга ук җитмәгән әле. Ул өзеклек арасында йөк машиналары күп йөри. Мондагы шоферлар да башка, бер-берсенә ярдәмчел: бензинын да уртаклаша, туктаган җирдә «табынына» да чакыра. Геологлар халкына охшаш сыйфатлары бар аларның.

Монда күп нәрсәгә үрнәк итеп геологлар, аларның фидакарьлеге йөртелә. Якутия геологларының үзәге — Большая Хатыма авылында. Без дә машинаны шул якка бордык. Олы юлдан әллә ни әчкә керәсе дә юк. Конторлары кечкенә агач өйгә урнашкан. Язуы да бар: «Востоккварцсамоцвет экспедициясе».

Экспедициянең җитәкчесе — Михаил Харин — асылташларга тәмам гашыйк кеше икән. Ул монда сугыштан соң ук килеп төшкән. Җирле халык башта гаҗәпләнгән: бер җәнлек тә атмый, кем булыр бу? диешкәннәр. Хәзер экспедиция келәтендә бу якның бөтен байлыгын күз алдына китерерлек асылташлар тупланган. Киштәләренә күз салсаң, хәйран каласың: аметист, сердолик, лазурит, нефрит, яшма, турмалин, чароит... Асылташлар дөньясы — бу якның тагын бер горурлыгы.

Экспедициянең халык кулланышы товарлары әзерли торган участогында эш кайный. Якутия асылташларыннан ясалган истәлекле бүләкләр бик тиз сатылып бетә. Чөнки ташларны шомартучы осталар, Геннадий Вещагин белән Николай Герасимов һәм ирле-хатынлы Балелиннар, участок начальнигы В. Вильчик сүзләре белән әйткәндә, «асылташларны бик яраталар, аларны тоялар».

Ташларны кисү-шомарту җайланмаларының рәсми булмаган баш конструкторы вазифаларын да слесарь Г. Вещагин үти. Ул — алты станок авторы. Дөрес, монда чит илдән сатып алынган җайланмалар да бар, тик Вещагинныкылар әйбәтрәк. Аның бер агрегаты «Люкс» фирмасыннан алдырылган дүрт станокны алмаштыра. Кызганычка каршы, шул гаҗәеп зирәк слесарьга бер генә авторлык таныклыгы да бирелмәгән. Ник дисәң, остабыз үзе ясаган станокларның... сызымын тапшырмаган икән!..

Төпченә китсәң, асылташ дөньясы каһарманнарының да чишелеш таба алмый интеккән мәсьәләләре шактый.

Күп, бик күп әле монда четерекле мәсьәләләр. Тик кешеләрнең җан аямый тырышып йөрүләрен күргәч, киләчәкнең якты, матур икәненә ышанасың.



**М. П. Виноградов,**

КПССның Балык Бистәсе район комитетының беренче секретаре

# ҮСЕШ ЮЛЫННАН

Төбәкнең тарихы анда көн күрүче кешеләрнең яшәү рәвешен, тормыш мәгънәсен һәм хыялларын чагылдыра. Районыбызның бай тарихи үткәне, кайнап торучы бүгенгесе һәм якты киләчәге бар.

Татарстан тарихын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләренә күз салсак, анда безнең яклар турында да шактый мәгълүматлар күрербез. «Безнең эраның IV гасырында Зөя елгасының түбән агымы буендагы уңдырышлы үзәннәргә, Иделгә тоташып киткән җирләр белән Кама уйсулыкларына Имән Кискә культурасы кабиләләре урнаша. Алар яшәгән урыннарны казыганда, археологлар тимер сабан, урак һәм тегермән ташлары тапканнар. Һәрбер поселокта ашлык саклау өчен цилиндрик формада бик күп чокырлар булган» (Татарстан АССР тарихы, Казан, 1970). Халкыбызның ерак тарихы әнә шул кабиләләргә барып тоташа. Безнең районга терәлеп диярлек утырган Имән Кискә авылы да шуның шаһиты булып тора. Төбәкнең әһәмиятле стратегик урыны җирле экономиканың һәм культураның үсешенә уңай йогынты ясаган. Моның шулай булганлыгын археология истәлекләре ачык раслый. Бездә борынгы шәһәр һәм авыл калдыклары, төрле тарихи вакыйгалар белән бәйле урыннар байтак. Болгар дәүләте составына кергән Кама буендагы бу җирләр башлыча ике крепость-кала: көньяк-көнбатышта Кашан (хәзерге Шуран һәм Сорочьи горы авыллары арасында урнашкан булган) һәм көнчыгышта Чаллы (хәзерге Тәбәрде Чаллысы авылы янындарак) шәһәрчеге йогынтысында булган. Соңгысының үзенчәлеге шунда — ул Болгар һәм Казан ханлыгы чорларын тоташтыручы шәһәрләрнең берсе. Анда тормыш XVI гасыр ахырларына кадәр дәвам иткән.

Район үзәге — Балык Бистәсенең үткәне дә ерак гасырларга барып тоташа. Монда яшәүчеләр бигрәк тә үзләренең ювелир әйберләре белән дан тоткан. Болгар морзалары һәм Казан аксөякләре соравы буенча осталар аеруча затлы беләзекләр, йөзек-алкалар, муенса-хәситәләр һәм башка бизәнү әйберләре эшләгәннәр. Ул әйберләрне ясау ысуллары Болгар сәнгатенә барып тоташа. Шушы әйберләрдә халык осталары үзләренең дөньяны күзаллауларын, матурлыкка, нәфислеккә омтылуларын да гәүдәләндергәннәр. Мондый зиннәтле бизәнчекләр ясау гадәте хәтта безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Бөек Октябрь революциясеннән соң да Балык Бистәсендә аерым һөнәрчеләр үз осталыклары белән танылдылар.

Моннан тыш балыкчылык һәм башка төр һөнәрчелек, әйтик, агачтан савыт-саба, чана-кәрәкләр ясау да шактый киң таралган булган. Балык Бистәсе кешеләренең затлы балык белән Казан ханнарын һәм соңрак Мәскәү патшаларын тәэмин иткәнлекләре дә тарихта билгеле нәрсә.

Әмма халыкның төп шөгыле игенчелек һәм терлекчелек булган. Бүгенге көндә дә ул шулай. Әмма бәхетле тормыш яулап алганчы, ирекле көннәргә җиткәнче әле бик күп тир һәм кан түгәсе дә булган. Менә шунлыктан бу төбәктә яшәүчеләр дә һәртөрле баш күтәрүләрдә, крестьян кузгалышларында һәм сугышларында актив катнашканнар. Шуларның иң күренеклесе һәм колачлысы — Пугачев хәрәкәте. Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, Пугачев полковниклары Бәхтияр Канкаев белән Мәсәгут Гомәров отрядларында хәзерге Балык Бистәсе районына кергән авыллардан да йөзләрчә кешеләр катнашкан. Тәбәрде Чаллысы авылы крестьяны Рахманкол Руслиев исә үзе үк полковник дәрәҗәсенә күтәрелә. Биредә шул еллардагы бер тарихи истәлекне китереп үтәсе килә. Бәхтияр Канкаев приказларының берсе

ул. Кичүләрне саклау өчен бирелгән шушы боерыктан да безнең яктагы кешеләрнең бу хәрәкәттә ничек катнашуларын аңлау кыен түгел.

«Полковник Бәхтияр Канкай угылыннан бирелде приказ. Син, керәшен Герачим Сабай углына. Чистай кичүенә һәм кичү әһелләренең үзләренә. Әүвәл Кичек авылына, янә Тәбәрде Чаллысына, янә Букәш авылына, янә Чураш авылына, янә Казаклар авылына, янә Сатылган авылына, янә Мукшы авылына, янә Чаллы Башына һәрвакытта даимчелек илән ун-унбиш кеше тотмак үзләренә. Кичүдә ошбу эш тапшырылды. Кичек авылының Мәнди Тукташ углына һәрвакытта яхшыдин һәм ямандин хәбәр булса югарыда язылган Герачимга репортовать итмәгә. Бу мәзкүр югарыдагы язылган сигез авыл җәмәгатьләрини поход сорап һичкем рәнҗетмәгәй. Ошбу мәзкүр кичү боердык. Атланганнары булса һәм кайтарырга һәм көн әлгәре анларны кеше сорап рәнҗетмәскә».

Патша властьлары баш күтәрүчеләрдән канлы үч ала. Әмма халыкның азатлыкка, якты тормышка омтылышын сүндерә алмый. Менә шунлыктан Балык Бистәсе кешеләре патшаның бәреп төшерелүе хәбәрен шатланып каршылый. Октябрь казанышларын яклау өчен бөтен халык күтәрелә. Гражданнар сугышында, мәсәлән, һәр авылдан йөз-йөз илле кеше катнашуы билгеле.

1929 нчы елда районда күмәк хуҗалыклар төзү башлана.

Тыныч тормышны фашистлар Германиясенең вәхшиләрчә һөҗүм итүе өзә. Районнан Бөек Ватан сугышы фронтларына барысы унбер меңнән артык кеше китә. Аларның 335 е — хатын-кызлар. Тик әйләнеп кайтырга нибары биш меңенә генә насыйп була. Калганнары Ватан азатлыгы өчен көрәштә, немец-фашист илбасарлары белән аяусыз көрәшләрдә яу кырында ятып кала. Без батыр якташларыбыз белән горурланабыз, аларны бүгенге яшьләргә үрнәк итеп куябыз. Район Ватаныбызга сигез Советлар Союзы Герое тәрбияләп бирде. Алар — Александр Максимович Меркушев, Климент Сергеевич Русаков, Александр Тимофеевич Сергеев, Игнатий Павлович Петухов, Миңнулла Сөнгат улы Гыйззәтуллин, Селиверст Васильевич Давыдов, Зәки Шәймәрдән улы Шәймәрдәнов һәм Михаил Иванович Рыжов. Югары Тимерлек авылында туып-үскән Бари Гани улы Шәвәлиев фашист амбразурасын күкрәге белән каплаган Александр Матросов батырлыгын кабатлый.

Хәзер ел саен районның яшь механизаторлары язгы чәчү һәм урып-җыю көннәрендә Советлар Союзы Герое Зәки Шәймәрдәнов исемендәге мактаулы призны алу өчен ярышып эшли. Өлкәннәр батырлыгы бүгенге яшьләргә рухи көч һәм дәрт бирә, аларны фидакарь хезмәткә чакыра.

Сугыш елларын коточкыч афәт еллары итеп картлар әле бүген дә искә ала. Хәер, ил күргән кайгы-хәсрәт онытылырлыкмыни?! Нинди генә авырлыкларга, мохтаҗлыкларга түзәргә туры килмәгән. Шулай булуга да карамастан, авыл халкы, үз авызыннан өзеп, фронтны тәэмин иткән, фронтовиклар турында кайгырткан. Сугыш елларында да район авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү планын тотрыклы үтәп бара. Ә кырларда хатын-кызлар һәм яшүсмерләр икәнен дә онытмыйк.

Фронтка башкача ярдәм итү ысуллары да табыла. Танклар һәм самолетлар төзү өчен район эшчәннәре туксан мең сум акча җыеп тапшыралар. Пионерлар һәм комсомолларның бу эштә башлап йөрүен әйтү аеруча күңелле. Котлы Бөкәш урта мәктәбе укучылары, мәсәлән, 6260 килограмм тимер-томыр җыялар, танк төзү өчен мәктәп исеменнән 15 мең сум акча җыеп бирәләр.

Болар — безнең үткәнебез, тарихыбыз...

Бүгенге көндә район нинди хәлдә, кешеләре нинди уй-ниятләр, нинди максатлар белән яши? Бүгенге тарихыбыз ничек языла?

Балык Бистәсе республика районнары арасында зурлыгы белән аерылып тормый. Мәйданы — 2053 квадрат километр, халкы — 34 мең. Район аша олы су юлы — Кама елгасы һәм республика башкаласы Казанны автомобиль төзүчеләр шәһәре һәм Түбән Кама промышленность комплексы белән тоташтыручы зур автомагистраль үтә. Ләкин безнең төп горурлыгыбыз — хезмәтләре белән тарихка яңа сәхифәләр язучы кешеләребез — ферма һәм басу хезмәтчәннәре — игенчеләр, терлекчеләр.

Районыбыз бөртекле һәм кузаклы культуралар игү, азык культуралары һәм бәрәңге үстерү белән шөгыльләнә, ит һәм сөт җитештерә. Унбиш колхозыбыз һәм алты совхозыбыз бар. Аларга 126898 гектар җир беркетелгән. Ләкин шунысын да әйтеп китү урынлы булыр, туфраклар нигездә көлсу туфрак, ачылыгы шактый югары - 68 проценты диярлек шундый. Шуның өстенә күп җирләр чокырлар һәм ерганаклар белән бозылган. Болар барысы да бездән туфракка карата сак булуны, җирләрне ашлауга һәм сугаруга зур игътибар бирүне сорый. Менә шунлыктан сугару - эшкәртүләргә җиде миллион сумнан артык акча тотылды инде. Хәзер районда алты мең гектарга якын җирдә ясалма яңгыр яудырыла.

Партия, совет, авыл хуҗалыгы оешмалары кадрлар әзерләүгә һәм аларның

осталыгын күтәрүгә беренчел дәрәҗәдәге мәсьәлә итеп карыйлар. Республика югары уку йортларында һәм техникумнарында районнан 150 егет һәм кыз белем ала.

Яшьләргә хезмәт тәрбиясе бирүне камилләштерә баруның беренче җимешләрен дә күрәбез. Үткән ел Корноухово урта мәктәбенең чыгарылыш класс укучылары райондагы барлык яшьтәшләренә мөрәҗәгать белән чыктылар — аларны бөтен класслары белән туган авылларында калырга, туып-үскән газиз туфракта үз көчләрен сынап карарга, авылларны ямьләндерү өчен яшь көчләрен кулланырга чакырдылар. Бу башлангыч бик күп яшьләрдә кайнар яклау тапты. Быел, мәсәлән, 160 тан артык егет һәм кыз үз язмышын туган авылы белән бәйләде.

Шушы эшнең нәтиҗәсе буларак, кадрлар белән тәэмин ителеш тә яхшыра бара. Әйтик, Тукай исемендәге, «Рассвет» колхозларында, «Шомбыт» совхозында механизаторларның 90 процenттан артыгы хәзер беренче һәм икенче класслы.

Район агропромышленность берләшмәсе советы, белгечләр хезмәтне оештыруның алдынгы ысулларын куллануга һәм хезмәткә түләүне камилләштерүгә зур әһәмият бирәләр. Быел, мәсәлән, 145 звено коллектив подряд ысулы белән эшли. Аларның күбесенең мактап сөйләрлек эшләре, матур хезмәт нәтиҗәләре бар.

Районда терлек азыгы заводы, консерв заводы эшләп килә. Ремонт-техника предприятиесе, «Агропромхимия», сөт һәм май комбинаты, урман хуҗалыгы, райпотребсоюз кебек оешмалар да бар. Аларның материаль-техник базасын ныгыту, транспорт оешмаларын көчәйтү буенча шактый эшләр башкарылды. Бу эшнең нәтиҗәлелеге турында унберенче бишьеллыкта район ирешкән экономик күрсәткечләр ачык сөйли. Ашлык җитештерү унынчы бишьеллык белән чагыштырганда — 16, сөт 13 процентка артты.

1986 елгы еш нәтиҗәләре буенча «Масловский» совхозы Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыкты һәм КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы белән бүләкләнде.

Культура һәм мәгариф өлкәсендә дә яңарышлар байтак. Культура йортлары һәм клублар эшләп тора, районда 17 урта һәм 11 сигезьеллык мәктәп, 44 китапханә бар. Соңгы елларда гына тагын биш мәктәп, сигез культура йорты, алты балалар бакчасы төзелде.

Районда техник һөнәр училищесы һәм аның филиаллары эшли, яшьләргә авыл хуҗалыгы һөнәрләренең серләрен өйрәтә, ел саен 400 дән артык механизатор һәм 30 тезүче әзерләп чыгара. Күптән түгел биредә тегү, машина белән сыер саву осталыгына да өйрәтә башладылар. Училище Бөтенроссия социалистик ярышында җиңеп чыкты. РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагына лаек булды.

Районда унбиш Ленин ордены кавалеры яши. Алар арасында «Масловский» совхозы директоры Галина Павловна Васильева, Черняховский исемендәге колхоз председателе Григорий Дмитриевич Хроленко, шул ук колхоз бригадиры, КПССның XXVII съезды делегаты Анна Сергеевна Сергеева, «Новая жизнь» колхозы механизаторы Леонид Егорович Егоров һәм башкалар бар.

«Гигант» колхозы тракторчысы, «Халыклар дуслыгы» ордены кавалеры, Татарстанның атказанган механизаторы Рәшит Гарәфетдинов исемен аеруча хөрмәт белән билгеләп үтәргә кирәк. Ул иң абруйлы, энергияле кешеләрнең берсе, район механизаторлары ярышында күп тапкырлар җиңүче булды, яшьләрнең тәҗрибәле һәм яраткан остазы.

Соңгы елларда терлекчелек өлкәсендә дә мактап телгә алырдай кадрлар үсеп чыкты. Мәсәлән, сыер савучылар — III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалеры Зәкия Гыймадиева, Анастасия Хәйруллина, Валентина Новикова, Ольга Галиуллина, Екатерина Шатова; терлекчеләр — Анна Слесарева, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Евгений Зайчиков. Аларның тырыш хезмәте район казанышлары елъязмасына яңа сәхифәләр булып языла.

Балык Бистәсе — күп кенә язучылар, шагыйрьләр һәм сәнгать осталарының туган төбәге. Без шагыйрьләр Миргазиз Укмаси, Зәйнәп Бәширова, Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, прозаик һәм драматурглар Сәит Шәкүров, Вакыйф Нуруллин, Әхәт Гаффар, язучы-галим Мөхәммәт Гали, шагыйрь һәм педагог Фәрит Ибраһимов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, театр рәссамы Петр Баландин, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Равил Шәрәфиев, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Рауза Хәйретдинова һәм Татарстанның атказанган артисты Хәлим Җәләлов исемнәрен атаганда зур горурлык хисе кичерәбез.

Районыбызның кыскача тарихына һәм бүгенгесенә күз салдык. Аны гади кешеләр яза. Механизаторлар, терлекчеләр, укытучылар һәм сәнгать осталары...

Җиребезнең хуҗалары — безнең хезмәт сөюче якташларыбыз. Районыбызның киләчәге алар кулында.

## Дамир Гыйсметдинов

# ПОЛЬШАГА — ДУСЛЫК КҮПЕРЕ

*Матбугатта хәбәр ителгәнчә, күптән түгел безнең республиканың КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, Профсоюзларның Татарстан өлкә Советы председателе Г. С. Баштанюк, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре В. Н. Фомин һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты инструкторы Д. М. Гыйсметдинов составындагы делегациясе, дуслык элемтәләре урнаштыру максатыннан, Польша Халык Республикасында булып кайтты. Польшаның Ломжа воеводствосы һәм ТАССР арасында хезмәттәшлек программасына куллар куелды.*

*Түбәндәге язмада, редакция үтенече буенча, КПССның Татарстан өлкә комитеты партияара элемтәләр хезмәткәре Дамир Гыйсметдинов әлеге сәфәрдән алган тәэсирләре белән уртаклаша.*

Быелгы яз Варшавага да соңарып, теләр-теләмәс кенә килә кебек иде. Аэропорт өстендә куе болытлар йөзә. Безне, Советлар Союзыннан көтелгән кунакларны, каршы алырга җыелган кешеләр тәмам хафага төшкән. Көннәрнең һаман ачылып җитмәвендә, әйтерсең лә, аларның да гаебе бар. Иллюминатордан карыйм: каршыларга килүчеләрнең кулларында — язгы чәчәкләр. Без, «Чыгарга мөмкин!» дигән сүз ишетелүгә, Ломжа воеводствосы вәкилләре янына ашыгачакбыз.

Мин бу воеводство турында аз белә идем. Утырган җирдән шул мәгълүматларны кабат хәтергә җыям: «Ломжа воеводствосы 1975 елда Варшава һәм Белосток воеводстволарыннан аерып алынган районнар бәрабәренә оештырыла. Аның мәйданында 11 шәһәр, 29 авыл (безнеңчә әйткәндә) районы бар. Зурлыгы 6684 квадрат километр, анда 332 мең кеше яши. 50 мең кешеле Ломжа воеводствоның үзәге итеп билгеләнә...»

Ломжаның борынгы шәһәр икәнлеген дә беләм. Ул 1958 елда, Новогруд һәм Визня шәһәрләре белән берлектә, үзенең мең еллык юбилеен бәйрәм итте. Шәһәр ашыкмыйча гына агып ятучы киң, якты Нарев елгасы буена урнашкан. Шаяннар, елга агышының сабырлыгы Ломжа халкына да пошмаслык булып күчкән, дип көләргә яраталар икән...

Ниһаять, самолет салонынннан чыгарга рөхсәт ителде. Безнең янда Калуга һәм Саратов өлкәләре делегацияләре дә бар. Каршылаучыларның буталуы да бик мөмкин иде. Тик, ни гаҗәп, без, үзебезнең ломжан дусларыбыз кочагына эләктек. Күрәсең, күңелдән-күңелгә дуслык җепләре тартылып та өлгергән. Минем каршыга аксыл сары чәчле егет килеп басты да:

— Роман Шмидт,— дип таныша башлады.— ПОРПның воеводство комитетында партияара элемтәләр буенча эшлим.

Без «Полонез» маркалы өр-яңа машинага утырып Варшаваның үзәнә киттек.

Варшава! Варшава! Риваятьләрдәге феникс кошы сыман хәрабәләрдән кабат терелгән гүзәл кала! Аның һәр ташы кешенең фидакарь иҗатына һәм карусыз хезмәтенә һәйкәл сыман. Сокланггыч та, гаҗәпләнерлек тә. Варшавага багышланган документаль фильм безне аеруча тетрәндерде. Фашистларның шәһәрдәге тарихи истәлекләрне, хайвани ләззәт тоеп, шартлатып-яндырып йөрүләре акылга сыймаслык. Кеше сыйфатларын җуеп, тәмам чыгырыннан чыккан фюрер Польшада восстание күтәрелүен ишеткәч, Варшаваның көлен күккә очырырга, полякларны үтереп бетерергә боерык бирә. Фашистлар шул әмерне тырышып үтиләр. Шәһәрдә немецларның хәрби комендатурасы урнашкан берд әнбер бина гына торып кала. Бөек Ватан сугышы елларында алты милли-

он поляк һәлак була. Польшаның матди югалтулары Франциянекеннән — 25, Великобританиянекеннән — 27 тапкыр күбрәк.

Сугыштан соң Варшаваның киләчәге турында бәхәсләр куера. Нишләргә: якындагы берәр мәйданда өр-яңа шәһәр салыргамы, әллә аны үз урынында элеккечә иттереп тергезергәме? Фикер алышуларда күп төрле һөнәр ияләре катнаша. Исәп-хисап, керемчыгымнарны күздә тотып эш итүчеләр, яңа шәһәр салыйк, диләр: ә романтиклар, шагыйрьләр патриотик хисләрне онытмаска чакыралар. Алар Варшава турында сүз алып барганда, чыгымнарны гына түгел, иң әүвәл поляк халкының милли горурлыгын, тарихи байлыгын алга куялар. Шәһәрне, аның үткәнен һәм киләчәген ихлас күңелдән яратучылар җиңә — Варшаваны нәкъ элекке төсле иттереп тергезергә хәл кылалар. Һәм шәһәр иң оста, иң фидакарь архитекторлар, төзүчеләр тарафыннан, әүвәлге һәр бизәген, һәр кирпечен берәмтекләп барлап, яңабаштан салына. Варшаваның кичергәннәре кешедәге иҗади-рухи байлыкның да, аңардагы ук җимергеч-дошмани көчнең дә ни икәнен аңлатучы мәгърур һәйкәлгә охшый. Биредә һәр урам, һәр таш-гранит шәһәрнең нинди вәхшилек корбаны булганлыгын да, үзенә карата нинди кайнар мәхәббәт күрсәтелүен дә хәтерли сыман.

Польша җирендә сугыш тирән эз калдырган. Биредә без вакыт та тигезләп бетерә алмаган дзот, окоп, блиндаж җимерекләкләрен күп очраттык. Нарев суының биек яры өстенә капитан Рагинис истәлегенә куелган һәйкәлгә чәчәкләр салдык. Ломжа ягында туып-үскән бу кыю капитан, фашист оккупантлары өерен юк итү өчен, үзе дә шартлау үзәгендә калган. Язгы чәчәкләрдән үрелгән икенче бәйләмебезне Польшаны немец илбасарларыннан азат иткәндә һәлак ителгән якташларыбыз һәйкәленә куйдык. Монда һәркем Советлар Союзының 600 мең солдаты Польша азатлыгы хакына һәлак булуын яхшы белә. Бу илгә азатлык алып килүчеләр арасында Татарстанның батыр уллары да бар. Бераз алга китеп әйтим, без Казанга кайткач, Совет-Польша дуслыгы җәмгыятенең Татарстандагы бүлекчәсен оештыру җыелышында ул каһарманнарның исеме зурлап телгә алынды: «...Польша җирендә ятып калган сугышчыларыбыз арасында Татарстанның күренекле язучысы Гадел Кутуй да бар,— диелде.— Польша азатлыгы өчен җан аямый көрәшкән якташларыбыздан Гайнулла ага Яфаев һәм журналист Вадим Луценко бүген безнең залда утыра. Бу иптәшләр, Совет-Польша дуслыгы утлы сугышларда чыныкты дип, горурланып әйтә алалар».

Әлбәттә. Шул ук сүзне яу кырында коралдаш поляк дуслары белән иңгә-иң торып сугышкан йөзләгән фронтовикларыбыз да әйтә ала. Без әле күбесен белмибез, шунлыктан бу хәбәрләрдән соң алардан хатлар килүенә өметләнәбез. Аларның хатирәләре нигезендә яңа мәгълүматларга баюбызга, яңа әсәрләр иҗат ителүенә ышанабыз...

— Күрдегезме, кояш чыкты! — Роман чын-чынлап шатланган иде.— Менә шулай бездә: җил дә вакытында исә, яңгыр да вакытында ява, дуслар җыелганны күргәч, кояш та чыкмый булдыра алмады!

Мин Габдулла Тукайның Казан арты табигатен дә нәкъ шулай тасвирлавын искә төшердем. Охшаш икән, кичерешләребез дә, табигать шартларыбыз да охшаш икән ләбаса!

«Полонез»ның Ломжа воеводствосы чигенә килеп җиткәнен сизми дә калганбыз. Безне воеводствоның япь-яшь җитәкчеләре ПОРПның воеводство комитеты беренче секретаре Мечислав Чернявски белән воевода Марек Стжалински, кыска гына сәламләү сүзе әйтеп, ихлас күңелдән каршы алдылар. Кызлар безгә чәчәкләр сузды, барыбыз бергә фотога төштек. Мондый эчкерсез очрашулар соңыннан да бик күп булды.

Без Польшада биш көн тордык. Бу вакыт эчендә без бер-беребезнең тормышкөнкүреше, хезмәте-сәнгате даирәсендәге уртаклыкларны эзләдек. Хәзер зур канәгатьләнү белән әйтергә мөмкин: эзләгәнебезне таптык, күп тармакларда — һәм сәяси, һәм экономик яктан, һәм әдәбият-сәнгать өлкәсендә уртаклашыр хәзинәләр ачтык. Кызык, йөрибез-йөрибез дә, сөйләшәбез-аңлашабыз да: «Кара, бу бит бездә дә шулай!» — дип куябыз.

Польшаның ныклы нигездә үсә баруы, илне тетрәтеп узган кризисның инде тәмам сүрелгәнлеге безне чын-чынлап шатландырды. Әмма поляк дусларыбыз хәзер дә кул кушырып утырмыйлар. Аларга Көнбатышның өзлексез тәэсир итеп торуын, католиклар чиркәвенең һәм дини гадәтләрнең йогынтысын һәрчак истә тотарга туры килә. Мондый катлаулы шартларда эшләү җитәкчеләрдән аеруча сизгерлек, осталык таләп итә.

Мәсәлән, берничә ел элек ПОРПның воеводство комитеты өчен яңа бина салалар. Инде күченәбез дигәндә генә партиядә бәхәс кузгала. Коммунистларның күпчелеге, халыкның ихтыяҗын күздә тотып, бинаны шәһәр поликлиникасына бирергә кирәк, дигән тәкъдим кертә. Кайберәүләр каршы чыга: «Һәрчак болай чигенә барсак, «Солидарность» йогынтысындагы яшь җилкенчәк башыбызга басар!» — диләр. Күпчелек тавыш белән бинаны поликлиникага тапшыралар. Һәм бу адымның дөреслеге раслана. Шәһәр халкы коммунистларының җан аямый гомум мәнфәгать өчен тырышуларын аңлый.

Үткәндәге четерекле хәлләр турында безгә ул чакта партиянең Ломжа воеводство комитеты беренче секретаре булган, хәзер Польша Халык Республикасының Мәскәүдәге илчелегендә советник булып эшләүче Влодзимеж Михалюк сөйләде.

— Ул көннәрдә коммунистларга бик сизгер булырга кирәк иде,— диде.— Бәхеткә каршы, безнекеләр ул сынауны уңышлы уздылар, халык хаклыкны таныды.

Шулай да поляк дуслар әле тыныч күңел белән яшәмиләр. Польша Берләшкән Эшчеләр партиясенең X съездында Войцех Ярузельский әйткәнчә, иң куркынычы — артта, әмма иң авыры алда әле. Безнең яңа дуслар яши торган воеводствода хәзер бөтен омтылыш мондый: иң дөрес юлны сайлап алу, тырышып һәм югары сыйфатлы итеп эшләү. «Визна» авыл хуҗалыгы комбинаты, «Нарев» киҗе-мамык комбинаты, «Мэра Блоне» заводы, өй җиһазлары комбинаты уңганнарын күреп сөйләшкәч, бездә шундый тәэсир калды. Киләчәктә бу завод-фабрикалар бездәге шундый ук коллективлар белән аралаша, тәҗрибә уртаклаша башлаячак.

Бу юнәлештә үрнәк алырлык мисалларыбыз да бар: күптән инде КамАЗ белән Польшадагы Прашка шәһәре автомобильчеләре, «Тасма» берләшмәбез белән Варшаваның «Органо-фотон» предприятиесе, «Түбәнкаманефтехим» берләшмәсе белән Плоцк шәһәрендәге химия заводы коллективлары үзара тамам дуслашып беттеләр. Шулай ук Польшаның әдәбият һәм сәнгать әһелләре, партия һәм дәүләт эшлеклеләре Татарстанда еш булалар. Заманында күренекле поляк лингвисты Бодуэн де Куртенэ эшләгән Казан университеты студентлары исә байтактан бирле Познаньдагы А. Мицкевич исемендәге университет студентлары белән дусларча аралашалар.

Димәк, без салачак дуслык күпере буш җирлектән башланмый. Бу юлы очрашканда да сүз әүвәлге элемтәләрдән чыгып алып барылды. Дөрес, әлегә без хәтта булган истәлекләр турында да аз беләбез. Хәтта ПОРПның воеводство комитеты секретаре Мечислав Бжезицки белән Роман Шмидтның да Идел буе хакында мәгълүматлары аз. Алар, мәсәлән, милли азатлык хәрәкәтендә катнашкан полякларның бу якларга сөргенгә җибәрелгәнлеген, ә, вакыты җиткәч, Идел буе халыклары белән берләшеп, гомум революцион күтәрелешкә катнашканлыкларын бездән генә ишетеп белделәр. Революционер Эдмунд Жебровскиның, Кызыл Армия частьларының берсендә командир булган Кара Тадеушның истәлеге алдында без хөрмәт белән баш ибез. Ломжа воеводствосында гына да Бөек Октябрь социалистик революциясенә катнашкан иллеләп көрәшче яши икән.

Гомумән алганда, ломжаннар үз тарихларын бик олылыйлар һәм аңа кагылышлы һәр истәлекне кадерләп саклыйлар. Ломжа шәһәренә X гасырда ук нигез салынган. Ләкин аңа еш кына чит ил баскыннары белән бәрелешергә туры килгән. XIII гасыр уртасында, мәсәлән, борынгы ятьвинг һәм литвалы кабиләләрнең һөҗүменнән соң шәһәрдән бары тик хәрабәләр генә торып калган. Әмма XIV йөздә ук ул яңадан аякка баса. Моңа көч бирердәй сәбәп чыга: Ломжа аша Корольләр Юлы дип йөртелгән, соңра Польша-Литва униясе төзелүдә зур әһәмияткә ия булган Варшава — Литва юлы салына. Пруссиягә илтүче Мәскәү — Познань юнәлешендәге юл да Ломжа аша үтә. Моңысы шәһәрдә сәүдәнең нык алга китүенә этәргеч була. Боларга өстәп, Ломжаның Бебжа — Нарев — Буг — Висла су юлындагы бер порт икәнлеген дә әйтергә кирәк. Шунлыктан әле XV гасырда ук Ломжаның шәһәр статусы алуы һәм гербында дәү ташлар аша сикерергә омтылучы болан сурәте булуы һич гаҗәп түгел.

XVI гасырда Ломжа аеруча алга китә. Шәһәрдә төзелеш арта, күпшы йортлар, таш түшәлгән урамнар, җәмәгать биналары барлыкка килә. Сәүдә, һөнәрчелек күзгә күренеп үсә. Таш амбарлар, зур мунча, ратуша, сугыш кирәк-яраклары складлы, металл кою җайланмасы һәм изге Михаил костеленың гаҗәеп бинасы салына. XVII гасырда исә табигать «холыксыз»лыгы, янгыннар һәм шведларның һөҗүме аркасында шәһәр тагын таркала, башкалардан тулы гасырга артка кала. Бары XVIII йөзнең икенче яртысында гына аның яңадан аякка баса башлавы мәгълүм. Тик Польшаның бүлгәләнүе, соңра Пруссиянең оккупациясе Ломжаның үсеп китүен тоткарлый. 1807 елда, Наполеон сугышына бәйле төстә, шәһәр кабат тулаем җимерелә, яндырыла...

Бер уйласаң, мондый катлаулы язмыш кичергән шәһәрдән яшь буынга билгеле булырдай истәлек-хәбәр дә калмавын ихтимал иде. Әмма без воеводствоның гаҗәеп бай тарихи истәлекләрен күрдек. Үзәге Чехановец шәһәре булган гминнада (районда) киң ачык мәйданда оештырылган этнография һәм тарих музее, фольклор төркеме башкаруындагы концерт — болар барысы да хезмәт сөючән ломжаннарның ата-баба узган юлны олылавын, һәм матур киләчәк хакына, аны кадерләп саклавын раслады.

Ломжа воеводствосының борынгы җире күп хәсрәтләр кичергән. Икенче бөтендөнья сугышы да аның халкының 60 процентын, корылмаларның 70 процентын харап итә. 1944 елның сентябрендә, Ломжа совет гаскәрләре тарафыннан азат ителеп, сугыш беткәч, илдә социалистик дәүләт оештырылганнан соң борынгы бу җир әр-яңадан чәчәк ата.

Шәһәрдә заман рухында салынган яңа биналар барлыкка килә: уку йортлары, тамаша урыннары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, спорт уены җайланмалары. Халык тарихы өчен кадерле булган архитектур истәлекләр тергезелә, яңа тәрдәге торак йортлар салына, аларда яшәү өчен бөтен уңайлыклар җайлана.

Шәһәрнең промышленносте, бигрәк тә азык промышленносте кызу темплар белән үсә башлый.

60 нчы елларда бик кыска ара эчендә бәрәңге эшкәртү предприятиесе, катнаш ашламалар фабрикасы, кошчылык комбинаты, сыек газ һәм сыра заводлары сафка баса. Икенче унъеллыкта «Нарев» исемле ил күләм әһәмияткә ия текстиль комбинаты, йорт җиһазлары фабрикасы эшли башлый. Хәзерге вакытта шәһәрнең һәрьяклап үсүен күздә тоткан, күп елларга чамалап төзелгән план расланган. Ломжа шул планга бәйле рәвештә үсәчәк.

Воеводствода булуыбызның бер көнендә безне «Гәрәбә» исемле микрорайонга алып бардылар. Нарев елгасының гәрәбәгә ни катнашы бар? — диярсез. Гәрәбә бит Балтик диңгезе буенда гына табыла.

Без дә шулай уйлаган идек. Тик, безнең гаҗәпләнүгә каршы, элек Нарев елгасында һәм аның Писе, Шкве, Регезе исемле кушылдыкларында гәрәбә җыйганнар икән. Аны «курп алтыны» дип йөрткәннәр, чөнки бу гәрәбәне курп атлы җирле халык җыеп эшкәрткән. Бу төр гәрәбә бизәнгечләр өчен дә, тылсымлы бөти итеп тә файдаланылган, кыйммәтле мал алганда да бик яраган. Хәтта никах балдагын да шушы гәрәбәдән ясаганнар. Костелга баручылар сәдака итеп гәрәбә валчыклары өләшкән. Әмма хәзер елганың бу сокландыргыч хәзинәсе беткән инде. 1976 елда аңардан төрле әйберләр ясаучы соңгы оста да дөньядан киткән. «Курп алтыны»ннан ясалган әйберләр исә Варшавадагы Җир музеенда һәм Ломжаның округ музеенда саклана.

Ломжаның иң зур байлыгы — аның кешеләре: галимнәре, талантлы педагоглары, кыю сугышчылары. Бу як кешелеккә Зигмунд Глёгр кебек тарихчыны бүләк иткән, монда язучы һәм галим Адам Хэнтнин үскән, табигать белгече Кшиштоф Клюк та, агалы-энеле галим Вагалар да, Варшава университеты ректоры Войцех Швейковский да, Берләшкән Милләтләр оешмасы судының халыкара председателе Богдан Винярский да — барысы да ломжаннар.

1975 елда шәһәрдә Вагалар исемендәге фәнни җәмгыятькә нигез салына. Илнең өч фәнни җәмгыяте монда үзләренең бүлекчәләрен булдырганнар: тарих, культура һәм тел, Адам Мицкевич исемендәге әдәбият җәмгыяте бүлекчәләре.

...Кадерле дуслар янында биш көннең узганын сизми дә калдык кебек. Ил-җирләрен карап та, сөйләшеп тә туймадык. Бу хакта әйткәч, ломжаннарның берсе:

— Менә яхшы, яңадан килергә сәбәп булыр,— диде.

Дөрестән дә, безнең дуслык элемтәләре яңа башлана гына бит әле. Иң кызыгы, тирән эчтәлекле очрашулар — алда. Ике арада сузылган күперне ныгытсак, партияләр һәм халыкларыбыз арасындагы дуслыкны чыныктырсак, тәҗрибә уртаклашуларны җайга салсак, беренче шытымнар Нарев һәм Идел ярларында гөрләп үсеп китәр.

Без Варшава белән саубуллашканда, илгә инде яз кояшы тулысынча хуҗа иде. Урамнарны, өйләрне генә түгел, безнең күңелләрне дә җылылык рәхәтләндерде.

*Казан — Варшава — Ломжа — Казан.*

# АЛИСӘ — ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ

Казан тимер юл вокзалында Мәскәү — Тында поездын каршы алучылар гадәттәгедән күбрәк иде. Поездның соңгарак калып киләчәген хәбәр иткәч тә, җыелган халык таралырга ашыкмады. Алар арасында республика Дәүләт физкультура һәм спорт комитеты җитәкчеләре дә, танылган шахматчылар да, журналистлар да бар. 16 яшькә кадәрге шахматчы кызлар арасында дөнья чемпионы булган Казан кызы Алисә Галләмованы каршыларга җыелганнар иде алар. СССРның спорт мастерлары, республикабызның иң көчле шахматчыларыннан саналган Наил Мөхәммәтҗанов белән Лев Волошиннарның сөйләшүенә колак салам.

— Татарстанның бер генә шахматчысын да болай тантаналы төстә каршылаганнары юк иде әле,— ди Н. Мөхәммәтҗанов.— Хәтта Рәшит абый Нәҗметдиновны да...

— Әйе,— дип аның сүзен куәтли Лев Волошин.— Казанга беренче тапкыр дөнья чемпионының алтын медале кайта. Соңгысы булмасын иде! Афәрин, Алисә!

— Рәшит абый исән булса, ничек шатланыр иде! Ул бит һәр яшь талант турында кайгырта, аларга уен серләрен бик теләп өйрәтә иде...

...Поездның килеп җитүе белдерелгәч, җыелган халык 12 нче вагон янына ашыкты. Менә вагоннан Алисә, аның тренеры Олег Ильясович Игъламов төшә. Алар чәчәкләргә күмелде. Каршылаучылар арасында Алисәнең әнисе Гамбәрия Муллагалиевна белән энесе Ринат та бар.

Перронда ук кыска гына митинг булып алды. ТАССР Дәүләт физкультура һәм спорт комитеты председателе Хәниф Мортазин яшь шахматчының уңышлары турында сөйли, зур исемне яулавы белән котлый. Аннан соң — республика Дәүләт физкультура һәм спорт комитетында, ТАССР Мәгариф министрлыгында, профсоюзларның өлкә комитетында очрашулар, журналистлар катнашында пресс-конференция...

Икенче көнне яшьтәшләре Алисәне республика пионерлары слетына җыелган делегатлар белән очрашуга чакырдылар. Ул анда да бик күп сорауларга җавап бирде, берьюлы берничә тактада уйнады. Кайтуына өч көн үтүгә ул, көндәшләре белән чын-чынлап көрәшер өчен, тагын шахмат тактасы каршына утырды. Бусы инде танылган шахматчы якташыбыз, биш тапкыр РСФСР чемпионы, халыкара мастер Рәшит Нәҗметдинов истәлегенә Казанда ел саен үткәрелә торган шахмат турниры иде. Иптәшләре аңа беренче тактада, ягъни башка командалардагы иң көчле малайларга каршы уйнауны ышанып тапшырдылар. Алисә монда да сынатмады — 9 уенда 8 очко җыйды һәм шулай итеп Казан командасына беренчелеккә чыгарга булышты.

Шуннан соң, Актаныш районы Татар Ямалы авылына әбиләренә кунакка кайткач кына, бераз ял итте ул. Рәхәтләнеп Агыйделдә коенды, яшьтәш кызлары белән бергә кичке уеннарга чыкты. Бирдә аның төп-төгәл биш ел булганы юк иде инде. Әбисе Тәхия дә, бабасы Муллагали дә оныкларының кайтуына бик шатландылар.

Июль уртасында Алисә хатын-кызлар арасында СССР беренчелегенең ярымфиналында катнашты. Ул ярышларда катнаша торсын, ә без аның шахматка ничек килү юлын карап китик әле.

Сезнең күбегезнең, мөгаен, «Алисаның могҗизалар илендәге маҗаралары» дигән китапны укыганыгыз бардыр. Аны 1865 елда Англиядәге Оксфорд колледжының математика укытучысы Чарльз Доджсон язган. Иң башта ул үзенең 10 яшьлек кызы Алисага «Могҗизалар илендә күргәннәре» турында әкиятләр сөйли торган булган. Бу әкиятләр кызга һәм аның сеңелләренә бик тә ошый, һәм шуннан соң Доджсон аларны китап итеп бастыра. Аның Льюис Кэрролл псевдонимы белән чыккан «Алиса Могҗизалар илендә» китабы моннан 122 ел элек дөнья күргән. Шул чордан бирле ул миллионлаган тираж белән илледән артык телгә тәрҗемә ителгән. Китап хәзер дә кибетләрдә һәм китапханәләрдә тормый — аны бик теләп укыйлар. Хәтерләсәгез, Алисаның Көзгеләр патшалыгындагы сәяхәте шахмат тактасыннан башлана. Һәр бүлек бер йөреш рәвешендә бирелгән. Соңгы унберенче бүлектә Алиса Королева була һәм каршы якка мат куя.

Тарих безгә әкият каһарманы Алиса Лидделлның шахматта оту серләре турында мәгълүматлар калдырмаган, әмма ул Казан кызы Алисә Галләмованы җиңә алмас иде.

Алисә дә шахматның могҗизалы дөньясына әкияттәгечә килеп эләгә. Кыз Казандагы 62 нче мәктәпнең III классында укыганда, класска бер абый керә дә: «Кемнәр шахмат уйный белә?» дип сорый. Алисә ялгышып кына кул күтәрә. Чынында, өйләрендә әнисе белән шашка гына уйный икән. Шушы ялгышу аны Идел буе районындагы «Прометей» клубының шахмат түгәрәгенә алып килә. Менә шуннан соң инде тылсымчы, ягъни тренер белән бергә могҗизалар дөньясына сәяхәт башлана. Олег Ильясовичка Алисәнең тыйнаклыгы, сабырлыгы, бер эшкә тотынса, аны ахырына кадәр җиткерүе ошый. Кыз, әкренләп, шахмат белән шулкадәр мавыга, башкалар атналар, айлар буе чишә алмый торган мәсьәләләрне дә икенче көнне үк чишеп алып килә башлый. Бервакыт тренер аңа өйгә бирерлек мәсьәләләр таба алмас була. Шахматтан хәбәре дә булмаган кыз, ел дигәндә, беренче разрядлы шахматчы дәрәҗәсенә күтәрелә. Бу — сирәк очрый торган күренеш.

Уңышлар, билгеле, үзеннән-үзе генә килми. Аның өчен шахматны ярату гына да җитми. Моннан дүрт ел элек О. И. Игъламов:

— Түгәрәктә Таня исемле бик талантлы бер кыз бар иде,— дип сөйләгән иде.— Ул, уңышка ирешә башлагач, тырышудан туктады һәм... фигуралы шуу түгәрәгенә китеп барды. Анда да озак йөрмәгән. Алдыңа билгеле бер максат куймасаң, даими шөгыльләнмәсәң, спортта уңышка ирешеп булмый. Ә Алисәдә шахматчы өчен кирәкле бөтен сыйфатлар да бар шикелле. Ул шахмат тактасы каршында сәгатьләр буена утыра ала. Турнирлар вакытында командадашлары җиңелсәләр дә, аларга кисәтү ясамый, ә хаталарын тыныч кына аңлатып бирә...

Кызның шахматчылар өчен бик кирәк булган тиз отып алу сәләте, яхшы хәтерле булуы кечкенәдән үк күренә.

— Алисәгә өч яшьләр чамасы булгандыр, мин аңа кибеттән рәсемле кубиклар алып кайтып бирдем,— дип сөйли аның балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче әнисе Гамбәрия Муллагалиевна.— Берничә минуттан ул аны дөрес итеп төзеп тә куйган иде инде. Үзе сабыр, үзе укырга да, шахмат түгәрәгенә йөрергә дә, миңа булышырга да өлгерә. Өйгә бирелгән эшләрен тәмамламыйча бервакытта да йокларга ятканы юк...

— Ә менә 4 нче класста укучы Ринат — Алисәнең киресе,— дип сүзгә кушыла әтисе — Казан шәһәре юл төзү-эксплуатация идарәсе шоферы Җәүдәт абый.— Аңардан гомердә дә шахматчы чыгачак түгел, шул хәтле кыбырсык, бер урында һич утыра алмый. Башта тимераякта йөреп карады, аннан көрәш түгәрәгенә күчте, хәзер әнә, ишкәкче булам, дип йөри...

Алисәнең өйгә бирелгән эшләре кайвакытта бик күпкә җыела. Ярышларга йөргәндә — аеруча. Әле ярый классташлары булышалар. Ул Казанның 16 нчы, 131 нче мәктәбендәге классташларына бик тә рәхмәтле. Алар да Алисәне яхшы хәтерлиләр булыр — күпме классташын шахмат уены серләренә өйрәтте бит ул.

Узган елның сентябрь аеннан А. Галләмова Мәскәүдәге махсус спорт-интернат мәктәбенең шахмат классында укый башлады. Бу адым, кызның әти-әнисе, тренеры белән киңәшкәч һәм республика Дәүләт физкультура һәм спорт комитетының ризалыгын алгач, осталыкны тагын да үстерү максатыннан ясалды. Алисә аңа кадәр Чиләбедәге танылган гроссмейстер Александр Панченко белән тыгыз элемтәдә яши иде. Дөресрәге, А. Панченконың читтән торып оештырылган шахмат мәктәбендә укыды. Мәскәүдә исә кыз РСФСРның атказанган тренеры Рудольф Киммельфельд җитәкчелегендә шөгыльләнә. Әмма ул Казан өчен, Татарстан өчен чыгыш ясавын дәвам итә. Зур-зур ярышларда катнашканда, анкета тутырганда: «Тренерың кем?» дигән юлга «О. И. Игъламов» дип язып куя.

Беренче разрядка ия булган Олег Ильясович моннан 15-20 еллар элек Казанның һәм республиканың иң көчле шахматчыларыннан берсе иде. Ул берничә тапкыр Казан дәүләт университеты чемпионы исемен ала, республика беренчелегенә уңышлы чыгыш ясый. Моннан ун еллар чамасы элек «Прометей» балалар клубында тренер булып эшли башлый.

— Беләсезме,— диде ул бер очрашу вакытында,— мин үземнең төп тренерым итеп Рәшит абый Нәҗметдиновны саныйм. М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында урнашкан югары спорт осталыгы мәктәбенә өч елдан артык йөрдем. Андагы шахмат түгәрәген ул чакта Рәшит абый җитәкли иде...

Шахмат кебек серле, күпкырлы уенда кемгәдер иярү, кемнедер кабатлау — бик кыен һәм бәхәсле алым. Шулай да Алисәнең уенында Рәшит абый уйнаган партияләрдәге кыюлыкны, ахырга кадәр уйнауны, көтелмәгән чишелешләр таба алуны күрергә була. Шахмат белгечләренең фикере шундый. Үзенең биш елдан артык шахмат уйнау дәверендә кыз ике йөзләп ярышта, турнирда катнашкан икән. Алар арасында, билгеле, «Прометей» клубы ярышлары да, укучыларның РСФСР чемпионаты да, СССР халыклары Спартакиадасы финалы да бар. Шунысы куанычлы: һәр ярыш — шахматчы кызның осталыгын



*Алисә тренеры О. И. Игъламов белән Казан вокзалында*

арттыруда бер адым. Әйтик, 1983 елда РСФСР укучылары ярышында ул тугызынчы урынны гына ала, әмма күп кенә мастерлыкка кандидатларны, шул исәптән, РСФСР чемпионы Свердловск кызы Юлия Деминаны да ота. Юлиянең тренеры Алисә уенын карап торганнан соң: «Минем укучым аның яшендә болай уйнамый иде әле, бу кыз бик ерак китәчәк»,— ди. Шахмат Казан кызын, чыннан да, бик еракларга — Австриянең Инсбрук шәһәрендә үткән дөнья чемпионатына кадәр алып китте. Ә аңа кадәр ул сайлап алу турнирларында күп кенә көчле шахматчыларны отты.

Грузия шахмат мәктәбенең даны еракларга билгеле. Соңгы 10 ел эчендә хатын-кызлар арасында дөнья чемпионы исеме өчен шушы республика вәкилләре генә көрәшәләр. Майя Чибурданидзе, Нона Гаприндашвили, Нана Александрия кебек шахматчыларны бөтен дөнья белә. Алисәгә дә сайлап алу турнирларында Кахиани, Лагвилава, Джанджгава, Тереладзе кебек яшьтәшләре белән көч сынашырга һәм җиңәргә туры килде. Ә шулай да ул укучы кызлар арасында ил чемпионы Софико Николадзены җиңүен иң зур уңыш дип саный. Дөнья чемпионкасы Майя Чибурданидзе туганының кызы булган Софико моннан алдагы ярышларда гына Алисәдән өстен чыккан иде бит. Тик Казан кызы сайлап алу турнирында бөтен көчен биреп уйнады, яшь буенча үзеннән өлкәнрәк спорт мастерлары Софиева, Матвеева, Зайцеваларны да бирелергә мәҗбүр итте. Һәм 16 яшькә кадәр булган кызлар арасында дөнья чемпионатына бердәнбер путевканы яулады.

Менә ул Ак Олимпиадалар башкаласы Инсбрук шәһәре. Бирегә малайлар һәм кызлар арасында шахмат таҗын дәгъваларга дөньяның 43 иленнән 70 кә якын шахматчы килде. Безнең командада Алисәдән тыш Ленинградта яшәүче 12 яшьлек татар малае Гата Камский да бар иде. Сүз уңаенда әйтеп китәргә кирәк: Гата кырыклап көндәше арасында унөченче булды. Алисә исә яшьтәшләре арасында аңа илдә генә түгел, ә дөньяда да тиңнәр юк икәнен раслады.

Беренче турда ул Франциядән Сабине Фрутоны, икенчесендә фин кызы Жоанна Паасикангасны отты. Шуннан соң бераз йомшабрак китте — өченче турда Болгариядән Кристина Ладйова, аннан соң Румыниядән Раду Луминита белән «ничья»га уйнады. Дүртенче тур тәмамланганнан соң таблога караса, исе китте — ул өченче урында гына бара икән. Кичен илебез делегациясе җитәкчесе, халыкара гроссмейстер Айвар Гипслис бүлмәсендә зур сөйләшү булып алды.

— Көндәшләреңнән куркып уйныйсың,— диде аңа танылган шахматчы.— Алар да синең кебек үк бу ярышларга беренче тапкыр гына килгәннәр бит — курыкма!

Аннан соң беренче турларда җибәрелгән кайбер хаталар тикшерелде, көндәшләренең уены анализланды һәм алга таба кем белән ничек уйнарга кирәклеге хәл ителде.

Алдагы турларда Алисә Галләмова Колумбия вәкиле Изолина Майюльне, Югославиядән Наташа Бойковичны, Венесуэладан Амелия Херндесны, Грециядән Анна-Мария Боцарины, Нидерландиядән Рената Лимбахны, Исландиядән Лилия Гретаршдотирны, Германия Федератив Республикасыннан килгән Каролина Глусны отты. 11 уеннан — 10 очко! Бу инде, ул — дөнья чемпионкасы дигән сүз иде.

ФИДЕ, ягъни Бөтендөнья Шахмат Федерациясе, президенты Кампоманес Алисәгә алтын медаль һәм алтын йөгертелгән кубок биргәндә, аның киләсе дөнья чемпионатына сайлап алуларсыз катнашу хокукына да ия булуын әйтте. Инсбрук шәһәре мэры Казан кызына хрусталь шахматлар бүләк итте.

Шахматчы кызлар, ярышларда бер-берсенә каршы уйнасалар да, матчлардан тыш вакытларда шәһәр буйлап сәяхәтләргә бергә йөрделәр, бергә төрле уеннар уйнадылар. Кызлар бер-берсе белән хат алышырга сүз куешып, елашып аерылыштылар. Алисә бигрәк тә болгар кызы Кристина һәм югославияле Наташа белән нык дуслашты. Кайтып китәр алдыннан Кристина аңа Болгариядә чыга торган «Народен спорт» газетасын күрсәтте. Анда дөнья чемпионаты шактый киң яктыртылган иде. Мәкаләләрнең башларына игътибар итте Алисә. Беренче язма «Болгария кызы — лидер» дип атала иде. Аннан соң «Көрәш кискенләшә» һәм «Медаль булырмы?» дигән мәкаләләр. Иң соңгы хәбәр «Медальсез калды» дип исемләгән...

Безнең ил газеталары бу чемпионат турында коры, бер-ике юлдан торган хәбәрләр генә биреп бардылар. Әмма без, Алисә өчен дулкынланып, аның уңышы өчен куанып тордык. 24 нче май көнне исә «Вакыт» программасын алып баручы диктор: «Австриянең Инсбрук шәһәрендә 16 яшькә кадәрге кызлар арасында Казан укучысы Алисә Галләмова чемпион булды» дигәч, шатлыкның чиге булмады сыман. Чөнки безнең Алисә анда Татарстан данын гына түгел, илебез данын яклап көрәште, совет шахмат мәктәбенең көчен тагын бер тапкыр раслады!

Күп кенә шахмат сөючеләрне хәзер «Алисә кайчан хатын-кызлар арасында дөнья чемпионы Майя Чибурданидзе белән уйнаячак?» дигән сорау борчый. Бик урынлы сорау. Тик әле моның өчен, ким дигәндә, ике-өч ел вакыт кирәк.

...Шахмат дөньясы могҗизалы, газаплы, сихри дөнья. Аңа килеп кергән кешеләр аны бервакытта да ташламыйлар. Алисәнең дә бу могҗизалар илендә адашмыйча йөрүен теләп калыйк!

**Атлас ГАФИЯТОВ.**

# ФИДАКАРЬЛӘР ФИДАКАРЬЛЕК КӨТӘ



Бер гасырлык юбилейлар... Көттереп, зарыктырып кына килә андый түгәрәк бәйрәмнәр. Ә соңгы елларда исә без моңарга беркадәр ияләнеп, хәтта күнегеп үк киттек кебек. Гасыр башындагы революцион күтәрелеш чорында халык бәгыреннән, аның рухи җегәреннән ярсу ташкын сыман бәреп чыккан талант ияләре, каһарман рухлы, нечкә әдәби зәвыклы олы художникларга йөзәр яшь тулды. Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм Г. Камал, Г. Колахметов һәм Ш. Камал, М. Галәү һәм К. Тинчурин... Исемнәрен атаганда гына да күңелгә горурлык хисе өермә булып керә. Һәм күпләренең бер гасырлык түгәрәк бәйрәмнәре республика һәм илебез җәмәгатьчелеге тарафыннан лаеклы рәвештә билгеләп үтелде.

Бу көннәрдә исә профессиональ татар әдәби тәнкыйтен нигезләүчеләрнең күренекле вәкиле — тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме, тел белгече һәм фольклорчы Җамал Вәлидинең тууына 100 ел тулды. Әдәбият белгечләре өчен бу исем таныш һәм гыйльми даирәдә ул үзгә бер хөрмәт белән искә алына. Әмма киң катлам укучылар өчен аның исеме берни сөйләмәскә дә мөмкин. Һәм гаеп укучыда түгел!

Татар совет әдәби тәнкыйте һәм эстетик фикере үсешенә Октябрьгә хәзерлек елларында тупланган идея-эстетик мирас ышанычлы нигез булды. Безгә бу чорның күренекле әдипләре Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларның эшчәнлеге инде шактый яхшы мәгълүм. Ә менә әдәбият һәм сәнгатьнең аеруча актуаль һәм принципиаль мәсьәләләренә мөнәсәбәттә алар белән бер үк сафта торган, аларны үзенең кайгыртучан һәм дәрәҗәле тәнкыйть сүзе белән яңадан-яңа иҗат биеклекләренә рухландырып килгән, урынсыз авыр сүз һәм ят күзләрдән аралап барган киң эрудицияле профессиональ тәнкыйтьчебез Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов (1887—1932) турында әлегә бик аз беләбез булса кирәк.

1887 елның 13 октябрендә Апас авылында туып, үз чорының иң алдынгы уку йортларыннан берсе булган Иж-Буби мәдрәсәсендә белем алган Җамал Вәлиди хезмәтләрендә күтәрелгән мәсьәлә һәм проблемалар әле дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаган. Чын әдәбият мәңге актуаль һәм мәңге искермәс булганы кебек, тулы мәгънәсендәге әдәби тәнкыйть тә озын гомерле. Бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский һәм Җ. Вәлидиләрнең вакыт җилләреннән дә тоныкланмый чыккан бай әдәби-эстетик мираслары моның гыйбрәтле үрнәкләре. Вәлиди тәнкыйте һәм эстетик карашлары системасында үзәк урын билэп торган тормышчанлык һәм халыкчанлык, һәр милли әдәбиятның дөнья халыклары әдәбиятларының алдынгы үрнәкләре белән бәйләнешы һәм әдәби осталык мәсьәләләре бүген дә үзләренең актуальлекләрен югалтмады, киресенчә, совет әдәбияты һәм культурасының аеруча әһәмиятле принциплары буларак яши бирәләр.

XX йөз башы әдәбиятыбызның классик дәвере дибез... Ә зур әдәбият лаеклы шартлар һәм үзенә лаек, әйдәп барырга сәләтле идея-эстетик чынбарлыктан башка тумый. Әлбәттә, тәнкыйть өстенә үтә зур җаваплылык төшә. Һәм ул елларда әлеге җаваплылыкны җилкәгә салучыларның күренекле вәкиле Җ. Вәлиди була.

Аның иң әлекке әдәби тәнкыйть мәкаләсе Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»е дөньяга чыгу уңае белән языла. Беренче тәҗрибәсе генә булуга да карамастан,

тәнкыйтьче әсәрнең идея-эчтәлегенә, әдипнең әдәби осталыгына принципиаль һәм житди анализ бирә, әдәби жәмәгатьчелекне үзенең фикри тирәнлеге һәм зәвык нечкәлеге белән жәлеп иттерә. Авторның Г. Ибраһимов иҗатына аеруча характерлы булган социаль активлык, психологик тирәнлек һәм романтик хикәяләү үзенчәлекләрен тоеп, төпле фикер йөртүе хәтта хәзер дә хәйран калдыра. Әйтерсең лә, яшь тәнкыйтьченең моннан сигез дистәгә якын ел элгәре әле яңа басылып чыккан әсәр хакында язган тәҗрибәсе түгел, ә тарих сынавын узган әсәр хакында бүгенге белгеч язган хезмәт. Гомумән, Г. Ибраһимовның зур талантын беренчеләрдән булып таныган тәнкыйтьче аның күптармаклы иҗат эшчәнлеген озак еллар дәвамында күздән кичереп барды. Әмма бу дәвамлылык танылган әдипнең һәр язганын хуплап бару, аларга мәдхия җырлау түгел, ә чын мәгънәсендәге принципиаль тәнкыйть була. Октябрьга кадәр һәм егерменче елларда да Г. Ибраһимов белән Җ. Вәлиди арасында житди, принципиаль бәхәсләр булып уза. Әдәби-эстетик фикер үсеше процессында көн тәртибенә килеп баскан, эзләнүләр юлында очраган проблемаларга капма-каршы мөнәсәбәттә торган чаклары да була аларның. Чын профессиональ бәхәс була бу, әдәби тәнкыйтебезгә әле дә үрнәк булып саналырга лаек бәхәсләшү һәм полемика мәктәбе. Ләкин әлеге профессиональ бәхәс ни дәрәҗәдә генә кискенләшмәсен, ике шәхес арасындагы мөнәсәбәтләр элеккечә үк сәламәт кала бирә. Г. Ибраһимов тәнкыйтьче замандашының иҗатын олылаудан туктамый. Берничә мәртәбә, аерым алганда, 1913 һәм 1918 елларда, Җ. Вәлидине татар әдәби тәнкыйтенең иң күренекле вәкиле дип язып та чыга.

Җ. Вәлидине, икеләнүсез, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләребездән беренче тукайчы дип санарга була. Ул тәнкыйть эшчәнлегенең таңында ук, Г. Тукай шигырьләре белән рухланып, аларның татар халкының күңеле көзгесе булуын кат-кат билгеләп узды. Бөек шагыйрьнең һәр яңа басылып чыккан китабы хакындагы иң житди сүзне, кагыйдә буларак, ул әйтте. Тукай шигырьләре тирәсендә бәхәсләр куерса, иң соңгы һәм авторитетлы сүзне шулай ук Җ. Вәлиди язып чыкты.

Җ. Вәлиди Тукайның замандашы иде. Шуңа күрә ул аның иҗатын үсештәге, хәрәкәттәге жанлы әдәби процесс буларак кабул итте, күп кенә замандашларыннан аермалы буларак, аны күккә чөю һәм тоташтан идеаллаштыру юлыннан да бармады. Тукай — шагыйрь! Әмма бу шагыйрь язмышы татар халкының үз язмышыдай, чөнки ул ахыргача туган халкының кайгы-шатлыкларын уртаклашып иҗат итте һәм аның иҗтимагый-политик аңы да халкыныкы белән бергә үсә, камилләшә барды дип саный тәнкыйтьче.

Халык шагыйре Г. Тукай иҗатын аның дөньяга карашы һәм идея-эстетик эволюциясе яктылыгында өйрәнүне Бөек Октябрь революциясеннән соң фәнни нигездә башлап җибәрүче шулай ук Җ. Вәлиди булды. Тәнкыйтьченең 1918 елда дөнья күргән «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи әсәре» һәм 1923 елда «Мәгариф» журналында басылган «Тукайның шагыйрьлеге» хезмәтләре бүген дә шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләр өчен житди чыганак булып кала бирәләр.

«Габдулла Тукаевның мәҗмугаи әсәре»ндә Җ. Вәлиди беренче тапкыр шагыйрь иҗатын чорларга бүлеп, аның үсеш баскычларын күрсәтте, гыйльми биографиясен тудыруга беренче һәм житди омтылыш ясады. Тәнкыйтьченең Тукай турында инде ун ел чамасы төрле вакытлы матбугат органнарында чыгып килгән мәкаләләрне туплап, аларга күзәтү ясавы да үз чоры өчен гаять зур әһәмияткә ия була. Әлеге хезмәттә ул Тукай поэзиясе турында сөйләшүне традициягә кереп барган халыкчанлык турында сөйләшү белән генә чикләмичә, аның лирикасына, сатирасына, балалар өчен язылган әсәрләре һәм тәрҗемәләренә аерым-аерым тукталып, һәркайсында шагыйрь ирешкән уңыш һәм кимчелекләрне күрсәтеп чыга. «Тукай үзенең мирасы белән рус шагыйрьләреннән бигрәк Лермонтовка охшый. Ләкин ул иҗтимагый урыны вә иҗтимагый мәсьәләләргә мөнәсәбәте ягыннан Некрасовка охшый төшәдер, ул да Некрасов кебек поэт-гражданиндыр», — дип яза тәнкыйтьче.

Ш. Камал әсәрләре исә Җ. Вәлидине үзләренең тормыш дөреслеген бөтен нечкәлекләре белән күрсәтеп, социаль вакыйгаларның гади күзләрдән яшеренгән «төп ягын» ачыктырып килүләре белән жәлеп итә. Тәнкыйтьченең үз сүзләре белән әйткәндә: «Ш. Камал вакыйгаларның тышкы барышын, тышкы төзелешен түгел, бәлки эчке ягын — психологический ягын әсас итеп тотадыр. Язучы үзенең хикәяләрендә нинди дә булса бер вакыйганы башыннан ахырына кадәр җентекләп сөйләп чыгу бурычы куймый, мәгълүм бер халәте рухия (психологический момент)ны эләктереп алып, шуны бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп бастыра». Ш. Камал әсәрләренең эчке хасиятен тирәнтен аңлап әйтелгән бу фикерләр бүген дә камиллеккә ирешкән тәнкыйть булып кала бирә. Шуның белән бергә Җ. Вәлиди үзенең Ш. Камал иҗатын анализлауга багышланган хезмәтләрендә татар әдәби тәнкыйте һәм әдәби-эстетик фикере тарихында иң элгәрге булып психологик анализ һәм әдәби геройларның психологиясен күрсәтүнең зарурлыгы, әһәмияте мәсьәләләрен күтәреп чыкты. Халык-

чанлык һәм реализм юлыннан үсеп барган әдәбиятыбыз тарихында игътибарга лаеклы вакыйга була бу.

Җ. Вәлиди әдәби тәнкыйть мәйданына килгән еллар милли әдәби-эстетик фикернең реализм мәсьәләләрен аңлауда җитди эзләнүләр алып барган, тәнкыйтьнең теоретик фикерләргә һәм фәлсәфи-эстетик принципларга игътибары күзгә күренеп үскән чорга туры килә. Шуңа күрә дә ул үзенең хезмәтләрендә аерым автор, аерым китап хакында сүз алып барудан бигрәк, көн тәртибенә килеп баскан җитди теоретик һәм практик проблемалар, тәнкыйди һәм эстетик концепцияләрне ачыклый һәм хәл итә баруга йөз тотты. Әдәби тәнкыйтебезнең формалашу чоры гына булуны да искә алсак, моның үз вакыты өчен ни дәрәҗәдә җитди һәм катлаулы хезмәт булуын күз алдына китерү кыен булмас. Шулар өстенә Россиянең дистәгә якын каласында чыгып килгән татарча вакытлы матбугат органнары һәркайсы әдәбият һәм милли культура үсеше проблемаларына үз мөнәсәбәтен белдереп килгән еллар. Әдәби-эстетик зәвык һәм культура ягы төрлечә, кайбер очракларда шактый ук түбән булган авторлар да кул кушырып утырмаган, һәммәсе халык исеменнән, милләт исеменнән кайгыртып купшы-олы сүзләр сөйләгән. Ислам дөньясы һәм Көнбатыш Европа илләрендә туып, күзгә чалынган теләсә нинди фәлсәфи-эстетик карашны үз халкына, татар культурасына көчләп тагарга ашкынучылар да аз булмый. Кыскасы, гаять каршылыклы һәм җаваплы чор.

Милли әдәби-эстетик фикер үсеше өчен үзен соң дәрәҗәдә җаваплы дип хис иткән тәнкыйтьче боларның һәммәсен күзәтеп барырга, кайгыртырга, бәхәсләшергә, юире кагарга, якларга тиеш була. Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимов кебек фикер ияләре белән бер сафта торган Җ. Вәлиди үз-үзен аямыйча иҗат итә, чын мәгънәсендәге революцион-демократик әдәби-эстетик фикернең өскә чыгуы өчен принципиаль көрәш алып бара. XX йөз башы татар әдәбияты һәм әдәби-эстетик фикере үсеше юлында кузгатылып та Җ. Вәлиди катнашмый калган полемика һәм бәхәсләр, гомумән, юктыр кебек. Үзенең беренче күләмле хезмәте — «Татар әдәбиятының барышы» дип исемләнгән китабында ук ул әдәби хәрәкәтнең иҗтимагый тормыш һәм тарихи чынбарлык белән турыдан-туры бәйләнештә булуына басым ясап, бары тормыш дөреслеген чагылдырган әдәбият кына укучының күңелен били, аңарда эстетик ләззәт тудыру сәләтенә ия була дигән нәтиҗәгә килә. Һәм шул башлаган юлыннан һичкайчан тайчанмый, реализм һәм халыкчанлык принципларына нигезләнгән әдәбиятның теоретик нигезләрен салыша. Бу юлда ул рус революцион-демократик әдәби тәнкыйте һәм эстетикасы традицияләреннән гаять бәрәкәтле үрнәк ала. Агымдагы әдәбиятның күп кенә уңышларын һәм кайбер җитешсезлекләрен турыдан-туры рус әдәбиятының классик үрнәкләре белән янәшә куеп чагыштырып анализлый, әдәби хәрәкәткә юнәлеш бирә. Вәлидинең бөек рус шагыйре А. С. Пушкин иҗатына мөнәсәбәте дә әлеге эстетик карашлардан чыгып аңлатыла. Ул Пушкин шигырьләрендә туган илгә, аның табигатенә һәм рус халкына булган әчкерсез яратуның чагылышын күрә. «Пушкиннан рус әдәбиятының яңа дәвере башлана,— дип яза тәнкыйтьче.— Чөнки аңа кадәр чын-чын гүзәл вә тугры хөкамә биреpłлек әсәр юк дәрәҗәсендә иде... Ниһаять, Пушкин ул дәвернең капкасын бөтенләй ябып, рус әдәбиятын икенче дәвергә (табигый һәм хакыйкатькә якын бер гүзәллек дәверенә) кертте».

Шул рәвешле, рус әдәбияты һәм әдәби-эстетик фикере аңарда, барыннан да элек, үзендә күтәрелгән мәсьәләләрнең тормышыбызга якынлыгы, әдәби процесска үрнәк булуы белән җитди кызыксыну уята. Бер үк вакытта ул рус әдәбиятының гасырлар дәвамына Көнбатыш культурасыннан билгеле кадәр читләшебрәк килгән әдәбиятыбыз өчен арадашлык функциясе үтәвен дә аңлап эш итә. «Руслар безгә Европаны каплый торган пәрдә түгел. Бәлки ачыграк итеп, якынрак китереп күрсәтә торган бер телескоптыр»,— дип яза ул 1912 елда ук. Һәм шушы уңайдан татар вакытлы матбугатында булып узган принципиаль бәхәсләрдә ныклы, какшамас позициядә тора. Н. Думавиның «Шәрыкмы, Гарепме?..» дип куйган соравына төпле һәм аяусыз җавап белән ул каршы чыга. Әдәбият һәм сәнгатьнең, әдәби-эстетик фикернең Гарепкә яки Шәрыкка мөнәсәбәте нинди дә булса «мода»га ияру яисә кемнең дә булса теләге, тырышлыгы белән генә тормышка ашырыла торган күренеш дип санаучылар ялгыша. «...Мөһим вә олуг тарихи яңаруларга «мода» дип карарга ашыгырга ярамый. Аңар тарихи вә иҗтимагый канун тудырган мәҗбүр итеп карарга кирәк»,— дип яза тәнкыйтьче («Аң», 1916, 4 сан, 69—70 битләр).

Принципиаль һәм туры сүзле тәнкыйтьченең иҗат эшчәнлегенә аның замандашы Г. Ибраһимовның ихтирам белән каравы хакында сүз булган иде инде. Тәнкыйтьче һәм фикер иясе буларак аның исеме Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек классикларыбыз тарафыннан да хөрмәт белән искә алына. Күренекле әдәбият галиме Г. Сагъди дә татар әдәби тәнкыйте тарихына караган хезмәтендә бу иҗатка югары бәя бирә:

«Шул вакыттагы татар әдәби тәнкыйтьчеләре арасында әдәби әсәрләргә бигрәк акыл, мантыйк ноктасыннан торып һәм иҗтимагый-әхлакый якларына күбрәк кагылып анализ ясаучы, аларга бигрәк шул яктан бәя куярга тырышучылардан берсе — Җ. Вәлиди иде. Татар тәнкыйтьчеләре арасында ул вакытта иң сабырлысы, уртача темпераментлысы да шул булды. Үзе «фәлсәфи тәнкыйть» нигезен алган иде», — дип язып чыкты (Г. Сәгъди. Бездә әдәби тәнкыйть. Казан, 1927, 18—19 битләр).

«Шура» журналының 1915 елгы беренче санында, әле тәнкыйтьчене̦ң яңа танылып кына килгән чорында, агымдагы әдәби тәнкыйтькә анализдан гыйбарәт булган мәкаләдә дә игътибарга лаек юллар бар: «Җамалетдин әфәнденең тәнкыйть яза башлавына һәм тәнкыйтьче булып танылуына ике ел гына әле. Шулай булса да бу тәнкыйтьчебезне халык яратып каршы алды. Чөнки моның, бердән, гыйльми вә әдәби көче, әдәби зирәклеге яхшы ук киң; икенчедән, бу зат үзен булдыра алганы кадәр вөҗдан вә гаделлек юлы белән алып барырга, шәхсияткә тукынмаска вә тойгысына әсир бирелмәскә тырыша. Турысын әйтсәк, кода-кодагыйлык, дус-ишлек, ага-энелек хәтерен саклау кебек шәхси эшләрне тәнкыйть язган чагында бераз онытып яза. Үзенең гыйльми вә әдәби күзе күрә алган кадәресен генә гомумгә тәкъдим итә. Менә шуның өчен дә ул үзен әз вакыт эчендә гомумгә ышанычлы кыяфәт белән таныта алды. (...)

Сүзебезнең ахыры буларак, Җамалетдин әфәнденең гаять зур камиллеген дә танып үтәбез, ки ул әдип вә шагыйрьләребезне үлчәүдә бик дөрес һәм тугры бер бизмәнгә маликтер. Сез карагыз аның (...) Ризаэтдин хәзрәт, Фатихлар, Шәриф Камал, Дәрдмәнд, Габдулла Тукаев һәм Сәгыйть Рәмиевләр хакындагы сүзләрен. Менә болар бит гаять дөрес һәм бик чыннан төшенелеп, аларның әдәби дәрәҗәләрен бик тугры үлчи белеп сөйләнгән сүзләр...»

Бу юлларны китерүнең максаты, аңлашылса кирәк, Җ. Вәлиди иҗатына замандашларының, шул чордагы вакытлы матбугатның мөнәсәбәтен ачыграк һәм тулырак күз алдына китерү омтылышыннан. Кемгәдер бу бәяләрдә беркадәр комплементар рух бар сыман тоелырга мөмкин. Ләкин һич алай түгел, шул ук мәкаләдә Җ. Вәлидинең тел һәм стиленә кагылышлы күп кенә тәнкыйть фикерләре дә әйтелә. Ә инде тәнкыйтьченең объективлыгы, принципиальлеге, туры сүзлелеге хакындагы бәяләргә аның үз замандашлары да һичкайчан һәм һичбер уңайдан шик белдермәде. Чөнки Җ. Вәлиди тәнкыйтьче шәхесе өчен аеруча кыйммәтле булган, ә безнең өчен — бүгенге әдәби тәнкыйтьчеләребез өчен — бик тә җитешмәгән, әлеге сыйфатларга чын-чынлап ия була.

Әйе, Җамал Вәлиди татар әдәби тәнкыйте һәм әдәби-эстетик фикерен нигезләүчеләрнең күренекле вәкиле, Октябрьгә кадәрге әдәби процессның аеруча авторитетлы фикер ияләреннән. Татар әдәбияты, әдәби тәнкыйте һәм эстетик фикеренең Совет дәверенә җитлеккән һәм бай рухи мирас туплап килүендә аның ихтирамга лаек зур өлеше бар. Шуның белән бергә ул Совет власте елларында да әдәбият, культура һәм аеруча халык мәгарифе өлкәләрендә эшләвен актив дәвам итә, тарих, әдәбият, фольклор һәм тел мәсьәләләренә караган хезмәтләр яза. Мисал итеп, аның «Татар теленең аңлатмалы тулы сүзлеге»н хәзерләүче булуын гына да искә алу җитәр.

Дөрес, егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында аның әдәби тәнкыйть эшчәнлеге, әдәби-эстетик эзләнүләре беркадәр сүлпәнләнә сыман. Ләкин моны һич кенә дә тәҗрибәле һәм югары зәвыклы тәнкыйтьченең әдәбият мәсьәләләренә битарафлыгы белән аңлату ярамас. Матур әдәбиятның тормышчанлыгы һәм халыкчанлыгы, сәнгать әсәре буларак камиллеге, әдәби осталык критерийлары элеккечә үк аның игътибар үзәгендә була. Кулыннан килгән кадәре ул татар совет әдәбияты һәм әдәби-эстетик фикеренең нигезләрен салышуга да өлеш кертә, әдәби осталык һәм сәнгатьлелек принципларын кайнар яклап бәхәсләрдә дә катнаша. Әмма, шуның белән бергә, беркадәр икеләнеп, уйланып калган чаклары да була, әдәбият-сәнгатькә мөнәсәбәттә формалашуга юл токкан һәм үзен сиздерергә керешкән социологик берьяклылыкларны кабул итә алмый ул, дистә еллар һәм гасырлар дәвамына туплана килгән үткәндәге рухи байлыкларны кадерсезгә чыгарырга омтылучыларны күреп күңеле рәнҗи.

Ләкин педагог һәм тел галиме, фольклорчы буларак армый-талмый эшләвен дәвам итә, әдәби һәм гыйльми алмаш тәрбияләүгә зур көч куя. 1921 елда ул Казанда Көнчыгыш Академиясендә укыта башлый; 1921—1922 елларда Татарстан Җир эшләре халык комиссариаты каршында мөдир урынбасары һәм терминология комиссиясе председателе булып эшли; 1922—1925 елларда татар рабфагында укыта; 1923—1931 елларда Көнчыгыш педагогия институтында доцент булып эшли.

Тынгысыз иҗат, фидакарьлеккә тиң эшчәнлек, кызганычка каршы, вакытсыз һәм бик иртә туктап кала, өзелә. Җ. Вәлиди шәхес культы корбаны булган татар әдәбияты вәкилләреннән иң элгәргесе. Очраклы рәвештәме-түгелме, аңардан — күре-

некле тәнкыйтьче һәм фикер иясеннән башлана. 1931 елның маенда ук ул бөтен көчен һәм язмышын багышлаган әдәбияттан йолкып алына һәм 1932 елның 30 ноябрендә вафат була.

Әлбәттә, йөз еллык көннәрендә бу хакта сөйләшү бигүк урынлы да тоелмаска мөмкин. Шулай да Җ. Вәлидинең бай әдәби-эстетик мирасы хакында сүз чыккан икән, әйтәсе килгән кайбер фикерләрем белән уртаклашып узасы килә. Менә ничә еллар инде без үзебезнең агымдагы әдәби тәнкыйтебездән канәгать түгел. Укучылар гына түгел, әдәби җәмәгатьчелек үзе дә. Ләкин бу жанр хакындагы сүзләр, кагыйдә буларак, зарланулардан ары узмый, бу зәгыйфьлекнең табигате һәм сәбәпләре хакындагы сөйләшүләрдән читләшеп киләбез. Миңа калса, безнең тәнкыйтьтә үткәндәге бай әдәби-эстетик мирас белән элемтә юк, ул өзелгән. Тамырсыз агачны хәтерләтә ул. Соңармый нәтиҗә ясап, безгә Курсави һәм Мәрҗаниләрдән башланып күп гасырлар дәвамында формалашып килгән гаять бай әдәби-эстетик фикеребезгә йөз белән борылырга вакыт. Мәктәптә әдәбият дәресләрендә һәм югары уку йортларының гуманитар факультетларында халкыңның әдәби тәнкыйть һәм фәлсәфи-эстетик фикере тарихын тиешле дәрәҗәдә һәм эзлекле рәвештә өйрәнми торып чын мәгънәсендәге белгеч яисә галим, тәнкыйтьче яисә язучы булып буламы икән?.. Әлеге өлкәләргә караган гыйльми хезмәтләр белән генә чикләнмичә, үткәндәге фәлсәфи һәм тәнкыйди-эстетик мирасның үзен хрестоматияләр рәвешендә дә дөньяга чыгара башларга вакыт инде. Әмма ни сәбәпледер авыр кымшанабыз һәм авыр кыймылдыйбыз, берәүнең дә үз өстенә җаваплылык аласы килми. «Моңарга кадәр басылмаган икән, нигә әле без басарга тиеш?.. Аларсыз да яшәп киләбез ич әле...» дип фикер йөртү дәвам итә. Моннан берничә ел элек Җ. Вәлидинең йөз еллыгына аерым хезмәтләрен җыеп китап итеп чыгару мөмкин булмасмы дигән өмет белән йөргәндә, минем үземә дә кристаллашып каткан, ташка әверелгән шундый позициягә барып төртелергә туры килде.

Ә вакыт үтә. Вакыт көтми! Халык рухының җегәре, аерылмас һәм югалмас мирасы булырга тиешле хезмәтләр архив шүрлекләрендә кала бирә. Фидакарьләр бездән дә фидакарьлек көтә.

P. S. Түбәндә укучылар игътибарына Җамал Вәлидинең иң элгәрге тәнкыйть тәҗрибәләреннән кайбер үрнәкләр тәкъдим итәбез.

Ринат **МӨХӘММӘДИЕВ**,
филология фәннәре кандидаты.

# Җамал Вәлиди

# ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР*

Әдәбият бигрәк тормышның җилен, дулкынын күрсәтә, шуның өчен тормыш никадәр җилле, дулкынлы булса, аның көзгесе булган әдәбият та шулкадәр рухлы, шулкадәр күренешле була.

Әдип, шагыйрь!

Болар тормыш дәрьясының уртасына ташланган бер көймәче. Әгәр дә дәрьяның өсте тын вә салкын булса, аның көймәчесе дә һичбер хәлдә күк илә дәрьяның тоташуыннан хасил булган иксез-чиксез бер төссезлектән башка бер нәрсә күрми. Аның күз алдында, калебендә шатлык вә, йә кайгы кеби бер хис уятачак һичбер хәл вә вакыйга тумый...

Әтраф тын, көймә тын, әлбәттә, күңел дә тын! Менә бер заман акрын гына бер җил исә, дәрья өсте бераз шадраланырга, көймә дә селкенергә башлый. Ул бара. Ләкин кая? Бу җил аны кая илтә? Әгәр ул аны үзенең төзәгән идеалына таба илтсә аның күңелендә әйтеп бетергесез бер шатлык вә өмет хисе уяна. Ул гамәл итәчәк җиргә зар вә интизар булып хәрәкәткә китерүче мәрхәмәтле җилне, сөйкемле дулкынны мактап артта калганнарга сәлам сөйләп җыр җырлый. Әгәр соң инде бу җил аны кире якка, ул теләмә-

---

* Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романына беренче рецензия. — Ред.

гән тарафка өстерәсә, аның үзеннән, үзеннән генә түгел, калебеннән сагыну вә бәхетсезлек көйләре, бу шомлы җилгә, рәхимсез дулкынга ләгънәт авазлары ишетелә.

Бәгъзе дулкын чиктән тыш зураеп китә, хәтәр минутлар килә, көймә чайкала, гамәл менеп, гамәл төшеп китә. Көймәче-нең күз алды караңгылана, ул хәзер җил кай яктан исә, көймә кая таба бара, аны карамый. Аңа хәзер җәһәт тә юк, артта калган яки бара торган җир дә юк, фәкать газраилне искә төшерә торган тау-тау дулкын бар да, шуның эченә ташланган бәхетсез җан бар. Ул диңгездә үзе кебек меңнәрчә көймәләрне, көймәчеләрне күрә. Аларның бәгъзесе балык тота, бәгъзесе йөк ташый, бәгъзесе моның шикелле бәхет вә сәгадәт эзләп әллә кая өмет уты белән яктыртылган бер идеальный ноктага бара. Аларның да кайсы теләгән тарафына, кайсы теләмәгән тарафына агалар. Аларга да бәгъзе каты дулкыннар чыга, кайсы күтәрелә, кайсы төшә, кайсы чайкала, кайсы бөтенләй капланып, дәрьяның упкын кочагына атылып мәңгелек юк була.

Көймәче-шагыйрь боларның һәммәсен күрә, һәммәсен сизә һәм үзе өмет борынына барып җиткәнче, яки дәрьяның упкын кочагына атылганчы шуларны көйли, җырлый.

Менә шуның өчен дә без милләтләрнең тарихында әдәбиятның иң бөек вә камиллек ноктасына җитүен, тормышның иң кайнаган вакытына туры килгәнлеген күрәбез.

Бу кайнау безнең күзебезгә милләтнең гомуми килешендәге ташкын, дулкыннар рәвешендә күренсә дә, асылда болар аның парлары, төтеннәре генә булып, аларның мәркәз ноктасы, корып черергә башлаган иске катлауны ертып тышка чыгарга маташучы яшь йөрәкләрдә янган ялкыннар. Бу ялкын торган саен куәтләнеп, милләттә зур бер фикри вә рухи инкыйлаб тудыра вә бу рухи инкыйлаб мең төрле әһәмиятле вә әһәмиятсез, яхшы вә яман, файдалы вә зарарлы яңа формалар, яңа сурәтләр, яңа күренешләр мәйданга куя. Иске тормышта һәр көнне үзенең бинасыннан бер таш төшкәнен вә һәр рухта бер хәят тамыры өзелгәнен сизеп, үзенең табигый булган каршы тору сәләтенә бар куәте илә тәэсир иттерә. Ул яңа күренешләрне, яңа сурәтләрне кулыннан килгән кадәр вата, җимерә, яшь йөрәктә янган ялкынга су сибә, чөнки ул анда киләчәктә куәтләнеп үзенең кальгасын вә кәгъбәсен яндырачак бик куркыныч янгын күрә. Ялкын бераз гына сүнгән кебек тә була. Озакламый икенче яктан элеккегә караганда әллә ничә өлеш артык бер куәт илә бөселеп чыга, теге җимерелгән, ватылган күренешләр, сурәтләр янә төгәлләнгән, янә дәгъвалырак бер төстә мәйданга киләләр. Бу хәлдә әдипкә, шагыйрьгә теләсә ул рух вә фикерләрне тикшерсен, аңлатсын, теләсә табигаи вә сәхраи сурәтләр, күренешләр ясасын — һәркайсына сәрмая җитәрлек була. Тик анда бу хәзинәдән файдаланырлык бер көч булсын.

Безнең тормыш тынычлык, яшеренлек вә гаять бер төрлелек илә мөмтаз. Татар тынычлык сөя, тынычлыкның һәрвакыт саулыкка туры килүен сөйли. Моның илә гүя тарихка үзенең үткәргән ничә гасырлык авыр тормышының данын тели... Ул яшеренлек сөя, гүяки серләре ачылудан, гыйффәт пәрдәсе ертылуыннан курка.

Аннан соң бездәге бер төрлелек материаль, иҗтимагый вә сәяси шартларыбыздан да килә. Бездә халык күп сыйныф вә катлауга бүленми. Бездә доктор, адвокат, инженер, чиновник һәм башкалар юк. Бездә халык мулла, мужик исемле ике зур кыйсемгә аерыла. Боларга сәүдәгәр вә шәкертләрне дә кертсәк, барысы дүртәү була. Моның аркасында әллә никадәр талант гадәт илә күмелә, әллә никадәр чын характерларны, табигый омтылышларны шәригать хәят күрсәтми. Бездә шәкертләр теләсә музыкант булсын,.. теләсә техник, теләсә галим вә фән кешесе булсын, алган тәрбияләре сәбәпле үзләрен бер төрле тоярга, бер төрле сүз сөйләшергә мәҗбүрләр. Мондый, яшерен, тыныч вә бер төрле тормыш даһи сәнгатькәрләр өчен тирән идеяләр вә зур күренешле темалар тудыра алмаган кебек, беллетристлар (гади хикәячеләр) өчен дә киң сәрмая бирә алмыйдыр. Ысулы җәдидә хәрәкәте әдәбиятыбызга бик шәп тәэсир итте, бу ысулы җәдидә дулкыны да бик ярсу дулкын, ул яхшы комедияләр бирә алыр. Әмма анда зур трагедияләр тудырырлык йөрәк ялкыннары юк. Аннан алынган трагедияләр күп вакыт «Татар милләтен тәрәккый иттермәүчеләр»дәге трагедия кебек булып чыга.

Инде хәзер ысулы җәдидә дәвере дә артта калып бара. Хәзер яңалык вә искелек низаглары чалбар балагыннан, иҗектән узып бара. Рухи вә

фикри бер инкыйлаб галәмәтләре күренә. Хәзер мәйданда бөтен барлыкка ата-бабасының кабере ягыннан караучы яшь йөрәкләр бар.

Безнең яшь йөрәкләр нинди кешеләр? Алар нинди дәрт белән яна? Бу көндә бөтен инсаниятне аптыратканнан сәяси, икътисади, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләр илә мәшгульләрме, әллә тел, милләт кебек мәсьәләләр тирәсендә генә кайнашалармы? Аларда һәркайсы бар. Ләкин боларның берсе дә безнең яшь йөрәкләрне характерламый. Хәзер әле аларның йөрәгендә ялкын бигрәк үзләре өчен яна. Болар һәр шәйдән элек үзләре кеше булырга, кешелек бәйсезлеге алырга, ягъни үзләре теләгәнчә уйларга, сизәргә, гомумән, үзләре теләгәнчә булырга телиләр. Аларны хәзер һәр шәйдән элек татар тормышының тарлыгы, караңгылыгы, бер төрлелеге эчләрен пошыра, яшеренлеге аларның күрергә теләгән бик күп нәрсәләрен томалый. Бигрәк тә аларның бик күбесе дөньяга инә күзе аркылы гына карый торган каты куллы хәзрәтнең һәм дөньяны чапан астыннан гына күргән бер бала җанлы абыстайның «әлли-бәлли итәр бу, Бохарага китәр бу» диеп тирбәтеп үстергән баласы. Бәлки дөньяга инә күзеннән дә тар бер тишектән караучы бер байның колы, бер җәмәгатьнең хезмәтчесе. Әгәр дә ул дөньяны үз күзе илә күреп, үз фикере илә уйлап үз күңеле илә сизәргә теләсә, ата-ана, җәмәгать разый түгел. Моның ризыкын кисәләр. Үз юлы илә дә ризык таба ала икән, һаман да моңа җан тынычлыгы юк. Чөнки тегеләрнең вә һәммәсеннән бигрәк шәфкатьле вә пакь калебле ананың рәнҗүе яшь йөрәкне борчый. Икенче тарафтан шул ук яшь йөрәк үзенең фәлән мулла, фәлән абыстай мәхдүме яки фәлән агай вә фәлән җәмәгать кешесе булуыннан элек инсан булуын сизә вә тегеләр өчен мәгариф инсаниясеннән ваз кичүне бик зур түбәнлек, йомшаклык саный. Аның өмет күгендә ялтыраган бер идеалы була. Ләкин алган тәрбиясе, шәригать хәяте яки сәләте илә ул идеаллар арасындагы аралыкның барып җитә алмаслык ерак дәрәҗәдә булуы аптырата. Ул тормышын яңа юлга салып карый, яңа тәрбия алырга тырышып маташа, ләкин юк инде, кояш ике мәртәбә чыкмый.

Менә башлый яшь йөрәк газапланырга, башлый аның йөрәгендә трагедия утлары уйнарга. Теге тарафта әллә кайчан җан тынычлыгы юк. Ата-ана баланың тәүфикъсызлыгы, азгынлыгы өчен никадәр кайгырса, моның өчен дә шулкадәр ут йота. Бәлки артыграк та. Чөнки бу гади тәүфикъсызлык түгел, бу тагын да куркынычы, тагын да ят бер хәл.

Бу яшь йөрәкләр аталары хәзрәтнең китап-корьәнле, фәрештәле өендә дә скрипка уйнарга оялмыйлар. Галимҗан әфәнде Ибраһимовның яңа чыккан «Яшь йөрәкләр» исемле бер романында шундый яшь йөрәкләр күрәбез. Әсәрнең беренче геройларыннан Сабир илә Зыя, бертуган ике яшь йөрәк. Һәр икесе Җәләл мулланың (яки Җәләшнең) мәхдүмнәре. Хәзрәтнең угылларында өмете бик зур. Алар өчен күз тоткан идеалы — үзе хыял кылып та ирешә алмаган «ахунлык», «мөдәррислек» хезмәте. Ата шулай уйлый иде, ләкин угыллар икенче төрле җавап бирде. Заман вә табигать тәэсиреннәндерме, атаның әмәле илә баланың гамәле кара-каршы килеп бәрелештеләр.

Зыя илә Сабирның табигатьләре бер-беренә бөтенләй башка. Мөхәррир монда инсаннарның табигатендә иң мөһим ике асасе булган хиссилек илә гамәлилекне бу ике геройда гәүдәләндереп соң дәрәҗәдә куерта.

Сабир калын, киң гәүдәле, караңгы, каты йөзле. Аның бөтен торышында юк-барга илтифат итмәү, хиссиятка бирелмәү төсе күренеп торган кебек, күзләре дә куәт вә җиңелмәслек белән карыйлар. Татар мәдрәсәләренә искән инкыйлаб җиле дә аны бөтенләй тилертми. Ул ысулы җәдидә файдасына, милләт тәрәккыйсе намына әллә нинди фәлсәфәләр сатмый. Әмма Зыя, киресенчә, гаять нәзек вә хисчән табигатьле бер фәрештә. Ул сөяргә яратылган бер күңел һәм сөелергә яратылган бер образ.

Шушы ике яшь йөрәк үзләренең шушы табигатьләре аркасында остазлары, ата-аналары каршында зур гөнаһлы булып күренәләр. Авылда «авыр», «төпле», «сабыр» дип аталып килгән Сабир хәзер үзсүзле исемен ала. Җәләш мулланың төзеп куйган ахунлыгына, мөдәррислегенә якын да килми.

Соң нишләмәкче була? Авылга кайтып, мужик булып, кара хезмәт итәргә тели(...)

Галимҗан әфәнде, гомумән, әсәрләрендә гүзәллекне вә табигатьне бик югары вә назик аңлаучы, яки аңларга тырышучы һәм сөюче бер күңел булып күренә.

Яшь йөрәкләр үзенең зурлыгына карамыйча, Галимҗан әфәндәнең башка әсәрләреннән ким түгел бер дикъкать вә ләззәт илә язылган. Шуның

аркасында әсәр күркәм чыккан. Бигрәк тә сүзгә осталык вә фикергә байлык җәһәтеннән әсәр татар әдәбиятында беренче урынны тотарлык.

Галимҗан әфәнде монда шәхси һәм лирик (эчке) шагыйрь булып күренә шикелле. Ул, тормышның иң ачык күренеп торган нокталарыннан бигрәк, үзенең хыялында ялтыраган йолдызларны күрсәтә. Ачык типлар вә характерлар, әсәрнең зурлыгына, темасы киңлегенә караганда азрак. Аннан соң адәмгә гел бер төсле хис, бер төрле әсәр бирүче, бер төрле күренешләр тәкрар итә вә бәгъзән шуның илә кирәклектән артык үз ителә.

Мин әсәрдән ике төрле гомумирәк фикер алдым.

Беренче: татарның хәзерге тормышы — күзле, колаклы, йөрәкле, миле булган вә янә күрү, ишетү, сизү, уйлау сәләте вә ихтияҗы булган инсан өчен гаять дәрәҗәдә тар, караңгы, яшерен. Ул үзенең иң якын, иң сөекле булган дустыны күрсәтми. Гашыйк вә яраткан тавышыңны ишеттерми, оялган вә сизгәнеңне тышка чыгарырга ирек бирми. Әлбәттә, бу хәлгә үзенең инсаниятә, кыйммәтен аңлаган сизгер яшь йөрәк чыдый алмый.

Музыкасыз дөньяда тора алмадыгы хәлдә, шул музыка остасы ата-анасы каршында кеше үтерү, урлау, эчү илә бер дәрәҗәдә санала.

Бу кешегә нишләргә кирәк? Үләргә. Аны тормыш кысып үтерә.

Икенче: сизгер йөрәкле вә назик рухлы кешегә дөньяда тору кыен. Тормыш дәрьясында идеал эзләп еракка китүче Зыяларны дулкын алып һәлак итә, әмма бик эчкә китмичә кырыйдарак кына балык тотучы Сабирлар җилдә дә, дулкында да яши алалар(...)

(«Вакыт», 1913 ел. 28 февраль.
Мәкалә кыскартылып тәкъдим ителә)

# ШИГЫРЬЛӘР ТИРӘСЕНДӘ*

Сөю... Бәгъзеләр, әгәр бу булмаса планеталар вә аларның кисәкләре бер-берсенә ябышып тормас иде диләр. Боларча күк җисемнәре арасында булган тарту көче үзе бер төр гыйшык вә мәхәббәттер. Бу гакыл вә тәҗрибәгә нигезләнгән бер фикер булудан бигрәк, миф булырга ошый. Бер вакыт бит әле бу кояшлар, ай һәм җирләр арасында әллә нинди ирлек-хатынлык мөнәсәбәтләре булу да гөман кылына иде. Бу да шуннан гына калган түгелме? Җансыз җисемнәр һәм гакылсыз җанварлар арасында мәхәббәт булып-булмавын бер якка ташлап, инсан вә инсаният хакында гына сөйләек...

Әгәр сөю хисе булмаса, мәнфәгать фикере генә инсанны бергә җыя алмас вә, җыйса да, бик тиз талаштырып аерыр иде. Без инсан башка хайваннардан үзенең гакылы белән аерыла дибез. Ләкин мәхәббәт, сөю дигән нәрсә булмаса, ул гакыллы инсан түгел, бәлки гакыллы хайван булыр, ягъни инсанда инсаният булмас, торганы нәфес омтылышы вә мәнфәгате өчен генә тырышу булыр иде.

Без нәфес омтылышын да инсаниятнең үсеше вә камилләшүендә бик зур фактор (гамәл) итеп таныйбыз, сөю исә һәр җирдә аның куәт вә тәэсирен әхлак илә янәшәдә тотарга тырышучы шуңа капма-каршы икенче бер гамәл булып мәйданга килә. Без тарих инсаниятәә гакыл куәте вә тәрәккыят илә бергә вә даимән аннан калышмый торган бер мәхәббәт вә әхлак идеясен күрәбез. Бер тарафтан Архимедтан Эдиссонга вә икенче тарафтан Сократтан Толстойга кадәр сузылган бу ике сызык инсаният арбасының ике тәртәсе.

Кешелек дөньясының тугры эздән баруы өчен боларның һәр икесе бер тигез кирәктер. Әгәр тәртә сыңар гына булса, әлбәттә, арба бер якка чалшаер иде.

---

* Зыя Ярмәки һәм Сабирҗан Мөлековның шигырь китапларына күзәтү. — Ред.

Мәхәббәт барлыкны матурлый, бизәкли, бу бөтен тупас матдәвилеккә бер фәрештәви ямь бирә, дөньяны шагыйранәләндерә (реальный тормышны идеализировать итә). Әлбәттә, ул бу усал вә чәнечкеле дөньяның бөтен чирен шигърият пәрдәсе илә өртеп бетерә алмый, ләкин шулай да шуңа тырыша вә киләчәктә үзенең җир йөзендә хаким булып калачагына ышана: «Җирдә мәхәббәт хөкем сөрәчәк!»

Дөрес, әле бу бер утопия. Әле шайтаннар һәммәсе богауланырга, иблис җәннәттән сөрелгән кебек, бу дөньядан сөрелергә вә шагыйрьнең иблис вә шайтаннардан да яман күрдеге «сары йөз» дә инсанны тәкъдире кеби уйнату куәтен югалтып, үзе балалар уенчыгы булып калырга тиеш. Шул вакытта гына мәхәббәт булыр, пәйгамбәрләрнең, философларның идеаллары шул вакытта гына барлыкка чыгар.

*Шигырь! Бу нәрсә?*
*Мәхәббәт тавышы түгелме?*
*«Әйтегезче, бер гүзәлдән кай*
*шагыйрь рухланмаган?*
*Пушкиныңмы, Байроныңмы,*
*Лермонтовмы, кайсысы?»*

Дөрес, шагыйрьләр гүзәллек гашыйкы. Ләкин бу ниндәй гүзәллек?

Әлбәттә, бу шагыйрьнең табигатенә, дәрәҗә фикеренә, мохитына карап төрлечә булыр.

Шагыйрь — мосаувир[1]. Шуның өчен һәр шагыйрь иң элек бер сурәткә сокланучы. Ул шагыйрь генә икән, аны һәрбер матурлык җәлеп итә. Ул беразга һәммә матурлыкны сөеп, һәр гөл каршысында сайрап ала. Шагыйрьләр өчен иң мул вә иң илаһи бер сөеләчәк нәрсә — ярдыр (хәтта шигырь телендә гүзәл үзе шул мәгънәдә йөри). Бик күп шагыйрьләр фәкать шуның белән генә яшиләр. Хосусан, хөррият фикрия вә тәрәккыят гыйлмия мәйдан алмаган җирләрдә мәхәббәт шигырьләре үзенең иң югары дәрәҗәсенә ирешә вә иң куәтле сәләтләрне вә иң бөек даһиларны үзенә әсир итәдер. Без бу хәлне иске шәрык-ислам әдәбиятында бик ачык күрәбез.

Рус мөхәррирләреннән профессор Овсянников-Куликовскийның әле бу көндә дә шигырьдә әһәмиятен югалтып бетермәгән гыйшыкның киләчәге хакында бер өйрәтүе игътибарга лаектыр.

Ул әйтә: Моннан соң гыйшыкның бу вакытка кадәр саклап килгән куәт вә тәэсире югала калганда шаять шөбһә ителмәс. Хәзер хатыннарыбызда күренгән тәрәккый, аларның хокук вә хезмәттә ирләр белән киткән саен тигезләнүләре, мәхәббәтнең хәзерге хәлен бик нык үзгәрешкә очратачактыр.

Чөнки ирләрдә хатыннарга мәхәббәт хисен гыйшык дәрәҗәсенә ирештерүче нәрсә хатыннарның җенси гүзәллек, ягымлылыкларын бик оста арттырулары вә хатынлык галәмәтләрен бөтен тышкы билгеләре, тышкы бизәкләре илә саклап килүләредер. Инде фикер вә хезмәт мәйданында хатыннар ирләр илә берләшкән саен арада гыйшык утын кабыздыручы җенси галәмәтләр, җенси бизәкләр дә бетәчәк. Куликовскийның бу өйрәтүенә караганда, гыйшыкны саклаучы нәрсә фәкать — пәрдәдер. Хатыннарны пәрдә артында курчак вә уенчык итеп, бизәп асраган вакытта гына чын гыйшык мөмкин, янәсе.

Чөнки алар пәрдәдән никадәр чыксалар, шул кадәр ирләшәләр, шул кадәр наз вә нәзәкатьләрен югалталар. Шагыйрьләр мәхбубәләренең йөзләрен кояшка, кашларын яңа туган айга, күзләрен йолдызларга охшаталар. Әгәр дә кояш, ай вә йолдызлар һичбер вакыт батмасалар һәм болытлар астына кермәсәләр, хәзерге дәрәҗәдә күркәм вә кадерле булып күренмәсләр иде. Чөнки мәхәббәтне җәлеп итүче нәрсә гүзәллек кенә түгел, бәлки наз дадыр. Бу өйрәтүдән соң инде иске заманның назлы шәрыгында гыйшык уты белән янып-көеп үлүләрнең, бу замандагы сөюләрнең салкынлыгының мәгънәсе бәлки бераз аңлашылыр.

Димәк ки, хәзер борынгы заманның ялкынлы гыйшкы сүнде. Соң инде шагыйрьләр кемне вә ничек сөяргә кирәк?

*Белү мөшкел кирәк кемне сөяргә,*
*Үзең аусаң да аудармый сөяргә.*
Г. Тукаев.

[1] Мосаувир — сурәт ясаучы, художник.

*Вакытлы сөеп ни бар,*
*Мәңге сөю мөмкин түгел.*
Лермонтов

Элекке шагыйрьләр гыйшык уты белән көеп яналар иде, хәзерге шагыйрьләр сөяргә бернәрсә таба алмыйлар вә шуның өчен зар еглыйлар, чөнки сөю шагыйрь өчен тын алу кеби бер рухи ихтыяҗдыр. Ансыз аның эче поша, рухы кысыла, ул буыла.

Габдулла Тукаев үзенең вакытында бик сөеп җырлаган сөю шигырьләренең агач ат булуына ышанып, шуларга эче пошып үлде. Вакытында азат мәхәббәтнең таңчысы булган бу кеше шул агач атларыннан соң бер нәрсә сөя алмады. Чөнки ул Лермонтов илә берлектә:

*Вакытлы сөеп ни бар,*
*Мәңге сөю мөмкин түгел,*

— ди иде.

Мондый шагыйрьләргә бик ярап бетмәсә дә, сөюнең икенче бер төрлесе бар. Толстой бабай сөюе. Толстой хакында ни диик? Иреклe, азат мәхәббәтнең таңчысы, диикме? Юк, аның иреклелек, таңчылык илә һич мөнәсәбәте юк.

Ул мәхәббәт диңгезе. Һәм һичбер шауламый, дулкынланмый торган мәхәбәт диңгезе. Ул сөя һәм йомшак, тыныч, садә, тойгы вә назсыз, шуның илә бергә нык бер сөю илә сөя.

Аның сөюе гаять киң: ул бөтен инсаниятне, хәтта бөтен дөньяны сөя. Аның сөюе өчен ямьлелек тә, наз да кирәкми.

Ләкин шунысы кызганыч: әле инсаният һаман шундый тыныч вә аңлы сөю юлына керә алмый. Аның иң зур бер өлеше фәкать үзен һәм үзенекен генә сөя, аның сөяргә яратылган шагыйрьләре дә шул ук гавам фикерен шагыйранә бер сурәттә: «Үзеңне сөй, ярат үзеңне үзең»,— диеп тәкрар итә...

Сөю хакында булган бу сүзләрне «Яшьлек дәртләре» исемле бер яңа шигырь мәҗмугасен укып-укып чыккач яздым. Мәҗмуганың тышына:

*Күңелләр сүнсә, бизсә һәм өметтән*
*Ачы кайгы белән болганса, бетсә,*
*Килер мәхзүн күңелгә зур ходайдан*
*Килеп болгар кызы алдыннан үпкә,*

— диеп язылган. Мәҗмуганың эче дә фәкать шундый сөю җырлары илә тулы.

Зыя Ярмәки әфәнденең нәзымга осталыгы юк түгел. Үлчәүлеләре укырлык. Ләкин караш, фикер вә сүз тезмәсендә һичбер яңалык юк.

Кирәк нәзымында, кирәк фикерендә таза бер иҗат әсәре күренми. Якынча алганда, һәр җирдә Тукаевның өслүб бәяны илә аның сөйләгән фикер вә хисләре әвәләнә. Боларны укыганда, гадәттә, Тукаев шигырьләренең җитлекми туган баласын күрәсең. Менә сезгә бер-ике үрнәк:

*Дөрес, син бит миңа елмаясың,*
*Уйнап-көлеп тора күзләрең.*
*Авызыңнан чыгып тавышларың*
*Шатландыра кеби сүзләрең.*

Тукаевның һәркайсыгыз да белә торган «Зиләйлүге» тәэсирендә язылган бу мисрагълар никадәр туң вә никадәр прозача чыккан. Әмма шуның ахыры булган:

*Син үзең дә чәчкә, былбылкаем,*
*Чәчкә берлән тулган җанкаең.*
*Йөзең нуры миңа көлеп тора,*
*Шатландыра мине, айкаем*

мисрагълары хакыйкатән аһәңле вә аңлаешлыдыр һәм яхшы гына оригинальный бер иярүдер.

Зыя әфәнденең каләме зур җимешләр вәгъдә итмәсә дә, гомумән карaганда, анда ияреп язуга сәләт күренә, бәлки тырышса, шул юлда тәрәккый итә алыр...

Мин «Яшьлек дәртләре»нә, андагы сөюләргә зур әһәмият бирмим. Ул яктан анда һичбер җитди нәрсә тапмыйм. Шагыйрьнең шәхесе белән танышлыгым юк. Шулай булса да аның эчендәге чын яшьлек дәртләренең

шигырьләрендә язылган дәртләр түгел, бәлки шундый шигырьләр язу дәрте булуына яхшы фикердәмен.

* * *

Менә сезгә кирәк булса тагын «Сабирҗан Мөлеков шигырьләре». Мәҗмуганың иң башында булган ошбу «Үгет»не укып карагыз:

*Телеңне тый, сүзеңне үлчәп сөйлә,*
*Киреләнмә, хәтта сүз һич әйтмәм дия*
*Ирек бирсәң әгәр дә син,*
*Ни әйтмәс ул сөяксез тел*
*Кызартыр йөзеңне, калдырып зур оятка ул.*

Шагыйрь әфәнде сүзне үлчәп сөйләргә куша. Моның өчен аңа, әлбәттә, беркем дә сүз әйтмәс дип беләм. Ихтимал, шундый дустанә вә зур үгете өчен аңа рәхмәт әйтүчеләр дә булыр. Дөрес шул, сүзне үлчәп сөйләргә кирәк. Ләкин шуның белән бергә нәзымны үлчәп язарга да онытмаска тиеш.

Гади кешеләрнең гади сүзләрендәге үлчәүсезлекне бәлки Сабирҗан әфәнде бер дәрәҗә гафу итәр, әмма аның һәм шигырь һәм нәзым булу дәгъвасы илә язылган нәрсәләренең үлчәүсезлеген һичберәү гафу итмәс дип беләм. Әллә, шагыйрь әфәнде, бу заманның шигыре гыйлме гаруз[1] калыпларына сыймый дигән сүзләрне ишеткәнегез бармы? Ләкин хәбәрегез булсын, ул сүз шигырь хакында әйтелә, әмма сезнең язганнарыгызда шигърияттә булмаган, таушалып-тетелеп беткән, Мәнди анасы да белә торган, гыйлем вә фикер кыйммәте күптән булмаган сүзләрнең монда бер кыйммәте булса, ул да аның нәзымында вә ритмында булачак. Инде бу да булмагач, аның нәрсәсе кала? Алар өчен нигә кәгазь, кара әрәм итәргә? Карагыз әле зинһар, халык көенә тәкълид итеп язган булган шушы нәрсәләренә күз салыгыз:

*Тәгәрәп лә тәгәрәп аккан ай яшь*
*Нәкъ яшенле яңгыр тосле.*
*Сыгылып, сыгылып аккан яшьләрдән соң*
*Инсан күңеле карар таба, тәмам тынычлый.*

Бу җырның әүвәлге мисрагында 11 иҗек, икенчесендә 8, өченчесендә 9 вә дүртенчесендә 13 иҗек. Безнең халык җырларының һәркайсы ритмлы булулары һәм бу җырның әүвәлге мисрагындагы кеби, (лай) һәм (ай) кеби тавышларның фәкать шул вәзен хөрмәте өчен генә әйтелүе неужели шагыйрьлек дәгъвасы кылган кешеләргә дә мәгълүм булмаслык бер мөшкил. Моны бит урам егетенең дә зәвыгы сизә. Сез, Сабир әфәнде, бу иҗек саннарына игътибар итмәсәгез, бу җырыгызны бер көйгә салып җырлап карагыз. Бик аз гына зәвыгыгыз булса, бәлки шунда сизәрсез.

Шулай, Сабирҗан әфәнде, дөрес әйтәсез: сүзне бик үлчәп сөйләргә кирәк. Мин үзем инде шуңа «хосусан ул үлчәүле булса» дигән сүзне кушасым килә.

Мин сезнең «телеңне тый» дигән сүзләрегезгә дә кушылам. Әлбәттә, инде үлчәп сөйли һәм үлчәп яза белмәгәндә, телне тыярга кирәк.

Сез, ихтимал, миңа: «Сез минем шигырьләрнең начар якларын күрсәткәнсез, әмма шигырь ничек булырга тиеш, аның хакында бер юл күрсәтмәгәнсез, уңай бер сүз сөйләмәгәнсез», — диярсез. Хакыгыз бар. Ләкин, гафу итегез, миндә бер дә шагыйрьлек юк, тик бер-ике җыр беләм, шуларның арасыннан берсен монда язам, мәгънәсез булса да, бәлки сезнең кеби шагыйрь булырга теләгән кешеләргә нәзым ягыннан бер үлчәү һәм үрнәк була алыр:

*Каләм юнсаң, озын юнгыл ботыны (11 иҗекле)*
*Нәзым язсаң, белеп язгыл чугыны (11 иҗек)*

Хәзергә сезгә әйтәчәк сүзем шул кадәр.

Хуш, сау булыгыз һәм башка иптәш мөхәррир вә шагыйрьләрегезгә миннән сәлам әйтегез.

(«Вакыт» газетасы, 1913 ел, 25 апрель)

[1] Гыйлме гаруз — шигырь үлчәве турындагы белем.

# ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Бездә шагыйрьләр үзләренең сәләтләренә, фикер вә аңлатып бирү рәвешләренә, заманнарына карап нинди дәрәҗә вә катлауларга бүленәләр? Әле моның хакында ачык бер нәрсә әйтеп булмый. Шаять бер көн бездә дә әлеге бүленешләр мәйданга килер. Тик шуны гына әйтергә кирәк ки, әлегә кадәр бездә бар кадәр фикер вә зәвык әһленең шигырь вә шагыйрьләрне аңлау дәрәҗәсен якынча өч төрле дәрәҗәгә бүлергә мөмкин. Беренчеләре: шигырьне бик ят вә читен булган гарәби вә фарсы сүзләрене күбрәк катнаштырып, мөмкин кадәр аңлашылмаслык рәвештә гарузга муафыйкъ ритм вә рифмада назымнар төзү, мәгънә вә фикер җә бер тиенлек әһәмияте булмаган сүз ясау дип аңлаталар. Боларча шигырь чын шигырь булса, аның теле нигә дә гавамга аңлашылмасын, бер төрлерәк муллалар да аны белгечләр, сүзлекләр ярдәменнән башка укый алмасын. Анда теләсә кайсы халыкның лөгате катышсын, ул лөгатьне дөньядагы лөгать китапларының берсеннән дә табып булмасын, болардан һичбер зарар юк, бәлки файда гына, чөнки бер яктан бу шагыйрь булган затның бик күп лөгать белгәнен, моның бәясе бик шәп булуын гына күрсәтә. Икенче тарафтан аның шигырьләрен һәр кешегә аңлашылып, кабул ителүдән саклый.

Бу фикер безнең муллалар арасында гына түгел, вакытында шәрыкның бөтен әдәбият даирәсендә хөкем сөргән фикердер. Моңа юл ачылу сәбәпләреннән берсе — заман вә мохитнең гыйлем вә фикер туңлыгында булынуы вә иҗат чишмәләренең бик калын традиция бозлары астында калуыдыр. Әлбәттә, туңлык мәңге калмый, кайчан да булса бер фикер кояшы чыга, ул әлек вөҗданнарны үзенең җылысы белән җылытып җанландыра. Бу вөҗданнар, бу фикерләр хәрәкәткә килә, бозлар шартлап ярыла, күтәрелә, кай гына тарафка карасаң, бер ватылу, җимерелү вә үзгәрү күренә. Шулай итеп мондай җимерелү-алмашыну көннәренең әдәбиятларында шундый үлгән җаннарның терелүеннән, туңган вөҗданнарның эрүеннән хасил булган болганчык бер фикер ташкыны, фикер бәхәсләре күренә.

Монда инде укучы халык сүзенә хөрмәтне бөтенләй бер якка ташлап, шигырьдә нинди булса да бер фикер, бер тавыш эзли. Аның бик гамәли, бик түбән булуын, үз тирәсендә генә әйләнүен, көнлек вакыйгалар илә бәйләнеп ятуын тели.

— Әмма оста соң безнең фәлән әфәнде шигырь язарга, биргән теге ишаннарның кирәген,— ди яшь фикерле шәкерт, һәм,— менә бу җире гарузга бик килеп бетми икән,— диюче атасы хәзрәткә:

— Кит аннан, син ни беләсең соң, карт бюрократ!— диергә хәзер тора.

Мин моны шигырьне аңлауда икенче караш яки икенче төр дип атыйсым килә. Бу төрдә шигырьдә игътибарга алынган нәрсә беренче дәрәҗәдә фикер, һәм дә фикернең гали, тирән-фәлән булуыннан бигрәк, заманга, халыкка, мәсләккә муафыйкъ булып-булмавыдыр.

*Җыелсалар да күп, хикмәт бар,*
*Киләчәк көннәргә икмәк бар.*
*Җыелышларның бер хикмәте,*
*Шәкертләрнең алга китмәке.*

Бу караштагыларның зәвыгы югарыдагы сатырларның шигырь булуын һич икеләнүсез кабул итә. Чөнки ул сатырлар җыелышырга, иттифакка өндиләр. Иттифак исә бик яхшы нәрсә, хәтта милләтнең бөтен тәрәккыясе шуңа терәлеп тора.

Өченче караштагылар шигырьне хәзерге Европадагычарак, ягъни аның шанына муафыйграк бер олылыкта аңларга тырышучылар булып, алар аны якынча: «безнең рух вә хыялыбызга тәэсир итәчәк, хиссиятебезне, тәэсириятебезне кузгатачак һәрбер нәрсә» дип белдерәләр вә шушы даирәдә тәмам илә хөр вә мөстәкыйль куялар. Боларча шигырь вә шагыйрьләр синеңминем фикердән, караштан югары торырга, дөньяның көнлек вагы-төягеннән өстен йөрергә тиеш.

Ул бүген туып иртәгә сулмасын. Безнең эше адәм исемле миллионнарча җир корты җыентыгының колагы ишетмәсә ишетмәсен, яки ишетсә

дә аннан бернәрсә аңламасын, бер ләззәт алмасын. Монда һич бер зарар юк. Чөнки болар һәммәсе дини вә фани мәхлуклардыр.

Шигырь мәңгелек өчен сөйләнергә тиеш. Ул шундый күркәм бер сурәт эчендә, шундый бөек, матур бер фикер калдырсын ки, аны тирә-яктагы ярканат күрмәсә күрмәсен, тик мәңгелекнең үзендә аны тыңлап ләззәт вә хис алучы бер-ике дәрт вә зәвык иясе булсын, ул хаят диңгезенә җәүһәр чәчсен. Аны алырга һәрбер гади балыкчының, аучының буе җитмәсен, бу зарар түгел, кайдан булса да, кайчан булса да, бер бик оста чумучы чыгар да аны чүпләп алыр.

Шигырь турысында булган бу өч төрле фикернең өчесендә дә хакыйкатьтән өлеш бар. Ләкин төрлесендә төрле дәрәҗәдә. Беренче фикер шул көенчә соң дәрәҗәдә беркатлы вә мәгънәсез.

Шигырьдә сүз зиннәтләре бер дәрәҗәдә булырга тиеш, болар шигырьнең тышына күркәмлек бирәләр. Ләкин асыл рух булган фикер вә мәгънәгә зарар килмәү шарты белән. Буш фикер вә мәгънәне сүз сәнгате илә зиннәтләү кабыкка ефәк вә атласлар киертү илә бер әйбердер. Шигырьдә сүз сәнгате булса да, максат ул түгел. Аннан соң сүз сәнгатенең дә төрле дәрәҗәсе бар...

Рифма-ритм исә һәрвакыт шигырьнең табигатеннән санала, ләкин асыл шигырьлек өчен боларның булуы да шарт кылынмый башлады инде.

Икенче фикер, ягъни шигырьдә бер фикер эзләү гаять табигый. Нигездә бәгъзеләр шигырьне уйлану, фикер итү дип игълан кылалар. Фикерсез һәр нәрсә җансыз; җансыз һәр нәрсә бар сурәтендә юклыктыр. Матур әдәбият, столярлык, алтынчылык, буяучылык кеби башка сыйфатлардан үзенең фикерлелек, җанлылыгы илә аерыла. Шигырьдә исә әдәбиятның башка төрләренә караганда вакытта да фикер ачык вә аңлаешлы булырга тиеш. Ләкин фикер белән фикернең аермасы бар.

Шигырьдә фикер түбән, әһәмиятсез яки әдәпсез булмасын, тирән, гали яки нечкә вә күркәм булсын. Аннан соң ул фикерне әйтеп бирү рәвешендә дә хикмәт бар.

Әгәр дә фикер фән вә фәлсәфәдәге кебек коры вә салкын мантыйк илә бәян ителсә, бу шигырь булмый. Шигырьдә фикерне җиткерү тасвир вә чагыштыру ярдәмендә һәм шагыйранә гыйбарә вә стиль илә булырга тиеш.

Өченче фикердә дә раслык бар. Шигырьне идеальный һәм болардан өстен бер күркәмлек дип игълан итү аның гали шанына бик туры килә... Ләкин, бу игъланга кызыгып, рухыбызның иң тирән нокталарына игътибар итеп, күңелебезнең иң нечкә кылларын хәрәкәткә китерә торган бәгъзе бер нәрсәләрне шигырьлектән чыгарасы килми. Бу фикер әһелләрендә шигырьне үзләренә монополиягә алу хиресе бар: болар «шигырьне аңлау өчен шагыйрь булырга кирәк, менә без һәммәбез кечкенә шагыйрьләребез» диләр... Шигырьне аңлау вә тәкъдир итү өчен азмы-күпме зәвык һәм тәрбия фикрия вә мәдәния булырга тиеш. Ошбу шартка ия бер шәхеснең фикер вә карашында ялгышлык булу мөмкин. Булса да меңнәрчә, йөз меңнәрчә шундый шәхесләрдән бөтен бер җәмәгатьнең ялгышлыкка төшүен бер дә дөрес күрми. Шагыйрьләргә генә аңлашыла торган шигырьләрне язуда инсаният өчен бер дә файда булмаган кеби, алар хакында кәгазь әрәм итү генәдер.

...Шигырь инсан өчен язылса, аның үлчәве дә инсаниятныкы булырга тиеш. Шигырь тугърысындагы әүвәлге фикер шигырьне үзенә күрә бер сәнгать итеп тану һәм аны үзеннән тыш бер максатка хезмәт итдеке өчен түгел, бәлки нәфесендә булган хосусиятларга карап тәкъдир итә. Шуның өчен шигырь сөйләүне бер сәнгать, бер кәсеп кабул кылып, шуның артыннан йөрүчеләр була. Мондый шагыйрьләр падишаһлар, түрәләр, вә байлар канаты астында яклау таба. Яки халыкның, мохитнең табигатендә, гадәтендә сүз уйнатуларга, сүз ярышларына булган кызыксыну вә игътибар аларның тишелеп үсүенә ярдәм итә. Бу ике галәм. Бездә өйрәнчек вә исемле мөмтазрак катлавыбыз өчен дә мондый шигырьләр язу сәнгате мәйдан алмады. Моның илә мәшгуль булучылар булса, алар да бик аз микъдарда, тик андамонда гына булгандыр. Шуның илә бергә томанлырак кына булса да, шигырьне шулай дип аңлау хакыйкатән бездә бар, ишәйде, ихтимал ки, әле дә бардыр әле.

Шигырьне безнең фикер ияләре теләсә ничек аңласын, бездә шигырь исемендә мәйданга килгән әсәр эчендә иң күп урынны соңгы төргә карый торган шигырь аладыр. Ягъни бездә шигырь атлы нәрсә нинди булса да

бер фикергә, әйтергә яраса, бер мәсләккә хезмәт итәдер. Бу шигырь тугрысында, әлбәттә, бик ерак китеп булмый. Тик XIX гасырның соңгы яртысындагы шигырь исемендә булган нәрсәләргә карасак, болар һәммәсе нинди булса да бер фикер өчен, үзенә күрә бер мәсләк өчен языла. Дөрес, ул чагында әле «миллият», «исламият», «җир һәм ирек» кеби гомуми вә галирәк булган төшенчәләр юк. Андагы фикерләр бик вак, әһәмиятсез булуы өстенә, аларны яклау яки хурлау да күбесенчә шул фикернең нигез салучысы булган берәүне мактау яки аның тарафдарларына шелтә вә гаепләү рәвешендә мәйданга чыга. Соңра әллә нинди җил илә бер вакыт безгә дә әлеге «ислам», «хөррият», «мәдәният», «мәгариф» кеби төшенчәләр килеп керә. Шулар илә бергә әллә никадәр шагыйрьләр чыгып, болар һәммәсе каләмнәрне шул җил уңаена хутка салалар.

Бераз вакыт үткәч, дулкын, җил бераз басылгач, тагы әллә нәрсәнең тәхет тәэсирендә өченче төрдәгеләрнең көткәне парчаларда күренә башлый. Ләкин мәңгелек өчен сөйләнгән бу шигырьләрнең зур бер өлеше уңышсыз иярүдән, күрә бер көчләп кушу вә дәгъвадан гыйбарәт булганлыктан, үле туган бала кеби дөньяда бер эз калдырмыйча кабергә озатылалар. Үле туган баланы соңыннан, әлбәттә, фәкать анасы онытмый. Ул да аны нинди булса да бер күркәм сыйфаты өчен түгел, бәлки аны йөкләп йөрүе һәм тудыру мәшәкатьләреннән, һәм дә ул үлмәсә, торса, аның аркасында ана булып, рәхәт күрәчәген уйлап искә төшерә.

Шуның кебек үле туган шигырьләрне дә, фәкать аларның шагыйрьләре искә төшерү, һәм дә бу искә төшерү ул шигырьләрдә булган бер хасият өчен түгел, бәлки аларны уйлап-уйлап тудыру мәшәкатен, һәм ул шигыре терек булса, аның аркасында зур бер шагыйрь булып дөньяда рәхәт вә хөрмәт күрәчәген уйлап була.

Бездә байтак шагыйрьләр бар, туганда тере иделәр. Вакытында яшәделәр, ләкин бу яшәү бик кыска булды. Аларның үз гомерләренә дә җитмәде. Аларның бәгъзесе бөтен язганнары илә үлемгә хөкем булдылар. Бәгъзеләренең арада берәр кыйтгалары яки берәр мисраглары яшәүгә хаклы булып исән калдылар. Ләкин бу бер кыйтга яки мисраг әлбәттә үзләренең ияләрен үлемнән коткара алмадылар. Ни өчен болар тиз беттеләр? Чөнки аларның тереклек сулары җир тормышының ниһаятьсез тирәнлегенә иңгән куәтле вә сыгылмалы тамырлар аркылы түгел, бәлки әле генә явып киткән яңгырның бер чеметем дымлыгыннан алына иде.

Бервакыт кояш күтәрелде, яңгырның дымы кипте. Ул арада әле генә монда үзенең тамырсызлыгына карамыйча үреп вә хәтта яфрак ярып ята торган агач та бөрешергә, кибәргә башлады. Хәят бетте. Вакытында ул шигырь исеме күтәрә иде, хәзер аны бик күтәреп мактап сөйләгәндә дә назым гына диләр.

Бездә байтак шагыйрьләр бар, алар үзләренең гомум әсәрләр яки күбрәк әсәрләре илә яшиләр һәм мондан соң да яшәячәкләренә күңел ышана, чөнки аларда тегеләрне үлемгә хөкем иткән хәлләр күренми. Бу шагыйрьләрне әлбәттә әлегә бөтенләй санап чыгып булмый, шулай да әһле фикер вә зәвыктан «бу шагыйрьләр кемнәр» дип сораса, боларның күбрәге иң элек ошбу өч исемне әйтәчәкләренә күңел ышана: Габдулла Тукаев, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев. Һәм боларны ошбу, без язган тәртип белән әйтерләр төсле тоела...

(«Вакыт», 1913, 24—26 июль саннарында.
*Мәкаләнең баш өлеше генә тәкъдим ителә)*

Библиография

# ЗАМАН КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАП

Классик поэзиябезнең узган юлында тау түбәләре булып торган, поэтик сүз сәнгатенең һәм, гомумән, иҗтимагый фикернең үсеш баскычларын гәүдәләндергән зур әдипләр бар. Шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари да, һичшиксез, шундый шәхесләр исәбенә керә. Аның исеменнән һәм күпкырлы иҗат эшчәнлегеннән башка рухи культурабыз өлкәсендәге XVIII һәм XIX йөзләр арасына туры килүче тарихи борылыш дәверен, ягъни торгынлыктан җанлануга һәм яңалыкка күчеш процессын күз алдына китерергә мөмкин түгел.

Кызганычка каршы, Утыз Имәнинең бай һәм катлаулы иҗат мирасы моңарчы, бергә тупланып, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгәне юк иде әле. Узган ел Татарстан китап нәшрияты тарафыннан биш мең данә тираж белән бастырып чыгарылган «Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар» (Казан, 1986) дигән җыентык бу өлкәдә беренче зур казаныш булып тора. Җыентык төрле жанрларга караучы ундүрт шигырьне, җиде поэманы үз эченә ала һәм, басым ясап әйтергә кирәк, аларның күбесе матбугатта беренче тапкыр игълан ителә.

Басманың гомуми эчтәлеге, төзелеш принциплары әдәби мирасыбызны барлау һәм мөмкин кадәр үтемле итеп пропагандалау бурычына буйсындырылган. Нәкъ менә киң катлам укучыларга исәп итеп чыгарылганга күрә дә Утыз Имәнинең әсәрләре анда, үзе язганча гарәп-фарсы алынмаларын саклап транскрипцияләнүдән тыш, бүгенге әдәби телгә юлга-юл күчермәсендә дә бирелгәннәр. Шуның өстенә, берничә шигырь һәм аерым поэмалардан өзекләр шагыйрь Әхмәт Исхак эшкәртүендә хәзерге поэтик сөйләмгә яраклаштырылып тәкъдим ителгән. Димәк, Утыз Имәнинең әсәрләре җыентыкта һәрьяклап бүгенге укучы аңларлык һәм хәтта хәзерге поэтик яңгыраште кабул ителерлек хәлгә китерелгән.

Ләкин җыентыкның һәркемгә аңлаешлы, популяр итеп төзелүеннән чыгып, аның фәнни дәрәҗәсен һәм әһәмиятен киметү дөрес булмас иде. Чөнки китап асылда ике планда: һәм популяр, һәм кирәгенчә фәнни итеп эшләнгән. Аерым алганда, Утыз Имәни әсәрләренең хәзерге хәрефләрдә транскрипциясе мөмкин кадәр оригиналның үзенчәлекләрен һәм элекке әдәби тел нормаларын саклап төзелгән, димәк, тарихи-документаль дөреслек сакланган. Шул ук вакытта төрле кулъязма нөсхәләр һәм вариантлар нигезендә күпчелек әсәрләрнең фәнни-чагыштырма текстлары булдырылган. Ахыр килеп, җыентык тиешле фәнни аппарат белән тәэмин ителгән: шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган кереш мәкаләдән тыш, әдәби текстларга һәм һәр әсәр белән бәйләнешле фактларга карата искәрмәләр һәм аңлатмалар бирелгән, шулай ук Утыз Имәнинең әлеге басмага кермәгән әсәрләре турында, кушымта итеп, аңлатмалы исемлек урнаштырылган. Текстологик әзерлек һәм күп эзләнү сорый торган бу эшләрнең барсын да, шагыйрьнең әсәрләрен транскрипцияләүне һәм хәзерге телгә күчермәләрен бирүне дә кертеп, борынгы әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов башкарган. Әгәр без бүген, һич икеләнмичә, Утыз Имәнинең җыентыгы яратып һәм җиренә җиткереп эшләнгән дип авыз тутырып әйтә алабыз икән һәм әлеге китапны канәгатьләнү белән кулга алабыз икән, без моның өчен, барыннан да элек, менә шушы әдәбиятчыга бурычлыбыз.

Ләкин әлеге басманың уңышлы һәм саллы булып чыгуына зур өлеш керткән, аны эшләүдә якыннан торып катнашкан тагын бер галим бар. Ул — җыентыкның фәнни редакторы һәм Утыз Имәнинең иҗатына, шулай ук аны тудырган чорга багышланган махсус мәкалә авторы — тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов.

Яшерен-батырын түгел: әдәби һәм иҗтимагый фикер үсешендә Утыз Имәнинең роле танылса да, аның иҗатына социаль-эстетик бәя күбрәк мораль-әхлак планында гына бирелә иде һәм шагыйрьнең аң-белемне олылавын яки гыйлем-мәгърифәткә өндәвен раслый торган, ягъни анализ өчен үтә җиңел, хәтта артык берьяклы дәлилләр белән генә эш итү гадәти бер шаблонга әйләнгән иде. Димәк, Утыз Имәнинең катлаулы һәм каршы-

лыклы дөньяга карашын тарихи чор үзенчәлекләренә, иҗтимагый процессларга бәйләп анализларга һәм ачыкларга омтылу җитәрлек дәрәҗәдә түгел иде.

Мисал эзләп ерак китәсе юк: татар әдәбияты тарихының 1984 елда басылып чыккан һәм, нигездә, фәннең соңгы казанышлары югарылыгында эшләнгән беренче томында да әле Утыз Имәнине тудырган чорның социаль-экономик һәм рухи тормышыбызда көнчыгыш торгынлыгыннан котылу һәм зур үзгәрешләр юлына аяк басу дәвере булуы тиешле югарылыкта ачылмаган. Киресенчә, XVIII йөзгә характеристика бирелгән күзәтүдә «тормышның һәр өлкәсендә феодаль тәртипләр хөкем сөрә» дигән берьяклы фикер уткәрелгән. Шулай итеп, Утыз Имәни иҗатының үзенчәлекләре дә томда чор тудырган тарихи-социаль үзгәрешләр фонында азрак ачыкланган.

Ә менә без сүз алып бара торган җыентыкта шагыйрьнең иҗат мирасы чын мәгънәсендә тарихи чор контекстында һәм шул исәптән татар чынбарлыгына һәм иҗтимагый фикер үсешенә бәйләп тикшерелгән. Димәк, тарихилык нигез принцип итеп алынган.

Билгеле, Утыз Имәни яшәгән һәм аны шагыйрь, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе итеп җитештергән заманны катлаулы һәм каршылыклы яклары белән күз алдына бастыру, әдипнең дөньяга карашын һәм иҗатын шул система эчендә урыны-урыны белән бөтенләй яңабаштан карап чыгу җиңел түгел. Шуңа күрә дә бу эшкә һәм тарих белемен, һәм әдәбият гыйлемен бердәй диярлек дәрәҗәдә үзләштергән, культура һәм әдәбиятыбыз тарихына бәйләнешле җитди хезмәтләр биргән кешенең алынуы бик урынлы. Нәтиҗәдә безнең алда Утыз Имәнинең шәхесе һәм аның иҗади эшчәнлеге моңа кадәр күпләргә анык билгеле булмаган, хәтта бөтенләй кәтелмәгән яклары белән ачылып киткән.

Бернична характерлы мисал китерик. Материаль һәм рухи культура өлкәсендә искелектән яңалыкка борылышның табигатен һәм алшартларын ачыклау өчен, җыентыкта башта көнчыгыш торгынлыгының татарлардагы үзенчәлеге анализлана һәм Утыз Имәнинең рухи эзләнүләре, идеологик көрәш орбитасына тартылуы, хаклы рәвештә, әлеге торгынлыктан соң башланган социаль үзгәрешләргә бәйләп аңлатыла. Шул ук вакытта бу чорда иҗтимагый фикер үсешенең дини реформация юнәлешендә баруы, моның бездә үзенчәлекле идеологик күренеш булуы басым ясап күрсәтелә һәм, әлбәттә, Утыз Имәнинең гомуми эшчәнлегенә һәм иҗатына хас булган күп кенә казанышлар да шушы милли үзенчәлек яссылыгында тикшерелә. Болар бар да әдипнең катлаулы иҗат мирасын өйрәнүгә яңача якын килү үрнәге булып торалар.

Утыз Имәнинең дини реформация белән бәйләнешле конкрет казанышларына килгәндә, алар шулай ук җыентыкта калку һәм нечкә итеп анализланганнар. Мәсәлән, әдипнең Диния нәзарәте керткән рәсми тәртипләргә — муллаларны махсус указ биреп билгеләүгә — каршы чыгуы асылда формаль бәрелеш кенә түгел, ә динне дөньяви власть органнарыннан, димәк, дәүләттән аеру мәсьәләсен күтәреп чыгу югарылыгына кадәр үсеп җиту дигән сүз икән. Алай гына да түгел, бу ахыр чиктә руханиларның эксплуататорлык табигатен фаш итә торган социаль протестка барып тоташа икән. Махсус мәкаләнең авторы бик дөрес билгеләгәнчә, нәкъ менә шушы хәл Габдерәхим Утыз Имәнине гадәти моралист шагыйрь дәрәҗәсеннән Диния нәзарәтенә, аның йөзендә дәүләт-хөкүмәт ихтыярына да буйсынудан баш тарткан, хөкем сөрүче тәртипләр белән килешмәвен ачыктан-ачык әйтергә җөрьәт иткән кыю җәмәгать эшлеклесе югарылыгына күтәрә.

Тагын шунысы характерлы: әдипнең руханиларга һәм чынбарлыктагы тәртипләргә карата протесты җыентыкта эволюцион планда, тарихи үсештә һәм каршылыклы процесс итеп анализлана. Бу протестның тернәкләнгән чоры аның «көфер падиша» тәртипләре белән ризалашмыйча читкә китүенә һәм «изге Бохара» җирендә өметләре өзелеп, рухи кризис кичерүенә бәйләп каралса, җәмгыять белән конфликтының аеруча көчәеп киткән һәм аерым тәгълимат хәленә килгән чоры «Утыз Имәни мәсләге» дигән карашлар системасына илтеп тоташтырыла. Табигый инде, шагыйрьнең фаш итү, тәнкыйтьләү пафосы, шулай ук чынбарлыкка карата ризасызлык һәм көрәш игълан итеп, тормышны үзенчә үзгәртергә, савыктырырга үйлавы турыдан-туры аның поэзиясендә, әсәрләрендә әдәби гәүдәләнеш таба.

Шундыйлардан иң характерлылары һәм җыентыкта аеруча уңышлы һәм күп яктан яңача анализланганнары —«Төхфәт-ел-гъәрабаз вә ләтаиф-ел-гъәаз» («Гәрбәтлектә йөрүчеләргә бүләк һәм аларның хурлыкка калу вакыйгалары»), «Гъәуариф-ез-заман» («Замана бүләкләре») һәм «Тәнзиһ-ел-әфкяр фи нәсаих-ел-әхйар» («Фикерләрне пакьләндерүче файдалы киңәшләр») исемле поэмалар. Боларның беренчесендә шагыйрьнең күңелен астын-өскә китергән һәм аңарда дин башлыкларына карата социаль нәфрәт уяткан сәбәпләрнең башы Бохараның гыйбрәтле чынбарлыгы мисалында ачыла. Баксаң, мөселман иленең изге үзәге һәм ислам дөньясының йөзек кашы булып саналган «шәһри Бохара» үзе дә бозыклык һәм яманлык оясы икән, руханиларның дин битлегенә төренеп кеше талау һәм азгынлык белән шөгыльләнүе бу «изге» җир өчен дә гадәти хәл икән. Чынбарлыкка карата әнә шундый кыю хөкем чыгарган бу поэманың җыентыкта беренче мәртәбә киң итеп һәм нәкъ менә шагыйрьнең дөньяга карашындагы борылышны ачу юнәлешендә анализлануы, безнеңчә, бик мөһим.

Югарыда исемләнгән икенче поэма («Замана бүләкләре») исә, махсус мәкаләдә бик дөрес күрсәтелгәнчә, Утыз Имәни әл-Болгариның туган якларына кайткач кичергән күңел эволюциясен чагылдыруы ягыннан әһәмиятле. Пугачев явыннан соң дингә азмы-күпме ирек бирелүен күреп башта бераз куанса да, шагыйрь тиз аңлый: динне кәсепкә әйләндереп халыкны имүче татар муллалары һәм ишаннары Бохара «этләреннән» әллә ни ерак китмәгәннәр икән, җитмәсә аларның наданлыгы, байлык артыннан куа-куа, «динне бозуы» аркасында гавамның иманы-ышанулары да хорафат һәм мәҗүси йолалар белән буталып беткән икән. Һәм иң көчле сизенү: кара халыкны наданлыкта һәм томаналыкта тоту дин башлыкларына талау һәм алдап табыш алу өчен кулай шарт икән. Поэма Утыз Имәнинең дөньяга карашында барлыкка килгән яңа үзгәрешләрне әнә шулай бербер артлы ачыклау, аның социаль аңы һаман үсә һәм үткерләнә баруын күрсәтү юнәлешендә анализлана һәм, иң мөһиме, әлеге процессның каршылыклы булуына басым ясала.

Әгәр иҗтимагый фикер өлкәсендә эзләнүләрнең бер очы Утыз Имәни әл-Болгарины үзе яшәгән гыйбрәтле чынбарлыкны тәнкыйтьләүгә, социаль явызлыкны инкарь итүгә китергән булса, икенче очы аны тәрбияви-идеологик чаралар ярдәмендә, ягъни «кешенең әхлагын һәм иманын төзәтү юлы белән социаль гаделлеккә ирешергә мөмкин» дигән иллюзион-утопик нәтиҗәгә илтеп чыгара. Көчле пропаганда коралы булган әдәбият аркылы шагыйрьнең әдәп һәм динне яңарту һәм сафландыру өчен көрәш алып баруы һәм аң-белемгә, гыйлемгә карата шашынып мәдхия җырлавы әнә шуннан килә.

Утыз Имәни әл-Болгари иҗатында рациональ акыл-фикернең үсеш алуына һәм җиңүенә китерәчәк янә бер башлангыч бар. Ул — барысы да «бер туфрактан яралган» һәм «атабыз Адәм белән анабыз Һава» дәвамы булган кешеләрнең төрле аллаларга табыну аркасында үзара дошманланып бетүе һәм аның сәбәпләре турында уйлану. «Замана бүләкләре» поэмасында күтәрелгән бу мәсьәләгә шагыйрь үзе дөрес җавап таба алмаса да, «алла ярдәме» белән төрле телләр һәм диннәр туып, шул нигездә «халыкара афәтләр» барлыкка килүне икърар итү үзе дә яңалык, хәтта зур кыюлык иде» дигән бик дөрес нәтиҗә ясала җыентыкта.

Безнеңчә, «Фикерләрне пакьләндерүче файдалы киңәшләр» дигән поэмасында Утыз Имәни илаһи «ихтыяр һәм теләк» белән төрле диннәр һәм халыклар яратылуы һәм аның кире нәтиҗәләре турында уйлануга кабат әйләнеп кайта. Әлеге теманы автор бу юлы — ислам динен мактап та, үзе хурлаган христиан диненнән аерыла алмаучы Гришка мисалында гәүдәләндерә. Җыентыкның махсус мәкаләсендә геройның шулай үз диненнән ризасызлыгы, христиан чиркәвенә карата каршылыклы хис кичерүе, фәндә беренче тапкыр буларак, XVIII йөзнең икенче яртысында рус дөньясында көчәеп киткән дини расколчылык хәрәкәтенә һәм аның йогынтысына бәйләп карала. Шуның белән бергә, Гришканың дини тотрыксызлыгы белән «шәригать хөкемен тотмаучы» татар мөселманнарының тотрыксызлыгы, поэманың үзендәге кебек, хаклы рәвештә тиңләштерелеп, бер яссылыкка куеп анализлана. Ләкин болардан чыгып, җыентыкта ни өчендер Утыз Имәни исламнан башка диннәргә карата кире позициядә торган, хәтта кайбер очракта аларга «тигез» мөнәсәбәт күрсәткән (359-360 битләр) дигән бәхәсле, тәгәл ачылып җитмәгән фикер дә үткәрелә һәм әлеге фикерне ныгыту өчен шагыйрьнең «Инҗил» (христианнарда «Евангелие»), «Тәүрат» (яһүдләрдә «Тора», христианнарда «Закон»), Зәбур («Псалтырь»ның бер өлеше) һәм «Коръән» китапларын изгеләштереп әйткән өзеге китерелә.

Безнеңчә, монда Утыз Имәни әл-Болгариның нәкъ менә «алла кодрәте» белән төрле диннәр яратылуның, киресенчә, үзара каршылык һәм «дини адашулар» өчен җирлек булуын сиземләве һәм шушы хәлгә ризасызлык белдерүе күз уңыннан ычкындырылган. Икенче төрле әйткәндә, хакимлек итүче христиан диненә карата тышкы яктан түземлек яки лояльлек күрсәтүенә карамастан, шагыйрьнең сүз алып барган әсәрендә дә асылда кешеләрне бер-береннән аера торган күпдинлелекне стихияле рәвештә кире кагуы игътибардан читтә калган. Шул ук вакытта югарыда саналган «Инҗил», «Тәүрат» һәм «Зәбур» кебек христиан һәм яһүд дине китапларын Утыз Имәнинең генә түгел, ә гомумән ислам диненең Мөхәммәткә кадәр иңдерелгән үз китаплары итеп санавы һәм изгеләштерүе дә исәпкә алынып бетмәгән.

Утыз Имәни әл-Болгари китапчылык эшен җайга салуны, кулъязма китапларның дөреслегенә һәм сыйфатлылыгына ирешүне кешенең әхлагын төзәтү һәм гыйлемен күтәрүдә мөһим корал итеп саный. Шул максатны күздә тотып, ул үзе «хөрмәтле-нурлы» дип санаган китапларны һәм үзе олылаган, борынгы әдипләр иҗаты булган әсәрләрне, халык арасында таралган төрле нөсхәләрен чагыштыру нигезендә, яңабаштан карап чыга һәм күп санлы хәреф, мәгънә хаталарыннан арындыра. Шул исәптән ул, болгар-татар язма поэзиясенә нигез салучы мәшһүр шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының заманында күп мәртәбәләр басылган атаклы «кыска редакция»сен төзи. Җыентыкта Утыз Имәнинең әлеге өлкәдәге эшчәнлеге дә тәфсилле итеп, кызыклы күзәтүләр мисалында тикшерелгән һәм, беренче буларак, әдипнең татар текстология фәненә нигез салуы «гыйлем»дә камиллеккә һәм төзеклеккә омтылуы сыйфатына бәйләп исбатланган.

Күренекле шагыйрь һәм фикер иясе яшәгән чор, бигрәк тә аның икенче яртысы, иске татар теленнән милли әдәби телгә күчә башлаган чор булуы белән дә үзенчәлекле. Аерым әсәрләре белән Утыз Имәни, әлбәттә, бу процессның үзәгендә булган һәм М. Госманов, Ә. Шәрипов мәкаләләрендә моңа шулай ук игътибар ителгән. Ахыр килеп, аларда, тиешле күләмдә булмаса да, әдипнең поэтикасын анализлауга да урын бирелгән. Аерым алганда, шагыйрьнең әсәрләрендә хистән бигрәк акылның өстенлек итүе, афористик фикерләү традицияләре катнашу, гаруз үлчәмнәре белән язу кебек сыйфатлар күрсәтелгән. Саналганнардан күренгәнчә, димәк, шагыйрьнең иҗатын художестволы-эстетик яктан өйрәнү хәзергә шактый сай, ягъни беренче күз ташлауда ук күренә торган якларны барлаудан әллә ни узмый әле.

Билгеле, җыентык игътибарны җәлеп итә торган башка төр кимчелекләрдән азат түгел. Әйтик, шагыйрь иҗатында суфыйчылык сыйфатлары шактый урын алуга карамастан, бу күренеш эстетика һәм тарихи поэтика яссылыгында бөтенләй анализланмаган, шигырьләрне төркемләүдә формаль-хронологик принцип өстенлек иткән. Безнеңчә, китап дөньяви рухтагы шигырь белән ачылырга тиеш иде. Моннан тыш, хәзерге телгә тәрҗемәләрдә дә төрле мәгънә хаталары бар. Мәсәлән, «һәуа берлә һәвәсдин тәркиб итде» дигән принципиаль мәгънәле гыйбарә «ихтыяр һәм теләк белән барлыкка китерде» дип алынасы урынга «нәфес белән күңел теләгән барлыкка китерде» дип ялгыш тәрҗемә ителгән, «мантыйк» фәне «схоластик логика» диясе урында хәзерге вакытта да өйрәнелә торган фән исеме белән «формаль логика» дип алынган.

Ләкин мондый кимчелекләр җыентыкның гомуми йөзенә, бәхәссез уңышларына күләгә төшерерлек дәрәҗәдә түгел. Басма, чыннан да, мәшһүр шагыйребезнең бөеклеген бай иҗат мирасы җирлегендә һәм иҗтимагый фикер үсеше яссылыгында ачучы оригинал хезмәт булып чыккан. Махсус мәкаләнең ахырында менә шуңа тагын бер тапкыр ышандыра торган яңа күзәтү бар. Ул Утыз Имәни әл-Болгари иҗатында башлангыч алган дөньяви-рациональ яралгыларның һәм иҗтимагый-эстетик фикер табышларының Мәрҗани һәм Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри һәм Риза Фәхретдинев эшчәнлегендә ак түбәле тауларга әйләнүен анализлауга һәм тынгысыз әдип кабызган утның, зурая-зурая, татар мәгърифәтчеләренең якты факелына әверелүен күрсәтүгә кайтып кала. Җыентыкның гомуми пафосыннан аңлашылганча, үзе яшәгән чынбарлык белән конфликтка кергән һәм социаль гаделлек өчен җан атып көрәшкән әдипнең иң зур бөеклеге дә әнә шунда, үзеннән соң үсеш алачак татар мәгърифәтчелек фикеренә бәрәкәтле нигез салып, ерак узганыбыз белән бүгенге көнебезне бергә тоташтыруында.

**Марсель БАКИРОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Халык һәм культура — аерылгысыз төшенчәләр. Халык үз культурасын тудыра, күз карасыдай саклый, ә культура аның рухи дөньясын канәгатьләндерә, тарихның иң ерак төпкелләреннән килгән буыннар арасындагы җанлы бәйләнешне тәэмин итә. Антогонистик җәмгыять шартларында, мәгълүм ки, культура изүче сыйныфлар контрольлегендә, алар тәэсире астында була. Культура — рухи культура казанышларына, халыкка аң-белем бирү өлкәсендәге төп позицияләргә хуҗа булып, алар фән, әхлак һәм сәнгатьнең бөтен тәэсир итү көчен хезмәт ияләренә каршы юнәлдерәләр. Шулай итеп, халык һәм культура арасындагы мөнәсәбәтләр бозыла, алар антигуманистик характер ала. Шуңа күрә капитализмнан социализмга күчү дәверенең бәхәссез закончалыкларының берсе булып культура революциясен тормышка ашыру булычы тора. Аның төп эчтәлеге булып культураның социаль вазифасын тамырдан үзгәртеп кору, аңа үзенең төп вазифасын — хезмәт кешесен рухи яктан баету бурычын кире кайтару тора.

Культураны үстерү, аның казанышларыннан иркен файдалану — изүче сыйныфларга каршы көрәштә җиңүгә ирешкән хезмәт ияләренең мөһим бурычы. Бу бурычларны тормышка ашыру өчен көрәш илнең төрле төбәкләрендә Бөек Октябрьнең беренче көннәреннән үк башлана. Ул В. И. Ленинның илебездә социализм төзү планы нигезендә һәм Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә алып барылды. Әмма Советлар Союзындагы халыкларның тормышын социалистик үзгәртеп кору юлында, бигрәк тә аның башлангыч этабында, аерым халыкка гына хас булган үзенчәлекләр, теге яки бу мәсьәләгә якын килүдә дә үзгәлекләр бар иде. Болар барысы да социалистик

үзгәртеп коруларның темпларында, масштабында һәм тирәнлегендә, иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә, шул исәптән иҗтимагый аң һәм культура сферасында да чагылыш тапты. Шул сәбәпле яңа тормыш төзүнең беренче адымнарын, һәр халыкның социалистик культурасын өйрәнүгә багышланган тарихи тикшеренүләр — ул халыкның гына түгел, ә бәлки СССР халыклары тугандашлыгы тәҗрибәсен гомумиләштерүдә дә, фәнни-танып белүдә дә зур әһәмияткә ия.

Союздаш һәм кайбер автономияле республикаларда, мәсәлән, Чувашстан АССРда, культура революциясе тарихына, социалистик культураның тууы һәм үсеше мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр Октябрь революциясенең кырык еллыгын бәйрәм иткән вакытларда ук дөнья күрделәр[1]. Әмма бу мәсьәләләрне чын-чынлап өйрәнү җитмешенче елларның беренче яртысында башланды. Татарстан тарихчылары нәкъ менә шул чорда ике томнан торган документлар һәм материаллар җыентыгы әзерләп чыгардылар[2]. Ләкин Татарстанда культура революциясе тарихы белән шөгыльләнүче галимнәребез бу проблемага багышланган монографик тикшеренүләр белән шактый соңардылар. Һәм менә 1986 ел азагында бу мәсьәләгә багышланган монография — «Татарстанда культура революциясе (1917—1937)» исемле китап басылып чыкты. Бу монографиянең дөнья күрүе Татарстанда культура революциясе тарихын өйрәнүдә күренекле вакыйга булды. Культурабыз тарихының мөһим бер чорына багышланган әлеге хезмәт, һичшиксез, киләчәктә бу өлкәдәге тикшеренүләр өчен катализатор ролен үтәячәк.

Совет тарих фәнендә, беренче чиратта академик М. П. Ким хезмәтләрендә, культура революциясенең эшчеләр сыйныфы һәм аның союзниклары тарафыннан политик властьны яулап алуга ук башлануы һәм, асылда, илдә яңа иҗтимагый стройның тәмам җиңүе мәсьәләсе хәл ителгән чорда тормышка ашырылуы күптән исбат ителде. Безнең илдә бу процесс Октябрь революциясенең җиңүе белән башланып, утызынчы елларның беренче яртысының азагына кадәр дәвам итте. Димәк, тикшерелә торган китап тышында билгеләнгән хронологик рамкаларның тулысынча урынлы булуы бәхәссез. Монографиянең «Бөек Октябрь алдыннан Татарстан культурасының торышы» исемле бүлек белән башлануы да бик урынлы. Анда Татарстанда культура өлкәсендәге яңа күтәрелешнең алшартлары, аның социалистик яңарышка күч биргән чыганаклары һәм үсешен тизләтү мәсьәләләре карала. Күләм ягыннан зур булмаган һәм тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмов тарафыннан язылган бу бүлектә шактый бай фактик материал гомумиләштерелгән. Бу материалның бер өлеше укучыга беренче тапкыр җиткерелә. Монда 1905—07 еллардагы революция чорындагы процессларның шул вакыттагы культураның төрле тармаклары үсешендә төсмерләнгән күренешләр белән тыгыз бәйләнеше бик уңышлы күрсәтелгән. Казан өчен традицион булган китап басу эше, яңа гына дөньяга килгән татар вакытлы матбугаты, халык мәгарифе системасы, әдәбият — барысы да яңалыкның искелеккә каршы көрәшенә җәлеп ителә. Бу идеология, культура, иҗтимагый аң өлкәсендәге көрәш иде. В. И. Ленин революциянең мондый факторлары турында фикер йөрткәндә халыкның укый-яза белү мәсьәләсенә аеруча зур игътибар биргән. «Надан кеше политикадан читтә тора, аңа башта әлифба өйрәтергә кирәк. Шунсыз политика була алмый, ансыз имеш-мимешләр, гайбәтләр, әкиятләр, хорафатлар гына була»[3],— ди В. И. Ленин 1921 елның октябрендә политик агарту өлкәсендә эшләүчеләрнең II Бөтенроссия съездында ясаган докладында. Шуңа күрә, рецензияләнә торган китапның беренче бүлегеннән алып азагына кадәр бу мәсьәләгә тиешле урын бирелгән. Беренче бүлектә халык мәгарифе мәсьәләсе аерым параграфта тикшерелә. Ул XIX гасырның беренче яртысында Казанда яшәгән галим К. Ф. Фуксның укый-яза белмәгән татар үзенең кардәшләре арасында дәрәҗәле саналмый, шуңа күрә һәрбер ата үз балаларын мәктәпкә бирергә тырыша дигән сүзләре белән башлана. Әмма мөселман руханиларының катып калганлыгы һәм ислам дине өйрәтүләре уку-укыту процессының үзәген корыттылар. Шуның нәтиҗәсендә дини уку йортлары — мәдрәсә һәм мәктәпләр, бигрәк тә авыллардагылары, провинциализм, фикер торгынлыгы чыганагына әверелделәр.

Татар яшьләре укый, гыйлем нигезләрен үзләштерә дигән иллюзия тудырып, динчеләр милләтне таш стенага китереп терәделәр, ә бу патша хөкүмәте өчен бик кулай иде. Тикшерелә торган хезмәттә боларның барысына да дөрес бәя бирелгән. Кызганычка каршы, 49—50 нче битләрдә 1897 елгы халык санын алу мәгълүматларының Казан губернасында яшәүче халыкларның укый-яза белү дәрәҗәсе хакында сөйләүче саннары бутап, укучы өчен аңлаешсыз итеп бирелгән. Ул мәгълүматларны бәлки шул халык санын алу материалларында ничек бирелгән, шулай бирергә кирәк булгандыр. Бу саннар Урта Идел төбәгендә яшәүче барлык халыкларның, шул исәптән губернада яшәгән русларның да,

[1] Михайлов П. М. Культурная революция в Чувашии. Чебоксары, 1957.
[2] Культурное строительство в Татарии (1917—1941). Казань, т. 1, 1971; т. 2 (1941—1970). Казань, 1976.
[3] Ленин В. И. Әсәрләр. 33 т. Казан, 1963, 57—58 бб.

рухи яктан талаганлыгын ачык чагылдыра. Бигрәк тә татарлар арасында русча укый-яза белүчеләрнең ул вакытта Казан губернасында яшәгән чуваш, мари һәм мордвалар арасында русча укый-яза белүчеләрдән дә азрак булуы күзгә ташлана. Әмма Октябрь революциясе алды елларында халык мәгарифенең торышына багышланган параграфта бу фактларны констатацияләү белән генә чикләнүне дөрес дип әйтеп булмый. Чөнки 1897—1917 еллар арасында ике дистә ел бар. Һәм нинди еллар әле! Рус-япон сугышы, 1905—1907 еллардагы революция, реакция һәм яңа революцион күтәрелеш еллары, Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елгы февраль революциясе — җәмгыятьнең иң түбән катлауларын да актив иҗтимагый тормышка күтәргән давыллы вакыйгалар.

Бу заманда халык тормышында газета-журнал хәбәрләренең роле кискен рәвештә арта, туганнарыннан, якыннарыннан аерылган миллионнар фронтка, госпитальләргә хат язалар һәм җавап көтәләр. Болар барысы да халыкның яңадан-яңа катлауларын укырга-язарга өйрәнүгә тарткан факторлар. Татарлар да җәмгыятьнең барлык катлауларын иңләп алган бу процесстан читтә калмадылар, әлбәттә. Егерменче йөз башларында казан татарлары арасында мәгариф һәм культураның сизелерлек алга китүенә В. И. Ленин да игътибар итә. «Соңгы ун елда, — ди ул Отто Гетчның 1913 елда басылган «Рус Төркстаны» исемле китабы буенча язган конспектында,— Россиянең мөселман халкы культура ягыннан нык үсте: Казан татарларында... һәр ике җенестән 100 җанга бер мәктәп туры килә; ә православныйларда — 1500—3000 кешегә бер мәктәп. Китап һәм газета әдәбияты тарату мөселман-татарларда чагыштырмача тагын да югарырак»[4].

Бу фикерләрне ул заманда ислам дине һәм Россиядә ислам динен тотучы халыкларның культурасын тирәнтен өйрәнүче белгеч Н. П. Остроумов та куәтли. 1914 елда Ташкентта басылып чыккан «Исламоведение» исемле хезмәтендә Н. П. Остроумов татарлар арасында XIX гасырда күренә башлаган дөньяви әдәбият, фәнни хезмәтләр таралуы «аз-азлап алга бара» дип билгеләп үтә. «Элегрәк рус мәктәпләрендә укучыларга ташланган кырын карашлар хәзер инде элеккеге әһәмиятен югалтты. Рус уку йортларында укучыларның саны арта бара, хәтта кызлар өчен дә мәктәпләр барлыкка килде», дип яза Н. П. Остроумов.

1915 елда Казан губернасында Беренче бөтендөнья сугышының өлкәдәге экономик хәлгә һәм социаль-политик тормышка ясаган йогынтысын өйрәнү уздырыла. Бу тикшерүнең хөкүмәт комиссиясе йомгаклары игълан ителгән очеркта түбәндәгеләр язылган: «Татар массалары... яңа идеяләрне үзләштерү сәләтеннән мәхрүм түгелләр. Моңа алар уку-укыту эшләре яңа ысул белән алып барыла торган мәктәпләр, шулай ук татар телендә чыгып килгән һәм күпчелеге азмы-күпме укый-яза белгән халыкка барып ирешкән газета-журналлар ярдәмендә ирешәләр»[5].

Әлбәттә, бу фикердә арттырып җибәрү дә бар, әмма ул, 1917 еллар алдында бу өлкәдәге реаль тенденцияне дөрес чагылдыра дип уйларга нигез бирә. Рецензияләнә торган китапның 56 битендә А. М. Горькийның 1911 елда дөнья күргән мәкаләсеннән алынган сүзләрне укыгач, моңа тагын бер кат ышанасың.

Октябрь революциясе алдыннан Казан губернасында яшәүче халыкларның культурасына бәя биргәндә түбәндәге фактларны да онытырга ярамый. 1897 елгы халык санын алу мәгълүматларында халыкның укый-яза белүен яшь аермалыклары буенча күрсәткән бик кызыклы таблица бирелгән. Аннан күренгәнчә, 1897 елда бу регионда яшәүчеләрдән 10 яшьтән алып 19 яшькә кадәрге ирләрнең 43,8%, ә хатын-кызларның 19,2% укый-яза белгән, ә өязләрдә, шәһәрләргә караган мәгълүматларны исәпкә алмаганда, бу сан ирләр арасында 40,5%, ә хатын-кызлар арасында 15,3% тәшкил иткән; 20 дән 29 яшькә кадәргеләр арасында бу күрсәткечләр түбәндәгечә була: губерна буенча гомумән алганда ирләр арасында — 39,0%, хатын-кызлар арасында — 15,7%, ә өязләрдә 38,3 һәм 12,0 процент була[6]. Ләкин шуңа игътибар итик: 1897 елгы халык санын алу вакытында 10 яшьтә булганнар 1917 елда утызынчы яшь белән барганнар, ә унтугыз яшьлекләр гомерләренең дүртенче дистәсен тутырганнар. Нәкъ менә шушы ике буын — 1897 елда 10 нан алып 29 яшькә кадәр булганнар буыны — 1917 елгы февраль һәм октябрь баррикадаларының теге яки бу ягында булучыларның төп өлешен тәшкил иткән.

Китапны укыганда авторларның Татарстанда Октябрь революциясенә кадәрге культура торышын өйрәнүнең соңгы казанышларын исәпкә алуларына игътибар итми мөмкин түгел. Әмма алар тарих фәнендә электән килгән кайбер традицияләрнең тәэсиреннән тулысынча арынып җитә алмаганнар. Китап классик язучыбыз Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» исемле хикәясенең сюжетын сөйләп чыгудан башланып китә. Бу баштан ук «татар культурасының артталыгы» (3 б.) турын-

[4] Ленин В. И. Әсәрләр. 39 т., Казан, 1968, 549 б.

[5] Великая Отечественная война. Казанская губерния. Краткий очерк на первый год. 1914—1915 гг. 128 б. (Кулъязма хокукында Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана.)

[6] Первая всеобщая перепись населения Российской империи. 1897 г., т. XIV. Казанская губерния. 1903, X б.

дагы фикерне ассызымлау өчен эшләнгән. Бу турыда китапның башка сәхифәләрендә дә укырга мөмкин. Әмма кайвакыт шундый сорау да туа: татар халкының культура өлкәсендәге казанышларына бу рәвешле үтә таләпчән, кырыс бәя бирү кирәк микән? Мәсәлән, хезмәтнең 63 битендә татарлардан берничә рәссам, шул исәптән профессиональ рәссамнарның булуы әйтелә. Һәм моннан шундый нәтиҗә чыгарыла: «Тулаем алганда шуны әйтергә кирәк, татар халкының культура ягыннан артталыгы сынлы сәнгать өлкәсендә үзенең бөтен ачыклыгы белән күренеп тора». Ай-һай, шулаймы икән. Монда бәя башкачарак булырга тиеш иде. Атап әйткәндә, билгеле бер тарихи сәбәпләр, үзенчәлекләр аркасында татар халкы культурасының күп кенә тармаклары XX йөз башына кадәр тиешле үсеш ала алмадылар. Бу күренешкә китапның 74 нче битендә авторларның үзләре тарафыннан ук дөрес бәя дә бирелгән.

Әлбәттә, мондый капма-каршылыклар булмасын өчен хезмәтнең беренче бүлегендәге өченче параграфта бик дөрес формалаштырылган төп фикерне эзлеклерәк рәвештә тормышка ашыру сорала иде. Анда әйтелгән: «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнүче массаларның тормыш шартларын чагылдырган татар халкының культурасы акрын, кыен, тигез булмаган, әмма туктаусыз үсештә булуы белән характерлана иде. Ул самодержавие органнары һәм гаять күп төрле калибрдагы «үз» карагруһчыларының каршылыгын җиңеп үсте» (50 б.).

Авторларга кайвакытта тиешле дәрәҗәдә фикерләү киңлеге, төрле күренешләрне танып-белүдә тарихчыларга хас булганча чагыштыруларга омтылу җитенкерәми төсле. Бу хәл авторларга Татарстанда культура революциясенең башлангыч этабында гомуми закончалыкларның һәм үзенчәлекләрнең чагылышы кебек мөһим мәсьәләләрне диалектик планда төрле яклап ачып салырга мөмкинчелек бирмәгән дип әйтергә урын бар. Бу юлларның авторына элек тә Татарстанда культура өлкәсендә барган процессларда ике төрле факторларның гамәлдә булуы турында язарга туры килгән иде инде. Аларның кайберләре культура революциясе бурычларын хәл итүне катлауландырдылар, ә икенчеләре исә, киресенчә, моңа булышлык иттеләр («Казан утлары», 1983, 11 сан). Монографиядә беренчеләре турында шактый төпле әйтелгән, ә икенчеләре исә бер җирдә дә махсус игътибарга алынмаган. Соңгысына Казанда югары, урта махсус һәм гомуми урта белем бирү йортларының үз вакыты өчен ярыйсы ук киң челтәре булу кебек мөһим моментларны кертергә була. Чистайда, Тәтештә, Мамадышта, Лаешта һәм Арчада да төрле уку йортлары аз булмаган[7]. 1917 елларда Татарстанда татар милли интеллигенциясенең — укытучылар, журналистлар, язучылар, врачлар, артистлар һәм башкаларның сан ягыннан зур булмаса да, социаль катлау буларак тәмам формалашкан катлавы була. Шулай ук татар халкының борын-борыннан уку-язуга, аң-белемгә, мәгърифәткә омтылуга зур игътибар бирүен дә исәпкә алмау мөмкин түгел.

Китапта капитализмнан социализмга күчү дәверендә урыннарда партиянең культура өлкәсендәге политикасын тормышка ашырудагы күпкырлы эшчәнлеген чагылдырган гаять бай фактик материал гомумиләштереп бирелгән. Культура революциясенең беренче адымнары тәҗрибәсен конкрет яктыртканда, беренче планга совет масса күләм информация һәм пропаганда чараларының үсеше һәм шулай ук хезмәт ияләре арасында культура-мәгърифәт эшләрен җайга салу мәсьәләсе куелуны бик урынлы дип санарга кирәк.


Китапның соңгы ике бүлегендә яктыртылган китап басу һәм көндәлек матбугат мәсьәләләре дә тикшеренү үзәгенә куелган мәсьәлә рамкаларыннан чыгып киткән. Бу бүлекләрдә китап продукциясенең эчтәлегендә булган үзгәрешләрне анализлау юк дәрәҗәсендә аз, көндәлек матбугат аша халык арасында алып барылган күпкырлы эшчәнлек хакында да бик аз язылган. Болар урынына полиграфия промышленностеның торышы, аның производство базасы турында сөйләүче саннар, фактлар шыплап тутырылган.

Рецензияләнә торган китап — илебездә иҗтимагый фикер үсешенең яңа этабында дөнья күргән басма, шуңа күрә анда Татарстанда культура революциясе тәҗрибәсен тәнкыйди анализлау да таләп ителә иде. Кызганычка каршы, китап авторлары моны максат итеп куймаганнар күрәсең.

Югарыда атап үтелгән кимчелекләргә карамастан, бу китапның дөньяга чыгуы республикабызда культура тарихын өйрәнүдә мөһим вакыйга булып тора. Бу уңайдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Татарстан китап нәшрияты хәзердән үк бу хезмәтнең тулыландырылган, төзәтелгән һәм, әлбәттә, зуррак тираж белән яңа басмасын чыгару әзерлегенә керешсеннәр иде дигән теләк белдерәсе килә.

**Гомәр САБИРҖАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

[7] Обзор Казанской губернии за 1913 год. Казань, 1915 (VI бүлек).



**Дәрдмәнд йорты**
(9 январь урамы, 28)

# ШИГЪРИЯТЕБЕЗ ШОҢКАРЫ

Дәрдмәнд... Әдәбиятыбызга, мәдәниятыбызга бәрәкәтле Оренбург җире бүләк иткән иң зур шәхесләрдән ул.

Фатих Кәрими сүзләре белән әйткәндә, «заман, урын, әхвәл үзгәрү сәбәбле үзләренең әһәмиятләрен һич югалтмый торган классик шигырьләр» иҗат иткән Закир Садыйк улы Рәмиев — Дәрдмәнд — 1859 елның 23 ноябрендә Эстәрледән кырык чакрым үрдәрәк ямьле Агыйдел буена салынган татар авылы Җиргәндә сәүдәгәр Мөхәммәтсадыйк Габделкәрим улы гаиләсендә дөньяга килгән. Булачак әдипнең бөтен гомере Оренбург, Орск һәм шул тирәдәге авыллар белән тыгыз бәйләнгән. Закирга 3 яшь тулганда, аларның гаиләсе Орск өязе Юлык авылына күчеп килә, күп тә үтми, Рәмиевләр алтын казу кәсебенә керешәләр.

Башлангыч белемне үз гаиләсендә алган Дәрдмәнд соңрак агасы Шакир белән шул ук өязнең Моллакай авылында мөдәррис Габдулла Сәед улы мәдрәсәсендә белем эсти. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, укымышлы әнисе тәэсирендә рус теленнән дә хосусый дәресләр ала.

Китап сөюче, белемнән тәм табучы Дәрдмәнд 1880 елда Истанбулга юнәлә, төрек телен һәм әдәбиятын өйрәнә, әдипләр һәм шагыйрьләр белән аралаша. Нәтиҗәдә Дәрдмәнд үз заманы өчен гаять зур эрудицияле шәхес булып формалаша.

Төркиядән кайткач, ул хуҗалык эшләре белән шөгыльләнеп, җәйләрен Верхнеуральск, Орск өязләренә сибелгән егермеләп алтын приискаларында үткәрә, кышларын исә Оренбургта яши. Истанбулдан кайткач, ул иҗат эше белән дә шөгыльләнә башлый: төрекчәдән тәрҗемә итә, шигырьләр яза. Тора-бара агасы Шакир белән Дәрдмәнд арасында үзенә күрә хезмәт бүленеше барлыкка килә: искиткеч нечкә тойгылы энесенең иҗатка тартылуын хуп күргән агасы хуҗалык эшләренең төп авырлыгын үз өстенә ала, ә Дәрдмәнд күбрәк уку-язу, китапханә туплау белән мәшгуль була. 1902 елда алар татарча газета чыгарырга ниятлиләр, ләкин властьлар рөхсәт бирми. Мондый мөмкинчелек Беренче рус революциясе елларында гына ачыла. 1906 елда алар Оренбургта «Вакыт» газетасын һәм 1908 елда революциягә кадәрге татар журналлары арасында иң бай, иң абруйлы, шул ук вакытта иң каршылыклы идеяләрне пропагандалаучы «Шура» журналын чыгара башлыйлар. Бу газета-журналларда атаклы татар язылылары, язучылар, галимнәр Риза Фәхретдинев, Фатих Кәрими, Җамал Вәлиди, Шәриф Камал һәм дистәләгән башка күренекле шәхесләр актив язышa.

Беренче рус революциясе елларыннан башлап Дәрдмәнд җәмәгать эшләренә дә актив катнашып китә: Беренче Дәүләт думасына Оренбург губернасыннан әгъза булып сайлана, Оренбург шәһәр идарәсендә берничә ел буе член булып тора, шәһәрдә ачылган җәмгыяте хәйриядә, рус мәктәпләрендә укучыларга ярдәм җәмгыятендә, ачларга ярдәм итү һәм ятимнәр тәрбияләү комитетларында председатель яки эшлекле, намуслы әгъза булып эшли, үз хисабына чит илләргә җибәреп, берничә шәкерт укыта.

1907 елның 12 июнендә «Вакыт» газетасы редакциясенә язган хатыннан Дәрдмәнднең бу эшкә нинди зур әһәмият биргәнен ачык күрергә була. «Ачлар өчен исемләнеп килгән акча ачлар ихтыяҗына сарыф ителгәндә, яхшы булыр иде. Бу хезмәтне Оренбург «җәмгыятемез» ничектер матлубынча (тиешенчә) башкарып җитә алмады. Инде Казан тарафында, әгәр һаман да ихтыяҗ бар булса, һәм Казан ачлар комитеты үз хезмәтендә яхшы дәвам кылмакта булса, идарәдәге акчаны Казанга җибәрүне мәслихәт күрәбез... Янә Самара һәм Уфа губерналарында ачыккан һәм бик йончыган авыллар, идарәгә мәгълүм булса һәм шул тирәләрдә кулына акча тапшырганда ышанычлылыгы һәм инабәтлелеге үзегезгә мәгълүм кешеләр булса, идарәдән туры шул кешеләргә язлап акча җибәрү җаиз (тиешле) булса кирәк дип уйлыйбыз»,— дип яза шагыйрь.

Бөек Октябрь революциясеннән соң да Дәрдмәнд, башка күп кенә сыйныфташлары кебек, туган илен ташлап китми.

> Атам-анам йорты өчен
> Булса мең җаным фида;
> Туган-үскән җирем өчен
> Соң тамчы каным фида,

— дип җырлаган шагыйрь башкача булдыра да алмас иде, мөгаен. «Коелган корыч кебек эслүбле, тирән мәгънәле» әсәрләре белән күп гасырлы әдәбиятыбыз тарихында тирән эз калдырган Дәрдмәнд 1921 елның октябрь аенда, юлда суык тидереп, 62 яшендә Орскида вафат була.

*З. Мөхәммәтҗанова рәсеме.*
*Җ. Миңнуллин тексты.*

## Җамал Вәҗиева

# ОСТАЗЫБЫЗ ИДЕ...

Татар әдәбияты буенча күпләгән дәреслекләр һәм хрестоматияләр авторы, Казан дәүләт педагогия институтында озак еллар буе яшь буынга белем биргән педогог һәм остаз Җамал Гали кызы Вәҗиевага шушы айда сиксән яшь тула. Юбилее белән котлап журнал укучыларга аның бер истәлеген тәкъдим итә.

Гадәттә беренче күргәндә кешенең нинди дә булса сыйфаты ошап хәтердә кала. Галимҗан ага Нигъмәти үзенең төзек матур гәүдәсе, гади, әмма пөхтә киеме, бәрхеттәй кара чәче, әчкерсез күз карашы, ягымлы йомшак тавышы белән безнең Көнчыгыш педагогия институты студентларының күңеленә бик якын булып урнашып калды. Моңа кадәр без Х. Бәдигый һәм аз гына булса да Гали Рәхим, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Шәрәф лекцияләрен тыңладык. Болар үз өлкәләрендә, һичшиксез, зур галим, тышкы күренешләре белән мәһабәт, әдәп-тәрбияләре ягыннан да югары торган интеллигент кешеләр иде. Алар да безнең хәтердә һәрберсе үз урынын уңай яктан алып тора...

Галимҗан ага Көнчыгыш педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасына беренче коммунист буларак килде. Ул 1919 елның язында Коммунистлар партиясенә член итеп алынган, газета-журналларда, үзәк башкарма комитеты аппаратында, дәүләт нәшриятында җаваплы эшләрдә чыныккан. Билгеле, эш исемдә, билетта гына да түгел, без аны бөтен рухы белән чын коммунист итеп таныдык.

Галимҗан ага үз эшен XX йөз башы татар классик әдәбиятын укытудан башлады. Бу курс Октябрь социалистик революциясенә кадәрге әдәби мирасның зур бер өлеше. Беренче лекциясен ул культура мирасын нигә, ни өчен файдалану кирәклеге турында марксизм-ленинизм өйрәтүләре белән башлады. Йомшак, сабыр һәм тыныч тавыш, фәнни фикерләренең ачык, эзлекле логик бәйләнешле бирелүе безне сокландырды. Галимҗан аганың 1922—1924 елларда ук инде Мәскәүдә чыга торган «Яшь эшче» журналында халык өчен популяр мәкаләләре һәм 1928 елда «Кызыл Татарстан» газетасында «Иске әдәби мирастан файдаланырга кирәкме?» исемле махсус мәкаләсе басылып чыккан иде. Шунлыктан да булса кирәк, ул материалын белеп, тарихи тирән аңлап, олы хөрмәт белән, иркен эш итте. Нәтиҗәне салмак, сабыр ясады, әдәбият исемлеген яздырды, консультация сәгатьләрен, практик дәрес булачагын искәртте. Болар да безнең өчен өр-яңа нәрсәләр, яңа алымнар иде. Бу лекция безгә, булачак телче һәм әдәбиятчы укытучыларга ерак юлларны күрсәтүче якты бер маяк булып калды. Студентларның эш алымнарына да уңай борылышлар ясалды, эшлексез, ялкауларга юллар киселде, мөстәкыйль эшләү, индивидуаль таләп мәсьәләләре алга куелды.

Кафедрага килү белән Галимҗан ага мәктәпләр өчен укытучылар хәзерләүдә һәм гомумән уку-укытуга караган беренче дәрәҗә әһәмиятле мәсьәләләрне тиз сизеп алды һәм шунда ук конкрет эшкә дә тотынды. Әле моңа кадәр әдәбият белеме, әдәбият теориясе һәм әдәбият тарихы курслары буенча системалы төзелгән, документ буларак формалашкан программалар юк иде.

1932 елның апрель аенда ВКП(б) Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турында» махсус карар кабул итте. Шул уңай белән Галимҗан ага кафедраның киңәйтелгән утырышында зур доклад белән чыгыш ясады. Әдәбият укыту алдында торган бурычлар, язучыларның үзләре, иҗат эшчәнлегенә, аерым әсәрләренә, шушы партия карары яктылыгыннан чыгып, дифференциаль якын килү мәсьәләләрен алга куйды. Үзе исә күтәренке рух, ялкынлы дәрт белән урта мәктәпләрнең бишенче классы өчен татар әдәбияты дәреслеге өстендә эш алып бара башлады һәм тиз арада тәгәлләп тә бирде.

1933 елның көзендә РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты пединститут дирекциясенә Оренбург педагогия институтына татар теле һәм әдәбияты белгечләре сорап кәгазь җибәрде. Эшне башлап оештырырга тәҗрибәле кешеләр кирәк иде. Бу эш тә Галимҗан ага җилкәсенә төште. Үзе белән ул хатыны Җиһан ханымны, мине, аспирант Солтан Байковны алды. Өй китапханәсендә нәрсәсе булса, шуны төяде. Бер купеда бардык, бер квартирада тордык, бер табактан ашадык.

Галимҗан ага Оренбургта әдәбият белемен һәм әдәбият теориясен, С. Байков борынгы һәм XIX йөз әдәбиятын, мин XX йөз башы һәм совет әдәбияты курсларын укыттык. Өченче курска җитеп студентлар төп белгечлек буенча бернәрсә укымаган, тыңлама-

ган иде. Планнары, программалары да юк. Күп эшне Җиһан ханымның актив ярдәме белән Галимҗан ага үзе башкарды. Без Солтан белән икәүләп аның ике ягына утырабыз да, иртәгә укытачак теманың планын, төп проблемаларын, материалларын сорашабыз, язабыз. Кайберләрен ул бездән сөйләтеп тә карый. Тәмам аргач, Җиһан ханым татар халкының моңлы көйләрен гармунда тартып җибәрә, бию көйләрен уйнап шаярта... Институт директоры Абдуллинның керпе баласы бар икән. Җыелышып аның йөрешен, нәни аякларын күзәтәбез, шикәр кимерүеннән сак кына көлеп тә алабыз.

Институтка якын гына Х. Ямашев исемендәге китапханә бар. Шуның зур гына залында Галимҗан ага: «Пролетариат әдәбиятының беренче үрнәкләре һәм Х. Ямашев», «Г. Тукай — халык шагыйре», «Классик әдип Г. Ибраһимов», «А. М. Горький һәм татар язучылары» темаларына докладлар сөйләде. Без дә чыгышлар ясадык.

Институт коллективы һәм гомумән Оренбург халкы арасында Галимҗан ага гаять зур хөрмәткә ия булды, аларда аның онытылмас якты эзләре калды. Бу тарихи вакыйгаларның җанлы шаһитләре Ш. Абилов, И. Ишмөхәммәтов, карт укытучы Гөлсем Хәсәновалар моны әле хәзер дә сагынып искә алалар.

...Галимҗан ага үзенең гаиләсе белән Казанның Эрнест Тельман урамындагы агач йортта, өске катта (хәзер 4 йорт, 7 квартира) яшәде. Тар гына агач баскыч, 4-5 хуҗаның гомуми кухнясын үтеп, озын гына коридорның сул ягында ике бүлмәле квартира. Кечерәге — йокы бүлмәсе дә, китапханәсе дә, эш бүлмәсе дә. Кояшка караган зуррак якта — зур агач кисмәккә утыртылган роза гөле яшел яфраклары белән ямь биреп тора. Бервакыт мин килеп кергәндә 4-5 яшьлек кызлары Йолдыз рәсемле китап укый, 2-3 яшьлек уллары Энгель нәрсәдер өя-сүтә, аның үз шөгыле. Ә бүлмәнең уртасында озын гына агач өстәл, Галимҗан ага машинкада басылган эшен төзәтә. Өстендә яңа юган кардай ак күлмәк, җиңнәрен терсәгенәчә сызганган, пөхтә итеп кырынган, дулкынланып торган кара чәчләре үзенә матурлык өстәп тора. Уйлары, фикерләре дөньясына чумган, нәрсәдер яза. Тынлык, һәммәсе эштә.

Минем арттан ук диярлек бүлмәгә К. Нәҗми, ә бераздан Г. Толымбай, К. Тинчурин һәм Ф. Сәйфи килеп керделәр. Сөйләшүләренә караганда, Галимҗан ага августта булачак Совет язучыларының беренче Бөтенсоюз съездында сөйләнәчәк доклады белән утыра икән. Алар шуны карап чыгарга, редакцияләргә җыелганнар. К. Тинчурин драматургия турында язган чыгышын К. Нәҗми кулына тапшырды. Мин шушы язманы гына укып чыгуларын тыңлый алдым. Аның эчтәлеге, рус телендә язылу ягыннан зур канәгатьләнү белдерделәр.

1934 елның сентябрь башында бу язучыларның мин тагын бер утырышына туры килдем. Анда съезд йомгаклары турында сүз барды. Съездда К. Тинчурин, Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, Ф. Сәйфи, Г. Толымбай тавыш бирү, Г. Ризван, Х. Туфан, К. Төхвәтуллин киңәш бирү хокукы белән катнашканнар. Докладны Татарстан язучыларының оргкомитеты җитәкчесе К. Нәҗми, драматургия турында К. Тинчурин чыгыш ясаган. Делегатлар съезддан зур канәгатьләнү белән кайтканнар. Аеруча А. М. Горькийның съездны ачып җибәрүе һәм доклады, ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре А. А. Ждановның речь аларны бик нык рухландырган. Эшләргә, яңача эшләргә, милли әдәбиятыбызның идея-эстетик ягын, сәнгатьчә эшләнеш сыйфатын тагын да үстерергә дигән дәрт балкый иде аларда.

Галимҗан ага өендәге мондый фәнни фикер алышуларга, аерым консультация, киңәшүләргә бик еш очрарга туры килә иде. Әлбәттә, мондый киңәшүләр, фикер алышулар шома гына үтмәде. Каршылыклар, ризасызлыклар, үз карашларын алга сөрүчеләр шактый булгалый иде. Әмма алар тупас шау-шусыз, үзара аңлашып тәмамлана иде. Теоретик яктан зур хәзерлекле, практик тәҗрибәле, татар әдәбиятын аркылысын-буйга карап чыккан, аның бәйләнешләре данрәсен киң күзаллый торган Галимҗан ага ул каршылыкларны чишү-сүтүдә ныклы терәк, ышанычлы галим булды. Аны тыңладылар, аңа ышандылар.

Югары Осланда язучыларның аерым йортлары, зур гына чия бакчалы дачасы бар иде. Җәйләрен төркем-төркем булып язучылар шунда ялга гаиләләре белән чыга торган булдылар. Галимҗан ага гаиләсенә ялганып ничә мәртәбә барсам да, аның дөнья мәшәкатеннән айнып, бушанып ял иткәнен хәтерли алмыйм. Аны һаман әдәбият-сәнгать мәсьәләләре, шуның җанлы кешеләре чолгап ала, ул шуның казанында кайный торган булды. Әдәбиятчылар яше дә, карты да аның тирәсенә җыйналды, аның янында тупланды. Чуваш язучысы Хузангай да, рус язучысы Зернит тә аңа киңәшкә килде, хөрмәт иттеләр. Институтта дөньякүләм тарих белгече профессор Сингалевич тә, дөньякүләм әдәбият белгече профессор Г. Ф. Линцер да, рус әдәбияты доцентлары Потоцкий һәм Подъячевлар да аның фәнни карашлары белән хисаплаштылар, хөрмәт иттеләр. Чөнки ул, Г. Ибраһимовтан соң, республикада һәм педагогия институтында әдәбият-сәнгать мәсьәләләренең иң авыр йөген тартучы интернационалист галим булды. Кенентенгә авыштырып намус белән эшләде. Гадел, тыйнак тормыш белән яшәде. Бөтен гомерен, барлык көчен илена, аның халкына багышлады. Хәзерге буынга үзенең хезмәт җимешләрен — зур мирас байлыгын калдырды.

# ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ ХАТЛАРЫ

*Хатлар. Саргая башлаган кәгазьләрдә сугыш елларында язылган хатлар. Шәхси архивымны актарганда, алар кулыма эләккән саен, хәтер мине үзенең канатларында утлы, михнәтле Бөек Ватан сугышы юллары буенча алып китә. Төрле вакыйгалар, аларның ачысы, төчесе, фронтовик дуслар искә төшә. Күңел сугыш кырларында ятып калган һәм бергә газап чиккән дусларга карата сагыну хисләре белән тула...*

*Менә кырык елдан артык инде ул хатлар минем истәлекле кәгазьләрем белән бергә шкафта саклана лар. Шулар арасында күренекле язучы мәрхүм Габдрахман Әпсәләмов хатлары да бар. Без аның белән 1943 нче елда бәйләнеш башладык. Яхшы хәтерлим: мин ул вакытта аның «Совет әдәбияты» журналында басылып чыккан фронт көндәлеге белән таныштым. Ул язма минем күңел кылларымны нык тибрәтте. Әпсәләмов дигән яшь язучының хикәяләрен укыган булсам да, моңарчы аның үзен күреп, аның белән шәхсән танышканым юк иде. Аның көндәлеге исә мине шулкадәр дулкынландырды, мин авторның адресын сорап, Казанга хат язмый булдыра алмадым. Тиздән миңа аның Полевая почта адресын җибәрделәр, һәм шул ук көнне мин Габдрахманга үземнең тойгы-кичерешләремне, аның көндәлеген укудан туган тәэсирләремне язып хат юлладым. Тиздән ул да миңа хат язып җибәрде. Шулай безнең арада хатлар аша бәйләнеш башланды. Бу бәйләнеш тора-бара дуслыкка әйләнде. Беребез Заполярьеда, икенчебез Россия уртасында булуга карамастан, без кара-каршы утырып гәп коручы дуслардай һич ара ераклыгын тоймастай якынайдык, сугыш тәмамланганчы элемтәне өзмәдек, дуслыкка тугрылыклы булып калдык.*

*Түбәндәге хатларны укыган кешеләр, мөгаен, Габдрахман Әпсәләмовның нинди мөлаем, дуслыкның кадерен бик белә торган, ярдәмчел кеше икәнлегенә игътибар итми калмаслар дип уйлыйм. Ул сыйфатлар, минемчә, хатларда бик ачык чагыла. Әйе, ул акыллы да, чиктән тыш тырыш та иде. Мин аны бары шулай гына хәтеремдә саклыйм.*

*Кызганычка каршы, безнең дуслык, сугыштан соң байтак кына вакыт дәвам итсә дә, көннәрдән бер көнне өзелде. Мин хәзер узган еллар ераклыгыннан дөресен икрар итә алам: монда Габдрахман да, мин дә гаепле түгел идек. Сәбәбен аңлату өчен бу сүз башы кысалары гына тар. Аның өчен аерым бер моңсу әсәр язарга кирәк.*

Атилла Расих
28.II.87

Расих дус!

Көтмәгәндә Сезнең хатыгызны алу мине гаять шатландырды. Чөнки безнең яшь язучылар арасында Сезнең иҗатыгызга аеруча өметле итеп карый идем. «Совет әдәбияты»нда эшләгән чакта (сугышка кадәр) Сезнең армиядән җибәргән хикәяләрегезне кертkән идек. Шуннан соң сез нәрсәләр язгансыздыр, нәрсәләр бастыргансыздыр — миңа билгеле түгел. Чөнки 1941 елның август аеннан бирле мин фронтта йөрим. Үз әдәбиятыбыз белән бәйләнешем бар барын — азмаз язгалыйм шунда — ләкин яңа чыккан әйберләрне укыганым юк. Хәтта үз әйберләремне дә күргәнем юк. Дуслар күп күбен, ләкин берсе дә журнал җибәрми.

Расих, нәрсәләр язасыз? Көндәлек дәфтәр алып барасыздыр, әлбәттә. Бик кирәк нәрсә ул.

Инде миңа мәгълүм булган кайбер Казан хәлләре турында: М. Җәлил, Кутуй, Хәким, Шамов, Ф. Хөсни, М. Әмир, Г. Галиев армия һәм фронт газеталарында

эшлиләр. Бар да җылы якларда булса кирәк, безнең фронтта берәү дә юк. Г. Разинны[1] автомобиль таптаган, мие селкенгән дип язганнар иде. «С. Ә.» редакторы Газый Кашшаф миңа хат язып тора. Язучылар союзында Х. Хәйри, Литфонда — М. Гали. «С. Ә.» һаман ташбака төсле шуыша — кичегеп чыга.

Илдән, кызлардан хатлар аласызмы? Хат көтәм. Сәлам белән:

*Г. Әпсәләмов. 19/V — 43 ел.*

P. S. Минем адрес: Полевая почта 68331 Д. Миңа.

---

[1] Гомәр Бәшировның элеккеге әдәби псевдонимы

Расих дус!

Бүген сезнең хатыгызны алдым. Киләчәктә хатлар язышуны шулай дәвам иттерсәк, ифрат күңелле булыр иде. Юкса ике ел сугыш кырларында йөри-йөри, тәмам солдат булып беттем. Казанлы дуслар хатка аерата сараннар — ничә бәйрәмдә бер хат җибәрәләр.

Беренче хатымнан соң Казаннан хат алганым юк, шуңа күрә «зур әдәбият» турында һичнәрсә яза алмыйм.

Минем үз тормышым соңгы вакытта берникадәр үзгәрде. Мине Политуправлениегә чакыртып алып, безнең фронтта татар телендә чыга торган газета редакциясендә эшләргә җибәрделәр. Хәзер шунда «прикомандированный» булып, вакытлыча эшлим. Бер нәрсә — редакциядә очраклы кешеләр, ләкин исемнәре югары — безнең кебек кечеләр түгел. Сез «сазлар» фронтында түгелме соң? «В бой за Родину» яисә «Ватан өчен сугышка» газеталары сезнең кулга төшмиләрме? Шул турыда тәфсилләп яз әле яме. Әгәр син бу газеталарны укымыйсың икән, ниндиләрен укыйсың? Аңлагансыңдыр шаять.

Членлык турында! Мин членмы, түгелме — үзем дә белмим. Официаль рәвештә гариза язганым юк. Бер хатларына караганда член итеп алганнар шикелле. Членлыкның бер кечкенә генә файдасы булса, ул да — гаиләңә ярдәм итүләре мөмкин. Чөнки моңа аларның фондлары бар. Мин Москвадан, әнкәйдән хат алдым. Аңа Язучылар союзыннан 1500 сум акча биргәннәр һәм ашханәгә беркеткәннәр. Формаль ягы ничек булгандыр, әйтә алмыйм.

Соңгы вакытларда безнең гаиләдә зур бәхетсезлекләр. Бер-бер артлы ике энем сугышта һәлак булганнар. Өченче энем яраланган, госпитальдә ята. Әнкәй карчык берүзе тилмереп йөри. Мин дә синең кебек аңа материаль ярдәм күрсәтә алмыйм. Чөнки 125 сум белән хәзер нәрсә эшләп була?!

Сугыш эчендә синең шундый зур-зур хикәяләр язуың өчен чын күңелемнән куанам. Башкалар аңламас, ә мин сугышта хикәя язуның нәрсә икәнен бик яхшы беләм — бигрәк тә урманда, землянкада. 42 нче елда мин, яраланып, госпитальдә яткан чагында гына ике хикәя яза алдым. Кыш көне, подразделение ялга чыккач, бер дәфтәр күләмендә ике хикәячек яздым. Яз башы берникадәр уңышлырак булды. Политуправление мине Илдар Маннанов (Советлар Союзы Герое) янына, Балыкчылар атавына, җибәрде, һәм мин аның турында бер табак күләмендә очерк яза алдым. Хәзер ул очерк Казанда ята.

Соңгы вакытларда тагы бер-ике хикәя язып ташладым. Менә шул. Басылып чыккан әйбереңне күреп укый алмагач, күңел дә әллә ничек сүрелеп китә. Синдә «Совет әдәбияты»ның кайсы номерлары бар? Мин бары бер номерны күргән идем — № 7.

Расих! Хатымның азагына таба «син» дип ычкындырганмын. Зинһар гафу ит һәм моннан соң гомумән «син» булып калыйк.

Сугыш башыннан бирле башыңнан үткәннәрне әзрәк яз әле. Казаннан хатлар аласыңмы? Нәрсә язалар?..

Моннан бер ун көн элек Казан кызларыннан бер хат алган идем. Хат эчендә «Кр. Татария» газетасыннан кисеп алынган бер мәкалә бар иде. Ул безнең агай-эне турында. Сине дә әзрәк таныштырып үтим. Башта шагыйрь Ф. Кәримне мактыйлар. Ул ике тапкыр яраланган һәм бик матур (аларча) «Парень с Волги» дигән поэма язган.

Г. Кутуй белән Нәфикъ Яһудин[2] хөкүмәт бүләкләре белән бүләкләнгәннәр. Кутуй нәрсә алгандыр белмим — Нәфикъ медаль (рәсемдә күрдем). Прозаиклардан Х. Госманны, А. Әхмәтне, шагыйрьләрдән С. Хәким, Ш. Мөдәррисне телгә алалар.

«Ватан өчен»дә (Северо-западный фронт) Х. Госман, Яһүдин, Мөдәррис, Мирсәй Әмир эшлиләр. «Ватан намусы өчен»дә (Калинин) Ерикәй. Башка газеталарда Ш. Маннур, А. Әхмәт, А. Шамов, Р. Ишморат, Ә. Фәйзи, Г. Хәбиб эшлиләр.

Менә мәкаләнең эчтәлеге һәм сине кызыксындырган нәрсәләр шул.

Син М. Гали белән хат алышасыңмы? Ул сине, ялгышмасам, яхшы белә иде. Әгәр хат язсаң, миннән сәлам.

Безнең тәрәзәдән Ак диңгез күренеп тора. Еш-еш диңгез дулкыннарына карап куям. Нәкъ шушы дулкыннар шикелле булды бит безнең тормыш.

Кәгазең бармы? Передовойда чакта мин кәгазьгә бик аптырый торган идем. Әгәр кәгазь кирәк булса, яз, җибәрермен.

Ярар, бик күп яздым. Укый-укый арып беткәнсеңдер.

Көч һәм сәламәтлек теләп:

*Г. Әпсәләмев. 11/VI-43*

---

[1] Сүз СССР Язучылар союзына член итеп кабул ителү турында бара.
[2] Сугышка кадәр матбугатта шигырьләр бастырган яшь шагыйрь.

Расих дус!

Кайнар сәлам сиңа. Озак-озак көткәннән соң, синең хатыңны алдым. Вакыт табып язуың өчен бик зур рәхмәт. Хат килмәгәч, мин, чыннан да, әллә нәрсәләр уйлап бетергән идем. Исән булуыңа бик шатландым.

Казаннан язган хатыңны[1] алдым һәм аңа үз вакытында җавап язган идем. Аннан соң да берничә хат язып салдым. Ахрысы һаман югалалардыр.

Казан абзыйлары бик сирәк язалар. Соңгы айда бер хат та алганым юк. Бары Гомәр Разин гына үткән ай ахырларында бер ачык хат җибәргән иде. Ул радиода эшли икән. Алар минем бер хикәяне радио аша тапшырганнар. Яңа хикәяләр сорыйлар. Ләкин алар агачта үсмиләр, сузылып алып кына булмый. Ә язарга вакыт бик чикле. Сез юлга чыккансыз[2] һәм бик уңышлы алга барасыз. Мин шатланып туя алмыйм. Без дә әкренләп юлга әзерләнәбез. Вакыт инде, бик күп гомер уздырдык. Казанда сыра эчәсе дә бар бит әле безнең.

«Совет әдәбияты»ның алтынчы номеры миңа килде. Синең әйбер 7—8дә булырга тиеш бит. Мин ул номерларны бик көтәм. 8 дә минем дә бер хикәячек булырга тиеш.

Иптәшләр бар да тик ятмыйлар. Һаман яңа әйберләр язалар. Бу бик күңелле хәл, сугыш безнең иҗат чишмәсен корыта алмады. Кутуй кайдадыр Брянск юнәлешендә, күптән түгел бер шигырен күрдем. Башкалар иске урыннарында.

Синең үзеңнең хәл-әхвәлең ничек? Иң элек сәламәтлек ярыйсымы? Син хәзер гаҗәп нәрсәләр күрәсең. Соңыннан алар бик кирәк булачаклар. Мин хәзергә күбрәк бер урында утырам. Дөресен әйткәндә, бу хәл шактый туйдырды инде.

Я, хәзергә сәламәт бул. Үзеңне сакла, син татар әдәбияты өчен кирәк булачаксың.

Вакытың сыйдырганда, хат яз. Сәлам белән кулыңны кысып:

*Г. Әпсәләм. 22/X—43.*

---

[1] Командование мине яхшы хезмәтем өчен Казанга кайтып килү мөмкинлеге белән бүләкләгән иде. Мин өйдә, өч елдан артык көрешми торганнан соң, ун көн чамасы торып, яңадан частема кайттым.
[2] Сүз безнең фронтның «Курская дуга» дип аталган данлыклы һөҗүме турында бара.

Расих дус!

Ерак төньяктан кайнар сәламнәремне ал. Синең язган хатларыңны икесен дә алдым. Исән-сау булуыңа чиксез шатландым.

Хатларың килгәнгә байтак көннәр булган инде булса кирәк. Ләкин мин «өйдә» юк идем. Сәфәрдә йөреп кайттым. Безнең фронт бик зур бит. Йөри башласаң, айлар кирәк.

Минем тормышта әллә нинди үзгәрешләр юк. Көннәр шаулап аккан елгалар кебек, һаман агалар да агалар. Тышта чатнап торган салкын кыш, агачлар ап-ак бәс белән уралган. Кояш бары берничә сәгатькә генә күренә дә яңадан югала. Ләкин төннәр якты. Еш-еш карасу зәңгәр күктә төньяк балкышы уйный. Андый чакларда тирә-як әллә нинди тылсымлы, хыялый бер төскә керә. Гүя сугыш та, караңгы землянкалар да күптән беткәннәр, югалганнар...

Мин бик еш Казанны, дусларны сагынам. Ләкин дуслар артык якынлык күрсәтмиләр. Соңгы ике-өч айда алардан бер хат та алганым юк. Мин сәфәрдә чакта «Сов. әдәбияты»ның 7 нче, 8 нче номерлары килгән. 8 нчедә синең «Ютазы егетең»[1] басылган. Мин аны укый башладым. Әле укып бетергәнем юк. Башлануы

оригиналь. Яхшы тәэсир калдыра. Гомумән, син язарга тиешсең. Безнең кайбер агай-энеләр тылда торып та кулга алырлык әйбер тудырганнары юк әле. Ә аларның мөмкинлекләре безнең мөмкинлекләргә караганда чагыштырмаслык рәвештә зур бит.

Шушы араларда Татгосиздаттан да бер хат килгән иде. 44 нче елга тематик план төзиләр икән. Нинди әйберләрең бар дип сораганнар. Хәзергә әле язган әйберләрем юк, шулай да планга бирәр нәрсә кертергә туры килер.

Ихтимал, син дә шундый ук хат алгансыңдыр. Алмаган булсаң, Гомәргә хат яз.[2] Минемчә, 44 нче елда синең аерым китабың чыгарга тиеш. Шулай бит?

Күптән түгел Афзал Шамовтан хат алдым. Ул Казанда булган. Ватан сугышы кырларында безнең кайбер иптәшләр һәлак булганнар: Рахман Ильяс, М. Вәдут, Бендецкий, К. Вахит. Рахман Ильясны үлгәннән соң Кызыл Байрак ордены белән бүләкләгәннәр. Мәрхүм зур батырлык күрсәткән ахрысы. Сибгат Хәким укуда. Ул ике тапкыр орден белән бүләкләнгән.[3]

Башка иптәшләр учреждение эше белән мәшгульләр. Сиңа исәлек итеп Илдар Маннанов турындагы очеркымны җибәрәм. Вакытың булса укырсың. Вакытың сыйдырганда, хат яз. Дусларча кулыңны кысып, сәлам белән:

*Г. Әпсәләм. 9/XII—43.*

[1] Сүз минем озын хикәям турында бара. Ул бер китабыма да кертелмәде, бары журналда басылган килеш кенә дөнья күрде.
[2] Абдулла Гомәр — Татиздатның ул вакыттагы матур әдәбият редакциясе мөдире, тәрҗемәче, журналист.
[3] С. Хәким 1943 елны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

...укучыны әзрәк алдагансың![1] Укучы баштан ук Фатих дошман тылына нинди эш белән килә, дошман тылында ул ничек хәрәкәт итәр дип көтә, ә хикәядә бу турыда бик томанлы рәвештә өстән-өстән генә әйтелә дә бөтен игътибар икенче якка юнәлдерелә. Шуңа күрә хикәянең экспозициясе артыграк шикелле тоела. Гомумән, хикәяң җиңел укыла һәм тәэсирләндерә.

Син дөрес әйткәнсең: без киләчәктә язучы булырга хәзерләнәбез. Бик авыр поприще. Шулай да, мин уйлыйм: тырышсак, ташка кадак кагарбыз. Мин синең өчен куанам, ышанырсыңмы, юкмы, мин синең әйберләреңне аеруча күзәтеп барам. Әгәр дә кайчан да булса бер очрашырга насыйп булса, барысы турында да сөйләшер идек һәм мин уйлыйм, хатларда гына түгел, тормышта да дус булыр идек. Мин [сине] бары бер тапкыр күрдем. («Совет әдәбияты»нда) һәм килешкилбәтеңне бик тонык хәтерлим. Әниеңне бернечә тапкыр күрдем (1941 нче елда) һәм аны яхшы хәтерлим. Ә син мине бөтенләй белми торгансыңдыр инде.

Тагын бер нәрсә. Кәшшафтан озын хат алдым.[2] Правлениенең отчетын җибәргән (син дә алгансыңдыр). Зур күләмле әсәрләр мәсьәләсен күтәргәннәр. Вакыт, әлбәттә. Татар әдәбияты киң мәйданга чыгарга тиеш һәм ул чыгар да. Обкомның бик яхшы карары бар ди. Гонорар мәсьәләсен дә рәтләгәннәр бугай. Ни әйтсәң дә иҗат өчен аның да зур әһәмияте бар.

Ярар, бу дөнья мәсьәләләре турында шуның белән туктатып торыйм. Укыйукый аргансыңдыр. Үзеңдә ни хәлләр бар? Кәефең, сәламәтлегең ничек? Гафу итсәң, синең иптәшең яисә йөрәк дустың бармы? Мораль ныклык саклау өчен моның шактый әһәмияте бар. Мәхәббәт каләмгә дә көч һәм куәт бирә, шулаймы? Сер булмаса яз әле.

Минем көннәр кәгазь буяп үтәләр. Эш шул кадәр күп һәм шул кадәр ардыра, иҗат итәр өчен рәт тә калмый. Һавалар бездә быел бик йомшак. Төньякта мондый [хәл] сирәк була диләр.

Сәламәтлек ярыйсы. Кайчагында эч кенә поша, ләкин монысын да җиңәрбез. Хат яз. Хуш. Сагынып:

*Әпсәләм. 4/II —44.*

Минем адрес яңа: Полевая почта — 31406.

[1] Бу хатның баш өлеше югалган. Әһәмияткә ия дип мин аны шул көенчә тәкъдим итәм. Сүз минем «Совет әдәбияты»нда басылган «Дошман тылында» исемле хикәям турында бара.
[2] Тәнкыйтьче, ул вакытта Язучылар союзы җитәкчесе Гази Кашшаф.

Расих дус!

Бүген синең хатыңны алдым. Озак хат язмауның сәбәбе үпкаләүдән түгел.

Соңгы вакытларда бездә кайбер үзгәрешләр булды. Кешеләр алмашынды. Мин язган идем бугай инде. Әхмәт Фәйзи белән очраштык. Ләкин ул берничә көннән [соң] Москва карамагына китте. Минем хуҗам хәзер Г. Хәбип, бәлки белә торгансыңдыр.[1] Элек «К. Татарстан»да эшләгән кеше.

Бездә һаман әле кар, әле яңгыр ява. Салкын. Алдынгы сызыкта да тынлык. Туйдырды инде болай тик яту.

Гомер вагонда үтә. Кайчагында күңел бик ямансулый башлагач, элек заманнарда поездларга утырып йөргән чаклар искә төшә һәм йөрәк сагышын башкаларга сиздермәс өчен күктә йөзгән болытларга карый башлыйсың.

«С. Ә.» 11, 12 саннарын мин дә алдым. Бүтәннәре юк әле. Бик соңга калып чыга. 2—3 саннарда минем бер хикәячек булырга тиеш. Синең бармы? Әле шушы араларда Гомәрдән хат алдым[2]. Хаты өч-дүрт юл. Минем китабымны җибәргән. Анысы да, хәерсез, 1 экземпляр җибәргән, шуңа күрә сиңа да җибәрә алмыйм. Авторскиларын сорап яздым, ләкин Казан җавап кайтарырга гомумән ашыкмый.

Хәниф Кәрим[3] шигырьләрен укыдыңмы? Көчле яза, безнең шагыйрьләрдән уздыра.

«С. Әдәбияты»ның иске һәм яңа саннарын барысын да фронт буйлап сәяхәт иттерәм. Әле шушы көннәрдә бер хат алдым. Заполярье таулары арасында синең «Ютазы егетеңне» укып чыкканнар һәм гвардиячеләргә ул бик ошаган. Димәк, безнең скромный хезмәтләр дә үз эшләрен эшли.

Марусянең[4] сәламенә каршы миннән дә аңа күп сәлам әйтегез. Мин, билләһи, аны хәтерләмим. Кем соң ул? Рогачевта минем булганым юк.

Мин Әширә Кәтиева белән хат алышам. Шагыйрә ул, бер институтта укыдык. Хәзер Москвада. Әйбәт кеше. Күрешергә насыйп булса таныштырырмын.

Иптәштән озак хат юк.[5] Әллә инде... онытты. Хат көтәм. Моннан соң аккуратныйрак булырмын. Ачуланма.

Бер күрергә зарыгып.

*Г. Әпсәләм. 7/V—44.*

Расих! Әгәр дә берәр кечкенә хикәяң булса миңа, газета өчен, җибәрсәң бик яхшы булыр иде. Берәр очерк, зарисовка булса да ярый. Вообщем үзең кара. Ләкин соравымны бушка куйма. Ярыймы? Гонорар үзеңнән күп алмабыз. Шул.

---

[1] Сүз күренекле журналист Габделхәй Хәбип турында. Г. Хәбип сугыштан соң озак еллар «Чаян» журналы редакциясендә эшләде.

[2] Язучы Абдулла Гомәр.

[3] Хәниф Кәрим — башкорт шагыйре.

[4] Маруся — хәтерем ялгышмаса, безнең полкта телефонистка булып хезмәт иткән кыз, ул Габдрахманны яхшы белгәнлеген миңа сөйләде.

[5] Габдрахманның хатыны, ул чорда Үзбәкстанда яшәгән Маһинур ханым (кыз фамилиясе Чумарина).

Расих дус!

Озак көткәннән соң бүген синең 20 майда язылган хатыңны алдым. Исәнлегеңә чиксез шатландым.

Мин яңарак кына «сәфәрдән» кайттым. Анда, ерак төньякта, әле кар, таулар ап-ак, уйсулыкларда күксел томан. Ара-тирә кар яугалый. Салкын.

Татар егетләре күп. Мин һәрвакыт үзем белән Такташны һәм «Совет әдәбияты» журналын сумкама салып йөртәм. Землянкаларда бергәләшеп укыйбыз. Синең әйберләреңне, бигрәк тә «Якташлар»ыңны яраталар. Мин ул турыда фронтның төрле почмакларыннан отзывлар алам. Отзывлар җибәрүчеләр арасында гвардияче Кашшапов та бар. Ул үзе тел-әдәбият укытучысы булган, югары белемле кеше. Аның отзывының (шулай ук башкаларның да) төп фикере: синең хикәяләрең укучыда көчле тойгылар тудыра, аларны дулкынландыра, ашкындыра, көрәшкә өнди.

Әхмәт Фәйзи белән очраштык та, бер көннән аерылыштык та. Ул Москвага китте, аннан 4 Украин фронтына җибәргәннәр дип ишеттек.

Озаклап сөйләшеп булмады. Мин аны күптән белсәм дә, якыннан таныш түгел. Пассивлыгының сәбәбе үзе әйтүенчә: фронт условиясендә язарга мөмкинлек юклыктан килә. Алар зур халык бит, тын кабинетларда язарга өйрәнгәннәр. Аннары ул театр китаплары яза, ә алар, үзең беләсең, сәхнәдә куела, китап булып басылмый.

Гомәрдән яңадан хат алганым юк. Бик койрыксыз кеше ул. Китап — минем хикәяләр җыентыгым. Исеме «Төньяк балкышы». Аны 1943 елда издательствога тапшырган идем, 1944 елда чыкты. Анда минем сиңа мәгълүм булган хикәяләрем тупланган.

Шунысы кызганыч: бары бер экземпляр жибәргәннәр. Берәүгә бер җибәреп булмый.

Симоновның һәм шул характердагы башка хикәяләрне укыдым. Ошадылар. Синнән дә шул юнәлештәге хикәяләр көтәбез. Галәветдиновыңны[1] яңа баштан эшли башлагансың. Бу турында нәрсә әйтергә дә белмим. Ничек кирәк тапсаң, шулай эшлә. Чөнки үз язганыңа үзең риза булмасаң, аны дөньяга чыгарудан ни файда.

Синнән пакет көтәм. Әгәр җибәргән булсаң, шушы көннәрдә килеп җитәр. Бу безнең өчен зур шатлык булачак.

«Совет әдәбияты» нигәдер бик кичекте. Әле булса 1 номеры килгәне юк. Әллә инде миңа гына җибәрмиләр.

Иҗат яңгырларым яумый. Соңгы айларда бернәрсә дә язганым юк. Үземә-үзем ачуланып йөрим шунда.

Марусяга сәлам. Ләкин зинһар аның кем икәнен ачыграк яз. Мин бөтенләй хәтерли алмыйм.

Ярар, күп сызгаладым. Үзең яз. Сагынычлы хөрмәт белән:

*Г. Әпсәләм. 8/VI—44.*

---

[1] Ул әсәренең исемен шулай атап ялгыша. Сүз мин язып ята торган «Шат күңелле Галләметдин» исемле повесть турында бара.

Расих дус!

Хатыңны алып чиксез шатландым. Ул күптән инде килгән булган, ләкин мин «өйдә» юк идем. Хәзер бездә дә урак өсте бит. Заполярьены дошманнан тазартуны тәгәллибез. Әле яңа гына шуннан кайттым.

Соңгы вакытларда бик еш чыгып йөрергә туры килгәләде. Шунлыктан һичнәрсә яза алганым юк. Әлеге «Батырлар китабы» өчен бер егет турында яза башлаган идем, белмим, бетереп булырмы икән. Ә язасы иде. Чөнки без язмасак, бүтәннәр язмаячак инде. Язсалар да күреп түгел, ишетеп язачаклар. Ә ишетеп язу ул инде үзе генә дә кимчелек.

Син, әлбәттә, яз. Үз частегездә герой булмаса, башка часть герое турында яз. Мин синең бер очеркыңны да укыганым юк әле. Шулай да өметем зур. Хикәяләрең моңа шаһитләр.

«Язылачак хикәяләр» һәм «Сагынылган мәхәббәт» турында[1] мин сиңа моннан алдагы хатларымда язган идем. Бәлки алгансыңдыр. Бу хатымда шуны гына әйтәм: һәр ике хикәяңдә дә җанлы тормыш һәм зур йөрәк тибеше сизелә. Аларны рәхәтләнеп, бирелеп укыйсың. Укыйсың һәм тәм табасың. Төп тойгы шундый. Әгәр дә исән булып, бер күрешергә туры килсә, бу турыда һәм гомумән әдәбият мәсьәләләре турында киң сөйләшер идек. Хатта, бигрәк аяк өстән язган хатта, күп итеп, киң итеп тукталып булмый.

Үзем хәзергә исән-сау. Туган илне бигрәк сагындым. Син ичмасам Казанга бер кайтып килдең. Мин ул бәхеткә ирешә алмадым. Һәм сугыш беткәнче ирешә дә алмам.

Яза башлаган повестым тукталып тора. Союзга яңа елга эшләп бетерермен дип вәгъдә биргән идем бирүен, әмма сугыш безнең белән хисаплашмый. Һәр көн үз таләпләрен китереп куя һәм иҗад эше көннән-көн артка калдырылып килена.

Үзеңдә ни хәлләр? Әүвәлге урыныңа кайткансың һәм поляк кызларын мактагансың. Ә без бер генә граждан кешесен күрергә дә зарбыз. Урман, таш-тау, кар һәм боз — менә безнең мохит. Заполярье!

Синнән хатлар көтәм. Исән бул, туган. Сагынып:

*Әпсәләм. 17/X—44.*

---

[1] Сүз 1944 елда «Совет әдәбияты»нда басылган минем хикәяләрем турында бара.

Расих дус!

Хатыңны алдым. Исәнлегеңне ишетеп чиксез шатландым. Беләсеңме, ерак Заполярьеда йөргәндә, салкын ташка сыенып аягүрә төн үткәргәндә Казанымны, дусларны, сине бик күп тапкыр исемә төшердем.

Хатларыңны алып торам. Үзем дә язам, ләкин минем хатларым я кире кайталар, я кайлардадыр югалып калалар. Шуңа күңелем әрни. Бу хатым да бәлки сиңа барып ирешмәс. Шулай да өмет итеп язам әле.

Шушы көннәрдә Әнәстән һәм Кәшшафтан[1] хатлар алдым. Казан хәлләре турында һич ни язмыйлар. Бөтен хатлары минем «Зәңгәр күзләр» исемле хикәям

турында бара. Алар аны уңышсыз дип тапканнар һәм шуның өчен гүя гафу үтенгән сыман, хатлар язганнар. Начар хикәя өчен әйбәтләп пешерергә кирәк. Югыйсә без «шаяра» башлыйбыз, шулай түгелме?

«Батырлар китабы» өчен Советлар Союзы Герое Фәхри Заһидуллин турында бер очерк җибәрдем. Белмим, ничек чыккандыр тагы. Бүтән бернәрсә дә язган юк. Гел алда булдым, һәм газета өчен вак-төяк әйберләр сызгаладым.

Үзеңнең хәлләр ничек, дускай? Кайчан Казанга кайтабыз да, кайчан Академиядә[2] бергәләп утырабыз инде?!

Нәрсәләр язасың? Ничегрәк урнаштың? Казаннан хатлар аласыңмы?

Хат яз. Бик көтәм. Хөрмәт белән:

*Г. Әпсәләм. 2/XI—44 ел.*

---

[1] Әнәс Камал һәм Гази Кашшаф. Ә. Камал ул вакытта «Совет әдәбияты»нда эшли инде.

[2] Сүз Татар академия театры турында бара. Чыннан да, сугыш беткәч, без Әпсәләм белән беренче тапкыр Академия театры фойесенда очраштык.

Расих дус!

Кайнар сәлам сиңа салкын төньягыннан. Ниһаять, биредә дошманның эшен бетердек. Хәзер язмыш кайсы фронтларга илтеп ташлар — билгесез. Син сугышып йөргән җирләргә барып чыксак, ничек булса да бер күреп, туйганчы сөйләшәсе килә. Югыйсә кайчагында күңел бик ямансулап куйгалый.

Соңгы вакытларда бик ялкауланып киттем. Бер генә хикәя дә язганым юк. Советлар Союзы Герое Заһидуллин турында бер очерк язган идем, белмим, ничек чыккандыр. Җавап алганым юк әле. Теге «Батырлар китабы»на барлыгы 4 битлек (машинкада) әйбер кирәк икән. Аның башлыгы Ерикиев[1]. Шуны ишеткәч, күңелем тәмам суынды. Бернәрсә язмаска булдым.

Үзеңнең эшләр ничек? Җыентык чыгару ягын хәстәрләмәдеңме? Укучылар синең әйберләреңне күптән көтәләр.

Казаннан һичбер хат-язу алганым юк. Үзем дә язганым юк. Юлда булганлыктан кәеф чуаррак.

Мин сиңа күп хатлар яздым. Тик син аларның берсен дә ала алмыйсың. Бу хатым да бәлки сиңа ирешмәс.

Сәламәт бул, туган. Сагынып:

*Г. Әпсәләм. 20/XI—44.*

---

[1] Шагыйрь Әхмәт Ерикәй. Күрәсең, бу вакытта Әпсәләмов күренекле шагыйрь, Татарстан Язучылар союзының сугыштан соңгы беренче председателе Әхмәт Ерикәй белән киеренке бер мөнәсәбәттә булган булса кирәк.

Расих дус!

Моннан берничә көн элек синең хатыңны алдым. Исәнлегеңне ишетеп, бик шатландым. Югыйсә синнән бик күптәннән хат-хәбәр юк иде. Минем берничә хатым кире кайтты.

Бүген «Хакыйкать» килде.[1] Анда сезнең өчәүләп төшкән рәсемегез бар. Аны күрү минем өчен чиксез зур шатлык булды. Тик ни өчен аны дүртенче биткә биргәннәр, аның урыны өченче биттә, югарыда булырга тиеш иде. Кара әле, әгәр кулыңда ялгыз төшкән бер рәсемең булса, ядкәр өчен җибәрсәңче. Югыйсә мин сине рәтләп күз алдыма китерә алмыйм (бер генә күрдем бит үзеңне). Мин дә сиңа рәсемемне җибәрермен.

Повестең турында.[2] Сюжеты ошый һәм реаль. Тик аның кай җире балалар өчен, шунысын аңлап җитмәдем. Балаларның яшен, үзенчәлеген — барысын да искә ала торгансыңдыр инде.

Мине бер нәрсә гаҗәпләндерә. Кайдан вакыт табасың син. Мин менә алтыҗиде ай эчендә бер хикәя яза алганым юк. Вак-төяк газета мәкаләләренә көчем түгелеп бетә.

Хәзер «эшсез» утырабыз. Газета вакытлыча (ә бәлки бөтенләй) чыкмый тора. Кая җибәрерләр икән — белмибез. Хәер, кая булса да барыбер.

Әле шушы араларда Мәскәүдә әниләрем янында булып кайттым. Дүрт ел инде күрешкәнем юк иде. Тәмам картаеп беткән. Бигрәк тә энеләремнең һәлак булулары (өчәү) аны саргайтканнар.

Үз бүлмәмә кердем, тузанланып беткән китапларымны актарып утырдым. Ә өстәлем артына утырып, язу язарга көчем җитмәде. Күңелем әллә нишләп китте.

Мин киткәндә өстәл биеклеге генә калган балалар хәзер җиткән кызлар, егетләр булганнар. Исем китеп карап тордым аларга һәм «гомер үтә икән» дип уйладым.

Хәбиб Казанда булып кайтты. Агай-энене күргән. Ләкин сәламнән башка берни дә алып кайтмаган. «Совет әдәбияты»ның 7—8 номеры гына килде. Эч пошыргыч дәрәҗәдә әкрен кыймылдыйлар.

Үзеңдә ни хәлләр бар? Киңәшмә күңелле үттеме? Тагын кемнәр бар иде? Нур кайда хезмәт итә?[3] Шигырь язамы, әллә «карт прозага» күчкәнме? Сәлам әйт үзенә.

Хат көтәм. Сәламәт бул дускай. Хөрмәт белән:

*Г. Әпсәләм. 15/1—45.*

---

[1] Сүз безнең фронт газетасы «Фронт хакыйкате» турында бара. Ул көннәрдә шул газета редакциясендә безнең фронттагы татар иҗатчылары очрашты. Редакциядә Шәрәф Мөдәррис һәм Гамир Насрый хезмәт итте. Газетада безнең (Х. Госман, Нур Гайсин һәм мин) фоторәсем басылган иде.

[2] Сүз Польша җирендә языла башлап, Берлин янында тәгалләнгән мажаралы повесть («Бәхет орлыклары») турында бара.

[3] Шагыйрь Нур Гайсин.

Расих дускай!

Синнән бик озак хатлар юк. Көтә-көтә аптырап беткәч, тагын язарга булдым. Моннан алда язган хатымны, бәлки, алгансыңдыр.

Шуннан бирле минем тормышта үзгәрешләр булганы юк. Моннан бер-ике атна элек «Совет Заполярьесын саклау өчен» медале алдым. Ул минем өчен бүтән бүләкләргә караганда да кыйммәтлерәк булачак.

Хәзер буш вакытым күп. Мөмкин кадәр аны әрәм итмәскә тырышам: укыйм һәм язам. «Ут сызыгында» дигән повестемне[1] тәмамлау турында сиңа хәбәр иткән идем бугай инде. Шушы көннәрдә Гомәргә тагы бер җыентык җибәрдем. «Зәңгәр кыя» исемле ул җыентыкка җиде хикәя һәм уннан артык очерк һәм сызмалар тупладым. Барысын да почта аркылы җибәрдем, барып җитсә ярый инде, югыйсә бик борчылам.

Хәзер яңа бер повесть өстендә эшли башларга уйлап торам.[2] Ватан сугышы көннәрендә бер татар гаиләсенең тарихын күрсәтергә уйлыйм. Син моңа ничек карыйсың?

Үзеңдә эшләр ничек? Сездә хәзер бик шаулы көннәр:[3] язарга бер дә рәт юктыр. Берлинның капкасын шакыйсыз бит, малай.

Октябрьне Казанда каршы алырбыз дип торам әле. Бергә утырып, рюмкаларның төбен тишсәк дөньясы җәннәт булыр иде без солдатларга!

«Совет әдәбияты»ның 7—8 номерыннан башкасын күргәнем юк. Казан ифрат әкрен кыймылдый. Әллә чыгып та миңа җибәрмиләрме икән.

Әһелләрдән бер хат та алганым юк. Берсе бер язмый.

Синнән хатлар көтәм. Тизрәк яз, дускай.

Хөрмәт белән:

*Габдрахман. 15/*II*—45.*

---

[1] «Ак төннәр» повестенең беренче варианты турында сүз бара булса кирәк.

[2] Сүз «Алтын йолдыз» романы турында бара. Минем белүемчә, ул әсәр язылып, Габдрахман армиядә чакта ук Казанга җибәрелгән иде. Тик аны башта өнәмәделәр, ул озак вакыт басыла алмады.

[3] Мин хезмәт иткән 3 нче армия бу көннәрдә Көнчыгыш Пруссиядә бик авыр сугышлар алып бара иде.

Гүзәл дустым Расих!

Мөбарәк хатыңны алып, чиксез шатландым. Синнән бик озак хатлар булмагач, мин дә, синең кебек үк, борчыла башлаган идем.

Минем моннан алда язган хатларым сиңа ирешмәгәннәр икән. Мин аларны 03560 Х га язган идем, хәзер адресың үзгәргән икән. Ә мин һаман шул бер җирдә. Заполярьедан киткәндә, сезнең якларга барабыз дигән хәбәр бар иде, гамәлгә ашмады. Менә өч ай инде Идел буендагы шәһәрләрнең берсендә резервта ятып, икмәк ашыйбыз һәм радио тыңлыйбыз һәм кызларны гыйшык утында яндырабыз. Бүтән эш юк. Мин бераз язгалаган идем, ләкин уңышсызлыкка очрадым. Казан әһелләре повестымны[1] тетеп салганнар.

Дөрес, үзләреннән хат та, рецензия дә алганым юк, Казанда булып кайткан шагыйрь Мостафа Ногман гына сөйләде. Мостафа белән бирелә очраклы рәвештә таныштык. Хәзер ул Мәскәүгә укырга китә бугай.

«Совет әдәбияты»ның бары 9 нчы номерын гына Мостафадан алып укыдым. Бүтәннәрен күргәнем юк. Җәләйнең мәкаләсе[2] турында сиңа язган идем инде. Әлбәттә, ул дөрес фикерләр күтәргән. Тел чатаклыгы бездә зур. Без алардан күз йоммаска тиешбез. Тик Җәләй куйган тар рамкага кысылып калу да без прозаиклар өчен ярамый. Без бит җанлы тел вәкилләре. Шуңа күрә иске грамматика кануннарына сыеп бетми торган җөмләләр бездә күп һәм күп булачаклар да. Болардан куркырга ярамый.

Бу турыда сиңа киңрәк язасы килгән иде, тик журнал кулда булмагач, гомуми замечаниеләрдән башка нәрсә әйтеп булмый.

«Шат күңелле Галләметдиненңне» көтәм.[3] Әгәр дә журналны табып укый алсам, фикеремне һичшиксез язачакмын.

Мин берничә хикәя язган идем. Бүгенгә кадәр ләм-мим дигән җавап алганым юк. Редакциядә утыручылар гаҗәп каты күңелле бәндәләр булып чыктылар. Ун хатка бер җавап язмыйлар.

Фатих Әмирхан хикәяләрен укып чыктым — бер хаят! Каюм Насыйриның Әбугалисинасын укыдым — халыкның хыял киңлегенә таң калдым.

Син журналлар аласыңмы? Расих дускай, син бәхетле! Көнләшәм. Каһәрләнгән мимеч җиренә аяк баскансыз. Ә мин... белмим, кайчан бу резервтан баш чыгар!

Хуш, сәламәт бул, яшә. Хатлар көтәм. Сәлам белән:

*Габдрахман. 25/III—45.*

---

[1] Сүз «Алтын йолдыз» турында бара булса кирәк.

[2] Күренекле тел галиме профессор Латыйф Җәләйнең минем «Сагынылган мәхәббәт» турында язган тәнкыйть мәкаләсенә. Бу минем иҗатыма карата беренче тәнкыйть сүзе иде. Мин аны ул вакыт күрәсең, яшьлегем аркасында һич тиешсезгә бик авыр кичердем.

[3] Мин төгәлләнмичә калган бу юмористик повестымның беренче главасын Ф. Хөснигә истәлек итеп (бастыру өчен түгел) җибәргән идем. Тик Фатих аны журналда бастырып чыгарган. Сүз шул турыда.

Расих дус!

Моннан берничә көн генә элек сиңа хат язып салган идем. Бүген 3 нче мартта язган мөбәрәк хатыңны алып, чиксез шатландым. Бу «эшсез» күңелсез көннәрдә синең хатларың миңа зур көч бирәләр. Югыйсә фронттан меңнәрчә километр читтә, тирән тылда адашкан бер шәһәрдә яшәргә мәҗбүр булуы бәгырьне телгәләп бетерә. Хандра бәласенә чумып беттем. Түзәрлек тәкать калмады. Перспектива да хәзергә томанлы. «Байкал күле балыклы» дип җырлап йөрергә туры килмәгәе әле дип борчылып йөрибез әле.

Хәер, язганны узган юк диләр. Күрербез. Җәләйнең мәкаләсе турында элекке хатларымда язган идем инде. Җәләй — академизм вәкиле (бу сүзнең начар мәгънәсендә). Ул яңа шытып килгән чәчәкләрдән курка. Дөрес, чәчәкләр арасында әремнәр дә күп. Тик без аларны утарбыз, йолкып бетерербез. Ә чәчәкләр чәчәк булып калырлар.

Синең иҗад уңышларыңа шатланып туя алмыйм. Яз, туган, яз. Күңелләребездә шәп өмет йолдызы кабыздың — сүндермә! Без үзара җыелып еш кына әдәбият мәсьәләләре турында гәпләшәбез. Бездә әдәбиятны яхшы аңлый торган егетләр бар. Шуларның берсе белән сине таныштырам. Аның фамилиясе Габидуллин, исеме Гыйззулла. Псевдонимы мөгезле — Гиз-эль-Габид (Безнең шаян телдә: Гиз-эль-Гыйфрит). Үзе шигырьләр язгалый. Шигырьләре югары культуралы, хисләргә бай. Татар телен, рус телен яхшы белә. Оренбургның Тел-әдәбият институтын тәмамлаган кеше.

Ул да синең хикәяләрең турында яхшы фикердә (монысы комплимент өчен әйтүем түгел). «Совет әдәбияты»ның унынчы номерын һаман күргәнем юк. Казанга үпкәләп хат яздым, берсенә бер җавап алганым юк. Бу кадәр җансыз кешеләр булырлар да икән!

Киңәшләрең өчен рәхмәт. Ләкин мин язуны ташладым. Әллә нигәдер канатларым салынып тора. Язган әйберләрнең дә язмышлары караңгылык эчендә.

Бер-бер этәргеч булмый торып язып булмас ахрысы. Ул этәргеч кайдан килер — белмим. Тик киләсенә ышанам. Әгәр язмасам, минем өчен тормышның мәгънәсе дә калмаячак.

Бу хатым бәлки сине Кенигсбергта, бәлки Данцигта, яисә Померания җирләрендә куып җитәр. Сәламәт бул, туган. Сугыштан соң шатлык белән күрешү насыйп булсын да бер өстәл артында, бер самавырдан баллап-вареньелап чәй эчәргә, язган әйберләребезне кайнар көенчә бер-беребезгә укырга насыйп булсын!

Хатларыңны туктатма. Кулларыңнан кысып:

*Габдрахман. 26/III—45.*

Расих, кадерлем!

Kaһәрләнгән мимеч илләреннән язган озын хатыңны алып, бик шатландым. Синең янып ашкынуың миңа көчле тәэсир итте. Югыйсә моннан элеккеге хатымда язганымча, канатларым салыныбрак тора иде. Хәзер бу мәгънәсезлек үтә шикелле, бүген берничә бит язып та ташладым.

Бер-бер артлы өч энекәшнең фронтта һәлак булуы, энкәйнең шактый авыр хәлдә яшәве, хатыннан озак хатлар килмәве, Казан әһелләренең аңлашылмас игътибарсызлыгы (язган әйберләргә һичбер төрле җавап бирмичә эндәшмәүләре) һәм башка күп күңелсезлекләр барысы бергә җыелып, кәефне кырганнар, хәтерне калдырганнар иде. Өч ай буенча һичнәрсә язмый тордым. Шунысы үкенеч: вакытым була торып язмадым, дөресрәге — яза алмадым. Ә синдә, сокланып әйтәм, дәртле теләкләр кайный.

Әлбәттә, татар әдәбиятын дөнья күләмендә күтәрү өчен бик күп, бик күп язарга кирәк. Хәзерге темп һич кенә дә ярамый. Шушы араларда Мирсәй Әмирдән хат алдым. Ул кайбер әдипләребезнең зур-зур романнар өстендә эшләүләре турында әйтеп китә. Мәсәлән, Разин — «Намус», Кави Нәҗми — «Туган ил», Мирсәй Әмир «Ут эчендә» романнарын тәгәлләп киләләр. Бу бик шатлыклы хәбәр бит. Моңа син дә, минем кебек үк, куанырсың.

Хатыңны яз белән, төнлә ишетелгән җыр белән башлагансың. Мин дә язны һәм җырны яратам. Язда бөтен җиһан, бөтен тереклек яңара, язның һәр тамчысы мәхәббәт, тормыш, азатлык һәм бәхет турында җырлый. Кайчагында мин күзләремне йомам да, бала чагымны, кардан ачылган болыннарда, кашлыкларда сарыклар көтеп йөргәнемне, боз акканын карарга баруларны хәтерлим һәм йөрәк әллә нинди, гомергә кабатланмас бер моң, бер сагыш белән кысыла. Гүзәл сабый чаклар!

Үткән елның декабрь аенда, салкыннан барлык агачлар бәскә төренгән иртәдә, алгы кырыйдан кайтканда, төньяк шәһәрләренең берсендә радиода татарча җырлаган тавыш ишеттем. Мин бик арыган һәм туңган идем. Җыр тавышын ишеткәч, яңадан туып киткән шикелле булдым. Кая китте аруларым-талуларым!

— Капитан,— дидем иптәшемә,— бу Рахманкулова җырлый бит, Рахманкулова!

— Җырласын,— диде капитан. Ул рус булганлыктан, аңа бу җыр гади бер җыр иде, ә мин Рахманкуловага бу гүзәл минутлары өчен мең рәхмәтләр укыдым. Аның көчле аһәңе киң кырлар, тын урманнар өстенә җәелде. Яңа күтәрелеп килгән кояшның тәүге нурлары белән тоташты. Гүя җырчы гына түгел, бөтен табигать җырлый иде. Бу иртәне мин бик озак, гомер буе оныта алмам.

Җәләйнең тәнкыйте турында мин сиңа берничә тапкыр яздым инде. Үткәннәрне кабатламас өчен шуны гына әйтәм: Наиләнең[1] куелган бурыч турында уйлавы дөрес. Бурычны үтәгән минутларда үзең турында, якыннарның һ. б. турында уйларга вакыт булмый. Үзеңне саклау бары инстинкт буенча гына эшләнелә. Ә аңа кадәр, ягъни бурычны турыдан-туры үти башлаганга кадәр, Наилә, әлбәттә, үзе турында да, үлем турында да уйлый алыр иде. Аннары шунысын онытырга ярамый: психологик яктан иң кыен минутлар бурычны үтәү процессында түгел, ә аңа кадәр булган вакыт эчендә. «Болай газапланганчы тизрәк башлансын иде»,— дибез бит без.

Мин сиңа хат язып торганда, Гиз Габид синең хатыңны һәм хикәяңне укып чыкты. Ул безнең бик чая егет. Җәләйнең тәнкыйте турында болай диде: «Эт өрер, бүре йөрер». Чыннан да, тәнкыйтьне ул кадәр авыр кичермә син. Үзең дөрес дип тапкан урыннарын төзәт, ә калганы калсын. Шул.

Ярар, бу турыда шуның белән тәмамлыйк. Дөнья хәлләренә күчсәк, эш болай тора: «Совет әдәбияты»ның 10 нчы санын күргәнем юк. Ә күрәсе, укыйсы бик килә. Редакциягә вак-төяк әйберләр җибәргәләгән идем — җавап алганым юк. Үзем һаман да әле Волга буенда, салкын вагонның өченче сәндерәсендә гомер кичерәм. Күңелсез, кысынкы, эч поша.

Нурга миннән сәлам яз. Ул мине белергә тиеш. Чыннан да, ул беркатлы, кызык кеше. Язарлык дәрте бармы соң?

Шулай ук Хатыйпка да сәлам яз. Мин аның «Ялкынлы йөрәген» укып чыктым. 42 нче ел өчен ярыйсы әйбер, бүгенге көн өчен гаять йомшак.

Синең тормышларың җайлы булуга мин бик шат. Әйе, атлар — кешеләр түгел алар. Авырсалар да, сөйләргә телләре юк ич аларның!

Менә сиңа «аванс». Бәләкәй генә рәсемемне җибәрәм. Үзең дә җибәр, яме.

Казаннан хатлар аласыңмы? Ярар, хәзергә хуш. Габид сиңа күп итеп сәлам җибәрә. Уңышлык теләп, сагынып:

*Габдрахман. 8/IV—45.*

[1] Сүз «Сагынылган мәхәббәт» хикәясендәге персонажның кичерешләре турында бара.

Расих дус!

Шатлык эчкә сыймый. Гасырларга калачак, буыннардан-буыннарга бәйрәм ителәчәк беренче җиңү көнен үткәрәбез. Котлы булсын бу гүзәл бәйрәмебез, туган! Без исән, халкыбыз исән, Ватаныбыз данга күмелгән. Яшибез, яшибез!

Башка әллә нинди матур, серле уйлар килә. Чын-чынлап иҗат эшенә чумасы көннәр якынлаша. Кем белә, бәлки алда тагын зур көрәшләр тора торгандыр. Тик шунысы ачык, иң явыз, иң мәкерле дошман юк ителде инде.

Синең мөбәрәк хатыңны алдым. Аның өчен зур рәхмәт. Моннан алда сиңа хатлар язган идем. Монысын бик ашыгыч язам. Озакламый паровоз тагарга тиешләр. Юл ачык инде. Кая икәнен үзең төшенә торгансың инде.[1]

Казаннан яңа бер әйбер алган юк. Хәер, алар безне үзебезне көтә торганнардыр инде. Хатлар яз.

Якын арада күрешүне теләп:

*Габдрахман. 10/V—45.*

---

[1] Габдрахман үзләренең японнарга каршы сугышка китәчәкләренә ишарәли.

Расих дус!

Синнән бик күптәннән инде хат алганым юк һәм тиз генә ала да алмам. Соңгы вакытларда бик күп үзгәрешләр булды. Язмышның җиңел канаты мине Тын океан буйларына китереп ташлады. Син хәзер кайда? Бәлки син дә бу якларададыр? Яз әле. Иртәгә командировкага чыгып китәм. Беренче командировка. Безнең газета чыга башлаганы юк әле. Тиздән чыга башлар дип әйтәләр. Яңа җирләрдә каләм ничек тибрәнер икән — белмим. Татарстанга кайтасы бик килгән иде. Бәйрәм бит анда. Ләкин кайтып булмады. Бәлки син ул бәхеткә ирешкәнсеңдер.

Бу хатны үземнең яңа адресымны белдерү һәм синең кайларда икәнеңне белү теләге белән язам.

«Совет әдәбияты» һәм бүтән әдәбият яңалыклары турында һичбер хәбәрем юк. Әгәр сиңа бер-бер нәрсә билгеле булса, яз.

Хәзергә исән бул, дускай. Минем моннан элек язган хатларымны алдыңмы? Сагынып:

*Әпсәләм. 16/VI—45.*

Расих дус![1]

Көтеп-көтеп арганнан соң, бүген һич тә уйламаганда, синең 27.07 дә язылган хатыңны алып чиксез шатландым. Югыйсә әллә нәрсәләр юрап беткән идем.

Безнең баштан тагын бик давыллы көннәр үтеп китте. Маньчжуриянең иңен иңләдем, буен буйладым дигәндәй. Бик күп тәэссоратлар алдым, бик күп материаллар тупладым. Тик шуларны рәткә саласы гына бар. Синең Казанга кайту ихтималыңа мин бик шатланам. Син агроном буларак кайткансың да инде бәлки. Шуңа күрә бу юлы ике адресың белән дә хат язам. Берсе җитмәсә, берсе җитәр әле.

Минем хәлләр ярыйсы күңелсез. Безнең газетаны окружной италәр һәм шушы Ерак Көнчыгышта калдыралар. Димәк, тагы билгесез вакытка кадәр шушында калырга туры килә. Бу минем өчен тереләй үлү белән бер. Әдәбияттан, культурадан, иптәшләрдән читтә яшәп, бигрәк тә утырып эшләр өчен минималь мөмкинлегең булмаганда, нәрсә генә язарга мөмкин?

Язучыларны кире кайтарырга тиешләр дигән хәбәр бар диләр. Тик моның өчен Казанның кайгыртуы кирәк. Ә анда хәзер дуслар юк минем, тиешле документларны кем рәтләр икән. Берәү дә рәтләмәс. Берәү дә уйлап та карамас.

Байтак кына иптәшләргә һәм Союзга рәсми рәвештә язып карадым. Җавап көтеп торам әле.

Әгәр дә син Казанга кайту бәхетенә ирешсәң, мине онытма әле. Югыйсә моннан ычкыну юк безгә. Мин бит — бәләкәй генә булсам да — офицер кеше, һаман тота бирерләр.

Ихтимал татар газетасы булмас та, ул вакытта «син русча яхшы беләсең» дип, я рус газетасында калдырырлар, я берәр хәрби чиновник итеп куярлар. Менә шуннан соң сайра инде.

Шул, Расих туган! Әгәр Казанга кайта алсаң, онытма. Бирeдә бер әйбер дә юк бит. «Совет әдәбияты»ның икенче номеры килде дә вәссәләм. Татарча бер китап укыган юк. Тәмам наданланып беттем.

Әниләреңә, дусларыңа сәлам. Хөрмәт белән:

*Г. Әпсәләмов. 15/IX—45.*

---

[1] Бу хатның азагына әнием «5/X ндә алдым» дип язып куйган. Димәк, хатны Габдрахман мин Казандадыр дип уйлап җибәргән. Хәлбуки мин демобилизацияләнеп Казанга бары кырык бишенче елның ноябрендә генә кайтып төштем.

Расих дус!

Сиңа зур рәхмәт. Бүген беренче сентябрьдә язган мөбәрәк хатыңны алдым. Синең өчен никадәр шатмын. Бу хатны бер дә шикләнмичә Чеховка язам.[1] Үткән хатымны бер үк вакытта ике адрес белән язган идем: Казанга һәм Берлинга. Монысын алай итүнең кирәге юк. Соңгы указ сиңа бөтен яктан юлны ача.

Минем исә эшләр шәптән түгел, малай. Офицерларны кайтару турында ләм-мим [сүз] юк. Шуның белән бергә сугыштан соң бу диңгез ярларында калуның минем өчен һичбер төрле кызыгы юк. Сугыш еллары башында тупланган материаллар, кичерешләр, тойгылар, күзәтүләр шулай ук барысы да әрәмгә китәр микәнни. Моңа кадәр язылганнар — диңгездән бер тамчы гына бит. Их, шундый дәрт һәм ярсу белән эшлисе килә. Ә бирeдә вак-төяк эшкә бөтен көч тә китә, ә иҗат эше икенче, өченче пландагы эш итеп карала. Алай гына да түгел, татар язучысының эшенә аерым кешеләр «вакыт үткәрү генә» дип карыйлар. Утырсаң, торып басарлык урын булмаган тар вагон купесы, язар өчен бер өстәлнең дә булмавы, болар барысы да иҗат эшен тоткарлыйлар. Сугыш дәвам иткән чакта мин башны бик югары тотсам да, хәзер ничектер йомшарып киттем. Язучыларны кайтару юлы бар дип сөйлиләр. Союзга язып карадым, ләкин игътибар итәрләр микән — белмим. Әгәр син анда булсаң, минем мәсьәлә буенча кызыксын әле.

Хикәя язган юк. Ә моннан берничә көн элек «Маньчжур сызмаларымны» җибәрдем. Шактый озын булды (55 бит). Минемчә, укучылар өчен бик кирәкле. Синең дә Берлин турындагы бер очеркыңны укыйсы килә. Ишморат һәм Г. Насрый очерклары бик йомшаклар. Аларның очеркларындагы фактлар үзләреннән-үзләре әһәмиятле булганлыктан гына журналга кергәннәр.

Хәзер бездә төнге ике сәгать, сездә кичке алты. Мин кижүдә.[2] Тәүлек буенча йокламаска. Ә йоклыйсы килә. Хәзер дә менә күзләр йомыла. Шуңлыктан хатны тәмамлыйм. Барыбер барысын да хатка язып бетереп булмый.

Сәламәт бул. Эшеңдә, иҗатыңда һәм сагынылган мәхәббәтеңдә уңышлык телим. Алла кызның яхшысын бирсен үзеңә. Хат яз. Хөрмәт белән:

*Г. Әпсәләм. 29/IX—45.*

---

[1] Без Казанда ул вакыт Чехов урамында яши идек.

[2] Сүз кизүдә, дежурда дигән мәгънәне аңлата.

# КОЯШ ЧЫКТЫ, НУР БАЛЫКТЫ...

Габдулла Тукайның әдип һәм шагыйрь булып формалашуында Уральск шәһәре, анда 1905—1907 елларда чыккан «Фикер» газетасы, «Уклар» һәм «Әлгасрел-җәдид» журналлары әһәмиятле роль уйнаганнар.

Бу органнарның оешу тарихы 1903 елдан ук башланып китә. Мөгаллим Камил Мотыйгый чыгарган кулъязма «Әл-Мәгариф» (1903) газетасы һәм кулъязма «Әлгасрел-җәдид» (1904—1905) журналы Уральск шәһәрендә татар матбугаты органнары туудa, алар тирәсенә прогрессив карашлы әдипләрнең тупланууында, милли-азатлык хәрәкәтенең үсешендә билгеле бер роль уйныйлар. 1904 елда К. Мотыйгый үзе укыткан «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә шәкертләр өчен китапханә һәм әдәбият түгәрәкләре оештыра. Бу «Мәҗлесе гыйльмия» түгәрәкләрендә «әдәбият һәм тормыш каршылыклары» хакында бәхәсләр бик еш була, аларның үзәгендә Тукай тора. Мәгърифәтче шагыйрьләрдән — Мирхәйдәр Чулпани, әдипләрдән — Әхмәтфәрит Ширвани, Әхмәтсафа Байтирәков һ. б. бу мәдрәсәгә еш киләләр. Шулай итеп, «Мотыйгыя» мәдрәсәсе прогрессив идеяләрне күтәрүче мәгърифәт үзәкләренең берсенә әверелә. Тукайның азатлык идеяләре дә шушында җитлегә башлый.

1905 елның 15 сентябрендә чыккан «Әлгасрел-җәдид» журналының «Игълан»ында ук Тукай азатлык көрәшенә күтәрелүдә мәгърифәт һәм басма сүзнең зур роль уйнаганлыгын билгеләп үтә, алар ярдәмендә халыкның үзаңы уяначагын, үсәчәген күрсәтә. «Газетаның файдасы кат-кат сыналган ич дөньяда»,— ди Тукай. Аның бу фикерләре К. Мотыйгый сүзләре белән дә туры килә. «Хәлбуки, газета-журналларның милләткә китердекләре файдалары галәмчә тәҗрибә улынмыш эшләрдәндер,— дип яза К. Мотыйгый шушы ук игъланда,—... Милләтемезе гафләт йокысыннан уйгатмая, тәгассыйб вә фанатизм кебек фаныйлыклардан котылдырмая, мәдәният вә мәгърифәт чук итмәя газета вә журналлардан башка юл вә гыйлаҗ юкдыр».

Рус телендә чыккан «Уралец» газетасының нәшире булган К. Мотыйгый 1905 елның 26 ноябрендә газетаның сердәше һәм дусты «Фикер» газетасын чыгара башлый. Газетаны нәшер итү эшенә, иң беренчеләрдән булып, Тукай тартыла. 1906 елның гыйнвареннан «Әлгасрел-җәдид» журналы да чыга башлагач, Тукай Уральск татар матбугатында төп фигураларның берсенә әверелеп китә. «Уралец» газетасында эшләүче рус социал-демократлары белән тыгыз бәйләнеш тиз арада «Фикер» газетасын һәм «Әлгасрел-җәдид» журналын көрәшчән матбугат органнары итә.

«Фикер» демократик-прогрессив газета буларак күтәрелеп китә. Башлангыч чорында ул үзе хакында болай дип белдерә: «Фикер» газетасы халкыбызга хәзерге бик кирәкле хәлләр вә хәбәрләр илә... хезмәт итәчәктер. Хосусан, милләт угылларының җөмлә ихтыяҗларыны сөйләп күрсәтәчәк вә белдерәчәкдер.

«Фикер» газетасы... казанча... гавам (халык) телендә язылачакдыр... Хосусан, халык иркенчелегенә сәбәп була торган нәрсәләрне язачакдыр» («Фикер», 1905, 18 декабрь).

Башлангыч чорында Уральск матбугаты «Казах конституцион-демократик партия»сенең программасын халыкка җиткерә, чөнки буржуаз ирек өчен көрәш милли-азатлык хәрәкәтенең җиңүенә кирәкле булган иң беренче шартлардан була. Казах кадетларының җир һәм буржуаз ирекләр өчен көрәш алып баруы, казах халкын милли азатлык хәрәкәтенә чакыруы — болар барсы да «Фикер» газетасына шушы партия белән каршылыкка кермәү өчен шартлар тудыра. Шул ук вакытта Уральск татар матбугаты самодержавие даирәләрен, карагруһчыларны, патша яклы төрле «ватанпәрвәр» партияләрне тәнкыйть итеп чыга, аларның халык азатлыгын буып торуларын аңлатып бирә, мәгърифәт һәм социаль прогресс байрагын югары күтәрә. Беренче Думага сайлаулар мәсьәләсенә килгәндә, ул Думаның киңәшче органы гына булмыйча, закон чыгаручы орган булуын, халыклар мәнфәгатеннән чыгып эш итүен тели. Әмма Думаның само-

державие алдында көчсезлеге, татар буржуазиясенең либераллык игълан итү, патша хөкүмәте алдында тез чүгү, азатлык хәрәкәте идеалларыннан ваз кичү фактларын ачык сөйләгән Уральск матбугаты озакламый казах кадетларына да ышаныч белән караудан туктый. Ә милли азатлык хәрәкәте идеяләрен пропагандалауны, яктыртуны дәвам итә. Шулай ук хатын-кыз азатлыгы, мәгърифәтне үстерү мәсьәләләрен көн тәртибеннән төшерми. Шушыларга нисбәттә дини-клерикаль газеталарны тәнкыйтьләп кенә калмый, мондый матбугатның азатлык хәрәкәте үсешенә тоткарлык ясавын да аңлатып бирә.

«Фикер» газетасының йөзен тагын да тулырак күз алдына китерү, юнәлешен билгеләү өчен «Бер фикерче» имзасы белән язылган «Һәркимиң кәндинчә вардыр мәхаль әндишәсе» («һәркемнең, һичшиксез, үз фикеренең урыны бар») мәкаләсенә игътибар итик. «Фикер» газетасы социализмның мөкатдәс икәнен беләдер. Белсә дә, заман икътизасынча (кушуынча) гына хәрәкәт итәдер,— дип яза Тукай бу мәкаләсендә.— ...Әүвәл милләт укысын, белсен, француз, нимсәләр кадәр күзе ачылсын. Шундаен соң Карл Маркс мәзһәбенә (юлына) яки ортодокс мәзһәбенә керергәме — анысын үзе белер.

«Фикер» газетасы: укыйк, ди, белик, ди, мәктәпләр салыйк, ди, ир вә хатын мәсави (тигез хокуклы) булсын, ди, социализмны чынлап аңларга әүвәлен мәктәп вә мәдрәсәләр кирәк, ди» («Фикер», 1906, 31 декабрь).

«Борһане тәрәккый» кебек буталчык мәсләкле газетага каршы язылган бу мәкаләдә Тукай «Фикер»нең милли азатлык идеяләренә тугрылыклы булуын тагын бер кат ачыклап үтә.

Уральск матбугатының социаль артталыкка, самодержавиегә каршы милли азатлык юлыннан баруы карагруһчыларның шушы органнарны туктату өчен һөҗүмнәр оештыру фактларыннан чыгып карасаң, тагын да ачыграк күренеп тора. «Уклар» журналы чыга башлагач һәм Беренче Дума таратылгач, карагруһчыларның бу прогрессив матбугат органнарына карата тупас басымы тагын да активлашып китә. Аларга җавап буларак, милли азатлык, мәгърифәт идеяләре белән коралланган «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналлары дини схоластиканы, суфыйчылыкны тагын да ныграк тәнкыйть итә, хөррият, ирек өчен көрәшнең генә дини фанатизмны җиңәргә мөмкинлек бирүен катгыйрак раслый башлый.

Уральск матбугаты «Бәянел-хак» һәм шуның кебек башка органнарга тиешле отпор биреп бара, аларның шәригатьне яклап маташуларының мәгънәсезлеген, дини кануннарны төрлечә бозып күрсәтүләрен ачыклап, үз тәнкыйтендә Көнчыгыш фикер ияләренең прогрессив фикерләрен уңышлы файдалана. Карагруһчылар, ал[illegible]рны фикер көрәшендә җиңә алмагач, погром оештырып, «Фикер» матбагасын җимерергә, К. Мотыйгыйга һәм аның гаиләсенә, Тукайга һөҗүм итү уена киләләр. Уральск шәһәрендә Хәйрулла Гаделшин үз тирәсенә фанатикларны җыеп, аларны шушы прогрессив органнарга каршы дәртләндерә башлый. Ул үзен дин сакчысы, динсез дәһриләргә каршы көрәшүче «хак мөселман» итеп күрсәтергә тырыша («Фикер», 1906, 10 июль).

«Фикер» газетасы шушылардан соң: «Йитәр дин исемендән инсан таламак! Йитәр шәригать исемендән халыкны каралтмак! Йитәр болганчык судан балык ауламак! Бетсен мөтәгассыйблар! Яшәсен яңа яшь милләт каһарманнары!»— дип белдереп чыга («Фикер», 1906, 28 июль).

1906 елның 15 августы төнендә карагруһчылардан берничә кеше «Фикер» матбагасына, тәрәзәсен ватып кереп, берникадәр зыян китерәләр. Бу хакта К. Мотыйгый полициягә хәбәр итсә дә, аларның ярдәмен ала алмый. Озакламый, шушы ук елның 27 августында Уральск халкының исендә калырлык вакыйга була. Тукай бу хакта «Уральскида Дума членын вә тәвабигын (иярүчеләрен) нагайкалау» мәкаләсендә язып чыга. Бу көнне митингка халык Беренче Дума члены В. В. Недоносков[illegible]ң чыгышын тыңларга җыелган була. Халык арасында тиз арада прокламацияләр дә таратыла. Әмма Недоносков чыгышын ясарга өлгерә алмый кала, атлы казаклар һәм полиция җыелган халык өстенә ташлана. Күпләрне камчылыйлар һәм кулга алалар. Аларга карагруһчылар ярдәм итешә, полиция белән бергә халыкны эзәрлекләүдә катнашалар. Үзләрен кыйнаучыларга халыкның каршы тормавына ачынып, Тукай болай дип яза: «Полиция әйткәндә «бунт» ярты сәгать кадәр аз бер мөддәт (вакыт) эчендә таратылды, бичара халык казакларга каршылык итәргә уйлап та карамады».

Бу вакыйгалардан соң Уральск матбугаты карагруһчыларга, самодержавиегә карата тәнкыйтен тагын да арттыра, мәгърифәт эшен юлга салуда практик чаралар күрүдә җитәкчелек итә башлый. Укытучы-мөгаллимнәр әзерләү өчен мәктәп салу мәсьәләсен К. Мотыйгый кузгатып җибәрә. Аның бу фикерләрен Тукай һәм шәһәрнең башка алдынгы карашлы яшьләре күтәреп ала. Әмма монда да алар карагруһчыларның каршылыгына очрыйлар. Ул арада Икенче Думага сайлауларга хәзерлек башланып китә. Төрле җирләрдә җыелышлар була. Шундыйлардан унынчы декабрьдә «Пушкин йортында» эшчеләрнең җыелышы уза. Ни сәбәптер монда катнашучы Краузе кебек банкир һәм байгуралар җыелышка үз теләкләрен такмакчы булалар. Аларның сүз болгатып сөйләү-

ләреннән соң К. Мотыйгый сикереп тора һәм, урындыклар өстенә басып, эшчеләргә үз мәнфәгатьләрен яклардай депутатны Думага сайларга кирәклеген аңлатып, чыгышын «Интернационал» җыры белән тәмамлый да иптәшләре белән җыелыштан чыгып китә. Алар артыннан башкалар да тарала. Шул ук көнне эшчеләр типографиягә килеп, К. Мотыйгыйга рәхмәтләрен белдерәләр («Фикер», 1906, 13 декабрь). К. Мотыйгый мондый җыелышларда бик еш катнаша, һәрбер чыгышында халыкны үз мәнфәгатьләрен якларга чакырып чыгышлар ясый. Тукай да аның белән бергә була, җыелышлар хакында да, халыкны үз мәнфәгатьләрен якларга чакырып та мәкаләләр яза. Аларның кайсыберләре русча тәрҗемә ителеп, «Уральский дневник» (1907, 17 январь) газетасында да басылып чыга.

«Безем бу журналны нәшер итмәктән максатымыз мал җәһәтенчә файда казану дәгелдер,— дип яза К. Мотыйгый «Мөхтәрәм мөштәриләремезгә тәнбия» («Хөрмәтле укучыларыбызга») мәкаләсендә.— Юк! Безнең башлыча максатымыз:

— Милләтемезе инкыйраздан (бетүдән) күтәрмәк юлында би хак (хаклы) социалист-демократик мәсләкендә (юлында) буларак нам хөррият (ирек исемен) казанмая хезмәт итмәкдер.

— Долой бюрократ, провокаторларны!

— Долой инсаннарга зарарлы адәмнәрне!

— Хөррият, ирек барча халыкга булсын, Русиядә улан барча халыкга улсын. Милләт, нәсел вә нәсәп аерылмаенча, русларга, мөселманларга, яһүдиләргә вә башка милләтләргә, ирләргә вә хатыннарга — барчасына тигез хаклар булсын.

Менә безнең сөйли торган сүземез ошбудыр.

Эштә безнең мәсләк тә будыр» («Әлгасрел-җәдид», 1906, декабрь, 620-621 б.).

Әмма К. Мотыйгыйга 1907 елда нәширлек һәм редакторлык эшен озак дәвам итәргә туры килми. «Шәһәремездәге администрациянең хөкеме буенча, биндән нашир вә мөхаррирлек бу көн алынды»,— дип яза К. Мотыйгый «Фикер» газетасының 1907 ел 22 февраль санында. Шушында ук басылган «Бу көндән соң барча нәшриятем тәхет идарәсенә тапшырылачак мөхтәрәм зата нәсихәтем» мәкаләсендә булачак редактордан «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдид»не элеккеге төп юнәлешеннән дәвам иттерүен үтенә.

1907 елның беренче мартыннан К. Мотыйгыйның «Тәрәккый» матбагасы сәүдәгәрләр Мортаза Гобәйдуллин һәм Вәлиулла Хәмидуллин кулына күчә. «Фикер» газетасының сигезенче март саны В. Хәмидуллин редакторлыгында чыга. Газета үзенең «әүвәлге... мәсләк үзрә дәвам итәчәген» белдерә («Фикер», 1906, 8 март). Уральск матбугаты, чыннан да, юнәлешен үзгәртми, диндарлык һәм суфичылыкны тәнкыйть итүен дәвам итә, татар либераль буржуазиясенең чын йөзен ачып бирүче мәкаләләр бастыра. «Фикер» газетасын чыгаруның, «Әлгасрел-җәдид» журналын хәзерләүнең һәм элеккеге төп юнәлештән тайпылмыйча дәвам иттерүнең бөтен авырлыгы Тукай җилкәсенә төшә. Бу вакытларда «Фикер» большевистик «Урал» газетасы тәэсирендә була, ә бу исә Уральск татар матбугатының эчтәлеген тагын да баетып җибәрә.

Икенче Думаның эшлексезлеген ачыклауда «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдид» күп эш башкара. Ул Думаның утырышлары хакында халыкка даими хәбәр итеп бара, сул партияләрне, бигрәк тә социаль-демократларны яклап чыгышлар ясый.

Әмма типографиянең төп хуҗалары булган Б. Турабрин, К. Ванюшин, Н. Аржанов Саратов Суд палатасының беренче апрель хөкеме буенча, матбаганы 1907 елның 29 маенда сатып җибәрәләр. Өченче июньдә самодержавие Думаны куып тарата, илдә прогрессив партияләрне, матбугат органнарын эзәрлекләү, реакция чоры башланып китә. «Фикер» газетасының һәм «Әлгасрел-җәдид» журналының туктатылуы очраклы хәл булмый, әлбәттә.

Беренче рус революциясе татар халкының үзаңы уяну һәм үсүгә, политик көрәшкә күтәрелүенә зур этәргеч була, демократик матбугат органнары, шул җөмләдән, «Фикер» газетасы, «Әлгасрел-җәдид» һәм «Уклар» журналлары да моңа зур өлеш кертә.

**Фәрит ЯХИН.**

# ТУПЛАР АТСА ДА, МУЗАЛАР ТЫНМАДЫ

Кешелек тарихы Бөек Ватан сугышы кебек канкойгыч бүтән сугышны белми. Әлеге сугыш утында дөнья тарихындагы беренче социалистик дәүләт язмышы, кешелек дөньясының киләчәк язмышы хәл ителде. Бу — төрле дәүләтләрнең экономика һәм оборона потенциалы сугышы гына түгел, ике капма-каршы идеология сугышы да иде.

Советлар иленә басып кергәндә, үз армиясенә социализм идеяләренең революцион йогынты ясавыннан куркып, фашист командованиесе солдат массаларын идея ягыннан эшкәртүгә аеруча нык игътибар итә. Тиз арада пропагандистлар һәм культура работниклары штатлары кертелә, кино, концерт кебек хискә тәэсир итү чаралары киң файдаланыла. 1941 елның ноябренә Гитлер армиясендә 60 меңләп фронт китапханәсе исәпләнә. Армиягә культура хезмәте күрсәтүдә 9 айда 14 мең артист катнаша. Фашист командованиесе совет халкының мораль көчен таркатырга, аны рухи төшенкелеккә салырга тырыша.

«Илебез куркыныч астында! Барыгыз да Ватан сагына!» дигән лозунг яңгыраган көннәрдә партия һәм хөкүмәтебез кыска срокта совет халкының материаль һәм рухи көчләрен дошманга каршы көрәшкә туплау программасын эшли.

Сәнгать интеллигенциясе эшчәнлеге дә үзәккә куела. Аның бурычы итеп совет сугышчыларын рухи һәм әхлакый коралландыруда Коммунистлар партиясенә ярдәм итү, тыл хезмәт ияләренең рухын ныгыту, күңелен күтәрү, ышаныч уяту билгеләнә. Әгәр социализмны тыныч төзү елларында сәнгать әсәрләре хезмәт батырлыгына өндәгән, совет кешесенең югары әхлакый сыйфатларына дан җырлаган булса, сугыш алды елларында алар илебезне теләсә нинди дошманнан сакларга әзер торырга чакырды. Ә инде Ватаныбызга үлем куркынычы янаган көннәрдә совет сәнгате халыкны Ватанны сакларга күтәрүче көч булды.

Бөтен идеология эшен, шул исәптән сәнгать учреждениеләре эшчәнлеген үзгәртеп кору сугышның беренче көннәрендә урнашкан галәмәт авыр шартларда бара.

Бөтен илебездәге кебек үк, Татарстанда да митинглар үтә, бу митинглардан туры фронтка китәләр. Сугышка кадәрге кебек үк, иҗат интеллигенциясе көрәшнең алгы сызыгында. Меңнәрчә сәнгать әһелләре кулларына корал тотып Ватанны, совет сәнгатен сакларга китә.

«22 июньдә Опера һәм балет театры яшьләре, барлык коммунистлар һәм комсомоллар Кызыл Армия сафларына язылырга гариза бирде,— дип искә ала хәзер М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры труппасы мөдире, ТАССРның атказанган артисты Л. С. Верниковский.— Без урыныбыз фронтта дип уйладык. Теләсә кайсы минутта кулыбызга корал алырга әзер, чакыру килгәнне генә көтә идек...».

Театр партоешмасы секретаре Мәхмүт Алиев, труппа мөдире Хафиз Гатов, опера солисты Казанский, хор артисты Семен Разумный һәм башкалар фронтка китә. Район һәм колхоз-совхоз театр коллективларында да ир-ат бөтенләй диярлек калмый.

Сугышның икенче көнендә 128 нче номерлы приказ белән фронтка китүче артистлар М. Гайнуллин, М. Надрюков, Ф. Халитов, рәссам М. Сутюшев, театр эшчеләре Т. Морозов, И. Слепнев, Д. Шакиров Татар дәүләт академия театрын калдыралар.

Коммунистлар, комсомоллар һәм партиясезләр фронтка китә. Гомер-гомергә туган туфракны якларга тиешле ирләр китә. Партия һәм комсомол патриотлар итеп үстергән кызлар китә.

«Сугышка кадәр мин Татар күчмә театры артисткасы идем. Без гастрольләр белән республика районнары буйлап йөрдек. Сугыш башланыр алдыннан Х. Садриның «Партизаннар» пьесасын куйдык, мин анда унсигез яшьлек партизан кыз Мәрьямне уйнадым. Ул чагында бик тиздән үзем дә фронт юллары буйлап кулыма мылтык тотып кына

түгел, пушка белән узармын дип башыма да китерми идем»,— дип искә ала 254 нче зенит полкы ветераны, элекке артистка З. Хәлиуллина.

Татар академия театрының унсигез яшьлек талчыбыктай сылу кызы — артистка Бикә Шакирова да ил язмышы хәл ителгәндә ныклык күрсәтә, берничә ай дәвамында үзен фронтка җибәрүләрен таләп итә торгач, теләгенә ирешә.

25 июньдә Татар дәүләт филармониясендә митинг була: ирләрнең күбесе корал тотып хәрәкәттәге армиягә китә. Гармун уйнап җибәрәләр: кемдер җырлый, кемдер елый. Кысып җитәкләшкән өч яшь кыз фронтка киткән иптәшләре артыннан карап кала, алар әле генә бөтен көчләрен һәм талантларын, кирәк булса тормышларын да Ватанга бирергә ант иткәннәр. Бу дус кызлар — нәфис сүз остасы Катя Краевская, биюче Люба Бердникова һәм җырчы Зита Измайлова. Митингтан соң ук алар мобилизация пунктына юнәлә, дәртле биюләре, илһамлы җырлары белән китүчеләр йөрәгенә халкыбызның җиңелмәслегенә ышаныч, тиздән җиңеп кайтуга ышаныч кабыза.

Тиздән филармония директоры А. А. Абдуллин, эстрада-концерт бүлеге артистлары А. Хронусов, Н. Мезин, җыр һәм бию ансамбле артистлары А. Зәйнуллин, К. Павлов, А. Басыйров, С. Хәйруллин, Вахитов һ. б. фронтка китә.

Казан Зур драма театры артистлары сугыш башланганда Кырымда була. Гастрольләр уңышлы үтә. Алдагы шимбә кичендә, 21 июньдә көньяк кояшында нурга күмелгән зур теплоход аларны Ялтага китерә. Якшәмбе кичендә биредә беренче спектакль куеласы була.

Ләкин иртән сугыш башлана, һәм немецлар инде Севастопольне бомбага тота...

Ялта урамнары буйлап нык басып хәрби отрядлар үтә. Һәрвакыт кеше кайнап торган кибетләр, кафелар ябыла; 22 июньдә кичен театр Ялтада гастролен башлап җибәрә. «Федор Иванович патша» дигән спектакль куела. Артистлар уйнаган курорт залы шыгрым тулы, билетлар җитми. Ә спектакльдән соң тамашачылар сәхнәне чәчәкләргә күмә. Бу көнне алар сәнгатьнең сихри дулкынын, җәлеп итү көчен гел бүтәнчә тойгандыр. Сугыш башланганын ничек тә онытып, белми торасылары килгәндер.

22 июньдәге бу спектакль, шыгрым тулы зал һәм чәчәкләр, бик күп чәчәкләр — болар бөтенесе кара афәт булып ябырылган «сугыш» сүзенә протест, аңа ышанырга теләмәү була.

«Һәр кичне спектакль куеп, һәркөн иртән күрсәтелгән пунктларда траншеялар казырга китә идек. Бу эшне белеп бетермәсәк тә, бөтен җаваплылыкны тоеп башкардык...»— дип искә ала элекке актриса Е. В. Лисецкая.

Тимер юлга хәрби эшелоннар бөялгән. Артистлар Казанга товар вагоннарында, төркем-төркем булып, күчә-күчә, көч-хәл белән кайтып җитәләр.

Сугыш Курчак театры татар труппасының да Татарстан районнарындагы гастролен туктата. Артистлар ашыгыч рәвештә Казанга кайта. Ирләрнең күбесе үзләре теләп фронтка китә. Г. Бакалов, Г. Медведев, Н. Сиражетдинов, Ф. Таһиров, Н. Ханфиев һ. б. кулларына корал ала. Моңарчы үзләренең сәнгате белән явызлыкка каршы көрәшергә һәм гаделлек тантанасына ышанырга өйрәткән артистлар өчен совет сәнгатенең, совет социалистик җәмгыятенең гуманлы принципларын үз гомерләре бәрабәренә аклар һәм саклар көн җитә.

Сәнгать учреждениеләрен үзгәртеп кору эше җиңел бармый. Байтак профессиональ кадрлар һәм бөтен техник персонал фронтка һәм оборона заводларына китә; сугышның беренче елында иҗат оешмалары эшчәнлеген финанслау киметелә; кирәкле автотранспорт фронт ихтыяҗларына алына.

Татар академия театры бинасында эвакуация пункты урнаша, һәм 1941 елның 4 ноябреннән театр вакытлыча Зур драма театры бинасына күчә. Спектакльләрне алар уртак сәхнәдә тигез шартларда куялар: айга 44 спектакль. Опера һәм балет театры да шул түбә астында эшли. Төп кадрлары фронтка алыну сәбәпле, Яшь тамашачы театры вакытлыча эшләми тора. Ул үзенең эшчәнлеген яңадан 1942 елның октябрендә — Сталинград артистлары исәбенә сафларын тулыландыргач кына, башлап җибәрә.

Сугышның беренче көннәрендә үк татар дәүләт филармониясенең Бутлеров урамында урнашкан бинасы хәрбиләргә бирелә. Репетицияләр филармония директоры З. С. Әхмәтова квартирасында үтә. Сугыш бара, һәм сәнгать әһелләре иптәшләре яу кырында кан түккәндә, барлык көенлекларны җиңәргә, бөтен көчләрен партия һәм хөкүмәтебез алар алдына куйган бурычларны хәл итүгә юнәлдерергә тиеш дип саныйлар.

Республика сәнгать учреждениеләре алдында халыкның бөтен көчләрен Ватан сугышына туплауда ярдәм итү, дисциплинаны һәм оешканлыкны ныгыту, предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү эшендә булышлык итү бурычы тора.

Әнә шул бурычлардан чыгып, СССР Халык Комиссарлар Советы каршындагы Сәнгать эшләре комитеты директив хатта иҗат оешмалары эшенең юнәлешләрен билгели:

1. Репертуарда халыкның патриотик тойгыларын чагылдыру, совет кешеләренең батырлыгын һәм кыюлыгын ачу...

2. Иң тиз арада сәнгать учреждениеләренең эш формаларын һәм методларын

үзгәртеп корып, чакыру пунктларында, вокзалларда эшләү өчен тиз кузгала алырдай коллективлар төзергә.

Республика сәнгать әһелләре, сугыш башланган көнне үткән митингта бик дөрес карар кабул итәләр: «Без, сәнгатьнең барлык төрләре эшлеклеләре, оборона пропагандасының үткен коралын тоткан сугышчылар буларак, тамаша һәм сурәтләү сәнгатенең барлык чаралары белән совет халкының кан дошманын — фашизмны кыйнарбыз, кирәк була калса, кулга винтовка һәм граната тотып, гомеребезне дә аямыйча, фашист баскыннарын тар-мар итәрбез!»

Халык массаларын тылда һәм фронтта бер йодрыкка туплауда сугышның беренче көннәрендә үк туган шигырьләр һәм җырлар зур роль уйный.

Филармония артистлары шигырьләрне, җырларны, такмакларны язылуга ук отып ала һәм репертуарларын Ватан сугышы рухы белән сугара.

Яңа репертуар белән артистлар вокзалларга һәм мобилизация пунктларына, предприятиеләргә һәм учреждениеләргә китә, республика районнарына чыга. Сугышның 10 нчы көнендә, Татарстан беренче яралыларны кабул иткәч, артистлар аларның дусларына, шефларына әверелә. 1941 елның 26 сентябрендә партия өлкә комитеты секретаре С. Ф. Имаметдинов җитәкчелегендә оештырылган авыру һәм яралы сугышчыларга һәм командирларга хезмәт күрсәтү буенча Республика комитетына ТАССРның атказанган артисткасы Л. Милова да керә.

Актерлар алдында репертуар проблемасы бик җитди тора. Илебезнең барлык театрлары югары художестволы актуаль әсәрләр җитмәүдән кыенлык кичерә. Бик тиз күренә башлаган «кече формалардан» (плакат, җыр, шигырь) аермалы буларак, драма әсәрләре тиз генә иҗат ителә алмый. Вакыйгаларның төбенә төшү өчен вакыт кирәк, совет кешесенең — фронтовикның һәм тыл хезмәтчәненең характерын төшенергә, батырлык чыганакларын аңларга кирәк иде. Шуңа күрә сугышның беренче чорында театрлар совет авторларының сугышка кадәр язылган иң яхшы әсәрләрен сайлап ала. Октябрьдә Казан зур драма театрында Вл. Соловьевның «Фельдмаршал Кутузов» исемле тарихи пьесасы буенча куелган спектакленең премьерасы була. Элек әйтелгән кимчелекләре булуга карамастан, пьеса тамашачыларның җиңү дәртен нығытуда зур роль уйный. Тамашачыларны да, пьеса геройларын да бер үк тойгылар дулкынландыра — үз илләренең язмышы өчен борчылу, рус халкы өчен горурлык тойгысы. Хәзер дә, авыр сынаулар заманында да, халык илбасарларның иманын укытыр дигән ышаныч ныгый. Җиңүгә ышаныч һәр тамашачы күңеленә күчә.

Әле 1940 елда ук, Мәскәү партия активы җыелышында сөйләгәндә М. И. Калинин болай ди: «Совет патриотизмын вәгазьләү халкыбызның элекке тарихыннан аерылган була алмый, тамырлары белән шуңа тоташмый кала алмый. Ул халкың кылган эшләр өчен патриотик горурлык белән сугарылырга тиеш. Бөтен совет патриотизмы халык үсешен алга җибәргән бабаларыбызның иҗади эшләренең турыдан-туры варисы булып тора». Шунлыктан театрлар репертуарында Ватаныбызның данлы тарихына караган пьесалар мөһим роль алып тора. Патриотизм темасы республикадагы сәхнә әсәрләренең төп темасына әверелә. Бу хакта Татар дәүләт опера һәм балет театры спектакльләре дә сөйли. 24 июньдә Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил либреттосына язылган «Алтынчәч» операсының премьерасы зур уңыш казана. Опера гүзәл музыкаль-драматургик образлар ярдәмендә халыкның үткәнен бүгенге көн белән ялгаучы җеп булды. «Бергә-бергә «Алтынчәч» операсы өстендә эшләгән чакларны онытасым юк,— ди СССРның халык артисты Нәҗип Җиһанов.— Таңга кадәр бәхәсләшә, теге яки бу күренешне иң әйбәт бирү юлларын эзли идек... Муса фронтка китәр алдыннан төне буе караңгы Казан урамнары буйлап йөрдек. Күп нәрсә сөйләштек, бигрәк тә сугыш, сынауларның авырлыгы хакында.

— Фашизм бөтен кешелек дөньясына кул күтәрде. Әлбәттә, без җиңәрбез, ләкин сугыш авыр булачак... Әйләнеп кайтасы бик килә...

Ул тынып калды. һәм кинәт кызу-кызу сөйләп китте:

— Әгәр һәлак булырга туры килсә, мин аларга гомеремне арзанга бирмәм.»

Бары тик югары әхлакый сыйфатларга ия кеше генә шагыйрь теле белән, либретто аша каһарманлык турында, халык гомере өчен үз гомерен корбан итү, бурыч һәм намус турында сөйли ала. Бу хокукны Муса Җәлил гомере бәрабәренә исбатлады:

...Бар җырымны илгә багышладым.
Гомеремне дә бирәм халкыма...

Бер үк вакытта театр ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар» пьесасы өстендә эшли. Бу пьесаны драматург Финляндия фронтындагы героик вакыйгалар уңаеннан яза. 26 июльдә үк булган премьера соңыннан тамашачылар аеруча яратып караган спектакльнең актуальлеген раслый. Сугышның беренче

елында бу темага югары художестволы әсәрләр булмый. Бу уңайдан Мәҗитов-Турайлының «Очрашу» пьесасы буенча куелган спектакль игътибарга лаек. Ләкин бик тиз арада язылган һәм куелган бу пьеса сугыш башлангач совет халкында килеп чыккан психологик үзгәрешләрне чагылдыра алмый, бары тик сәхнәдә Совинформбюро хәбәрләренә комментарийлар гына бирә.

Татар авторларының күбәеп китүе зур патриотик күтәренкелек турында сөйли. Сугыш башланганнан соң бер айдан театрның режиссерлар коллегиясендә Мәҗитовның очучылар тормышыннан язылган «Батырлар юлы» пьесасы, бер айдан Т. Гыйззәтнең «Серле казна» пьесасы укыла. Художество советы пьесаны актуаль һәм хәзерге вакыйгаларга туры килә торган дип таба һәм колхоз-совхоз театрлары репертуарларына кертү өчен тәкъдим итәргә диган карар чыгара.

Сугышның беренче айларында язылган пьесалар буенча куелган спектакльләр сугыш вакыйгаларын тыштан гына чагылдырсалар да, алар шулай да үз рольләрен — патриот спектакль, агитатор спектакль рольләрен үйнадылар.

1941 елның 6 август хатында Сәнгать работниклары союзы Үзәк Комитеты яңа шартларга туры килә торган репертуар булдыру зарурлыгын әйтә. Бигрәк тә бер пәрдәле пьесаларга, скетчларга, такмакларга игътибар юнәлдерелә.

Сугышның беренче чорында бер пәрдәле пьесалар театр репертуарында аеруча тансык була. Алар сугыш вакыйгаларына бик тиз җавап бирә һәм мөһим патриотик функцияләр башкара. «Патриотлар», «Элемтәчеләр» кебек үткен темалы бәләкәй сәхнә әсәрләрен республика театрлары беренче көннәрдән үк репертуарга кертәләр. Зур гомумиләштерүләр дәгъва итмичә, әллә ниткән декорацияләр кирәкми торган шундый пьеса-скетчлар колхоз-совхоз театрлары өчен бик кулай булып чыга.

Республиканың күренекле композиторлары Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи сугыш елларында такмак жанрында да эшли. «Хәзерге чорның политик торышы эчке ресурсларны мөмкин кадәр тизрәк һәм тәвәккәл рәвештә үзгәртеп коруны таләп итә»,— диелә филармония директорының 1941 елның 6 июлендә биргән приказында. Эстрада-концерт бүлегенең барлык артистлары һәм договор нигезендә эшләүче артистлар шәһәргә, республикага хезмәт күрсәтүче бригадаларга керә. ТАССР җыр һәм бию ансамбле, халык уен кораллары оркестры өч бригадага бүленә. Ансамбльләрнең, оркестрларның, эстрада артистларының концерт программалары бик тиз яңартылып тора. Филармония буенча приказларда программалар нигездә патриотик, халыкны Германия фашизмына каршы хәлиткеч көрәшкә, кешеләрнең сугышчан рухын һәм оешканлыгын күтәрергә өнди торган репертуарны эченә алырга, анда башлыча антифашистик һәм оборона темасына язылган әсәрләр булырга тиеш диелә.

Бу эштә филармониягә Татарстан Композиторлар союзы зур ярдәм күрсәтә.

«Без, культура фронты работниклары,— ди Н. Җиһанов ТАССР Композиторлар союзының сугыш башлангач җыелган беренче утырышында,— барыбыз бер булып бөтен көчебезне Ватанны саклауга бирергә тиешбез. Без илебез оборонасына ярдәм итәрлек җырлар иҗат итәргә тиешбез». Республика композиторлары сугышның баштагы ай ярымында 28 марш, солдат җыры һәм өндәү-чакыру җыры уен кораллары өчен маршлар язалар. Болар Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, З. Хәбибуллин — Г. Кутуй, М. Җәлил, Ә. Исхак, Ә. Ерикәй һ. б. сүзләренә язган җырлар.

1941 ел азагына ук Казан хәрәкәттәге армиягә өч концерт бригадасы җибәрә. Мәскәү янынннан башланган юлларында алар Совет артисты исемен югары йөртте.

Фронт концерт бригадалары төзүдә Татар дәүләт филармониясе аеруча актив катнаша. Иң яхшы җырчыларын, гармунчыларын, биючеләрен, нәфис сүз осталарын фронтка җибәреп кенә тора. Җыр һәм бию ансамбле хәрәкәттәге армиягә беренчеләрдән чыга, ул Кызыл Армия сугышчылары арасында зур мәхәббәт казана.

Фронт бригадаларына берләшеп, артистлар үзләренең төп бурычларын яхшы аңлыйлар: бөтен халыкны Германия фашизмына каршы Ватан сугышына мобилизацияләү эшенә ярдәм итеп, сугышта совет кешеләренең рухын ныгыту. Фронт концерт бригадалары төзү буенча бөтен эшчәнлек шушы бурычка буйсындырыла.

Сәнгать әһелләре, бөтен совет халкы белән бергә иңгә-иң торып, тоташ стена булып Ватанны сакларга баса. Берәүләре кулларына корал алып фронтка китә, станок янына баса, икенчеләре дошманга үз сәнгатен юнәлтә, бу коралны көннән-көн көчлерәк, тәэсирлерәк итә.

Кинематографистлар да тамашачыларга «Чапаев» фильмының гаять зур йогынтысы булганын белгәнгә күрә, фильмның ахырын үзгәртә. Анда Чапаев елганы кичеп чыга, атка атлана һәм, тамаша залына борылып, Совет иле өчен сугышка керергә чакыра. Чапаев белән бергә йөзләрчә кеше: кечкенә малайлар һәм кызлар — руслар, татарлар — бөтен Совет халкы көрәшкә күтәрелә. Сәнгатьнең көче шундый.

**Г. МӘҖИТОВА.**

# ТАРИХТАН БЕР СӘХИФӘ

Быел мин Әзһәр Мөхәммәдиевнең «Борынгы хәзәр һәм болгар-татар акчалары» дигән китабын укыдым. Ул, нумизматика фәненә таянып, VIII—XIV гасырларда Идел буенда акча әйләнеше һәм акча сугу эшен өйрәнүгә багышлап язылган.

Бу китап VIII—XIV гасырларда Идел буенда акча сугу үзәкләре, товар-акча мөнәсәбәтләре, акча-авырлык системалары турында кызыклы факт һәм версиялардән гыйбарәт. Ләкин беренче карашка конкрет бер темага гына багышланган бу хезмәттә автор күп төрле тарихи, фәлсәфи, филологик проблемаларга да үз фикерен әйтә. Борынгы акча системасын өйрәнеп, галим шул чор төрки дәүләтенең экономик, социаль һәм культура үсеше турында мөһим фактлар бирә. Акча сугу эше дәүләтнең эчке һәм тышкы политикасы белән нык бәйле булганлыктан, автор Хәзәр каганлыгы, Болгар дәүләте, Кыпчак олысы башында торган күпсанлы тарихи шәхесләрнең алып барган политикасына, аларның аерымлы сыйфатларына кагылырга тиеш була.

Хезмәттә хәзәр һәм болгар шәһәрләре, имәнкискә культурасы хакында бай материал бар. Алтын Урда дәүләтенең башка атамалары, аларның этимологиясе турында да кызыклы гына язылган. Үз фикерен раслау өчен, галим кайбер тарихи чыганакларга, борынгы сәяхәтче яки тарихчылар калдырган истәлекләргә таяна. Шулай да, тарихи әдәбияттагы бәхәсле мәсьәләләр яки яңа ачышлар турында әйткәндә, автор «кайбер тарихчылар, галимнәр» дип, гомуми сүзләр белән генә чикләнмичә, укучыны кызыксындырган сорау буенча каян өстәмә мәгълүмат алырга икәнен дә күрсәтсә, яхшы булыр иде.

Ә. Мөхәммәдиев бу хезмәтендә «татар» сүзенең килеп чыгышын кытай, монгол тарихи чыганакларына таянып аңлата һәм «татар» дип барлык монголларны атаганнар, «татар» сүзе аларның кушаматы булган дигән фикергә кушыла. Ләкин ничек «татар» этнонимы төрки халык болгарларга «ябышып» калган, бу турыда автор үз версиясен әйтми. Ә. Мөхәммәдиев хәбәр иткән фактлар никадәр дөреслеккә туры килә, тагын нинди гипотеза, версияләр бар, бу турыда башка галимнәрнең фикерләре нинди, шуларны ишетәсе килә, чөнки татар халкы өчен бу әһәмиятле сорау һәм аны тәгаен ачыкларга кирәк.

Ә. Мөхәммәдиевнең яңа чыккан китабы — зур эзләнү, күпьеллык хезмәт нәтиҗәсе. Бай фактик материал белән бергә китапка борынгы акчалар төшерелгән таблицалар, археологик экспедиция, казу эшләре вакытын чагылдырган фоторәсемнәр урнаштырылган, алар барысы да чал тарих түрендә калган борынгы бабаларыбызның тормышын ачыграк күзалларга ярдәм итә.

Китапның уңай яклары белән бергә, шуны да әйтәсе килә: кайчак автор фикер эзлеклелеген югалтып җибәрә. Мәсәлән, кереш өлешендә автор Алтын Урданың бөтен Идел буена җәелгән булуын ялгыш фикер дип әйтә, һәм Алтын Урда һәрвакыт күчмә Урда булган ди, ә бишенче бүлектә исә «гомумән, Идел буен... үз эченә алган» бу дәүләтне «күчеп йөргән хан станы дип кенә күз алдына китерү дөрес түгел»,— дип дәлилли. Гомумән, тарихи экскурсларның төрле бүлекләрдә кабатланып килүе укучыны ялыктыра.

Кыскасы, бу хезмәттә борынгы хәзәр һәм болгар-татар акчалары турында һәм акча системасының халык тарихына бәйле булуыннан чыгып ясалган нәтиҗәләр бик мөһим. Ә кайбер аерым тарихи, этнографик проблемалар авторның үз позициясеннән генә чыгып аңлатылган дигән уй кала һәм аларга карата башка галимнәрнең дә фикерләрен ишетәсе килә. Укучы төрки халыклар тормышы, тарихы турында шушындый яңа фәнни һәм әдәби хезмәтләр көтә.

Әлфинә **СИБГАТУЛЛИНА**.
Алабуга шәһәре.

* * *

Өлкән язучы Гөлсем Мөхәммәдованың «Сикәлтәле туры юл» исемле повесте бик күп укучыларның көтеп алган әсәре булды.

Повестьта Галимҗан Ибраһимовның Уфада Галия мәдрәсәсендә укуын ташлаган көненнән алып, 1917 елгы Февраль революциясе чорына кадәрге тормышы, революцион һәм әдәби эшчәнлеге яктыртылган.

Әсәрне документаль нигездә тасвирлап язу — чын мәгънәсендә уңышлы башкарылган. Язучы повестьның беренче «Саубуллашу» исемендәге бүлегеннән үк укучыны үзе белән ияртә һәм әсәрнең алдагы эчтәлеге белән кызыксыну артканнан-арта бара. Авторның шул чор кешесе буларак, ул елларны бик яхшы белүе, аның өстенә Галимҗан Ибраһимовның характерын, шәхси якларын һәм язылган әсәрләрен җентекләп өйрәнгәнлеге сизелеп тора.

Автор татар теленең мөмкинлекләреннән оста файдаланган, әсәр җиңел укыла. Һәр бүлектә шул чорның рухын сиземләп, вакыйгаларны күңелдән кичерәсең. Повестьта гарәп, фарсы сүзләре бик сирәк, кирәкле урында гына кулланыла. Шуңадыр, алар укучыны ялыктырмый. Кыскасы, өлкән язучы Гөлсем Мөхәммәдовага бу документаль повесте өчен зур рәхмәт.

**Сәлах ШӘРИПОВ.**
Азнакай районы, Чалпы авылы.

* * *

«Казан утлары» журналының 1986 ел 11 санында Һади Атласов турында язылган мәкаләне укыгач, шушы хезмәтне язучы галимнәргә үземнең зур ихтирамымны белдереп, рәхмәт сүзләре язарга булдым.

Совет властеның иң киеренке елларында мәгариф өлкәсендә үзенең хезмәте белән эз калдырган Һади Атласов минем өчен бик якын. Мин аны зур ихтирам белән искә алам. Ул олы җанлы кеше иде.

Бу фикерне раслау өчен, халкыбызның батыр улы, гвардия полковнигы Бари Юсуповның миңа язган хатыннан бер өзек китерәм: «Гасимә апа! Сез, минем туган апам Нурылбанат белән Һади Атласов мәктәбендә укыган кызлар, барыгыз да укытучы булып халыкка файда китердегез, алар тарихка керми кала. Шул хакта киңәшеп эш итәргә иде...» Баринның бу теләген, инде хәзер васыятен (ул вафат булды) үтәү йөзеннән мин дә үземнең истәлекләрем белән уртаклашам.

Укытучы булып китүемә беренче мәхәббәт орлыкларын салучылар Әлмәт авылында яшәүче Һади ага Атласов һәм аның хатыны Хөсникамал апа булдылар.

Хәтерем ялгышмаса, 1913-14 елларда безнең күрше йортта рус теле укытучысы Кочемасова фамилияле бер апа яши иде. Мин аның идәннәрен, керләрен юам, ул мине укырга өйрәтә. Бу инде миңа эш хакы. Икенче көнне Сәрби абыстайга бер пүлән утын күтәреп барам да, анда без берничә кыз, көйләп-көйләп, сабак өйрәнәбез. Мине бу хәлләрдән коткаручы Һади ага һәм аның хатыны булды.

Һади ага үзләре торган йорт ишегалдындагы кечкенә дүрт почмаклы йортта кызлар мәктәбе ача. Без Әлмәт авылы кызлары Хәдичә Сабитова, Мөхтәрәмә Фәридова, Нурылбанат Юсупова һ. б. шунда укыйбыз. Мәктәптә Һади ага тарих, география укытты. Хөсникамал апа безне укырга-язарга өйрәтте. Уку әсбаплары юк, китаплар юк. Һади абый кечкенә кара такталар китерде. Шул тактага акбур белән язып укырга, язарга өйрәндек.

1917 елның җәе. Әлмәттә Һади Атласов җитәкчелегендә Бөгелмә контонындагы авылларда эшләү өчен укытучылар курсы ачалар. Курс ике айлык. Атласов мәктәбендә укыган кызлар, Бигәш, Нәдер, Мактама кебек авыллардан да яшьләр җыела.

Безне Һади Атласов, Гыйрфан Балтанов, Хөсникамал Атласовалар укытты. Курс беткәч, балалар укыту өчен, авылларга таралдык.

Мин 17 нче елда Мактама Башы исемле авылда, бер крестьян йортына авыл балаларын җыеп, үзем белгән кадәр белем бирдем. 1918 ел җәй Бөгелмәдә 2 айлык укытучыларның белемен күтәрү курсы ачыла. Курска азмы-күпме укытучылык профессиясе белгән яшьләр җыела. Аерым фәннәр, укыту методлары турында безгә шул ук Атласов, Балтанов, К. Туйкә, А. Әсәдуллин, Виноградов иптәшләр дәрес бирә. Курс тәмамлангач, бөтен курсантларны җыеп, поезд белән Сембер шәһәренә — В. И. Ленин торган, укыган йортны күрү, Идел ярлары, Жигули тауларын күрү өчен экскурсиягә җибәрделәр. Дөнья күрмәгән яшьләр өчен гадәттән тыш зур ачыш булды бу. Бөгелмә мәгариф бүлегенең мәктәпләр челтәрен җитәкләүче Гариф Рафиков безгә һәр күргән, күренгән әйберне

сөйләп аңлатып барды. Шатланып Бөгелмәгә кайттык. Бөгелмәдә безне укыткан укытучылар каршылады. Һади ага безнең эшебезгә уңышлар, мәктәпләрдә, халык арасында үзебезне ничек тотарга киңәшләр бирде.

Безгә белем биргән укытучыларыбызны хөрмәт белән искә алабыз. Аларның күбесе һәлак булды. Соңгы елларда матбугат битләрендә менә шушы исемнәре югалып барган хөрмәтле педагогларыбызны К. Туйкә, Ф. Туйкә, З. Тәрҗеманов иптәшләргә карата бик кыска гына язылган мәкаләләр күренде.

Һади Атласов турында язылган мәкалә күпләрне шатландырды. Журнал кулданкулга күчеп йөрде. Башка шәһәрләрдә яшәүче, яшьлегендә Атласов биргән дәресләрне тыңлаган иптәшләрдән дә журналны сорап хатлар килде. Мин «Казан утлары»н Мәскәүгә, Уфага, Ташкентка җибәрдем. Зур галим, нинә төрле тел белгән педагогның эзсез югалуы никадәр авыр булуын без — аның укучылары авыр кичердек. Хәзер мәкаләне уку безгә җиңеллек бирә.

**Гасимә МОСТАФИНА-РӘФИКОВА,**
Ленин ордены кавалеры, Татарстанның атказанган укытучысы.
Казан шәһәре.

* * *

Хөрмәтле иптәшләр!

«Казан утлары» журналын укып барам. Сезгә бер үтенечем бар иде. Минем улым Рөстәм җиде телдә укый-яза белә. Әмма татар китапларына, мәсәлдәгечә «төлке виноградка караган шикелле» кызыгып карый. Төрле сәбәпләр аркасында аңа туган телебезне өйрәнү мөмкин булмады. Казаннан ике ел элек үк татарча-русча сүзлек сорап язган идек. Җавап килмәде. Сезгә зур үтенечебез бар: искергән, теткәләнеп беткән булса да, бер сүзлек табып җибәрә алмассызмы?

**Роза ГӘЛЛӘМОВА.**
Уфа шәһәре.

**РЕДАКЦИЯДӘН:** Татарстан китап нәшриятында быел «Татарча-русча сүзлек» дөнья күрәчәк. Сүзлеккә түбәндәге адрес белән заказ бирергә мөмкин:

420057, ТАССР, г. Казань, ул. Октябрьская, 18.

Магазин «Книга — почтой».

## АВТОРЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА

Редакциягә бары тик машинкада басылган кулъязмаларның беренче нөсхәләре генә кабул ителә. Әсәрләр 210 × 297 мм лы форматтагы ак кәгазьгә ике интервал калдырып басылырга тиеш. Бер биттә иң күбе — 30 юл була. Кәгазь битендә сулдан — 25 мм, өстән — 20 мм, уң яктан — 10 мм, астан 25 мм чиста ара калдырыла.

Күләме ун биттән арткан кулъязмалар ике нөсхәдә җибәрелергә тиеш.

Әдәбият һәм культура тарихына караган мәкаләләрдә чыганак исемнәренең, алардан өземтәләрнең төгәл булуы, һәртөрле атамалар, инициалларның татарча дөрес язылышы зарур.

Барлык материалларның ахырында авторның тулы исем-фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, гаилә хәле турында мәгълүматлар һәм почта индексы белән тулы адресы күрсәтелә.

# ЭШЧЕМЕ, ГАЛИММЕ?

Ерак җирдән килгән бер укымышлыны мин Казанда ике иптәшем белән таныштырган идем. Һәркайсының өйләренә бардык, иркенләп әңгәмә корып утырдык. Озакламый кунагым туган ягына кайтып китте һәм миңа, кызыклы кешеләр белән таныштыруым өчен рәхмәт әйтеп, хат салды. Ул анда фән кандидатын түгел, слесарь иптәшемнең исемен атап: «Галим Хәмит Вәлиевкә зинһар сәламемне тапшыр. Белем иясе ул!» дип язган иде.

Гаҗәпләндем. Сәер ич: дипломлы фән кандидатын түгел, урта мәктәпнең кичкесен генә тәмамлаган эшчене алга чыгарсын әле! Дөрес, Хәмит әйбәт егет. Слесарьлыгы өстенә буяучы һөнәрен дә үзләштерде. Һәвәскәр фотограф, бакчачы, шахматчы. Гаилә җанлы, ике матур кыз үстерде. Болар бар да дөрес. Әмма мондый кешеләр әземени илдә?

Хәер, ул телгә дә оста ич әле. Юк, күп сөйләнә торган кеше түгел, сүз байлыгы мул, дип кенә әйтүем. Сөйләсә, мәгънәле итеп сөйли инде ул. Белеп, иптәшләренә нинди дә булса яңалык ачып. Балның шифасы турындамы, аквариум балыкларының үрчүе хакындамы, Ибн Халдун фәлсәфәсе яки берәр техник ачыш тарихын таныштырыпмы — кызыклы һәм файдалы итеп. Уйлап карасаң, бу кадәр мәгълүматны урта мәктәптә көндез укыган, хәтта анда укыткан кешеләр дә белеп бетерми ләбаса!

Бик яшьли ата-анасыз кала ул. Казанга килеп һөнәр училищесын бетерә дә Авиация берләшмәсе цехына килеп керә. Утыз елдан артык бер урында, бер үк эштә. Роботка әйләнерлек, билләһи. Ә гез сөйләшеп карагыз Хәмит белән!

— Шәхси китапханәмә Г. Тукайның «Шигырьләр»е мая булды,— ди Хәмит.— Туганнан туган абыем бүләк иткән иде. Кат-кат укыдым, ятлап бетердем мин аны. Шуннан соң бүтән шигырь китапларына да юл ачтым. Яхшы китап якын сердәш, дус кебек икән ул, аннан аерыласы килми. Шуңа күрә мин бер заман үземә ошаган әсәрләрне сатып алырга, җыярга тотындым. «Казан утлары»на язылгач, шәхси китапханәм журналлар исәбенә дә ишәя башлады. Шигырьдән хикәя, повесть, романнарга, аннары — фәнни-популяр хезмәтләргә күчтем. Татарчадан — бүтән телләргә. Хәзер мин кая барсам да, әүвәл китап кибетенә йөгерәм. Былтыр Анапада Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына тап булдым. Бөтен ялыма ямь өстәде бу китап, рәхәтләндем укып. Ата-бабаларым рухы белән сугарылгандай, Татарстаным кочагында иркәләнгәндәй булдым.

Хәмит Вәлиевнең шәхси китапханәсендә берсеннән-берсе кызыклырак китаплар тезелеп тора: Андерсен, Стендаль, Эренбург томнары, Ә. Кәримуллин, М. Госманов, О. Сөләйманов, В. Бартольд тикшеренүләре, сәнгать альбомнары, тарихи хезмәтләр, энциклопедик белешмәләр һәм, әлбәттә, татар әдәбиятының барлык җәүһәрләре.

— Элек сукыр булганмын икән,— ди Хәмит.— Шул кадәр кызык дөньяның барлыгын искәрмәгәнмен. Без бала чакта «Кем ул? Нәрсә ул?» китабы кебек матур бизәлгән бай эчтәлекле белешмәләр туган телебездә басылмый иде. Хәзер шуны сатып ал...п шатландым, оныкларыма ярап куяр. Гаҗәп бит: яңа китап укыган саен күпме каһарман якын дустыңа әйләнә, ерак илләр якыная, күңел офыклары киңәя бара. Хәзер мин «Үткәннең фикер ияләре» сериясен җыя башладым әле. Ибн Рөшди, Гегель, Берон, Эл-Бируни...— бөек галимнәр турында. Бу китаплар кешенең ничек үсүен, аның сәләте ничек ачылуын сурәтли, гомер итәргә үрнәк бирәләр. «Фән һәм техника иҗатчылары» сериясе дә бай эчтәлекле. Шулай да иң яраткан китабым — Н. Исәнбәт чыгарган «Татар халык мәкальләре». Андагы фикер байлыгы, чичәнлек! Аннары «Кабуснамә». Әллә кайчан язылган әсәр ул, ләкин бер дә искермәгән, әле бүген дә киңәшче була ала. Гомумән, китап кибетенә керми торган кешеләрне мин караңгы базда гомер итүчеләр саныйм. Китапны бернинди телевизор, радио, кинофильм алыштыра алмый. Бүләккә китап сайлаудан да мәгънәлерәк эш юк кебек...

Китаплар, китаплар. Татарча, казакъча, үзбәкчә, русча... Аерым шүрлектә — автографлы басмалар. Үз әсәрләрен, җыентыкларын Х. Туфан, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Н. Фәттах, М. Мәһдиев кебек күренекле язучылар матур теләкләр тели-тели бүләк иткән. «Синдә әдәбият турында бик яхшы сөйләгәнең өчен рәхмәт!» дип язган Г. Ахунов. «Синдәй кешеләр дөньяда яшәгәндә сәнгать уты сүнмәс», дип сокланган Ф. Шәфигуллин. «Хәмит дуска, әйбәт якташка, яхшы күңелле кешегә, яратып», дип имзасын салган Т. Миңнуллин.

Хәмит бу китапларны аеруча кадерләп саклый. Ләкин бикләп тотмый, дусларына, күршеләренә дә укыта. Һәркайсының берәр мавыктыргыч, кызыктыргыч ягын әйтеп тәкъдим итә. Йөзләгән томның. Чынлап та, эшче Хәмит кенә түгел, галим Хәмит ул!

**Т. РАМАЗАНОВ.**

## СЕЗНЕҢ ӨЧЕН, ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕЛӘР!

*Татарстан китап нәшрияты киләсе елда 354 исемдә китап, брошюра, альбом һәм башка төр басмалар нәшер итүне планлаштырды. Ул басмалар нәшриятның (1988 елга аннотацияле тематик планында шактый тулы чагылды. Әлеге тематик план белән Таткниготорг һәм Татпотребсоюз карамагындагы китап кибетләренең сәүдә залларында танышып була.*

*Түбәндә без 1988 елда дөнья күрәчәк кайбер басмаларның исемлеген тәкъдим итәбез.*

### 1. ПРОЗА ҺӘМ ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Фәтхи Бурнаш. Яшь йөрәкләр. *Пьесалар.*
Ибраһим Гази. Әсәрләр. *3 томда. II, III томнар.*
Мирсәй Әмир. Әсәрләр. *3 томда. III том.*
Нәкый Исәнбәт. Әсәрләр. *4 томда. I, II томнар.*
Фатих Хөсни. Без яшь идек... *Повестьлар*
Риза Ишморат. Дусларым, осталарым. *Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Камал, М. Җәлил, Һ. Такташ, Ә. Фәйзи, К. Тинчурин хакында истәлекләр.*
Батулла. Кичер мине, энкәй. *Пьесалар.*
Рафаэль Мостафин. Җәлилчеләр. *Документаль очерклар.*
Нәби Дәүли. Кояшка таба. *Повесть.*
Марсель Зарипов. Югары траектория. *Очерклар.*
Туфан Миңнуллин. Өмет. *Хикәяләр, повесть.*
Җәмит Рәхимов. Кыядагы чәчәкләр. *Роман.*
Мөхәммәт Мәһдиев. Фронтовиклар. *Роман.*
Ринат Мөхәммәдиев. Чияләнгән төен. *Повесть, хикәяләр.*
Аяз Гыйләҗев. Дус кызым кияүгә чыга. *Пьесалар.*
Әхәт Гаффар. Сызылып таңнар атканда. *Повестьлар.*
Марсель Галиев. Алтын тотка. *Повестьлар, хикәяләр.*
Якуб Зәнкиев. Иртеш таңнары. *Роман.*
Фаил Шәфигуллин. Кешелек тавы. *Юмористик һәм сатирик хикәяләр, юморескалар, фельетоннар.*
Ибраһим Нуруллин. Фатих Әмирхан. *Документаль повесть.*
Мәгъсүм Хуҗин. Урак өсте болытлары. *Повесть.*
Зәки Зәйнуллин. Үрләр аша. *Повесть.*

### 2. ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘР

Габделҗаббар Кандалый. Шигырьләр һәм поэмалар.
Габдулла Тукай. Шигырьләр, поэмалар. *Сувенир басма.*
Өмет йолдызлары. *XIX гасыр ахырында һәм XX гасырның башында иҗат иткән татар шагыйрьләренең күмәк җыентыгы.*
Роберт Әхмәтҗанов. Орчык җыры. *Шигырьләр.*
Рәшит Әхмәтҗанов. Йөрәк бәйрәме. *Шигырьләр.*
Кадыйр Сибгатуллин. Инану. *Шигырьләр.*

Мөнир Мазунов. Офыклар. *Шигырьләр, поэмалар, җырлар.*
Фәннур Сафин. Чәчәк гомере. *Шигырьләр, поэмалар.*
Зиннур Мансуров. Ваем. *Шигырьләр.*
Нурия Измайлова. Минем җәй. *Шигырьләр.*

## 3. ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ҺӘМ КУЛЬТУРА ТАРИХЫНА КАРАГАН КИТАПЛАР

Азат Әхмәдуллин. Фәтхи Бурнаш. *Монография.*
Тәлгат Галиуллин. Илһам чишмәләре.
Нур Гыйззәтуллин. Әдәбият һәм тормыш.
Мансур Вәлиев. Учагың сүнмәсен.
Салих Маннапов. Тамыр тирәнлеген яфрак тоя.
Татар әдәбияты тарихы. *6 томда. V том.*

## 4. БАЛАЛАР ӨЧЕН ӘСӘРЛӘР

Һади Такташ. Караборынның дусты. *Хикәя.*
Абдулла Алиш. Әкиятләр һәм хикәяләр.
Дәрҗия Аппакова. Кечкенә Бануның тарихы. *Повестьлар.*
Нәҗип Мадьяров. Салават күпере. *Шигырьләр.*
Нур Гайсин. Минем туганнарым. *Шигырьләр.*
Роберт Миңнуллин. Безнең авыл зоопаркы. *Шигырьләр.*
Фуад Садриев. Ике икең ундүрт. *Хикәяләр һәм әкиятләр.*
Самат Шакир. Кыңгырау чәчәкләр. *Шигырьләр.*
Хәниф Хөснуллин. Чикерткә ник сикерә? *Нәниләр өчен шигырьләр.*
Ренат Харис. Матур өй. *Шигъри әсәр.*
Флүс Латыйпов. Карагай. *Хикәяләр, повестьлар.*
Идел. Әдәби *альманах.*

## 5. ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Тарихи һәм лирик җырлар. *«Халык авыз иҗаты» күптомлыгының соңгы китабы.*

*Киләсе елда дөнья күрәсе басмаларга алдан заказ биреп кую өчен, китап кибетләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Республикабыздан читтә яшәүчеләр үзләрен кызыксындырган китапларны «Китап-почта» кибетләре аша алдыра алалар.*

*Биредә 1988 елда нәшрият бастырып чыгарачак барлык китапларны да тәкъдим итү мөмкин түгел, әлбәттә. Шуңа күрә без матур әдәбият сөючеләргә китапханәләргә барып, китап кибетләренә кереп, Татарстан китап нәшриятының 1988 елга тематик планы белән якыннанрак танышырга киңәш итәбез.*

Әхмәт **СӘХӘПОВ**,
Татарстан китап нәшрияты редакторы

# Хөрмәтле укучыларыбыз!

Татарстан китап нәшрияты рус телендә басып чыгарган түбәндәге китаплар сатуда бар:

**Алишев С. Х.** По следам минувшего (Үткәннәр эзеннән). Тарихи тикшеренү. 128 бит. Б. 20 т.

**Амир М.** Агидель (Агыйдел). Повестьлар. 384 бит. Б. 1 с. 50 т.

**Арсланов М.** Хусаин Уразиков (Хөсәен Уразиков). Тормыш юлы һәм иҗат юлы очерклары. 168 бит. Б. 40 т.

**Ахмадуллин А.** Горизонты татарской драмы (Татар драмасы офыклары). Тикшеренү. 216 бит. Б. 55 т.

**Бикчурин Ш.** Твердая порода (Каты токым). Роман. 240 бит. Б. 1 с.

**Гилязев А.** При свете зарниц (Аҗаган нур яктысында). Повестьлар. 544 бит. Б. 2 с.

**Еники А.** Повести и рассказы (Повестьлар һәм хикәяләр). 256 бит. Б. 1 с.

**Забиров И.** Джалиль и джалильцы (Җәлил һәм җәлилчеләр). Очерклар. 144 бит. Б. 35 т.

**Илялова И.** Театр имени Г. Камала (Г. Камал исемендәге театр). Тикшеренү. 328 бит. Б. 1 с. 50 т.

**Камал Ш.** Избранные (Сайланма әсәрләр). 2 том. Романнар. 440 бит. Б. 2 с. 30 т.

**Камал Ш.** Когда рождается прекрасное (Матур туганда). Роман. 351 бит. Б. 1 с. 60 т.

**Каримуллин А.** Книги и люди (Кешеләр һәм китаплар). Очерклар. 304 бит. Б. 1 с. 30 т.

**Каримуллин А.** Татарская книга пореформенной России (Реформадан соңгы Россиянең татар китаплары). Тикшеренү. 320 бит. Б. 1 с. 20 т.

**Магдеев М.** Фронтовики (Фронтовиклар). Роман. 304 бит. Б. 1 с. 20 т.

**Маликов Э.** Сквозь годы (Еллар аша). Шигырьләр һәм поэмалар. 128 бит. Б. 55 т.

**Мингалим Р.** Растут мальчики (Малайлар үсә). Шигырьләр. 72 бит. Б. 15 т.

**Мустафин Р.** Муса Джалиль (Муса Җәлил). Тормышы һәм иҗаты. Тикшеренү. 384 бит. Б. 90 т.

**Мухаммадиев Р.** Проблемы формирования татарской литературной критики (Татар әдәбияты тәнкыйте формалашу мәсьәләләре). Тикшеренү. 144 бит. Б. 35 т.

**Наджми К.** Весенние ветры (Язгы җилләр). Роман. 432 бит. Б. 2 с.

**Нафигов Р.** Тукай и его окружение (Тукай һәм аның тирәлеге). Тикшеренү. 208 бит. Б. 55 т.

**Нигмедзянов М.** Композиторы и музыковеды Советского Татарстана (Совет Татарстаны композиторлары һәм музыка белгечләре). Тормыш һәм иҗат юллары турында белешмәлек. 208 бит. Б. 1 с. 20 т.

**Расих А.** Лунные ночи (Айлы төннәр). Роман. 176 бит. Б. 90 т.

**Сабитов Г.** Айбаш. Балалар өчен хикәя. 12 бит. Б. 10 т.

**Садрижиганов Дж.** Воспоминания (Хатирәләр). Татар музыка сәнгате сәхифәләре. 152 бит. Б. 45 т.

**Сафиуллин Г. Б.** Дорогами победы (Җиңү юллары буйлап). Генерал язмалары. 352 бит. Б. 85 т.

**Сафиуллина Ф., Галиуллин К.** Русско-татарский разговорник (Русча-татарча сөйләмлек). 304 бит. Б. 80 т.

Слово о Тукае (Тукай турында сүз). Мәкаләләр. 432 бит. Б. 90 т.

**Тагиров Г.** Татарские танцы (Татар биюләре). Рәсемнәр белән биюләр өйрәткеч. 256 бит. Б. 1 с. 80 т.

**Гарджеманов Дж.** Юность Лобачевского (Лобачевскийның яшьлеге). Роман. 334 бит. Б. 1 с. 35 т.

**Тукай Г.** Стихи, поэмы и сказки (Шигырьләр, поэмалар һәм әкиятләр). 416 бит. Б. 1 с. 10 т.

**Тукай Г.** Водяная (Су анасы). Әкият. Балалар өчен рәсемле китап. 14 бит. Б. 20 т.

**Фахрутдинов Р. Г.** Мелодия камней (Ташлар моңы). Татар халкының урта гасырлардагы тарихы очерклары. 224 бит. Б. 55 т.

**Халикова Х.** Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X — начала XIII в. (X—XIII гасыр башы Идел Болгарстанының мөселман каберлекләре). Тикшеренү. 160 бит. Б. 1 с. 50 т.

**Хасанов Х.** Казань в годы первого штурма царизма (Царизмны беренче штурмлау елларында Казан). Очерк. 192 бит. Б. 55 т.

**Червонная С. М.** Художники Советской Татарии (Совет Татарстаны сурәтчеләре). Белешмәлек, фотолар белән. 464 бит. Б. 2 с. 20 т.

*Якындагы кибетләрдә табылмаса, соратып алдыру өчен адреслар: 420057 г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой». 420084. г. Казань, ул. Баумана, 19. Книжный магазин № 1. Отдел «Книга — почтой».*

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР! Июнь-июль айларында китап кибетләренә Татарстан китап нәшриятының 1988 ел тематик планы киләчәк. Анда басылачак һәр китапның кыскача эчтәлеге языла, якынча күләме һәм бәясе күрсәтелә. Темплан белән вакытында танышырга һәм кирәкле басмаларга алдан ук заказ бирергә тырышыгыз. Бары шул очракта гына теләгегез тулысынча үтәлүе мөмкин!

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

27 июльдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе, очерк һәм публицистика секциясе урак өстендә республикабыз районнарында эшләячәк «Урак-87» язучылар бригадасы членнарының киңәшмәсен уздырды.

Игенчеләр янына иҗади командировкага китәчәк язучылар алдында торган бурычлар турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин, секция житәкчесе Марсель Зарипов сөйләде. Фикер алышуларда Р. Харис, Р. Фәйзуллин, К. Тимбикова һ. б. катнашты.

Киңәшмәдә ТАССР Агропромы председателе урынбасары, министр М. Ә. Сираев катнашты һәм язучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде.

### ИГЕНЧЕЛӘР ЯНЫНДА

Август аенда күп кенә язучылар республикабыз районнарына иҗат командировкасында булып, игенчеләр белән очраштылар, колхоз һәм совхозларда барган киеренке хезмәт көннәрендә үз иҗат көчләре белән быелгы уңышны җыеп алуга өлеш керттеләр.

Барлас Камалов — Чүпрәле районында, Рафаэль Мостафин — Баулы, Ринат Мөхәммәдиев — Мамадыш, Равил Фәйзуллин — Балык Бистәсе, Флера Гыйззәтуллина, Рафкать Кәрами, Нияз Акмалов Аксубай районнарында хезмәт коллективларының эшләре белән танышып, әдәбият сөючеләр белән иҗади очрашулар уздырдылар.

### ДУСЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

4 августта Татарстан Композиторлар союзында Казанга гастрольгә килгән Алма-Ата Уйгур музыкаль комедия театры артистлары белән дусларча иҗади очрашу булып узды.

Очрашуда республикабызның күренекле композиторлары, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера-балет театры артистлары һәм музыка белгечләре катнашты. Ике халыкның әдәбият-сәнгать багланышлары турында жылы сөйләшү булды, татар композиторлары әсәрләре, уйгур һәм татар халык җырлары башкарылды.

### КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

24 июльдә Мәскәүдә РСФСРның атказанган, Татарстанның халык художнигы Васил Маликов әсәрләреннән күргәзмә ачылды. Күргәзмәгә аның йөзгә якын әсәре куелган. Күргәзмәне меңнәрчә мәскәүлеләр һәм кунаклар карады.

Август башында Әлмәттәге Картиналар галереясында СССР Художниклар союзы члены Мансур Саттаровның күргәзмәсе ачылды. Анда авторның җитмештән артык сынлы сәнгать әсәре белән танышырга мөмкин булды.

Мәскәүдә яшәүче М. Саттаров илебезнең әһәмиятле яңа төзелешләрендә еш була, төзүчеләр белән тыгыз элемтәдә торып иҗат итә. Алар арасында республикабызның танылган төзүчеләре — Социалистик Хезмәт Герое Р. Саттаров, А. Иваев, Н. Тюнин, СССР Дәүләт премиясе лауреатлары П. Силантьев, Н. Высоцкий һәм башкалар бар.

### ГАЛӘМДӘ — ҖӘЛИЛ ПЛАНЕТАСЫ

1972 елның 17 маенда СССР Фәннәр академиясенең Кырым астрофизика обсерваториясе астрономы Т. М. Смирнова кече планета ачты. Мәгълүм булганча, каталогта даими номер алган планетаны беренче булып ачкан кешенең күк җисеменә үзе теләгән исемне бирергә хакы бар. Гадәттә планета атамаларында заманыбызның мәшһүр кешеләре исемнәре, шулай ук ил тормышындагы истәлекле вакыйгалар мәңгеләштерелә. Астроном Смирнова Муса Җәлил шигырьләрен ярата, аның тормышын, иҗатын һәм батырлыгын яхшы белә. Шуңа күрә ул герой шагыйрь истәлеген мәңгеләштерергә карар итә. 1986 елның 26 мартында Кече планеталар үзәге (Смитсон астрофизика лабораториясе, АКШ) бу атаманы раслый. Кояш системасының шушы аерылгысыз кисәкчеге шул көннән башлап «3082. Җәлил кече планетасы» дип йөртелә. Галәмдәге һәйкәлнең Кояштан уртача ераклыгы 384 миллион километр. Аның Кояш тирәли әйләнеп чыгу арасы — дүрт ел да ике ай. Җәлил планетасының Җир белән чираттагы якынаюы 1987 елның 3 январенда, планета Игезәкләр йолдызлыгына кергәч булды.

Астероидка Җәлил исеме бирелү турындагы таныклык Кырым астрофизика обсерваториясендә саклана.

### МӘСКӘҮДӘ САБАН ТУЕ

12 июльдә Мәскәүнең Измайлово паркында халкыбызның милли бәйрәме — сабан туе булып узды.

Бәйрәмне отставкадагы генерал Рафкать Вәлиев һәм аның сугышчан дусты Николай Поздниев ачып җибәрделәр.

Бик күп милли уеннар, күп төрле ярышлар узганнан соң, сабан туенда катнашучыларның бөтен игътибары көрәшчеләргә төбәлде. Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Мордовия республикалары, Ульяновск, Пенза, Куйбышев, Саратов өлкәләреннән килгән көрәшчеләр көчләрне сынаштырдылар. Абсолют ба-

тырның исеме мәгълүм булды. Ул — шофер булып эшләүче Рәис Мөҗипов.

Сабан туе соңында «Хыял» ансамбле чыгышы башланып китә. Ансамбль артистлары Роза Хәбибуллина, Бәрхет Гәрәев, үзешчәннәр Зөлфия Садыйкова, Зөлфия Трепалина җырлавын һәркем яратып кабул итте.

### ЭНЦИКЛОПЕДИК СҮЗЛЕКТӘ

Мәскәүнең «Советская энциклопедия» нәшриятында 752 биттән торган бер томлык «Әдәби энциклопедик сүзлек» басылып чыкты. Томлыкның 434—435 битләрендә татар әдәбиятының үсеш тарихы яктыртылган, иҗатлары белән аерым чорларны характерлый алырлык язучылар саналган, аларның аерым хезмәтләре күрсәтелгән. Кол Гали, Котби, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Г. Кандалый, Акмулла, К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Х. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Г. Әпсәләмов, С. Хәким... Бүген дә актив иҗат итүче әдипләребездән Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, Ш. Галиев, И. Юзеевләрнең исемнәре, аларның төп әсәрләре исемлеге бирелгән.

### «ШУКТУГАН»НЫ 25 ТЕЛДӘ УКЫЙЛАР

Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» әкиятповестен Фрунзе шәһәрендәге «Мектеп» нәшрияты кыргыз телендә бастырып чыгарды. Бу — «Шуктуган»ның китап булып чыккан 25 нче басмасы.

### ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Хезмәт ияләренә музыкаль-эстетик тәрбия бирүдәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы Исламия Мәхмүтовага һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Нәҗибә Миннуллинага, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.


## Хөрмәтле укучыларыбыз!

СССР Язучылар союзы органы булган «ДРУЖБА НАРОДОВ» журналы илебездәге барлык әдәбият вәкилләренә киң урын бирә. Киләсе елда да журналда яңа әдәби әсәрләр, әдәбиятлар үсешенә, тәрҗемә мәсьәләләре һәм аерым язучылар иҗатына кагылышлы мәкаләләр дөнья күрәчәк.

«Дружба народов» журналының Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 70250, бер елга язылу бәясе 13 сум 20 тиен.

Башкортстан Язучылар союзы органы булган «АГЫЙДЕЛ» журналы Уфада башкорт телендә чыга. Журналда башкорт әдәбиятының иң күренекле әсәрләре, Башкортстан хезмәтчәннәренең эшләре һәм казанышлары турында очерклар, әдәби тәнкыйть һәм сәнгать материаллары даими басылып килә. «Агыйдел»нең Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73001, бер елга язылу хакы 7 сум 20 тиен.

# КӨМЕШЧЕЛӘР ИҖАТЫ

Балык Бистәсе авылы ювелирларының тирә-юньгә таралган даны турында безнең көннәргә килеп җиткән тарих ядкарьләре һәм истәлекләре ачык сөйли. Аларның берсендә, мәсәлән, сәнгатьнең чын бәһасен белгән кешеләрнең ниндидер оста ясаган йөзекне... дөягә алыштырып алулары турында сөйләнә. Бу риваять, хәзергечә әйткәндә, реклама вазифасын да үти: анда ювелирларның осталыгы, алар ясаган әйберләрнең затлы булуы пропагандалана. Ә Кама буе көмешчеләре (алар үзләрен шулай дип атаганнар) ясаган зиннәтләрнең Урта Азия һәм Себердә генә түгел, Германия, Англия, һәм хәтта Америкада да таралуы мәгълүм.

Татарлар, кыргызлар, казахлар, чувашлар, марилар өчен милли бизәнү әйберләре иҗат иткәндә Балык Бистәсе зәркәнчеләре металл эшкәртүнең Идел буенда Болгар заманыннан ук яшәп килгән традицияләренә таянганнар. Нәкъ менә шул болгар-татар мотивлары аларга кабатланмас төсмер биргән дә инде.

«Памятная книга Казанской губернии на 1863 год» дигән китапта Балык Бистәсе турында мондый мәгълүмат китерелә: «...монда беренче килеп утыручылар балыкчылар булганнар. Балыкны, мөгаен, Казан патшалары сараена җибәргәннәрдер». XVI гасырның азагында патша өстәленә балык җибәрүнең хаҗәте калмаганнан соң, авылда яшәүчеләр көмешчелек белән шөгыльләнә башлыйлар. Ювелир промыселы бирегә шактый озак — XX гасыр башларына кадәр яши, ә аеруча актив чоры үткән йөзнең икенче яртысына туры килә.

Зәркәнчеләр аерым заказлар үтәү белән шөгыльләнмәгәннәр диярлек, алар зиннәтле әйберләрне ярминкәләрдә тулаем сатуны, яисә арадашчы сәүдәгәрләргә тапшыруны өстен күргәннәр. Нигездә арзанрак металлар: бронза, бакыр, җиз, мельхиор һәм көмеш кулланылган. Бизәү өчен Бохара һәм Австриядән китерелә торган сердолик, төсле пыяла, фирәзә һәм мәрҗән файдаланылган. Төрле алкалар, балдак һәм йөзекләр, каптырма, төймә, чулпы, беләзек кебек әйберләр кою, чүкү, каралтып нәкышлау ысуллары белән ясалган. Металл чыбыкларны үреп эшләү һөнәрчеләрдән аеруча зур осталык таләп иткән.

Балык Бистәсендә 1909 елда сәнгать-һөнәр остаханәсе ачылу ювелирларның профессиональ осталыгы үсүгә яңа этәргеч ясый. Һөнәрчеләр бөтерчекләнгән зиннәтле эмаль каплау ысулын татар халык сәнгатендә беренчеләрдән булып үзләштерәләр, аны көнкүрештә кулланыла торган вак кирәк-яраклар: тоз савыты, шырпы савыты, сөлге бөҗралары һәм бизәү әйберләре ясауда файдалана башлыйлар. Модерн стилендә башкарылган һәм урта буржуа зәвыкына исәпләнгән бу әйберләр берникадәр вакытка шәрык мотивларын да каплап китә.

Халык сәнгате осталарының эшчәнлеге егерменче-утызынчы елларга кадәр кооператив башлангычында оешкан промыселларда дәвам итә.

Балык Бистәсе осталарының гүзәл хезмәте — аерым алганда, Татарстан сынлы сәнгать музеенда саклanучы зиннәтле әйберләре — аларның югары камиллеккә ирешкән осталыгы, бай иҗат фантазиясе турында сөйли.

**Людмила КОРОБЦОВА**,
Татарстан сынлы сәнгать музее
фәнни хезмәткәре.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда А. М. Горький һәйкәле.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)